КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ

Ә. Н. ХУҖИӘХМӘТОВ
Р. Р. НАСЫЙБУЛЛОВ

МӘГАРИФ ФӘЛСӘФӘСЕ ҺӘМ ТАРИХЫ

Югары һәм махсус уку йортлары өчен лекцияләр курсы

КАЗАН
2015

УДК 371
ББК 74.204
Х98

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителә.
Казан (Идел буе) федераль университетының психология һәм мәгариф институты гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә (беркетмә № 3, 26 март, 2015 ел).

Әлеге китап материалларын нәшрият рөхсәтеннән башка яңадан бастырып чыгару «Автор хокукы һәм эргәдәш хокуклар турында» Россия Федерациясе Законын бозу була. Моның өчен закон нигезендә җавапка тарту каралган.

Рецензентлары:
педагогика фәннәре кандидаты,
Казан федераль университеты доценты ***Р. Г. Габдрахманова***;
педагогика фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының баш белгече ***С. П. Федоров***;
педагогика фәннәре докторы, Сургут дәүләт университеты профессоры ***Р. Х. Шәймәрданов***.

Хуҗиәхмәтов Ә. Н.
Х98 Мәгариф фәлсәфәсе һәм тарихы: югары һәм махсус урта уку йортлары өчен лекцияләр курсы / Ә. Н. Хуҗиәхмәтов, Р. Р. Насыйбуллов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2015. – 372 б.

ISBN 978-5-00019-394-5

Россиянең һәм Татарстанның атказанган укытучысы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, академик, педагогика фәннәре докторы, профессор, педагогика кафедрасы мөдире Ә. Н. Хуҗиәхмәтов, педагогика фәннәре кандидаты, доцент Р. Р. Насыйбуллов тәкъдим итә торган бу китапта кешелек җәмгыяте үсешендә педагогиканың барлыкка килүе һәм үсеше, күренекле мәгърифәтчеләрнең һәм педагогларның тәгълиматы бәян ителә, педагогика фәненең үсеше фәлсәфи анализлана. Югары һәм махсус урта уку йортлары аспирантлары һәм студентлары, халык мәгарифен оештыручылар, укытучылар, тәрбиячеләр өчен нәшер ителә.

УДК 371
ББК 74.204

ISBN 978-5-00019-394-5

© Хуҗиәхмәтов Ә. Н., Насыйбуллов Р. Р., 2015
© Казан университеты нәшрияты, 2015

К Е Р Е Ш

Педагогика — кешегә тәрбия бирү турындагы фән ул. Педагогика "*педагогос"* — *"балалар җитәкчесе"* дигән сүздән алынган. Борынгы Грециядә балаларны мәктәпкә алып бару, алып кайту һәм аларны карау эше тапшырылган кешеләрне *педагоглар* дип атаганнар. Соңыннан тәрбиячеләрне һәм укытучыларны педагог дип атый башлаганнар. Аларның эше *педагогик эшчәнлек* дип атала башлаган.

Педагогика — тәрбия бирүнең максатлары һәм бурычлары, эчтәлеге, алымнары һәм аны оештыру турындагы тәгълимат ул. Икенче төрле әйткәндә, үсеп килүче яшь буынны нинди эшләр башкарырга әзерләргә, аларда нинди сыйфатлар булдырырга, аларны нәрсәгә һәм ничек өйрәтергә, ничек тәрбияләргә дигән сорауларга педагогика җавап бирә.

Педагогиканың предметы, җәмгыятьнең махсус функциясе буларак, — кеше тәрбияләү. Башкача әйткәндә, педагогиканың предметы булып тәрбия эшчәнлеге тора.

Кешелек җәмгыяте үсеше тарихында үсеп килә торган яшь буынны тәрбияләүгә һәркайчан зур игътибар бирелеп килгән. Кешелек җәмгыяте әле иҗтимагый сыйныфларга бүленмәгән, кеше өстеннән хакимлек итү булмаган чакта, өлкәннәр үз тәҗрибәләрен яшь буынга турыдан-туры эш процессында тапшыра торган булганнар. Ул чор тәрбиясендә аңлылыкка караганда стихиялелек күбрәк булган. Ләкин борынгы җәмгыятьтә үк инде, алга барган саен, тәрбия эше максатка юнәлтелгәнрәк була барган.

Иҗтимагый сыйныфлар килеп чыккач һәм алар арасында көрәш җәелеп киткәч, хаким сыйныфлар тәрбия эшен хезмәт ияләрен изү чараларыннан берсе итеп файдаланганнар. Шуның белән бергә, үсеп килә торган яшь буынны тәрбияләү тәҗрибәсе акрынлап туплана барган, махсус тәрбия йортлары барлыкка килгән, тәрбия һәм укыту эше белән махсус шөгыльләнүче кешеләр килеп чыкканнар, булган тәҗрибәнең мәгънәсенә төшенү, аны гомумиләштерү зарурлыгы туган. Шулай итеп, кешелек җәмгыяте ихтыяҗларыннан мәктәп барлыкка килә, ә аннары үсеп килә торган яшь буынны тәрбияләү һәм аңа белем бирү турындагы фән — педагогика килеп чыга. Педагогика тәрбия бирүнең максатлары һәм бурычлары турындагы, аның эчтәлеге, методлары һәм оештырылуы турындагы тәгълиматны эченә ала. Икенче төрле итеп әйткәндә, педагогика: үсеп килә

торган яшь буынны нинди максатларга хәзерләргә, нәрсәгә һәм ничек өйрәтергә, аларда нинди сыйфатлар тәрбияләргә, дигән сорауларга җавап бирә.

Педагогиканы өйрәнү нигә кирәк? Аны белмичә дә балаларына яхшы тәрбия биргән кешеләр азмыни? Икенче яктан караганда, педагогиканы яхшы белүчеләрнең хәтта үз балаларына да начар тәрбия бирү очраклары юкмыни? Беренчеләре, педагогиканы белгән булсалар, балаларын тагын да яхшырак тәрбияләгән булырлар иде. Ә икенчеләренең балаларын начар тәрбияләве аларга бу эштә педагогика ярдәм итә алмаганлыктан түгел, бәлки аларның үз белемнәрен практикада кулланмауларыннан килә. Педагогиканы теоретик яктан да, практик яктан да өйрәнергә кирәк, ягъни тәрбия бирү юнәлешенә һәм тәрбия чаралары системасына яхшы төшенергә генә түгел, бәлки бу белемнәрне эштә куллана белергә дә, балаларга дөрес һәм уңышлы тәрбия бирә белергә дә өйрәнү кирәк. Педагогика фәнен белү нигезендә тәрбияләү сәнгатен, ягъни педагогика эше осталыгын үзләштерә барырга кирәк.

Мәгълүм ки, хәтта бик талантлы кеше дә белем һәм осталыкларын камилләштерү өстендә күп эшләгәндә генә гүзәл нәтиҗәләргә ирешә. Педагогик белем һәм осталыклар педагогия хезмәтен камилләштерә. Алар ялгышлардан саклап кала. Тәрбиячеләрнең педагогик белемнәре булмауның балаларга никадәр зарар китерүе сер түгел бит.

Тәрбия өлкәсендәге ялгышларны төзәтү бик кыен була. Алар балаларның әхлакый яки физик яктан гарипләнүләренә китерә. Педагогик белемнәре булмаган тәрбиячеләр, кайчакта, ихтыярсыздан, балалардагы кимчелекләрнең артуына сәбәпче булалар, аларның уңышларын һәм талантларын томалап калдыралар, аларга үсәргә ирек бирмиләр.

Олуг фикер ияләренең бик күбесе тикмәгә генә педагогиканы гомуми белем фәне дип санамый, чөнки тормышта бөтен кеше тегеяки бу күләмдә бала тәрбияләү белән шөгыльләнә.

Педагогик эшчәнлекне һөнәр итеп сайлаган кешегә педагогиканы белү бигрәк тә кирәк. Педагогик белемнәре булмаган кеше мәктәпкә килсә, эшкә ничек керешеп китәргә дә белмәячәк. Эше нәтиҗәле булсын өчен, аңа тәрбиянең максатын һәм бурычларын ачык белү зарур. Бары шунда гына аның эшендә тиешле дәрәҗәдә максатка омтылучанлык туачак. Сезнең игътибарга тәкъдим ителә торган лекцияләр курсы да нәкъ менә шуңа хезмәт итәр дип уйлыйбыз.

* * *

Беренче лекция

ПЕДАГОГИКАНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ ҮСЕШЕ

Тәрбия эше кешелек җәмгыяте барлыкка килгәннән бирле яши. Тәрбия балаларның бер-берсенә һәм олыларга мөнәсәбәтләренә, аларның уен-хәрәкәтләренә, хезмәткә, тулаем бөтен җәмгыять карашларына юнәлеш биреп килгән. Тәрбия — иҗтимагый күренеш. Ләкин гомуми җәмгыять юк, ягъни борынгы җәмгыять, колбиләүчелек җәмгыяте, феодаль җәмгыять булган, шунлыктан гомуми тәрбия дә юк. Хаким сыйныфлар тәрбия аша үз сәясәтләрен, үсеп килә торган яшь буынга үз йогынтыларын үткәрәләр.

Бер иҗтимагый стройны икенчесе белән алыштыру революцион юл белән эшләнә һәм строй үзгәрү белән бергә, тәрбия бирүнең эчтәлеге, аны оештыру формалары һәм методлары да үзгәрә. Тәрбия бирүнең практикасы да, теориясе дә тигез һәм эзлекле үзгәрми, бәлки иҗтимагый, сыйнфый көрәштә үзгәрә. Димәк, педагогика — тарихи фән ул.

Борынгы җәмгыятьтә сыйныфлар булмаган. Балалар бертөрле тәрбия алганнар, һәм бу тәрбия турыдан-туры хезмәт процессында, шулай ук балаларның уеннарында тормышка ашырыла торган булган. Ләкин, хезмәтнең җенескә карап бүленүе сәбәпле, ир һәм кыз балаларны тәрбияләүдә берникадәр аерма булган. Мәсәлән, ир балалар — аучылыкка, кызлар торак тирәсендәге эш төрләренә өйрәтелгәннәр. Ләкин борынгы җәмгыятьтә үк инде, гәрчә махсус тәрбия бирү йортлары булмаса да, өлкәннәрнең тәҗрибәсен махсус рәвештә яшь буынга тапшыру белән шөгыльләнүче кешеләр килеп чыккан. Җәмгыять тәрбия эшен контрольдә тоткан, аны оештырган һәм аңа тиешле юнәлеш биргән. Димәк, ул чорда ук инде тәрбия эше саф стихияле процесс кына булмаган.

Җәмгыятьне сыйныфларга бүлү килеп чыккач, бай балаларын тәрбияләү ярлы балаларын тәрбияләүдән кискен аерыла. Мәсәлән, борынгы колбиләүчелек дәүләте Спартада бары тик хаким сыйныф балалары гына дәүләт исәбенә тәрбияләнгәннәр. Спарталылар хакимлек иткәннәр, җир хуҗалары һәм колбиләүчеләр булганнар. 9000 спарталы гаиләсе коллыкка төшерелгән 250000 илот һәм

периэк гаиләсен изгән. Мондый хәл бары тик хәрби көч куллану аркасында гына була алган.

Спарталылар үз балаларын хәрби хакимлеккә әзерләгәннәр. Шуңа күрә аларда төп укыту предметы гимнастика һәм хәрби эш булган. Балаларда үз дәүләтенә ихлас бирелгәнлек, сугышчанлык, батырлык, тәртип, көч, җитезлек, чыдамлык, тыйнаклык, колларга җирәнеп карау һ. б. ш. сыйфатлар үстерергә омтылганнар.

Егетләрне хәрби лагерьга җибәргәннәр, алар анда чыныгу алганнар. Физик тәрбиягә зур игътибар биргәннәр. Шулай ук музыкага, җыр һәм биюгә өйрәнгәннәр. Бу дәресләр, һәм гомумән тәрбия, хәрби рухта булган.

Олы кешеләргә һәм идарәчеләргә һичсүзсез буйсыну, колларга, физик хезмәткә җирәнеп карау — Спартада хакимлек иткән изүче сыйныфларның балалары әнә шул рухта тәрбияләнгәннәр. Колларның һәм "ирекле" дип йөртелгән гади халыкның балалары мәктәпләрдә яки башка төрле уку йортларында бернинди дә тәрбия һәм белем алмаганнар. Алар, һөнәрчеләр гаиләләрендә һәм турыдан-туры җир хуҗаларында эшләп, физик хезмәткә өйрәнгәннәр, хуҗаларына буйсынучанлык рухында тәрбияләнгәннәр.

Безнең эрага кадәр VII – V гасырларда Афинада Спартага караганда башкачарак икътисади шартлар булган. Биредә сәүдә шактый үскән. Идарәчеләр белән халык арасында власть өчен көрәш барган. Гәрчә биредә дә хуҗалык колбиләүчелек хуҗалыгы булып, аз санлы "гражданнар" йөз меңнәрчә коллар өстеннән хакимлек итсәләр дә, шулай да Афинада балаларга тәрбия бирү инде гимнастика, хәрби эш һәм хәрби музыка белән генә чикләнә алмаган. Афинадагы колбиләүчеләр үз балаларының белем алулары киң күләмдә сәүдә итү һәм сәяси тормышта актив катнашу өчен кирәкле сыйфатларга ия булулары белән кызыксынганнар.

Ул заманда Афина халкының шактый зур катлаулары сәяси көрәшкә тартылган. Афина урамнарына һәм мәйданнарына җыелган халыкка хәрби көч белән генә түгел, бәлки оратор сүзе белән дә йогынты ясау кирәк булган. Шунлыктан Афинада хәрби сәнгать белән беррәттән ораторлык сәнгатенә дә бик югары бәя бирелгән. Бай ата-аналарның уллары 7 яшьтән 17 яшькә кадәр түләүле хосусый мәктәпләргә йөргәннәр. Анда алар үзләрен яхшы тоту кагыйдәләренә, дөрес язарга, санарга, әдәби сүз сөйләргә, шулай ук җыр, поэзия һәм гимнастикага өйрәнгәннәр. Афинаның җир һәм сәүдә эшлеклеләре улларына физик һәм хәрби тәрбия биргәннәр, яшьләр

сәяси һәм фәлсәфи әңгәмәләр алып барганнар, сөйләм осталыгына ия булганнар. Аеруча бай балалары бу сәнгатькә аерым "софист" укытучылардан бик күп акча түләп өйрәнгәннәр. Грек философы Платон әйтүенчә, Афина яшьләре шулардан белем алганнар, игенчеләр һәм һөнәрчеләр белән идарә итәргә өйрәнгәннәр.

Хезмәт ияләренең балаларына килгәндә исә, алар мәктәптә укымаганнар. Көндәлек эш тәҗрибәсе аша һөнәрчелеккә өйрәнгәннәр, хезмәт тәрбиясе алганнар. Кол балаларын мәктәпкә алмаганнар.

Шулай итеп, антик колбиләүчелек җәмгыятендә колбиләүчеләр сыйныфы тарафыннан юнәлеш бирелә торган тәрбия бу сыйныфның хакимлеген ныгытуга һәм изелүчеләр сыйныфын буйсындыруга юнәлдерелгән булган.

Хаким сыйныф балалары заманына күрә киң белем алганнар. Ә кол балалары фәннәрдән һәм сәнгатьтән бөтенләй читтә кала килгәннәр.

Коллар революциясе колбиләүчелек җәмгыятен җимерде, аңа алмашка феодаль җәмгыять килде.

Төрле иҗтимагый төркемнәрнең таркаулыгы һәм үз эченә бикләнгәнлеге, чиркәү йогынтысының гаять дәрәҗәдә үсүе, аерым феодалларның үзара өзлексез көрәш алып барулары сәбәпле, тәрбия бирүнең максатлары антик җәмгыятьтәгегә караганда башкачарак куела. Башка феодалларга һәм крестьяннарга каршы көрәшү өчен рыцарьга сөнге, кылыч белән эш итәргә, атта йөрергә һ. б. ш. өйрәнергә кирәк була һәм аңарда шул сыйфатларны тәрбиялиләр дә. Рыцарьга бернинди дә диярлек фәнни белем кирәк булмаган. Шуңа күрә, кагыйдә буларак, дөньяви феодалларның бөтенесе дә диярлек укый-яза белмәгәннәр, фән яки физик хезмәт белән шөгыльләнүчеләргә җирәнеп караганнар.

Урта гасыр җәмгыяте тормышында бик зур роль уйнаган чиркәү һәм руханилар, хакимлекләрен һәм йогынтыларын ныгыту өчен, халыкка: "теге дөньядагы" тормыш хакына түзәргә кирәк, бары "теге дөнья" гына чын дөнья, дип аңлатырга тырышканнар. Чиркәүгә, феодалга буйсыну, хис-теләкләрен тыю, үз фикере булмау, сыкранмыйча авырлыкларга түзү – тәрбияләнүче алдына куела торган таләпләр әнә шулар булган. Дин бердәнбер хакыйкать чыганагы булып саналган. Ләкин дини хакыйкатьләр чынбарлыкны белүгә түгел, ә гайре табигый көчләргә, "алланың җир йөзендәге вәкиленең" абруена нигезләнгәннәр. Чиркәү алдында тулысынча,

сукырларча баш ию һәм һичсүзсез буйсыну, дөнья фәнен дошман күрү әнә шуннан килә. Фән дингә хезмәт иткән. Нинди генә булмасын, чын фәнни фикер каты җәзага дучар ителгән, күп кенә галимнәрнең башлары чиркәү җәлладлары тарафыннан киселгән.

Урта гасырларда крестьяннар үзләрен коллыкка төшергән дөньяви һәм рухани феодаллар тарафыннан бик каты изелгәннәр. Белем алу ягыннан бөтенләй караңгылыкта кала килгәннәр.

Феодаль җәмгыятьтә тәрбия эше катлаулана дияргә була. Дворяннарның үз эченә бикләнгән катлавын тәшкил итүче (анда дворянлык мирас буенча тапшырыла) дөньяви феодаллар чиркәү һәм монастырь мәктәпләрендә фән белән шөгыльләнүне түбән эш итеп санаганнар. Кайбер эре феодалларның сарайларында югары катлау балалары өчен үз мәктәпләре булгалаган. Соңыннан дворян балалары өчен өстенлекле мәктәпләр — ир балалар өчен хәрби һәм дөньяви уку йортлары, кызлар өчен махсус институтлар төзелгән. Бу уку йортларына бүтән катлау балалары алынмаган.

Руханилар аерым катлау тәшкил иткәннәр. Крестьяннар, һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр дә шулай ук үз эченә бикләнгән катлау группаларын тәшкил иткәннәр, бу группалардан чыгу аерата нык чикләнгән булган.

Урта гасырларда феодаль җәмгыятьтә чиркәү һәм монастырь мәктәпләре күп булган. Бу мәктәпләрдә бирелә торган белемнәр тормыш белән бәйләнмәгән, аларда әйберләрнең үзләрен өйрәнү белән түгел, бәлки һәртөрле ясалма билгеләмәләр, төшенчәләрне телдән өйрәнү белән генә шөгыльләнгәннәр. Шуның белән бергә аларда бөтен нәрсә тамгалар белән, дини мәгънәдә аңлатыла торган булган.

Яңа педагогикага нигез салучы, "Бөек дидактика"ның авторы *Ян Амос Коменскийның* бу "схоластик сафсата"га карашы менә нинди булган: "Бер елда төшенә алырдай нәрсәләр белән укучыларны биш, ун һәм аннан да күбрәк ел тоткарлаганнар. Аңга акрынлап кертә барырга мөмкин нәрсәләрне көчләп такканнар, укучыларның башына тукып, тыңгычлап керткәннәр. Үзең күреп һәм аермачык күз алдына китереп була торган нәрсәне, караңгы, буталчык итеп, нәкъ табышмаклар төсле чуалтып аңлатканнар... Укучыларның башларын күбесенчә чүп-чар сүзләр, мәгънәсез лыгырдаулар, фикер калдыклары, сөрем белән тутырганнар".

Шулай итеп, феодаль җәмгыятьтә дә тәрбия эше сыйнфый характерда булган. Бирелә белем бирү, нигездә чиркәү һәм руха-

нилар кулында булганга күрә, дини рухта, тормыштан аерылган, күп сүзле, үтә схоластик булган.

Буржуазия иске, феодаль җәмгыятькә каршы аяусыз көрәш алып бара, атап әйткәндә, феодаль җәмгыятьтәге тәрбиянең катлаулылыгына кискен каршы чыга, белем бирү өлкәсендә тигез хокуклылыкны таләп итә иде. Бу таләп ул вакытта, һичшиксез, алдынгы таләп иде.

Буржуаз педагогика феодализмга каршы көрәш чорында күп кенә прогрессив таләпләрне алга сөрде. Балаларга схоластик, тормыштан аерылган белем бирү урынына, мәктәпнең тормыш белән бәйләнгән булуы, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, белем бирүдә күрсәтмәлелекне куллану һәм укучыларга гуманлы мөнәсәбәт таләп ителде. Ир һәм кыз балалар өчен гомуми укыту программасы кертү турындагы мәсьәлә куелды. Белем бирүне элеккегә караганда шактый тизләтергә, өстәвенә күбрәк балаларны укытырга мөмкинлек бирә торган яңа форма һәм методлар эшләнде.

XVIII гасыр уртасында ул чорның иң зур педагогик фикер ияләреннән берсе Жан Жак Руссо кеше хокукларын һәм шәхеснең ирекле үсешен бик нык яклап чыкты. "Табигый тәрбия бирү" идеясен алга сөреп, ул: кешеләр ирекле, сәләтле булып туалар, ә җәмгыять аларны боза, чөнки барлык тәрбия учреждениеләре социаль тигезсезлек һәм изү рухы белән сугарылган. Табигый хәлдә генә кешеләр арасында фактик тигезлек яши һәм кешене кеше коллыкка төшерү булмый, дигән караштан чыгып эш итте. Шуңа күрә Руссо, тәрбия эшен бозык җәмгыятьтән читтә алып барырга, аны җәмгыятькә бәйсез (ирекле) итәргә кирәк, дип саный иде.

Руссоның карашы үз вакыты өчен алдынгы булса да, аның төп идеясе тормышта була алмый иде.

Һәр фәннең үз тарихы була. Аның теоретик нигезләренә төшенү һәм аларны үзләштерү өчен әлеге тарихны белүнең әһәмияте зур. Шуның өчен педагогика курсын өйрәтүне аның үсеше турында кыскача гына тарихи күзәтүдән башлап китәргә кирәк.

Педагогика — борынгы белем тармакларының берсе һәм ул асылда җәмгыять үсеше белән аерылгысыз. Бу фикер аңлашыла төшсен өчен, бер җитди нәрсәгә игътибар итәргә кирәк. Педагогик белемнәр кеше эшчәнлегенең тәрбиягә бәйле үзенчәлекле даирәсенә карый. Чынлап та, педагогика турында сөйләгәндә, гадәттә, бу

сүз тәрбия төшенчәсе белән тәңгәлләшә. Ә тәрбия эше кешелек җәмгыяте барлыкка килгәннән бирле яши. Хезмәт коралларын ясауга һәм табигать хәзинәсен үзләштерүгә бәйле җитештерү тәҗрибәсен, шулай ук хезмәттәшлек һәм күмәк эшчәнлек тәҗрибәсен туплап, кешеләр бу тәҗрибәне яшь буынга биреп калдырырга тырышканнар. Иҗтимагый үсеш кешеләрнең һәр буыны ата-бабалар тәҗрибәсен баетып һәм тагын дә камилләштереп үзеннән соң килгән буыннарга тапшыруы нәтиҗәсендә мөмкин була. Шулай итеп, туплана килгән җитештерү, әхлакый һәм социаль тәҗрибәне яшь буынга тапшыру — кешелек җәмгыятенең яшәеше һәм үсеше өчен мөһим алшарт һәм аның төп вазифаларыннан берсе. Менә шуңа күрә тәрбия эше кешелек җәмгыятенең барлыкка килүе һәм үсеше белән аерылгысыз.

Башка иҗтимагый күренешләр кебек үк, тәрбия бирү эшчәнлеге һәм аның характеры бер урында тормый, җәмгыятьтәге шартлар йогынтысында даими камилләшә һәм үсә. Озак вакытлар дәвамында, мәсәлән, өлкәннәр белән күмәк хезмәт эшчәнлегендә һәм көндәлек аралашу нәтиҗәсендә, балалар җитештерү һәм әхлак тәҗрибәсе туплаганнар. Ыруглык җәмгыяте урнашканга кадәр һәм ыруглар яшәгән чорда, әле тәҗрибә үзе дә чагыштырмача гади булган заманнарда да бу шулай була. Менә шуңа күрә бу чорда тәрбия эше аерым бер иҗтимагый бурыч буларак аерылып тормый һәм кешеләрнең профессиональ эшчәнлегенең махсус өлкәсен тәшкил итми, ягъни балалар өчен махсус тәрбия учреждениеләре дә, педагогик эшчәнлек белән махсус шөгыльләнүче һәм бала тәрбияләүне профессияләре иткән кешеләр дә булмый. Бу хәл колбиләүчелек чорында да озак вакытлар саклана.

Аннары кешелек җәмгыяте үсешенең билгеле бер баскычында, аерым алганда колбиләүчелек строеның соңгырак чорында, җитештерү һәм фән шактый үсеш алгач, тәрбия эше иҗтимагый вазифа буларак аерылып чыга, ягъни махсус тәрбия бирү учреждениеләре, балаларны өйрәтүче һәм аларга тәрбия бирүче профессия кешеләре барлыкка килә. Бу күп кенә борынгы илләрдә шулай була, әмма малайлар өчен ачылган мәктәпләр турындагы азмы-күпме мәгълүматлар безгә Якын Көнчыгыш илләреннән һәм Борынгы Грециядән килеп җиткән.

Педагогик фикерләү теориясе башлангычларын философия нигезләреннән эзләргә кирәк, чөнки ул борынгы заманнардан ук тор-

мышның мәгънәсе, кеше яшәешенең максатлары, җәмгыятьтә аның роле һәм урыны, кешене тормышта үз урынын табарга әзерләү турындагы сорауларга җавап эзләүче фән буларак билгеле.

Фәлсәфи фикерләү колбиләүчелек җәмгыятендә үк шактый үсеш ала. Төзек фәлсәфи система *Сократ* (безнең эрага кадәр 469-399 еллар). *Платон* (б. э. га кадәр 427-347 еллар), *Аристотель* (б. э. га кадәр 384-322 еллар), *Демокрит* (б. э. га кадәр 460-370 еллар) кебек борынгы фикер ияләре тарафыннан тудырыла. Аларның фәлсәфи тәгълиматында кешене тәрбияләү, шәхес формалаштыру, аның тормыштагы урынын билгеләү мәсьәләләре белән бәйле идеяләр һәм принципларны табарга була.

Борынгы заман педагогикасы дин белән бәйле була: яхшы белән яман турындагы дини күзаллаулар бәян ителгән һәм дингә ышанучыларга гаилә һәм җәмгыять әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрнең аерым нормалары билгеләнгән изге китаплардан үзенчәлекле педагогик васыятьләр, тәртип кагыйдәләре турында — кешеләр, балалар һәм ата-аналар арасындагы мөнәсәбәтләр турында күрсәтмәләр табарга була.

Тәрбия һәм белем бирү мәсьәләләре соңгырак гасырларда да күп кенә фикер ияләре, язучылар, галимнәрнең игътибарын – гәрчә аларның кайберләре тәрбия эшчәнлеге белән турыдан-туры шөгыльләнмәсәләр дә — үзенә даими җәлеп итеп килгән. Яңарыш чоры язучылары һәм фикер ияләре *Витторино да-Фельтре* (1378-1446) һәм *Ф. Рабле* (1494-1553), инглиз философы *Дж. Локк* (1632-1704), XVIII гасыр француз мәгърифәтчесе *Ж. Ж. Руссо* (1712-1778), *К. А. Гельвеций* (1715-1771), *Д. Дидро* (1713-1784) һәм башка-лар бала табигате, аны тәрбияләүнең максаты, юллары һәм чаралары турындагы үзләренең якты уй-фикерләре белән педагогик фикерләү үсешенә йогынты ясадылар.

Педагогиканы фәннең бер тармагы буларак рәсмиләштерү иң элек бөек чех педагогы *Ян Амос Коменский* (1592-1670) исеме белән бәйле. Аның "Олуг дидактика" исемле зур хезмәте хаклы рәвештә беренче фәнни педагогика китабы дип исәпләнә.

Педагогик фикерләү үсешендә һәм педагогиканың фән буларак формалашуында күренекле Швейцария педагогы *И. Г. Песталоцци* (1746-1827) һәм немец педагогы *А. Дистервегның* (1790-1866) хезмәтләре һәм педагогик эшчәнлек тәҗрибәсе зур әһәмияткә ия.

Педагогика теориясе үсешенә революциягә кадәрге Россиянең прогрессив педагог һәм мәгърифәтчеләре керткән казанышлар да

зур. *Л. Н. Толстой* (1828-1910) крестьян балалары өчен мәктәп ача, күп кенә дәреслекләрне, шул исәптән мәшһүр "Әлифба" һәм арифметика дәреслеген үзе яза, патша мәктәпләрендә хөкем сөргән хәрефкә ябышып ятуга һәм коры формализмга каршы чыга. Балаларның иҗади сәләтен үстерергә чакыра, һәр баланың шәхесен ихтирам итәргә өйрәтә. Танылган рус хирургы һәм либераль җәмәгать эшлеклесе *Н. И. Пирогов* (1810-1881) төрле катлау балалар өчен билгеләнгән мәктәпләрне кискен тәнкыйтьләп чыкты, баланы "кеше итеп үстерергә" тиешле тәрбия эшенә гомуми карашларны тамырдан үзгәртү кирәклеген яклады.

Педагогика фәне үсешенә *К. Д. Ушинский* (1824-1870) керткән өлеш аеруча зур. Аның педагогик карашлары "Тәрбия җимеше буларак – кеше" исемле хезмәтендә бәян ителгән. Алар аның берничә буын балалар укып үскән, үзе төзегән уку китапларында, шулар исәбендә "Туган тел" һәм "Балалар дөньясы" дигән мәгълүм китапларында методик гәүдәләнеш таба.

К. Д. Ушинскийдан соң ук танылган татар галиме һәм мәгърифәтче, педагог һәм язучы *Каюм Насыйри* (Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров) (1825-1902) халыкчан тәрбия идеясен алга сөрә. Аның "Тәрбия китабы", "Әхлак рисаләсе", "Казан татарларының ышанулары һәм гореф-гадәтләре" дигән хезмәтләрендә татар халкының гуманистик педагогикасы турында гаять бай материал тупланган. Рус җәмәгатьчелеген татар халкының рухи мәдәнияте белән таныштыру максатыннан К. Насыйри күп кенә зирәк һәм хикмәтле сүзләрне русчага тәрҗемә итеп бирә.

Демократик педагогиканың формалашуына күренекле татар мәгърифәтчесе һәм язучысы *Галимҗан Ибраһимовның* (1887-1938) эшчәнлеге шактый йогынты ясады. Ул гуманлы тәрбиянең күп кенә юнәлешләрен җентекләп эшләде. Бу мәсьәләдә аның "Тәрбия эшендә иреклелек һәм гуманлылык нигезләре" дигән хезмәте игътибарга лаек.

Оешкан төстә алып барылган тәрбиягә озак еллар дәвамында балалар гына тартылып килде һәм шуңа күрә педагогиканы *балаларга тәрбия бирү турындагы фән* дип атыйлар иде. Ә хәзер исә, белем бирү һәм тәрбия балаларга гына түгел, асылда бөтен кешегә дә кагылганлыктан, педагогиканы *кешене барлык үсеш баскычларында тәрбияләү турындагы фән* дип әйтәләр. Педагогиканы болай аңлату бик актуаль, чөнки хәзерге чорда белем бирүнең мәктәпкәчә учреждениеләрдән башлап гомуми белем бирү, профес-

сиональ белем бирү, хезмәт ияләренең квалификациясен күтәрүнең күптөрле формаларына кадәр барлык буыннарын эченә алган тулы бер системасы булдырыла.

Хәзерге заманда кешеләр тормышында бик җитди кыенлык килеп туа: фән һәм техниканың төрле тармакларында белемнәр күләме гадәттән тыш тиз үсә, шуңа күрә кешегә белем бирүдә, тәрбия, укыту эшендә элеккеге эчтәлек нигезендә, элекке алымнарны кулланып кына чордан калышмыйча алга бару кыенлаша.

Педагогикада үсешләренең төрле баскычында балалар һәм яшьләрнең кешелек дөньясы туплаган рухи байлыктан нәрсәне үзләштерергә тиешлеген билгеләүдә яңа критерийлар булдыру зарури. Яшь буынны үзлегеннән белем алу һәм үз-үзен тәрбияләү ысуллары һәм алымнары, мөстәкыйль рәвештә фәнни эзләнүләргә, фәнни тикшеренүләргә тизрәк кереп китәргә булышырдай алымнар белән коралландыру мәсьәләсе аеруча кискен тора.

Хәзерге катлаулы шартларда педагогларның осталыгына таләп арта бара. Бүген педагоглар тәрбиясендәге балалар элеккеге чор балаларыннан аерылып тора, тормышның төрле өлкәләрендәге күренешләр һәм вакыйгалар турында, техник һәм фәнни казанышлар, әдәбият һәм сәнгать әсәрләре һ. б. турында мәгълүмат бирүче каналлар күп булу сәбәпле, хәзерге балалар иртә өлгерәләр, таләп һәм омтылышлары да җитдирәк була бара. Педагоглардан укучыларның танып-белү, интеллектуаль һәм гамәли эшчәнлек активлыгын үстерүгә исәпләнгән метод һәм алымнар куллану таләп ителә. Педагогика укытучыларны үз эшенең остасы итәргә тиеш тә. Ул теоретик фән генә түгел, ә гамәли фән дә (мәсәлән, медицина кебек).

Алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнеп һәм гомумиләштереп, фәнни күзәтү һәм тәҗрибәләрдән файдаланып, педагогика белем, осталык һәм күнекмәләрне, үз-үзеңне тоту гадәтләрен үзләштерүдә, танып-белү сәләтен һәм дөньяга карашларны үстерүдә ныклы нәтиҗәләр бирергә, белем һәм тәрбия ысулларын, аларны куллану шартларын табу һәм нигезләү мәсьәләсен хәл итәргә тиеш.

Хәзерге чорда яшь буынны тәрбияләүнең үзенчәлеге шул, бу эштә күп кенә көчләр: гаилә, иҗтимагый оешмалар һәм учреждениеләр катнаша. Педагоглар алар белән хезмәттәшлек итә. Педагогиканың бурычы — бергәләп эшләү дәверендә төп җаваплылык педагог-белгечләр өстенә төшүен истә тотып, әлеге хезмәттәшлек-

нең эчтәлеге һәм алымнары, вазифаларны бүлешү һәм көчләрне берләштерү мәсьәләләрен хәл итү.

Барлык өлкәләрдә белемнәрнең күпләп туплануына һәм фәнни-тикшеренүләр күләменең бик тиз үсүенә бәйле рәвештә фәннәрнең дифференциацияләнүе һәм специальләшүе, ягъни кайчандыр бердәм исәпләнгән төп фәннең күп кенә аерым тармакларга бүленүе һәм аларның мөстәкыйль фән буларак үсә башлавы торган саен ныграк сизелә.

Соңгы елларда педагогика фәнендә да специальләшү һәм дифференциацияләнү сизелерлек үсә. Әле чагыштырмача күптән түгел генә философиянең бер өлешен тәшкил иткән педагогиканың хәзерге вакытта аерым бер юнәлештә үсә башлаган күпсанлы тармаклары барлыкка килде. Аларның инде кайберләре, мәсәлән, мәктәп педагогикасы, мәктәпкәчә яшьтәге балалар педагогикасы кебекләре мөстәкыйль педагогик фән булып танылдылар. Башкалары исә, төрле категориядәге укучыларны тәрбияләү үзенчәлекләрен чагылдыру зарурлыгыннан килеп чыгып, әлегә формалашу һәм фәнни тармакның предметын ачыклау баскычында гына торалар. Мәсәлән, өлкәннәр педагогикасы һәм аңарда мөстәкыйль тармак буларак тиз үсә баручы югары мәктәпләр педагогикасы шундыйлардан санала.

Педагогиканы, тәрбияләнүчеләрнең яшенә карап, *мәктәпкәчә яшьтәгеләр педагогикасы, мәктәп яшендәгеләр педагогикасы* (яисә мәктәп педагогикасы) һәм *өлкәннәр педагогикасына* бүлеп йөртәләр.

Яшьләрне төрле уку йортларында укыту һәм тәрбияләүнең билгеле бер үзенчәлекләренә бәйле рәвештә билгеле бер яшьтәгеләр группаларын тәрбияләүдәге аерымлыкларны өйрәнүче педагогикадан шушы үзенчәлекне чагылдырган тармаклар бүленеп чыга. Мәсәлән, мәктәп педагогикасыннан профессиональ-техник училище шартларында укыту-тәрбия эше барышының үзенчәлекләрен чагылдырган профтехбелем педагогикасы бүленеп чыга.

Халык хуҗалыгы һәм мәдәниятнең барлык өлкәләрендә кадрларның белемен күтәрү системасы барлыкка килде, шуңа бәйле әлеге системада эшләүче белгечләрне өйрәтүне оештыру һәм аның методикасының үзенчәлекләре игътибарны җәлеп итә. Бу исә өлкәннәр педагогикасының, ягъни өзлексез белем күтәрү педагогикасының аерым тармагын өйрәнү предметы булырга тиеш. Ул формалаша башлады гына әле.

Аерым предмет методикалары — конкрет фәннәрне укыту һәм өйрәтү закончалыклары турындагы фәннәр дә педагогика тармакларына керә.

Хәзерге вакытта мәктәптә өйрәнелә торган төп уку предметлары методикасы (физика, химия, география, тарих һ. б. укыту методикасы) аеруча анык формалашкан.

Аерым курслар (мәсәлән, югары уку йортларында философия, педагогика, психология һәм күп кенә башка фәннәр буенча) укыту методикалары да барлыкка килә башлады. Гомуми мәктәпләрдә укырга комачауларлык дәрәҗәдә күрү, ишетү, сөйләм сәләте бозылган, шулай ук психикасы какшаган балаларны укыту, тәрбияләү һәм аларны хезмәткә әзерләү үзенчәлекләрен тикшерүче фән педагогик фәннәрнең махсус группасына карый. Педагогиканың тармаклары махсус педагогика яисә дефектология дигән гомуми исем астында йөртелә.

Дефектология үз чиратында аерым мөстәкыйль тармакларга бүленә: чукрак-телсез һәм чукрак балаларны укыту һәм тәрбияләү мәсьәләләре белән — *сурдопедагогика,* сукырлар белән — *тифлопедагогика,* акылы зәгыйфьләр белән — *олигофренопедагогика,* тотлыгучы һәм сакау балалар белән — *логопедия* шөгыльләнә.

Үзенең тикшерү өлкәсе булган, мөстәкыйль һәм инде шактый үсеш алган фән булуына карамастан, педагогика башка фәннәрдән аерым үсә алмый. Педагогларның эшчәнлек объекты булып физик һәм акыл ягыннан үсеп килүче шәхес тора, шуңа күрә педагогика барыннан да элек кешене өйрәнүче фәннәр белән тыгыз бәйләнгән.

Җәмгыять әгъзасы буларак кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны турындагы мәсьәлә белән иҗтимагый фәннәр шөгыльләнә; биологик үсешнең бер продукты буларак, кеше *биология фәненең,* нигезендә физиологиянең өйрәнү объекты булса, үзенең эчке дөньясы белән һәм фикер йөртү сәләтенә ия буларак ул *психологиянең* өйрәнү объекты булып тора.

Нәкъ менә шуңа күрә дә әлеге фәннәр булачак педагоглар өчен уку предметы булып торалар, гомуми һәм профессиональ әзерлек буенча аларның уку планына кертелгәннәр.

Бу багланышлар нәрсәдә чагыла соң? Философия, барыннан да элек, башка фәннәр кебек үк, педагогиканың да методологик нигезе. Философия һәм педагогиканың кешене тәрбияләү максатлары проблемасы, фәнни караш формалаштыру проблемасы, коллектив һәм шәхеснең үзара элемтәсе, кешенең әйләнә-тирә чынбар-

лыкны танып-белү формаларының берсе буларак, укучыларның танып-белү теориясен эшләү белән бәйләнгән гносеологик проблемалар кебек күп кенә уртак проблемалары бар.

Педагогика шулай ук яшьләргә әхлакый, эстетик тәрбия бирү бурычларын хәл итүдә булыша торган *этика, эстетика* кебек философиянең чагыштырмача мөстәкыйль тармаклары белән дә тыгыз бәйләнгән.

Социаль тирәлекнең кешегә йогынтысын, кешенең җәмгыятьтә тоткан урынын өйрәнүче социология белән дә педагогиканың багланышлары ныгый.

Педагогик социология, педагогика һәм социология чигендә барлыкка килгән яңа фән буларак, җәмгыятьнең социаль үзгәрешләр процессы барышы, кешеләрнең профессиональ мәшгульлеге турындагы социологик тикшеренү мәгълүматларын һәм нәтиҗәләрен мәктәп, гаилә һәм җәмәгатьчелек хәл итәргә тиешле тәрбия мәсьәләләренә күчерә.

Педагогика шулай ук *экономика* белән дә, атап әйткәндә, аның халык мәгарифе экономикасы дип йөртелгән тармагы белән дә тыгыз бәйләнгән. Халык мәгарифе экономикасы мәгълүматлары балаларны алты яшьтән укыта башлауга бәйле рәвештә чыгымнар үсешен, мәктәпләрнең структурасын һәм классларда укучылар, укытучылар санын билгеләү, мәктәп биналарын төзү һәм башка чыгымнарны билгеләү өчен кирәк.

Бу мәсьәләләрне хәл иткәндә педагогика да, экономика да туу, үлем-җитем, күченүләр кебек халык саны проблемаларын өйрәнә торган *демография* мәгълүматларына таяна. Туучылар санын, халыкның яшь үзенчәлекләрен, күченүләрне исәпкә алмыйча һәм фараз итмичә генә мәктәпләр төзү, тиешле санда укытучылар әзерләү мәсьәләләрен хәл итү мөмкин түгел.

Биология фәннәре, аерып әйткәндә физиология, педагогика һәм психология өчен табигый фәнни база итеп карала.

Укыту һәм тәрбия эшенең конкрет мәсьәләләрен хәл итү, ял режимы төзү өчен *яшь чорлары физиологиясе* (ул балалар, яшүсмерләр, егетләр һәм кызлар организмының төзелеш үзенчәлекләрен өйрәнә) һәм *мәктәп гигиенасы* (мәктәптә барлык төр дәресләрдә гигиена мәсьәләләрен — укыту-тәрбия режимына һәм шартларына бәйле рәвештә укучыларның сәламәтлеген, физик үсешен һәм эшкә сәләтен өйрәнә) аеруча зур әһәмияткә ия.

Педагогиканың *психология* белән бәйланышлары күптәннән килә. Педагогика өчен *яшь чорлары психологиясе* һәм *педагогик психология* бик әһәмиятле. Яшьләренә карап максатка юнәлдерелгән укыту һәм тәрбия шартларында балаларның психик үсеш закончалыкларын педагогик психология өйрәнә.

Соңгы елларда кеше һәм техниканың үзара мөнәсәбәтләрен тикшерүче *инженерлык психологиясе* белән педагогика арасында элемтәләр ныгый бара. Психологиянең бу тармагы биргән мәгълүматлар педагогикага хәзерге мәктәпләрдә техник чаралар кертүнең фәнни методикасын эшләргә ярдәм итә.

Кешенең шәхси үзенчәлекләрен өйрәнүче *дифференциаль психология* педагогиканы һәр укучыга индивидуаль якын килү алымнарын тормышка ашыруда зарури мәгълүматлар белән коралландыра.

Төрле группалардагы балаларның шәхес булып өлгерү үзенчәлекләрен өйрәнеп, *социаль психология* укучыларны коллективта тәрбияләү проблемаларын тикшерү һәм аларны коллектив аша тәрбияләү методикасын эшләү өчен күп кенә кыйммәтле мәгълүматлар һәм фактлар белән педагогиканы баета.

Катлаулы динамик системаларны идарә итү турындагы фән — *кибернетика* белән дә соңгы елларда педагогиканың элемтәләре урнашты. Кибернетиканың гомуми идеяләрен педагогикада куллануның гамәли нәтиҗәләреннән берсе — программалы укыту булды.

Педагогиканың башка фәннәр белән бәйланышларында *этнография* һәм *фольклористика* фәннәре аерым урын алып тора. Халык традицияләрен, төрле халыкларның йолаларын һәм гореф-гадәтләрен, халык иҗаты ядкәрләрен өйрәнү педагогиканың аерым бер тармагы — халык мәдәнияте ядкәрләренең педагогик асылын өйрәнә торган *халык педагогикасы* дигән тармагы өчен чыганак һәм нигез булып тора.

Болар барысы да үз предметы һәм тикшеренү өлкәсе булган педагогиканың чиктәш фәннәр белән тыгыз бәйләнешен күрсәтә. Төрле факторлар йогынтысында бара торган кеше үсешенең аерым якларын өйрәнүче башка фәннәрдән аермалы буларак, педагогика гомумән кеше белән эш итә һәм кешенең тулы канлы шәхес булып формалашуының иң нәтиҗәле юлларын эзли.

Педагогиканың башка фәннәр белән бәйланыш формалары төрле-төрле һәм түбәндәгеләрне эченә ала:

- фәнни идеяне алу һәм аны педагогикада иҗади файдалану (мәсәлән, кибернетик идарә идеясе);

- башка фәннәр туплаган мәгълүматлардан файдалану (мәсәлән, төрле яшьтәге укучыларның эшкә сәләте турында физиология мәгълүматлары);

- башка фәннәрнең методикасыннан файдалану (мәсәлән, математик ысуллардан);

- уртак проблемаларны педагогика белән бергәләп хәл итү өчен ике яисә берничә фәннең көчләрен берләштерү (мәсәлән, мәктәп балаларын системалы укытуны тагын да иртәрәк башлау мөмкинлекләрен өйрәнү өчен психология, физиология һәм педагогиканың бергә эшләве);

- педагогик күренешләрнең асылы турындагы күзаллауларны баету һәм тирәнәйтү өчен яисә яңаларын билгеләү өчен башка фәннәрнең терминнарын һәм төшенчәләрен файдалану (мәсәлән, кибернетикадан алынган кайтма бәйләнеш турында төшенчә).

Педагогика чиктәш фәннәрнең материалларын һәм мәгълүматларын әзер хәлендә түгел, ә аларны җентекләп сайлап алу, махсус педагогика күзлегеннән чыгып эшкәртү нигезендә, аларны педагогикада куллану шартларын һәм чикләрен ачыклагач кына файдалана.

* * *

Икенче лекция

БОРЫНГЫ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ТӘРБИЯ

Кайбер галимнәрнең тәрбиянең барлыкка килүе хакындагы күп кенә концепцияләре кеше үсеше турында вульгар-эволюцион күзаллаулар йогынтысында туган. Бу исә тәрбиянең социаль асылына әһәмият бирмәүгә, тәрбия процессын биологияләштерүгә китерә.

Хайваннар дөньясында өлкән буыннарның яшь буынга әйләнә-тирә мохиткә җайлашу күнекмәләрен бирүне "кайгыртуы" турындагы җентекләп җыелган фактик материалларга таянып, андый концепция тарафдарлары (мәсәлән, Ш. Летурно, А. Эспинас) хайваннарның инстинкта буйсынып кылган эш-гамәлләрен борынгы кешеләрнең тәрбия практикасы белән тиңләштерәләр, шулай итеп тәрбиянең бердәнбер нигезе — кешеләрнең нәсел дәвам итүгә омтылышы һәм табигый сайланыш законы дигән ялгыш нәтиҗәгә киләләр.

Кайбер галимнәр арасында, шулай ук балаларның актив рәвештә өлкәннәргә охшарга омтылышы тәрбия нигезе булып тора, дигән фикер киң таралган. Шул рәвешле, тәрбия барлыкка килү сәбәпләрен биологиягә бәйләп аңлатуга психологиягә бәйләп аңлату каршы куела. Бу теориягә, социаль күренешнең барлыкка килүен фәкать психологик факторлар белән генә аңлатырга тырышуның теләсә нинди омтылышлары кебек үк, ачыктан-ачык идеализм хас. Гәрчә, әлбәттә, тәрбия процессында, балаларның яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашу процессында охшарга тырышу, охшату элементларының барлыгын да инкарь итеп булмый.

Борынгы кешеләрнең хезмәт эшчәнлеге һәм шул процесста формалашкан иҗтимагый мөнәсәбәтләр тәрбия барлыкка килүнең төп шарты булып тора. "Маймылның кешегә әверелү процессында хезмәтнең роле" дигән классик хезмәтендә Ф. Энгельс "хезмәт кешене тудырган" дип яза. Кеше формалашуның биологик алшартлары хезмәт аркасында хайвани халәттән кеше халәтенә күчүнең нигезе булып хезмәт итә алган. Кеше хезмәт кораллары ясый башлаган чордан кешелек җәмгыяте барлыкка килгән.

Борынгы кешеләрнең яшәүгә һәм үрчүгә булган табигый ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлгән хезмәт эшчәнлеге кешелек

җәмгыятен тудырган, анда кешенең формалашуы социаль закончалыклар белән билгеләнә башлаган. Иң гади хезмәт коралларын куллану һәм аларны аңлы рәвештә күбрәк, катлаулырак итеп ясау хезмәт күнекмәләрен һәм тәҗрибәне үсеп килүче буыннарга тапшыру зарурлыгын тудырган.

Башта бу хезмәт эшчәнлеге, көнкүреш һәм иҗтимагый тормыш процессында барган. Тора-бара тәрбия кеше эшчәнлегенең һәм кеше аңының аерым өлкәсенә әверелә.

Борынгы җәмгыять үсешенең беренче баскычында — ыруглык җәмгыятенә кадәр — кешеләр табигатьнең әзер продуктларын үзләштергәннәр, ауга йөргәннәр. Яшәү чыганаклары табу процессы үзенчә гади дә, шул ук вакытта катлаулы да булган. Эре ерткычларны аулау, табигать көчләре белән көрәшү күмәкләп тормыш итү, эшләү һәм куллану шартларында гына тормышка ашырыла алган. Бөтен нәрсә уртак булган, коллектив әгъзалары арасында социаль аерымлыклар булмаган.

Борынгы җәмгыятьтә иҗтимагый мөнәсәбәтләр кан кардәшлеге белән тәңгәл килә. Анда хезмәт һәм социаль функцияләр бүленеше табигый биологик нигезләрдә корыла, шуның нәтиҗәсендә ирләр һәм хатын-кызлар арасында хезмәт бүленеше, шул рәвешле иҗтимагый коллективның яшь буенча бүленеше яши.

Ыруглык строена кадәр җәмгыять яшь буенча өч төркемгә бүленгән: балалар һәм яшүсмерләр; тормышта, хезмәттә тулы кыйммәтле һәм тулы хокуклы катнашучылар; уртак тормышта тулы кыйммәтле катнашырга җитәрлек физик көчләре булмаган өлкәннәр һәм картлар (борынгы җәмгыять строе үсешенең алдагы баскычларында яшь буенча төркемнәр саны арта).

Кеше, тугач, иң элек үсеп килүчеләр һәм картаючыларның уртак төркеменә эләгә, ул шунда яшьтәшләре һәм тәҗрибәле картлар белән аралашып үсә.

Тиешле биологик яшькә җитеп, беркадәр аралашу тәҗрибәсе, хезмәт күнекмәләре алгач һәм тормыш кагыйдәләре, гореф-гадәтләр белән танышкач, кеше икенче яшь төркеменә күчкән. Күпмедер вакытлардан соң бу күчеш чорында инициацияләр, "багышлаулар" булган, ягъни яшьләрнең тормышка әзерлекләре: мохтаҗлыклар, авыртуларын кичерә белүләре, батырлык, чыдамлык күрсәтә белүләре саналган.

Бер яшь төркеме әгъзалары белән икенче яшь төркеме әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләр язылмаган, әмма катгый үтәлә торган гореф-гадәтләр һәм традицияләр белән көйләнгән, ул гореф-гадәтләрне туып килүче социаль нормалар ныгыткан.

Ыруглык строена кадәрге җәмгыятьтә әле табигый сайланыш һәм мохиткә җайлашуның биологик механизмнары да кеше үсешенең хәрәкәтләндерүче көчләреннән берсе булып кала. Ләкин җәмгыять үсә барган саен, анда формалашучы социаль закончалыклар һаман зуррак роль уйный башлый, әкренләп беренче урынга ук чыгалар. Борынгы җәмгыятьтә бала үзенең тереклек эшчәнлеге, өлкәннәр эшенә катнашу, алар белән көндәлек аралашу процессында тәрбия һәм белем алган. Ул, соңрак кабул ителгәнчә, тормышка әзерләнеп кенә калмаган, ә үзе булдыра алган эшчәнлеккә турыдан-туры катнашып киткән, өлкәннәр белән, алар җитәкчелегендә күмәк хезмәткә, күмәк көнкүрешкә өйрәнгән. Бу җәмгыятьтә һәммә нәрсә күмәк булган. Балалар да бөтен ыругныкы исәпләнгән: алар башта — ана ыругыныкы, аннары ата ыругыныкы булганнар. Хезмәттә һәм өлкәннәр белән көндәлек аралашуда балалар һәм яшүсмерләр үзләренә кирәкле тормыш һәм хезмәт күнекмәләрен үзләштергәннәр, гореф-гадәтләр белән танышканнар, борынгы кешеләр тормышындагы йолаларны һәм үзләренең барлык вазифаларын башкарырга, үзләрен тулысынча ыруг мәнфәгатьләренә, өлкәннәр таләбенә буйсындырырга өйрәнгәннәр.

Малайлар өлкән ирләр белән беррәттән ауга, балыкка йөргәннәр, корал ясаганнар, кызлар исә өлкән хатын-кызлар җитәкчелегендә азык җыйганнар, уңыш үстергәннәр, ризык әзерләгәннәр, савыт-саба ясаганнар, кием теккәннәр.

Матриархат үсешенең соңгы этапларында яшь буын яши һәм укый торган беренче оешмалар — яшьләр йортлары барлыкка килгән. Малайлар өчен аерым, кызлар өчен аерым ул йортларда балалар ыругның иң өлкән кешеләре җитәкчелегендә тормышка, хезмәткә, "багышлауларга" әзерләнгәннәр.

Патриархаль ыруглык җәмгыяте стадиясендә терлекчелек, җир эшкәртү, һөнәрчелек барлыкка килә. Җитештерүче көчләрнең үсеше һәм кешеләрнең хезмәт тәҗрибәләре киңәюгә бәйле рәвештә тәрбия дә катлаулана, ул инде күпьяклырак һәм планлы төс ала. Балалар терлек карарга, җир эшкәртергә, һөнәргә өйрәнәләр. Яхшырак оешкан тәрбиягә ихтыяҗ тугач, ыруглык общинасы үсеп килүче буынны тәрбияләү эшен тәҗрибәлерәк кешеләргә тапшырган. Алары, хезмәт күнекмәләре бирү белән бергә, балаларны туып килүче дини культ кагыйдәләре, риваятьләр белән таныштырганнар, язарга өйрәткәннәр. Риваятьләр, уен һәм биюләр, музыка һәм җыр, бөтен халык авыз иҗаты әхлак, үз-үзләрен тоту, билгеле бер характер тәрбияләүдә бик зур роль уйнаган.

Үсеш нәтиҗәсендә ыруглык общинасы "үзидарәле, кораллы оешмага" әверелә. Хәрби тәрбия яралгылары барлыкка килә: малайлар җәядән атарга, сөңге кулланырга, атта йөрергә һ. б. өйрәнәләр. Яшь төркемнәрендә анык эчке оешма барлыкка килә, башлыклар аерылып чыга, "багышлауларның" программасы катлаулана, хәзер инде яшьләрне моңа ыругның махсус билгеләнгән өлкәннәре әзерли. Белем башлангычларын үзләштерүгә, ә язу барлыкка килгәч — язуга зур игътибар бирелә башлый.

Тәрбия эшен ыруглык общинасы билгеләгән аерым кешеләр тормышка ашыру, аның эчтәлеген һәм ахырдан сынаулар программасын киңәйтү, катлауландыру — болар һәммәсе шуны раслый: ыруглык строе шартларында тәрбия җәмгыять эшчәнлегенең аерым формасы буларак аерылып чыга башлый.

Шәхси милек, коллык һәм гаилә барлыкка килү белән борынгы җәмгыять таркала. Гаилә иң мөһим иҗтимагый күренешләрнең берсенә, җәмгыятьнең төп икътисади ячейкасына әверелә, балалар тәрбияләү функциясе ыруглык общинасыннан аңа күчә. Гаилә тәрбиясе тәрбиянең массачыл формасына әверелә. Әмма "яшьләр йортлары" да яшәүләрен дәвам итә, шулай ук мәктәпләр барлыкка килә.

Халыкның хакимлек итүче төркемнәре (жрецлар, юлбашчылар, ыру башлыклары) белем бирүне физик хезмәт таләп итүче эшләргә өйрәтүдән аерырга омтылалар. Белем яралгыларын (басуларны үлчәү, су басуларны алдан әйтү, кешеләрне дәвалау алымнары һ. б.) хакимлек итүче төркемнәр үз кулларында туплыйлар, шуның белән үз өстенлекләрен ныгыталар. Бу белемнәргә өйрәтү өчен махсус учреждениеләр — мәктәпләр төзелә. Алар юлбашчыларның, жрецлар, ыру башлыкларының хакимлеген ныгытуда файдаланыла. Мәсәлән, Борынгы Мексикада аксөяк балалары физик хезмәттән азат ителә, аерым бинада укыйлар һәм гади кешеләрнең балаларына мәгълүм булмаган фәннәрне өйрәнәләр (пиктографик язу, йолдызларны күзәтү, мәйданнар исәпләү һ. б.). Шушы хәл аларны башкалардан өстен итә.

Физик хезмәт иҗатчыләр өлешенә кала. Аларның гаиләләрендә балалар бик яшьли эшкә өйрәнә, ата-аналары аларга үз тәҗрибәләрен тапшыралар. Оешкан төстә мәктәпләрдә тәрбияләнү өстен хокуклы кешеләрнең балаларына гына мөмкин була.

* * *

Өченче лекция

КОЛБИЛӘҮЧЕЛЕК ҖӘМГЫЯТЕНДӘ ТӘРБИЯ, МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИК ФИКЕР

Тарихи үсеш нәтиҗәсендә борынгы община строе яңа иҗтимагый формация — **колбиләүчелек строе** белән алышына. Борынгы Көнчыгышта беренче сыйнфый җәмгыятьләр барлыкка килә, матди һәм рухи мәдәнияткә нигез салына. Моны исә алардан күпмедер дәрәҗәдә Греция һәм Рим халыклары кабул итә, үзенчә эшкәртә.

Борынгы Көнчыгыш илләрендә мәктәп. Борынгы Көнчыгыш илләрендә мәктәп торган саен халыкның хакимлек итүче төркеме хокукына әверелә бара.

Бик борынгы заманнарда мәктәп Һиндстанда туа һәм ныгый. Анда гади җир эшкәртүчеләр ачкан община мәктәбе меңнәрчә ел эшләвен дәвам итә. Шул ук вакытта шәһәрләрдә аксөякләр һәм байлар гыйбадәтханәләрендә ачылган мәктәпләр дә зур әһәмияткә ия була.

Мәктәпләр шулай **Кече Азия һәм Африкада** да киңрәк үсеш ала. Биредәге күп кенә дәүләтләрдә әледән-әле кабатланып торган елгалар ташу кебек табигать күренешләрен файдаланып, ясалма сугаруга бәйле җир эшкәртү булган.

Кешеләр табигать күренешләрен күзәткәннәр, су басуларны алдан әйтергә өйрәнгәннәр, плотиналар һәм төрле корылмалар төзү тәҗрибәсен туплаганнар. Астрономия, геометрия, арифметика, медицина фәннәренең яралгылары күренә; төзелешләр өчен иң гади машиналар барлыкка килә. Барлык шушы мәгълүматлар халыкның хакимлек итүче катлаулары кулында туплана, еш кына гайре табигыйлек, серлелек пәрдәсенә төрелә. Ябык жрецлар яисә сарай мәктәпләреннән тыш, дәүләт һәм хуҗалык белән идарә итү ихтыяҗларына хезмәт итүче мәктәпләр дә туа. Болар — күчереп язучылар, хезмәткәрләр һ. б. мәктәпләр. Әкренләп кайбер илләрдә язу ысулы да үзгәрә. Мәсәлән, Мисырдагы жрецлар мәктәпләрендә катлаулы иероглиф язуына ("изге язучы") өйрәтәләр, ә күчереп язучылар мәктәбендә гади (иератик) язу файдаланыла.

Язарга һәм санарга өйрәткәндә кайбер укытуны җиңеләйтүче ысуллар, мәсәлән, төрле төстәге ташлар ярдәмендә санау, исәпләүнең гадиләштерелгән алымнары һ. б. кулланыла. Барлык халыкларда да бармак белән санау киң таралган була.

Борынгы Кытайда түбән һәм югары мәктәпләр булган. Югары мәктәпләрдә өстен хокуклыларның балалары укырга һәм катлаулы иероглиф ысулы белән язарга өйрәнгәннәр, философия һәм мораль (дини характердагы), язучылар һәм шагыйрьләр иҗатлары белән танышканнар. Шунда ук астрономиядән дә кайбер мәгълүматлар алганнар.

Бик борынгы кульязмаларда (Кытай, Һиндстан, Мисыр һ. б.) тәрбия турында, укытучыга һәм укучыга таләпләр турында кыйммәтле фикерләр очрый.

Дисциплина, аеруча күчереп язучылар мәктәпләрендә, бик каты була, тән җәзалары киң кулланыла. **"Баланың колагы — аркасында"**,— диелә бер борынгы Мисыр кульязмасында.

Күпчелек гади кешеләрнең һәм колларның балалары мәктәпләрдә әзерлек үтмиләр; хезмәткә һәм үз-үзеңне тоту нормаларына бәйле төп белем һәм күнекмәләрне аларга ата-аналары һәм тирә-юньдәгеләр бирә.

Борынгы Грециядә тәрбия, мәктәп һәм педагогик фикер. Борынгы Греция — зур булмаган берничә колбиләүчелек дәүләтеннән (полислардан) торган ил. Аларның мөһимрәкләре Лакония (баш шәһәре — Спарта) һәм Аттика (баш шәһәре — Афина) булган. Бу дәүләтләрнең һәр икесендә аерым тәрбия системасы урнашкан: спарта һәм афина тәрбия системалары.

Бу ике системаның аермасына дәүләтләрнең икътисади һәм сәяси үсешендәге кайбер үзенчәлекләр һәм аларның мәдәни хәлләре сәбәп булып тора. Әмма ике дәүләт тә колбиләүчелек дәүләте була, һәм иҗтимагый тәрбия системасы фәкать колбиләүче балаларына гына хезмәт күрсәтә. Грециядә колларга "сөйләшә торган корал" итеп кенә карыйлар. Алар бөтен хокуклардан, шул исәптән мәктәпләрдә уку хокукыннан да мәхрүм ителгән була.

Лакония (Спарта) Пелопоннесның (көньяк-көнчыгышындагы) уңайлы гаваньнары булмаган территорияне биләгән. Илдә коллар хезмәтенә нигезләнгән җир эшкәртү хакимлек иткән. Тулы хокукларга ия булмаган азсанлы ярым азат җирле халыкның күпчелеге һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Тугыз мең колбиләүче гаиләсе 250 меңнән артыграк халыкны кол итеп тоткан. Спартада

колларны рәхимсез эксплуатацияләгәннәр, һәм еш кына коллар баш күтәргәннәр. Спарталыларның тормышы төп бер таләпкә буйсындырылган — даими хәрби хәзерлектә тору, колларга карата рәхимсез көч куллану.

Тәрбияне дәүләт тормышка ашырган, ул спарталыларның балаларыннан ныклы, чыдам сугышчылар, булачак колбиләүчеләр әзерләүне бурыч итеп куйган.

Моңа кадәр өйләрендә тәрбияләнгән спарта малайлары, җиде яшь тулгач, дәүләт карамагындагы махсус тәрбия учреждениеләренә урнаштырылганнар. Агелла дип аталган бу учреждениеләрдә аларны 18 яшькә кадәр укытканнар, тәрбияләгәннәр. Агелла җитәкчесе итеп властьларга мәгълүм кеше — педоном билгеләнгән. Үсмерләрнең физик тәрбиясенә аерым игътибар бирелгән: аларны чыныктырганнар, суыкка, ачлыкка, эссегә, авыртуларга түзәргә өйрәткәннәр. Хәрби-гимнастик күнегүләргә зур игътибар бирелгән. Яшь спарталыларны йөгерергә, сикерергә, диск һәм сөңге ыргытырга, көрәшергә, кул сугышы алымнарына, сугышчан җырлар җырларга өйрәткәннәр. Физик тәрбиягә музыка, җыр һәм сугышчан рухтагы дини биюләр кушылган.

"Уку һәм язу мәсьәләсенә килгәндә,— дип яза грек тарихчысы Плутарх,— балалар иң кирәкле нәрсәләргә генә өйрәнгәннәр, калган тәрбия исә бер генә максатка хезмәт иткән: карусыз тыңлау, чыдамлык һәм җиңү фәне".

Үсеп килүче колбиләүчеләрдә колларга нәфрәт, аяусызлык тәрбияләү төп бурыч булган. Шушы максатларда алар **"криптияләрдә"**, ягъни төннәрен **коллар аулауда** катнашканнар. Бу болай эшләнгән: яшь спарталылар отряды, шәһәрнең берәр кварталын яисә шәһәрдән читтәге районны чолгап алып, теләсә нинди кол – илотны үтергән.

Әхлакый һәм сәяси тәрбия дәүләт җитәкчеләренең яшьләр белән махсус әңгәмәләре вакытында бирелгән. Алар ул әңгәмәләрдә борынгы бабаларының ватан дошманнары белән көрәштәге ныклыгы, батырлыгы турында, геройлар турында сөйләгәннәр. Балаларны анык һәм кыска җавап бирергә ("лаконик сөйләмгә") өйрәткәннәр.

18-20 яшьлекләр, махсус эфеблар төркеменә күчерелеп, хәрби хезмәткә тартылганнар. Кызларның хәрби һәм физик тәрбиясенә зур игътибар бирелгән. Ирләр сугышка яисә баш күтәргән кол-

ларны бастырырга киткәндә, хатын-кызлар шәһәр һәм торакларны саклаганнар, колларны буйсындырып тотканнар.

Афина тәрбиясе башкача оештырылган була. Афинада икътисади тормыш Спартадагы шикелле чикләнмәгән. Коллар шәхси милек булып исәпләнгән.

Афинада безнең эрага кадәр V-IV гасырларда мәдәният бик нык үсә. Грек философиясенең күп төрле формаларында дөньяга карашның хәзерге барлык төрләренең яралгысы була. Шушы чорның кайбер философларның карашларында материализм элементлары да, диалектика элементлары да күренә. Табигать белеме, математика, тарих, сәнгать, әдәбият, гүзәл грек архитектурасы һәм скульптурасы үсә.

Афиналылар физик яктан да, әхлакый яктан да гүзәл кешене генә идеал дип исәпләгәннәр, акыл, әхлак тәрбиясен, эстетик һәм физик тәрбияне кушарга омтылганнар. Ләкин бу идеал тулысынча югары социаль катлауга — колбиләүчеләргә генә кагылган. Физик хезмәт бары тик колларның гына бурычы дип саналган. Шулай да, катлауларга аерылу сәбәпле, колбиләүчеләр арасыннан тумыштан азат һәм иреккә җибәрелгән аз милекле шактый зур төркем аерылып чыга. Алар һөнәрчелек яисә башка төр эшчәнлек белән, шул исәптән укытучылык белән дә, шөгыльләнергә мәҗбүр булалар. Бай колбиләүчеләр аларга кимсетеп, җирәнеп карый.

Афинада балалар җиде яшькә кадәр өйдә тәрбияләнә. Җиде яшьтән малайлар мәктәпкә йөри башлый. Кызлар тәрбияне гаиләдә алалар, йорт эшләренә өйрәнәләр. Афинада хатын-кызның гомере җәмгыятьтән читтә, йортның хатыннар ягында (гинекеядә) уза.

Иң әүвәл балалар (7 яшьтән 13-14 яшькә кадәр) **грамматист һәм кифарист** мәктәпләрендә укыйлар (йә бер үк вакытта, яисә башта — грамматист, аннары кифарист мәктәбендә). Бу мәктәпләр хосусый һәм түләүле булганлыктан, тумыштан иреклe, әмма байлыгы булмаган кеше балаларының (демосларның) шактый өлеше анда укый алмаган. Мәктәпләрдә дәресләрне **укытучы-дидаскаллар** алып барган (**"дидаско"** — мин укытам, соңрак: **"дидактика"** — укыту теориясе). Малайларны мәктәпкә берәр кол озата барган, ул кол педагог дип аталган (**"пайс"** — бала, **"вгогейн"** — алып барырга дигән сүзләрдән).

Грамматистны мәктәптә укырга, язарга, санарга өйрәткәннәр. Хәрефләрне кушып укыту ысулы кулланылган: балалар әүвәл хәрефләрнең исемнәрен (альфа, бета, гамма һ. б. ш.) өйрәнгәннәр,

аннары алардан иҗекләр, сүзләр ясаганнар. Язарга өйрәтү өчен балавызлы такталар кулланылган, ул такталарга нечкә таяклар (стильләр) белән хәрефләр язганнар. Санарга бармаклар, ташлар һәм счетка охшаганрак исәпләү тактасы (абака) ярдәмендә өйрәнгәннәр. Кифарист мәктәбендәге малай, гадәттә, әдәби белем һәм эстетик тәрбия алган: музыкага, җырга, шигырь сөйләргә өйрәнгән ("Илиада" һәм "Одиссея"дан өзекләр укыганнар).

13-14 яшьлек малайлар **палестра** дип аталган уку йортына (көрәш мәктәбенә) күчкәннәр. Биредә алар ике-өч ел буена физик күнегүләр белән шөгыльләнгәннәр, бишле ярыш дип аталган бу системага йөгерү, сикерү, көрәш, диск һәм сөңге ыргыту, йөзү кергән. Алар белән сәяси һәм әхлакый темаларга әңгәмәләр үткәрелгән. Палестрада физик тәрбия һәм әңгәмәләр белән иң атаклы кешеләр җитәкчелек иткән.

Аннары яшьләрнең баерак өлеше гимназияләргә кергән (соңрак — гимназияләр). Алар анда, дәүләтне идарә итүдә катнашырга әзерләнү өчен, философия, сәясәт, әдәбият өйрәнгәннәр, гимнастика белән шөгыльләнүләрен дәвам иткәннәр.

Ниһаять, Спартадагы кебек үк, 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге егетләр **эфебияга** күчкәннәр, анда аларның **хәрби һәм сәяси тәрбияләре** дәвам иткән. Алар ныгытмалар төзергә, хәрби машиналарны идарә итәргә өйрәнгәннәр, шәһәр гарнизоннарында хезмәт иткәннәр, диңгез эшенә өйрәнгәннәр, җәмәгать бәйрәмнәрендә һәм театр тамашаларында катнашканнар.

Афина республикасындагы колбиләүчелек җәмгыятенең әчтән катлауларга бүленүе тәрбия өлкәсендә дә күренә: күпьяклы тәрбия алу бай колбиләүче балаларына гына мөмкин була. Тумыштан ирекле төп халык массаларының (демос) балалары мәктәпләрдә укый алмый. Әтиләре балаларын һөнәргә, кайберләре исә укырга-язарга да өйрәтә. Бу законда каралган була: закон нигезендә аз милекле ата-аналар балаларын нинди дә булса һөнәргә өйрәтергә тиеш булалар, шулай булмаган очракта аларның балалары карт ата-аналарының матди хәлен кайгыртудан азат ителә. Физик хезмәт белән шөгыльләнүче тумыштан иреклеләргә колбиләүче аксөякләр түбәнсетеп карый. Коллар исә "сөйләшә торган корал" буларак кына бәяләнә.

Борынгы Грециядә педагогик теориянең тууы. Борынгы грек галим-философлары **Сократ, Платон, Аристотель һәм Демо-**

критның халык алдында ясаган чыгышларында һәм хезмәтләрендә тәрбия һәм укыту турында кыйммәтле фикерләр бар.

Сократ (б. э. к. 469-399 еллар) — философ-идеалист. Чыгышы буенча гади халыктан булуына да карамастан (ярлы һөнәрче — сынчы малае), ул җирбиләүче консерватив аксөякләр идеологы була. Бу аның фәлсәфи һәм педагогик карашларында чагылыш таба. **Сократ**: дөньяның төзелешен, әйберләрнең физик табигатен танып белү мөмкин түгел, кешеләр фәкать үз-үзләрен генә танып белә алалар, гомуми һәм үзгәрмәс әхлакый төшенчәләр бар, дип санаган.

Тәрбиянең максаты, **Сократ** фикеренчә, әйберләрнең табигатен өйрәнү түгел, ә үз-үзеңне таный белү, әхлакны камилләштерү булырга тиеш.

Сократ — трибун философ, әхлак темаларына мәйданнарда һәм башка җәмәгать урыннарында чыгышлар ясаган. Чыгышларында әзер положениеләр һәм нәтиҗәләр бирмәгән, сораулар һәм җаваплар ярдәмендә тыңлаучыларын "хакыйкатьне" үз көчләре белән эзләргә дәртләндергән. Бу ысул **Сократ** ысулы дигән исем алган, соңрак шуннан юнәлеш бирүче сораулар ысулы белән Сократ әңгәмәсе дигән ысул барлыкка килгән.

Платон (б. э. к. 427-347 еллар) — философ-идеалист, Сократның шәкерте, объектив идеализм теориясен тудыручы, ул "идеяләр дөньясын" — беренчел, ә тоеп беленә торган әйберләр дөньясын икенчел дип санаган, әйберләрнең җисемсез формалары (ул аларны "төрләр" яисә "идеяләр" дип атаган) барлыгы фикерен алга сөргән. Ул дөньяны идеяләр дөньясына һәм күренешләр дөньясына бүлгән. Аныңча, идеяләр мәңгелек һәм үзгәрешсез. Әйберләр исә бары идеяләр дөньясының күләгәсе генә.

Платон, Афина аксөякләренең вәкиле, аксөякләрнең мәңгелек хакимлеге теориясен күтәреп чыккан. Идеаль аксөякләр дәүләте конституциясен төзегән. Анда өч иҗтимагый төркем: философлар, сугышчылар, һөнәрчеләр һәм җир эшкәртүчеләр яшәргә тиеш булган. Философлар идарә итә, сугышчылар дәүләт тәртибен саклый, ә өченче төркем эшләп теге икесен ашата, киендерә. Бу дәүләттә коллар да була. Коллар кебек үк, һөнәрчеләр һәм җир эшкәртүчеләр дә хокуксыз. Түбән җанлы бу кешеләр карусыз, тыңлаучан булырга тиеш.

Бу дәүләтнең максаты, **Платон** фикеренчә, — иң югары бәхет идеясенә якынаю: ул беренче чиратта тәрбия юлы белән тормышка ашырыла, шуңа күрә тәрбиягә аеруча әһәмият бирелә.

Тәрбия, ди **Платон**, дәүләт тарафыннан оештырылырга һәм хаким төркемнәр — философлар һәм сугышчыларның мәнфәгатьләренә туры килергә тиеш. Платон педагогик системасында үзенең идеяләрен канәгатьләндерә торган Спарта һәм Афина тәрбияләрен бер системага берләштерергә омтылган.

3 яшьтән 6 яшькәчә балалар дәүләт тарафыннан билгеләнгән тәрбиячеләр җитәкчелегендә мәйданчыкларда уеннар уйныйлар. Тәрбия чарасы буларак сабыйларның уенына, шулай ук балаларга сөйләү өчен материал сайлауга Платон зур әһәмият бирә. Ул аларга бик кечкенәдән җәмгыять тәрбиясе бирүне яклый.

7 яшьтән 12 яшькә кадәрге балалар, дәүләт мәктәпләренә йөреп, укырга, язарга, хисапка, музыка һәм җырга өйрәнәләр, ә 12 яшьтән 16 яшькә кадәр — физик тәрбия мәктәбенә — гадәти гимнастик күнегүле палестрага йөриләр. Палестрадан соң 18 яшькә кадәрге яшүсмерләр, күбесенчә гамәли максатларда (сугышчылар әзерләү өчен) арифметика, геометрия һәм астрономия өйрәнәләр. 18 яшьтән 20 яшькә кадәр — эфебия, ягъни хәрби-гимнастик әзерлек. Акыл хезмәтенә сәләте күренмәгән егетләр 20 яшьтән сугышчылар булып китәләр. Яшьләрнең абстракт фикер йөртүгә сәләте азрак өлеше 30 яшькә кадәр белем алуның өченче, югары баскычын уза. Алар философия, шулай ук арифметика, геометрия, астрономия һәм музыка теориясен, әмма инде фәлсәфи-теоретик планда өйрәнәләр. Дәүләт хезмәтенә әзерләнәләр. Аеруча сәләтле бер өлеше философиягә өйрәнүен тагын 5 ел (35 яшькә кадәр) дәвам итә, аннары алар 35 яшьтән 50 яшькә кадәр дәүләт белән җитәкчелек итәләр.

Платон фикеренчә, хатын-кызларны тәрбияләү Спартадагы шикелле булырга тиеш.

Платон системасында бөтен тәрбия физик хезмәткә тирән нәфрәт рухында корыла, булачак философларга һәм сугышчыларга "хәтта ул турыда уйлау да" тыела. Кол балалары белем алуга якын да җибәрелми.

Платон мәктәпкәчә тәрбия, дәүләт тәрбиясенең эзлекле системасы турында күп кенә мөһим фикерләр әйтә, уңай мисал белән тәрбияләү таләбен күтәреп чыга һ. б.

Аристотель (б. э. к. 384-322 еллар) — Платон шәкерте, Александр Македонскийның тәрбиячесе, борынгы Грециянең бик зур

философы һәм галиме була. Ф. Энгельс болай дип яза: "Борынгы Греция философлары барысы да тумыштан стихиячел диалектиклар булганнар һәм Аристотель, алар арасында иң универсаль башлы кеше, диалектик фикерләүнең иң әһәмиятле формаларын тикшергән инде".

Дөньяны идеяләр һәм күренешләр дөньясына бүлгән укытучысы Платонның капма-каршысы буларак, **Аристотель:** дөнья бердәм һәм әйберләр идеясе әйберләрнең үзләреннән аерылгысыз, дип таный. Идеяне, Аристотель фикеренчә, формага тиңләштерергә мөмкин. Һәм предметта без матдә һәм форманы аерабыз. Матдәдә әйбер мөмкинлекләре бар: матдә, теге яисә бу форманы алып, әйбергә әверелә. Мәсәлән, мәрмәр матдәсе, билгеле бер форма алгач, статуя була ала.

Бөтен тормыш – үсеш процессы ул. Бу процесс тышкы көчләр йогынтысында түгел, ә эчке үсеш буларак бара. Аристотель тышкы дөньяның чынлыгына шикләнмәгән һәм танып белүнең нигезенә тоеп белү тәҗрибәсен, сизүне салган. Танып белүдәге ялгышлар, **Аристотель** уенча, ялган фикер йөртүдән, ягъни тоеп белү тәҗрибәсен ялгыш аңлатудан килеп чыга. Шунысы әһәмиятле, **Аристотель** форма һәм эчтәлек берлеген күрсәтә һәм үсеш идеясен күтәреп чыга.

Кешедә **Аристотель** материя һәм форма кебек аерылгысыз яши торган тән һәм җанны күрә. Аристотель фикеренчә, өч төрле җан бар: үсемлек җаны (туклануда һәм үрчүдә күренә); хайван җаны (үсемлекләрдәге үзлекләрдән тыш, тою һәм теләкләрдә күренә); акылга ия җан (үсемлек һәм хайваннардагы үзлекләрдән тыш, аңа фикер йөртү яки танып белү хас). Кешедәге җанның хайван өлешен, акылга буйсындырылганлыктан, ихтыярлы дип әйтергә була.

Ә аның өч төренә, **Аристотель** фикеренчә, тәрбиянең өч ягы туры килә: **физик тәрбия, әхлакый тәрбия** һәм **акыл тәрбиясе**.

Тәрбиянең максаты, аныңча, җанның иң югары — акылга ия һәм ихтыярлы якларын үстерү. Һәрбер матдәдә үсеш мөмкинлеге булган шикелле үк, кешегә дә табигать сәләтнең яралгыларын гына бирә; үсеш мөмкинлеге тәрбия белән тормышка ашырыла. Табигать җанның өч төрен дә бик тыгыз беркеткән, тәрбиядә дә без, физик, әхлакый һәм акыл үсешен бергә бәйләп, табигатькә иярергә тиешбез.

Дәүләтнең, **Аристотель** фикеренчә, гомумән алганда ахыргы максаты бер — барлык **кешеләргә дә бердәй тәрбия** кирәк, һәм бу тәрбия шәхси инициатива эше булырга тиеш түгел, ә аны дәүләт кайгыртырга тиеш. Гаилә һәм җәмгыять тәрбиясе үзара бәйләнгән булырга тиеш. Дәүләт бердәй тәрбия бирүне кайгыртырга тиеш диюе белән Аристотель, билгеле, колларны күз алдында тотмаган.

Кешелекнең тарихи тәҗрибәсен берләштереп, Аристотель яшь чорларын билгеләгән һәм үсеп килүче кеше гомерен өч чорга бүлгән: 1) 7 яшькә кадәр, 2) 7 яшьтән 14 яшькә кадәр (җенси өлгергәнлек чоры), 3) җенси өлгергәнлек чорыннан 21 яшькә кадәр. Аныңча, чорларга шулай бүлү кешенең табигатенә туры килә дә инде.

Аристотель гаилә тәрбиясе мәсьәләсендә дә күп кенә киңәшләр бирә. 7 яшькә кадәр балалар гаиләдә тәрбияләнә. Балага яшенә туры килгән ризык ашатырга, хәрәкәт гигиенасын тәэмин итәргә һәм аны әкренләп чыныктырырга кирәк. 7 яшьтән малайлар дәүләт мәктәпләренә йөрергә тиеш була.

Физик тәрбия акыл тәрбиясеннән алда барырга тиеш. Малайларны иң элек гимнастика укытучылары кулына тапшырырга кирәк, әмма аларның артык аруына юл куярга ярамый. Организм ныгыганчы, җиңел күнегүләр генә эшләтергә кирәк. Аристотель фикеренчә, физик, әхлакый һәм акыл тәрбиясе үзара бәйләнгән. Башлангыч белем бирү чорында, гимнастикадан тыш, укырга, язарга, грамматикага, рәсем һәм музыкага өйрәтергә кирәк. Үсмерләр мәктәптә җитди белем алырга: әдәбият, тарих, фәлсәфә, математика, астрономия һәм музыканы өйрәнергә тиеш. Музыканы, рәсем шикелле үк, профессиональ максатларда түгел, ә матурлык хисен үстерү өчен өйрәнергә кирәк. Хатын-кызлар, Аристотель уйлавынча, табигатьләре белән ирләрдән аерылып торганлыктан, алар шикелле белем ала алмыйлар.

Үз фәлсәфәсендә ихтыяри, эшлекле башлангычларны алга сөргән Аристотель әхлак тәрбиясе өлкәсендә әхлакый эш-гамәлләрдә әхлак күнекмәләре һәм күнегүләренә зур әһәмият биргән. Табигый сәләт чаткылары, күнекмәләрне үстерү (өйрәтү, кирәкле эш-гамәлләрне еш кабатлау) һәм акыл — әхлак тәрбиясенең өч чыганагы менә шушылар.

Яхшылык тәрбияләү өчен әхлакый тотыш гадәтләрен һәм күнекмәләрен формалаштыручы яхшы уйланылган күнегүләр кирәк, һәрбер теләктә һәм эшчәнлектә, Аристотель фикеренчә, кимлек,

артыклык (арттырып җибәрү) һәм уртаклык булырга мөмкин. Һәрнәрсәдә бары тик уртаклык, бары тик тигезләнеш яхшы һәм файдалы. Үз-үзеңне тотуда арттырып җибәрүләргә дә, җитешсезлекләргә дә юл куймау — яхшылык була. Үз-үзеңне шулай тотарга күнегү зарури. Платоннан аермалы буларак, Аристотель: гаилә тәрбиядән читләшми, әхлак тәрбиясен кайгырту күбрәк гаилә өстенә төшә, дип саный.

Аристотельнең карашлары антик педагогика үсешенә зур йогынты ясый. Әмма урта гасырларда, Аристотель фәлсәфәсе бик популяр чорда, поплар, Аристотельдәге җанлы нәрсәләрне үтереп, үлене мәңгеләштерделәр...

Атомистик теорияне тудыручы күренекле фәлсәфәче — материалист **Демокритның (б. э. к. 460-370 еллар)** карашлары Борынгы Греция фәлсәфәсенең иң югары ноктасы булып тора. Ул үз хезмәтләрендә тәрбия мәсьәләләренә күп игътибар бирә, табигать законнарына, имеш-мимешләргә ышану һәм куркуны җимерә торган чын белемгә мөрәҗәгать итә. Ул аллага ышануны кире кага, "аллалар ихтыяры" — уйдырма, кешеләр хыялы гына дип саный.

Демокрит беренчеләрдән булып тәрбиянең табигатькә ярашлылыгы мәсьәләсен күтәрә. "Табигать һәм тәрбия охшашлар",- дип яза ул. "Укыту хезмәт нигезендә генә гүзәл нәтиҗәләргә китерә",- ди Демокрит. Тәрбия эшендә хезмәтнең роле зурлыгын ассызыклап, "бер күнеккәч җиңеләя торган даими хезмәт" таләп итә. Ул начар мисалга иярүдән кисәтә һәм әхлакый эш-гамәлләрдә күнегүне бик әһәмиятле дип саный.

Демокрит колбиләүчелек нигезләренә тәнкыйди караш уята, табигатьне чын-чынлап танып белергә, тәрбияне хезмәт белән бәйләргә чакыра.

Борынгы Римда тәрбия һәм мәктәп. Рим республикасында колбиләүчелек үсә; байлык туплану халыкның катлауларга аерылуына китерә, бу исә мәктәпләрнең, байлык һәм чыгышка карап, башлангыч һәм югарырак баскычтагы грамматик мәктәпләргә, ә соңрак оратор мәктәпләренә бүленүенә сәбәп була.

Башлангыч мәктәпләр хосусый һәм түләүле була. Анда тумыштан ирекле булмаган ярлы сыйныфларның (плебейларның) балаларын укырга, язарга һәм хисапка өйрәткәннәр, илнең законнары белән таныштырганнар. Бай, аксөяк балаларына башлангыч белемне өйдә бирүне кулай күргәннәр.

Грамматик мәктәпләр дә хосусый һәм түләүле булган, аларда өстен хокуклыларның балалары латин һәм грек телләрен, риторика (әдәбият һәм тарихтан кайбер мәгълүматлар белән сөйләү осталыгы) өйрәнгәннәр. Мондый мәктәпләр сайланып куела торган җитәкче урыннарга омтылучыларга ораторлык сәнгатенә өйрәнү өчен кирәк булган.

Рим республикасының соңгы йөзьеллыгында махсус **риторлар (ораторлар) мәктәпләре** барлыкка килә. Анда киләчәктә югары дәүләт хезмәтенә урнашырга теләгән аксөяк балалары зур түләү исәбенә риторика, фәлсәфә һәм хокук белеменә, грек теле, математика һәм музыкага өйрәнгәннәр. Греция тарафыннан яулап алынганнан соң (б. э. к. II гасыр) Римда грек мәдәнияте тарала, аксөякләр грек телендә сөйләшә башлый.

Рим империясе барлыкка килгәннән башлап, грамматик һәм риторлар мәктәпләре **дәүләт мәктәпләре** итеп үзгәртелә. Ул мәктәпләрнең бурычы император хакимиятенә тугрылыклы түрәләр әзерләү була. Андагы укытучыларны императорлар үз сәясәтләрен карусыз үткәрүчеләргә әверелдерергә тырышканнар, шуның өчен аларга хезмәт хакы түләгәннәр һәм төрле өстенлекләр биргәннәр. Риторлар мәктәпләренә аларның игътибары аеруча зур булган.

Христиан дине хакимлек итүче дин һәм император хакимлегенең таянычы дип игълан ителгәч, укытучылар итеп христиан дине вәкилләрен билгели башлаганнар, мәктәпнең бөтен эше ачыктан-ачык чиркәүгә йөз тота. Христианнар борынгы грек мәдәниятенә, антик фән һәм мәктәпкә дошман караштa торганнар.

Борынгы Римда педагогик һәм методик положениеләр эшләү. Рим педагогларыннан иң атаклысы **Марк Фабий Квинтилиан (б. э. к. 42-118 еллар)** булган. Аның **"Оратор тәрбияләү турында"** дигән әсәренең сакланып калган өзекләреннән авторның төп педагогик карашлары турында хөкем йөртеп була. Квинтилиан үз заманындагы грек һәм Рим фәлсәфи-педагогик әдәбияты белән яхшы таныш булган. Риторлар мәктәбе укытучысы буларак, ул үзенең бай тәҗрибәсен дә гомумиләштергән. Педагогика тарихында бу, һичшиксез, мәктәп практикасы белән тыгыз бәйләнгән беренче эшләрдән берсе була.

Квинтилиан азат гражданнарның балалары табигый сәләткә күбрәк ия дип санаган. Аныңча, алар арасында томана һәм сәләтсезләр сирәк очрый. Бала мәктәптә тәрбияләнсен, укытучы һәр балага сак һәм игътибарлы мөнәсәбәттә булсын. Укытучы үзе

белемле, тотнаклы булырга, балаларны яратырга, уңга-сулга бүләк һәм җәза өләшмәскә, укучыларына үрнәк булып торырга һәм аларны игътибар белән өйрәнергә тиеш. Һәр укытучы укытуның бөтен баскычларын да узарга тиеш. Югары типтагы мәктәп укытучысы әүвәл башлангыч мәктәптә укытырга тиеш була.

Квинтилиан баланың кече яшьтән сөйләмен үстерүгә зур әһәмият биргән. Бу максатларда ул өйгә дөрес, сөйләмле нянялар алырга, балага уйнар өчен иптәшләр сайларга, бала аралаша торган иптәшләренең үз-үзләрен тотышына игътибар бирергә, начарларын читләштерергә тәкъдим итә. Тел һәм музыкага өйрәнү, **Квинтилиан** фикеренчә, дөрес сөйләшергә ярдәм итә, сөйләм стилен яхшырта, аны сәнгатьлерәк итә. Логик фикерләү, фикер төзеклеге һәм эзлеклелеге булдыру максатларында ул математика (арифметика һәм геометрия) өйрәнү кирәклеген, укытуны теоретик киңәшләргә, охшату һәм күнегүләргә нигезләнеп төзү зарурлыгын күрсәткән. Белем нигезләрен ашыкмыйча, ныклы итеп салу аеруча мөһим дип саналган.

Квинтилиан киңәшләрендә укытучы-практик тавышы тоемлана. Аның Яңарыш чорында өр-яңадан ачылган әсәрләрен бик күп укытучылар сүрелмәс кызыксыну белән өйрәнгәннәр һәм ул бүген дә актуаль.

* * *

Дүртенче лекция

ФЕОДАЛЬ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ТӘРБИЯ, МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИК ФИКЕР

Борынгы феодализм чорында тәрбия. Феодаль җәмгыятьтә, барлык җирләрне биләп, үзләренә буйсынган крестьяннарны эксплуатацияләүче феодаллар һәм руханилар хакимлек итә. Чиркәү феодаль җәмгыятьтә югары катлауның идеологик таянычы була. Ф. Энгельс күрсәткәнчә, феодаль үсеш стадиясен узучы көнбатыш дәүләтләрдә "интеллектуаль белемгә монополия поплар кулында була, һәм шулай итеп белем алу үзе күпчелек дини характер ала".

Балалар һәм өлкәннәрне укытуның бөтен эчтәлеге дин белән сугарылган була. Барлык диннәр дә гади кешеләрне хуҗаларга буйсынырга, алар мәнфәгатенә хезмәт итәргә өйрәтә. Христиан дине бу максатта кеше табигатенең тумыштан гөнаһлылыгы турындагы тәгълиматны эшкә җигә, тыелуга, суфыйлыкка, киләчәктә теге дөньяда җанны коткару өчен тән рәхәтләреннән ваз кичәргә өнди.

Иран, Сүрия, Палестина, Мисырда һәм Африканың бөтен төньяк яр буенда VII-VIII гасырларда гарәпләрнең яулап алулары нәтиҗәсендә зур дәүләт барлыкка килә, ул Кытай, Һиндстан, Европа белән тыгыз икътисади элемтәләр урнаштыра. Гарәпләр тарафыннан яулап алынган илләрнең мәдәнияте югарырак була, яулап алынган илләр шул мәдәниятне кабул итәләр.

VIII гасырда гарәпләр Пиреней ярымутравын басып алалар, һәм Көнбатыш Европа территориясендә күп кенә югары **мөселман мәктәпләре** ачыла. Шуларның иң әһәмиятлесе Кордованың университет тибындагы югары мәктәбе, анда Көнбатыш Европаның төрле илләреннән студентлар җыелган. Кордова хәлифәлеге Урта гасырлар башында Көнбатыш Европага бик күп антик әсәрләр, аерым алганда Аверроэс исеме белән мәгълүм булган гарәп философы, Ибн-Рөшд (XII гасыр) шәрехләмәсендә Аристотель хезмәтләре үтеп керүдә күпер ролен үти.

Рим империясе IV гасырда Көнбатыш һәм Көнчыгыш империяләренә бүленә. Көнбатыш империя берничә дәүләткә таркала. Тарихка Византия исеме белән кергән Көнчыгыш империя мең ел

диярлек яши. Византиядә, христиан дине өстенлек итүгә карамастан, антик мәдәниятнең кайбер элементлары сакланып кала. Мәктәпләрдән тыш, күп кенә шәһәрләрдә чиркәү карамагындагы югары мәктәпләр булган, анда изге язма текстлары белән беррәттән антик философлар, шагыйрь һәм язучылар хезмәтләрен өйрәнгәннәр. Тәре походлары чорында Көнчыгыш белән Көнбатышның аралашуы сәбәпле, антик дөньяның күп кенә әсәрләре Көнбатыш Европага да мәгълүм булган. Көнчыгыш Европада Византия мәдәнияте таралуда славяннарның роле зур була. Бу мәдәният (шул исәптән кайбер дини-тәрбияви трактатлар) Борынгы Руська да үтеп керә.

Византия империясен төрекләр яулап алган чорда (XV гасыр) күп кенә Византия галимнәре Европага күчеп китәләр һәм шунда антик философия әсәрләрен тараталар.

Көнбатыш Европада чиркәү мәктәпләре. Көнбатыш Европа илләре тормышында католик чиркәве зур әһәмияткә ия була. Ул бөтен белем алу системасын үз кулында тота. Урта гасырлардагы монастырьларда гыйбадәт ихтыяҗларында китаплар күчереп языла, күчереп язучылар әзерләнә, китапханәләр һәм мәктәпләр төзелә.

Иң әүвәл **монастырь мәктәпләре** формалаша. Кайбер монастырьларда эчке һәм тышкы мәктәпләр була: эчке мәктәпләрдә ата-аналары монахлыкка биргән малайлар укый, аларның яшәүләре дә монастырьда була; тышкы мәктәпләрдә шул чиркәү мәхәлләсендәге кешеләрнең балалары белем ала.

Чиркәү идарәсе үзәкләрендә балаларны укырга бирә торган епископ тулай торакларыннан собор, яисә **кафедра мәктәпләре** (епископ кафедрасы каршында оештырылган мәктәпләр) үсеп чыга. Күп кенә урыннарда алар эчке мәктәпләргә (укучылар шунда яшиләр) һәм тышкы мәктәпләргә бүленәләр (тышкы монастырь һәм кафедра мәктәпләрендә, кагыйдә буларак, дворян балалары һәм, сирәк кенә булса да, шәһәрнең танылган кешеләренең балалары укый).

Һәм, ниһаять, күп кенә мәхәллә чиркәүләре каршында, **мәхәллә мәктәпләрендә**, укыту беркадәр системага салынган була. Мәктәпләрдә малайлар гына укый. Мәхәллә мәктәпләре йә чиркәү бинасында, яисә балаларны укытырга алынган дин әһеленең фатирында урнаша. Анда латинча догалар укырга, чиркәүдә җырларга һәм, сирәгрәк булса да, язарга өйрәтәләр. Чит телдә укыганнарының мәгънәсен еш кына балалар үзләре аңламаганнар.

Монастырь һәм собор мәктәпләренең кагыйдә буларак, уку өчен аерым биналары да булган; анык укыту сроклары билгеләнгән. Укытучылар — уку-укыту күнекмәләре алган руханилар булган.

Мәхәллә мәктәбендә уку берничә ел дәвам иткән: балалар белән бергә яшьләр һәм хәтта "китап гыйлеменә" өйрәнергә карар иткән өлкәннәр дә укыган. Баштарак укытучы материалны балаларга аңлаешсыз латин телендә укыган, тегеләре аны кычкырып кабатлаганнар; ә укучылар яза белгән җирләрдә дәресне балавызлы тактага язып барганнар, аннары, ятлагач, сөртеп ташлаганнар, һәрбер укучыны такта янына чакырганнар, ул шунда белгәннәрен сөйләргә тиеш булган.

Латинча укырга хәрефләр кушу ысулы белән өйрәткәннәр, ә ул механик рәвештә ятлауга нигезләнә, шуңа күрә уку процессы бик авыр булган. Уку материалы булып дини китаплар хезмәт иткән, аларның эчтәлеген балалар аңламаган. Китап басу барлыкка килгәнче төрле кул белән язылган кулъязма китаплардан файдаланганнар, ә бу исә уку техникасын үзләштерүне бик кыенлаштырган. Шулай ук язу техникасы да гаять катлаулы булган.

Укытучы укучыларын хаталары өчен бер дә аямаган: каты тән җәзалары киң таралган булган. Чиркәү дә тән җәзасын хуплаган, ул: **"кеше табигате белән гөнаһлы"**, тән җәзасы җанны коткарырга булыша, **"иблисне куа",** дип өйрәткән.

Түбән мәктәпләргә (башлангыч мәктәпләргә) баштарак католик руханиларының балаларын гына кабул иткәннәр. Ә XI гасырдан, руханиларга никах тыелгач, ул мәктәпләргә шәһәр кешеләре һәм кайбер крестьян балаларын ала башлаганнар. Мәктәпләрдә чиркәү хезмәтчесе яки монах булырга җыенмаганнар да укый башлаган.

Төп халык массасы мәктәпләрдә белем алмаган; ата-аналары балаларны көндәлек хезмәт процессында тәрбияләгәннәр. Гаиләләрдә һәм һөнәрче остаханәләрендә һөнәр өйрәнчеклеге системасы барлыкка килгән. Эшкә өйрәтү һәм эш үзе берьюлы башкарылган: хезмәт күнекмәләре алып, укучылар зур осталык һәм җитезлек күрсәткәннәр.

Монастырьларда һәм собор мәктәпләрендә укыту курсы әкренләп киңәя барган, аларга грамматика, риторика һәм диалектика (дини философия башлангычлары) кертелә, ә кайберләрендә арифметика, геометрия, астрономия һәм музыкага да өйрәтәләр. Шулай итеп, монастырь һәм собор мәктәпләренең бер өлешендә югарырак белем бирелгән. Аның эчтәлеген **"ирекле җиде сәнгать"** тәшкил

иткән. Моннан тыш, "фәннәр таҗы" дип саналган дини тәгълимат укытылган.

Аеруча зур әһәмият грамматикага бирелгән, латин теленең грамматик формаларын өйрәнгәннәр, төрле дини китапларны тикшергәннәр, дини-мистик эчтәлекле аерым грамматик формалар һәм гыйбарәләрне ятлаганнар. Риторика баштарак чиркәү законнары җыентыкларын өйрәнүгә һәм чиркәүләрнең эш кәгазьләрен төзүгә кайтып калган, аннары аңа чиркәү вәгазьләре хәзерләү бурычы йөкләнгән. Укучыларны диалектика дини темаларга бәхәскә әзерләгән, дин кануннарын якларга өйрәткән. Арифметика дәресләрендә укучылар өч гамәл, яисә, сирәгрәк булса да, дүрт гамәл (бүлү гамәле ул чорда бик катлауландырылган булган) белән танышканнар, саннарның мистик мәгънәләрен үзләштергәннәр. Астрономияне белү пасха көннәре билгеләү өчен исәпләүләрдә һәм йолдызлар буенча күрәзәлек итүгә булышкан; музыкага өйрәтү чиркәүдә гыйбадәт кылуга бәйле булган. Уку предметларының һәммәсенә дә дини-мистик төсмер бирелгән.

Асыл зат феодаллар тәрбияләү. Рыцарь балалары — "җир һәм крестьян хуҗалары" — башкача тәрбияләнә, аларда хәрби-физик күнекмәләр, крепостниклар әхлагы, тәкъвалык тәрбиялиләр, "югары җәмгыятьтә" үзләрен ничек тотарга өйрәтәләр.

Рыцарь тәрбиясенең эчтәлеген "җиде рыцарь әхлагы" тәшкил иткән: **атта йөрү, йөзү, сөнге, кылыч һәм калкан тота белү, кылыч ярышы, ау, шахмат уены, шигырь чыгарып аны җырлый белү.** Шахмат уены тырышлык һәм дөрес ориентлашу сәләте тәрбияләү чарасы итеп корылган. Шигырь чыгарып җырлый белү югары җәмгыятьтә аерылып тору, сугышчан батырлыкларны данлау һәм сөйгән ярыңны мактау өчен кирәк булган. Рыцарьга укыйяза белү мәҗбүри булмаган, урта гасырлар башындагы рыцарь катлавының бик күп вәкилләре (графлар, герцоглар) укый-яза белмәгән. Рыцарь балаларын дини хакыйкатьләр белән гадәттә берәр рухани таныштырган.

Феодалларның өлкән уллары 7 яшькә кадәр гаиләдә тәрбияләнгәннәр; 7 яшь тулгач аларны өлкән феодал (сюзерен) замогына, феодал хатынының ярдәмчесе вазифаларын башкарырга җибәргәннәр; 14 яшь тулгач, аларга тантаналы шартларда кылыч тоттырганнар; 14 яшьтән 21 яшькә кадәр алар сюзеренның корал йөртүчесе булганнар, атта йөрергә, корал тотарга өйрәнгәннәр. Яшь егет походларда һәм ауда сюзерен янында булган, рыцарь турнир-

ларында һ. б. катнашкан; 21 яшь тулгач махсус йола буенча аларга рыцарь исеме бирелгән. Күренекле феодалларның башка малайлары гаиләдә калган. Алар анда рыцарь әхлагы күнекмәләре һәм замок капелланыннан дин сабаклары алганнар, кайвакыт уку-язуга өйрәнгәннәр, ә кайберләре, епископ сараена барып, чиркәү хезмәтенә әзерләнгәннәр.

Затлы гаилә кызларының белеме егетләрнекенә караганда югарырак булган. Аларның күбесе монастырьларда махсус уку курслары узган. Кайберләре латин авторларының проза һәм поэзия әсәрләре белән таныш булганнар.

Схоластика. Урта гасырларда университетларның барлыкка килүе һәм үсеше. Цех, гильдия һәм шәһәр мәктәпләре. XII – XIII гасырларда Көнбатыш Европа илләре арасында икътисади элемтәләр ныгый, феодаль йомыклык кими бара, шәһәрләр үсә, аларда һөнәрчелек һәм сәүдә алга китә. Югары җәмгыять мәдәнияте үсә. Хөкем сөрүче дин кагыйдәләренә каршы килә торган дини тәгълиматлар (ересь) барлыкка килә һәм тарала. Динне философия белән ныгыту зарурлыгы, сукырларча ышанмау, әмма ышанган нәрсәңне аңлау зарурлыгы туа. Бу бурычны XII – XIII гасырларда схоластика үз өстенә ала, ул инану һәм акылны, дин һәм фәнне, килештерүне максат итеп куя. **Номинализм** һәм **реализм** теорияләре барлыкка килә. Номинализм теориясе тарафдарлары гомуми төшенчәләр юк, алар бары тик исемнәр, кеше акылының абстракт төшенчәләре генә, дип раслыйлар; реализм юнәлеше вәкилләре исә, киресенчә, гомуми төшенчәләр әйберләрдән дә алданрак яшәгән, диләр. Маркс номинализмны материализмның беренче, әлегә йомшаграк чагышылы дип әйткән. Номинализм белән реализм арасында кискен көрәш бара, динифәлсәфи темаларга диспутлар оештыра. Схоластика ул чорда формаль-логик фикерләүне үстерә, кагып калган дини-фәлсәфи фикерне җанландыра. Әмма соңрак схоластика юкка чыга, еш кына файдасыз фәлсәфә сатуга кайтып кала, алга таба хәрәкәт итүдә киртә була. Мәктәп һәм мәгариф өлкәсендә ул укучыларның еш кына схоластик сорау-җавап формасында бирелгән әзер белгеләмәләрне ятлауларына, мөстәкыйль фикер йөртүдән баш тартуга китерә.

XII гасырда Италия, Франция, Англиядә, аннары башка илләрдә дә **университетлар** ачыла. Урта Европада XIV гасырда Чехиядә (Прагада), бераз соңрак Польшада (Краковта) университет ачыла.

Кагыйдә буларак, урта гасыр университетлары галимнәр инициативасы белән барлыкка киләләр һәм үзидарә хокукыннан файдаланалар, ягъни яшәү тәртипләрен үзләре билгелиләр, хезмәт урынындагы кешеләрне (ректор һ. б.) үзләре сайлап куялар һәм үз хокукларын бик тырышып яклыйлар.

Чиркәү, укытуга монополиясеннән файдаланып, шундук университетларны үзенә буйсындырырга омтыла, аларга төрле өстенлекләр һәм матди ярдәм (бенефицияләр) бирә, үз университетларына нигез сала. Мәсәлән, XII гасырда Париж университетына нигез салына, ул башка католик университетларына үрнәк була. Әкренләп чиркәү университетларга баш булып ала, дини тәгълимат факультеты иң мөһим факультетка әверелә.

Урта гасыр университетларында дүрт факультет була. Әзерлек, ягъни артистлык (сәнгать) факультетында "ирекле җиде сәнгать" укытыла. Урта мәктәп ролен уйнаган бу факультетта 6-7 ел укыгач, аны тәмамлап чыгучылар сәнгать магистры дәрәҗәсен алалар. Аннары төп өч факультетның берәрсендә (дини тәгълимат, медицина яисә юридик факультетта) укуны дәвам иттерү мөмкинлеге бирелә. Анда 5-6 ел укыганнан соң фәннәр докторы исемен алырга була.

Университетта укытуның төп формасы лекция була: профессор китаптан текстны укый һәм шәрехләп бирә. Шулай ук алдан хәбәр ителгән доклад тезислары нигезендә диспутлар оештырыла.

Шәһәрләрдә һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләрне чиркәү мәктәпләре канәгатьләндерми, алар чиркәүнең мәгариф өлкәсендә монополиясенә каршы көрәшәләр.

Һөнәрчеләр үзләренең **цех мәктәпләрен** ачалар, анда аларның балалары туган телләрендә укырга-язарга, хисапка өйрәнәләр, дин сабаклары алалар, һөнәргә исә өйдә, этиләренең остаханәләрендә өйрәнәләр. Купецлар да шундыйрак программалы **гильдия мәктәпләре** ачалар. Бу мәктәпләрдә белем бирү чиркәү мәктәпләрендәгедән шактый аерыла. Әкренләп алар шәһәр үзидарәсе (магистрат) карамагындагы шәһәр башлангыч мәктәпләренә әвереләләр.

Яңарыш чорында (XIV – XVI гасырларда) мәктәп һәм педагогик фикер. Феодаль җәмгыятьтә капиталистик җитештерү ысулының яралгылары барлыкка килү, мануфактура, сәүдә һәм

шәһәрләр үсеше, яңа, ул вакыт өчен прогрессив сыйныф — буржуазия килү — Яңарыш чорының үзенчәлекләре әнә шулар.

Буржуазия феодализм белән көрәштә үз идеологиясен булдыра. Буржуазиянең фәнгә ихтыяҗы була, шуңа күрә ул чордагы фәннең чиркәүгә каршы восстаниесендә катнаша. Яңарыш чорында математика, астрономия, механика, география, табигать белеме зур үсеш ала. Бу төрле өлкәләрдәге бөек ачышлар һәм уйлап табулар чоры була: Европада китап басуга нигез салына, Һиндстанга диңгез юлы һәм Америка ачыла.

Яңарыш чоры эшлеклеләре — **гуманистлар** — алгы планга кеше культын куялар һәм шәхесне коллыкка төшерүче дөньяга — дини карашка каршы нык көрәшәләр. Әмма алар күтәреп чыккан прогрессив таләпләр чикләнгән күләмдәге кешеләргә — җәмгыятьнең югары катлавына гына кагыла. Алар крестьяннарны изүгә каршы чыкмыйлар, крестьяннарның белемгә хокукын якламыйлар, халыкны мәгърифәтле итү турында аз кайгырталар, гади халыкның төп шөгыле физик хезмәт булырга тиеш дип саныйлар.

Гуманистлар асыл сөяк балаларының тулы кыйммәтле физик һәм эстетик тәрбия алуларын, антик әдәбият җәүһәрләрен өйрәнү өчен кирәкле латин һәм грек телләрен белүләрен таләп итәләр.

Белем бирү программасына шулай ук математика, астрономия, механика, табигать белеме кебек табигать фәннәрен кертәләр.

Гуманистлар бала шәхесенә ихтирам белән карыйлар, схоластик укыту һәм каты тәртипләргә каршы чыгалар.

Гуманист педагоглар җитәкчелек иткән мәктәпләрдә уку эчтәлегенә чиркәү йогынтысы аз була, әмма шулай да дин шактый мөһим урын били.

Гуманистларның педагогик карашлары аксөяк һәм бай балалары укыган аерым мәктәпләр практикасында гына чагылыш таба.

Шул ук вакытта шәһәр мәктәпләре дә үсүләрен дәвам итә, ул мәктәпләрдә һөнәрче һәм сәүдәгәр балалары башлангыч белем ала. Кызлар мәктәпләре ачыла (кагыйдә буларак, хосусый мәктәпләр). Шәһәр мәктәпләренең күбесендә уку туган телдә бара. Башлангыч мәктәпләр белән беррәттән, XVI гасырда югары (латин мәктәпләре) һәм урта мәктәпләр (коллегиум, гимназияләр) эшләгән. Хәлле кешеләрнең балалары өчен ачылган бу мәктәпләрдә 8-10 ел укытканнар. Католик чиркәвенә каршы көрәшүче кайбер сектант оешмалары, мәсәлән, Урта Европадагы анабаптистлар, Чехиядәге

таборитлар һ. б., үз секталарына кергән кешеләрнең балалары өчен туган телдә гомуми башлангыч белем бирүне оештырганнар.

Яңарыш чорында педагогик фикер төрле илләрдә төрлечә үскән, чөнки ул һәр илнең үзенә генә хас үзенчәлекләрен чагылдырган.

Мәсәлән, Италиядә антик фәлсәфә белгече гуманист **Витторино да-Фельтре (1378-1446)** "Сөенеч йорты" исемле мәктәп оештыра. Бу мәктәп гуманлы педагогика принципларына нигезләнә.

Мәктәпне табигать кочагындагы менә дигән сарайда ачалар. Бинаны баштанаяк Витторино күрсәтмәләре нигезендә мәктәп ихтыяҗларында махсус рәвештә яңадан җиһазландыралар. Урта гасыр мәктәпләреннән аермалы буларак, яңа мәктәп чиста һавалы, якты була. Укучыларның физик тәрбиясенә аеруча зур игътибар бирелә. Классик телләр һәм классик әдәбият төп укыту предметлары була, укучылар математика, астрономия белән шөгыльләнәләр, табигатькә экскурсияләр ясыйлар. Уенга, кешенең физик һәм рухи көчләрен үстерүгә зур әһәмият бирелә.

Гуманизм идеяләре Италиядән Франциягә дә үтеп керә.

Яңарыш чоры педагогик фикеренең иң күренекле вәкилләреннән берсе француз язучы — гуманисты **Франсуа Рабле (1494-1553)** була. Атаклы **"Гаргантюа һәм Пантагрюэль"** романында ул Урта гасыр схоластик тәрбиясен тасвирлауда үткен сатира алымы куллана, схоластик тәрбиягә гуманистик тәрбияне каршы куя. Гуманистик тәрбия бала өчен яхшы уйланган режим, күпьяклы белем алу, мөстәкыйль фикерләүне, иҗат һәм активлыкны үстерүне күздә тота.

Романның эчтәлеге болай: улы Гаргантюаны тәрбияләү өчен король һәммә нәрсәне ятларга мәҗбүр итүче схоласт галимнәрне чакыра. Гаргантюа кайбер схоластик китапларны баштан ахырына кадәр һәм, киресенчә, ахырыннан башына кадәр сөйли алырлык итеп ятлый, нәтиҗәдә томаналана гына.

Шуннан соң әтисе, схоласт укытучыларны куып чыгарып, гуманист укытучы чакыра. Бу укытучы бөтен нәрсәне кискен үзгәртә. Гаргантюа физик күнегүләргә күп вакыт бирә, фәннәрне дөрес һәм эзлекле үзләштерә башлый. Урман-кырларга чыгып табигатьне күзәтә, үсемлекләрне җыеп гербарий төзи; йолдызларны күзәтеп астрономияне өйрәнә. Укыту күргәзмә әсбаплар кулланып китаплар уку, әңгәмәләр юлы белән алып барыла. Гаргантюа берничә музыкаль инструментта уйнарга, җырларга өйрәнә. Фәннәрне аңлап үзләштерә.

Рабле укытуның күргәзмәлелеге, тормышчанлыгы идеясен яклый. Ул укытуны әйләнә-тирә чынбарлык белән бәйләргә киңәш итә.

Яшь буынны хезмәт эшчәнлеге процессында тәрбияләү фикерен беренче булып инглиз гуманисты Томас Мор (1478-1535) әйтә. Теоретик белем бирүне хезмәт белән берләштерү идеясен дә нәкъ менә ул күтәреп чыга.

"Иң яхшы дәүләт төзелеше һәм Утопия исемле яңа утрау турында файдалы һәм кызыклы алтын китап" дигән әсәрендә (1516) Англиянең гаделсез социаль җәмгыятен кискен тәнкыйтьли һәм аңа Утопия исемле фантастик утраудагы идеаль стройны каршы куя. Ул утрауда хосусый милек булмый. Морның социализмы фәнни түгел, бары хыялый гына була. Мор җәмгыятьнең барлык әгъзаларының ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен дворяннардан, дин әһелләре һәм башка эшлексезләрдән котылу җитә дип исәпли. Шул ук вакытта ул "Утопия"дәге бөтен авыр һәм пычрак эшләрне хәрби колларга һәм үлем җәзасыннан йолынган җинаятьчеләргә йөкли. Болар утопик социализмга нигез салучының карашлары җитлекмәгән һәм тарихи яктан чикләнгән булуын раслый.

Томас Мор тәрбиягә зур әһәмият бирә. Аның сурәтләвенчә, "Утопия" утравында барлык балаларга — малайларга да, кызларга да — бертигез иҗтимагый тәрбия һәм башлангыч белем бирелә; бөтен кеше киң белем ала. Укыту туган телдә алып барыла. Уку һәм язудан тыш, мәктәпләрдә арифметика, геометрия, астрономия, музыка, диалектика, табигать белеме өйрәтелә. Утопиялеләр күргәзмә әсбаплардан киң файдаланалар.

Мор яшь буынны хезмәт эшчәнлегенә әзерләүгә зур игътибар бирә һәм шәхеснең төрле яклап үсеше турында кыйммәтле фикерләр әйтә. Ул болай ди: барлык утопиялеләр дә шөгыльләнергә тиешле бер эш бар, ул да булса — җир эшкәртү. Балалар җир эшкәртү теориясен мәктәпләрдә өйрәнәләр, ә практиканы шәһәр тирәсендәге кырларда үтәләр. Җир эшкәртүдән тыш, һәрбер утопиялегә тагын нинди дә булса махсус һөнәр билгеләнә, һәрбер кеше аны өйрәнергә тиеш була. Физик хезмәт һәрбер утопияле өчен мәҗбүри булса, акыл хезмәте исә иң зур хозурлык санала. Бик аз кешеләр генә, фәкать акыл хезмәте белән шөгыльләнеп, физик хезмәттән азат итәләр. Болар — аерым билгеләнгән җәмәгать йортларында фән белән шөгыльләнүче галимнәр. Ләкин өметне

акламасалар, аларны яңадан һөнәрчелек һәм җир эшкәртүгә кайтаралар.

Буш вакытларын утопиялеләр китапханә һәм музейларда үткәрәләр, бик мавыгып белемнәрен күтәрәләр. Теләүчеләрнең барысына да дәүләт шул китапханә һәм музейлардагы китаплар, приборлар һ. б. файдаланырга тулы хокук бирә. Күп кенә гади гражданнар, үзлекләреннән тирән белем алып, галимлеккә күчереләләр.

Педагогик фикерне үстерүдә **Томас Морның педагогик идеяләре зур әһәмияткә** ия була. Ул гомуми белем бирү принцибын тәкъдим итә, хатын-кызлар һәм ирләрнең бертөрле белем алырга тиешлеген әйтә, үзлегеңнән белем алуны, өлкәннәрне укытуны киң оештыру фикерен күтәреп чыга, хезмәт белән тәрбияләүнең мөһимлеген ассызыклый, акыл һәм физик хезмәт арасындагы каршылыкны бетерү мөмкинлеге турындагы идеяне беренче булып әйтә. Туган телдә укытуны таләп итә, уку предметларының үзәгендә табигать белеме булган киң даирәсен билгели. Мор башлангыч утопик социализм педагогик идеяләренең беренче хәбәрчесе була.

Шулай итеп, феодаль җәмгыять эчендә капиталистик җитештерү ысулы туу һәм үсү тәрбиягә караштa шактый зур үзгәрешләргә китерә. Яңа теорияләр туа. Яңа сыйныфның белем алу ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиешле мәктәпләр дә барлыкка килә.

* * *

Бишенче лекция

МОНОПОЛИСТИК КАПИТАЛИЗМГА КАДӘРГЕ ЧОРДА МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИКА. ЯН АМОС КОМЕНСКИЙНЫҢ ПЕДАГОГИК ТЕОРИЯСЕ

XV – XVII гасырларда халык массаларының феодаль дворяннар һәм феодализмның идеологик терәге булган католик чиркәү белән көрәше кискенләшә. Феодализмга каршы протест еш кына динидемократик, сектантлык хәрәкәте формасын ала.

Шундый демократик сектант оешмалары арасында Чехиядә XV гасырда христиан-коммунистик **таборитлар** общинасы була, общинаның исеме шушы хәрәкәтнең үзәге Табор шәһәреннән алынган. Таборитлар **Чехиядәге гусит милли-дини хәрәкәтенең** төп, плебейлар канаты булып, бу хәрәкәт чех халкын изүче немец дворяннарына һәм католик чиркәүгә каршы юнәлә. Таборитлар әйтүенчә, тиздән "әфәнделәр дә, ялчылар да" булмаячак, бөтен кеше бертигез булачак, шәхси милек бетәчәк, һәммә нәрсә уртак булачак.

Феодаль реакциянең берләштерелгән көчләре XV гасырның беренче яртысында таборитлар общинасын тар-мар итә. Аның калдыкларыннан "чех (богема) туганнар" дигән уртачыл карашлы демократик община оеша, аңа крестьяннар һәм һөнәрчеләр керә. Бу община чех халкының азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшүче патриотларны туплый. Чехларның азатлык хәрәкәте феодализмга каршы Европа халыклары алып барган көрәшнең бер өлеше була. Утыз еллык сугыш чорында (1618-1648) чех протестантлары илләреннән куыла.

"Чех туганнар" общинасының юлбашчыларыннан берсе бөек славян педагогы **Ян Амос Коменский (1592-1670)** була. Ул "чех туганнар" общинасына кергән гаиләдә туа, община акчасына урта һәм югары белем ала, аннары общинаның священнигы итеп сайлап куела һәм аның туганнар мәктәбен җитәкли. **Коменский** немец дворяннары һәм католик чиркәве золымына каршы көрәштә актив катнаша. Утыз еллык сугыш вакытында общинаның башка әгъзалары белән ул да эзәрлекләнә, илен ташлап китәргә мәҗбүр була.

"Чех туганнар"ның бер өлеше килеп урнашкан Польша шәһәре Лешнода **Коменский** туганнар мәктәбен җитәкли, соңрак епископ итеп сайлана. Биредә 1631 елда ул "Телләрнең һәм барлык фәннәрнең ачык ишеге" дигән уку китабы төзи, бу китапта латин телен үзләштерү әйләнә-тирә дөньяны өйрәнү белән бергә бара. Сөргендәге авыр тормыш шартларына да карамастан, **Коменский** бу чорда үзенең атаклы **"Бөек дидактика"** әсәрен яза (1632), бу хезмәт укыту процессы турындагы фәнгә нигез сала. Китап бик күп телләргә тәрҗемә ителә һәм Коменскийны бөтен дөньяга таныта. Шул ук елларда **Коменский** мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбияләү буенча "Ана мәктәбе" дигән дөньяда беренче махсус кулланма яза (1633).

Үзенең күп газаплар чигүче иленә хезмәт итүне Коменский бөтен дөньяга хезмәт итү белән бергә алып барырга тырышкан. Ул төрле яклап социаль үзгәртеп корулар идеясе белән чыккан. Канлы сугышлар һәм каты сәяси һәм дини ызгышлар чорында ул дөньяда тынычлыкны саклауны, сәясәт, фән һәм мәгърифәт өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек урнаштыруны таләп иткән. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм иҗтимагый тормышны яхшырту максатларында дөньяның барлык илләре белән элемтә тотучы универсаль үзәк төзергә тәкъдим итә. **Коменский** "Кешеләрнең эш-гамәлләрен төзәтү турында гомуми киңәш" дигән бик зур хезмәтнең 7 томын яза. (Үзе исән чагында нибары 2 томы дөнья күрә, калганнары 1935 елда гына табыла һәм соңрак Чехословакия Республикасында басылып чыга). Китапта ул гуманлы һәм демократик "**Һәммә кешеләрне һәммә нәрсәдә төрле яклап төзәтү**" программасын билгели.

Аның халыкара элемтәләре бик киң була. Англиядә ул табигать һәм җәмгыять турында бөтен кешегә дә аңлашырлык энциклопедик белемнәр җыелмасы "Пансофия" өстендә эшли.

Мәсхәрәләнгән иленә Швециянең ярдәм итүенә өметләнеп, Коменский шунда яши, телләр укыту методикасы һәм дәреслекләр төзи. Ул шулай ук Венгриядә дә яши, анда мәктәп мәсьәләләре буенча консультант булып эшли. Күп кенә фәлсәфи һәм педагогик әсәрләрен, шул исәптән "Әйберләр дөньясы рәсемнәрдә" дигән гүзәл уку китабын, шунда яза. Бу китап бик күп телләргә тәрҗемә ителә.

1656 елда Швеция — Польша сугышы вакытында "чех туганнар" общинасының соңгы сыену урыны булган. Лешно шәһәре

яндырылгач, Коменский Голландиянең Амстердам шәһәренә килә, шунда 1670 елда вафат була.

Коменскийның дөньяга карашында стихиячел материализм, гуманизм һәм демократизм. Коменскийның әсәрләрендә шул чорның яңа идеяләре тирән чагылыш таба. Шул вакыттагы халык хәрәкәтләреннән, аерым алганда "чех туганнар"дан, Коменский демократизм, хезмәт ияләренә тирән мәхәббәт, дворяннарга һәм католик чиркәвенә тискәре мөнәсәбәт ала. Ул ачу белән: хәзерге стройда берәүләр артыгын ашый, икенче берәүләр исә ачтан интегә, өстәвенә күпчелек авыр хезмәткә дучар ителгән, дип билгеләп үтә. Коменскийның демократлыгы бердәм мәктәп булдыруны, нинди катлаудан булуларына, байлыкларына һәм җенесләренә карамастан туган телдә гомуми мәҗбүри белем бирүне таләп итүендә күренә.

Коменскийның дөньяга карашындагы күп кенә сыйфатлар Яңарыш чоры мәдәнияте йогынтысында барлыкка килә. Яңарыш чорыннан ул гуманизм, көр күңеллелек, оптимизм кебек сыйфатлар ала. Урта гасырлардагы караңгы суфыйлыкка, кеше табигатенең гөнаһлылыгы турында чиркәү өйрәтүләренә каршы буларак, Коменский: кеше — иң камил, иң гүзәл җан иясе, "гаҗәеп микрокосм", — дип өйрәтә. Коменский әйтүенчә, "табигать җитәкчелегендә кеше һәммә нәрсәгә ирешә ала". Кеше — тән һәм җан гармониясе ул. Мәктәпне Коменский "гуманлылык остаханәсе" дип саный.

Яңарыш чоры гуманист педагогларыннан аермалы буларак, Коменский тәрбия системасын аерым кешеләре, җәмгыятьнең аксөяк югары катлавы өчен түгел, ә халыкның демократик катлаулары, халык массасы өчен иҗат итә.

Коменский дидактикасының төп идеяләр сенсуалистик характерда: чынбарлык дөньяны тоеп белү нигезендә танып белү, реализм, күргәзмәлелек принцибы. Коменский раславынча, "интеллектта элек сиземләүләрдә булмаган берни дә юк". Бу Бэконның сенсуалистик фәлсәфәсенә туры килә, ә ул **инглиз материализмына** һәм **хәзерге заманның тәҗрибәләр ясаучы** фәненә чын нигез салучы була. Коменский Бэконның "Фәннәрне бөек торгызу" әсәрен фәлсәфәнең туып килүче яңа гасырындагы иң якты әсәр дип атый. Бэконның индуктив методында ул "табигать серләренә үтеп керү" юлын күрә.

Коменский барлык балаларны да — баймы ул, ярлымы, аксөяк-ләр нәселеннәнме, гади нәселдәнме, малаймы ул, кызмы, шәһәрдә яшиме, авылдамы — туган телләрендә укытуны таләп итә. Башкача әйткәндә, Коменский гомуми башлангыч белем бирү идеясен күтәреп чыга. Аның "ярлылар арасында еш кына гаҗәп сәләтле кешеләрнең күренми калып юкка чыгуларына" ачуы кабара.

Коменскийның дөньяга карашларында, бер яктан, стихиячел материализм, реализм элементлары, тормышка, тәҗрибәгә таяну омтылышы, икенче яктан, динилек бергә үрелеп бара. Аныңча, дөнья — "ходай иҗаты", танып белү — "һәммә нәрсәдән ходайны эзләү". Фани дөньяны Коменский бакый дөньяга әзерлек кенә дип саный һәм тәрбиянең максатын шунда күрә. Дөньяга карашындагы шушындый капма-каршылык аның педагогикасында да чагылыш таба.

Коменский фикеренчә, **тәрбиянең** өч баскычы, өч бурычы бар: үз-үзеңне һәм әйләнә-тирә дөньяны танып белү (акыл тәрбиясе), үз-үзеңне идарә итү (әхлакый тәрбия) һәм аллага омтылу (дини тәрбия). Урта гасыр педагогларыннан аермасы буларак, ул беренче бурычны хәл итү бик мөһим дип санаган.

Коменский тәрбиянең ролен бик югары бәяли. Кеше — тәрбияләнгәнгә күрә генә кеше була, ә тәрбияләү өчен иң кулай вакыт — балачак, ди ул. Аныңча, "теләсә нинди баланы чын кеше итәргә мөмкин". Сәләтле, тырыш һәм педагог йогынтысына тиз бирелүчән балалар белән беррәттән, бик аз гына булса да сәләтсез, ялкау һәм кире балалар да бар, әмма аларын да тәрбияләргә һәм укытырга кирәк, дип исәпли.

Коменскийның бөтен педагогик әсәрләрендә, аеруча төп иҗаты булган "Бөек дидактика" әсәре аша кызыл җеп булып дөрес тәрбия һәр очракта да табигать белән ярашырга тиеш дигән фикер уза.

Тәрбиянең табигатькә муафыйклыгы принцибы, Коменскийдан башлап, XVIII, XIX гасырлар педагогик системаларында еш очрый, шуның белән бергә атаклы педагогика теоретикларының һәрберсе (**Коменский, Руссо, Песталоцци**, **Дистервег һ. б.)** бу принципны үзенчә аңлый.

Коменский, **табигатьнең бер өлеше буларак кеше аның төп, гомуми законнарына буйсына, бу законнар үсемлек һәм хай-ваннар дөньясында да, шулай ук кешегә мөнәсәбәттә дә гамәл-дә,** дип исәпли. Аныңча, "мәктәпнең төгәл тәртибен табигатьтән алырга кирәк", "табигать гамәлләрендә күренә торган процесслар-

ны" күзәтүдән чыгып эш итәргә кирәк. Ул тәрбия закончалыкларын табигать законнарына охшатып билгеләргә тиеш. Коменскийның дөрес дидактик фикерләрен аның бәян итү формасыннан аера белергә кирәк.

Коменский үзенең тәрбия һәм укыту өлкәсендәге тирән гомумиләштерүләренә җәмгыять тормышын, тәрбия тормышын күзәтүләрдән, педагогик тәҗрибәдән чыгып килгән. Үзенең укытучылык эшчәнлеге һәм чорның алдынгы педагогик тәҗрибәсе нигезендә Коменскийда "Бөек дидактика" әсәрендә чагылыш тапкан тирән теоретик фикерләр туа һәм формалаша. Педагогик тәҗрибәсен ул фәлсәфи яктан нигезли. Элек һәрбер педагогик положениене дини дәлилләр, гадәттә, изге язмалардан алынган өзекләр белән нигезләгәннәр.

Коменский, бу иске ысулдан һич кенә дә баш тартмыйча, дәлилләүнең Яңарыш чоры алып килгән яңа ысулын — табигатькә таянуны кертә һәм табигать белән тәрбиянең гомуми закончалыкларын формалаштырырга тырыша.

Табигать законнары турында сөйләгәндә, ул табигатьне ходай иҗаты дип саный. Хәер, мондый тарихи чикләнгәнлек ул чорның барлык галимнәренә, хәтта чиркәү тәгълиматларын кире кагучы, табигатьнең төрле өлкәләрендәге чын законнарны ачучыларына да, хас була.

Тәрбиянең табигатькә муафыйклыгы принцибының табигатьнең гомуми законнарына иярү икәнлеген аңлау белән бергә, Коменский яшь чорларына бүлү, мәктәп системасын һәм кайбер дидактик принциплар һәм кагыйдәләрне нигезләгәндә кешенең табигатенә (тумыштан килгән сыйфатларга) һәм балаларның табигый яшь үзенчәлекләренә таяна.

Яшь чорларына бүлү. Мәктәпләр системасы һәм укытуның эчтәлеге. Коменский, кешенең табигатеннән чыгып, үсеп килүче буынны дүрт яшь чорына бүлә, аларның һәрберсе алтышар ел:

- балалык чоры — туганнан алып 6 яшькә кадәр,

- үсмерлек чоры — 6 яшьтән 12 яшькә кадәр,

- яшьлек чоры — 12 яшьтән 18 яшькә кадәр,

- балигълык чоры — 18 яшьтән 24 яшькә кадәр.

Бу бүленешнең нигезенә ул яшь үзенчәлекләрен куя: балалык чорында буй һәм сизу органнары яхшы үсә; үсмерлек чорында хәтер һәм хыял, шулай ук аларның башкаручы органнары – тел һәм кул үсеш ала; яшьлек чоры, күрсәтелгән сыйфатлардан тыш,

фикерләү ("аңлау һәм хөкем йөртү") үсешенең югарырак дәрәҗәсе белән характерлана; балигълык чорында ихтыяр һәм гармония саклау сәләте үсә.

Бу яшь чорларының һәрберсе өчен, яшь үзенчәлекләреннән (баланың табигатеннән) чыгып, **Коменский белем алуның аерым баскычларын билгели.**

6 яшькә кадәрге балалар өчен ул әниләр мәктәбе тәкъдим итә, биредә ана җитәкчелегендәге мәктәпкәчә тәрбия күздә тотыла. Үсмерлек чорына (ягъни 6 яшьтән 12 яшькә кадәрге балалар өчен) һәр общинада, авылда алты еллык **туган тел мәктәбе** каралган. Яшьләргә (12 яшьтән 18 яшькә кадәр) һәр шәһәрдә **латин мәктәбе**, яисә **гимназия** булырга тиеш. Балигъ булган яшьләргә (18 яшьтән 24 яшькә кадәр) һәрбер дәүләттә, яисә зур өлкәдә **академия** ачуны күздә тота.

Һәр алдагы баскыч үткәннең дәвамы булып тора. Шул рәвешле, Коменский **бердәм мәктәп демократик принцибын күтәреп чыга.**

Академиядән кала һәр баскыч өчен Коменский укыту эчтәлеген җентекләп эшли. **Әниләр мәктәбе**, балаларның табигый үзенчәлекләрен исәпкә алып, алты яшькә кадәр балаларга безне чолгап алган табигать һәм җәмгыять тормышы турында башлангыч мәгълүматлар, җанлы тәэсирләр бирергә тиеш. Балалар табигать белеме өлкәсеннән су, җир, һава, ут, яңгыр, кар, боз, таш, тимер, агач, үлән, балык, кош, үгез һ. б. боларның нәрсә икәнлеген белергә тиеш. Бала астрономиядән нәрсәнең һава, кояш, ай, йолдыз дип аталуын, аларның кайда чыгып кайда батуын белә. Шулай ук ул географиядән дә башлангыч мәгълүмат ала (тау, үзән, елга, авыл, шәһәр һ. б.).

Коменский балаларны бик кечкенәдән хуҗалык алып барырга, хезмәткә өйрәтергә, моның өчен аларны йорт кирәк-яраклары һәм аларның кулланылышы белән таныштырырга киңәш итә. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның әхлак тәрбиясе, ди ул, аларда чама хисе, пөхтәлек, эш сөючәнлек, өлкәннәргә ихтирам, тыңлаучанлык, туры сүзлелек, гаделлек һәм, иң мөһиме, кешеләрне ярату хисе тәрбияләүдән гыйбарәт.

Коменскийның иң зур хезмәте шунда ки, ул мәктәпкәчә тәрбия буенча "Әниләр мәктәбе" дигән дөньяда беренче кулланма эшли.

Туган тел мәктәбе, Коменский фикеренчә, алты еллык булырга тиеш. Анда, нинди катлаудан, нинди милләттән булуларына һәм

нинди дин тотуларына карамастан, малайлар да, кызлар да белем алсын.

Ул заманнардагы башлангыч мәктәпләр ике-өч еллык кына булган, анда догалар ятлау, уку, язу һәм иң гади исәп-хисапка өйрәтү белән чикләнгәннәр. Коменскийның бик зур хезмәте шунда: ул **башлангыч мәктәпнең әһәмиятен күтәргән,** ягъни укуның вакытын арттырган, аның туган тел мәктәбе булуына басым ясаган (ә руханилар кулындагы чиркәү мәктәпләрендә балаларга аңлаешсыз латин телендә укытканнар), башлангыч мәктәптә укыту эчтәлеген геометрия, география, табигать белеменнән башлангыч мәгълүматлар бирү, җыр һәм хезмәт укыту белән киңәйтелгән. Әлбәттә, дин сабагына зур урын биргән.

Латин мәктәбендә (гимназиядә) укыту эчтәлеген Коменский шул чордагы урта мәктәптә укыту предметлары даирәсеннән алган: бу "ирекле җиде сәнгать". Әмма шул чордагы схоластик мәктәпнең шушы фәннәренә ул яңа уку предметлары өсти. Болар: физика (табигать белеме ул чагында шулай атала), география, тарих. Гимназиядә латин, грек телләре, туган тел һәм тагын берәр яңа тел укытыла.

Коменский: телне (грамматиканы) өйрәнгәннән соң укучылар табигать белеме (физика), математика, аннары этика, диалектика кебек фәлсәфи фәннәрне өйрәнүгә күчәргә, ә уку курсын риторика өйрәнү белән тәмамларга тиеш, чөнки шушы эзлеклелектә сөйләмнең матурлыгы өстенә эчтәлеклелек һәм тирәнлек тә өстәлә, дип саный. Мәктәп системасындагы гимназиянең алты классының һәрберсенең үз исеме була: грамматика, физика, математика, этика, диалектика һәм риторика класслары.

Фәннәрне ул чор өчен гадәти булмаган шушы эзлеклелектә куюы белән Коменский үзенең фәлсәфи карашларыннан — сенсуализмнан чыгып эш итә, шул заманның новаторы була, әмма бер фәнне (яисә үзара якын берничә фәнне) бер вакытта укыту, аннары гына башка фәннәрне өйрәнүгә күчү ягында була. (XVIII гасыр азагында бер үк вакытта төрле предметлар укытыла башлый. Хәзерге уку планнары шушы принципның алга таба үстерелеше булып тора).

Академиядә Коменский дини тәгълимат, юридик һәм медицина кебек, ул чор өчен гадәти факультет булырга тиеш дип саный.

Коменскийның дидактик карашлары. Сенсуалистик фәлсәфәгә ияреп, Коменский танып белү һәм уку нигезенә тоеп белү тәҗрибә-

сен куя, **күрсәтмәлелек принцибын** теоретик яктан нигезли һәм җентекләп ачып бирә. Күрсәтмәлелек аңа кадәр дә кулланылган. Аның хакында гуманист педагоглар да, мәсәлән, "Утопия" утравындагы укытуны тасвирлаганда Томас Мор да әйткән булган. Кулъязма китапларда да, басма китапларда да рәсемнәр элек тә булган, әмма бу күрсәтмәлелек Коменский биргән теоретик нигезләрдән башка гына, тәҗрибәгә таянып кына кулланылган. Коменский күрсәтмәлелекне киң мәгънәсендә, күрү органнарын гына түгел, ә тою, сизү органнарының барысын да әйберләр һәм күренешләрне яхшырак, ачыграк тоюда эшкә җигү дип аңлый. Ул дидактиканың "алтын кагыйдәсен" игълан итә: "Мөмкин булган һәммә нәрсәне хис-тойгы белән: күренә торганны — күз белән; ишетелә торганны колак белән; исләрне — борын белән; тәмне — авыз белән; сизеп тоя торганны — капшау юлы белән сиземләп тою мөмкинлеге бирелергә тиеш. Нинди дә булса предметларны берьюлы берничә төрле тойгы белән сиземләп тоеп була икән, аларны берничә тойгы эләктереп алсын".

Коменский укытуны әйберләр турында сүз сөйләүдән түгел, ә аларны конкрет күзәтүдән башлауны таләп иткән. Мөмкин булган һәрнәрсәне табигый хәлендә күзәтергә кирәк, ә турыдан-туры күзәтү мөмкин булмаганда әйберләрне картина, модель, рәсемнәр алыштыра.

Иң мөһим дидактик принципларның берсе буларак күрсәтмәлелекне эшкәртүдә Коменский зур хезмәт куя: күрсәтмәле укытуның инде шул чорда булган беркадәр тәҗрибәсен нигезли, гомумиләштерә, тирәнәйтә, киңәйтә, үзенең дәреслекләрен рәсемнәр белән баетып, күрсәтмәлелекне гамәлдә киң куллана.

Реаль дөньяны тәҗрибә аша өйрәнергә чакырып, Коменский "яшьләрнең башына сүз, фикер боткасы тутыручы" схоластик укытуны тәнкыйтьли, "схоластика чытырманлыгыннан чыгарга" (аның бер хезмәтенең исеме шундый) чакыра.

Мәгънәсез, механик ятлауга каршы Коменский аңлы уку таләбен куя. Ул болай дип яза: "Акыл белән яхшы аңланмаган бернәрсәне дә ятлатырга ярамый". Укучылар "укыганнарының көндәлек тормышта нинди файда китерүен укытучы ярдәмендә ачык аңларга тиешләр. Күренешләрне өйрәнгәндә укучыларны бу күренешләрнең сәбәбен аңлауга китерергә кирәк. "Һәрбер предметны тәмам аңлап бетерми торып өйрәнүдән туктамаска кирәк", ("тәмам аңлап бетергәнче өйрәнергә кирәк").

Коменский **укытуның системалылыгын** яклый. Укучыларга күренешләр арасындагы бәйләнешне аңлауга китерү һәм уку материалын балаларга тәртипсез рәвештә түгел, ә төп положениеләр рәвешендә кыскача гына итеп бирү зарурлыгына күрсәтә. Укытуда, ди ул, фактлардан һәм мисаллардан аларны системалаштыручы нәтиҗәләргә һәм кагыйдәләргә килергә кирәк; конкреттан — абстрактка, җиңелдән — авырга, гомумидан — өлешкә килергә; башка предмет яисә күренеш турында гомуми күзаллау бирергә, аннары аның аерым якларын өйрәнүгә күчәргә кирәк, ди.

Коменский фикеренчә, **укытуның эзлеклелеге** зур әһәмияткә ия. Укучыларга үзләштерергә тәкъдим ителгән материалны шундый итеп бирергә кирәк, ул инде яңа материалны өйрәнүгә әзерлек булсын. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, Коменский башта аларның хис-тойгыларын, аннары хәтерләрен, фикерләүләрен һәм, ниһаять, сөйләмнәрен һәм кулларын үстерергә киңәш итә, чөнки укучы үзләштергәнен дөрес сөйләп бирә һәм эштә куллана белергә тиеш.

Коменский, укыту **балалар көче җитәрлек** булырга тиеш, дигән дидактик таләп белән чыга. Балалар үзләштерәсе материал аларның яшь үзенчәлекләренә туры килергә тиеш. Укытуның көч җитәрлек, аңлаешлы булуына ачык аңлату, төп фикерне сырлап-бизәкләп тормый җиткерү белән ирешелә.

Укучыларның материалны **нык үзләштерүләре** дидактик таләбен күтәреп, Коменский "ныклы нигез" салу зарурлыгын, укытканда ашыгу ярамавын, укучыларның материалны әйбәтләп үзләштерүләренә ирешү кирәклеген искәртә; бер-берсенә бәйләү мөмкинлеге булган предметлар "бәйләнештә" укытылырга тиеш. Һәр темага кыска, төгәл кагыйдәләр ярдәмендә йомгак ясалырга тиеш.

Яңа материалны яхшылап үзләштерүдә күнегүләрнең һәм үткән материалны кабатлауның әһәмияте гаять зур. Укытучы, яңа материалны аңлаткач, берәр укучыны такта янына чыгарып, әле генә сөйләгәннәрен кабатлата; шуны ук эшләү өчен тагын бер укучыны чыгара. Шундый күнегүләр һәм кабатлаулар ярдәмендә укытучы үзе сөйләгәннәрдән балаларның нәрсәне аңламаганлыкларын бик ачык күрә. Берничә тапкыр кабатланган материал хәтердә бик нык кала. Шулай кычкырып кабатлаганда үзләштергән материалыңны сөйләп бирү күнекмәсен үстерүнең әһәмияте бик зур, үзләштерү үзе дә аныграк, ныграк була. Коменский бу максатта укучыларга үзләштергән материалны башкаларга да аңлатырга тәкъдим итә.

"Эшлисе эшне эшләп карап өйрәнергә кирәк",— ди Коменский, күнегүләр оештыру кагыйдәләрен биреп. "Мәктәпләрдә язу осталыгына — язып, сөйләү осталыгына — сөйләп, җырлау осталыгына — җырлап, нәтиҗә чыгару осталыгына — нәтиҗә чыгарып һ. б. өйрәнсеннәр, мәктәп — эш кайнап торган остаханә булырга тиеш". Күнекмәләргә дөрес өйрәтү өчен укучыларга башкарылырга тиешле эшнең билгеле бер формасын һәм нормасын бирү тиеш; инструментларны ничек куллану (мәсәлән, сызым сызганда һ. б.) турында сөйләп кенә калмаска, ә эштә кулланып күрсәтергә кирәк. Күнегүләрне тулы эш башкарудан түгел, ә кечкенә элементлардан башларга кирәк; бу укуга да (башта — хәрефләр һәм иҗекләр, аннары — сүзләр, иң ахырдан — җөмләләр), язуга да, грамматикага да, башка күнекмәләргә дә кагыла.

Балаларга охшату үрнәген күрсәтеп, укытучы башта формага төгәл охшатуны таләп итәргә тиеш, соңыннан бу эш ирекләрәк башкарылырга мөмкин. Укучылар җибәргән барлык төгәлсезлекләрне укытучы шунда ук төзәтә, кагыйдәләргә таянып искәрмәләр ясый. Укытканда синтез анализ белән берләштерелергә тиеш.

Коменский укучыларның **танып белү сәләтләрен** мөмкин кадәр ныграк **үстерергә**, "белемгә сусау һәм укуга кайнар дәрт кабызырга" омтылган, моның өчен, дигән ул, күңелле нәрсә белән файдалы нәрсәне берләштерергә, балаларның кызыксынучанлыгын хупларга кирәк. "Укучыларымда мин һәрвакыт күзәтүдә, сөйләмдә, практикада һәм кулланылышта мөстәкыйльлек үстерәм",— зип язган ул.

Мәктәптә укытуны оештыру. Класс-дәрес системасы. Коменский чирекләргә бүленгән уку елы, каникул төшенчәсен гамәлгә керткән, уку көнен оештыруны билгеләгән (туган тел мәктәбендә I уку сәгате, латин мәктәбендә 6 сәгать), укытуның класс-дәрес системасын теоретик эшкәртеп гамәлдә кулланган.

Ул чорда укучыларны мәктәпкә төрле вакытта, бөтен ел буена кабул иткәннәр. Укучылар класста бергә утырсалар да, күпчелек очракта аларның барысы белән берьюлы күмәк дәресләр уздырылмаган: һәр укучы үзенә бирелгәнне аерым өйрәнгән, һәр укучының шәхси уку-өлгерү тизлеге булган. Укытучы һәр укучы белән аерым шөгыльләнгән. Коменский мәктәпкә укучыларны елына бер тапкыр гына кабул итүне, укытучының бөтен класс белән күмәк эш алып баруын яклаган. Ул укытуда класс-дәрес системасына нигез салган, дәресләрне планлаштыру һәм алып бару буенча күрсәтмә-

ләр биргән, дәреснең бер өлеше — укучылардан сорауга, икенче өлеше яңа материалны аңлатуга һәм шул материалны хәтердә ныгыту күнегүләренә бирелергә тиеш дигән. Аныңча, һәр дәреснең аерым темасы һәм төп бурычы булырга тиеш. Укытучы барлык укучыларның да дәресләрдә актив катнашуларын игътибар белән күзәтергә һәм дәрес вакытында класста тәртип сакларга тиеш.

Коменский төзегән дәреслекләр. Коменский дәреслекнең нинди булырга тиешлеге хакында күп кенә файдалы теоретик фикерләр әйткән, шул чор өчен үрнәк булырдай берничә дәреслек төзеп, үзенең теоретик положениеләрен гамәлгә ашырган. Ул, дәреслектә уку материалы җитәрлек дәрәҗәдә тулы, ләкин дәреслек үзе кыска булырга тиеш, анда игътибарны төп нәрсәдән читкә юнәлтерлек артык детальләр булмасын, дип таләп итә. Дәреслектә материал системалы урнаштырылып, балаларга аңлаешлы, ачык, гади телдә язылган булырга тиеш.

Коменский төзегән дәреслекләрдән икесе — "Телләрнең һәм барлык фәннәрнең ачык ишеге" (1631) һәм "Әйберләр дөньясы рәсемнәрдә" (1658) — аеруча киң таныла.

Бу дәреслекләрнең беренчесендә Коменский, үзенең дидактик принципларына туры килгән һәм әкренләп катлаулана барган җөмләләр (фразалар) сайлап, бер үк вакытта тел дәреслеге дә, баланы төрле өлкәләрдән ул аңларлык белемнәр белән таныштыручы китап та бирә.

Икенче дәреслек ("Әйберләр дөньясы рәсемнәрдә") үзенә күрә балалар өчен рәсемнәр белән бизәлгән башлангыч белемнәр энциклопедиясен тәшкил итә, һәрберсе рәсемле 150 кыска мәкаләдә табигать (галәм, географиядән мәгълүматлар, үсемлекләр, хайваннар, кеше тәне турында) кеше эшчәнлеге (һөнәрләр, авыл хуҗалыгы, транспорт, мәдәният һ. б.), иҗтимагый тормыш (дәүләт идарәсе, суд) турында мәгълүматлар бирелә. Шул ук вакытта зур педагогик осталык белән укучыларның сөйләме дә баетыла: дәреслек туган тел һәм латин теленнән мәгълүматлар бирә.

Китап бик күп телләрдә тәрҗемә ителә һәм 150 елдан артыграк башлангыч белем бирүдә яхшы дәреслек хезмәтен үти. XVIII гасырның икенче яртысында бераз эшкәртелеп төрле исемнәр белән ("Күренеп торган яктылык", "Галәм тамашасы") берничә тапкыр Россиядә басылып чыга. Бөек немец шагыйре Гете XIX гасыр башында аны үзе шуннан белем алган үрнәк уку китабы буларак искә ала.

Әхлак тәрбиясе. Тәртип мәсьәләсе. Кешенең үзен идарә итүе, Коменский фикеренчә, тәрбиянең өч максатыннан берсе. Аңа әхлак тәрбиясе нигезендә ирешелә.

Платон һәм Аристотельгә ияреп, Коменский төп, кардиналь яхшылык дип акылны, чама хисен, батырлык һәм гаделлекне санаган. Әйберләр турында дөрес хөкем — игелекнең нигезе, шуңа күрә акыл — игелекле, тормышның җитәкчесе. Чама хисе кешегә һәр нәрсәдә чама белү өчен, беркайчан да күңел бирү, күңел кайтуга кадәр барып җитмәс өчен кирәк. Батырлыкка үз-үзеңне тота алу, чыдамлык, кирәк булганда файда китерергә әзер тору, бурычыңны үтәү кебек сыйфатлар керә.

Шуңа төп яхшылыклардан тыш, Коменский балаларда тыйнаклык, тыңлаучанлык, киң күңеллелек, җыйнаклык, пөхтәлек, итәгатьлелек, өлкәннәргә ихтирамлылык, хезмәт сөючәнлек тәрбияләргә киңәш иткән.

Әхлакый тәрбия чаралары итеп Коменский түбәндәгеләрне санаган: ата-ана, укытучылар, иптәшләренең үрнәге; үгет-нәсихәт, балалар белән әңгәмәләр; балаларның әхлаклы тоту күнегүләре (мәсәлән, батырлык тәрбияләгәндә); бозыклык, ялкаулык, уйлап эш итмәү, тәртипсезлек белән көрәш. Әхлакый тәрбия процессында әйбәт гадәтләр булдыруның әһәмияте бик зур.

Дисциплинаның әһәмиятенә күрсәтеп, Коменский "Дисциплинасыз мәктәп — сусыз тегермән белән бер" дигән чех мәкален китерә. Коменскийның бик зур хезмәте шунда, ул урта гасыр мәктәбендәге таяк дисциплинасына каршы чыга, балаларга кешелекле мөнәсәбәт күрсәтергә чакыра, әмма шул ук вакытта укытучының балалар арасында тиешле дисциплинаны да саклавын таләп итә. Тәртипне күбрәк "яхшы үрнәк, ягымлы сүз, һәрчак ихлас һәм ачыктан-ачык әйбәт мөнәсәбәт белән" сакларга кирәк, ди ул.

Коменский, балаларга тән җәзасы бирүгә кискен каршы чыга. "Чыбык һәм таяк — ирекле кешеләр өчен бөтенләй дә яраксыз коллык кораллары, аларга мәктәптә гомумән урын булмаска тиеш, алар мәктәптән куылырга тиеш, мин катгый рәвештә шуны таләп итәм". Әмма аның икеләнүе тән җәзасы мәсьәләсендә дә күренә: ул укуда начар өлгергән өчен тән җәзасы куллануны катгый кире кага, ләкин укучы көферлек күрсәткән, яисә киреләнгән очракта рөхсәт итә.

"Яхшы оештырылган мәктәп законнары" дигән кечкенә генә әсәрендә Коменский кыска гына кагыйдәләр рәвешендә мәктәп режимын дөрес оештыру, мәктәпне идарә итү, укытучыларның

вазыйфалары, укучыларның үз-үзләрен тотышына кагылышлы бик күп файдалы күрсәтмәләр бирә.

Кагыйдәләрдә җентекләп укучыларның белемен исәпкә алу тәртибе һәм ысуллары билгеләнгән: кизүчеләр көн саен барлык укучыларның да белемен тикшерә; укытучы һәр дәрестә берничә укучының белемен тикшерә; мәктәпнең ректоры айга бер тапкыр сынау юлы белән өлгерешне тикшерә. Сынаулар шулай ук һәр чирек азагында үткәрелә, ә уку елы беткәч, класстан класска күчерү имтиханнары була.

Укучылар мәктәпкә соңга калмый килергә һәм билгеләнгән урыннарына утырырга тиеш. Ниндидер сәбәп белән укучы дәрескә килә алмаса, әти-әниләре бу хакта кизүчегә хәбәр итәргә тиеш, кизүче исә укытучыга әйтә. Дәресләрдә укучылар укытучы сөйләгәнне игътибар белән тыңларга тиеш. Укучылар мәктәптән тыш та үзләрен тыйнак һәм әдәпле тотарга тиешләр. Коменский болай дип яза: "Тәртипне көлү яисә нәфрәт уятырлык шаяртып яки ачу белән түгел, ә курку һәм ихтирам уятырлык җитдилек белән сакларга кирәк. Шулай булгач, яшьләр белән җитәкчелек иткәндә — җитди сабырлык, шелтәләгәндә — мәсхәрәсез кисәтү, җәза биргәндә — рәхимле таләпчәнлек булырга тиеш".

Укытучының роле һәм аңа таләпләр. Коменский укытучыга бик зур әһәмият биргән, укытучылык эшен бик мактаулы, "җир йөзендәге һәммә профессияләрдән өстен", дип санаган. Бу укытучыга карата яңа, прогрессив караш була, чөнки элегрәк укытучы эшен, аеруча башлангыч мәктәп укытучысының эшен ихтирам итмәгәннәр. Коменский, бер яктан, халыкның укытучыны ихтирам итүен, икенче яктан, укытучының, җәмгыятьтә нинди мөһим функция башкаруын аңлап, үз дәрәҗәсен саклавын таләп иткән. Укытучы, дип язган ул, намуслы, эшлекле, үз дигәнендә нык торучан, игелеклелекнең үрнәге булырга, шул сыйфатларны укучыларына да сеңдерергә, белемле һәм эш сөючән булырга тиеш. Эшен чиксез яратырга, укучыларын аталарча кайгыртырга, аларда белем алу омтылышы уятырга тиеш. "Укытучы иң әүвәл укучыларын үз үрнәгенә ияртү хәстәрен күрергә тиеш". Укытучының динлелеген Коменский иң мөһим сыйфатларның берсе дип санаган.

Коменскийның педагогик теориясенең аннан соңгы гасырларда педагогиканы һәм мәктәп практикасын үстерүдәге әһәмияте. Ян Амос Коменский бөтен дөньяда педагогик фикер һәм мәктәп үсешенә бик зур йогынты ясаган. Аны мәктәп эшен ях-

шырту өчен төрле илләргә (Англия, Швеция, Венгриягә һ. б.) чакырганнар. Төрле телләргә тәрҗемә ителгән дәреслекләре бик күп илләрдә, шул исәптән XVIII һәм XIX гасырларда Россиядә дә, киң таралган, алар 150 елдан артыграк башлангыч белем бирүдә иң яхшы уку китапларыннан исәпләнгәннәр һәм башка алдынгы педагоглар өчен дәреслек язу үрнәге булып хезмәт иткәннәр.

Бөек рус педагогы К. Д. Ушинский XIX гасырның 60 нчы елларында болай дип яза: фәнне балалар өчен яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып педагогик бәян итүнең башлангычы итеп "без инде Корениусның "Әйберләр дөньясы рәсемнәрдә"сен саный алабыз".

Коменский дидактика өлкәсендә уку эшен оештыруның бик күп тирән, прогрессив дидактик идея, принцип һәм кагыйдәләрен (уку елы, каникуллар: уку елын чирекләргә бүлү, балаларны мәктәпкә бер генә вакытта — көз көне алу, сыйныф-дәрес системасы, укучыларның белемнәрен исәпкә алу, уку көненең озынлыгы һ. б. ш.) тәкъдим итүче новатор булган. Аның бу мәсьәләләргә караган тәкъдимнәре әле дә булса тулаем алганда төрле илләр мәктәпләрендә кулланыла.

Педагогиканы үстерүдә Коменский, Лейбниц фикеренчә, философияне үстерүдә Декарт һәм Бэкон, астрономияне үстерүдә Коперник кебек үк роль уйнаган. Шуның белән бергә аның педагогика өлкәсендә тәкъдим иткән яңалыклары (гомуми белем бирү, бердәм мәктәп, башлангыч мәктәптә алты ел укыту идеяләре, кайбер башка дидактик принциплар һәм кагыйдәләр) бик әкрен юл ярган. Бөек педагогның алдан күреп әйткән бик күп идеяләре, хыяллары 200-250 елдан соң гына (анда да чикләнгән күләмдә) мәктәп практикасына кертелә.

XIX гасырның икенче яртысыннан башлап, прогрессив педагоглар Коменскийның әһәмиятен торган саен ныграк аңлый башлыйлар (аеруча славян илләрендә һәм Россиядә).

Коменскийның педагогик теориясе чех халкының милли азатлык хәрәкәте, шулай ук Европа халыкларының феодализмга каршы көрәше нәтиҗәсендә туа. Фәнни характердагы бу теория дөнья мәдәниятенә зур өлеш булып керә.

* * *

Алтынчы лекция

ДЖОН ЛОККНЫҢ ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ

Локкның социаль-сәяси һәм фәлсәфи карашлары. XVII гасырда Англия промышленность перевороты өчен җирлек әзерләгән буржуаз революция кичерә. Бу яңа заман, буржуазия хакимлеге заманы җитүен хәбәр итүче революция иде.

Анда буржуазия дворяннарның буржуаллашкан өлеше белән союзда чыгыш ясый, ул революциянең характерлы үзенчәлеге шунда була.

1688 елда сыйнфый компромисс — шушы ике социаль группа арасындагы килешү нәтиҗәсендә король тәхеттән төшерелде дип игълан ителә һәм аның урынына принц Вильгельм Оранский чакырыла. Оранский илнең буржуаз үсешен гарантияләүче "Хокуклар декларациясен" кабул итә. Маркс әйтүенчә, (данлы революция) Вильгельм III Оранский белән берлектә властька җиңел табыш артыннан куучы җирбиләүче һәм капиталистларны куя".

Энгельс сүзләре белән әйткәндә, Джон Локк "1688 елгы сыйнфый компромисс баласы иде". Маркс аны бөтен сыйфатлары белән яңа буржуазия вәкиле буларак характерлый.

Джон Локк 1632 елда провинция адвокаты гаиләсендә туа. Аның әтисе революциядә катнашкан була. Иске Вестминстер мәктәбендә схоластипик урта белем алганнан соң, Локк Оксфорд университетына укырга керә, анда Декарт, Бэкон, Ньютон кебек зур галимнәрнең хезмәтләре белән мавыга, табигать фәннәре белән кызыксына, медицина белән шөгыльләнә. Университетны тәмамлагач, Локк анда грек теле һәм әдәбияты укытырга кала. Илдә җәелеп киткән революцион көрәшкә сагаеп карый, гади халыктан күтәрелгәннәрне яратмый. 1667 елда Локк либераль сәяси эшлекле Лорд Шефтсбери белән таныша, аларның гаилә табибы һәм оныкларының тәрбиячесе булып китә. Шефтсбери буржуазия ягыннан корольгә каршы чыга. Шуңа күрә аны, аның белән бергә Локкны да җәберли башлыйлар, һәм алар Голландиягә эмиграциягә китәргә мәҗбүр булалар. 1688 елдан соң Локк Англиягә кире кайта һәм шул чор буржуаз җәмгыятендә мактаулы урын били. 1704 елда

үлә. Локк үзенең хезмәтләрендә король власте алышынуны һәм Англиянең яңа дәүләт төзелешен дәлилләргә омтыла. Ул дәүләт барлыкка килүнең килешү теориясен һәм "табигый хокук" теориясен яклый, кешеләр башта табигый халәттә яшәгәннәр, азат һәм тигез булганнар дип исбатлый. Алар үзләренең табигый хокукларын үз теләкләре белән хакимнәргә биргәннәр, шуның өчен хакимнәр аларның гомерләрен, ирек һәм мөлкәтләрен сакларга тиеш булганнар. Моннан: югары хакимият иясе халык булган, ул үзе биргән властьны, әгәр монарх үз вазифаларын үтәмәсә, кире дә ала алган, дигән нәтиҗә чыга.

"Кеше акылы турындагы тәҗрибә" дигән төп фәлсәфи хезмәтендә (1690) Локк кеше аңында "тумыштан килгән идеяләр" һәм күзаллаулар юк, бала күңеле "чеп-чиста язу тактасы шикелле" дип расларга тырышкан. Бу положениедән чыгып, кеше үсешендә тәрбиянең роле бик югары бәяләнә. Локкның, белем һәм идеяләр тоеп белү тәҗрибәсеннән килеп чыккан, дигән тәгълиматы буржуазияне феодаль аристократия идеологларының идеяләр, "рыцарьлык сыйфатлары", дәүләтне идарә итү сәләте, аксөякләрнең белем алуга аерым хокуклары тумыштан килә дигән, ул чакта киң таралган раслауларына каршы көрәшкә коралландыра.

Локкның тумыштан килгән идеяләрне тәнкыйтьләве материализмның идеализм белән көрәшендә уңай роль уйный. Шул тәнкыйтькә XVIII гасыр мәгърифәтчеләре таяна.

Күзаллаулар безнең аңыбызга тойгылар, сизү әгъзалары аша килә, ди Локк. Бу — дөньяны танып белүнең төп чарасы. Шул рәвешле, биредә ул **материалистик сенсуализм** позицияләренә баса. Әмма Локкның философиясе **дуалистик характерда.** Аның фикеренчә, тышкы тәҗрибәдән башка, акылның үз эшчәнлеге булган эчке тәҗрибә дә бар. Бу нәрсә аның философиясендә идеалистик элементлар да булуын күрсәтә, моны хакыйкать безнең аңыбызда объектив чынбарлыкның чагылышы түгел, ә күзаллаулар һәм төшенчәләрнең үзара ярашуы, дигән раслаулар да бик ачык ассызлыклый. Шушы положениеләрдән чыгып, Локк үз-үзеңне күзәтүгә нигезләнгән эмпирик психологиянең күп кенә мәсьәләләрен эшли. Ул без сайлаганга бәя бирүче, кешегә бәхет һәм файда китерә торган нәрсәне билгеләүче кеше акылының аерым әһәмиятен күрсәтә. Акыл тәрбиясе шуңа күрә аеруча әһәмияткә ия була.

Локкның этикасы тумыштан килгән әхлакый идеяләрне кире кагуга нигезләнә. Игелек — рәхәтлек китерә, яисә аны арттыра, газапны киметә һәм явызлыктан саклап кала алучы нәрсә. Явызлык — газаплар китерә, яисә арттыра, рәхәтлекне киметә яисә рәхәтлектән мәхрүм итә алучы нәрсә. Бу положениеләр феодаль дини этикага каршы юнәлгән була. Шул ук вакытта Локк бар нәрсәне тудыручы һәм иҗат итүче буларак ходайның барлыгын инкарь итми, бала күңеленә алла турында һәм диннең әһәмияте турындагы ныклы төшенчәләрне бик иртә сеңдерергә кирәк дип саный.

Локк үзенең педагогик карашларын **"Тәрбия турында уйланулар"** (1693) дигән китабында бәян итә.

Джентльмен тәрбияләү. Без үз гомеребездә очрата торган кешеләрнең уннан тугызы тәрбия аркасында яхшы яисә яман, файдалы яисә файдасыз була, дигән Локк. Тәрбиянең бурычы итеп ул гади кешене түгел, ә джентльмен, "алдын-артын уйлап, төрле эш итә белүче" **джентльмен тәрбияләүне** санаган. Ул — чыгышы белән дворян булырга, "нәзакәтьле мөгамәләсе белән аерылып" торырга, шул ук вакытта буржуаз эшкуар, эшлекле кеше сыйфатларына ия булырга тиеш.

Джентльмен физик, әхлакый һәм акыл тәрбиясе алырга тиеш, ләкин мәктәптә түгел, чөнки, Локк фикеренчә, мәктәп — "төрле катлаудан чыккан, начар тәрбия алган малайларның чуар төркеме җыелган учреждение ул". **Чын джентльмен өй тәрбиясе ала,** чөнки "хәтта өй тәрбиясенең кимчелекләре дә мәктәптә алган белем һәм күнекмәләрдән күпкә файдалырак". Локк, аксөяк гаиләләре практикасыннан чыгып, джентльмен тәрбияләү эшен яхшы әзерлекле, җитди тәрбиячегә тапшырырга киңәш иткән.

Локк **физик тәрбиягә** гаять зур әһәмият биргән. "Безгә исәнлек (сәламәтлек, эшләребез алга барсын һәм уңышлы булсын өчен кирәк",— дигән ул һәм җентекләп эшләнгән, шул чор фәне югарылыгында торган система тәкъдим иткән. "Сәламәт тәндә — сәламәт акыл",— дип кабатларга яраткан. Шуңа күрә бик кечкенәдән баланың тәнен чыныктыру, бала ару-талуларны, авырлыклар, үзгәрешләрне җиңел кичерерлек итүгә ирешү зарур. Локк бала тормышында катгый режимның әһәмиятен җентекләп нигезләгән, кием-салым, азык, һавага чыгу, спорт белән шөгыльләнү турында киңәшләр биргән.

Дөрес физик тәрбия кыюлык, ныклык кебек сыйфатлар булдыруга да ярдәм итә. "Джентльменга шундый тәрбия бирергә кирәк, ул теләсә кайсы вакытта корал тотып солдат булырга әзер торырга тиеш".

Локкның морале, әйтеп үткәнебезчә, **файда һәм шәхес мәнфәгатьләре принцибыннан** килеп чыга. Чын джентльмен үз бәхетен үзе таба белә, әмма шул ук вакытта бу мәсьәләдә башка джентльменнарга да комачауламый. Кешеләр "акыллы" булырга һәм теләкләренә ирешергә омтылырга гына түгел, реаль мөмкинлекләрен дә исәпкә алырга тиешләр. Шуңа күрә кеше үзен акыллы тотарга, дәрт-хисләрен йөгәнли белергә, тәртипле булырга, акылга буйсынып эш итәргә тиеш.

Характер һәм әхлак тәрбияләү, ихтыяр көче үстерү — тәрбиянең иң мөһим бурычлары. Баланы узындырырга ярамый, ләкин аның законлы теләкләрен үтәми калдырырга ярамый. Баштарак "курку һәм ихтирам хисләре" тәрбиячегә баланың үз-үзен тотышы белән идарә итү мөмкинлеге бирсә, соңрак бу хисне мәхәббәт һәм дуслык "алыштырырга тиеш".

Ниндидер сүз куерту түгел, ә һәрвакыт **үрнәк, мохит, баланың тирә-юне** төп тәрбия чарасы булачак. "Нинди генә вәгазьләр укымасыннар, көн саен нинди генә әдәплелек сабаклары бирмәсеннәр, барыбер баланың үз-үзен тотышына иң зур йогынтыны аның компаниясе һәм тирә-юнендәгеләрнең эш-гамәлләре ясаячак, шиксез хакыйкать шушы", — ди Локк. Балаларда ныклы әйбәт гадәтләр тәрбияләү аеруча мөһим.

"Балаларны хәтердән шунда ук чыгып китә торган кагыйдәләр белән тәрбияләргә ярамый. Аларны нәрсәгә булса да өйрәтергә уйласагыз, шуны җае чыккан саен гамәлдә куллану юлы белән ныгытыгыз һәм, мөмкин булса, ул җайны үзегез чыгарыгыз".

Гадәт тәрбияләү бик кечкенәдән башланырга тиеш. Тупаслык, көч белән уңай нәтиҗәгә ирешеп булмый; моңа ягымлы сүз, балалар оныткан нәрсәне ипләп кенә исләренә төшерү рәвешендә җайлап кына аңлату белән ирешергә кирәк. Берьюлы берничә гадәткә дә өйрәтеп булмый. Башта бер гадәтне ныгытырга, аннары гына икенчесенә күчәргә кирәк,— тәрбиячененң бурычы шуннан гыйбарәт.

Бөтен тәрбия процессын дөрес юнәлтү өчен **баланың шәхси үзенчәлекләрен** игътибар белән өйрәнергә, "өстенлек итүче дәртләрен һәм хакимлек итүче гадәтләрен" ачыклар өчен, бала үзе

сизмәгәндә аны күзәтергә кирәк, чөнки шушы сыйфатлар аермасына туры китереп сезнең методларыгыз да аерымланырга тиеш..."

"Коллар дисциплинасы кол характерын тәрбияли" дип, Локк тән җәзасына каршы булган. Ләкин бала үзсүзлеләнгән, тыңларга теләмәгән очракларда кулланырга мөмкин дип санаган.

Локк дини тәрбиягә әһәмият биргән, әмма иң мөһиме — балаларны йолаларга өйрәтү түгел, ә иң югары зат буларак аллага мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү дип исәпләгән.

Джентельменнар укыту эчтәлеге. Локк фикеренчә, ул чорда кабул ителгәннән шактый киңрәк. Джентельменны укырга, язарга, рәсем ясарга, туган телгә, француз, латин телләренә (латин теле һәммәсе өчен дә түгел: сәүдә эшләре, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүчеләргә бу тел кирәкми), география, арифметика, геометрия, астрономия, хронология, этикага өйрәтү тиеш, шулай ук аңа тарих һәм закон белеменнән, бухгалтериядән мәгълүматлар, атта йөрү һәм бию дәресләре бирергә кирәк.

Бу программа урта гасыр традицияләреннән кискен аерыла. Локк тәкъдим иткән һәр предмет укучыга билгеле бер файда бирергә, аны тормышка әзерләргә тиеш. Белемнәргә практик характер бирергә кирәк иде.

Локк укучыларына нинди дә булса һөнәр (столяр, токарь, балта остасы), яисә бакчачылык һәм авыл хуҗалыгы шулай ук парфюмерлык, лаклау һәм гравировкалау белән шөгыльләнергә тәкъдим иткән. Хезмәт тәрбиясенең зарурлыгын ул болай аңлаткан: саф һавада эшләү сәламәтлек өчен файдалы, ә һөнәр белүнең эш кешесенә, эшмәкәрлеккә кирәк булуы бар. Хезмәт мәгънәсез тырай тибүгә юл куймый.

Тәрбияче, бала белән шөгыльләнгәндә, **анда укуга кызыксыну уятырга, аның белемгә омтылышын үстерергә** тиеш. Укуны бала өчен кызыксыз шөгыльгә әвереләдерергә ярамый. Укытучы балаларның яңалыкка омтылышыннан файдаланырга, әмма шул ук вакытта аларны кызыксыз эшләрне дә эшләргә өйрәтергә тиеш. Баланың кызыксынучанлыгыннан киң файдаланырга кирәк, чөнки аннан белем алуга омтылыш туа. Балаларның сорауларына игътибарлы булырга кирәк, ялган яисә икеле-микеле җаваплар бирергә ярамый. Балаларда аңлау һәм мөстәкыйль фикер йөртү сәләте тәрбияләргә кирәк.

Локкның "эшче мәктәпләре" турындагы антидемократик проекты. Югарыда без инде Локкның мәктәпләргә тискәре мөнәсә-

бәтен билгеләп үткән идек. Ул булачак джентльменны "тупас гавам", кара халык балалары йогынтысыннан сакларга кирәк, дип санаган, Локк фикеренчә, алар зур осталык һәм елгырлык белән бакча басарга гына сәләтле.

Халыкка шушылай ачыктан-ачык нәфрәте Локкның "эшче мәктәпләре" турындагы язмасында аеруча нык чагылыш таба. Аның фикеренчә, "эшче халык балалары" һәрвакыт җәмгыять өстенә авыр йөк булып төшәчәк. Шуңа күрә һәрбер мәхәлләдә "эшче мәктәпләре" оештырырга кирәк, ярдәм сораган, хәерче ата-аналарның 3 яшьтән 14 яшькә кадәрге балаларын мәҗбүри тәртиптә шунда бирергә кирәк. Бу балалар мәктәптә бары "туйганчы ипи генә" ашаячак. Суык вакытта, кирәк дип табылса, ипигә өстәп бераз җылы ботка бирергә мөмкин. Шушы җитәр-җитмәс ризык өчен дә балалар эшләргә, мәсәлән, җеп эрләргә, бәйләм бәйләргә һ. б. тиеш. Балалар эшләгән әйберләрне сатып, акчасын аларга киткән чыгымны каплауга тотарга кирәк. Аеруча шунысы мөһим, ди ул, балаларны мәктәптән укытучы күзәтчелегендә чиркәүгә алып барырга бик уңай булачак, ә бу исә куәтле тәрбия чарасы булыр. Түләү бәрабәренә осталарга читтән өйрәнчекләр алу мөмкинлеге бирелә. Өйрәнчекләр акчаны мәктәпкә түләргә тиеш. Шулай итеп балалар осталарга да, фабрикантларга да эшләячәк.

Локкның тәгълиматлары педагогик системасыннан, бигрәк тә социаль һәм прогрессив юнәлешләре ягыннан, шактый нык аерылса да, Локкның фәлсәфи һәм педагогик хезмәтләре, дәүләтнең килешү нигезендә барлыкка килүе һәм "табигый хокук" теориясе француз мәгърифәтчеләренә сизелерлек йогынты ясый.

* * *

Җиденче лекция

ЖАН-ЖАК РУССОНЫҢ ПЕДАГОГИК ТӘГЪЛИМАТЫ

XVIII гасыр уртасында Франциянең иҗтимагый-сәяси хәле. Мәгърифәтчелек фәлсәфәсе. Франциядә капиталистик строй 1789-1794 еллардагы буржуаз революциягә кадәр бик күп элгәре урнаша. Нигездә аграр илдә XVIII гасырның икенче яртысында капиталистик мануфактура киң тарала. Ләкин феодаль мөнәсәбәтләр капитализм үсешенә нык тоткарлык ясый.

Илнең барлык халкы өч катлауга бүленә. Беренче катлау — гаять күп җирләргә хуҗа булган руханилар. Бу катлау салым түләүдән азат ителә, аның үз суды була. Икенчесе — җирләрнең шактый өлешенә хуҗа дворяннар катлавы. Феодаль хокуклар бу катлауга крестьяннарны эксплуатацияләүдә киң мөмкинлекләр бирә. Өченче катлауның өстенлекләре булмый, аның күпчелек өлешен бөтенләй хокуксыз крестьяннар тәшкил итә. Феодаль түләүләр һәм авыр дәүләт салымнары нәтиҗәсендә крестьяннарның матди хәле бик авыр була. Өченче катлау бертөрле генә булмый: аңа һөнәрчеләр, эшчеләр, шәһәр ярлылары да керә. Өченче катлауда җитәкче урыннарны сәүдәгәрләр, фабрикант һәм банкирлар тота. Яшәү шартлары төрлечә булуга карамастан, алар барысы да феодаль тәртипләргә оппозициядә торалар. XVIII гасыр уртасында буржуазия, өченче катлау составына кереп, ашыкмыйча, икеләнә-икеләнә генә куәтле халык хәрәкәтенә кушыла һәм аның корольгә, руханилар һәм дворяннарның өстенлекләренә, катлауларга бүленгән тәрбия системасына каршы чыгышларына җитәкчелек итә.

Феодаль стройга каршы юнәлгән халык хәрәкәте XVIII гасырның бөтен сәяси тормышына зур йогынты ясый. Бу чорда буржуаз идеологияне чагылдыручы язучы һәм галимнәрнең феодаль тәртипләргә каршы көрәше җанлана. Әсәрләрендә алар революциягә кадәр бик күп элек дөньяга феодаль карашларны тәнкыйтьлиләр, рәсми диннәрне тар-мар итәләр (мәгърифәтчеләрнең кайберләре атеистлар була). XVIII гасырның 50-80 нче елларында, ягъни революция алдыннан, аларның чыгышлары аеруча үткен төс ала.

Француз мәгърифәтчеләре феодализмның аянычы буларак динне, феодаль стройны һәм феодаль идеологияне тәнкыйтьлиләр.

Локк позицияләреннән чыгып, алар дәүләтнең килешү нигезендә килеп чыгуы теориясен яклыйлар (Руссо, Дидро һ. б.) һәм "кешенең" табигый халәтендә" һәрвакыт ирекка, тигезлек һәм туганлыкка "табигый хокукы" бар", дип исбатлыйлар.

XVIII гасыр мәгърифәтчеләре яңа эра, Җирдә акыл хакимлеге эрасы, җитүен көтәләр.

Бу чорда буржуазия идеологлары чын күңелдән үзләрен өченче катлау вәкилләре генә түгел дип саныйлар. Алар нинди дә булса аерым сыйныф вәкилләре ролендә түгел, ә газап чигүче бөтен кешелек ролендә чыгалар.

Ләкин властьны кулына алгач, үз хакимлеген урнаштырырга омтылыш, буржуазия хезмәт ияләренә каршы, үсеп килүче эшчеләр сыйныфына каршы һөҗүмгә күчә.

Француз мәгърифәтчеләре тәрбиянең куәтле көченә ышаналар. Яңа кеше тәрбияләп, шуның белән бөтен дөньяны яңартачакларына алар шикләнми. Алар фикеренчә, мәгърифәт үткәннән калган ялганны, хорафатлар, наданлыкны бетерәчәк, феодализмга хас барлык тискәре күренешләр юкка чыгачак.

Француз мәгърифәтчеләре арасында күренекле урынны Жан-Жак Руссо һәм фәлсәфәче-материалистлар тоткан.

Жан-Жак Руссоның тормышы. Руссо 1712 елда Женевада, һөнәрче-сәгатьче гаиләсендә туа. Системалы белем алмый. Күп еллар Франция һәм Швейцариядә ил гизә, бик күп һөнәрләргә тотынып карый. Формалашып җиткәч, утыз яшендә, Руссо Парижга килә һәм анда шул чорның яңа буржуаз интеллигенциясе, аның иң яхшы вәкилләре — публицистлар һәм философлар белән таныша. 1749 елда Дижон академиясе "Фән һәм сәнгать прогрессы әхлак яхшыруга яисә начараюга ярдәм иттеме?" дигән темага сочинение конкурсы игълан итә. Дидро киңәше белән Руссо шушы темага язарга алына. Бу әсәрендә ул социаль тигезсезлеккә, аксөякләр һәм эшлексезләргә, феодаль җәмгыять мәдәниятенә һәм фәненә кискен каршы чыга. Шул хезмәте өчен Руссо Дижон академиясе бүләген ала.

1755 елда Руссо "**Кешеләр арасында тигезсезлекнең килеп чыгуы һәм нигезләре турында фикер йөртү"** исемле икенче хезмәтен иҗат итә. Анда диалектика элементлары да була. Аннары "Иҗтимагый договор" пәйда була. Руссо тигезсезлекнең цивилизация белән бергә үсүен исбатлый. "Иҗтимагый договор" хезмәтендә, Локкның договор теориясен үстереп, ул цивилизацияле (ягъни феодаль) җәмгыятькә каршы идеал итеп, имештер, "табигый

халәтендәге", ниндидер җәмгыятьне куя. Анда кешеләр азат һәм тигез булганнар, аннары эшләп тапкан мөлкәтләрен саклап калу өчен хокукларыннан баш тартканнар. Руссо туганлыкны, эксплуататорлар изүен тәнкыйтьләгән һәм, халык мәнфәгатьләренә җавап бирмәгән власть законсыз, башлангыч иҗтимагый килешүне боза; ул килешү буенча кешеләр үзләре сайлаган, халыкка хезмәт итәргә бурычлы властьларга ирекле рәвештә кайбер хокукларын биргәннәр, дип исбатлаган. Әдәби формага төрелгән бу әсәр корольне һәм феодаль тәртипләрне бәреп төшерергә чакыру була.

1762 елда Руссоның **"Эмиль, яки Тәрбия турында"** дигән роман-трактаты чыга, ул авторны бөтен дөньяга таныта. Бу әсәрендә Руссо яңа, ягъни буржуаз җәмгыятьнең ирекле кешесен тәрбияләү юлын күрсәтә. "Эмиль" чыгу аксөякләр һәм руханиларның ярсуын кузгата. Гәрчә Руссо атеист булмаса да, хөр фикерлелеге өчен, китап Парижның бер мәйданында яндырыла, ә авторы чит илгә качарга мәҗбүр була. Бары үләр алдыннан гына, физик һәм мораль яктан арыган, талчыккан Руссо туган иленә кайту мөмкинлеге ала. Ул 1778 елда үлә.

Руссо әсәрләре революция алды буржуаз җәмгыятенең алдынгы вәкилләрен тирән дулкынландыра, бу әсәрләрнең йогынтысы Франциядән бик еракларга тарала.

Руссоның иҗтимагый-сәяси һәм фәлсәфи карашлары. Хакимият һәм байлык тигезсезлек тудырды, ди Руссо, шуңа күрә кеше үзенең ирекен югалтты. "Кеше туганда ирекле туса да, бөтен җирдә ул богаулы", — дип яза ул. Руссо хакимлекне халыкның үз кулында булырга тиеш дип саный, һәркем эшләргә тиеш дип таләп итә. Ул, вак милекне генә калдырып, дворян-феодаллар милкен юк итәргә чакыра. Руссоның бу тәгълиматы шул чор өчен революцион була. Ул вак милекчеләр (һөнәрчеләр, крестьяннар) мәнфәгатен чагылдыра һәм буржуаз строй урнашуга китерә. Руссоның идеалы — **эшләп тапкан вак буржуаз милек** һәм шушы милеккә, шулай ук һәркемнең хезмәтенә нигезләнгән җәмгыять төзелеше.

Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү мәсьәләсен караганда, Руссо **сенсуалист** буларак фикер йөртә: безнең аңыбызда сиземләү ярдәмендә, тою органнары аша алынмаган бер генә нәрсә дә юк. Ләкин ул бу положениедән материалистик нәтиҗәләр ясый алмаган. Руссо, рәсми динне кире кагып, "хисси динне" яклаган, һәрбер кеше үзенчә инанырга тиеш дип исәпләгән. Аныңча, "галәмне яратучы алла кулыннан чыккан һәммә нәрсә яхшы, һәммә нәрсә кеше кулында начарлана".

Руссо фикеренчә, кешене җәмгыять боза. Моннан шундый нәтиҗә чыга: баланы бозык җәмгыятьтән читтә, цивилизацияләрдән еракта, "табигать кочагында" тәрбияләргә кирәк.

Кешеләр үз хезмәтләре исәбенә яшәргә тиеш. Хезмәттән башка кеше нормаль яши алмый. Ләкин гаделсез, бозык дөньяда күпләр чит кешеләрнең хезмәт җимешләрен үзләштерә. Чын-чыннан иркле кеше — үз хезмәте белән яшәүче ул. Руссо фикеренчә, эш бирәүгә дә бәйле булмаган, үз ирегең бәяли һәм яклый белгән кеше тәрбияләүдә тора. Үз ирегенең кадерен белгән кеше, әлбәттә, хезмәткә нигезләнгән башкалар ирегең дә ихтирам итәргә өйрәнә.

Руссо: хезмәт ияләренең балаларын тәрбияләргә кирәкми, аларны тормыш тәрбияләгән инде, дигән. Феодалларны, аксөякләрне яңадан тәрбияләргә, аларның балаларына дөрес тәрбия бирергә кирәк, шул чагында дөнья үзгәрер. Шуңа да ул "Эмиль, яки Тәрбия турында" әсәрендә аксөякләр гаиләсеннән чыккан Эмильне төп герой итә. Тәрбия нәтиҗәсендә ул хөр фикерле булырга һәм үз кул көче белән яшәргә тиеш.

Табигый һәм иркле тәрбия. Балалар, Руссо фикеренчә, табигатенә туры килә торган табигый тәрбия алырга тиеш. Бу — тәрбияләгәндә **баланың табигатенә** ияррергә, аның **яшь үзенчәлекләрен** исәпкә алырга кирәк дигән сүз. "Табигать балаларның үсеп җиткәнче бала булуларын тели",— дип яза Руссо. Ул тәрбияне өч чыганактан: табигатьтән, тирә-юньдәге кешеләрдән һәм әйберләрдән алалар дип исәпли. Табигать белән тәрбияләү, аның фикеренчә, кеше сәләтләренең "эчке" үсеше, сизү әгъзалары үсеше юлы белән тормышка ашырыла; кешеләр тәрбиясе — кешене шушы сәләтләр һәм әгъзалар үсешен файдаланырга өйрәтү; һәм, ниһаять, әйберләр тәрбиясе — кешенең үзенә очрый һәм аңа йогынты ясый торган әйберләрдән ала торган шәхси тәҗрибәсе. Дөрес тәрбия барлык өч фактор да (табигать, кешеләр, әйберләр яисә тышкы хәлләр белән тәрбияләү) үзара килешеп, бер юнәлештә эш иткәндә була.

Табигый тәрбия белән турыдан-туры бәйләнешкә Руссо иркле тәрбияне дә куя. Кешенең табигый хокукларыннан беренчесе, ди ул,— ирек. Шушы положениегә таянып, ул ятлаулы, каты дисциплиналы, тән җәзалы һәм баланың шәхесен бастырып торучы схоластик мәктәпкә каршы чыга. Ул **бала шәхесен ихтирам итүне,** аның мәнфәгатьләре һәм ихтыяҗлары белән исәпләшүне таләп итә. Аның иркле тәрбиягә чакыруының уңай ягы нәкъ менә шунда.

Руссо тәрбиячененең юнәлеш бирү ролен зур әһәмияткә ия дип санаган, ләкин бу рольне үзенчә аңлаган. Тәрбияче, дигән ул, уку-

чысын мәсьәләне хәл итүгә юнәлтә генә, баланың мәнфәгатьләре белән аның үзенә сиздермичә идарә итә, башлыча читләтеп йогынты ясый. Бөтен мохитне, баланың тирәлеген шундый итеп оештыра, нинди дә булса карарга, нәтиҗәгә килергә ул мохит үзе ярдәм итә. Руссо тәрбия чарасы буларак мәҗбүр итүне кире кага.

Яшь чорларына бүлү. Укучысының тормышын Руссо дүрт чорга бүлә. **Беренче чор** — туганнан алып 2 яшькә кадәр, бу чорда баланың физик тәрбиясе игътибар үзәгендә торырга тиеш. **Икенче чор** — 2 яшьтән 12 яшькә кадәр, Руссо сүзләре белән әйткәндә, "акылның йоклаган чагы", бу чорда бала әле хөкем йөртә һәм логик фикерли алмый, монда башлыча "тышкы тойгыларны" үстерергә кирәк була, киләчәктә, өлкәнрәк яшьтә кулланыш табар өчен баланың көче туплана. **Өченче чор** — 12 яшьтән 15 яшькә кадәр, бу елларда акыл тәрбиясе киң җәелдерелә, баланың акыл ихтыяҗлары канәгатьләндерелә. **Дүртенче чор** — "давыллар һәм дәртләр чоры" — 15 яшьтән алып балигъ булганчыга кадәр. Бу чорда күбрәк әхлак тәрбиясе бирелә.

Баланың яшь үзенчәлекләре турындагы фикерләре Руссоның табигать тәрбиясенә карашлары белән туры килә һәм диалектикадан да мәхрүм түгел. Ул баланың табигый үсеш баскычларының һәрберсе өчен әйдәп баручы башлангыч табарга омтылган, тәрбия процессында төп игътибар шул чорда шул башлангычка юнәлтелергә тиеш. Шуның белән бергә һәр баскыч икенчесе белән тыгыз бәйләнештә була.

Руссо кешенең табигатен тирәнтен аңларга һәм аның үсеш үзенчәлеген ачыкларга омтылган. Әмма ул бала үсеше законнарын дөрес күрсәтә алмаган. 2 яшьтән 12 яшькә кадәр бала логик фикерләүгә сәләтсез, бу яшьтә балалар әхлак төшенчәләрен аңламыйлар дигән раслаулар дөрес түгел.

Руссо үсешне тәрбиядән анык аермаган, шуның белән ул тәрбия процессын биологияләштергән дип әйтергә була. Ләкин шунысы әһәмиятле, ул балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алуны таләп иткән. Руссо, һәр бала тормышка аерым темперамент алып килә, шул темперамент аның сәләтен һәм холкын билгели, аны үзгәртергә яисә үстерергә һәм камилләштерергә кирәк була, дип язуы белән дә хаклы. Ул трафаретка, тәрбиягә бертөрле генә якын килүгә кискен каршы чыккан. Тәрбияченең бурычы — баланың яшь үзенчәлекләрен яхшы белү, индивидуаль һәвәслекләрен һәм сәләтләрен тирәнтен өйрәнү.

Бик кечкенә яшьтә (ике яшькә кадәр) бөтен нәрсәнең нигезе — **физик тәрбия.** Мөмкин булса, баланы анасы үзе имезергә тиеш. Гадәттә баланы башын селкетмәслек итеп, аякларын турайтып, кулларын гәүдәсе буйлап сузып төреп яткыралар.

"Ярый әле сулыш алу мөмкинлеге калдырсалар!" — ди Руссо. Шул рәвешле тугач ук баланы ирегеннән мәхрүм итәләр, ә моны эшләргә, табигатькә комачауларга ярамый.

Руссо Эмильнең физик тәрбиясенә җентекләп туктала. Баланы чыныктыру, аның физик көчен ныгыту юлларын күрсәтә.

Ике яшьтән яңа тәрбия чоры башлана. Баланы бу яшьтә фикер йөртергә, хикәя һәм экиятләр өйрәнергә мәҗбүр итү ярамый, аңа төрле үгет-нәсихәтләр уку да кирәкмәс. Бу яшьтә, Руссо фикеренчә, иң мөһиме — **баланың тышкы хисләрен үстерү.** Руссо бу өлкәдә бик күп күрсәтмәләр бирә. Элеккечә үк баланың сәламәтлеген ныгыту, аны физик яктан үстерү белән ныклап шөгыльләнергә кирәк. Әлегә аны укытырга ярамый. Кирәк дип тапкан очракларда бала үзе үлчәсен, санасын, чагыштырсын. 12 яшькә кадәр китапны бар дип тә белмәсә, бигрәк тә яхшы; ә инде укырга өйрәнгән икән, беренче һәм бердәнбер китабы "Робинзон Крузо" булсын, чөнки аның герое кеше яшәми торган утрауда үзенең табигать эчендәге гади генә көнкүреше өчен кирәкле бөтен нәрсәне үзе булдырган.

Руссо фикеренчә, балада бу яшьтә әхлак төшенчәләре булмый, әмма шунысы бәхәссез, бу чорда үрнәкнең тәрбияви роле бик зур. 12 яшькә кадәр бала бернинди әхлакый, абстракт төшенчәләрне дә аңламый, шулай да әйберләрнең үзләрен танып белүгә бәйле нәрсәләрнең кайбер аерым абстракт төшенчәләр формалаштырырга ярдәм итүе мөмкин. Руссо: бала бу яшьтә бер мөһим идеяне — милек идеясен тулысынча үзләштерә ала дип саный. Эмильнең бакчада эшлисе килә, ул борчак утырта. Әмма аның борчагы бакчачы Робертның кавын төрткән җиренә туры килә. Роберт белән бәрелешеп алганнан соң, бала милек идеясенең табигый рәвештә "хезмәт итү юлы белән беренче булып кулга төшерү" хокукына барып тоташуын аңлый. Шул рәвешле Руссо, үзенең бу яшьтә балада абстракт төшенчәләр формалаштыру мөмкин түгел дигән төп положениеләренә каршы килеп, милек идеясе бала аңына барып җитәрлек була ала, дип саный.

Җәза бирүләрне кире кагып, Руссо "табигый нәтиҗәләр" алымын күтәреп чыга. Баланың ирегеն фәкать әйберләр генә чикли ала. Бала, табигать белән очрашкач, һичшиксез, аның законнарына буйсыну кирәклеген аңлаячак. Кешеләргә мөнәсәбәтнең нигезендә дә

шушы ук фикерләр салынырга тиеш. Бала тоткан бер әйберсен вата икән,— ачуланмагыз, ватылырдай бөтен нәрсәне аннан ераграк кына куярга тырышыгыз. Үзе утырган урындыкны ваткан икән,— яңасын бирергә ашыкмагыз. Урындыксыз кыен икәнен аңласын. Үз бүлмәсендәге тәрәзә пыяласын вата икән,— яңа пыяла куймагыз, "акылсыз баладан томаулы бала яхшырак". Ә инде пыяла ватуын дәвам итә икән, караңгы бүлмәгә бикләргә кирәк: Руссо моны җәза дип түгел, бала гаебенең "табигый нәтиҗәсе" дип санаган.

Унике яшьлек Эмиль физик яктан нык, мөстәкыйль, тиз ориентлаша һәм иң мөһим нәрсәләрне тотып ала белә, ул үзенең тышкы сизү органнары аша әйләнә-тирә дөньяны танып белгән. Үсешенең өченче, **акыл һәм хезмәт тәрбиясе** тормышка ашырыла торган чорына аяк басарга ул инде әзер. Бу яшьтә балада, Руссо фикеренчә, җитәрлек дәрәҗәдә әхлак төшенчәләре булмый әле, һәм ул кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тиешенчә аңлый алмый, шуңа күрә үзен чолгап алган табигать белән бәйле нәрсәләрне өйрәнергә тиеш. Өйрәнү өчен предметлар сайлаганда **баланың кызыксынуыннан** чыгып эш итәргә кирәк. Баланың үзе күргән әйбер белән кызыксынуы табигый хәл, шуңа күрә аны география, астрономия, табигать белеме кызыксындыра. Руссо балага бу белемнәрне бирүнең күренешләрне ул үзе мөстәкыйль тикшерүгә нигезләнгән оригиналь методикасын тудыра. Ул Эмильне фәнни хакыйкатьләр ачучы, компас уйлап табучы тикшеренүче хәленә куя.

Руссоның дидактикасы балада үзенчәлелек, күзәтә белү, зирәклек үстерүгә нигезләнгән. Бөтен нәрсә балага **иң югары күрсәтмәлелек** белән тәкъдим ителергә тиеш. Аның фикеренчә, күрсәтмәлелек — Эмиль турыдан-туры үзе таныша торган табигать, тормыш фактлары ул. Яңа, ирекле кешенең акыл тәрбиясен сурәтләргә тырышып, Руссо баланың шәхси тәҗрибәсен фәндә чагылыш тапкан кешелек тәҗрибәсе белән бәйли алмаган. Ул реаль белемне китаплардан түгел, ә табигатьтән алуны яклый. Шуның белән бергә ул балада күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык һәм активлык тәрбияләүнең зур әһәмияткә ия булуын, аның табигать һәм тормыш белән турыдан-туры аралашуының укытуда мөһимлеген бик ачык күрсәткән.

Физик хезмәт — җәмгыятьтә кешенең котылгысыз бурычы. "Баймы ул — ярлымы, көчлеме — көчсезме, эшсез трай тибеп йөрүче һәрбер гражданин — мошенник". Шуңа күрә ирекле кеше төрле һөнәрләр һәм авыл хуҗалыгы эшләрен белергә тиеш, шул

чагында гына ул чынлап та үзен туендыра һәм иреген саклый ала. Эмиль бик күп файдалы һөнәрләр өйрәнә.

Беренче чиратта бала столярлык һөнәренә өйрәнә (бу һөнәрнең тәрбияви әһәмиятен Руссо бик югары бәяли), аннары башка күп кенә һөнәрләр белән таныша. Эмиль һөнәрчеләрчә көн күрә, хезмәт кешесен, хезмәтнең үзен, хезмәттәшлекне ихтирам итә башлый. Ул үзе эшләп тапкан икмәкне ашап яши. Хезмәт — ирекле кешенең иҗтимагый бурычы, шулай ук тәрбия чарасы да.

Хәзер инде Эмильнең тормышка әзерлеге бар, һәм Руссо аны уналтынчы яшенә чыккач җәмгыятькә кайтара. Дүртенче чор — **әхлак тәрбиясе** чоры килеп җитә, ә әхлак тәрбиясен җәмгыятьтә генә биреп була. Хәзер инде бозык шәһәр җитәрлек чыныгу алган Эмильне куркытмый.

Руссо, тиздән революцион көрәшкә керешәчәк сыйныф вәкиле, "өченче катлауның" иң яхшы кешеләре — гомумкешелек идеалларын чагылдыручылар дип ихлас күңелдән ышана. Шуңа күрә Эмильне бөтен кешеләрне дә яратырга өйрәтү зарур, һәм Руссо әхлак тәрбиясенең өч бурычын күтәреп чыга: **яхшы хисләр, яхшы фикер, яхшы теләк тәрбияләү.**

Яшүсмер кешеләрнең газапларын, мохтаҗлык һәм хәсрәтләрен күрсен, ул шулай ук әйбәт мисаллар да күрәчәк; анда яхшы хисләрне әхлак турында фикер йөртүләр түгел, ә реаль эшләр тәрбияләячәк. Яхшы фикер тәрбияләү бөек кешеләрнең биографиясен, тарихны өйрәнү юлы белән тормышка ашырыла. Яхшы теләк исә яхшы эшләр башкарганда гына тәрбияләнә ала.

Бу яшьтә Руссо җенси тәрбия бирүне дә кирәк дип санаган. Иң элек ул тиешсез китаплар уку, аз хәрәкәтләнү кебек зарарлы гадәтләрне бетерергә тәкъдим иткән; яшүсмер эшлекле тормыш белән яшәргә; хәрәкәтләнергә, физик хезмәт белән шөгыльләнергә, күбрәк саф һавада булырга тиеш. Руссо фикеренчә, балаларның җенси тормыш турында сораулар бирмәве хәерлерәк, ә инде биргәннәр икән, "ялган җавап бирүдән аларны дәшмәскә мәҗбүр итү әйбәтрәк". Бала моңа гаҗәпләнмәячәк, ди ул, чөнки ул аңлый алмастай сорауларга тәрбияче элек тә җавап бирмәгән бит. Эмильне җитәрлек дәрәҗәдә әзерлекле дип тапса, тәрбияче, каушамыйча, җитди һәм гади җаваплар бирергә, баланың җенси тормыш турында читтән, яраксыз чыганаклардан мәгълүмат алуына юл куймаска тиеш.

Руссо фикеренчә, 17-18 яшькә кадәр балага дин турында сөйләү кирәкмәс. Ул Эмильнең әкренләп илаһи башлангычны танып белү-

гә үзе килүенә ышана. Балаларга дини хакыйкатьләрне җиткерүгә каршы була. Чын дин, — ди ул, — йөрәк дине. Галәмнең акыллы төзелеше турында фикер йөртеп, бала аның иҗатчысы турында фикергә киләчәк, дип саный Руссо.

Эмильнең кәләше Софи капма-каршы тәрбия алган булырга тиеш. Руссо аңлавынча, хатын-кызның бурычы ир-атныкыннан тамырдан аерыла. Башкалар фикеренә җайлашу, мөстәкыйль фикере, хәтта үз дине дә булмау, башкалар ихтыярына буйсыну — хатын-кызның язмышы шул. Хатын-кызның "табигый халәте" — бәйлелек, "кызлар үзләрен буйсыну өчен яратылган дип хис итәләр", кызлар акыл хезмәте белән шөгыльләнергә тиеш түгел, дип саный Руссо. Аның ирләр һәм хатын-кызлар тәрбияләү эчтәлеген кискен каршы куюы аңлашыла, — ул гаилә идеалын һөнәрче, вак буржуа гаиләсендә күрә. Руссоның болай фикер йөртүе аның вак буржуа табигатенә туры килә һәм реакцион булып тора.

Руссоның педагогик теориясенең әһәмияте. Руссо 1789 елгы француз революциясен идеологик яктан әзерләүдә философ-мәгърифәтчеләр арасында мөһим урын били. Күп кенә каршылыклары һәм ялгышуларына карамастан, аның педагогик карашлары үзенең тарихи прогрессив ролен уйный. Аның карашлары феодаль педагогикасының капма-каршысы була һәм баланы яратуга нигезләнә. Руссо укытуның актив методларын, баланың яшь үзенчәлекләрен исәпкә алуны, хезмәт тәрбиясен, укытуның тормыш белән тыгыз элемтәдә булуын таләп итә.

1789-1794 елгы француз буржуаз революциясе тәмамланганнан соң, буржуаз педагоглар Руссоның педагогик идеяләренә сагаеп карый башлыйлар. Демократ Руссо куркыныч тоела башлый, аның актив, мөстәкыйль фикер йөртә белүче, ирекле кеше тәрбияләү турындагы уйлары ныгый алган буржуаз җәмгыятьнең реакцион идеологиясенә каршы килә.

Н. К. Крупская болай дигән: "Хәзерге заманның картаеп какшаган буржуазиясе Руссо мирасыннан баш тарта. Аның әле үз сыйныфлары мәнфәгатен халык эшеннән аермаган нигез салучылары Руссоны күкләргә чөяләр иде; хәзерге буржуазия, гәрчә традиция буенча аны "бөек" дип атаса да, һәрвакыт "утопист" дип тә өстәп куя, Руссога кимсетеп, салкын карый. Өстәвенә, әсәрләрендәге чыннан да утопик нәрсәләрне генә түгел, аның демократизмын, аның "кешегә", хезмәткә ихтирамын да утопия дип аңлый".

* * *

Сигезенче лекция

XVIII ГАСЫР ФРАНЦУЗ МАТЕРИАЛИСТЛАРЫНЫҢ (ГЕЛЬВЕЦИЙ, ДИДРО) ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ

Француз материалистларының фәлсәфи карашларына кыскача характеристика. Француз философ-мәгърифәтчеләре арасыннан карашларының эзлеклелеге һәм сугышчан принципиаль позицияләре белән философ-материалистлар аерылып торган. Алар феодаль дәүләт учреждениеләренә һәм чиркәүгә кискен каршы чыкканнар, француз революциясенең үткен идеологик коралын әзерләгәннәр. Дидро, Гельвеций, Гольбах әсәрләре тыелган, конфискацияләнгән, властьлар тарафыннан ут төртеп яндырылган, авторлар үзләре эзәрлекләнгән, еш кына башка илләргә китәргә мәҗбүр булганнар.

Француз материалистлары дин белән эзлекле, актив көрәшүчеләр булганнар, аларның дөньяга атеистик карашларының замандашларына гына түгел, киләчәк буыннарга да йогынтысы гаять зур булган. Чиркәү һәм дин — феодализмның төп терәге, ә бу терәкне җимерү — революциянең зарур шарты була. Бу чорда динне тәнкыйтьләү һәрбер башка тәнкыйтьнең алшарты иде.

Философ-материалистлар диннең чыганагы наданлык, коллык, деспотлык һәм руханиларның халык массаларын алдаулары дип исбатларга тырышканнар. Руханиларның халыкны мәгърифәтле итүдә гамьнәре юк, диләр алар, халык никадәр мәгърифәтсез булса, аны алдавы да шулкадәр җиңелрәк. Әмма алар диннең социаль асылын аңламаганнар, аның белән көрәшүнең дөрес юлларын күрсәтә алмаганнар. Француз материалистлары мәгърифәт барлык хорафатларны юкка чыгарыр дип санаганнар. Фән, сәнгать, һөнәрләр кешеләргә яңа көч бирә, табигать законнарын танып белүгә ярдәм итә, ул белемнәр аларны диннән баш тартуга китерергә тиеш.

Феодаль хөкүмәткә дин халык белән җиңелрәк идарә итү өчен кирәк, ләкин гадел, мәгърифәтле, игелекле хөкүмәткә ялган сафсаталар кирәк булмаячак. Шуңа күрә руханиларның мәктәпләр белән идарә итүенә юл куярга ярамый, мәктәптә дин сабагы да укыты-

лырга тиеш түгел, укучыларны табигать законнарын танып белүгә китерүче предметлар кертергә кирәк. Яңа җәмгыятьтә үзеңне тотуның әхлак нормалары нигезләренә өйрәтүче предмет кертүдә максатка ярашлы, мораль курсы шундый предмет булырга тиеш.

Француз материалистлары тәгълиматы буенча, дөньяда бары бертуктаусыз хәрәкәттәге материя генә бар, материя — физик чынбарлык. Алар табигатьтәге һәм хәрәкәттәге гомуми үзара тәэсир итешүне материянең табигый үзлеге дип таныйлар. Ләкин француз материализмы хәрәкәтне механик аңлау чикләреннән чыкмый һәм метафизик, читтән торып күзәтү характерында була.

Локк сенсуализмына таянып, француз материалистлары танып белүнең башлангыч ноктасы итеп тышкы дөньядан алына торган хис-тойгыларны саныйлар. Дидро сүзләре белән әйткәндә, кеше музыкаль инструментка тиң, ә аның сизү органнары — клавишалар: табигать шул клавишаларга басса, инструмент тавыш чыгара — кешедә сиземләү һәм төшенчәләр барлыкка килә.

Табигатькә карашларында материалист буларак, француз философлары иҗтимагый үсеш законнарын аңлатуда идеализм позицияләрендә торалар. Алар, "дөнья белән фикерләр идарә итә", шулай булгач, фикерләрне үзгәртүгә ирешү белән бөтен феодаль калдыклар һәм диннәр юкка чыгачак, мәгърифәт таралачак, закон чыгару яхшырачак һәм акыл хакимлек итә башлаячак, дип раслыйлар. Димәк, кешеләрне инандырырга, яңадан тәрбияләргә кирәк, шул чагында иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең характеры тамырдан үзгәрәчәк. Шуңа күрә француз материалистлары тәрбияне иҗтимагый стройны үзгәртү чарасы дип санаганнар. Алар, кешене әйләнә-тирә мохит һәм тәрбиянең пассив продукты итеп карый, мохит йогынтысына да артык зур бәя биргәннәр. Кешеләрнең мохитне дә, шулай ук үз табигатьләрен дә үзгәртүче революцион эшчә илегенең ролен аңламаганнар. Иске материализмның өзлексезлеге аның идеаль этәргеч көч барлыгын тануында түгел, дигән Ф. Энгельс, ә ераграк үтеп керергә, бу көчне булдырган сәбәпләргә барып җитәргә омтылыш ясамыйча (тырышмыйча), шуларда тукталып калуында.

Француз материалистлары Гельвеций һәм Дидроның педагогик карашлары аеруча зур әһәмияткә ия була.

Клод Адриан Гельвецийның (1715-1771) педагогик карашлары. 1758 елда Гельвецийның "Акыл турында" дигән атаклы китабы басылып чыга. Дингә һәм гамәлдәге стройга каршы килүдә гаепләп, властьлар бу китапны тыялар. Китап бөтен халык алдында

яндырыла. Гельвеций чит илгә китә һәм **"Кеше, аның акыл сәләтләре һәм аны тәрбияләү турында"** дигән яңа әсәр яза (әсәр 1773 елда басылып чыга).

Гельвеций идеяләрнең тумыштан килүен танымый һәм, сенсуалист буларак, кешенең бөтен күзаллау һәм төшенчәләре тоеп сиземләү нигезендә барлыкка килә дип уйлый. Ул кешенең мохит һәм илдә хакимлек итүче иҗтимагый-сәяси строй йогынтысында формалашуына зур әһәмият бирә. Гельвеций сүзләре белән әйткәндә, **яшүсмернең яңа һәм төп тәрбиячеләре — ул яшәгән дәүләтне идарә итү формасы һәм халыкта шушы идарә итү формасы тудырган гореф-гадәтләр**.

Феодаль строй кешеләрне гарипләндерә, дигән ул. Чиркәү кешеләрнең холкын боза, дини әхлак икейөзле һәм шәфкатьсез. "Гражданнарын тәрбияләүне попларга ышанып тапшырган милләтләр бәхетсез", — ди Гельвеций. Анынча, әхлак вәгазен дөньяви власть үз кулына алырга тиеш. Хәзерге әхлак ялгышлар һәм хорафатларга, дингә корылганлыктан, дөрес аңланучы, ягъни иҗтимагый мәнфәгатькә туры килүче шәхси мәнфәгатьтән килеп чыга торан яңа әхлак булдырырга тиеш. Әмма иҗтимагый мәнфәгатьне Гельвеций буржуаз позициядән чыгып аңлаган. Җәмгыятьнең нигезен ул шәхси милектә күргән.

Гельвеций барлык гражданнар өчен бердәм тәрбия максаты формалаштыру зарур дип санаган. Бу максат — бөтен җәмгыятьнең бәхетенә, мөмкин кадәр күбрәк гражданнарның хозурына һәм бәхетенә омтылу. Шәхси бәхет һәм "милләт бәхете" идеяләрен берләштерергә сәләтле патриотлар тәрбияләргә кирәк. Буржуаз акыл иясе буларак, Гельвеций милләт бәхетен чикләбрәк аңлатса да, тәрбия максатын шулай аңлау тарихи прогрессив характерда була.

Гельвеций раславынча, бөтен кешеләр дә белем алуга бер үк дәрәҗәдә сәләтле, чөнки аларның тугандагы рухи сәләтләре бертигез була. "Кешеләрнең тумыштан тигезлеге турындагы" бу раслау демократизм белән сугарылган: ул социаль чыгышына бәйле рәвештә кешене табигать тигезсез яраткан диюче шул чорның дворян идеологлары теориясенә һөҗүм ясый. Әмма Гельвеций кешеләр арасында бернинди дә табигый аерма юк диюе белән хаклы түгел.

Гельвеций фикеренчә, кеше фәкать мохит һәм тәрбия йогынтысында гына формалаша. Шул ук вакытта "тәрбия" төшенчәсенә ул бик киң мәгънә бирә. Гельвеций "гадәти мәгънәсендәге тәрбияне

генә түгел, шәхеснең бөтен тормыш шартларының җыелмасын да" тәрбия дип аңлый. Гельвеций әйтүенчә, "Кешене тәрбия кеше иткән", "Тәрбия барысын да булдыра". Тәрбиянең дә, мохитнең дә ролен ул артык югары бәяләгән, кешене тирәлегендәге предметлар һәм хәтта очраклы хәлләр дә тәрбияли дип уйлаган. Болай аңлату кеше формалаштыруда стихияле факторларны артык югары бәяләүгә һәм оешкан теорияне бәяләп бетермәүгә китерә.

Аныңча, балаларның башын дин белән томалый торган схоластик мәктәп чын кешеләр генә түгел, гомумән аек фикерле кешеләр дә тәрбияли алмый. Шуна күрә мәктәпне тамырдан үзгәртеп кору, аны дөньяви, дәүләт мәктәбе итү һәм өстен хокуклы дворяннар кастасының белем алуга монополиясен бетерү кирәк. Халыкка мәгърифәт бирү, кешеләрне яңадан тәрбияләү зарур. Гельвеций мәгърифәт һәм тәрбия нәтиҗәсендә хорафатлардан, юкка-барга инанулардан азат кеше, чын атеист, патриот, бәхетен "милләтләр бәхете" белән берләштерә алучы кеше туачак дип өметләнгән.

Дени Дидроның (1713-1784) идеологик карашлары. Дени Дидро XVIII гасыр француз материализмының күренекле вәкиле була. Аның әсәрләрен властьлар дошманлык белән каршылый. Аның "Күзлеләргә гыйбрәт өчен сукырлар турында хатлар" әсәре дөньяга чыгуга, Дидроны кулга алалар. Иреккә чыкканнан соң, ул бөтен көчен "Фәннәр, сәнгать һәм һөнәрләр энциклопедиясен" әзерләү һәм бастыруга бирә. Ул чордагы буржуаз интеллигенциянең иң яхшы өлешен үз тирәсенә туплаган энциклопедия буржуаз француз революциясен идеологик яктан әзерләүдә гаять зур роль уйный.

Барлык француз фәлсәфәче-материалистлары арасыннан Дидро иң эзлеклесе була: ул материянең юкка чыкмавы, тормышның мәңгелеге, фәннең бөек роле турындагы фикерне кайнар яклаган.

Дидро тойгыларга зур әһәмият биргән, әмма танып белүне аларга гына кайтарып калдырмаган, ә бик хаклы рәвештә тойгыларны акыл белән эшкәртүнең зур әһәмияткә ия булуын әйткән. Сизү органнары — бары шаһитлар гына, фикер йөртү ис сизү органнарыннан алынган мәгълүматлар нигезендә акыл эшчәнлеге нәтиҗәсе.

Дидро тәрбиянең ролен югары бәяләгән, әмма Гельвеций белән бәхәсендә аның чиксез куәтен инкарь иткән. Ул диалог формасында үзенең мәгълүм **"Гельвецийның "Кеше" китабын системалы рәвештә кире кагу"** әсәрен яза (1773-1774).

Бер үзенчәлекле урынын китереп үтик:

"Гельвеций. Мин акыл, даһилык һәм яхшылыкны тәрбия продукты буларак карадым.

Дидро. Бары тәрбиянеке генәме?

Гельвеций. Бу фикер миңа әле дә дөрес кебек тоела.

Дидро. Ул ялган, шуңа күрә аны беркайчан да чын-чыннан ышандырырлык итеп исбатлап булмаячак.

Гельвеций. Тәрбиянең даһилыкка һәм кешеләр, халыклар холкына без уйлаганнан зуррак йогынты ясавы мәсьәләсендә минем белән килештеләр.

Дидро. Сезнең белән ризалашырдай нәрсә шушы гына да инде".

Дидро Гельвецийның тәрбия бөтенесе дә эшли ала дигән положениесен катгый рәвештә кире кага. Аныңча, тәрбия белән күп нәрсәгә ирешергә мөмкин, әмма ул балага табигать тарафыннан бирелгәнне генә үстерә. Тәрбия юлы белән яхшы табигый сәләтлелек билгеләрен үстерергә һәм начарларын киметергә була, ләкин моңа кешенең физик төзелешен, табигый үзенчәлекләрен исәпкә алган очракта гына ирешергә була.

Дидроның табигый аерымлыкларның кешеләр үсешендәге әһәмияте, тәрбияләгәндә баланың физик төзелеше һәм психикасындагы үзенчәлекләре белән исәпләшү зарурлыгы турындагы положениесе уңай бәягә лаек. Ләкин XVIII гасыр француз материалистик философиясенең чикләнгәнлеге сәбәпле, Дидро, ялгышып, кеше табигатен үзгәрмәүчән, абстракт бер нәрсә итеп карый. Асылда исә, кешенең табигате тарихи үсеш барышында үзгәрә.

Дидро, яхшы табигый сәләтлелек билгеләре аерым кешеләрдә генә дию дөрес түгел, киресенчә, аксөякләргә караганда гади халык арасында талантлар күбрәк очрый, — дип санаган.

Шул ук вакытта Дидро халык арасындагы талантлар күпләп һәлак була, чөнки начар иҗтимагый строй гади халыкның талантлы балаларын дөрес тәрбия һәм белем алудан мәхрүм итә диюе белән хаклы була. Ул киң халыкны мәгърифәтле итүне яклый, аның бик зур азатлык ролен таный. Дидро сүзләре белән әйткәндә, "мәгърифәт кешене абруйлы итә, һәм кол шундук үзенең кол булыр өчен тумаганлыгын аңлый".

Гельвеций шикелле үк, Дидро да француз феодаль тәрбия системасын тәнкыйтьләгән, руханилар кулындагы башлангыч мәктәпләр гади халык балаларын тәрбияләүгә игътибар итми, ә классик типтагы привилегияле урта мәктәпләр фәннәргә нпфрәт кенә

тәрбияли һәм бик начар нәтиҗә бирә, дигән. Укыту һәм тәрбия системасы бөтенләе белән яраксыз, "халык мәгарифе методын нигезенә кадәр үзгәртү кирәк".

Нинди социаль катлаудан булуларына карамастан, балаларның һәммәсе дә укырга тиеш. Мәктәпләр, руханилар карамагыннан алынып, дәүләт карамагына бирелергә тиеш. Башлангыч белем алу түләүсез һәм мәҗбүри булырга тиеш, мәктәпләрдә җәмәгать туклануы оештыру зарур. Ярлы балалары укуның кадерен бай балаларына караганда күбрәк белә. Дидро катгый рәвештә урта мәктәпне үзгәртеп коруны таләп иткән. Урта классик белем мәктәпләренең зарарлы йогынтысына каршы чыккан, аларда фәнни нигездә математика, физика, химия, табигать белеме, астрономия укытуны тәэмин итү зарур дип санаган, реаль белем бирүне тормышка ашыруны таләп иткән.

1773 елда Екатерина II чакыруы буенча Дидро бер елга якын Петербургка килеп яшәгән. Мәгълүм булганча, Екатерина ул чорда "мәгърифәтле эшлекле" һәм эзәрлекләнгән фәлсәфәчеләрне канат астына алучы ролен уйнаган.

Дидро 1775 елда "Россия өчен университет планы" исемле Россиядә халык мәгарифен яңа нигезләрдә оештыру планын эшли (университет дигәндә ул бөтен халык мәгарифе системасын күздә тота). Екатерина, әлбәттә, Дидро планын тормышка ашырырга җыенмый да, чөнки ул артык радикаль план була.

* * *

Тугызынчы лекция

ФРАНЦУЗ БУРЖУАЗ РЕВОЛЮЦИЯСЕ ЧОРЫНДА ПЕДАГОГИК ФИКЕР ҺӘМ МӘКТӘП

18 гасырның 70-80 елларында Франциядә революцион ситуация барлыкка килә.

Феодаль җәмгытьнең эчендә яңа капиталистик уклад формалары үсеп җитлегә. Әмма феодаль-абсолют монархия режимы капитализм, авыл хуҗалыгы, промышленность һәм сәүдә үсешен тоткарлый. 1789-1794 елгы француз буржуаз революциясе "өченче катлауның" феодализм белән кискен бәрелеше була. Ул феодаль-монархия строен җимерә һәм капитализм үсешенә җирлек әзерли. Гәрчә үз чорының тарихи шартларында XVIII гасыр француз буржуазиясе алдынгы, революцион сыйныф буларак чыкса да, революциягә көч һәм колачны фәкать халык массалары гына бирде. Шунсыз аның җиңүе мөмкин булмас иде. Халык революциядә төп катнашучы, аның хәрәкәтләндерүче көче була. Халык феодаль контрреволюция белән көрәшнең бөтен авырлыгын үз җилкәсендә татый, революцияне алга этәрә; халык массаларының революциядә иҗади катнашуы һәммә нәрсәдә, шул исәптән халык мәгарифе өлкәсендә дә күренә. Халык массалары мәгарифне оештыру белән кызыксына, белемгә омтыла. Күп гасырлар буенча феодаллар һәм руханилар халыкны караңгылык һәм наданлыкта тоталар. 1790 елда әле ирләрнең 53 проценты һәм хатын-кызларның 73 проценты укый-яза белми.

Мәктәпне яңа нигездә төзү мәсьәләләре гомуми кызыксыну уята. Бу өлкәдә тәкъдим ителгән проектларга француз мәгърифәтчеләре (аеруча Руссо) һәм француз материалистлары (Гельвеций, Дидро) идеяләре турыдан-туры йогынты ясый. Халык мәгарифен үзгәртеп кору проектлары тирәсендә кискен сыйнфый көрәш бара.

Ул чорда прогрессив буржуазия вәкилләре 1789-1794 елларда халык мәгарифе өлкәсендә күп кенә алдынгы идеяләр күтәреп чыгалар. Ләкин аларның берсе дә тормышка ашырылмый диярлек. 9 нчы термидор (1794 елның 27 июле) контрреволюцион перево-

ротыннан соң, эре реакцион буржуазия властька килгәч, аның мәнфәгатьләренә җавап бирүче халык мәгарифе системасы урнаша.

Бу чорда хезмәт ияләре халык мәгарифе өлкәсендә революция елларында ирешелгән аз гына казанышлардан да мәхрүм ителәләр.

Буржуаз француз революциясе чорында халык мәгарифен үзгәртеп кору буенча иҗат ителгән проектлардан иң прогрессивлары Кондорсе һәм Лепелетье проектлары була.

Кондорсе проекты. Жан Антуан Кондорсе (1743-1894) күренекле философ, экономист, математик, физик, шулай ук жирондистлар партиясе җитәкчеләреннән берсе була. Ул проектын Закон чыгару мәҗлесе оештырган иҗтимагый мәгариф комитетына тәкъдим итә.

Кондорсе: халыкка белем бирү — дәүләтнең бөтен гражданнар алдындагы бурычы; мәктәпнең һәммә баскычларында да укыту гомуми һәм бушлай, кыз һәм ир балалар өчен тигез булырга тиеш; дин сабагын укыту туктатылырга тиеш, дип игълан итә.

Кондорсе түбәндәге мәктәп системасын тәкъдим итә:

1) *Дүртьеллык курслы беренчел (башлангыч) мәктәп.* Нинди катлаудан һәм ата-аналарының нинди профессия кешеләре булуына карамастан, ул мәктәпкә барлык малайлар һәм кызлар да керергә тиеш. Бу мәктәпләр халкы 400 гә җиткән һәммә җирдә ачыла. Укыту программасы: уку, язу, грамматика һәм арифметикадан башлангыч мәгълүматлар, авыл хуҗалыгы һәм һөнәрләр белән, илдәге җитештерүнең гомуми торышы белән танышу. Моннан тыш, анда иҗтимагый строй һәм әхлак нигезләре өйрәнелә. Башкача әйткәндә, мәктәптә киң гомуми белем бирү программасы һәм хезмәткә өйрәтү күздә тотыла.

2) *Өчьеллык курслы икенче баскыч мәктәбе (икенчел мәктәп).* Аңа башлангыч мәктәпне тәмамлаучылар керә. Икенче баскыч мәктәбе халкы 4000 гә җиткән һәрбер шәһәр яисә округта ачыла. Укыту программасы: математика, табигать белеме, сәүдә буенча башлангыч мәгълүматлар, әхлак принциплары һәм җәмгыять белеме, һәрбер мәктәптә китапханә һәм машина модельләре, табигать белеменнән коллекцияләр, һөнәрчелек кораллары җыелмасы, метеорологик күзәтүләр өчен приборлар куелган кабинетлар булырга тиеш.

3) *Институтлар* — бишьеллык курслы уку йортлары, анда урта белем алу тәмамлана һәм яшьләр тормышта турыдан-туры катнашу өчен беркадәр профессиональ әзерлек алалар. Кондорсе

бөтен илгә нибары 110 институт ачарга тәкъдим иткән, ягъни гади халыкка мондый төр белем алу мөмкинлеге булмаган. Институтларда, Кондорсе фикеренчә, профессиясенә карамастан, һәрбер кеше һәм гражданин өчен дә файдалы фәннәргә өйрәтәләр, һәм авыл хуҗалыгы, механика, хәрби эш, медицина буенча беркадәр профессиональ белемнәр бирәләр.

4) *Лицейлар* — югары уку йортлары (бөтен Франциядә унбер лицей) — аерым кешеләр, буржуаз җәмгыятьнең югары катлавы өчен феодаль реакциянең терәге булган схоластик университетлар урынына ачыла.

Шул рәвешле, Кондорсе үзенең проектында бердәм дөньяви мәктәп идеясен күтәреп чыга. Анда барлык баскычтагы мәктәпләр дә административ яктан һәм программалары белән үзара бәйле була, чөнки институтлар — үз департаментындагы мәктәпләр белән, ә лицейлар үз округларындагы институтлар белән идарә итә. Уку йортларының бөтен системасы белән исә Фәннәр һәм сәнгать милли институты — административ һәм тикшеренү үзәге идарә итәргә тиеш.

Шушы системасын нигезләп, Кондорсе болай ди: *кеше акылы белем тәэсирендә чиксез үсешкә сәләтле, кешелекнең алга таба үсүе фән ирешкән уңышларга бәйле.*

Кондорсе проекты тулаем алганда прогрессив була, ләкин аның күп кенә положениеләрендә халык мәнфәгате түгел, ә күтәрелеп килүче буржуазия мәнфәгате чагылыш таба.

Мәсәлән, Кондорсе укучыларның матди хәлен яхшырту өчен берни дә тәкъдим итми, ә шул ук вакытта фәкыйрь ата-аналарның балаларын эшләтмичә укыту мөмкинлекләре булмаган. Дин урынына яңа, буржуаз җәмгыятьтә үзенең тотуның төп нормаларын ныгытырга тиешле буржуаз әхлак курсы кертелгән.

Ләкин Кондорсе проектында прогрессив таләпләр дә чагылыш таба: дин сабагын укыту бетерелә, дөньяви мәктәп яклана, физика-математика фәннәренең зур әһәмияте ассызыклап күрсәтелә, белем алуда ирләр һәм хатын-кызларның тигез хокуклыгы таныла.

Кондорсе проекты Закон чыгару мәҗлесендә тыңлана, әмма кабул ителми. Аны Конвентка тапшыралар.

Конвент 1793 елның 30 маенда нигезенә Кондорсе проекты салынган декрет кабул итә. Бу декретта дәүләтнең барлык гражданнарга башлангыч мәктәп күләмендә белем бирергә тиешлеге таныла, әмма укытуның түләүсезлеге һәм мәҗбүрилеге, белем

алуга ирләр һәм хатын-кызларның тигез хокуклылыгы, укытуның дөньяви характеры турында берни дә әйтелми. Башлангыч мәктәпләрне 400 дән 1500 гә кадәр халкы булган торак пунктларда ачу күздә тотыла. Шул рәвешле, Кондорсе проектының күп кенә прогрессив идеяләреннән жирондистлар үзләре баш тарталар.

Лепелетье проекты. Жирондистлар Конвенттан куылгач, власть тулысынча ул чорда иң революцион партия — якобинчылар кулына күчә. Якобинчылар халык массаларының таләпләренә җавап бирә торган күп кенә чаралар үткәрәләр (спекуляция белән көрәш һ.б.), халык мәгарифе мәсьәләләрен дә башкача куялар. Иҗтимагый белем комитеты яңадан сайлана. Бу чорда Лепелетье проекты бик популяр була, аны "Якобинчылар клубы", Париж секцияләре энтузиазм белән каршылый, Конвентның бик күп депутатлары уңай бәяли. Бу уңышны ике нәрсә белән аңлатып була. Беренчедән, Кондорсе проектының йомшак якларын исәпкә алып һәм хезмәт ияләре теләгенә туры китереп, Лепелетье белем бирүне халыкка аңлаешлы итәргә омтылган. Икенчедән, монда автор шәхесе дә зур роль уйнаган. Гәрчә **Луи Мишель Лепелетье** (1760-1793) аксөякләр гаиләсеннән булса да, мәсләге буенча ул якобинчыларга кушыла һәм корольгә үлем җәзасы бирүне яклап тавыш бирә, шуның өчен король гвардиясе офицеры тарафыннан үтерелә.

Лепелетье үлгәннән соң, аның проектын энесе мәгариф турында яңа закон әзерләү комиссиясенә бирә, ул комиссиянең башында якобинчыларның юлбашчысы Робеспьер тора. Заманына күрә иң прогрессив документ — Лепелетье проектында мәктәпне чын-чынлап бөтен халыкныкы итү һәм "бердәнбер байлыклары хезмәт булган граждан-пролетарийларга" ярдәмгә килү теләге ачык чагылыш тапкан. "Мескен бала,— ди Лепелетье,— сез аңа укырга тәкъдим итәсез, тик сез иң элек аңа бер сынык ипи бирегез". Нәкъ менә шушы позицияләрдән ул Кондорсе проектын кискен тәнкыйтьли. Бу проектта, ди Лепелетье, гомуми башлангыч белем бирү игълан ителгән генә, чынлыкта исә бу белемне халыкның фәкыйрь өлеше алу мөмкинлеген тәэмин итәргә кирәк.

Француз мәгърифәтчеләре эшен дәвам иттерүче Лепелетье яңа эшен иҗат итүдә тәрбиянең хәлиткеч ролен яклый. Шушы максаттан ул милли тәрбия йортлары оештырырга тәкъдим итә. Дәүләт акчасына көн күрүче бу йортларда барлык балалар да: 5 яшьтән 2 яшькә кадәрге малайлар һәм 5 яшьтән 11 яшькә кадәрге кызлар

әзерлек ала. 600 гә кадәр балага исәпләнгән мондый "йортлар" шәһәрләрдәге һәрбер районга бирәү һәм авылларда бер канунга бирәү оештырылырга тиеш. Руссога ияреп, Лепелетье интернаттагы балалар мохитнең зарарлы йогынтысыннан аерылган булачаклар дип саный. Мондый "йортлар" конфискацияләнгән дворян замокларында һәм монастырь биналарында урнаштырырга мөмкин. Аларны тоту чыганакларының берсе керемгә карап салына торган прогрессив налог булырга тиеш, шул чагында "ярлы балалары байлар исәбенә тәрбияләнәчәк". Моннан тыш, балаларның үзләренең җитештерүчән хезмәте бу "йортларны" тотуга өстәмә чыганак булачак.

"Милли тәрбия йортларында" балаларның физик тәрбиясенә игътибар ителергә тиеш, ләкин гимнастик күнегүләр белән генә чикләнергә ярамый, басу-кырларда һәм махсус остаханәләрдә планлы рәвештә физик хезмәт оештырырга кирәк. Ул "йортларда" хезмәт күрсәтүче персонал булырга тиеш түгел: барысын да балалар үзләре эшли. Эш тәнне чыныктыра, мускулларны ныгыта һәм, иң мөһиме, "хезмәткә күнегү" тәрбияли.

Лепелетье акыл үстерүнең киң программасын да тәкъдим итә: "йортларда" язу, хисап, геометрия элементлары, әхлак, иҗтимагый төзелеш ("Кеше һәм гражданин хокуклары декларациясе"н өйрәнү), ирекле халыклар һәм француз революциясе тарихыннан хикәяләр, авыл хуҗалыгы һәм йорт эшләре нигезләре өйрәнелергә тиеш.

Нәтиҗәдә, Лепелетье фикеренчә, яңа яшь буын, "көчле, эш сөючән, тәртипле һәм намуслы, яңа гражданнар, патриотлар булып тәрбияләнәчәк".

Лепелетье проекты, һичшиксез, революцион һәм демократик характерда, ләкин шул ук вакытта ул вак буржуаз утопия дә була.

"Милли тәрбия йортлары" оештыру "басынкы һәм тыныч революцияне" тормышка ашырачак, фәкыйрьләрне байлар исәбенә тәрбияләү юлы белән иҗтимагый тигезсезлекнең кимчелекләрен төзәтәчәк, дип саный Лепелетье, ләкин бу утопия була. Шул ук вакытта аның проекты мәгарифне халык мәнфәгатьләрендә катгый демократияләштерү юлларын билгели.

Конвентта проектны тәнкыйтьлиләр: аерым алганда, аны тормышка ашырган чакта туачак кыенлыкларны күрсәтәләр. 1793 елның 13 августында Лепелетье проекты кабул ителә, әмма түбәндәге төзәтмә белән: балаларны "милли тәрбия йортларына" бирү мәҗбүри түгел, "йортлар" белән беррәттән, килеп укучы балалар өчен

дә мәктәпләр ачарга кирәк. Ләкин бу карар да шул ук елның октябрендә юкка чыгарыла. Лепелетье проектының язмышы Конвентның бик күп өлкәләрдәге, шул исәптән халык мәгарифе өлкәсендәге, зур башлангычларының ахырына кадәр җиткерелмәве турында сөйли.

Башлангыч мәктәпләр челтәрен җәелдереп җибәрү турындагы практик мәсьәлә дә хәл ителми. Гәрчә 1793 елның декабрендә Конвент мәҗбүри башлангыч белем бирү турында декрет кабул итсә дә, 1794 елның уртасына ачылырга тиешле 23 мең мәктәп урынына нибары 8 мең мәктәп эшли.

Термидориан реакциясе чорында мәктәп. Гракх Бабефның педагогик идеяләре. Халык мәгарифе өлкәсендә бераз гына ирешелгәннәр дә 9 нчы термидор переворотыннан соң яңа властьлар тарафыннан юкка чыгарылган. Мәсәлән, 1894 ел ахырында — башлангыч белем бирүнең мәҗбүрилеге, ә бер елдан соң аның түләүсезлеге бетерелә.

Шул ук вакытта яшь гражданнар күбесе өчен югарырак белемгә омтылуның кирәксезлегенә басым ясала. Буржуазия балаларын укыту өчен хосусый мәктәпләр ачарга рөхсәт ителә. Урта белән үзәк мәктәпләрдә (330 мең халкы булган җирдә бер мәктәп) бирелә. Буржуазия балаларын "промышленность эшчәнлегенә" әзерләүче бу мәктәпләр программасында реаль белемнәргә: физика, математика, табигать белеменә зур игътибар бирелә.

Шул ук вакытта “Иҗтимагый эшләр үзәк мәктәбе” дигән атаклы югары мәктәп ачыла. Тиздән ул Политехник мәктәп дип йөртелә башлый һәм соңрак физика-математика фәннәрен үстерү эшендә күренекле роль уйный.

Бөтен мәктәп системасы гади халык балаларына белем бирүне чикләүне күздә тотып үзгәртеп корыла.

Термидориан реакциясе чорына хезмәт ияләренең килеп туган хәлдән ризасызлыгы көчәя. 1795-1796 еллар башында Гракх Бабеф торган революционерлар төркеме Директорияне бәреп төшерү һәм 1793 елгы конституцияне торгызу максатында восстание әзерли башлый. Бабеф гражданнарның тулы социаль тигезлегенә ирешү бурычын куя. Энгельс әйтүенчә, Бабеф революция чорындагы француз демократиясе идеяләреннән соңгы нәтиҗәләр ясый.

Бабеф һәм аның тарафдарлары революцион юл белән властьны алып, коммунистик строй урнаштыруны максат итеп куялар. Ләкин алар булачак стройны тигезләүчелек коммунизмы итеп күзаллый-

лар. Восстаниене әзерләгән Комитет яңа кеше тәрбияләүгә бәйле күп кенә педагогик мәсьәләләрне дә тикшерә. Дөрес оештырылган тәрбияне Комитет социаль тигезлекнең нигезе итеп карый. Тәрбия милли булырга, яңа дәүләт власте тарафыннан оештырылырга, чын-чыннан гомуми һәм тигез, ягъни барлык балалар өчен дә бертөрле булырга тиеш. Тәрбиянең төп бурычы — ялкынлы патриотлык, революцион ватанга мәхәббәт үстерү. Яңа кешеләр белемле һәм яхшы физик үсешкә ия булачак. Авыл җирләрендә "тәрбия коммуналары" оештырылырга тиеш, анда балалар, җәмгыятьтән аерылып чын гражданнар һәм коммунистлар булып үсәчәк.

Ләкин Бабефта, бик кыйммәтле идеяләр белән беррәттән, карашларның чикләнгәнлеге нәтиҗәсе буларак, ялгыш положениеләр дә бар. Ул промышленностьның, пролетариат роленең әһәмиятен аңламаган, шәһәргә тискәре караштa торган, җәмгыять үсешендә фәннең әһәмиятенә бәя бирмәгән.

Бабефның педагогик карашларына һәм "Тигезләр заговоры" комитетының тәрбия мәсьәләләре буенча тәкъдимнәренә Руссо һәм Лепелетьеның йогынтысы бик зур була.

1789-1794 еллардагы француз буржуаз революциясе чорында халык мәгарифен үзгәртеп кору буенча күп кенә проектларда чагылыш тапкан педагогик идеяләр дөньяның бик күп илләрендә прогрессив педагогик фикер үсешенә зур йогынты ясый.

* * *

Унынчы лекция

ИОГАНН ГЕНРИХ ПЕСТАЛОЦЦИНЫҢ ПЕДАГОГИК ИДЕЯЛӘРЕ

Песталоццины ң педагогик эшчәнлеге. Иоганн Генрих Песталоцци (1746-1827) Швейцариянең Цюрих шәһәрендә врач гаиләсендә туа. Аның тәрбиясенә әнисе һәм турылыклы хезмәтчеләре, гади крестьяннар зур йогынты ясыйлар. Песталоцци крестьяннарның авыр хәле белән якыннан таныша һәм кече яшьтән халыкка тирән теләктәшлек итә.

Песталоцци әүвәл башлангыч мәктәптә, аннары латин урта мәктәбендә һәм гуманитар юнәлештәге югары уку йорты — коллегиумның филология һәм фәлсәфә бүлекләрендә белем ала. Коллегиумда француз мәгърифәтчеләре йогынтысында алдынгы, демократик идеяләр үскән була.

Песталоцци француз мәгърифәтчеләренең әсәрләрен яхшы белгән, 17 яшендә Руссоның "Эмилен" укып чыккан. "Иҗтимагый килешү" шикелле үк, бу әсәр дә үсмергә бик нык тәэсир иткән һәм аның үзен аямыйча халыкка хезмәт итү ниятен ныгыткан. Цюрихның алдынгы яшьләре "Тире иләүчеләр йортындагы Гельвеция (Швейцария) җәмгыяте" дигән түгәрәк оештыралар (аның җыелышлары күнчеләр цехы йортында уза торган була). Үзләрен "патриотлар" дип атаучы түгәрәк әгъзалары әхлак, тәрбия, сәясәт проблемаларын тикшерәләр, крестьяннарны талап бөлгенлеккә төшерүче түрәләрне фаш итү белән шөгыльләнәләр. 1767 елда түгәрәкне шәһәр властьлары яба, ә яшь кенә Песталоцци түгәрәкнең башка әгъзалары белән беррәттән кулга алына. Коллегияне тәмамлагачтан, ул халыкның хәлен яхшырту турында изге хыялын тормышка ашыру белән шөгыльләнергә ниятли. 1769 елда ул социаль эксперимент башлый. Бурычка алган акчасына кечкенә генә биләмә сатып ала, аңа "Нейгоф" ("Яңа хуҗалык") дигән исем бирә. Бу хуҗалыкта тирә-юньдәге крестьяннарны хуҗалык алып барырга өйрәтү өчен, күргәзмә ферма оештырмакчы була. Тәҗрибәсез Песталоцци тиздән бөлгенлеккә төшә.

1774 елда ул Нейгофта "Фәкыйрьләр өчен приют" ача, шунда ятим һәм караучысыз калган иллеләп бала җыя. Пестолоцци уенча, приют балаларның үз хезмәтләре исәбенә яшәргә тиеш була. Тәрбияләнүчеләр кырда, шулай ук туку һәм эрләү станокларында эшлиләр. Песталоцци үзе балаларны укырга, язарга, хисапка өйрәтә, тәрбияли. Шул рәвешле приютында балаларны укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү омтылышы ясап карый.

Песталоцци: "кеше хезмәтеннән фабрика индустриясе ала торган табышның шактый өлешен тулаем кешелек ихтыяҗларына туры килә торган чын тәрбия учреждениеләре төзүдә файдаланырга уйлаган идем...",— дип яза. Ләкин, кулларында сәяси власть һәм матди средстволар тупланган даирәләр тарафыннан яклау тапмаган-лыктан, аның эше барып чыкмый. Балалар приютны көч җитмәслек авыр хезмәт исәбенә генә тота алалар, әмма гуманист һәм демократ Песталоцци аларны эксплуатацияләүгә бара алмый һәм барырга теләми дә. Ул балалар хезмәтенә, иң элек аларның физик көчләрен, акыл һәм әхлакый сәләтләрен үстерү чарасы итеп карый, балаларда тар һөнәр күнекмәләре түгел, ә күпьяклы хөрмәткә әзерлек тәрбияләргә омтыла.

Песталоцциның Нейгоф тәҗрибәсенең бик зур әһәмияте шунда. Тәҗрибәсен дәвам итәргә матди средстволары булмау сәбәпле, ул тиздән приютын ябарга мәҗбүри була. Ләкин уңышсызлыклар аны халыкка ярдәм итү юлыннан тайпылдыра алмый. Песталоцци, игътибарны крестьяннарның хуҗалыгын ничек торгызырга, тормышларын ничек җитешле итәргә, хезмәт ияләренең әхлак һәм аңнарын ничек күтәрергә дигән мөһим мәсьәләне хәл итүгә юнәлтергә омтылып, унҗиде ел буе әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнә. 1781-1787 елларда "Лингард һәм Гертруда" дигән социаль-педагогик роман яза. Романда төпле хуҗалык итү һәм балаларга дөрес тәрбия бирү методлары ярдәмендә крестьяннарның тормышын яхшырту идеяләрен алга сөрә.

Песталоцци, әлбәттә инде, киң танылa. 1792 елда революцион Франциянең Закон чыгару мәҗлесе, ирек өчен көрәшеп, дан казанган 18 кешегә, шул исәптән Песталоццига да, француз гражданины дигән мактаулы исем бирә.

1798 елда Швейцариядә буржуаз революция була һәм Гельвеция (Швейцария) республикасы төзелә. Станц шәһәрендә дворяннар һәм католик руханилар коткысы белән крестьяннарның контрреволюцион восстаниесе кабына. Ул бастырылганнан соң бик күп

караучысыз балалар кала. Яңа хөкүмәт Песталоццига шулар өчен тәрбия учреждениесе оештырырга куша. Элеккеге монастырь бинасында Песталоцци приют ача, анда 5 яшьтән 10 яшькә кадәрге 80 бала кабул ителә. Балаларның хәле физик яктан да, мораль яктан да коточкыч була.

Песталоцци приютны зур бер гаилә итәргә омтыла, аларга кайгыртучан ата һәм якын дус була.

Станцта чагында дусларының берсенә язган хатында ул болай ди: "Иртәдән кичкә кадәр мин алар арасында берүзем идем...

Кулларым — аларның кулларында, күзләрем аларның күзләрендә булды. Алар белән бергә еладым, алар белән бергә көлдем. Минем бернәрсәм дә: йортым да, дусларым да, хезмәтчеләрем дә юк иде, фәкать алар гына". Песталоццины аталарча кайгыртуына тәрбиядәге балалар ихлас якын итү һәм мәхәббәт белән җавап бирәләр, бу исә аларның әхлак тәрбиясен уңышлы тормышка ашырырга ярдәм итә.

Хәрби хәрәкәтләргә бәйле рәвештә приют бинасын лазаретка алалар, приютны ябалар. Песталоцци 1799 елдан Бургдорф шәһәре мәктәпләрендә эксперименталь эш алып бара башлый. Ул балаларны укырга-язарга һәм хисапка өйрәтү буенча үз методикасының укытуның традицион ысулларыннан өстенлеген исбатлый ала, һәм властьлар аңа бу методиканы киңрәк кулланырга рөхсәт итәләр.

Бургдорфта интернатлы урта мәктәп һәм шул мәктәп каршында Песталоцци җитәкчелегендә укытучылар әзерләү бүлеге ачыла. XIX гасыр башында аның "Гертруда балаларын ничек укыта", "Аналар китабы, яки балаларны күзәтүгә һәм сөйләмгә өйрәтү буенча Аналар өчен кулланма", "Күргәзмәлелек әлифбасы, яки Үлчәм турында күргәзмә тәгълимат", "Саннар турында күргәзмә тәгълимат" дигән әсәрләре чыга, аларда башлангыч белем бирүнең яңа ысуллары тасвирлана.

1805 елда Песталоцци институтын Швейцариянең француз өлешенә — Ивердонга (немецча исеме — Ифертен) күчерә һәм үз карамагына бирелгән замокта зур институт (урта мәктәп һәм педагогик уку йорты) оештыра. Институт тиздән бөтен дөньяга танылa. Анда галимнәр, язучылар, сәяси эшлеклеләр килеп йөри, университетларга керергә яисә чиновник булырга әзерләнүче бик күп аксөяк һәм бай буржуаз балалары укый.

Тәгълиматы һәм эшчәнлеге халык массалары өчен түгел, ә аксөякләр һәм байлар мәнфәгатьләрендә файдаланылуына Песта-

лоцци бик көенә. 1825 елда өмете өзелгән Песталоцци илле ел элек социаль-педагогик эшчәнлеге башланган Нейгофка кайта. Биредә сиксән яшендә ул үзенең соңгы әсәрен — "Аккош җырын"н яза (1826). Үз-үзен аямыйча бөтен көчен һәм талантын хезмәт ияләренә бирүенә карамастан, аларның авыр социаль һәм матди хәлләрен яхшырта алмавының сәбәбен аңлый алмыйча, Песталоцци 1827 елда дөнья куя.

Песталоцциның социаль-педагогик һәм фәлсәфи карашлары. Песталоцциның карашлары демократик характерда, ләкин гарихи чикләнгән була. Песталоцци халкын яңадан аякка бастыру турында хыяллана, ләкин хезмәт ияләренең тормышын аларны укыту һәм тәрбияләү юлы белән үзгәртү мөмкинлегенә ышана. Ул чордагы җәмгыятьтә кешеләрнең социаль һәм хокукый тигезсезлеге яшәп килгән иҗтимагый мөнәсәбәтләр нәтиҗәсе икәнлеген аңламый, халык михнәтләренең чыганагын икътисади шартлардан түгел, ә мәгърифәт булмаудан күрә.

Тәрбия һәм белем бөтен халык казанышы булырга тиеш дип раслап, Песталоцци җәмгыятьне социаль үзгәртеп коруның мөһим рычагларыннан берсе итеп мәктәпләрне санаган. Аның фикеренчә, Һәрбер кешенең чын кешелек көчләрен уятып ныгытканда гына күптәннән борчып торган социаль проблемаларны хәл итү, җәмгыятьне тамырдан үзгәртеп кору мөмкин булачак. Моны фәкать тәрбия процессында гына эшләп була.

Песталоцци кешене тәрбияләү һәм үстерүнең бик мөһим чарасы дип хезмәтне саный. Хезмәт физик көчләрне генә түгел, акылны да үстерә, шулай ук әхлак та формалаштыра. Эшләгән кешедә хезмәтнең җәмгыять тормышында бик зур роль уйнавына ышаныч туа, шул ышаныч кешеләрне ныклы иҗтимагый союзда берләштерүче мөһим көч булып тора.

Песталоцци һәр кешедәге көчләрнең үзлегеннән үсү идеясен, кешенең һәрбер сәләте тикторыш хәленнән чыгарга, җитлеккән көч булырга омтыла дигән идеяне алга сөрә. "Күзнең — күрәсе, колакның — ишетәсе, аякның — йөрисе, кулның — тотасы килә,— ди Песталоцци. Шулай ук йөрәк тә ышанырга, яратырга тели. Акылның фикер йөртәсе килә".

Кешенең шулай рухи һәм физик эшчәнлеккә омтылуы, Песталоцци уенча, аңа ходай тумыштан биргән сыйфат, тәрбия аны тормышка ашыруга булышлык итәргә тиеш.

Бөтен тәрбиянең үзәге — кешенең әхлагын формалаштыру; "кешеләрне эшлекле ярату" — кешене әхлакый мөнәсәбәттә шушы нәрсә алга алып барырга тиеш. "Кешеләрне эшлекле ярату" "табигый дин"гә дә бәйле. Рәсми дингә һәм руханиларга Песталоццины карашы тискәре була. "Алдакчы,— ди ул изге атага,— дөнья яратылганнан бирле син, кешеләрне ахмак мәҗүсилеккә күндерү өчен, алла исемен файдаланасың... Син үлем байраклары белән селтәнәсең, әйтерсең лә алар мәхәббәт байраклары".

Танып белү, ди Песталоцци, тоеп сиземләүдән башлана һәм күзаллауларны эшкәртү юлы белән кеше аңында төзүче көчләр буларак яшәүче, әмма ачылу һәм җанлану өчен тойгылар бирә торган материалга мохтаҗ идеяләргә барып тоташа.

Песталоццины дөньяга карашы тулаем алганда идеалистик, булса да, прогрессив характерда, чөнки гуманизм, демократик омтылышлар белән сугарылган һәм анда беркадәр материалистик раслаулар һәм диалектик положениеләр бар.

Тәрбиянең максаты һәм асылы. Башлангыч белем бирү теориясе. Песталоцции фикеренчә, тәрбиянең максаты — кешенең барлык табигый көч һәм сәләтләрен үстерү, өстәвенә әле ул күпьяклы һәм гармонияле үсеш булырга тиеш.

Тәрбиянең йогынтысы бала табигатенә туры килергә тиеш. Педагог баланың табигый үсешен тоткарларга түгел (мәктәпләрдә шулай булган), ә бу үсешкә дөрес юнәлеш бирергә, аны тоткарлау һәм читкә юнәлтү ихтималы булган каршылык һәм йогынтыларны бетерергә тиеш.

Песталоцци аңлавынча, тәрбиянең төп принцибы — табигать белән ярашу. Ләкин максатчан тәрбия һәр кешегә дә кирәк, чөнки ансыз, кеше җәмгыять әгъзасы буларак, аннан таләп ителгән дәрәҗәдә барлык көчләренең үсешенә ирешә алмаячак.

Песталоцци бала табигатен идеаллаштырмый. Ул: "Әгәр табигатьнең кеше көчләрен үстерүгә куйган тырышлыкларына ярдәм итмәсәң, кешеләр бозык-хайвани хисиятләреннән әкрен котылалар,— дип саный. Дөрес куелган тәрбия балаларга кешелек көчләрен үстерүдә ярдәм итәргә тиеш. Баланың тәрбиясе белән үсеше арасындагы бәйләнешне Песталоцци образлы итеп болай тасвирлый: тәрбия үзенең бинасын бик нык утырган зур кыя (табигать) өстендә төзи (кешене формалаштыра) һәм шул кыяда һәрвакыт нык торса — куелган максатларына ирешә.

Тәрбиянең асылы турында шундый күзаллаудан чыгып, Песталоцци кешенең көчләрен аның табигатенә ярашлы рәвештә үстерергә ярдәм итүче яңа тәрбия методлары булдырырга омтыла. Баланың тәрбиясе, ди ул, сабый дөньяга килгән көннән үк башланырга тиеш: "Бала туган сәгать — аның беренче уку сәгате". Менә шуңа күрә дә чын педагогика — ананы дөрес тәрбия методлары белән коралландырырга, ә педагогик сәнгать бу методиканы шулкадәр гадиләштерергә тиеш ки, аны теләсә кайсы ана, шул исәптән гади крестьян хатыны да үзләштерә алсын. Гаиләдә башланган табигатькә ярашлы тәрбия соңыннан мәктәптә дәвам итәргә тиеш, әлбәттә.

Песталоцци ул чордагы мәктәпләрне антипсихологик мәктәпләр дип атый. Табигатьтән аерылган балалар ул мәктәпләрдә озак вакытка салкын һәм үле хәрефләр дөньясына, чит сүзләр ташкынына кереп китәләр. Үсәсе урынга бала мондый хәлдә томаналана гына, чөнки аның ихтыяҗлары һәм омтылышлары белән исәпләшүче булмый.

Песталоцци фикеренчә, **баланың барлык көчләре табигый юл белән үсәргә тиеш.** Кешеләргә мәхәббәт — кешеләрне яратуның нәрсә икәнлеге, ни өчен аларны яратырга кирәклеге турында бертуктаусыз сөйләп тору юлы белән түгел, ә баланың үзенең игелекле эш-гамәлләре нигезендә үссен. Акыл, кеше фикерләрен үзләштерү юлы белән түгел, ә үз башыңны эшләткәндә камилләшә. Баланың физик үсеше, аны хезмәткә хәзерләү, шулай ук, иң гади физик көчләр эшкә җигелгәндә башкарыла. Кешенең физик көчләре тормыш зарурлыгы һәм кешенең эчке ихтыяҗы тәэсирендә хәрәкәткә килә.

* * *

Унберенче лекция

КӨНБАТЫШ ЕВРОПАда ҺӘМ АКШта ПЕДАГОГИК ФИКЕР

Мәктәп һәм педагогика үсешендә империализмның аерым үзенчәлекләре чагылышы. XX гасыр ахырында иске, "ирекле" капитализмның империализмга әверелү чоры башлана. Бу чакта Көнбатыш Европада монополистик капитализм үсә бара, һәм XX гасыр чигендә финанс капиталның өстенлеге урнаша. Бөтен дөнья капиталистик илләр тарафыннан бүленгән булган һәм дөньяны яңадан бүлү мәсьәләсе чиратка куелган, ә бу инде империалистик сугышларга китергән. Империализм ул сәясәттә һәм идеологиядә реакциянең һөҗүмгә күчүен аңлата. Империализм чорында сыйнфый каршылык кискенләшкән шартларда буржуазия теорияләре кризис кичерәләр. Реакцион империалистик буржуазия идеологлары хезмәт ияләрен эксплуатацияләүнең артуын, милләтчелекнең, милитаризмның көчәюен, яулап алу сугышларын акларга, буржуаз стройның мәңгелеген, гаделлеген һәм какшамаслыгын ничек булса да расларга омтылалар. Реакция педагогика фәненә дә, мәгарифнең нигезенә, халык мәгарифе өлкәсендәге буржуазия сәясәтенә турыдан-туры йогынты ясый.

Капиталистик үсешкә ия булган илләрдә (АКШ, Франция, Англия, Германия) буржуазия мәктәп мәгарифен киңәйтергә һәм яхшыртырга мәҗбүр була. Чөнки аңа катлаулы машиналар белән эш итә алучы, җитештерүнең белемле хезмәткәрләре кирәк булган. Шул ук вакытта пролетариат саны арта, эксплуататорлар белән оешкан төстә көрәш ныгый, халыкның капиталистик изүгә каршы каршылыгы көчәя бара. Пролетариат өзлексез рәвештә мәктәпне һәм мәгарифне халык мәнфәгате өчен үзгәртеп коруны таләп итә.

Революцион социал-демократларның мәктәп һәм халык мәгърифәте өчен көрәше. Марксизмга нигез салучылар тәгълиматына таянып, революцион социал-демократлар, хезмәт ияләренең мәгърифәте, аларның балаларына яхшы сыйфатлы белем бирү өчен актив көрәш алып барганнар.

Француз социалисты Поль Лафарг (1842-1911) Париж коммунасын, эшчеләрнең беренче хөкүмәте буларак, кайнар сәламлә-

гән һәм аның мәгариф өлкәсендәге тәҗрибәсен югары бәяләгән. Пролетариат дошманы булган идеологиягә, дингә ул бөтен гомере буенча эзлекле рәвештә каршы чыккан, мәктәп мәгарифенең дөньявилыгын, халык укырлык мәктәпне яклаган.

Август Бебель (1840-1913) рәхимсез реакция шартларында герман социал-демократиясенә нигез салучыларның берсе булган. Франко-Пруссия сугышы чорында рейхстаг депутаты буларак Париж коммунасын яклау авазын күтәреп чыккан, коммуна үткәргән гамәлләрне хуплаган. "Йөрәгендә ирек һәм бәйсезлек хисләре сакланып калганнар барысы да Парижга ышаныч белән карыйлар. Киләчәк изелгәннәр өчен булачак",— дип кыю рәвештә әйткән. Бебель теориягә зур әһәмият биргән. Эшчеләргә фәнни нигездә киң һәм тирән белем бирүне таләп иткән. Хезмәт ияләренең белем алуга хокукын, "кешелекнең изелгән өлеше" — хатын-кызлар мәнфәгатьләрен кайнар яклап чыккан. Шул ук вакытта, ул халыкның чын мәгарифе тик пролетар революциясеннән соң гына мөмкин булачак, дип санаган.

Клара Цеткин (1857-1933) — XX гасырның 80 нче еллардагы герман социал-демократиясенең күренекле эшлеклесе. Пролетар революция, пролетариат диктатурасы, хатын-кызны капитализм богауларыннан азат итү, яңа мәктәп өчен ялкынлы көрәшче. Берничә хезмәтендә ("Мәктәп мәсьәләсе һәм эшчеләр сыйныфы", "Школьный вопрос и рабочий класс, "Хатын-кыз һәм аның икътисади хәле" — бүлек: "Хатын-кыз һәм балаларны тәрбияләү" бүлеге һ.б. ("Женщина и ее экономическое положение — глава "Женщина и воспитание детей" и др.) ул марксистик позицияләреннән чыгып Германиядәге мәгариф хәленә анализ үткәргән, буржуазия мәдәниятен һәм мәктәбен кискен тәнкыйтькә тарткан. Буржуазия җәмгыяте мәдәнияте товар дәрәҗәсенә кадәр төшерде, ул товарны акчасы булган һәркем сатып алырга мөмкин, диеп аңлаткан.

XX гасыр чигендәге герман мәктәп хәлен Клара Цеткин бер дә канәгатьләнерлек түгел, дип тапкан. Күп фактик материалларны анализлаганнан соң халык мәктәбендә укытуның тар карашлары һәм шовинистик юнәлешле икәнен, урта һәм югары мәктәптә хезмәт ияләре өчен керү мөмкинлеге юклыгын, барлык мәктәпләрдә дә балалар аның укыту эчтәлеге белән агулауларын ачыклап күрсәткән. Революция генә педагогика һәм мәктәпне кискен рәвештә үзгәртә ала. Бу, ләкин, пролетариат революциясе булганчы мәгарифнең, мәктәпнең, барлык эшен, укыту эчтәлеге

үзгәрүнең, хезмәт ияләре өчен барлык төрдә укыту мөмкинлегенең яхшыруын башкармаска дигәнне аңлатмый.

Клара Цеткин гомуми мәҗбүри түләүсез башлангыч укытуны таләп иткән, ярлы балаларны дәүләт исәбенә уку ярдәмлекләре, туклану һәм кием белән тәэмин итүне кирәк дип тапкан. Динне мәктәптән катгый рәвештә алып ташларга, дип таләп куйган.

Урта мәктәпнең уку планын һәм программасын беренче чиратта тарих һәм табигать белеме буенча үзгәртеп коруны тәкъдим иткән, тарихны укытканда шовинизмнан котылырга, табигать белемен укыту фәнни булырга, библия риваятьләреннән һәм чиркәү догматикасыннан азат ителергә тиеш дип язган К. Цеткин. Буржуазия мәктәптә әдәбиятны үзенең сыйнфый мәнфәгатеннән чыгып укыта, әдәбият нык үзгәртелеп бирелә, моның белән кискен көрәш алып барырга, балаларга прогрессив әдәбиятта чагылдырылган чын тормышны күрсәтергә, аларны күндәмлеккә түгел, ә көрәшергә өйрәтергә кирәк, дип әйткән ул.

Хатын-кызларга тигез хокук бирү өчен көрәш кирәк. Шуңа күрә берләштереп укыту, **К. Цеткин** фикеренчә, зур сәяси роль уйный. Хатын-кызга беленмәгән табигый көчләрен кулланырга никадәр күбрәк мөмкинлек бирсәләр, пролетариатның азатлык өчен көрәшендә ул шулкадәр тизрәк катнаша башлаячак. Хатын-кызны җәмгыять тормышында катнашырга актив тартырга кирәк, шуның сәбәпле, балаларны иҗтимагый тәрбияләү эшен киң җәелдерергә кирәк һәм бу эш киләчәктә иң таралган булып танылачак.

Клара Цеткин ясле, балалар бакчасы һәм балаларның башка учреждениеләр челтәрен киңәйтү өчен көрәшкән, мәктәп һәм балалар бакчалары биналарының архитектура, педагогика һәм гигиена якларыннан үрнәк булган яңа типларын төзү турында таләпләр куйган.

Бөтен гомере буе ул халык мәгарифе өчен эзлекле көрәштә катнашкан, марксистик педагогиканың күренекле теоретигы булган. Ул Советлар Союзында булган, совет мәктәбе һәм педагогикасы тәҗрибәсен өйрәнгән һәм пропагандалаган.

Карл Либкнехт (1871-1919) герман социал-демократиясендәге сул як җитәкчеләрнең һәм Германия коммунистлар партиясе төзүчеләренең берсе, яшьләр арасында сәяси-мәгърифәт пропагандасын киң алып барган, аларны социализм һәм интернационализм рухында, шовинизм һәм милитаризм белән килешмәүчәнлек рухында тәрбияләү эшен башкарган. Тарихның һәр чорында өстен

сыйныфлар мәгърифәтне үз файдасына кулланганнар. Халыкны караңгылыкта һәм наданлыкта тотканнар, дип дәлилләгән Карл Либкнехт үзенең чыгышларында. Белемнәрен һәм көчләрен үз җитәкчелегендәге кешеләргә белем һәм тәрбия бирүдә кулланучы һәм чын мәгарифне кимсетергә омтылмаучы бернинди дә өстен торучы катлам, өстенлектәге сыйныф әлегә булганы юк.

Революцион социал-демократлар дин дәресләрен мәктәптән тулысынча чыгарып бетерүне таләп иткәннәр. Мәктәптә дин дәресләренең булуы җитди куркыныч хәл, чөнки дин үсеп килүче буынны коллык рухында тәрбияләргә тиешле, дип язган Карл Либкнехт. Клара Цеткин либералларның позицияләрен кискен тәнкыйтьләгән, чөнки либераллар мәктәп турындагы мәсьәләдә чиркәү белән килешүгә барганнар. Поль Лафарг, католикларның дөньяви белем бирүгә һәм Франция мәктәпләрендә фәнни белем кертүгә каршы чыгуларын фаш иткән.

Революцион социал-демократлар пролетариатның җиңүенә тулысынча ышанганнар. Пролетариат җиңгәннән соң социалистик җәмгыятьтә генә күп санлы хезмәт ияләре белем алуга ирешәчәкләр һәм кешенең һәрьяклап үсеше өчен барлык алшартлар булдырылачак.

Шул ук вакытта, буржуазия мөнәсәбәтләре өстенлек откан шартларда да революцион социал-демократлар халык мәгарифен демократлаштыру өчен зур программаларны яклап чыкканнар.

Пролетар революцион хәрәкәт эшлеклеләренең педагогик карашларына оппортунистларның каршы чыгуы. Башта герман, ә соңыннан халыкара социал-демократиянең кайберәүләрендә сәяси һәм педагогик җитди мәсьәләләргә әкренләп ревизионистларча караш барлыкка килгән.

Элек күрсәтелгәнчә, К. Маркс герман социал-демократия партия программасын "Гот программасын тәнкыйтьләү" исемле хезмәтендә тәнкыйтьләгән иде. 1891 елда Эрфурт партия съездында яңа программа проекты кабул ителгән, аны Ф. Энгельска фикер чыгарырга җибәргәннәр. Энгельс аны җитди тәнкыйтькә тарткан. Буржуазия белән килешүчәнлек тенденциясе, ә ул инде Эрфурт программасында ук сизелә башланган, вакыт үткән саен көчәйгәннән-көчәя барган.

Германия социал-демократия партиясенең 1906 елдагы Мангейм съездында тәрбия һәм белем бирү мәсьәләләре буенча, ә анда халык мәгарифе мәсьәләләре буенча, тезислар тапшырылган

булган, кискен көрәш кызып киткән. Съездда чыгыш ясаучы Клара Цеткин тәрбия һәм белем бирү мәсьәләләрен коммунистлар тарафыннан чын марксистларча хәл итү үрнәген күрсәткән.

Съездда кайбер чыгыш ясаучыларның оппортунистик позицияләре ачыкланган. Алар пролетариат диктатурасы турында, халык мәгарифе өчен революцион көрәш турында, дин мәсьәләсенең социал-демократ өчен хосусый эш икәнлеге турында, милитаристлар мәктәптән яшьләрне империалистик сугышка әзерләү өчен файдаланулары турында телгә алмаганнар.

Германия социал-демократия партиясенең югары өлеше беренче бөтендөнья сугышы чорында немец империалистик дәүләт мәнфәгатьләрен уртаклашуын таныган.

Шундый ук позицияне инглиз лейбористларның һәм француз социалистларның кайберләре яклаганнар. Алар хөкүмәтләренең һәм буржуазиянең колониаль талауларын аклаганнар, аяусыз колониаль эксплуатацияне "ак тәнле кешенең кыргый халыклар арасында мәдәният булдыру миссиясе", дип аңлатканнар. II интернационал эшлекчеләренең берсе — Вандервельде католик монахларның миссионер "мәгърифәт" эшчәнлеген һәрьяклап хуплаган, колониаль илләрдәге, мәсәлән Бельгия Конгосында, мәгариф эшенең барысын да алар кулына тапшырырга кирәклеген раслап маташкан.

Оппортунистлар, пролетариат мәнфәгатьләре, социализм, "яхшы сыйфатлы кеше" тәрбияләү турында сүзләр белән капланып, эшче сыйныфларыннан билгеле булганнарының аңын таркатканнар һәм буржуазия өстенлеген ныгытканнар.

XX гасыр ахырындагы һәм XX гасыр башындагы буржуазия педагогик теорияләр. Бу чордагы буржуазия педагогик теорияләре бик күп төрлеләрдән булганнар. Ләкин аларның нигезендә, бер яктан, буржуазия мәнфәгатьләреннән чыгып массаларга белем бирүне оештыруны раслау, икенче яктан, өстен сыйныф балаларын җәмгыятьтә һәм дәүләттә идарә итәргә әзерләүне булдыру мәсьәләләре дә торган.

Эре буржуазия таләпләрен канәгатьләндерү исәбеннән мәктәп төзү өчен, киң җәелгән "яңа мәктәпләр" дип аталган юнәлеш барлыкка килгән. Женевада "яңа мәктәпләрнең халыкара берләшмәсе" ("международное объединение новых школ") төзелгән. Ул Англиядә, Франциядә, Бельгиядә, Швейцариядә, АКШта һәм башка илләрдә барлыкка килгән шундый мәктәпләр өчен гомуми таләпләр

формалаштырган. Интернат тибындагы уку йортлары булган "Яңа мәктәпләр" ул заманда хосусый кешеләр яисә буржуазия педагогик оешмалар тарафыннан корылган булганнар. Кагыйдә буларак, анда яшәү һәм уку өчен түләү бик күп һәм привилегиялеләр өчен генә үти алырлык булган. Бу мәктәпләрдә фәнни белемнәрнең ролен һәм укыту процессында укытучының җитәкче ролен киметүгә китерә торган "ирекле һәм актив" методлар кулланылган.

Бу мәктәпләрдәге укыту эше күпчелек мәктәпләргә караганда яхшырак куелган булган: берләштереп укыту кулланылган, физик тәрбия югары дәрәҗәдә булган, дәресләрне алып бару өчен югары квалификацияле укытучылар тартылган, яхшы җиһазланган кабинетлар һәм лабораторияләр оештырылган, эстетик тәрбиягә төп игътибар бирелгән. Кайбер мәктәпләрдә буржуазия парламенты тибындагы укучылар үзидарәсе кертелгән булган. Шөгыльләр исәбендә кул эшенә (слесарьлыкка, агач остасы эшенә) өйрәтү булган. Балалар бакчачылык эшендә катнашканнар, авыл хуҗалыгы белән танышканнар. Әмма бу мәктәпләрдә физик хезмәт белән бәйле шөгыльләргә әзерләмәгәннәр, андый эш хезмәт ияләре балалары өчен, мондый мәктәпләргә керә алмаганнар өчен тәкъдир булган. Мәктәпләр матур табигать кочагында урнашкан булганнар.

"Яңа мәктәпләрнең" теоретигы һәм оештыручысы француз педагогы Э. Демолен булган. Шәһәрләрдәге бала тирәсендә "бәрелеш кызып китүе һәм баланы ниндидер сыйныфка тарту омтылышы" аның ачуын китерә торган булган. Белем бирү һәм тәрбия, аның фикеренчә, сыйныфтан өстен торырга тиеш. Ләкин бу мәктәпләр буржуазиянең бай өлеше балаларына гына хезмәт күрсәтүенә ул каршы чыкмаган.

Бу мәктәпләрнең күренекле теоретигы швейцар педагогы А. Ферьер, фикеренчә, "яңа мәктәпләр" — гамәли педагогиканың лабораторияләре. Анда балаларның акылын ятлана торган белемнәр белән ул кадәр түгел, ә күбрәге фикерләү сәләтен камилләштереп үстергәннәр. Укучыларны күзәтергә, гипотезалар тәкъдим итәргә, фараз итүләрен тикшерергә өйрәткәннәр. Укыту тулысынча фактларга һәм тәҗрибәләргә, баланың инициативасын һәм мөстәкыйльлеген тәрбияләүгә нигезләнгән булган. Ферьер баланың яшьләр чорын җентекләп исәпкә алырга, һәрбер тәрбияләнүче белән шәхси эш итүне башкарырга, аның уңай сыйфатларын эзләп табарга һәм үстерергә кирәк дип санаган.

Казна уку йортларына караганда "яна мәктәпләр" укыту һәм тәрбияләүне яхшы куюы белән аерылып торганнар. Ләкин алар чынлыкта исә капиталистик промышленность җитәкчеләрен, булачак "колониаль эшлеклеләрне" әзерләгәннәр. Өстен сыйныф мәнфәгатьләрен чагылдырганга күрә буржуазия даирәсендә зур популярлык казанганнар.

"Яңа мәктәпләргә" сәяси гадел бәяне Н. К. Крупская биргән. "Бездә еш кына буржуазиянең "яңа мәктәпләрен" идеальләштерәләр,— дип язган ул 1912 елда,— тышкы якка игътибар итәләр, демократизмнан читләшкән һәм бу мәктәпләрдә хөкем сөрүче үтәли сеңгән филистерство рухын күрмиләр. Дәресләр дә бакчаларда үтә, рәсем ясау да искиткеч куелган, кул эшләре дә кертелгән, балаларның үзешчән сәнгате өчен дә иркенчелек бар, балалар белән мөгаләмә дә тәрбияли һ. б., һ. б. Ә бу мәктәпләрдә балаларны хәзерге яшәешкә, шовинизмга, надан халык өчен диннең яхшы булуына, дипломнан башка саклану юк икәнлегенә баш ияргә өйрәтәләр..."

XIX гасырның ахырында һәм XX гасырның башында берничә педагогик теория барлыкка килә. XX гасырдагы буржуазия педагогларына да алар йогынты ясый торалар.

"Гражданлык тәртибе" һәм "хезмәт мәктәбе" педагогикасы. XX гасыр башында Германиядә башка илләрдә **Георг Кершенштейнер** (1854-1932) педагогик теориясе популяр булган. Кершенштейнер "гражданлык тәрбиясе" һәм "хезмәт мәктәбе" идеясе белән чыккан. Аның фикеренчә, мәктәп эше тулысынча империалистик Германиягә хезмәт итү өчен куелырга тиеш. "Гражданлык тәрбиясе" балаларны берсүзсез дәүләткә буйсынырга өйрәтергә тиеш. Ул киң халык мәктәбе аркылы башкарылырга тиеш. XIX гасырның ахырында — XX гасырның башында Германия икътисады бик тиз үскән. Буржуазиягә техник яктан коралланган һәм аның мәнфәгатенә сәяси яктан тугрылыклы тәрбияләнгән эшчеләр кирәк булган һәм Кершенштейнер бу таләпләргә туры килә торган педагогика төзегән. "Хезмәт мәктәбе" теориясе һәм яшьләрне киләчәк һөнәрчелек эшчәнлегенә әзерләү аның "гражданлык тәрбиясе" карашлары белән бәйләнгән.

Кершенштейнерны пролетариатның аңы үсүе һәм эшчеләр хәрәкәтенең ныгуы борчый. "Эчке дошманнарга" каршы, пролетариат аңы ияләренә каршы пушкалар да, броненосецлар да, хәтта бер бөтен армия штыклары да тора алмый. Нәзакәтле, тик

ышанычлырак һәм көчлерәк тәэсир итүче башка корал укучыларга "дәүләт мәсьәләләрен аңлауны, моның нәтиҗәсендә гражданлык бурычы һәм ватанга мәхәббәт аңын" ышандыручы сәяси тәрбия куллану кирәк. Ул биредә хезмәт ияләренә шовинистик тәрбия бирүне, алардан күндәм эшчеләр һәм солдатлар әзерләүне күз алдында тоткан.

Хезмәт ияләре балаларының мәктәптә булу срогын киметү хата булыр иде, дип санаган Кершенштейнер. Мәктәпне "реформалаштыру" һәм аны "хезмәт" мәктәбенә әйләндерергә кирәклеге турында фикер әйткән. Аның фикеренчә, укучылар мәктәптә кул эше белән шөгыльләнергә һәм техник күнекмәләр алырга, кирәкле кораллар ярдәмендә төрле материаллар белән эш итә белергә тиеш. Бу бурычны үтәү исәбеннән һәрбер халык мәктәбендә гамәли дәресләр өчен остаханәләр, бакча, мәктәп ашханәсе булырга тиеш. Тәрбияләнүчеләр мәктәптә эшләп, һәрвакыт яхшы эшләү өчен үзләренә кирәкле сыйфатларны эзлекле рәвештә үстерергә, кул эше процессларын тагын да тырышыбрак, намуслырак, уйлабрак башкарырга өйрәнергә тиешләр. Шуның өстенә, халык мәктәбе укучыларга киләчәк һөнәр эшчәнлеге өчен гомуми хезмәт әзерлеге бирергә тиеш.

Халык мәктәбендә гомуми белемне күп бирергә ярамый, дип санаган Кершенштейнер. Аның әйтүенчә, "хезмәт мәктәбенең асылы шунда ки, белемне әзрәк биреп, күбрәге осталык, күнекмәләр һәм эш сөю, шулай ук тиешле гражданлык инанганлыгы булдыру". Кершенштейнерның хезмәт ияләре балаларына белемне әзрәк бирергә омтылуы, аның ачыктан-ачык, реакцион икәнен күрсәтә.

Халык мәктәбендә "гражданлык тәрбиясен" кую таләбен Кершенштейнер Мюнхен шәһәрендә тормышка ашыра алган. Ул анда берничә ел халык мәгарифе эшен җитәкләгән. Халык мәктәбеннән башка ул анда өстәмә мәктәпләр дигәнне дә оештырган.

Ул мәктәпләр токарь станокларында эшләүчеләрдән чәчтарашларга кадәр булган эре, урта һәм вак промышленностьтәге төрле белгечлек һәм профиль эшчеләргә хезмәт күрсәткән. Предприятие хуҗалары 2-3 ел буена үзләренең эшчеләрен укыту өчен һәр атна саен 8-10 сәгатькә азат итәргә тиеш булганнар. Өстәмә мәктәпләрдә гомуми белемнәр бик әз бирелгән. Дәресләр уку, язу, санау һәм табигать белеме буенча (профессиягә якынайтып) үткәрелгәннәр.

Мәсәлән, сыра кайнату промышленностендә эшләүче яшүсмерләр табигать белеме буенча әчешү процессларын, закваскалар ясауны өйрәнү белән чикләнгәннәр.

Яшь эшчеләрне өстәмә мәктәпләргә тарту, Кершнештейнер исәбенчә, аларның "гражданлык тәрбиясен" көчәйтер һәм эшчеләр хәрәкәтендә катнашуларын бүлдерер.

Кершенштейнер, чынында исә, халык мәгарифенең икеле системасы ягында булган. Күндәм һәм акыллы эшчеләр әзерләүче "халык мәктәбе" урта мәктәп белән (гимназияләр, реаль училищелар белән) берничек тә бәйләнештә тормаган. Үзенең "хезмәт принцибын" ул урта мәктәпләргә таратмаган. Хезмәт, аның фикеренчә, реаль училищеларда лабораторияләрдә башкарыла, ә гимназияләрдә хезмәт эшчәнлеге китаплар һәм дәреслекләр өстендә эшләү белән чикләнә.

Кершенштейнер социализмны һәм революцион хәрәкәтне дошман күргән. "Буржуазия җәмгыятен" дошманлык таратучы" кешеләрдән оештырылган тәрбия генә ышанычлы саклый ала", дип санаган ул. Кершенштейнер яшермичә, үзе әйткәнчә, аның тәрбиясе "пролетариат дип исәпләнгәннәрнең" (урониясе шундый булган) диктатурасына каршы юнәлдерелгән.

Кершенштейнерның эшче яшьләрне әзерләү формасын тәкъдим итүе һәм аның карашлары империалистик Германиядә популяр булганнар. XX гасыр башында һәр урында Мюнхен үрнәге буенча өстәмә мәктәпләр ачыла башлаган һәм башлангыч мәктәпләргә "хезмәт принцибы" кертелгән.

Н. К. Крупская Кершенштейнер карашларын дөрес бәяләгән: "һәрбер демократизмнан ул ерак тора. Ул буржуазия дәүләтенә баш ия, бигрәк тә аның мәнфәгатьләрен саклый һәм үзенең педагогик эшчәнлеген шуңа туры китерә... яңа методлар белән элекке максатларны күздә тота торган мәктәпне тели... Кершенштейнерлар кулындагы яңа методлар балалар индивидуальлеген белеп, аларның хисләренә, дөньяга карашларына тәэсир итә торган, тиешле әхлак һәм идеология сеңдерә торган нәзәкатьлерәк һәм камилләшкәнрәк чара булып кына калалар..."

"Гамәли" педагогика. Германиядә шул ук елларда буржуазиянең башка зур педагогы Вильгельм Август Лай (1862-1926) үзенең эшчәнлеген җәелдереп җибәргән. Ул башка илләрдә дә, аерым алганда, революциягә кадәрге Россиягә бик билгеле булган.

Лай педагогикасы биологияләштергән һәм тәрбияләү процессын механик рәвештә аңлаткан. Һәрбер тышкы ярсыту иң гади төзелешләрдән алып кешегә кадәр барлык организмнарда җавап хәрәкәте яисә реакция булдыра. Шуның белән бергә, рефлектор акт бер үк схема буенча үтә: зиһенгә алу — эшкәртү — чагылыш (яисә тасвирлау).

Бу механик схемасын Лай тәрбияләү һәм укыту процессына, карата да кулланган. Бу процесс, аның фикеренчә, тышкы тәэсирдән һәм укучының җавап реакцияләреннән гыйбарәт. Укучылар күзәтү ярдәмендә тәэсиргә һәм зиһенгә алуга җәлеп ителәләр бу тышкы йогынтылар аңда эшкәртеләләр һәм, ниһаять, төрле гамәлләр ярдәмендә зиһенгә алынганның һәм эшкәртелгәннең чагылышы барлыкка килә.

Зиһенгә алынган һәм логика, эстетика, этика, шулай ук дин номерлары буенча эшкәртелгән тәэсирләр тәрбиянең барлык өлкәләрендә һәм баскычларында тышкы чагылышлар белән тутырылырга тиеш. Педагогик процесстагы бу чагылышка яисә тасвирламага Лай зур әһәмият биргән, чөнки нәкъ шушында укучы үз активлыгын гамәлләр аркылы белдерә ала.

Шунлыктан, аның барлык теориясе "гамәли педагогика" дип аталган. Лай фикеренчә, педагогик процесстагы чагылыш чаралары булып тасвирлау эшчәнлегенең күп төрләре тора: рәсем ясау, әвәләү, модельләштерү, сызым, драмалаштыру, җыр, музыка, биюләр, шулай ук үсемлекләрне һәм хайваннарны карау, тәҗрибәләр үткәрү, сөйләм һәм язма эшләр һ. б. Барлык укыту эше шушы положение нигезендә төзелергә тиеш, дип уйлаган. Мәсәлән, табигать белемен өйрәнгәндә мәктәп участокларында чәчү, үсемлекләр үстерү мөмкинлеген бирәләр. Берәр сәбәп аркасында мондый мөмкинлек булмаса, сыйныф бүлмәсендә яисә мәктәптә чүлмәкләрдә чәчәкләр булырга тиеш, аларны укучылар карарга тиеш. Дәресләрдә укучылар сурәтләүләр башкарырга, "тасвирламалар" ярдәменнән файдаланырга тиеш.

Лай чагылышларның төрле чараларын кулланырга тәкъдим итсә дә, хезмәтне аерым фән дип түгел, ә укытуның принцибы дип санаган. Укыту процессында хезмәт йомгаклау буыны булып тора.

Лай үзе тәкъдим иткән педагогик процесс схемасы нигезендә "табигый уку планын" төзегән. Барлык укытуны ул "күзәтмәле әйберле" һәм "формаль тасвирламалы" төрләргә бүлгән. Беренчегә ул "зиһенгә алу" белән бәйле нәрсәләрне керткән: табигать терек-

леге (табигый тарих, физика, химия, география), кеше яшәеше (тарих, гражданлык белеме, халык хуҗалыгы турында тәгълимат, әхлак, фәлсәфә һәм педагогика; икенчегә ул, үзенең фикеренчә, "чагылдыру" өчен материалны керткән: сурәтләү, экспериментлар, хайваннарны карау, математика аркылы тасвирлау, сүз аркылы тасвирлау (тел), сәнгать аркылы тасвирлау, "әхлак өлкәсендәге иҗат, сыйныф җәмгыятендә үзеңне тоту" һ. б. Аның фикеренчә, укуның нигезендә "күзәтмәле-әйберле материал ята". Ул формаль тасвирламалы укыту дәресләрендә эшкәртелүгә дучар була". Уку материалын Лай шулай ясалма рәвештә бүлгәндә табигый тарих "күзәтмәле-әйберле укыту"га, ә үсемлекләрне һәм хайваннарны карау — формаль тасвирламалы укытуга эләгә.

Югарыда күрсәтелгәнчә, Лай педагогиканы биологияләштергән, тәрбиянең иҗтимагый күренеш икәнен, биология законнары белән тулысынча аңламаган. Лай, моннан башка, "чагылышка" артык игътибар биргән, акыл эшенең әһәмиятен киметкән, "гамәли мәктәпне" иллюстратив мәктәпкә әверелдергән. Балалар шактый вакытларын рәсем ясауга, әвәләүгә, драмалаштыруга бирәләр. Тасвирлау эшчәнлеге белән артык мавыгу систематик уку эшеннән шактый тайпылдырган, ә бу инде гомуми белем дәрәҗәсенең кимүенә китергән.

Лай гомеренең соңгы елларында ачыктан-ачык реакцион позициягә күчкән, үзенең хезмәтләрендә тәрбия өчен диннең һәм расаның әһәмиятлелеген күрсәткән. Герман расасы беренче урында, дип герман милләтчелеген данлыклаган.

Экспериментал педагогика. XX гасыр ахырында Германиядә, Англиядә, АКШта үзенә исем алган экспериментал педагогика шактый мөһим урын тоткан. Баланы эксперимент аркылы өйрәнү өчен яңа методлар табу аның бурычы булган. Фәнни-педагогик тикшерүнең башка методларын ул кире каккан. Бу юнәлештәге педагогларның эшчәнлегендә уңай яклар да булган, кайбер тикшеренүләр педагогик процессның аерым якларын тирәнтен аңларга ярдәм иткәннәр. Шулай да бу педагоглар балага җәмгыять шартларыннан тыш булган кебек караганнар, тәрбияне иҗтимагый түгел, ә биология күренеше генә итеп аңлатканар. Бу фән сыйныфтан, партиядән тыш тора, димәк ул "сәясәткә кагылмый", шул ук вакытта "фәлсәфә" педагогикасы (буржуазия педагогикасының башкаларын шулай атаганнар) субъективлыклы һәм төгәл методлар белән алынган фәнни таләпчән фактларга таянмый, дип басым ясап

әйткәннәр эксперименталь педагогика вәкилләре. Чынлыкта исә, эксперименталь педагогика баланы буржуаз идеология рухында тәрбияләү максатыннан чыгып аның күңеленә йогынты ясый торган чаралар табарга тырышкан. Алар тәкъдим иткән методлар төгәл һәм объектив булмаганнар. Күп очракларда экспериментлар ясалма шартларда үткәрелгәннәр һәм өстен сыйныфларга кирәкле нәтиҗәләр биргәннәр.

Балаларның акыл сәләтлелеген тикшерү өчен "тест методлары" киң кулланылганнар. Алар сораулыклардан һәм мәсьәләләрдән гыйбарәт булганнар, үзләренең катлаулыгыгы белән баланы еш кына бутаганнар. Тестлар универсальлеккә дәгъвалаганнар һәм "абстракт балага" исәпләнгән булганнар. Дөрестән дә алар буржуазия катламы кешеләрнең балаларын тәрбияләүгә яраклаштырылганнар. XX гасыр ахырында АКШта экспериментатив педагогика нигезендә педагогика барлыкка килә. Ул тиз арада Көнбатыш Европа илләренә таралып киткән һәм шулай ук Россиягә күчкән.

Балаларның язмышы, имеш, нәселдәнлек һәм иҗтимагый мохит аркылы алдан ук билгеләнә, ә мохит үзгәрешсез кала, дип раслаганнар педагоглар. Бу реакцион тезисны педагоглар балаларның күп өлешен акыл үсеше артта калганнар, дефектлы һәм мәшәкатьле категориясенә кертү өчен кулланганнар. Педагоглар фәнни булмаган тестларны киң кулланып, хезмәт ияләре балаларының акыл мөмкинлекләре түбән дигән нигезсез нәтиҗә ясаганнар.

Немец эксперименталь педагогикасының күренекле вәкилләреннән берсе Әрнет Мейман (1862-1915) булган. Ул "эксперименталь педагогикага кереш лекцияләре" ("Лекции по введению в экспериментальную педагогику"), исемле өч томлы систематик курс төзегән. Баланы һәрьяклап өйрәнү өчен ул педагогика, психология, психопатология, анатомия һәм физиология мәгълүматларын берләштергән. Мейманның баланы барлык мөнәсәбәтләрдә өйрәнергә омтылышын дөрес дип танып була, ләкин моның ясалма шартларда гына үтәлергә тиешлеге дөрес түгел. Дәрестәге, гадәти мәктәп шартларындагы педагогик экспериментка ул каршы булган. Югарыда күрсәтелгән фәннәрдән башка, педагогика нигезе дип, Мейман буржуазия этикасын, эстетикасын һәм дин турында ниндидер фәнне санаган. Шулар арасында аның фәнни йомгаклары реакцион үзенчәлекле булмаган. Ләкин Мейманның акыл тәрбиясе

турындагы фикерләре, мәктәп эше гигиенасы турында, мәктәп һәм мәктәптән тыш тормышның укучыга тәэсире турында фикер йөртүләре хәзер дә зур кызыксыну уята. Эксперименталь дидактика оештыру кирәклеге турында бурыч куюы шулай ук игътибарга лаек. Ләкин Мейман үзе баланы тулаем өйрәнмәгән, баланың психик функцияләрен (игътибарны, хәтерне һ. б.) аерым-аерым тикшергән. Шуның белән бергә, укучыларны укытучылар түгел, ә күпчелектә психологлар (башкача әйткәндә, педологлар) тикшерергә тиеш, дип уйлаган. Болай итү укытучыларга укучыларны көн саен тәрбияләү һәм укыту процессында тикшерергә мөмкинлек бирмәгән. Беренче бөтендөнья сугышы алдында Мейман шовинизм һәм расизм үзенчәлекле статьялар белән чыккан.

АКШта эксперименталь педагогика киң таралган булган. Бу юнәлешнең күренекле вәкиленнән **Эдуард Торндайк** (1874-1949) булган. Ул бихевиоризм тәгълиматына нигезләнгән. Бу тәгълимат буенча кешенең үз-үзен тотышы — механик рәвештәге стимуллар аркылы булдырылган һәм күп тапкырлар механик күнегүләр аркылы организмда ныгытылган саф тышкы реакцияләр. Димәк, барлык тәрбия дрессировка, стимуллар белән билгеләнгән тиешле реакцияләрнең камилләшүенә әверелеп кала.

Торндайк һәм аның шәкертләре эксперименталь педагогик эшне чынында тестларга кайтаралар. Акыл сәләтлелеген билгеләү өчен кулланып килгән тестлар белән беррәттән баланың ниндидер фән буенча камилләшү дәрәҗәсен белү өчен өлгереш тестлары кертелгән. Балаларны шулай өйрәтү ысулы XX гасырның 40-50 елларында АКШта, Англиядә, ФРГда киң кулланылган. "Объектив дәлилләүгә" дәгъва булган бу тестлар чынында буржуазиягә кирәкләрнең белем алуларын дәвам иттерергә сайлап алу өчен, хезмәт ияләре балаларын югары типтагы мәктәпләргә кертүне кыенлаштыру өчен хезмәт иткәннәр.

Баланы өйрәнү мәсьәләләрендә эксперименталь педагогика билгеле бер дәрәҗәдә алга китәргә ярдәм иткән. Эксперимент һәм махсус приборлар куллану ярдәмендә балалар үсүенең һәм үсешенең кайбер үзенчәлекләре ачыкланган: балаларның төрле яшь чорында аерым органнарның нисбәте, сулыш һәм кан әйләнеше өлкәләрендәге үзгәрешләр. Балалар үсешенең тигезсезлеге, кайбер яшьтә тизләнүе яисә әкренәюе расланган. Күрүне, ишетүне, капшап тоюны тикшерүдә мөһим нәтиҗәләр алынган. Шулар ярдәмендә

сенсор тәрбия һәм күрсәтмәлелек проблемаларын хәл итү өчен берничә кагыйдә кертергә мөмкинлек барлыкка килгән. Балаларның игътибарын, хәтерен, акыл эшенең кайбер үзенчәлекләрен (хәтерне тәрбияләү өчен күнегүләр), ә шулай ук балаларның төсләр аеру күзалламаларын өйрәнүдә билгеле бер нәтиҗәләр хасил булган.

Прагматик педагогика. XX гасырның 90 нчы елларында АКШта, үзенә исем алган, "прагматизм фәлсәфәсе" барлыкка килгән, ә соңыннан зур үсешкә ия булган. Бу фәлсәфә идеализмнан һәм материализмнан югары, гүя объектив хакыйкать юк һәм кеше аңа якынлаша алмый, дигәннәр прагматизмны яклаучылар. Прагматизм (прагма, грекча — эш, гамәл, гамәли фәлсәфә) материализмның да, идеализмның да метафизикасыннан көлә, тәҗрибәне, так тәҗрибәне генә артык югары күтәрә, практиканы гына бердәнбер критерий дип таный, фән "чынбарлыкның абсолют копиясе" түгел дигән сылтама ясый, һәм боларның барысыннан да практик максат өчен, практика өчен генә бик шәпләп алланы китереп чыгара.

Хакыйкать критерие итеп прагматистлар файданы таныйлар. Шуның белән бергә, файданың әһәмияте "эчке канәгатьлек", яисә үзеңне канәгатьләндерү аркылы билгеләнә.

Америка фәлсәфәчесе һәм педагогы **Джон Дьюи** (1859-1952) прагматизмның бер юнәлешендәге күренекле вәкиле булган. Юнәлеш "инструментализм", дип аталган, һәрбер теория, идея бер индивидумга файдалы икән, ул "гамәл инструменты" итеп каралырга тиеш, дип раслаган. Андый фәлсәфәдә төзелгән педагогика билгеле, принципсыз, "эшләштермәде" үзенчәлекле булып кала. Дьюиның ахыр чиктәге — идеалы — "яхшы тормыш". Дьюи капитализмның кайбер якларын буш сүз белән тәнкыйтьләгән булып, Америка империализмы мәнфәгатьләренә туры килгән үзенең социологиясен, тәрбия турындагы фикерләре кебек, яшереп килгән. Педагогика мәсьәләсе буенча аның позициясе үз гомерендә берничә тапкыр үзгәргән, шулай да принципиаль нигезе үзгәрешсез сакланып торган. Дьюиның XIX гасыр ахырындагы мәктәпне тәнкыйтьләве күпләр тарафыннан, гомумән алганда, буржуазия мәктәбенә карата оппозиция дип, ә педагогикада, аерым алганда, хезмәт тәрбиясе һәм мәктәпнең тормыш белән бәйләнеше өлкәсендә "яңа сүз" кебек кабул ителгән. Утызынчы елларга кадәр совет мәктәбен уңай бәяләве, СССРга килүләре һәм Совет хөкүмәтенең мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеген

гомумән яхшы бәяләве прогрессив җәмәгатьчелектә Дьюиның популярлыгын булдырган. Ләкин икенче бөтендөнья сугышыннан соң АКШ та реакциянең көчәюе сәбәпле, Дьюиның СССРга карата мөнәсәбәте кискен үзгәрә. Аның сәяси карашлары реакцион булганнан була бара, аның педагогик киметергә кирәк ("проектлар методы", "прогрессив тәрбия" дип аталган теория һ. б.) дигәнне аңлата. Ул Советлар Союзының дошманы булып китә, ә гомеренең соңгы елларында фашизмга ачыктан-ачык теләктәшлек белдерә.

Радикаль рәвештә үзгәргән тормыш шартлары белем бирү куелышын да радикаль үзгәртүне таләп итә. Әмма бу үзгәрешләр нинди булырга тиеш? Дьюиның фикеренчә, белемне җәмгыятьнең "интеллектуаль импульслары, тенденцияләре һәм һәвәслекләре" булган азчылыгы, ә ягъни өстен сыйныф балаларын алганда гына "интеллектуаль белем" дөрес дип табыла. Хезмәт ияләренең улларында һәм кызларында "тар практикалы импульслар, тенденцияләр һәм һәвәслекләр" генә булганга күрә, мәгарифнең күп мәктәпләргә исәпләнгән яңа системасын "практик импульсларны" җәелдерү өчен балаларга фәнни белемнәр үзләштерү урынына "Нәрсәдер эшләргә, нәрсәдер ясарга" булышырлык иттереп оештырырга кирәк.

Димәк, Дьюи хезмәт ияләренә системалы белем кирәк түгел, дип раслый. Саф белем алу өчен бик күпчелекләргә "турыдан-туры иҗтимагый нигез" юк, шулай да уңышлар була икән, бернинди дә иҗтимагый файда юк. Эшчеләр сыйныфының "импульслары" икенчегә — тормыш өчен практик әзерлеккә юнәлгәннәр. Мәктәпнең бурычы — үсеп килүче буынны тиешле рәвештә тәрбияләп һәм укытып, сыйныф буынны тиешле рәвештә тәрбияләп һәм укытып, сыйныф каршылыкларын йомшарту.

Бала үсешендә зур рольне Дьюи нәселдәнлектә күргән. Өстәвенә реакцион аңлату ягында торган. Аның әйтүенчә, индивидуумның акыл һәм физик сыйфатлары җыелмасы раса казанышлары булып торалар һәм нәселдән нәселгә күчәләр дигән нәселдәнлек теориясе барысы тарафыннан танылган положениегә әверелде.

Дьюи күрсәткәнчә, тәрбия эше нәселдәнлеккә таянырга тиеш һәм баланың инстинктларыннан һәм практик тәҗрибәсеннән алынырга тиеш. Бу тәҗрибәне тәрбия бертуктаусыз киңәйтә һәм тирәнәйтә. Тәрбия процессындагы төп фигура — бала. Ул кояш һәм бөтен педагогик процесс аның тирәсендә әйләнә. Бөтен эш

башы балада. Аның көчләре ачыкланырга, мәнфәгатьләре канәгатьләнергә, сәләтлелеге күнегергә тиеш.

Педагогик процесста игътибарны балага юнәлдерергә һәм бала мәнфәгатьләреннән чыгып укытуны оештырырга, дип Дьюиның чакыруы ахыр чиктә системалы укытудан баш тартуга, бала тәрбияләүдә фәнни белемнәрнең ролен киметүгә китерә.

"Нәрсәдер эшләтеп укыту" гына балаларны тормыш белән бәйли ала дип санаган Дьюи, системалы белемне тиешле бәяләп җиткермичә. "Хезмәт белән шөгыльләнү мәктәп тормышының үзәге булып куела", дип әйткән ул. Тормышта хезмәтнең күп төрләре булганга күрә укучылар аларның төрле формалары белән дә танышырга тиеш. Аларның эшләре күпкырлы булырга тиеш һәм бакчада, ашау бүлмәсендә, ашханәдә, хәзерге машиналар белән җиһазланган төрле индивидуаль ашханәләрдә башкарылырга тиеш. Шөгыльләрне ниндидер бер бирем тирәсендә, мәсәлән, кечкенә өй төзү буенча, оештырырга кирәк. Бу шартларда балалар башта масштаб буенча план сызалар, арифметика дәресендә өйлек материал бәясен санап чыгаралар, тел дәресендә өй төзү белән бәйле сүзләрнең язылышын үзләштерәләр, рәсем һәм әвәләү дәресләрендә өй өчен бизәүләр хәзерлиләр. Барлык фәннәрне дә балаларның яшен һәм мәнфәгатен исәптә тотып шулай итеп өйрәнергә мөмкин һәм кирәк.

Хезмәт тәрбиясенең, ролен дөрес бәяләп, Дьюи аны гомуми киң белем белән бәйләми. "Нәрсәдер эшләтеп укыту" положениесе укучыларга фәнни белем бирүне бәяләп җиткермәүгә, укытучы ролен төшерүгә китерә торган булган. Дьюи укытучысы укыту процессының җитәкчесе булмыйча, оештыручы, консультант булып кына кала.

Дьюи фикеренчә, мәктәптә даими уку сыйныфлары, программалары, расписаниесе булырга тиеш түгел. Дьюи бала мәнфәгатен төп башлангыч итеп күрсәтеп, мәктәп эшен планлы рәвештә оештыруга комачаулаган, укучыларның мөстәкыйль тикшеренүләренә аларны системалы белемнәр белән коралландыруны каршы куйган.

* * *

Уникенче лекция

ФЕОДАЛИЗМ ЧОРЫНА КАДӘР ҺӘМ ФЕОДАЛИЗМ ЧОРЫНДАГЫ ТӘРБИЯ, МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИК ФИКЕР

Борынгы славяннарда тәрбия һәм укыту. Европа территориясендә элек-электән яшәп килгән Көнчыгыш славян кабиләләре бүтән халыклар кебек ыруглык җәмгыяте башлангычы вакытыннан, борынгы община строе таркалу һәм җәмгыятьнең сыйныфларга бүленү чорына хәтле озын тарихи үсеш юлы үткәннәр. Көнчыгыш славяннарның борынгы община строе чорында балалар тәрбияләве башка халыкларга да хас үзенчәлекләре белән билгеле. Тәрбияләү балаларның турыдан-туры община тормышында һәм яшькә карап хезмәт эшчәнлегендә, шулай ук йолаларда, тантаналы бәйрәмнәрдә, табыну чыгышларында катнашулары аркылы башкарылган. Балалар бөтен община тәрбиясе астында булганнар: 7-8 яшькә кадәр кечерәк балаларны – хатыннар, ә соңыннан үсмер малайларны һәм егетләрне – ирләр, үсмер кызларны һәм җиткән кызларны хатыннар тәрбияләгәннәр. Моның өчен борынгы славяннар башка халыклар кебек кешеләрне төрле яшьтәге төркемнәргә бүлгәннәр дип уйларга була. Ә соңгы матриархатта яшьләр төркеменә хәзерләү кебек “багышламалар” (инициацияләр) алып торган.

Парлы семья килеп чыккач балаларны җәмгыятьтә тәрбияләнү гаиләдә тәрбияләү белән алышынган. Гаилә, ата кеше кул астында, бала тәрбияләүдә һәм өйрәнүдә әһәмиятле орган булып китә. Балалар ата-аналарның шөгыльләрен – игенчелек, аучылык, терлекчелек, кәсеп төрләрен мираслыштырганнар. Бөтен семья тормышында катнашкан балалар кирәкле гамәли күнекмәләр һәм белеп эшләүләрне, карашларны, күзаллауларны, төшенчәләрне, әхлак таләпләрен һәм нормаларын үзләштергәннәр. Кәсепкә һәм сәнгатькә, мәсәлән сынлы сәнгатькә, өйрәтүне аерым осталар башкарганнар. Кайбер балалар мәҗүсиләр гыйбадәтханәләрендә борынгы гади (пиктографик) язуга өйрәнә алганнар. VIII гасырда славяннарның пиктографик язуның бер төре булган борынгы "сызыклы һәм

чәнечкеле" язу формасын кулланулары турында мәгълүматлар бар. Җәмгыять сыйныфларга бүленгәнгә күрә иҗтимагый катлаулардагы балаларны тигезсез тәрбияли башлаганнар. Мәсәлән, елъязма күрсәтүләренчә, X гасырда князьләр йортында князь балаларын тәрбияләүче һәм өйрәтүче (хәрби осталыкка да) махсус шәхесләр барлыкка килгән.

Киев дәүләтендә тәрбияләү һәм хосусый өйрәтү. VI – VIII гасырларда борынгы славяннар җәмгыятендә башлангыч феодаль мөнәсәбәтләре формалашу өчен кирәкле алшартлар туа, һәм VIII – IX гасырлар чигендә Европада бик зур башлангыч феодаль дәүләт — үзәге Киевта булган Русь барлыкка килә. Ул феодаль бүленешләргә һәм монгол-татарлар яулап алганчыга кадәр яшәп килгән. Карпат тауларыннан Уралга кадәр, Кара диңгездән Ак диңгезгә кадәр зур территориягә таралган күп санлы кабиләләрне Киев князьләре хакимияте астында туплаган берләшмә төзелүе, Киев дәүләтендә югары мәдәният, мәгариф, яңа формаларда тәрбияләү һәм өйрәтү өчен уңайлы шартлар тудырган. 988 елда Киев князьләренең халыкны чукындыру сыйнфый мөнәсәбәтләрне һәм Русьне феодальләштерүне ныгытырга мөмкинлек биргән. Византиядән кереп дәүләт диненә әверелгән Христианлык феодаль стройны урнаштыруда идеологик чара булып киткән. Мәдәният һәм мәгарифне үстерү өчен антик мәдәниятне мираслаучы Византия белән нык элемтә тоту бик әһәмиятле булган. Князьләр хакимияте үзенең сәяси максатларыннан чыгып, Византия руханиларыннан бәйсез булган милли чиркәү оештырырга омтылган. Шуның өчен князьләр руханилар әзерләү өлкәсендә көчле эшкә керешкәннәр. Идарә итү өчен дә дәүләткә белемле кешеләр кирәк булган. Камилләшкән әлифба (кириллица) борынгы урыс сәясәте һәм мәгарифнең киләчәктә үсеше өчен бик әһәмиятле булган. Ул хәрефле-авазлы грек алфавиты нигезендә борынгы славяннар теленең фонетик системасын исәптә тотып төзелгән. Яңа әлифбаның көнчыгыш славяннар сөйләменә якынлыгы борынгы бердәм урыс халкының тел уртаклыгын көчәйтүгә һәм әдәбиятнең, телнең үсешенә ярдәм иткән. Болар барысы да педагогик яктан әһәмиятле булганнар, туган телдә укый-язарга өйрәтүне оештырырга, балалар тәрбияләгәндә халык авыз иҗаты әсәрләрен кулланырга, демократик халык арасында да уку-язу белемен тарата алуга мөмкинлек биргән.

Беренче мәктәпләр. 968 елдагы елъязма күрсәткәнчә, князь Владимир киевлыларны чукындырганнан соң ук чиркәүләр төзи

башлаган, күренекле кешеләрнең (гомумән дружиначылар арасыннан) балаларын җыярга һәм укырга өйрәтә башларга ("даяти нача на учение книжное") дип руханиларны билгеләгән. Князь Ярослав Новгородта укырга өйрәтергә 300 староста һәм поп баласын җыярга ("собра от старост и поповых детей 300 учити книгам") дип күрсәтеп киткән. Смоленск князе Роман Ростиславович берничә мәктәп оештырган. Галицк князе Ярослав Осмомысл (XIII гасыр) училищелар ачкан һәм монахларга балаларны монастырьларда укытырга боерган.

XI гасыр ахырында Киевның бер хатын-кызлар монастыренда кызлар училищесы ачылган, анда кызларны укырга, язарга, җырларга һәм тегү эшенә өйрәткәннәр. Бу һәм башка мәгълүматларга таянып X – XIII гасырларда Киев дәүләтендә чиркәү һәм монастырьларда дәүләткә кирәкле руханилар һәм белемле кешеләр әзерләү өчен училищелар булдырылган дип әйтергә була.

Князь Ярослав Мудрый сарай даирәсендә югары мәктәп булган. Аннан шул вакыттагы күп мәдәният эшлеклеләре: язучылар, елъязмачылар, тәрҗемәчеләр һәм китап күчереп язучылар, дин әһелләре, гомумән, белемле кешеләр чыккан.

Киев-Печерск монастыренда монахлар өчен **"китап гыйлеменә өйрәтүче"** мәктәп булуы мәгълүм. Бу мәктәптән берничә дистә югары руханилар чыккан.

Гади кешеләрнең балалары гаиләдә тәрбияләнгәннәр. Аларны авыл хуҗалыгы һәм өй эшләренә өйрәткәннәр. Ниндидер кәсепкә өйрәнсен дип балаларны осталарга тапшырганнар. Аларның кайберләрен руханиларның "грамота осталары" кәсеп белән бергә укырга, язарга, чиркәүдә җырларга өйрәткәннәр. Мәсәлән, бер хикәяттә сөйләнгәнчә, Новгород егете Василий Буслаевны әнисе

Грамота өйрәнергә биргән,
грамотага Василий тиз өйрәнгән;
- яз дигән каләмең белән,
язарга да Василий тиз өйрәнгән;
- Җыр өйрән син чиркәүдә,— дигән,
Җырларга да Василий тиз өйрәнгән.

Башка хикәятләрдә дә батырларның белемлелеген раслаучы мәгълүматлар очрый. Алар, күрәсең, "грамота осталарыннан" өйрәнгәннәрдер.

* * *

Унөченче лекция

XI – XIII ГАСЫРЛАРДАГЫ ПЕДАГОГИК ӘДӘБИЯТ

XI – XII гасырларда Киев дәүләтендә тәрҗемә һәм оригиналь кулъязма җыентыклар барлыкка килгән. Алар арасында педагогик эчтәлекле текстлар һәм әйтемнәр булган.

"Пчела", "Изамрагд" (изумруд), Святославның "Изборник", "Злато струй", "Златоуст" (грек чиркәү язучысы һәм өндәүчесе Иоан Златоуст кушаматы буенча) исемле җыентыкларда Сократ, Демокрит, Аристотель әйтемнәре һәм текстлары булган. Святославның "Изборник" җыентыгында, мәсәлән, Аристотельнең җитди математик трактаты һәм Киев кешесенең үзенчәлекле уку методикасы буенча педагогик әсәр урнаштырылган. Монголлар басып алганчы ук Русьта, "Учение им же ведати человеку числам всех лет" кебек үзенчәлекле укыту кулланмалары булган. Ул Кирик Новгородец тарафыннан төзелгән һәм Урта гасырлардагы югары математик һәм әдәби өстенлекләргә ия трактат булып тора. Киев Русеның юридик ядкәре атаклы "Русская Правда" (XI гасыр) әсәренә математик мәсьәләләр кертелгән. Алар гомумән гамәли санауда һәм хуҗалык исәпләүләрендә күнекмәләр алу өчен китерелгән уку ярдәмлеге булган. Санау эшләре греклар абакасын хәтерләткән җайланмада башкарылган. Борынгы урыс абакасы ярдәмендә (соңгырак чордагы чут төймәләре прототибы) чия, кара җимеш төшләре кебек вак әйберләр белән параллель рәтләрдә төрле дәрәҗәдә саннар җыелган: аста — берәмлекләр, уртада — дистәләр, соңыннан йөзләр һ. б. ш.

Ул вакытлардагы педагогик әдәбиятта балаларда динилек, ата-анага, олыларга ихтирам тәрбияләү турында, ата-аналарга балаларның физик үсешен һәм сәламәтлеген, әхлак һәм акыл үсешен тәэмин итү турында, таләпчәнлек күрсәтү, тыңламаганнарга тән җәзасы бирү, таләпчәнлек белән беррәттән, назлау турында киңәшләр бирелгән.

XII гасыр үзенчәлекле педагогик ядкәр булып "**Князь Владимир Мономахның балаларга үгет-нәсихәте**" тора. Акыллы дәүләт эшлеклесе Владимир Мономах үз балаларына ничек яшәргә киңәш

биргән, аларны ватанны яратырга һәм дошманнардан сакларга, эшлекле, хезмәт сөючән, батыр булырга чакырган. Балаларда тәвәккәллек, кыюлык тәрбияләргә, әмма кешелекле, ярдәмчел булырга, ятимнәрне һәм тол хатыннарны якларга, көчлеләргә көчсезләрне рәнҗетмәскә, олыларны хөрмәтләргә, яшьтәшләренә карата ягымлы булырга чакырган. Аллага дәрвишлек, монахлык, ашаудан тыелу белән түгел, ә изге эшләрең белән ярарга кирәк. Владимир Мономах чит телләр белгән этисен истә тотып кешеләрне укырга чакырган. Үзенең киңәшен белемлелекне йөрәге белән кабул иткән барлык кешеләргә багышлаган. Мәгариф, белем бирү борынгы бердәм урыс халкының тырышлыгы аркасында Киев дәүләтендә югары дәрәҗәгә җитә. Монгол явы чорында бу халык өч мөстәкыйль халыкка бүленә. Великорус, украин, белорус халыклары үзләренең элекке бердәмлеген мәңге истә калдырдылар һәм шуңа тартылалар.

Тамырларының берлеген, тарих һәм мәдәни уртаклыкны аңлау XIV – XVII гасырларда бу халыкларның мәгариф, мәктәп һәм педагогик фикер үсешен булдырды.

XIII – XV гасырларда Русьта мәгариф һәм укыту. Киев дәүләтендәге югары дәрәҗәгә җиткән мәдәният үсеше феодаль ваклану сәбәпле тукталып калган. Басып алучылар тарафыннан камалган шәһәрләр янган, мәдәният байлыклары, шулай ук кулъязмалар, педагогик үгет-нәсихәтләр юкка чыккан.

Шулай да, авыр шартларга карамастан, урыс мәдәнияты үсешен туктатмаган. Шундыйлардан киң һәм бай Новгород җире, Тверь, Владимир һәм ныгый да, күтәрелә дә башлаган Мәскәү князьлекләре булган.

Новгород икътисади яктан көчле һәм сәяси мөстәкыйль сәүдә шәһәре булган. Анда китапларны күчереп язу киң таралган һәм китап күчереп язучылар күп булган. Руханилар вәкилләре генә түгел дөньяви кешеләр дә китаплар күчерү өчен күчереп язучыларны яллаганнар. Новгород кәсепчеләре арасында киң таралганнары "китапчы" һөнәрчеләре булган. "Китапчыларны", гадәттә, гаиләдә өлгерткәннәр: яшьләрне өйрәтүче күчереп язучы этиләре булган. Кайчакта бу гаиләләрдә башкалар да акчалата түләгәч "өйрәнүдә" катнаша алганнар.

Кулъязма китапларны бай бояр өйләрендә генә түгел, гади халыкта да сатып алганнар. Бу инде укый белүнең киң таралуын күрсәтә. Новгород һәм Псков күчереп язучылары текстка үзләрен-

нән өстәп язарга яратканнар. Оста ирләр һәм хатын-кызлар һөнәрчеләр эшләнмәләренә үзләренең имзасын куя торган булганнар.

Новгородта үткәрелгән археологик казылмалар XII – XV гасырларга тиң булган күп санлы тузга язылган грамоталарны, хатларны һәм башка документларны күрсәтә. Табылган грамоталарның күбесе — гади Новгород гражданнарының хосусый хат алышмалары. Туздагы хатлар очлы сөяк таякчык—"язмалык" ("писало") белән тырналып язылганнар. Бу хатлар Новгород җирендә укый-яза белүнең авылларда, шәһәрләрдә ирләрдә генә түгел хатын-кызлар арасында да киң таралганын ачык исбатлый. Тузъязмалар соңыннан Псков, Рязань, Смоленск һәм Русьның башка шәһәрләрендә дә табылган.

Археологлар Новгород малае Онфим язган берничә тузъязма тапканнар. Өйрәнчек Онфимның грамоталар җыентыгы (текстлар күчермәсе, диктантлар, яшьтәшенә тапшырылмаган хаты) урнашып беткән укыту, яздыру һәм санату методикасын аңларга мөмкинлек бирә.

Бу Новгородта ук борынгы урыс алфавитының 36 хәрефе белән тактаның бер ягында тырнап язылган агач әлифба табылган. Бу әлифбаларны кәсепчеләр эшләгән һәм һәркем алырлык бәядә саткан булганнар.

Язарга өйрәтүнең башы "язмалык" белән балавызланган тактага хәреф-таяк кисәкләрен, аркылы таякларны, озынча түгәрәкләрне һәм соңыннан хәрефләрне тырнап язудан торган. Иҗекләрне язуны, иҗекләрне сүзләргә һәм җөмләләргә ялгануы укучы Онфим грамоталарыннан күреп була. Такта кисәкләрендә язып өйрәнгәч тузда язарга керешкәннәр. Берничә туз кисәкләрен "дәфтәр" итеп җыеп теккәннәр.

Балаларны укытканда хәрефләрне ялгау методын кулланганнар. Китап уку методикасы "Избранник Святослава" (1076) дигән әсәргә кертелгән. "Китап уку турында... сүз" ("Слово... о чтении книг") бүлегендә чагылдырылган. Укырга һәм язарга өйрәткәндә халык сөйләм иҗаты: мәкальләр, әйтемнәр һәм табышмаклар кулланганнар.

Санарга өйрәтү бармаклар белән санаудан башланган, соңыннан славяннарда цифраларны белдерә торган хәрефләр символикасын өйрәнгәннәр. Табылган тузъязмаларның күбесе цифраларны язу күнегүләрдән тора.

XV гасырда Новгородта төзелгән борынгы әлифба дәреслеге (азбуковник), энциклопедик типтагы сүзлекләр кулъязмалары хәзерге вакытка кадәр сакланып калганнар.

Мәсәлән, грек, болгар һәм башка телләрдән алынган 350 язма сүзнең аңлатмасы бирелгән. Бу сүзлекләр шуны уйларга нигез бирә ки, мондый белешмәләргә мохтаҗ булган күп кенә укучылар саны булган.

Новгород "еретик" хәрәкәтләрнең үзәге булган. Ул вакытта оппозицион дини тәгълиматлар (богословские "ереси") да сәяси хәрәкәтләр булып саналганнар. Новгород "еретиклары" белемлелеге белән аерылып торганнар. Новгород еретикларның кулъязма китаплар җыентыкларында астрономия, табигать белеме хәтта философия, дини мәсьәләләр буенча әсәрләр очрый. Бу инде китап хуҗаларының укымышлы булуын исбатлый.

"Грамота осталары" ("Мастера грамоты"). XIII – XIV гасырларда монастырьларда һәм кайбер чиркәүләрдә грамота мәктәпләре булган. Мәсәлән, Троице-Сергиевск монастырьдагы мәктәпнең кечерәйтелгән формасы сакланып калган. Ләкин князьләр дә, чиркәү дә мәктәпләрне җитәрлек санда ачмаганнар. Күпчелек халыкка грамота осталары ярдәменнән файдаланырга туры килгән.

Грамота осталары XII гасырда Киев дәүләтендә үк барлыкка килгәннәр. Алар үзләренең торакларында, читтә, ата-аналар өйләрендә балаларны укырга, язарга һәм санарга түләүле өйрәткәннәр. XIII – XIV гасырларда "грамота осталарында" укыту ешрак очрый башлаган. Бер грамота остасында укучы балалар саны күбәя төшә (8-12 кешегә җитә). Бу инде чын мәктәпкә әйләнә.

Грамота осталары булып үзләренең һөнәрләренә өстәп, хәтта төп һөнәр итеп балаларны өйрәтүдә дьячоклар һәм дөнья ("мирские") халыклар шөгыльләнгәннәр. Кайбер грамота осталарының төп кәсебе китап күчереп язудан һәм укучыларны грамота нечкәлекләренә өйрәтүдән торган. Грамота осталарының кайберләре югарырак типта дип, әйтерлек булганнар. Алар аерым укучыларны (күрәсең, баерак гаиләләрдән) укырга, язарга гына түгел, әдәбиятка, хәтта математикага өйрәткәннәр.

Мәгарифне һәм тәрбия эшен тулысынча үз кулына алырга тырышкан чиркәү, грамота осталары ярдәменнән файдаланса да, аларга кире караштa торган. Чөнки бу дөньяви укытучылар еш кына элекке тәгълиматларга ябышып эш иткән православиегә кар-

шы торганнар. Бу Новгород, Псков, Мәскәү "еретикларының" чыгышыннан (XVI гасыр) билгеле булган.

XV – XVI гасырларда Рус дәүләтендә мәгариф, мәктәп һәм педагогик фикер. XV – XVI гасырларда аерым Рус кнәзьләре таралган киң территориядә үзәкләшкән бердәм Рус дәүләте төзелү процессы барган. Бу вакытта товар-акча мөнәсәбәте, кәсеп, промысел, шәһәр, мәдәният һәм мәгариф үсеше күзәтелә. Шул ук вакытта көчле темплар белән крестьяннарны крепостнойлыкка төшерү бара.

Мәскәү кнәзьлеге төньяк-көнчыгыш җирләрендә җитәкче булып китә. Ул халыкны монгол-татар кысуына каршы берләштерә. Бу көрәш 1380 елда рус гаскәрләренең ханнарны тулы җиңүе белән тәмамлана.

Илне чит яучылардан азат итү өчен көрәш, бердәм Рус дәүләте төзелүе беррәттән великорус халкы булдырылуы белән барган. Бу инде мәдәният һәм мәгариф үсүенә актив ярдәм итә.

Монастырьларның һәм кнәзьлек хакимиятләрнең Мәскәүдә китап саклау урыны булдыру, китап күчерү, мәктәпләр ачу эшчәнлеге белән беррәттән дөньяви грамота осталарының хосусый педагогик гамәлләре сизелерлек дәрәҗәдә җанланып китә. Гади халыктан чыккан кайбер укытучыларның эшчәнлеге чиркәү йогынтысындагы мәгарифтән аермалы буларак эчтәлеге белән еретик хәрәкәтләре кебек фикерлелекле, гуманизмлы һәм рационализмлы булган.

Шул вакытта хөр фикерлеләр арасында гуманистик үзенчәлекле оппозицион әсәрләр чыга.

Мәсәлән, XV гасыр ахырында Мәскәү еретик түгәрәкнең әгъзасы Федор Курицын **"Грамота турында язма"** ("Написание о грамоте") дигән гуманистик әсәр булдырган. Ул анда феодализмга һәм чиркәүгә каршы демократик фикерләр тәгъбирләгән.

И. Федоровның идеяләре, аның укыту системасы соңыннан урыс укыту китапларының башкаларында әлифбаларда һәм башлангыч әлифбаларда кулланылган. Көнкүреш, хуҗалык киңәшләре һәм гаиләдә балаларны тәрбияләү киңәшләре җыентыгы — "Домострой" шулай ук XVI гасырга туры килә. Ул ялгансыз турылыкта яшәргә ("в правде жить и в кривде не жить") өйрәткән, өй эшләрен җайлау киңәшләрен биргән. Алладан куркытып, кирәкле җәзаны биреп бала тәрбияләүгә багышланган аерым бүлекләре бар.

"Домострой" балаларны алладан куркытып, дини йолаларны үтәп, өлкәннәргә берсүзсез тыңлатып тәрбияләргә куша. Каты дисциплина турында сөйли, тән җәзасын бирергә киңәш итә. Ләкин балаларга таләпчәнлек һәм катылык күрсәтү белән беррәттән "Домострой" ата-аналарга балаларны яратырга әйтә, аларның нормаль үсүе һәм үсеше турында кайгыртырга чакыра, балаларда кыюлык, тайпылмаучанлык, эш сөючәнлек, сакчыллык, хуҗалыклылык, ихтирамлы мөгамәләдә булуны ("вежества") тәрбияләргә куша.

XIV – XVII гасырлардагы Украина һәм Белоруссия бертуганнар мәктәпләре (братские школы). XVI гасырда һәм XVI гасырның беренче яртысында Украина һәм Белоруссия дә Польша — Литва дәүләтенең хакимиятенә буйсынганнар. Польша паннары украин һәм белорус халыкларын җәберләгәннәр, монафыйклар ярдәмендә аларны поляклар һәм католиклар итәргә тырышканнар. Украина һәм Белоруссиянең эре җир биләүчеләренең күбесе ассимиляция процессына бирелде: поляк телен һәм мәдәниятен үзләштерде, католиклыкка күчте, үзләренең балаларын поляк уку йортына бирделәр. Бу милли — мәдәният буйсындыруга халык массасы, кәсепчеләр сатучылар, шулай ук Запорожье казаклары түбәнрәк руханилар, кечкенә утарлы алпавытлар бүтән мөгамәләдә булдылар. Алар поляк-католиклар изүенә каршы көрәш алып барганнар, аерым дини-милли оешмалар — бертуганлыклар (братства) төзегәннәр. Анда эш демократик принцип буенча алып барылган (гомуми җыелышта, күпчелек тавыш белән һ. б.) поляклар католиклар мәктәбенә каршы булган бертуганнар мәктәбен булдырганнар. Ул мәктәпләр милли һәм дини яктан җәберләүчеләргә каршы көрәш чарасы булып киткәннәр.

1586 елда беренче булып Львов (украин) мәктәбе барлыкка килә. Бу мәктәпнең уставы төзелгән була. Бу әһәмиятле документны Украина һәм Белоруссиянең башка бертуган мәктәпләре нигез итеп файдаланганнар. Иң якын унъеллыкларда Вилен, Брест, Могилев, Луцк, Киев һәм Украина, Белоруссиянең башка шәһәрләрендә бертуганнар мәктәбе барлыкка килә.

Безгә кадәр сакланган Львов мәктәбе уставы һәм аны әз генә үзгәртеп кабул иткән Луцк мәктәбе уставы бертуган мәктәпләрнең шундый демократик оешмаларын сурәтлиләр. Бертуганлыкның гомуми җыелышында бертуганнар мәктәбенең ректоры һәм укытучылары сайланган. Бертуганлык алардан башка ике попечитель-

не — мәктәпне иҗтимагый күзәтүчеләрне билгеләгән. Устав күрсәтүенчә бертуганлыкның һәрбер әгъзасы килеп мәктәпнең эше белән танышырга хокуклы булган.

Баланы мәктәпкә биргәндә әтисе ректор белән килешү төзегәннәр. Анда мәктәп баланы нәрсәгә өйрәтергә тиешлеге, ата-ананың мәктәпкә карата бурычлары күрсәтелгән (курс беткәнче баланы алмаска, баланың мәктәпкә төгәл йөрүенә комачауламаска һ. б.). Устав укытучыларның тиешле сыйфатын җентекләп билгеләгән. Укытучы динчел, акыллы, тыйнак, хикмәтле, сабыр, тотнаклы булып эчүче, азгын, ришвәтче, ачулы, көнләшүче, кешедән көлүче, әшәке сөйләүне, сихерче, уйдырма сөйләүче, булмаска тиеш. Балаларга карата таләпчән, ләкин ярату мөнәсәбәттә булырга тиеш. Әхлакый тәрбияләү белән берьюлы ул балаларның сәламәтлеге турында кайгыртырга физик тәрбияләүне уеннар, ярышлар кулланып башкарырга тиеш булган. Бөтен сословиеләрнең балалары иҗтимагый һәм материал хәлгә карамыйча алынырга тиеш булганнар. Ятимнәр бертуганлыкның тулы иждевениесендә яшәгәннәр. Бертуган мәктәп укытучыларына устав буенча демократик таләпләр куйганнар. Укытучы байларның балаларын, гарип ятимнәрне, урамда сорانып йөргәннәрне дә бертигез яратырга тиеш булган. Беркемне дә артык күрмичә мөмкинлегенә карап укытырга.

Балалар мәктәпкә бик иртән килергә тиеш булганнар. Дәрес калдыру, соңга калу рөхсәт ителмәгән. Берәр укучы мәктәпкә килми калса, укытучы өенә барып дәрескә килмәү сәбәбен белешергә тиеш булган. Иртә белән укучылар өйдә эшләнгән язу эшләрен күрсәткәннәр һәм телдән җавап тотканнар. Соңыннан сыйныф дәресләре башланган. Төшке аштан соңгы тәнәфес үткәч укытучы өй эшләре биргән. Шимбә көнне атна буена үткәннәр кабатланган.

Бертуган мәктәпләрдә беренче урында славян телен өйрәнү торган. XVI гасырда һәм XVII гасырның башында бертуган мәктәпләрнең укытучылары берничә басма славян грамматика чыгарганнар: 1591 елда Львов бертуганлыгы чыгарган "эллинословен телендә матур сөйләү грамматикасы" ("Грамматика доброглаголивого эллинословенского языка"); 1596 елда Вильнода чыккан бертуганнар мәктәбенең укытучысы Лаврентий Зизан төзегән "Словен теле грамматикасы" Киев бертуганнар мәктәбе укытучысы Мелетий Смотрицкий тарафыннан төзелгән, 1691 беренче тапкыр,

соңыннан 1648 елда Мәскәүдә икенче тапкыр бастырылган "ЯСловен грамматикасы".

Грек, латин теле, грамматика, риторика, диалектика (тривиум дип аталган фәннәрнең гуманитар циклы), квадривиумның кайбер элементлары (арифметика, геометрия, астрономия, музыка) буенча укытканнар.

Львов, Луцк, Могилев, Вильно, Киев кебек зур шәһәрләрнең бертуганнар мәктәпләрендә бу фәннәрнең тулы курсын укытканнар, ә башка бертуганнар мәктәпләрендә укыту курсы славян, грек, латин телләрен, риторика һәм җырны өйрәнү белән чикләнгән. Бертуганнар мәктәбенең укыту эшләрендә сыйныф-дәрес системасы элементлары булган, халык иҗаты кулланылган. Аларда яңалыкка, әһәмияткә ия булган үзенчәлекләр кертелгән: мәктәпнең демократик тәртибе, укуга күп балаларны тарту, кирәкле дидактик кагыйдәләр.

Заманында алдынгы мәктәпләр буларак Украинаның бертуганнар мәктәпләрендәге демократик үзенчәлекләренең күбесе Коменскийның прогрессив принципларына якын.

Балаларны Украина һәм Белоруссияне җәберләүче поляк паннарына һәм иезуитларына каршы көрәшү рухында тәрбияләгән бертуганнар мәктәбе бу дәүләтләрнең 1654 елда Россия белән кушылу өчен көрәшендә зур роль уйнаганнар.

Киев академиясе. 1615 елда ачылган Киев крещение (богоявление) бертуганлык мәктәбе 1632 елда Россиянең беренче югары уку йорты — Киев-бертуган коллегиясенә әверелә, соңыннан академия хокукына ирешә.

Киев-бертуган мәктәбе башында ректорлар торганнар. Аларның белеме төпле булып, кайберләре әдәбият әсәрләренең авторы да булганнар. Шундыйлардан, мәсәлән, Львов мәктәбе ректоры Тов Борецкий булган, соңыннан Киев митрополиты. Ул Украина белән Россиянең кушылуын нык яклаган.

Киевны үзләренең хакимлеге астында тоткан поляк корольләре бу мәктәпкә академия хокукын бирмәгәннәр. Ә мәктәпнең курслары гадәти поляк академиясе курсларына тиң булган. Академия хокукын һәм титулын Петр I генә биргән.

Академиядә 8 класс булган. Алар бүлекләрдән (отделениеләрдән) торган: түбән — 4 класс, урта — 2 класс, югары бүлекләр — 2 класс. Уку срогы 12 елга кадәр сузылган. Түбән бүлекләрдә славян, грек, латин һәм поляк телләре (уку, язу, грамматика), догалар,

катехизис, арифметика, музыка, җир буенча укытканнар; урта классларда — поэзия (пиитика) һәм риторика; югары классларда — фәлсәфә, ә XVII гасыр ахырыннан — дин өйрәтмәләре. Академиягә укучыларны төрле катлаулардан (сословиеләрдән) алганнар. Руханилар балалары башка катлау укучыларыннан аз булганнар.

Киев академиясе зур мәдәният үзәге буларак, Россия мәгарифенең үсешенә көчле йогынты ясаган.

Мәсәлән, аның йогынтысы буенча Харьковта, Черниговта коллегиумнар барлыкка килгән. Ул мәгариф өлкәсендә эшлеклеләр төркемен (Епифаний Славинецкийны, Симеон Полоцкийны һ. б.) булдырган. Бу эшлеклеләр XVII гасырның икенче яртысында Мәскәү грек-латин мәктәбен оештырганнар. Киев академиясе үрнәге буенча 1687 елда Мәскәүдә Славян-грек-латин академиясе барлыкка килә. Петр I академиядән чыкканнарга һәм укытучыларга (Феофан Прокоповичка, Стефан Яворскийга һ. б.) үткәргән реформаларына каршы төшүче элекке урыс руханилар белән көрәштә таянган. XVIII гасырдагы Славян-грек-латин академиясе һәм руханилар семинариясе ректорлары һәм рефектлары да Киев академиясеннән чыккан булганнар. Мәскәү университетының кайбер беренче профессорлары да анда белем алган булганнар.

XVII гасырда Рус дәүләтендә мәгариф үсеше. Башлангыч һәм грек-латин мәктәпләре. Урыс халкы XVII гасырның башында мөстәкыйльлеген юкка чыгарырга маташучы чит ил интервентлардан саклап кала. Тышкы дошманнар белән көрәштә урыс халкының үзаңы үсә.

XVII гасырда феодаль җирбиләү үсә, бик зур киңлекләр үзләштерелә, кәсепләр һәм сәүдә үсешләре күзәтелә, крепостной мануфактура һәм бердәм бөтенроссия базары барлыкка килә, Көнбатыш Европа белән сәүдә элемтәләре көчәя. Катлау вәкилләре монархиясе формалаша. Халык массасы крепостнойлыкка каршы көрәш алып бара. Бу көрәш еретик тәгълиматларда чагылдырылган. Бу вакыйгалар урыс әдәбияте үсешенең алга китүенә сәбәп булганнар, мәгариф ихтыяҗын көчәйткәннәр, мәктәп һәм педагогик фикер үсешенә китергәннәр, бигрәк тә XVII гасырның икенче яртысында.

Бик күп әдәбият әсәрләре, дөньяви һәм сатирик повестьлар, төрле эшлеклеләрнең биографияләре, шулай ук кульязма әлифба дәреслекләре һәм басма әлифбалар, китап басу эше алга китә. Урыс диңгезчеләре һәм сәяхәтчеләре Азиянең көньягында һәм көнчы-

гышында берничә мөһим ачышларга ия булалар. Әкренләп цифраларны славянча билгеләүдән гәрәпчә билгеләүгә күчәләр. Бу инде математик белемнәр үсешенә һәм математикага өйрәтүгә нык ярдәм итә.

XVII гасыр, бигрәк тә аның икенче яртысы XVIII гасырның башында Россия тарихында үткәреләә торган мәгариф реформасына хәзерлек чоры булган.

Укырга, язарга өйрәтүче чиркәү һәм монастырь башлангыч мәктәпләре саны арткан. XVII гасырның икенче яртысында укырга өйрәтүне басма әлифба буенча алып барганнар. Башта алфавитны хәрефләрнең славян исемнәре белән ятлаганнар: аз, буки, веди, глагол, добро, есть, ите һ. б. Соңыннан укучылар "икеязма" (двоеписьменные) ачык иҗекләрне, алфавитның тартык хәрефләрен һәрбер сузык хәрефләр белән эзлекле рәвештә ятлаганнар.

ба, ва, га, да... ша, ща,

бе, ве, ге, де... ше, ще,

бя, вя, гя, дя... шя, щя.

Соңыннан "өчъязма" иҗекләр ясалганнар.

бра, вра, гра... һ. б.

бре, вре, гре... һ. б.

Шуның өстенә һәрбер хәрефне, соңыннан бөтен иҗекне әйтергә кирәк булган.

буки-аз-ба, веди-аз-ва һ. б.

Укырга, хәреф җыю методы белән, өйрәтүне балаларның эмоциясенә нык тәэсир итә торган беренче уку китабы — чосослов һәм псалтырь материаллары буенча үткәрелгән. Язарга өйрәтү ул кадәр авыр булмаган. Чөнки славян әлифбаның хәрефләр язылышы четерекле түгел.

Гади грамота мәктәпләреннән башка кайбер зур шәһәрләрдә һәм монастырьларда югары типтагы, грамматика исемле мәктәпләр ачылганнар. Шулай ук квалификацияле "грамота осталары" ярдәмендә өйдә укыту да катлауланган.

Моны күп санлы әлифба дәреслекләре исбатлыйлар. Анда грек галиме Иоанн Дамаскин язган грамматика курсы, ә соңыннан Лаврентий Зизаний һәм Мелетий Смотрицкий грамматикалары урнаштырылган. Югары мәктәпләр һәм өйдә укыту өчен билгеләнгән кулъязма әлифба дәреслекләрендә кыска грамматика курсларыннан башка, дүрт гамәлне аңлаткан арифметика курслары да кертелгән булган.

XVII гасырның икенче яртысында Мәскәүдә бер-бер артлы грек-латин мәктәпләре барлыкка килә. Мәсәлән, бу гасыр уртасында бояр Ртищев Андреевск монастыренда, Мәскәү тирәсендәге Воробьевлар тавында грек-латин мәктәбе ачкан. Анда латин һәм грек телләре, риторика һәм фәлсәфә буенча укытканнар.

1653 елда Епифан Славинецкий җитәкчелегендә Чудов монастыренда грек мәктәбе ачылган була. 60 нчы еллар уртасында Спасск монастыренда (Мәскәү үзәгендә) Симеон Полоцкий тарафыннан Заиконоспасск грек-латин мәктәбе оештырылган була. XVII гасырның 80 нче елларында хөкүмәт Мәскәү типография каршында грек училищесы ача. 80 нче еллар уртасында укучылар саны 233 кә җитә. Поляк, швед, немец кебек төрле телләрдән тәрҗемә итүчеләр училищеләре һәм тәрҗемә эшенә хосусый өйрәтү, бигрәк тә Посольск приказда булганнар.

Мәктәпнең күпчелеге чиркәү катнашы буенча түгел, ә укымышлы кешеләр ярдәмендә яисә хөкүмәт тарафыннан, кайчакта чиркәү каршы булса да ачылганнар. Көнбатыш Европа фәненә тартучы яңа мәгарифне яклаучылар һәм чит илнең православный патриархларына таянган элекке урыс руханилары арасында яңа ачылачак мәктәпләрдәге белем нигезе буенча бик каты көрәш барган. Консерватив чиркәүлеләр латин теленә һәм дөньяви фәннең элементларына (грамматикага, риторикага, арифметикага) каршы төшкәннәр һәм укучылар изге язмаларны уку белән чикләнүне таләп иткәннәр.

Славян-грек-латин академиясе. Мәскәүдә Киев үрнәге буенча академия булдыру фикере XVII гасырның 70 нче елларында барлыкка килә. Андый академияне оештыру инициаторы Белоруссиядән Мәскәүгә килгән атаклы язучы һәм педагогы Симеон Полоцкий булган. 1682 елда ул академиянең "Привилегиясен" (оештыру грамотасын) төзегән. Ләкин патша ул грамотаны башта расламаган.

Проект буенча академиягә православиеле кешеләр генә кабул ителгән. Академия дәүләткә һәм чиркәүгә кирәкле белемле кешеләрне әзерләүне максат итеп куйган. Проект буенча "җиде иректе фән" (грамматика, риторика, диалектика, арифметика, геометрия, астрономия, музыка), дини тәгълимат һәм суд эшчәнлеге фәннәре укытылган. Проект буенча академия алдында белем күтәрү, ләкин православие кануннарын үтәү, ересьләргә һәм православиедан

тайпылучыларга каршы көрәштә таяныч булу мәсьәләләре дә куелган булган.

Патриарх һәм аның тирәсендә руханилар академия ачуны бик озак тоткарлап торганнар. Ачылыш 1687 елда гына булган. Академиянең төп укытучылары ике галим грек монахлары — Падуан университетының фән докторлары абыйлы-энеле Ионикш һәм Софроний Лихудлар булган. Алар укытучыларны сайлап алганнар, үзләре академиянең югары классларында риторика һәм фәлсәфәне укытканнар, грек һәм латин телләрендә православие эчтәлекле грамматика, пинтика, риторика дәреслекләрен төзегәннәр. Яңалыклары белән канәгать булмаган элекке урыс руханилары Лихудларны академиядән алдырып ташлап, провинциаль монастырьга яптырырга ирешәләр. Биш елдан соң гына Лихудларга Новгород шәһәренә күчеп урнашырга мөмкинлек бирелгән. Алар анда Мәскәү академиясе үрнәгендә славян-грек-латин училищесы ачканнар һәм укытканнар. XVII гасырның башында бу училище Новгород епархиясендәге башка шәһәрләрдә училищелар тарату чыганагы булган.

Славян-грек-латин академиясе руханилар гына түгел, ә медик-хирургия мәктәпләренә укучылар хәзерләгән. Укучыларның күбесе 1725 елда фәннәр Академиясе каршында ачылган университет студентлары булып киткәннәр. Славян-грек-латин академиясендә М. В. Ломоносов, танылган язучы А. Д. Кантемир, архитектор В. И. Баженов һәм шулай ук XVII гасырдагы мәдәният, фән, мәгариф өлкәсендәге күренекле эшлеклеләр укылганнар.

1755 елда Мәскәү университеты ачылгач, академия филологик һәм фәлсәфи типтагы югары уку йорты дәрәҗәсен югалткан һәм руханилар академиясенә әверелгән. XIX гасырның башында аны Троице-Сергиевск лаврага күчергәннәр.

XVIII гасырдагы уку дәреслекләре. XVI гасырда һәм XVII гасырның беренче яртысында Мәскәүдә бастырылган беренче китаплар арасында уку дәреслекләре күп булган. Ул вакытта басылган китаплар кыйммәт һәм сирәк булганнар. Мәктәптә һәм өйдә укыту кулъязма әлифба дәреслекләре (азбуковниклар) кулланылган. Кайберләрендә уку дәреслекләре итеп башлангыч әлифба, грамматика, арифметика буенча мәгълүматлар, дини-әхлак үгетләре кертелгән булган. Икенчеләрендә грек теле буенча башлангыч мәгълүматлар, табигать белеме буенча ("Күк күкрәү һәм яшен турында", "елның дүрт вакыты турында", "кайбер

хайваннар тасвирламасы турында"), тарих буенча ("Иулий Кесарь турында", "Царьградны алу турында", "Ян Гусны яндыру турында", "Рус дәүләтенең барлыкка килүе турында", "Борис һәм Глебны үтерү турында") статьялар китерелгән. Бу әлифба дәреслекләре югары типтагы мәктәпләрдә һәм аннан соң укыту процессларында да грамматика буенча уку ярдәмлеге булып кулланылгандыр.

Әлифба дәреслекләр энциклопедик типтагы сүзлекләр төрендә дә булганнар. Анда аңлашылмаган сүзләр һәм сөйләм аңлатмалары урнаштырылганнар. Энциклопедик типтагы әлифба дәреслекләр-сүзлекләр зурларга китап укыганда һәм югары типтагы мәктәпләрдә кирәкле белешмә китабы булганнар.

"Балалар йолаларының гражданлыгы" ("Гражданство обычаев детских") китабы XVII гасырның икенче яртысында язылган һәм кульъязма списогы буенча киң таратылган. Бу заманындагы прогрессив эшлеклесе Епифан Славинецкий тарафыннан төзелгән, Эразм Роттердамскийның әхлак тәрбиясе турындагы әсәрдән иҗади тәрҗемә китап. 164 сорау-җавап итеп төзелгән "балаларның матур йолалары" ("благолепных обычаев детских") дигән бу җыентыкта үзеңне әдәпле тоту (поза, ишарә, мимика, кием-салым һ. б.), өйдә, кунакта өстәл артында, очрашуларда, балалар белән уйнаганда мәктәптә тоту кагыйдәләре бирелгән.

"Балалар йолаларының гражданлыгы" — искиткеч педагогик әсәр. Балаларның җәмгыять тормыш кагыйдәләрен үтәү аларның эчке югары сыйфатларын кешеләргә әдәпле һәм хөрмәтле карашын, тыйнаклыгын, горурлык хисен чагылдыра дип әйтелгән анда.

* * *

Ундүртенче лекция

ФЕОДАЛИЗМ ТАРКАЛГАН ҺӘМ КАПИТАЛИЗМ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ БАШЛАНГАН ЧОР МӘГАРИФЕ

Мәгариф өлкәсендәге XVIII гасыр башы реформалары. XVIII гасыр җиткәндә Россия күпмилләтле киң булган феодаль-абсолютлы дәүләткә әверелгән.

Мануфактура производствосы һәм металлургия промышленносте нык үсеп киткән. Халыкара әһәмияте шактый арткан һәм ныгыган була. Ил сизелерлек алга киткән булса да, Көнбатыш Европа илләреннән артка калган. Җитештерү көчләрен һәм оборона сәләтен үстерү теләге буенча Петр I нең дворян хөкүмәте мәдәният, фән һәм техника өлкәләрендә төрле реформалар үткәргән. Бу реформалар беренче дәвердә дворянлыкны күтәрүгә мөмкинлек биргән. Армия, флот һәм дәүләт аппаратындагы барлык команда постлары дворяннарга бирелгән. Туып килгән сәүдәгәрләр катлавы өчен дә күп эшләнгән.

Педагогика һәм мәктәп үсеше өчен мәгърифәт реформалары бик мөһим булган, әйтик гражданнар алфавитын кертү, периодик матбугатның барлыкка килүе, атап әйткәндә, "Ведомости" исемле беренче газетаны бастыру, оригиналь һәм тәрҗемә ителгән дөньяви әдәбият чыгару, фәннәр Академиясен оештыру. Беренче дөньяви дәүләт мәктәпләрен ачу Россия культурасы өчен бик әһәмиятле вакыйга булган.

1701 елда Мәскәүдә математика һәм навигация фәннәре мәктәбе ачылган. Европа өчен бу беренче реаль училище булган. 1708 елда Галле (Германия) шәһәрендә ачылган реаль училище "Математика, механика һәм экономика реаль училищесы" хосусый булган, әз (12) укучылар укыткан һәм нибары берничә ел гына көн күргән.

XVIII гасырның беренче яртысында эш иткән Мәскәү мәктәпләре дәүләтнеке булганнар һәм аларда ел саен кимендә 200, ә кайчакта 500 бала укыган.

Мәктәпнең уку планына математика (арифметика, алгебра, геометрия, тригонометрия), астрономия, географик мәгълүматлар һәм махсус фәннәр: геодезия, диңгездә йөзү һәм башка дөньяви фәннәр

кертелгән булганнар. Киң профильле профессиональ-техник уку йорты буларак, мәктәп төрле һөнәр белгечләрен чыгарган.

Укучылар бирегә ирекле һәм мәҗбүри рәвештә алынган. Мәҗбүри рәвештә крепостной строй вакытында идарә итүче катлаудагы торгынлыкта һәм бәйрәмнәрчә яшәп гадәтләнгән дворяннарның укырга теләмәгән балаларын алганнар. Күп укучылар түбән катлаулардан (дьяк, дьякон, посадской һәм солдат балалары) булганнар. Алар белем һәм техник белгечлек алырга теләгәннәр.

Бу мәктәптә эшләү өчен Англиядән профессор Форварсон һәм ике укытучы чакыртыла. Алай да төп укытучы булып мәктәпкә бөтен көчен һәм булдыклыгын биргән белемле математик һәм искиткеч педагог Леонтий Филиппович Магницкий (1669-1739) санала.

Уку ярдәмлекләре төзелгән була. Алар арасында **Л. Ф. Магницкий китабы "Арифметика — саннар фәне" ("Арифметика – это наука числительная")** мөһим роль уйнаган, әлбәттә.

1715 елда мәктәптәге математика һәм навигация фәннәренең диңгез класслары Петербургка күчерелгән һәм алар нигезендә ДИҢГЕЗЛӘР АКАДЕМИЯСЕ ачылган.

Мәктәптә билгеле уку сроклары куелмаган булган. Укучылар индивидуаль тәртиптә бер фәнне үзләштергәч, икенче фәнгә күчкән. Шуның сәбәпле чыгарылышлар шәхси уңышларга карап, яисә ведомстволарның таләбе буенча төрле вакытта булган.

Бу мәктәпне бетергән тәрбияләнүчеләр төрле хуҗалык, идарә, мәдәният һәм фән тармакларына, ә кайберәүләр яңа ачылачак мәктәпләргә укытучы итеп җибәрелгән. Дворян балалары белем алуларын Диңгезләр академиясендә дәвам итә алганнар. Кайчакта Мәскәү мәктәбендә үзләренең сәләте һәм тырышлыгы белән аерылып торган түбән чик кешеләре дә ул академиягә керә алганнар. Бу мәктәптә тәрбияләнеп чыкканнар Россияне өйрәнү өчен фәннәр Академиясе оештырган экспедицияләрдә катнашканнар.

Махсус һәм гомуми белем мәктәпләре. Петр I патшалыгы вакытында Петербургта, Мәскәүдә һәм башка зур шәһәрләрдә артиллерия мәктәпләре, порт-шәһәрләрдә — навигация мәктәпләре (навигацкие школы), шулай ук Мәскәүдә хирургия, инженер, төрле телләрдә ("разноязычная") мәктәпләр ачылган.

XVIII гасырның башында тау токымнары эше белгечләренә кирәкле Урал рудасын эшкәртүче беренче металлургия заводлары

корылган. 1721 елда урыс галиме һәм дәүләт эшлеклесе Урал тау заводларын идарә иткән **В. Н. Татищев җитәкчелегендә Уралда беренче тау промышленносте мәктәбе** ачылган. Соңыннан барлык Уралның дәүләт заводларында арифметика мәктәпләре, кайберләрендә тау промышленносте мәктәпләре, Екатеринбургта бөтен Уралның арифметика һәм тау промышленносте мәктәпләрен идарә итүче Үзәк мәктәп ачылган. Бу мәктәпләрдә укучыларны гомуми һәм махсус белем биреп әзерләүне бик оста берләштергәннәр.

XVIII гасыр башында дәүләт гомуми белем мәктәпләре ачмакчы булганнар. Укырга, язарга, арифметикага шулай ук алгебра, геометрия, тригонометрия буенча гади мәгълүматлар биреп өйрәтү өчен 1714 елда барлык чиркәү епархияләренә "цифир" училищелар ачу турында указ җибәрелгән. 1718 елда 42 "цифир" училищесы ачылган. Анда да математика һәм навигация фәннәре мәктәпләренә кебек барлык катлау балалары (крепостной крестьян балаларыннан башка) ирекле һәм мәҗбүри рәвештә алынганнар.

Дөньяви мәктәпләрне оештыру белән бергә руханилык белеме алуда да реформалар үткәрелгән. Башлангыч архирея мәктәпләре һәм руханилар семинарийлары ачылган. Аларда да гомуми белем алу программасы киң кулланылган. Кайчакта күчмә халыклар балалары (дети податного населения) укыганнар. Крепостной крестьяннар дәүләт мәктәпләрендә белем алудан мәхрүм булганнар. Тик сирәк кенә гади халыкның аерым балалары дьячокларда һәм өй укытучыларында чиркәү грамотасын өйрәнгәннәр.

Сыйнфый катлаулар аркасында чикләнгән булуга карамастан, реформалар мәгариф һәм мәктәпләр үсешенә зур йогынты ясаганнар.

1725 елда Петр I үлгәннән соң Петербургта Фәннәр академиясе ачылган. Петр I исән чакта ук Академиянең Уставы бастырылган. Көнбатыш Европадан күренекле галимнәр чакыртылган, җиһазларга заказ бирелгән. Академияне оештыру буенча башка чаралар күрелгән булган. Академия каршында университет һәм гимназия ачыла. Чит ил галимнәре анда урыс галимнәрен һәм белгечләрен әзерләргә тиеш булганнар.

Фәннәр академиясенә богословие кертелмәгән булган, барлык эшләр дөньяви характерда үткәрелгән. Анда бөек чит ил галимнәре

эшләгән (Эйлер, абыйлы-энеле Бернуллилар, Гмелин, Паллас һ. б.), фәнни тикшерүләр үткәрә алуга ирешкән урыс кешеләре дә эшләгән. Аларның күбесе демократик катлаулардан чыккан кешеләр булган. Иң беренче итеп М. В. Ломоносов турында әйтергә була.

М. В. Ломоносов һәм аның урыс педагогикасы һәм мәктәбе өчен әһәмияте. Урыс халкының бөек улы М. В. Ломоносовның сокланырлык күпкырлы эшчәнлеге үзенең туган илен көчле бай һәм белемле иттерү өчен булган патриотик омтылышы белән рухланган.

Михаил Васильевич Ломоносов (1711-1765) крестьян-помор улы, башта Холмогор янындагы үзенең авылында өй укытучыларында Смотрицкий һәм Магницкий дәреслекләре буенча укыган. 19 яшендә ул җәяү Мәскәүгә килә һәм үзенең крестьяннардан чыкканын яшереп славян-грек-латин академиясенә керә. Иң яхшы укучы буларак, Петербургка академия гимназиясенә командировкага җибәрелә. 1736 елда аны чит илгә укуын дәвам итәргә җибәрәләр. Анда күренекле галимнәрдә укый.

1741 елда Ломоносов Петербург фәннәр академиясенең адъюнкты, соңыннан 1745 елда химия профессоры, ә киләчәктә академик булган. Аның эшчәнлеге аеруча күпкырлы һәм нәтиҗәле булган. Ул кайбер фән тармакларын булдырган. "Искиткеч ихтыяр көчен гаҗәеп аңлау сәләте белән берләштереп, Ломоносов мәгарифнең барлык тармакларын кочагына ала... Тарихчы, оратор, Механик, Химик, Минеролог, Рәссам һәм Шагыйрь — ул барысын да сыный һәм барысына да төшенә",— дип язган А. С. Пушкин. Ломоносов урыс классик философиясенә, философия материализмына, фәнни табигать белеменә нигез салган. Ул табигатьнең гомуми законын — табигать белеменең нигезе булган материя һәм хәрәкәтнең саклану законын ачкан.

Ломоносов исеме белән урыс грамматикасын һәм Россиядә әдәбият телен булдыру бәйләнгән. Әдәбиятның, поэзиянең, сәнгатьнең киләчәк үсеше өчен бу бик мөһим булган. Ломоносов урыс теленең лексикасын фәнни терминнар белән баеткан. Академиклар арасыннан беренче булып урыс телендә физика буенча лекцияләр укыган һәм фәнни эшләр язган.

Файда күрү максатыннан чыгып эш иткән сарай наданнарына таянып урыс фәненең үсешен һәм "россиян" галимнәрен әзерләүне тоткарлаган реакцион галимнәр белән Ломоносов туктаусыз көрәш алып барган. Крестьяннарга уку йортларына керү бикле булуы

турында ачу хисе белән әйтә торган булган. Россиядә катлауларга карамый торган мәктәпләр ачуга барлык мөмкинлекләр белән ирешкән.

Урыс фәне үсеше өчен патриотик көрәшендә Ломоносовның университетта һәм Фәннәр академиясе гимназиясендә педагогик эшчәнлеге зур урын алып торган.

1758 елдан бирле бу уку йортларының җитәкчесе буларак, Ломоносов гимназия һәм университетның гомуми эш кагыйдәсен билгеләгән, гимназиянең укыту планын һәм университетның укыту тәртибен төзегән, укыту принципларын һәм методларын билгеләгән. 1758 елда үзе төзегән "Академия гимназиясенең регламенты" документында Ломоносов гомуми белем бирүче һәм катлауларга карамый торган мәктәпләргә басым ясаган.

Гимназия һәм университет өчен ул берничә дәреслек булдырган. 1748 елда аның тарафыннан "Риторика", 1755 елда — "Россия грамматикасы" язылган. Бу укыту кулланмалары 50 ел буена урыс гомуми белем мәктәбе өчен иң яхшылардан саналган. Аларда Ломоносовның тел һәм әдәбият турында алдынгы тәгълиматы урын алган. Бу тәгълиматта чынбарлыкка булган реаль мөнәсәбәт чагылдырылган. Ломоносов тарих буенча китап язган. Тәрҗемә иткән "эксперименталь физика" китабында табигать күренешләрен философия материализмы рухында аңлаткан. Физик законнарны беренче тапкыр бу китапта догматик рәвештә түгел, ә укучыларга законнарны төшендерерлек итеп физик тәҗрибәләр аркылы биргәннәр.

Мәскәү университетын булдыруда Ломоносов бик актив катнашкан.

Дворяннар катламының ябык уку йортлары. XVIII гасырда дәүләт башкарган икътисади, сәяси һәм мәдәни чаралар дворянлыкның күтәрелүенә китерде. Дворянлык хакимлек итүче катламга әйләнә һәм зур өстенлек ала. 1731 елдан башлап дворяннар өчен үзенә аерым хәрби мәктәпләр — кадетлар корпуслары булдырыла. Анда дворян балалары офицер чинында хәрби хезмәткә әзерләнгәннәр.

Дворяннар катламының беренче ябык мәктәбе — шляхта коры җир корпусы (сухопутный шляхетский корпус) 1731 елда Петербургта ачылган. Аның үрнәге буенча барлык кадетлар корпусы төзелгән. Дворян балалары бу мәктәпләрдә махсус хәрби әзерлек белән беррәттән киң гомуми белем һәм "дөньяви" тәрбия алганнар.

Кадетлар корпусында дүрт класс булган. Аларның һәркайсында укыту ике елдан дүрт елга кадәр алып барылган. Барлык уку срогы уртача 10-12 ел тәшкил иткән. Класслар саны кире юнәлештә алып барылган, беренче класс дүртенче дип, ә чыгарылыш классы беренче дип саналган.

Башлангыч ике классларда (дүртенче һәм өченчедә) гомуми белем фәннәрен өйрәнгәннәр: тел-әдәбият (словесность), математика, тарих һәм география, ә югары классларда — махсус фәннәр. Корпуста шулай ук сыбай йөрүгә, фехтованиегә, бию һәм музыкага, дворян балаларын яхшы манерага, югары һәм дөньяви җәмгыятьтә тотарга өйрәтүгә күп игътибар биргәннәр.

Петр I заманында ачылган дәүләт мәктәпләрендә професбилгеләнүе һәвәслек һәм теләккә карап гражданнар яисә хәрби хетмәттә специальләшү мөмкинлеге буенча башкарылган.

Үзләренең балалары өчен ябык уку йортлары оештырган дворяннар педагогиканың соңгы казанышларын кулланганнар. Физик һәм эстетик тәрбиягә, укучыларны гуманлы методлар буенча өйрәтүгә зур игътибар биргәннәр. Кадетлар корпусында яхшы төзелгән китапханә, үзенең театры, укучылар арасында шигъри иҗат итү, журнал чыгару, кичәләр үткәрү төрле күңел ачулар, прогулкалар һ. б. булган.

Дворяннар катламын яклау сәясәте көчәюе аркасында бу уку йортларында укыту XVIII гасырда ачыктан-ачык сословиеле характерга күчә.

1752 елда Диңгезләр академиясе кадетлар диңгез корпусына — дворяннар катламының чикләнгән мәктәбенә әйләнә, Петербургтагы артиллерия һәм инженерлар мәктәбе Дворян артиллеристлары, Дворян инженерлары корпусына әйләнә.

Петербугта һәм Мәскәүдә чит ил пансионнары — тәрбия-белем бирүче хосусый йортлар ачыла. Алпавыт утарларына чит илләрдән, бигрәк тә Франциядән дворян балаларын француз теленә һәм дөньяви манераларга өйрәтүче тәрбиячеләр һәм гувернерлар чакырылган.

Рухани балалары өчен руханилар мәктәпләре оештырыла. Халыкның түбән катламнары өчен аерым мәктәпләр кулланыла. Мәсәлән, сакланып калган берничә цифир училищесын гарнизон мәктәпләренә әверелдерәләр, анда солдат балаларын укыталар.

XVIII гасырның уртасында Россиядә барлыкка килгән катлам системалы мәгариф шундый үзенчәлекләр белән аерылып

торган: һәрбер уку йорты аерым катламга билгеләнгән, төрле катлам мәктәпләре программалары да бер-берсеннән аерылган булган. Дворян мәктәпләре чәчәк аткан булса, башка катламнар мәктәбе мохтаҗлыкта яшәгәннәр.

Мәскәү университеты һәм аның педагогика, мәктәп үсешенә йогынтысы. XVIII гасырның икенче яртысына таба аз санлы урыс интеллигенциясе — М. В. Ломоносов тирәсендә тупланган прогрессив галимнәр барлыкка килгән. Ул вакытта иң мөһим проблема булып "табигать россияннарыннан" галимнәр кадрларын әзерләүче туган ил фәне үзәге төзү торган. Мәскәү Петербургтан соң урыслар тормышында икътисади, мәдәни һәм иҗтимагый үзәк булганлыктан, Ломоносов фәннең яңа бу үзәге Мәскәүдә оештырылырга тиешлеген исбатлаган.

1755 елның апрелендә М. В. Ломоносовның турыдан-туры катнашуы буенча Мәскәүдә өч факультеттан: юридик, фәлсәфә, медицина факультетларыннан торган университет ачылган. Көнбатыш Европа университетларыннан аермалы буларак, дини тәгълиматлар факультеты булмаган әлеге бер факультеттагы эш структурасы һәм юнәлеше табигать фәннәре (бигрәк тә физиканы) һәм иҗтимагый (тел-әдәбият һәм тарих) фәннәре үсеше мәнфәгатен тәэмин иткәннәр. Медицина факультетында исә табигать фәннәренең барлык күләмен өйрәнергә тиеш булганнар. Философия факультеты составына тарих-филология кафедралары кергән. Мәскәү университеты дөньяви мәгариф үзәге булып киткән.

Галимнәрнең фәнни эш алып бару мөмкинлекләре турында кайгыртып, М. В. Ломоносов университет буенда төрле ярдәмче учреждениеләр (физика кабинеты, анатомия театры һ. б.) булдыру хәстәрен күргән.

Университет каршында ике гимназия ачылган. Мәгариф мәсьәләләре һәм формаларының самодержава-крепостной строй таянычы һәм дворяннар катламы карашы исәбе буенча бер гимназия дворяннар өчен һәм икенчесе кешеләрнең төрле чиннарына (крепостной крестьяннардан башка) тиешле булган. Гениаль Ломоносовның крестьяннарга университетта белем бирү рөхсәтен булдыру хыялы тормышка ашырылмыйча калган.

Гимназиядә урыс, латин һәм бер чит телне, тел-әдәбият, математика һәм тарих өйрәнгәннәр. Урта белем алу университет гимназиясендә туган телне өйрәнүдән башлануын әйтеп китү мөһим.

Бу гимназия тәҗрибәсе нигезендә 1758 елда Казанда — Мәскәү университеты профессорлары инициативасы нигезендә университетка керергә хәзерләү гимназиясе ачыла. Мәскәү университеты 30 ел буена бу гимназияне укытучылар, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре һәм җиһазлар белән тәэмин итеп торган. **Бу гимназия нигезендә 1804 елда Казан университеты ачылган.**

Россиянең фән, мәгариф һәм мәдәният үсешендә тирән эз калдырган Мәскәү университеты һәм университет гимназиясе булдыруда М. В. Ломоносовның тәгъбир ителерлек хезмәте бик зур.

Мәскәү университеты каршында атаклы урыс архитекторы Казаков мәктәбе эшләгән. Анда "табигать россияннарыннан" зодчийлар һәм төзүчеләр хәзерләүне максат итеп куйганнар. Мәскәү университетын тәмамлаган бөек урыс архитекторы Баженов та мәктәп ачкан. Ул мәктәптә талантлы разночинецлар һәм крепостнойдан ирекә чыгучылар укыган. Мәскәү университеты һәм гимназия профессорлары һәм укытучылары XVIII гасырдагы урыс мәгарифе эшенә гаять зур өлеш керткәннәр. Мәсәлән, профессорлар Аничков, Барсов, Двигубский һәм башкалар дәреслекләр төзегәннәр. Мәскәү гимназиясе һәм университетта тәрбияләнүчеләрдән профессорлар Афонин, Карамышев (табигать фәннәре белгече К. Линейда диссертация яклаганнар), профессорлар Перевощиков һәм Десницкий (Адам Смитта диссертация яклаганнар), язучы-мәгърифәтче Фонвизин һәм Новиковлар туган ил фәне һәм мәгарифнең күренекле башка эшлеклеләре булганнар.

Ломоносов шәкертләре һәм аның эшен дәвам иттерүче университет профессорлары һәм укытучылары тәрбия мәсьәләсе буенча күп шөгыльләнгәннәр. Университет актлары вакытында үзләренең чыгышларында бу галимнәр мөһим педагогик мәсьәләләргә зур игътибар күрсәткәннәр. Алар укыту методикасы өстендә эшләгәннәр һәм аерым предметлар (тарих, математика һ. б.) буенча укыту өчен үзенчәлекле кулланма төзегәннәр. "Университетка керү өчен хәзерләү ысулы" ("Способ учения подготовляющегося к университету") исемле бу кулланма 1771 елда урыс, латин, немец һәм француз телләрендә чыккан. 1779 елда Россиядә университет каршында укытучылар өчен беренче семинария ачылган. Ул Мәскәү, Казан гимназияләре һәм пансионнар өчен укытучылар әзерләгән.

XVIII гасырның икенче яртысында университет каршында төрле әдәбият һәм фәнни җәмгыятьләр эшләгән. Мәктәптә

укытуны үстерүдә "Типография җәмгыяте", ә анда күренекле язучы-сатирик һәм мәгърифәтче-педагог Н. И. Новиков зур роль уйнаган. Бу җәмгыять провинция шәһәрләрендә китап кибете, җирле типографияләр һәм китапханәләр оештыру өчен иганә җыйганнар, шулай ук мәктәпләр һәм өйдә укыту өчен күп уку-укыту китаплары чыгарган.

Мәскәү университеты каршындагы типография эшчәнлегендә чит ил педагогик хезмәтләрен тәрҗемә итү зур урын алып торган. Тәрҗемә ителгән китаплардан Коменскийның **"Хисләр дөньясы картинкаларында"** ("Лицо чувственных вещей в картинках") исемле дәреслеге һәм башка әсәрләре, Локкның **"Тәрбия турында уйланулар"** ("Мысли о воспитании") дигән трактаты, Руссоның **"Эмиль, яисә тәрбия турында"** ("Эмиль, или о воспитании") исемле китабы (Екатерина II сатудан тыйган) булган.

Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышыннан соң хөкүмәт Мәскәү университетының барлык җәмгыятьләрен тыйган, кайбер эшлеклеләрен кулга алган, крепостька япкан, ә соңыннан сөргән. Бу эзәрлекләүгә карамастан Мәскәү университеты һәм аның прогрессив эшлеклеләре мәдәнияткә, мәгарифкә, мәктәпкә һәм Россиянең педагогик карашына йогынты ясауны дәвам иткәннәр.

И. И. Бецкойның педагогик эшчәнлеге. XVIII гасырда крепостной крестьяннарны алпавытларның каты эксплуатацияләве ахыргы чиккә җиткән.

Крестьяннар һәм алпавытлар арасында сыйнфый көрәш көчәеп киткән, дәһшәтле крестьяннар сугышы кабынып китә.

Екатерина II үзенең патшалык итүен 1762 елда дәүләт законнарын һәм төрле катламнарның хәлен яхшыртырга сүз бирүдән башлый. Ул француз мәгърифәтчеләре белән хат алышып торган, аларны муафыйклы рәвештә халык мәгарифенең проектын төзергә һәм яхшыртырга чакырган, тәрбия һәм мәктәп эшен яхшыртырга сүз биргән. Бу эшкә Иван Иванович Бецкойны (1704-1795) тарткан. И. И. Бецкой күп еллар Франциядә үткәргән, француз мәгърифәтчеләре белән очрашкан, мәгърифәткә якын булган учреждениеләр белән танышкан. Аның инициативасы буенча 1763 елда Мәскәүдә яңа гына бала тапкан хатыннар өчен госпитале булган тәрбияханә ачылган. Соңыннан Петербургта һәм провинциаль шәһәрләрдә тәрбияханәләр төзелгәннәр.

И. И. Бецкой Екатеринага Россиядә балалар тәрбияләү эшен гомуми үзгәртеп кору турында доклад тәкъдим иткән. Бу

доклад 1764 елда "Яшүсмерләрне тәрбияләүне генераль оештыру" ("Генеральное учреждение о воспитании особого пола юношества") дип бастырылган һәм закон көченә кергән. Докладта күрсәтелгәнчә Россиядә ябык тәрбияләү-укыту учреждениеләре төзеп, анда балаларны 5-6 яшьтән 18 яшькә кадәр тотып, барлык катламнардан "яңа токым кешеләре" тәрбияләнергә тиеш. Бу вакыт арасында балалар гади кешеләрнең бозыклыгына эләкмәсен өчен түбәндәге тормыштан аерылырга тиеш булганнар.

Бецкой кадетлар корпусында һәм гимназияләрдә укыту-тәрбияләү эшенең куелышын үзгәрткән, тәрбияләү вакытын озайткан, крепостной крестьяннардан башка барлык катламнар өчен яңа тәрбияләү-укыту учреждениеләре, атап әйткәндә, Сәнгать академиясе каршында училище һәм малайлар өчен коммерция училищесы, Петербугта мещаннар кызлары бүлеген керткән, дворянкалар өчен Смольный асылзат кызлар институты ачкан.

XVIII гасырның барлык мәгърифәтчеләре кебек, Бецкой иҗтимагый тормыштагы тәрбия эшенең роленә югары бәя биргән, "барлык яхшылыкның һәм начарлыкның тамыры — тәрбия" дип әйткән. Ул яңа "токым кешеләрне" — крестьяннар белән гуманлы мөнәсәбәттә торган һәм дәүләт белән гадел идарә итүче дворяннарны, шулай ук промышленность һәм сәүдә белән шөгыльләнүче — "кешеләрнең өченче чины" — разночинецларны булдыру турында уйлаган. Бу яңа кешеләр тәрбияләнгән карашларын һәм гадәтләрен балаларына, ә алары инде киләчәк буыннарга тапшырырлар, шулай итеп әхлаклылык һәм кешеләр кыланышы үзгәрер, һәм, димәк, җәмгыять чистарыр, дип ышанган ул. Ул җәмгыятьне үзгәртеп коруны, ләкин крепостной стройны саклап калуны һәм аңа кагылмауны тәкъдим иткән.

Әхлакый тәрбиянең төп чарасы булып "алладан куркытып" аңлату, балаларны әйләнә-тирәдәге мохиттан аерып тоту, уңай үрнәкләр торачак, дип уйлаган Бецкой. Ябык тәрбия учреждениеләрдәге балаларда хезмәт сөю омтылышын хуплауны, тик ятудан читләшү гадәтләрен булдыруны, ихтирамлык, фәкыйрьлек һәм бәхетсезлеккә мәрхәмәтлелек күрсәтүне тәкъдим иткән.

Бецкой физик тәрбиягә зур әһәмият биргән. Төп чаралары итеп чиста һаваны, зыянсыз мәзәкләр һәм уеннар белән күңел ачуны санаган. Акыл тәрбиясе мәсьәләләрен искә алып, уку процессы балалар өчен күңелгә ятышлы булырга, ирексезләмичә башкарылырга, балалар һәвәслегенә таянырга тиеш дип күрсәткән ул. Яшүс-

мерләрне өйрәткәндә ятлау белән чикләнмичә, күрсәтеп һәм ишеттереп өйрәтергә тәкъдим иткән. Балаларны ирексезләгәндә аларның сәләтләре зәгыйфьләнә дип кисәтү ясаган, балаларга физик җәза бирүне катгый рәвештә тыярга кушкан. Моның турында "Мәскәү өенең генераль планы"нда ("В генеральном плане Московского дома") әйтелгән: "Беркайчан да, бернинди сәбәпкә карамыйча балаларны кыйнамаска дигән законны шунда ук һәм мәңгегә кертергә һәм беркетергә".

Хатын-кызларга белем бирүче буларак, Бецкой хатын-кызның баланы, бигрәк тә кече яшьтәге баланы, тәрбияләү эшендәге роле зурлыгын икърар иткән, җәмгыятьтә хатын-кызны ана һәм тәрбияче буларак, хөрмәтләүне булдыру турында әйткән. Беренче хатын-кызлар тәрбияләү-укыту учреждениесе — Асылзат кызлар институты (Смольный институты) ачуда зур роль уйнаган. Ләкин Бецкой карашларында сыйныф, дворянлык белән чикләнү эзе ачык күренеп тора: балалар йөрәгенә "алладан курку" хисен тагарга кушуында, крепостной стройны тәрбияләү нәтиҗәсендә яхшыртып булуга иллюзор ышануында, балаларны тирәлектәге чынбарлыктан аерып алырга омтылуында, катлам нигезендә тәрбияләү системасын оештырырга теләвендә. Ул система буенча һәрбер катламга үзенә хас мәктәп туры килә, ә крепостной кешеләр укудан мәхрүм калганнар.

Шәһәрләрдә училищеләр булдыру. Ф. И. Янкович эшчәнлеге. Россия шәһәрләрендә икътисади үсеш, шәһәрләр һәм шәһәр халкының саны үсүе, крестьяннар сугышын тар-мар иткәннән соң крепостникларның урындагы дәүләт аппаратын ныгыту мәсьәләсен куюы (1775 елда һәркайда губернияләр теркәү) хөкүмәттән өстенлексез шәһәр халкына мәктәпләр оештыру эше белән шөгыльләнүне таләп иткәннәр.

1782 елда Петербургта Халык училищеләре комиссиясе — хөкүмәт — бюрократ органы төзелгән. Аңа ул вакыттагы урыс мәдәниятенең, атаклы эшлеклеләре кертелмәгән. Бу комиссиянең эшчән әгъзасы булып серб кешесе Федор Иванович Янкович (1741-1814) китә. Ул Австро-Венгриядән император тәкъдиме буенча чакыртылган булган. Янкович Коменский идеясен үткәрүче зур дидакт булган.

1786 елда хөкүмәт тарафыннан комиссия әзерләгән "Россия империясенең халык училищелар уставы" ("Устав народным училищам в Российской империи") бастырыла. Устав буенча

шәһәрләрдә кече (икееллык курслы) һәм төп (бишьеллык курслы, дүрт класс составында, соңгы класс икееллык) халык училищелары ачарга рөхсәт ителгән.

Төп училищеларның уку планына түбәндәге предметлар кертелгән: уку, язу, санау, (кыска катехизис), изге тарих, матур язу, рәсем ясау, арифметика, тарих (гомуми һәм урыс тарихы), география, грамматика, геометрия, механика, физика, табигать тарихы, архитектура.

Төп училищеларда китапханәләр һәм укыту кабинетлары ачарга, анда табигать тарихы, математика, физика буенча күрсәтмә әсбаплар булдырырга тәкъдим ителгән.

Өяз шәһәрләрендә кече училищелар ачылганнар. Анда төп училищеның башлангыч классларында укытыла торган фәннәрне өйрәнгәннәр.

Укучылар өчен дәреслек булып **"Кеше һәм гражданин вазифасы турында китап"** саналган. Анда самодержавие-крепостниклык идеологиясе рухында аллага, патшага, кешеләргә карата тиешле бурычлар турында балаларга аңлатма бирелгән.

Халык училищесының материал тәэминаты һәм аны идарә итү педагогик администрациягә түгел, ә губерния чиновниклары җитәкчелегендә булган җәмгыять карамагындагы әмерләргә йөкләтелгән. Мәктәпләр җирле хакимлекләргә бирелгән булганнар. Ә алар мәктәп үсешен теләп бетермәгәннәр, педагогиканы белмәгәннәр, укытучыларны вак чиновниклар дип санаганнар һәм кимсеткәннәр.

Россиядә XVIII гасыр ахырында 315 кече һәм төп училищелар ачылган. Анда барлыгы 20 000 укучы укыган һәм 700 укытучы эшләгән. Россия кебек зур ил өчен бу мәктәпләр һәм укучылар саны бик аз булган. Яңа ачылган училищеларда укыту эше Янкович белән бергә Петербург халык төп училищесында актив катнашкан урыс галимнәре төзегән принциплар һәм методлар нигезендә алып барылган. Ул училище 1782 елда ачылган, чынында исә, булачак халык училище өчен укытучыларны әзерләүче семинарий ролен уйнаган. Фәннәр академиясе һәм Мәскәү университеты эшлекләләре уку планында каралган барлык фәннәр буенча дәреклекләр төзегәннәр. "Халык училищесы укытучыларына ярдәмлек" дигән бик җитди дидактик трактат язганнар. Бу китапта барлык укыту-тәрбияләү мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр бирелгән, мәктәптә

индивидуаль системалы укыту урынына класс-дәрес укыту эшен оештыру тәкъдим ителгән.

Түбәндәге методлар тәкъдим ителгән:

Бердәм, яисә күмәк уку. Класста укытучы яисә каршыга чыккан укучы укый торган китап башкаларда да булырга тиеш.

Бердәм кулланма. Класста яисә өйдә өйрәнә торган уку дәреслегенең авыр урыннарын укытучы аңлатып җибәрә.

Таблицалар. Дәреслек буенча планнар, тезислар, текст конспектлары төзү.

Башлангыч хәрефләр белән күрсәтү. Билгеләмәләрне яисә кагыйдәләрне тасвирлаган хәрефләрне тактада яисә дәфтәрдә башлангыч хәрефләр белән күрсәтү. Бу хәтергә алуның мнемоник ысулы булган.

Сораштыру (вопрошение) — укучылардан сорау алу. Шунда ук укучыларның ничек аңлавын ачыклыйлар. "Ярдәмлектә" әйтелгәнчә, укытучы күбрәк укучыларның хәтеренә түгел, ә аңына кагылырга һәм төшендерергә, гел ятлаттыру белән булмаска тиеш. Ләкин төзелгән методлар башлыча дәреслек текстын хәтергә алуны исәптә тоткан. Класста дәреслекне үзләштерүне җиңел әйтү исәбеннән текст өстендә зур эш алып барылган. Бу инде тәкъдим ителгән укыту ысулының мөһимлеген исбатлый.

Халык училищеларында елына ике тапкыр сынаулар үткәрелергә тиеш булганнар: уку елының уртасында башка класс укытучылары барында хосусый сынаулар, ә уку елы ахырында — халык алдында — бик күп санда чакырылган шәхесләр һәм шәһәр дворянлыгыннан, сәүдәгәрләр, руханилар һәм чиновниклар катлавыннан кунаклар алдында сынаулар.

Халык алдындагы сынаулар тантаналы рәвештә үткәннәр: укытучылар фәннең һәм хөкүмәт укытуның әһәмиятлеген пропагандалап сәламләү речьләрен әйткәннәр. Укытучылар шигырьләрен сәнгатьле укыганнар. Кунаклар имтиханнар программасына туры китереп укучыларга сораулар бирә алганнар.

"Укытучыларга ярдәмлек" рәсми дидактика булып саналган, укытучыларга бу китапның тәкъдимнәрен берничек тә читкә тайпылмыйча катгый рәвештә үтәргә кушылган.

Россиянең педагогик караш вәкилләреннән XVIII гасырның икенче яртысында крепостнойлыкка каршы юнәлешкә якын торучылардан Г. С. Сковорода, Н. И. Новиков һәм революцион урыс мәгърифәтчелек вәкиле А. Н. Радищев булганнар.

Г. С. Сковороданың педагогик карашлары. Украинаның бөек философы, демократы һәм мәгърифәтчесе Григорий Саввич Сковорода (1722-1794) рәсми динне һәм чиркәүләрнең үле схоластикасын куркусыз фаш итүче булган. Аның дөньяга карашы гомумән идеалистик булса да, карашларында М. В. Ломоносов белән якын торган материалистик элементлар булган. Барысы да табигатьтән башланган, табигать фәзәдә (пространствода) һәм вакытта чиксез, аның башы да ахыры да юк дип уйлаган Г. С. Сковорода.

Сковорода тумыштан килгән идеяләрне икърар итмәгән, белемнәрнең чыганагы тирә-яктагы дөнья дип санаган. Тәрбия турында өстенлек алган фикерләрне ул бик нык тәнкыйтьләгән. Гади халык педагогик иҗатка сәләтле, чит ил теорияләрен механик рәвештә гамәлгә кертү зыянлы, дигән мөһим фикерне саклаган.

"Рәхмәтле Еродий" ("Благодарный Еродий") дигән мәсәлдә украин дворяннарының французларга һәм немецларга механик рәвештә иярүләрен көлеп чыккан. Бер маймыл үзенең балаларына гади халык шикелле түгел, ә аерым, "затлы" тәрбия биргәне турында сөйли. Бу тәрбияне француз укытучылары алып барган. Алар мартышкаларны Марокка хуҗасының сараена урнаштыру өчен җырларга, уйнарга, биергә, дөньяви кыланышларга өйрәткән.

Методика хакимнәрнең (чынында, урыс дворяннарының) зәвыкларына һәм таләпләренә маймылларча охшарга тырышучы мартышкага Сковорода капма-каршы итеп гади һәм чынлап та вөҗданлы Еродий ләкләкне күрсәтә. Үзенең балаларын тәрбияләгәндә ләкләк аларны тик ятудан, әдәпсезлектән, эгоизмлыктан саклап калырга тырыша.

Сковорода Руссо кебек табигатькә муафыйклык таләпләрендә тәрбияләүне яклап чыккан, шулай да җәмгыять тормышының идеаль формасы итеп кешеләрнең борынгы халәтләрен санамаган, балалар табигатен артык күрмәгән, һәм балаларны җәмгыятьтән табигать кочагына аерырга кушмаган. Балаларны табигать үзенчәлекләренә туры китереп тәрбияләргә кирәклеге турындагы уйлары иҗтимагый уңай эчтәлекле булган. Сковорода кешеләрне нindидер эшчәнлеккә сәләтләре һәм мәнфәгатьләре буенча, ә җәмгыятьтә иҗтимагый мөнәсәбәтенә һәм хәленә карамыйча билгеләүне таләп иткән.

Тәрбияче тәрбияне идарә итәргә, ә табигый хасиятләрне күнекмәләрдә һәм эшчәнлектә җәелдерергә тиеш дип санаган Сковорода. "Рәхмәтле Еродий" дигән мәсәлдә ләкләк маймылга "Әти миңа

канат булдырган, ә очарга үзем өйрәндем, ул миңа әйбәт йөрәк бирде, ә мин үз ихтыярым белән аны күнектерәм",— дип әйтә. Кешенең әхлаклы камилләшүендә Сковорода хезмәт тәрбиясенең әһәмиятен ачыклаган. Ул алдынгы дидактик таләпләр белән чыккан, укучылар материалны төшенеп өйрәнергә һәм үзлектән уйлап чыгарга тиеш дип басым ясаган.

Сковорода барлык балаларга да белем бирергә, ирләргә һәм хатыннарга белем бирүдә тигез хокук кертергә тиешлеген яклаган.

Н. И. Новиковның педагогик эшчәнлеге һәм карашлары. XVIII гасырның икенче яртысындагы атаклы мәгърифәтче-педагог Николай Иванович Новиков (1744-1818) Мәскәү университетында укыган. Анда аның дөньяга карашы формалашкан һәм мәгърифәт эшчәнлеге башланып киткән. Новиков патша хакимлегеннән бәйсезлектә булган халык училищеларын оештыру хәрәкәтенә җитәкчелек иткән, җәмәгать инициативасын өстенлексез халыкка мәктәпләр төзүгә юнәлдергән. Ул өй укытучыларының балаларны укыту эшен дөресләп җибәрергә тырышкан. Күп дәреслекләр эшләп чыгарган: башлангыч әлифба, әлифба, төрле фәннәрдән дәреслекләр. Новиков "Балалар йөрәге һәм аңы өчен китап" ("Детское чтение для сердец и разума") исемле балалар журналының оештыручысы һәм редакторы булган. Журнал чыгаруны соңыннан мәгълүм тарихчы һәм язучы Н. М. Карамзинга тапшырган. Нәтиҗәдә В. Г. Белинский бу журналга югары бәя биргән. Новиков җәмгыять фикерен тәрбия мәсьәләсенә тарту исәбеннән "Трутень" (әрәмтамак), "Живописец" (Рәссам) кебек сатирик журналларында педагогик темаларга багышланган статьялар урнаштырган.

Новиковның барлык мәгърифәт эшчәнлеге самодержавиегә, крепостной режимга һәм аның тудырган нәрсәләренә, шул исәптән, крепостной системадагы тәрбия эшенә нәфрәт белән сугарылган. Коллыкка, деспотизмга һәм башбаштаклыкка каршы көрәшне ул мәгърифәт позициясеннән алып барган. Иҗтимагый проблемаларны хәл итү чарасы итеп Новиков мәгарифне күргән. "Кешеләрнең барлык ялгышларының сәбәбе наданлык, ә камилләшүнең сәбәбе — "белем",— дигән ул.

Новиков кешеләрне әхлакый камилләшүгә өндәгән. Әгәр алар укымышлы һәм белемле булсалар, игелекле булачаклар дип уйлаган, фәнне һәм динне бергә килештерергә омтылган, дини тәрбия балаларны һәм яшьләрне әхлак тәрбияләүнең өлеше итеп күргән. Ләкин Новиков рәсми динне һәм хөкем сөргән чиркәүне яклау-

чы булган. Ул дингә түзү ягында торган, православие руханиларын тәнкыйтьләгән, төрле каршы идеяләр тәкъдим иткән дөнья үзенең табигый законнары буенча алга бара, дигән фикерне әйткән.

Аның фикеренчә, тәрбияләү максаты булып үзенең эшчәнлеген ватанга һәм гражданнарына файда китерүгә юнәлдергән актив ихтирамлы шәхес формалаштыруда тора.

Һәрбер кеше никадәр укымышлы булса, шул кадәр хөкүмәткә файдалырак булыр дип, Новиков балаларга киң һәм күпкырлы акыл белеме бирергә чакырган.

Мәгариф балаларның акылын баетып кына чикләнми, ә фикерләү сәләтен үстерә, дип санаган ул. "Аларның аңы күнектерелгән һәм төрле белемнәр белән баетылган булырга гына түгел, ә нәрсә белергә теләүләрен, дөреслекне ялганнан аера алырлык һәм тикшерү сәләтен булдырырлык итеп күнектерергә кирәк".

Педагогика системасында зур урын алган халыкчан тәрбия идеясеннән чыгып, Новиков башта балалар туган телне, һәм әдәбиятне, үз иленең тарихын һәм географиясен өйрәнергә тиеш дип санаган. Укыту эчтәлегенә ул гуманитар, шулай ук төгәл фәннәрнең һәм табигать белемнәренең "элементар низеләрен" керткән.

Новиков балаларга үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын, кешеләрнең хезмәт эшчәнлеген һәм процессларын өйрәтергә кирәк дип санаган. Дворяннар Россиясендә үсеп килә торган буында физик эш белән шөгыльләнүче гади кешеләргә карата кимсетү хисен тудырган вакытта, ул тәрбиячеләрне балаларда эшчәннәрне хөрмәтләү хисен булдырырга турыдан-туры өндәгән. "Балаларны крестьяннарның өйләренә һәм келәтләренә, рәссамнарның һәм кул осталарының эш урыннарына йөртегез, аларга җирнең төрле-төрле байлыклары ничек эшкәртелә, кешеләр файдасына һәм куанычына ничек әзерләнә торган урыннарын күрсәтегез, шунда кулланыла торган коралларны белергә һәм аның белән эш итүчеләрне хөрмәтләргә өйрәтегез".

Әхлак тәрбиясе өлкәсендә Новиков шулай ук әһәмиятле тәкъдимнәр ясаган. Ул балаларны яратырга һәм ихтирам итәргә, аларны уңай үрнәкләрдә тәрбияләргә, аларда үзләренең кылган эш мотивлары турында уйлауны, әхлак гамәлләрендә туктаусыз күнегүләрне булдырырга кирәк дип санаган. Тән җәзасы бирүгә Новиков кискен рәвештә каршы чыккан. Балаларның аңын уңай әхлак күзалламалар белән баетырга, барысыннан да алда

"кешеләрнең натураль тигезлеге турында төшендерергә" кирәклеген күрсәткән, балаларда кешеләргә карата, аларның халәтләренә, милләтләренә, иҗтимагый хәлләренә бәйләнмичә, мәхәббәт хисен үстерергә өндәгән ул. Ярлыларга, җәберләнгәннәргә карата кызгану уяту өчен балаларны ярлыларның, авыруларның һәм үлем хәлендәгеләрнең аяныч, ләкин гыйбрәтле торак урыннарына йөртергә, авыру һәм мохтаҗ кешеләргә икмәкнең ничек авыр килгәнен күрсәтергә киңәш биргән.

Балаларда дөреслекне яратуны, хакыйкатьне курыкмыйча саклап калуны, кечкенәдән үк файдалы эшне белүне тәрбияләү бик мөһим.

"Прибавления к Московским ведомостям" (Мәскәү ведомостьләренә кушымта) журналында Новиков "Балаларны тәрбияләү һәм аларга үгет бирү; файдасы зур белемнәрне җәелдерү һәм гомуми иминлек өчен" дигән искиткеч әһәмиятле мәкаләсен бастырган.

Үз вакыты өчен бу бик мөһим педагогик хезмәт була. Анда физик, әхлак һәм акыл тәрбиясе мәсьәләләре карала. Автор педагогиканы тәрбияләү теориясе итеп камилләштерергә чакырган, бу фәнне шактый материаллар булганлыктан педагогика дип атала алачагын исбатлаган, басма эшләрен укучыларга, ата-аналарга, тәрбиячеләргә педагогикада булган балаларны ничек тәрбияләргә дигән мәгълүматларны җиткерергә тырышкан. Новиковның эшчәнлеге һәм карашлары Россиянең алдынгы кешеләренә, аерым алганда, А. Н. Радищевка зур йогынты ясаган, әлбәттә.

* * *

Унбишенче лекция

XIX ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА РОССИЯ МӘКТӘБЕ ҺӘМ ПЕДАГОГИКАСЫ

XVIII гасырның ахырында һәм XIX гасырның башында бөтен дөньяда тарихи мөһим вакыйгалар булып үттеләр. Философлар чорны гомумән буржуаз-демократик, "аерым алганда буржуаз милли хәрәкәт", "үзеннән артык яшәгән феодал учреждениеләренең тиз җимерелү чоры" дип атадылар.

1812 елда Европаны Наполеон хакимлегеннән коткарган Ватан сугышы, бу сугышның тәэсире нәтиҗәсендә Көнбатышта милли-азатлык өчен хәрәкәт күтәрелүе, Испания вакыйгалары, Грециядә баш күтәрү, самодержавие-крепостной стройга каршы революцион-декабрист дворяннарының чыгышы — бөтендөнья тарихи мөһим вакыйгаларның кыскача исемлеге шул.

Бу вакытта Европаның барлык илләрендә заманда прогрессив булган буржуаз стройны кую өчен алдынгы көчләрнең феодализмга каршы көрәше барган.

Россиядә дәүләти мәктәпләр мәгарифен төзү. Феодаль-абсолютик учреждениеләрне җимерүгә китерүче тарихи шартлар булгач, монархлар либерализмга ялагайлана башлыйлар. Россиядә крепостной мөнәсәбәтләрнең кризисы аркасында җәмәгатьчелек фикере басымына каршы килә алмыйча патша хөкүмәте мәгариф реформасын үткәргән.

Александр I патшалыгы башлануы белән беррәттән, дәүләт идарәсенең иске системасын, заманына туры килгән коллегия — министрлыклар белән алыштыру да булган. Дәүләт аппаратын үзгәртеп корып хөкүмәт барыбер самодержавие-крепостной строй нигезләрен саклап калган. Тышкы фасадын гына яңарта төшкән.

Патша хөкүмәте тарафыннан оешытырылган министрлыклар арасында 1802 елда халык мәгариф министрлыгы төзелгән. Патша бюрократик аппаратының бу органына "халык" исемен бирү, хөкүмәт аппаратының эшчәнлек юнәлешен мәгариф өлкәсендәге бөтен халык мәнфәгатен канәгатьләндерү өчен борырга дип беркатлы уйлап, алдынгы урыс кешеләре тарафыннан хөкүмәткә тәкъдим

ителгән. Монафыйкларча халык исеменә күчкән мәгариф министрлыгы башка министрлыклар кебек һичшиксез сыйнфый, крепостной алпавытлар мәнфәгатьләре һәм аларның терәге — самодержавие хөкүмәте ягында булган.

1803 елда **"Халык мәгарифенең алдагы кагыйдәләре"** ("Предварительные правила народного просвещения"), ә соңыннан **"Университетлар карамагындагы уку йортлары уставы"** ("Устав учебных заведений, подведомых университетам") бастырылган. Алар өстендә эшләргә урыс мәдәниятенең алдынгы эшлекләре дә тартылганнар. Бу документ буенча мәктәп мәгарифенең яңа системасы формалашкан. Аңа дүрт уку йорт төре кергән: мәхәллә училищесы (приходское училище), өяз училищесы (уездное училище), гимназия һәм университет. Элекке системага караганда бу система капиталистик мөнәсәбәтләр үсешенең башлану процессына турырак килгән.

Кабул ителгән устав буенча Россия 6 уку округына бүленгән: **Мәскәү, Петербург, Казан, Харьков, Вильно һәм Дерпт округлары.** Һәрбер укыту округы башына университет куелган.

Моңа кадәр Россиядә **өч университет** булган: Мәскәүдә, Дерптта (хәзер Тарту шәһәре), Вильнода һәм тагын Петербургта. Казанда һәм Харьковта университетлар ачылырга тиеш булган. Фән һәм укытудан башка университетларга административ-педагогик функцияләр тапшырылган булган. Алар округтагы барлык уку йортларын идарә итәргә тиеш булганнар. Шуның сәбәпле университет советларында училищелар комитеты төзелгәннәр һәм университетлар профессорлары методист һәм инспектор ("визитатор") функцияләрен үтәргә тиеш булганнар.

Халык мәгариф системасында уку йортларының түбән буыны катгый рәвештә югары буынга буйсындыру урнаштырылган булган: мәхәллә училищелар өяз училищеның күзәтүчесенә (смотрительгә) буйсынган, өяз училищелары — гимназия директорына, гимназияләр — университет ректорына, университет — уку округының караучысына (попечителенә).

Берьеллык укыту курслы мәхәллә училищелары шәһәрләр һәм авылларның һәрбер мәхәлләсендә ачыла алганнар. Мәхәллә училищелар, беренчедән, өяз училищега укучылар әзерләргә, икенчедән, түбән катлам халыкка дини тәрбия һәм уку, язу һәм санау күнекмәләре бирергә тиеш булганнар. Бу мәктәпләр хөкүмәттән акча килмәү сәбәпле киңәя алмаганнар.

Мәхәллә училищеларының уку планына шундый уку фәннәре кергәннәр: алла законы һәм вәгазь, (закон божий и нравоучение), уку, язу, арифметиканың беренче гамәлләре, шулай ук "Кеше һәм гражданин вазифалары турында" ("О должностях человека и гражданина") китабының кайбер бүлекләре буенча уку. Бу китап 1786 елдан соң халык училищеларында официаль ярдәмлек булып кулланылган, самодержавиегә тугрылыклык хисен тәрбияләргә исәпләнгән булган. Училищеда дәресләр атнасына 9 сәгать исәбеннән үткәрелергә тиеш булган.

Ике ел укыту сроклы өяз училищелар губерния һәм өяз шәһәрләренең һәрберсендә бер, ә чаралар булганда күбрәк санлы итеп оештырылганнар. Шәһәрләрдә кече училищелар өяз училищеларына әверелгәннәр.

Өяз училищелар максаты, беренчедән, гимназиягә укучылар әзерләү, ә икенчедән, өстенлексез киң катлам балаларына "промышленность хәлләренә карап кирәкле белемнәр" җиткерү булган.

Өяз училищеларның уку планына алла законы, "Кеше һәм гражданин вазифалары турында" китабын өйрәнү, Россия грамматикасы (Российская грамматика), башка телдә сөйләшкән халыклар ягында өстәмә рәвештә җирле тел грамматикасы, гомуми һәм урыс географиясе, гомуми һәм урыс тарихы, арифметика, геометриянең башлангыч кагыйдәләре, физиканың һәм табигать тарихының башлангыч кагыйдәләре, край хуҗалыгына һәм промышленностена кагылышлы технология кагыйдәләре, рәсем — барысы 15 уку фәне кертелгән. Күп предметлык укучылар өчен көч җитмәслек йөкләмә булган. Барлык фәннәрне ике укытучы алып барган. Аларның атна йөкләмәсе 28 сәгать тәшкил иткән, һәрбер укытучы 7-8 фәннән укытырга тиеш булган.

Кече училищеларга караганда өяз училищеларын финанслау яхшырак булган. Кече училищелар җәмгыять карамагының приказы буенча фида кылулар исәбенә тотылган булсалар, өяз училищелар өлешчә дәүләт бюджеты исәбенә, шулай ук урында халыкка налог салып җыелган чара исәбенә тотылганнар. Бу хәл өяз училищелар саны үсүенә уңай йогынты ясаган.

Гимназияләр һәрбер губерния шәһәрендә халык өчен төп училищелар нигезендә, алар булмаганда яңа урта мәктәпләр ачылырга тиешле булганда оештырылганнар. Гимназиядә укыту курсы срогы дүрт ел тәшкил иткән. Дворяннар һәм чиновниклар өчен ачылган-

лыктан, гимназияләр алдында, беренчедән, университетка әзерләү, ә икенчедән, әдәплелекне кешеләргә туры килгән мәгълүматларны алырга теләүчеләр өчен кирәкле фәннәрне укыту максаты торган.

Гимназиянең уку планы бик киң энциклопедик булган. Планга латин, немец һәм француз телләре, география һәм тел, гомуми һәм Россия дәүләте статистикасы, фәлсәфи фәннәрнең (метафизика, логика, нәсихәт) һәм нәфис фәннәрнең (тел-әдәбият, поэзия теориясе, эстетика) башлангыч курсы, математика (алгебра, геометрия, тригонометрия), физика, табигать тарихы (минераль, ботаника, зоология) коммерция теориясе, технология һәм рәсем кертелгән.

Гимназиядә сигез укытучы һәм рәсем укытучысы (йөкләмәсе атнага 16 дан 20 сәгатькә кадәр булган рәсем укытучысы булдыру тәкъдим ителгән). Һәрбер укытучы фәннәр циклы: фәлсәфә һәм нәфис фәннәр, физик-математик дисциплиналар, экономия фәннәре алып барган. Привилегияле халыкка исәпләнгән, урта мәктәп педагоглары өчен гади халыкка исәпләнгән өяз училищелары педагогларына караганда бу инде уңай укыту шартлары тудырган.

Гимназиянең уку планында алла законы предметы булмаган. Болай булу 1804 ел уставы да алдынгы урыс кешеләренең йогынтысы нәтиҗәсеннән тора. Шулай да гимназияләрдә урыс телен укыту күздә тотылмаган. Моның сәбәбен бюрократиягә хас булганга урыс халкына кимсетеп караудан аңлатып була.

1786 елның халык өчен училищелар уставында кебек, фәннәрне укытуны тормыш белән бәйләнештә тотарга тәкъдим ителгән. Мәсәлән, математика һәм физика укытучысы укучыларны өйрәткәндә тегермәннәрне һәм җирле предприятиеләрдәге машиналарны күрсәтергә тиеш булганнар. Табигать тарихы укытучысы укучылар белән минераллар, үләннәр, туфрак үрнәкләре җыйган, аларның үзлекләрен һәм аерым билгеләрен аңлаткан.

Гимназиядә күрсәтмәле рәвештә укыту өчен китапханә, географик карталар һәм атласлар, глобуслар булдыру, табигать дөньясының үз әйберләрен җыю, сызымнар һәм машина модельләре, геометрия һәм геодезия приборлары, физика дәресләре өчен күренешле кулланмалар ясау тәкъдим ителгән.

Халык массаларына хезмәт итүче өяз училищелары, бигрәк тә мәхәллә училищелары белән чагыштырганда гимназияләр яхшырак материаль шартларга куелган булганнар. Дәүләт гимназияләрне тулысынча үз карамагында тоткан. Гимназия бетерүче дворяннардан чыккан яшүсмерләрнең төрле дәүләт хезмәт урыннарын алуга

зур мөмкинлекләре булган. Тапшырылган кешеләр (податные люди) гимназия бетергәч, сенат карары буенча гына, башлангыч һәм урта мәктәпләренең укытучылар булып раслана алганнар.

Университетлар халык мәгарифенең югары баскычын тәшкил иткәннәр. Аларга гимназия курслары буенча белемгә ия булганнар гына керә алганнар. Устав төзүдә катнашкан галимнәргә ташлама ясап патша хөкүмәте университетларга берникадәр автономия биргән. Университетларны сайланма советлар идарә иткәннәр, профессорлар, шулай ук, ректор һәм деканнарны сайлаганнар. Аларга фәнни җәмгыятьләр төзергә, типография тотарга, газеталар, журналлар, уку һәм фәнни әдәбият бастырырга рөхсәт ителгән. Профессорларга студентларга карата йогынтыларын гуманлы рәвештә башкарырга тәкъдим ителгән. Студентлар төрле җәмгыятьләр, түгәрәкләр, иптәшләр сходкаларын оештырырга хаклы булганнар.

Ләкин университетларның төп бурычы хөкүмәт хезмәтенә, шул исәптән, мәгариф өлкәсенә чиновникларның бөтен төрләрен әзерләү булган. Мәктәпләрдә укырга бөтен катламнарга мөмкинлек булса да, крепостной катламнан мәктәпкә керә алу-алмау турында аерым әйтелмәсә дә, чынлыкта исә халык мәгарифендә катлау системасы булдырылган. Шул ук вакытта бу системага буржуазия мәктәпләр үзенчәлеге дә хас булган: мәктәп программаларының күчүчәнлеге, барлык баскычта белем алуның түләүсезлеге, ирекле катлам балаларының мәктәпкә керүенең формаль мөмкинлеге. Ләкин катлам крепостной строй терәгеен хөкүмәт яңа төзелгән системадан боздырмаска тырышкан. Мәсәлән, устав бастырылудан соң бераз вакыт үткәч министр гимназиягә крепостной крестьян балаларын алырга рөхсәт юк дип аңлаткан.

Уку йортларында XVIII гасырның 80 нче елларында халык өчен училищелар комиссиясе төзегән "уку ысулы" кертелгән. Барлык укытучылар "Халык училищелары укытучыларына кулланма" китабы тәкъдим иткән укыту оештыруны һәм методларны үтәргә тиеш булганнар. Официаль дидактика кагыйдәләреннән тайпылу элеккечә берничек тә рөхсәт ителмәгән. 1804 елның уставында 1786 елның уставындагы кебек укытучылар чиновниклар дип саналган. Патша хөкүмәте аларның педагогик иҗат хокукын танымаган.

Катлам — крепостной строе булу сәбәпле, тудырылган кыенлыкларга карамастан, илдә мәктәп эше тайпылусыз үсә барган.

Моңа капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсеше, халык, бигрәк тә шәһәр халкы саны үсүе, белемгә ихтыяҗлык, алдынгы галимнәрнең һәм укытучыларның эшчәнлеге сәбәп булганнар. 1812 ел Ватан сугышы алдыннан Россиядә 47 губерния шәһәре һәм һәрберсендә диярлек гимназияләр, өяз һәм мәхәллә училищелары булган. Өяз шәһәрләрендә өяз, мәхәллә һәм кече училищелар булган.

Петербургта һәм Мәскәүдә башка шәһәрләргә караганда мәктәпләр үсеше тизрәк барган. Ләкин башкаларда да мәктәпләр әз булган: Мәскәүдә 20, Петербургта барлыгы 17. Гимназияләр белән чагыштырганда (Мәскәүдә һәм Петербургта берәр гимназия) алар укучылар белән тулган булган. Халык санына җитәрлек мәктәпләр челтәре булдыру өчен хөкүмәт акча бүлмәгән. Авылларны алганда, аларда бөтенләй диярлек мәктәп булмаган, чөнки моңа крепостной хокук комачаулаган.

Халык мәгарифе министрлыгы XIX гасыр башында гимназияләр өчен һәм өяз училищеларының кайбер фәннәре буенча дәреслекләр булдыру өстендә эш үткәргәннәр. Бу эшкә иң беренче урыс университетларында укытучы чит ил профессорлары тартылган. Урыс галимнәре төзегән уку ярдәмлекләрен министрлык еш кына мәктәпләргә үткәрмәгән. Шулай да университетлар, бигрәк тә Мәскәүдә шактый уку әдәбиятын чыгарганнар. Ил күләме зур булганлыктан, ә тимер юллар булмаганлыктан, министрлык тарафыннан чыгарылган китаплар провинциягә барып җитмәгәннәр һәм мәктәпләрдә укыту официаль карар белән исәпләшмичә, университетларда чыккан китаплар буенча алып барылган.

1812 елның Ватан сугышы башында хөкүмәт 1804 елдагы уставның либераль положениеләреннән читләшә барган һәм халык мәгариф системасын халыкта самодержавие-крепостной идеологияне тарату өчен кулланырлык чаралар күргән. 1811 елдан башлап барлык уку йортларында алла **законы фәнен** керткәннәр.

1812 елдагы Ватан сугышыннан соң ирек сөючән теләкләр көчәя башлагач декабристларның яшерен оешмалары барлыкка килгән, алдынгы фикерләр мәктәпләргә үтеп керә башлаганнар. Уку йортларында тыелган әдәбият таратканнар: Пушкин, Грибоедов һәм шагыйрь-декабрист Рылеев, Одоевский һәм башкаларның шигырьләрен. Анда югары граждан патриотик хисләр, үзеңне илгә хезмәт итүгә багышлау теләге, тираннар белән көрәш турында җырланган. Кайбер мәктәпләрдә алдынгы укытучылар крепостной хокукның

гаделсезлеге һәм Россия чынбарлыгының караңгы яклары турында укучыларга сөйләгәннәр.

Хөкүмәткә каршы хисләр таратуда туган ил тарихын укыту зур роль уйнаган. 1812 елдагы Халык сугышының героик эпизодларыннан калган якты истәлекләр халыкның рус дәүләте тарихындагы роле турында сорауны башкача куярга мәҗбүр иткән. Кайбер уку йортларында антик халыкның тарихын һәм әдәбиятын кинаяле аңлатканнар, җөмһүрият һәм крепостнойлыкка каршы фикерләр таратканнар. Грекларның һәм римлыларның ирек сөюенә басым ясалган, "Рим ирек белән үскән һәм коллык белән үлгән" дип чагыштыру үткәргәннәр.

Ил буенча җәмгыятьнең канәгатьсезләнүенә һәм крестьяннар, казаклар, солдатлар һәм крепостной эшчеләр арасындагы чуалышка каршы патша хөкүмәте аракчеевчылар режимы белән җавап кайтарган.

Патша указы артында крепостной крестьян балалары гимназияләргә, институтларга, университетларга алынырга тиеш түгел дип игълан ителгән булган. Гади кешеләргә мәктәптә укуны авырлаштыру өчен 1819 елда мәхәллә, өяз училищеларда һәм гимназияләрдә укуны түләүле иткәннәр.

Мәктәпләрдә дини тәрбияне көчәйтү максатыннан, Халык мәгарифе министрлыгын 1817 елда Руханилар эше һәм Халык мәгарифе министрлыгы итеп үзгәрткәннәр (1824 елда ул яңадан үзгәртеп төзелгән). Бердәм министрлыкның җитәкчесе итеп А. Н. Голицын куелган. Ул берьюлы Россиядә библия җәмгыяте президенты булган. Министрлык максат итеп халыкны тәрбияләүне "Изге берләшмә" акты буенча диндар рәвештә башкаруны куйган. "Изге берләшмә" 1815 елда революцияләрне һәм халыкның хөр фикерлелеген бастыру өчен зур Европа илләрен оештырган.

Яңа министрлыкның чаралары иң беренче дини тәрбияне көчәйтүгә юнәлдерелгән булган. 1819 елда барлык мәктәпләрнең уку планнары үзгәргән, "изге язмадан уку" кертелгән, табигать фәнен укыту тыелган булган.

Укучыларда "ирек сөю хисләре үстерә торган фәннәр", мәсәлән, философия, политик экономия, табигать хокукы, эстетика гимназия курсларыннан алып ташланган.

Реакция, бигрәк тә, университетларга хирыс ташланган. 1819 елда Сембер губернаторы һәм җирле библия җәмгыяте президенты Магницкий урыс һәм Көнбатыш Европа университетларының фән-

ни һәм укыту эшчәнлегенә карата погромга чакыра торган тәнкыйть белән чыккан. "Алласыз университет профессорлары законлы хакимиятләргә ышандырмау һәм нәфрәтләндерү өчен мескен яшьләргә яшертен агу бирәләр, ә китап бастыру эше аны бөтен Европа буйлап тарата",— дип язган ул. Магницкий хөкүмәтне ахыр чиктә зыянлы юнәлешне бетерергә, ә Казан университетын халык алдында җимереп ташларга чакырган.

Казан уку округының караучысы итеп билгеләнгән Магницкий мәктәпләрне идарә итүдә аракчеевлар методын кулланып директорга һәм Казан университет ректорына кулланма төзегән. Чынбарлыкта ул 1804 елда расланган университетлар уставын юкка чыгарган. Кешенең төп гаделлеге хакимияткә буйсыну, ә тәрбияләү чарасы булып иң беренче дин торырга тиеш дип басым ясалган кулланмада.

Казан университетында укытуны үзгәртеп корырга әйтелгән. Философияне апостол послание рухында, ә сәяси фәннәрне Иске тәурат (Ветхий завет) һәм өлешчә Платон һәм Аристотель тәгълиматлары нигезендә укытырга тәкъдим ителгән. Математиканы өйрәнгәндә студентлар игътибарын өч цифрасының изге икәненә юнәлдерергә, ә табигать тарихы шөгыльләрендә барлык кешелек дөньясының Адәм белән Һавадан килеп чыкканын кат-кат әйтергә тәкъдим ителгән. Магницкий укыту эшеннән яхшы профессорларны һәм прогрессив фикердәге укытучыларны алган.

Казан университеты язмышына педагогик институт нигезендә 1819 елда оештырылган Петербург университеты да дучар булган. Философия һәм сәяси фәннәр курсын алып баручы профессорлар крепостной хокукның һәм монарх рәвешендә идарә итүнең гаделсезлеге турында ачыктан-ачык лекцияләрендә сөйләгәннәр.

Петербург университетын җәзага тарту өчен хөкүмәт тарафыннан куелган карагруһчы Рунич алдынгы профессорларны вазифаларыннан чыгарган, кайбер студентларны куган, Магницкий төзегән кулланманы университетта кулланган, уку округы территориясендә аракчеевлар тәртибен керткән. Университет каршында эшләгән укытучылар институтын япкан. Анда укый-язарга, арифметикага, тарихка, географиягә башлангыч өйрәтүләрнең иҗади методлары төзелгән булган.

* * *

Уналтынчы лекция

ТАТАР ХАЛЫК ПЕДАГОГИКАСЫНДА *ТӘРБИЯ*

Халык педагогикасы дип кешеләрнең табигый шартларда күзәтүләр нәтиҗәсендә туплаган тәҗрибәсен киң халык массаларын тәрбияләү һәм белем бирү өчен куллану ысулларын атыйлар.

Аның нигезендә белем һәм тәрбия бирүдә киң халык массаларының тәҗрибә, сәләт һәм осталыкларыннан уңышлы файдалану ята.

Халык педагогикасы, фәнни педагогикадан аермалы буларак, фәкать гади белемнәр суммасын куллана белү осталыгыннан гыйбарәт. Ә фәнни педагогика, халык педагогикасын теоретик яктан тагын да тулыландырып, яшь буынга тәрбия һәм белем бирүнең тулы бер системасын тәшкил итә. Халык педагогикасы белеме фәнни педагогикадан терминологияләр формасының үзенчәлекле булуы белән аерыла, шуңа да карамастан, халык педагогикасы тәрбия һәм укыту процессын билгеләүнең төп нигезе булып тора.

Халык педагогикасын өйрәнгәндә еш кына безгә башка фәннәргә, бигрәк тә фольклор һәм этнография кебек, тәрбия бирүдә мөһим фактик материал бирүче фәннәр һәм чыганакларга мөрәҗәгать итәргә туры килә.

Тәрбияви өлкәдә фольклор әсәрләре аеруча мөһим роль уйный. Шуңа күрә дә яшь буынны тәрбияләү процессында еш кына педагоглар халык авыз иҗатыннан уңышлы файдаланалар. Халык авыз иҗатында халыкның әхлакый идеаллары, хезмәт сөючәнлеге, өлкәннәргә ихтирам, әдәплелек, дуслык, туган илгә булган чиксез мәхәббәте, дөреслек, сафлык кебек сыйфатлары чагылыш таба. Моннан тыш халык педагогикасында белем һәм тәрбия бирү өлкәсендә һәр халыкның аерым, үзләренә генә хас принциплары, өйрәтүнең үзенчәлекләре чагыла. Алар шулай ук халык педагогикасында зур әһәмияткә ия булып торалар.

Халык педагогикасында аның поэзиясе дә киң урын алып тора. Аның гади һәм образлы әсәрләре балалар күңеленә тиз үтеп керә. Халык поэзиясе балалар күңелендә яхшылыкны, игелеклелекне,

гаделлекне аңлау, күзаллауга ярдәм итә. Балаларның фантазиясен үстерә, аны тагын да баета. Бу исә үз чиратында, аларда иҗатка омтылыш тудыра. Халык педагогикасын өйрәнгәндә, халык авыз иҗатының аерым бер жанрына гына өстенлек бирү мөмкин түгел. Аларның барысы да үзләренә хас педагогик кыйммәткә ия булып торалар. Халык авыз иҗатының барлык төр жанрларында да халык массаларының педагогик зирәклеге ачык чагыла.

Төрле халыкларның педагогика өлкәсендәге үсешен өйрәнгәндә һәм аларны үзара чагыштырып караганда, барлык халыкларның тәрбия өлкәсендә уртак идеаллары, омтылышлары күзгә нык ташлана. Татар халык педагогикасының демократик үсеше рус, чуваш, башкорт, мари һ. б. күрше республикалар халыклар педагогикаларының үсеш юлларына охшаш. Бу, бер яктан, әлеге халыклар белән тыгыз иҗади аралашып яшәүне аңлатса, икенчедән, төрле милләт халыкларының үткәндәге ерак тарихка барып тоташкан тирән дуслык тамырларыннан килә.

Халык педагогикасында яшь буынны тәрбияләүнең күп гасырлык тәҗрибәсе тупланган. Яшьләргә әхлак тәрбиясе бирү өлкәсендә халык гасырлар буе яшәп килгән үзара мөгамәләне чагылдырган нормаларга таянган.

Халык педагогикасында игътибарны җәлеп итәрлек, кызыксындырырлык уңай тәҗрибәләр һәм халыкларның гади әхлак нормалары хәзерге мәктәпләрдә дә яшь буынны тәрбияләү процессында мөһим роль уйный.

Тәрбия эшләрен уңышлы алып бару өчен җирле халыкларның яшьләрне тәрбияләүдә кулланыла торган традицияләренә таяну, аларның гореф-гадәтләренә игътибар бирү зур әһәмияткә ия. Шуның өстенә, балаларга җирле халыкка якын һәм аңлаешлы булган әхлак тәрбиясе бирү тәҗрибәсе ата-аналарның педагогик аңлылыгын үстерүгә дә уңай йогынты ясый.

Әхлак тәрбиясе бирүдә балаларның зурларны ихтирам итүләренә нык игътибар ителә. Яшьләрнең әхлакый принциплары формалашуда гаилә тәрбиясенең роле бик зур. Гүзәллек белән тупаслыкны, яхшы белән ялганны буташтырмау, үзара мөнәсәбәттә ихти-рамлылык, ялагайлык, ясалмалылык кебек сыйфатларны аера белү яшь кешене чолгап алган тирәлекнең йогынтысы тәэсирендә бара. Һәр кешедә, аеруча үсмер чакта, үзенә генә хас нечкәлек, эмоциональ сизгерлек, тәэсирләнүчәнлек була. Билгеле, шәхеснең бу сыйфатлары үсешендә, уңай яки кире якка үзгәрешендә аны тәр-

бияләгән гаилә йогынтысы зур урын алып тора. Татар халык педагогикасында яшьләрдә әхлак тәрбиясе принципларын формалаштыруга, баланы кечкенәдән өлкәннәрне ихтирам итәргә өйрәтүгә зур игътибар бирелгән. Мәсәлән, кендек әбисе, баланы беренче тапкыр суда коендырганда ук:

Картны күрсәң,
- Бабай,— диген,
Карчыкны күрсәң,
- Әби,— диген,
Яшьне күрсәң,
- Җиңги,— диген,
Тәмле-татлы телле бул!

дип такмаклый торган булган. Бу әйтем аннан соң баланың әтиәнисе тарафыннан күп тапкырлар кабатланган һәм ул сабыйның күңел түренә бик иртә кереп, сеңеп калган. Өлкәннәр яшьтән үк зурларны ихтирам итмәгән баланың үзенә дә начар буласын аларның күңелләренә сеңдереп торганнар. Моңа ышандыру өчен экиятләр, мәзәкләр кулланылган.

Балалар кечкенәдән гаделлеккә, игелеклелеккә омтылалар. Алар бу үрнәкләрне өлкәннәрдән күреп кабул итәләр. Әгәр дә өлкәннәр боларның киресен эшләсә, балаларның да шуны ук кабатлавы табигый күренеш. Кешегә нинди мөнәсәбәттә булсаң, үзеңә дә шундый мөнәсәбәттә булырлар. Халык педагогикасында да бу фикер нык үстерелгән.

Балага әхлак тәрбиясе бирү — тәрбиянең төп бурычы. Әхлак тәрбиясе бирүнең нигезендә баланы яхшылыкка өйрәтү, начар эшләрдән кисәтү, нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнлеген белерлек итеп, тәрбияләп үстерү ята. Ата-ананың вазифасы үз балаларының кече яшьтән әнә шул принципларны үзләштереп үсүенә, аларның көндәлек күнекмәләренә әйләнүенә ирешүдән гыйбарәт.

Татар халык педагогикасында элек-электән укуга зур игътибар бирелгән. Укыган, белемле кешеләрне олылар хөрмәт иткәннәр. Татар халкында китапка игътибар аеруча зур булган. Крестьян өйләрендә дә китапны тактадан шүрлек ясап, кадерләп шунда саклый торган булганнар. Халкыбыз аң-белемгә багышлап, күп санлы әйтемнәр, мәкальләр иҗат иткән. "Уку — инә белән кое казу", "Беләге юан берне егар, белеме булган меңне егар" мәкальләре әнә шундыйлар.

Күп тапкырлар тикшерү һәм өйрәнүләр нәтиҗәләре, халыкларның кешелекле, әдәпле, кунакчыл булу сыйфатлары аларның характерының асылын чагылдыра. Өлкәннәр элек-электән яшьләрне кунакны каршы алу йолаларына өйрәтә килгәннәр. Татарлар килгән кунакны беркайчан да кунак итмичә, сыйламыйча җибәрмәгәннәр. Гадәттә, килгән кунакны чәй белән сыйлаганнар. Моны татар халык әйтемнәрендә дә еш очратырга була. ("Ачык чырай, такта чәй", "Ачык чырай, якты йөз, ипи белән тоз").

Татар халкы, кунак килер алдыннан, үз хуҗалыгын тәртипкә китерә. Халык мәкалендә дә "Кунак аз утырыр, күп күрер",— диелә. Ихтирам йөзеннән татарлар кунакны капка төбенә чыгып каршы алалар.

Халыкта тагын мөһим мораль таләп булып, коллективны ихтирам итү санала. Кешеләр гасырлар буе авырлыкларны җиңеп чыгуда, табигать көчләренә каршы көрәштә, зур эшләрне башкарганда коллектив көченең өстенлеген күреп яшәгәннәр. Шуңа күрә татар халык педагогикасында өлкәннәр тарафыннан балаларда кече яшьтән үк гаиләдә, күршеләр, авылдашлар һәм хезмәтәшләр белән яхшы мөгамәләдә, дус-тату яшәү үрнәкләре тәрбияләүгә зур әһәмият бирелә. Бу уңайдан "Берлектә көч", "Күмәк күтәрсә, күлне күтәрә", "Ише күпнең көче күп" дигән татар халык мәкальләрен китерергә була.

Халык педагогикасы үз-үзеңне генә яратуга, эгоизмга, кискен каршы чыга. Коллективтан йөз чөергән, үзен башкалардан өстен куйган кеше халык һәм коллектив тарафыннан ихтирам казана алмый. Ялгыз, башка кешеләр белән аралашмыйча, аларның ярдәменнән башка яшәү, гомер итү ифрат авыр булыр иде. Бу хакта татар халкында "Бер карлыгач яз ясамас", "Тауны кәҗә сөзеп җимерә алмый" дигән зирәк мәкальләр юкка гына иҗат ителмәгән.

Башка халыклар педагогикасында киң чагылыш тапкан кебек, татар халык педагогикасында да яшь буынга патриотик тәрбия бирү әхлак тәрбиясе өлкәсендә мөһим чара булып тора.

Туган ил — халыкның бишеге ул. Аның белән кешенең бөтен тормышы, гомере бәйле. Шуңа күрә дә Туган ил — халык өчен бар нәрсәдән дә кадерле, газиз. Моның шулай икәнлеге гасырлар буе телдән телгә, буыннан буынга күчеп килгән халык авыз иҗатында да тирән чагылыш таба. Мәсәлән, "Илем — минем этием дә, әнием дә", "Үз илем — алтын бишек", "Илнең төтене дә тәмле", "Үз илеңнең эте дә якын" һ. б. Туган илне еш кына эти, әни, бишек кебек

йөрәккә, күңелгә иң якын булган кешеләр һәм әйберләр белән чагыштыралар.

Әхлак тәрбиясе бирүдә халык авыз иҗатыннан әйтем һәм мәкальләр аеруча әһәмиятле роль уйный. Алар һәр халыкның гасырлар буе тупланган кыскача әхлак кагыйдәләре булып торалар. Халык авыз иҗатының бу төр жанрларында халыкның яшь буынга, гомумән, хезмәт ияләре массаларына әхлакый тәрбия бирү принциплары тирән чагылыш таба.

Мәкаль һәм әйтемнәр татар халык педагогикасында һәрвакытта да тәрбия өлкәсендә инандыру, ышандыру, гыйбрәт алу ролендә кулланылып килде. Алар халыкның бөеклеген, акыл иясе булуын, зирәклеген күрсәтәләр. Мәсәлән, кешелеклелек, әдәплелек сыйфатларын тәрбияләүгә караган мәкальләрне генә алып карыйк. "Кешене хөрмәтләү — үзеңне бәяләү", "Олыласаң олыны — олыларлар үзеңне", "Өеңә килгәнгә өйдән үпкә әйтмә", "Бәлешнең төбе, өйнең түре — кунакка", "Сабыр төбе — сары алтын" һ. б.

Тыйнаклык, нәзакәтлелек турында да халыкның зирәк мәкальләре һәм әйтемнәре шактый. "Үзеңне үзең мактама, сине кеше мактасын", "Кешедән көлмәк, үзеңә килмәк" һ. б.

Тәрбиянең иң гади чагылышы — баланың тыңлаулы булуы. Халык элек-электән балаларда әнә шул сыйфатны тәрбияләүгә зур әһәмият биргән. Чөнки тыңлаулы баланы эшкә өйрәтү җиңел, андый балада башка әхлак нормалары да тизрәк формалаша.

Балаларда тыңлаучанлык сыйфатларын ничек булдырырга соң?

Педагогик өйрәнүләр тәҗрибәсе күрсәтүеннән чыгып караганда, баладан ул үти алырлык нәрсәне генә таләп итәргә кирәк. Бу — тыңлаучанлык тәрбияләүнең иң беренче шарты. Икенчесе — бала үзеннән безнең нәрсә таләп итүебезне яхшы аңларга тиеш. Өлкәннәр кушканны үти алса, бала үзе дә куана. Киләчәктә дә шулай булырга тиешлегенә төшенә, аңарда кушканны үтәү теләге тәрбияләнә.

Димәк, тыңлаучанлык белән бергә балада ихтыяр көче дә тәрбияләнә. Ә балада ихтыяр көче ныгысын өчен, өлкәннәр үзләре үрнәк күрсәтергә тиешләр. "Оясында ни күрсә, очканда шуны эшләр" дип, халык гаиләнең ролен юкка гына күтәрми.

Балага белем һәм тәрбия бирү иң кыен, иң четерекле эш. Ул гасырлар буе килгән һәм киләчәктә дә чишелергә тиешле мәңгелек мәсьәлә. Бер генә ата-ана да аннан читтә кала алмый. Шуңа күрә балага дөрес тәрбия бирү ата-ана авторитетына нык бәйләнгән.

Ата-ананың авторитеты аларның гражданлык вазифаларын ничек үтәвендә һәм шәхси тормышында, җәмгыятькә мөнәсәбәтендә, үз-үзләрен тотуда ачык чагыла. Чыннан да, әгәр бала алдында ата-ананың авторитеты булса, ул аларның кушканнарын, киңәшләрен сүзсез үти, ата-анага охшарга тырыша. Халык мәкальләрендә юкка гына: "Атасы болан атмаган, улы колан атмас", "Ана сөте белән кермәгәнне тана сөте белән кермәс" дип әйтмиләр.

Сүз дә юк, гаиләдә бала тәрбияләү зур түземлелек, җаваплылык, кайгыртучанлык сорый.

Әти-әниләр генә түгел, өлкәнрәк апалары һәм абыйлары да нәниләрне тәрбияләүдә үзләреннән өлеш кертәләр. "Аганы күреп эне үсәр, апаны күреп сеңел үсәр" дигән мәкаль чынбарлыкны дөрес күрсәтә.

Татар халык педагогикасында өлкән абыйлары турында аеруча горурланып әйтелә. Бу — борынгыдан килгән гадәт. Өлкән туган һәрвакыт үзенең кече туганнарына ярдәм итә, кирәк вакытта саклый да, ягъни башкалардан кыерсыттырмый. Өлкән балалар кечкенәләрне карый беләләр. Бу гадәт аларга шулай кечкенәдән күчә килгән, чөнки әти-әниләре башка хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгәндә, кечкенәләрне өлкән балаларына карарга кушканнар. Бу вазифаларны олырак яшьтәге балалар бер дә авырсынмыйча, шулай булырга тиеш дип башкарганнар. Алар кечкенәләрне карый, еласа — юата, ачыкса — ашата һәм тирбәтеп йоклата белгәннәр. Бу эшләрне алар җиренә җиткереп, үзенә бер осталык белән башкаралар. Өлкән балалар кечкенәләрне үзләренә җәлеп итә беләләр, аларга төрле кызыклы һәм маҗаралы, мавыктыргыч әкиятләр сөйлиләр. Әниләреннән ишеткән бишек җырын җырлап, кечкенә энеләрен яки сеңелләрен тирбәтеп йоклаталар.

Кагыйдә буларак, кечкенә балалар үзләреннән өлкәнрәк апалары яки абыйлары киңәшләренә карусыз буйсыналар, аларны карышмыйча, сүзсез тыңлыйлар.

Шулай итеп, күп гасырлар буе тупланган тормыш тәҗрибәсе нәтиҗәсендә татар халык педагогикасында яшьләргә карата мораль нормалар һәм таләпләр барлыкка килә. Шулай ук аларга әхлак тәрбиясе бирүдә үзенчәлекле методлар һәм алымнар формалаша.

Халык педагогикасында гасырлар буе балалар тәрбияләү һәм аларга белем бирү эшенә бик нык әһәмият бирелеп килгән һәм ул буыннан-буынга шулай дәвам итә.

Халык педагогикасы яшь буынга белем алу, производство, фән һәм сәнгать өлкәсендә иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнү, әхлакый камилләшү өчен җирлек тудыручы чараларның башлангыч нигезен тәшкил итә.

Элек мәктәпләрдә системалы белем алудан мәхрүм ителгән киң хезмәт ияләре массалары балаларының рухи үсеше халык тәҗрибәсе нәтиҗәсендә генә тормышка ашырылды.

Халык элек-электән кешелек тормышында белемнең зур роль тотканын тирәнтен аңлаган. Белем яхшы тормыш өчен көрәшне җиңеләйтүче зур көчкә ия. Моның шулай икәнлеге татар халык авыз иҗатында да киң чагылыш тапкан. Мәсәлән, "Беләге юан берне егар, белеме булган меңне егар", "Белемле үлмәс, белемсез көн күрмәс" һ. б.

Халык гыйлем һәм мәдәният өлкәсендә укуның, белем алуның әһәмиятен тирәнтен төшенә: "Укыган ил төзер, укымаган ил бозар", "Гыйлемлелек — нур, наданлык — хур" һ. б.

Халык фәнне, гыйлемне барлык байлыклардан да югары бәяли. Мәсәлән, бер экиятнең герое этисе биргән бөтен акчасын уку, белем алу өчен тотып бетерә. Ә этисе акчаны сәүдә эшләре башлап җибәрү өчен биргән була. Герой үз чоры өчен зур белем ала, укырга, язарга өйрәнә, шахмат һәм скрипкада яхшы уйнауга ирешә. Уку аңа тора-бара халыкның тирән ихтирамын яулауга, танылган кеше булырга, дәрәҗәле исем алырга ярдәм иткән.

Фәкать укуга, аң-белемгә омтылган кеше генә тормышта дөрес юлны таба. "Алтынга омтылган — югалган, акылга омтылган — юл алган", "Алтынга ия булган — хур булган, акылга ия булган — зур булган" һ. б.

Байлык артыннан куган кеше исә зур гыйлемгә ия була алмый: "Алтынга исе киткән, акылыннан читкә киткән", "Белем малдан кадерле" һ. б.

Халык бик күптәннән барлык балаларның да мәктәп-мәдрәсәләрдә укып белем алулары хакында хыялланган. Халыкның балаларга гомуми белем бирү хыялы "Саран һәм юмарт" экиятендә ачык чагыла. Юмарт шәһәрдә иң атаклы, күренекле кешегә әйләнеп, барлык балаларны да укыта, аларга белем бирә. Мәктәпләр, остаханәләр ача, аларда балалар белән оста мастерлар, акыллы, зирәк кешеләр шөгыльләнә.

Татар халкы кешенең акылын һәм зирәклеген югары бәяли. Татар халык экиятләрендә иҗтимагый-сәяси әһәмиятле булган

мәсьәләләрне хәл иткәндә дәүләт идарәчеләренең халыкка мөрәҗәгать итүе очраклы гына түгел. Сүз дә юк, дәүләт эшләрендә катнашу теләге халыкның хыялында гына була. Чынлыкта исә, дәүләт башлыклары халык фикере белән һич тә исәпләшеп тормаганнар. Шуңа да карамастан, халыкның коллектив аңын, фикерен хезмәт ияләренең тәҗрибәсен, белемен куллану үз вакытында акрынлап үсә, көчәя барган. Кайбер әкиятләрдә патшалар һәм ханнар, акыллы, зирәк көрәштәшләре хакына үзләренең тәхетләреннән баш тартканнар. Бу, бер яктан, халыкның гадел дәүләт башлыклары турындагы хыялын чагылдырса, икенче яктан, барысын да булдыра, эшли ала торган зирәк акылның җиңеп чыгуына ышануын күрсәтә.

Барлык татар халык әкиятләрендә һәрвакытта да җиңеп чыгучы уңай геройларның тапкырлык, зирәклек, акыллылык, уйлап табучанлык сыйфатлары мактала. "Диюләрне җиңгән", "Дутан батыр", "Әйгали батыр", "Корчаңгы тай", "Камыр батыр", "Гөлнәзек" һ. б. әкиятләрдәге геройлар һәрвакытта да үзләренең иң көчле дошманнарын акыл һәм тапкырлык белән җиңеп чыгалар.

Халык әдәпсезлек һәм наданлыкны өнәмәгән, аннан ачы көлгән. Түбәндәге мәкальләр бу фикерне тагын да ачыграк чагылдыра:"Сукыр тавыкка бар да бодай", "Надан белән бәхәсләшү — үзе наданлык билгесе", "Надан белән сукыр, икесе бер", "Наданга тик тору җавап", "Наданның белгәне — белмим" һ. б. Андый кешенең башка кешеләргә ярдәм итүе үтә чикләнгән, ягъни ул башкаларга бер файда да китерми, китерә дә алмый. Шуңа күрә дә халык: "Арпа-көрпә аш булмый, надан кеше баш булмый", "Надан кешенең өйрәнәсе килмәс, өйрәтәсе килер", "Надан сукырдан яман", ди.

Халык педагогикасы мирасының әһәмияте кыйммәте ир-балалардан да, кыз балалардан да бер үк төрле акыл тәрбиясе таләп ителүдә. Хатын-кызларны күздә тотып, халыкта: "Матурлык туйда кирәк, акыл көн дә кирәк",— диләр. Кайбер татар халык әкиятләрендә кызларның акыл һәм зирәклек, тапкырлык ягыннан батырларга бирешмәве һәм хәтта кайчагында бу яклары белән алардан өстен чыгулары турында әйтелә. "Акыллы кыз" әкиятенең герое Мәгъфүрә падишаһның малае Абдулладан акыллырак булып чыга. Шуңа күрә патша малаен акыллы, тапкыр, зирәк Мәгъфүрәгә өйләндерә. Моның белән генә чикләнмичә, үзенең патшалыгы белән идарә итүне дә аңгыра малаена түгел, ә зирәк Мәгъфүрәгә калдыра. Татар халык әкиятләрендә шундый сюжет киң таралган:

зирәк кыз үзенең булачак киявенең акылын, тапкырлыгын, зирәклеген тикшереп, сынап карый. Бу сынауны уңышлы үткән егетләр зирәк кызның күңелен генә яулап калмаганнар, шул ук вакытта үз халкының тирән ихтирамын да яулаганнар.

Җитәштерүчән хезмәт нәтиҗәсендә кешедә файдалы фәнни белем һәм хезмәт тәҗрибәсе туплана. Ул яшь буынга күчә бара һәм мәктәпләрдә дәвам иттерелә, тагын да камилләштерелә һәм үстерелә. Бу өлкәдә халык педагогикасының да роле зур. Халык үзенең табигать һәм җәмгыять турындагы белемнәрен фән һәм әдәбиятка нигез салуга чыганак булган халык авыз иҗатында киң чагылдырган.

Халык өйрәтүенең эчтәлеген табигать, туган җир һәм аның байлыклары, хайваннар дөньясы турындагы белемнәрнең бергә тупланып бирелүе тәшкил итә. Анда халыкның астрономия, тарих, медицина һ. б. өлкәләрдә күзәтүләре, табигатьне танып белү сәләтләре, шул өлкәдәге белем һәм тәҗрибәләре чагыла.

Татар халык мәкаль һәм әйтемнәрендә авыл хуҗалыгы эшләре буенча тирән, мәгънәле файдалы киңәшләр, зирәк фикерләр әйтелгән. Мәсәлән, "Игенеңне яшел урма, урагыңның теше сынар", "Көзге ашлыкны көлгә чәч — язгы ашлыкны бозга чәч", "Ни чәчсәң, шуны урырсың", "Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың" һ. б. Күп кенә татар халык әкиятләрендә дә халыкның игенчелек өлкәсендәге гасырлар дәвамында тупланган белем һәм тәҗрибәләре турында сөйләнә.

Яшүсмерләр крестьян хуҗалыгында өлкәннәрдән зоотехника һәм ветеринария белемнәре дә үзләштергәннәр. Алар теге яки бу хайванның күпме файда биргәнен, нинди үрчем алу мөмкинлеген яхшы чамалаганнар. Хайваннар авырып киткәндә, аларны җиренә җиткереп, өлкәннәр тәҗрибәсеннән чыгып дәвалаганнар. Күп кенә авторлар үзләренең әсәрләрендә һәм хезмәтләрендә татарларда күп кенә ат докторлары булуы хакында бәян итәләр. Аларның хезмәтеннән хәтта татарлар белән күрше яшәгән башка милләт халыкларының да бик теләп файдаланулары билгеле. Кызганычка каршы, татар халкының халык ветеринариясе өлкәсендәге тәҗрибәсе, казанышлары өйрәнелмәгән. Шулай да, халыкның зоотехник белеменнән чыгып, атның тешләренә, сыерның мөгезендәге билгеләренә карап, аларның яшьләрен билгеләү тәҗрибәсе киң таралган. Тавык оясында маяга һәрвакыт бер йомырка калдырырга кирәклеге дә халыкка мәгълүм. Ул тавыкның йомырканы төрле урынга салмыйча, гел бер ояга гына салуын тәэмин итә.

Халык педагогикасында кешеләрнең хайваннар, җәнлекләр, кошлар, балыклар һәм бөҗәкләрнең характерларын, аларның файдалы һәм зарарлары якларын күзәтүләре, йорт хайваннарын дәвалавы, аларны тәрбияләве, бөҗәкләргә, кимерүчеләргә һәм ерткыч җәнлекләргә каршы көрәше зур урын алып тора. Халыкның һава торышы турында озак еллар буена күзәтүләрдән чыгып тупланган, ышандырырлык сынамышлары да бар.

Мәсәлән, аяз һаваны белдерүче билгеләр: "Кояш батканда болыт кызара", "Көндез җил, кич тын була", "Төтен туры булып югары күтәрелә", "Ай көмеш төсендә, бик якты була", "Чыпчыклар оя ясый".

Яңгырлы һаваны белдергән билгеләр: "Кояш чыкканда болыт кызара", "Ай тирәсендә зур түгәрәк хасил була", "Төтен түбән төшә", "Кошлар түбәннән оча", "Чебиләр бер урынга җыела".

Ел фасыллары буенча күзәтелгән билгеләр: "Кыш карсыз булса, җәй ярлы була", "Кышкы көннәр җәйне әйтер, җәйге көннәр җайны әйтер".

Халык тәҗрибәсе нәтиҗәсендә, балаларда саннар белән эш итүнең эзлекле күнекмәләре барлыкка килә. Халык тудырган математик мәсьәләләрнең күпчелеге балаларда аналогик фикер йөртүне сорый, зирәклекне, тапкырлыкны үстерүгә юнәлдерелгән.

Татар халык педагогикасында математик белем һәм хисаплау алымнарын, ысулларын балаларның аңына математик табышмаклар аша җиткерү, сеңдерү киң таралган. Сыер, кәҗә, сарык, аларның аяклары, мөгезләре, колаклары турындагы табышмаклар математик хисаплауга, аңны үстерүгә юнәлдерелгәннәр. Мәсәлән, атка атланган җайдак турындагы табышмак: "Ике башлы, алты аяклы, егерме тырнаклы, дүрт тояклы".

Телдән хисаплау күнегүләре өчен генә хезмәт иткән табышмаклар да бар. Микъдар санын күзаллауны һәм ел, ай, атна, көн турындагы белемнәрне үзләштерү шулай ук математик табышмаклар аша башкарыла: "Унике йолдыз, бер ай", "Бер өянкедә унике ботак", "Һәр яфракның бер ягы кара, бер ягы ак" һ. б.

Яшь буынга тапшырылып килгән, кеше һәм кешелек җәмгыяте турындагы белемнәр тулы бер комплекска ия. Ул үз эченә туган тел, тарих, халык фәлсәфәсе, эстетика, педагогика һәм психология турында төрле мәгълүматларны ала.

Сөйләм теленә ия булу балага тапшырылып килә торган белемнәрне үзләштерүдә төп нигез булып тора. Туган тел аша яшь буынга халыкның бай рухи мәдәнияте, аның дөньяны танып белүе,

идеаллары, халыкның озак еллар буе тупланган белеме һәм тормыш тәҗрибәсе тапшырыла. Туган тел балаларга укыту-тәрбия бирүдә, аларда әхлак нормаларының формалашуында мөһим чара булып тора.

Балаларның тел байлыкларын үстерүдә аларга әниләренең сөйләгән әкиятләре, бишек җырлары зур әһәмияткә ия. Аналар балалар белән әле аларның телләре ачылганчы ук сөйләшә башлыйлар. Моның әһәмияте шунда, балалар әниләренә охшарга тырышалар, сүзләрне һәм фразаларны отып калалар. Балаларның тел һәм акыл үсешедә балалар фольклоры да шулай ук зур роль уйный.

Татар халык педагогикасы тәҗрибәсендә балаларның сөйләм телендәге логопедик җитешсезлекләрне (сакаулыкны, тотлыгуны) бетерү өлкәсендә халык тәҗрибәсе нәтиҗәсендә тупланган белемнәрне куллану уңышлы нәтиҗәләр бирә. Бу кимчелекләрне бетерү максатыннан халык педагогикасында тизәйткечләрдән файдаланалар. Кече яшьтәге балалар бигрәк тә к, г, р, ж, авазларын авырдан әйтәләр. Тизәйткечләрдә күбесенчә менә шул авазлар катнаша да инде.

Логопедик максаттан чыгып, балалар белән күп авазлар катнашкан озын сүзләрне кызу-кызу әйтү күнегүләрен башкарырга кирәк. Балаларны хезмәт шартларында тәрбияләү күпкә нәтиҗәлерәк. Әлеге тизәйткечләрнең күпчелегенең хезмәт процессында тууын ассызыклап үтәргә кирәк.

Балаларның сөйләм телен үстерүдә шулай ук сәхнәләштерелгән күп кенә балалар уеннары да зур роль уйный. Үзләре башкарган драма уеннарында балалар, рольләр буенча, нинди дә булса персонаж буларак катнашалар. Мәсәлән, "Кабак", "Алырмын кош", "Аксак мәче", "Аксак төлке", "Тел алыш", "Почмак алыш" һ. б.

Балаларның рольләр буенча кара-каршы сөйләшүләре дидактик яктан да югары бәяләнә. Алар аерым бер конкрет персонажны, аңа охшатып уйнарга тырышалар. Күп кенә башлангыч белем бирү методистлары, педагоглары һәм хәзерге мәктәп тәҗрибәсе шулай ук бу методка зур игътибар бирә.

Сәхнәләштерелгән уеннарда персонаж исеменнән сөйләү хәтерләү сәләтен яхшыртуга, акылны камилләштерүгә, сөйләм телен үстерүдә, сәнгатьлелеккә ирешүдә мөһим чара булып тора һәм бу өлкәләрдәге күнекмәләрне ныгыта.

Халык авыз иҗаты — ул халыкның телдән тарихи елъязмасы. "Рус-француз сугышы бәете", "Япон сугышы бәете" һ. б. бәетләрдә

татар халкының туган иленә, халкына булган тирән патриотик хисләре турында әйтелә. Аларда аерым шәхесләргә, тарихи вакыйгаларга халык тарафыннан характеристика бирелә.

Халыкның күп буыннар тарафыннан гасырлар буе тупланып килгән тормыштагы зирәклеге, тапкырлыгы халык өйрәтүенең эчтәлеген баеталар, тулыландыралар. Педагогик әһәмияткә ия булган татар халык әкиятләрендә, мәкальләрендә, әйтемнәрендә, җырларында, табышмакларында, бәетләрендә һәм легендаларында халыкның дөньяга карашы чагылдырыла.

* * *

Кайбер дидактик принципларның әһәмиятен аңлауда халык педагогикасы зур уңышларга ирешкән.

Системалылык, эзлеклелек. Укыту-өйрәтүдә ашыгырга кирәкмәгәнен, укытуда һәркемнең аңына барып җитәрлек эзлеклелекне сакларга кирәклеген халык яхшы аңлаган. "Көчең җитмәгән ташка тотынма", "Барын да эшлим дигән берен дә эшли алмас", "Берьюлы күпкә кулың сузсаң, берсен дә тоталмассың", "Күпне кочаклаган аз учлар" һ. б. татар халык мәкальләрендә дә шул хакта сүз бара.

Күп кенә халык мәкальләре уку, белем алу өлкәсендә системалылыкның мөһим шарт булуы хакында искәртәләр. Мәсәлән, "Аз белмәгән, күп белмәс", "Әкрен барган ерак барыр, йөгергән артта калыр", "Тырышкан тамчы ташны тишкән" һ. б.

Күрсәтмәлелек. Белем үзләштерүдә күрсәтмәлелек һәм шәхси тәҗрибәнең әһәмияте бәя биреп бетергесез мөһим чараларның берсе. "Күпне күргән күп белер", "Ышанма кеше сүзенә, ышан үз күзеңә", "Бер тапкыр күрү ике тапкыр ишетүдән яхшырак" һ. б. Бу мәкальләр күрсәтмәлелек принцибының балаларны укыту процессында һәм, гомумән, дөньяны танып белү процессында зур әһәмияткә ия икәнлеген раслыйлар. Тирән белем үзләштерүдә кешедән аңлы эшчәнлек һәм активлык таләп ителә. Бу хакта балаларга: "Укыдым дип әйтмә, аңладым дип әйт",— диләр. Укучыларның мөстәкыйль фикерләренә тиешле нәтиҗә ясалырга тиеш: "Кеше акылын ишет, үз акылың белән эш ит". Халык педагогикасындагы кеше яшь вакытта гына түгел, ә үзенең бөтен гомере буе яңадан-яңа белемнәрне үзләштерергә, аларны үзенең тормыш тәҗрибәсендә куллана белергә тиеш дигән фикер зур кыйммәткә ия. "Мең ел яшә, мең ел өйрән", "Җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел",

"Бер савыт та күләменнән артыкны сыйдырмый, гыйлем савыты гына күпме салсаң да киңәя бара", "Гыйлем күп — гомер кыска" һ. б.

Кабатлау, күнегүләр. Тирән, ныклы белем үзләштерүгә кабатлау һәм күнегүләр нәтиҗәсендә ирешелә. "Чәйнәмәсәң йота алмассың", "Ун кат укы, бер кат яз". Бу өлкәдә балаларның хәтер культурасына аеруча зур игътибар бирелә. Күпчелек балалар уеннары шактый катлаулы кагыйдәләрне, җыр текстларын истә калдырырга, хәтерле ныгытырга, яхшыртырга ярдәм итәләр. Кече яшьтәге балала аларны өлкәнрәкләрнең уеннарын күзәткәндә күңелләренә сеңдереп, хәтерләп калалар. Ишетү, истә калдыру һәм әкият сөйләү шулай ук хәтер ныклыгын үстерә, аны камилләштерә. Халык педагогикасында балаларның сөйләмен, хәтерен яхшырту өчен кулланыла торган һәм истә калдыру максатыннан иҗат ителгән шактый озын шигъри хикәяләр бар. Хәтердә калдыру культурасы уеннар вакытында үстерелә һәм камилләштерелә.

Акыл тәрбиясе өлкәсендә башка ысуллар һәм методлар да киң кулланыла. Танып белүгә корылган уеннар, күзәтүләр, кабатлау күнегүләре, балаларның укуга аңлы карашын үстерү ысуллары һ. б. уңышлы кулланыла.

Күзәтүчәнлекне үстерү. Баланың күзәтүчәнлек сәләте аларның көндәлек тормыш нәтиҗәсендә үсә. Әйтик, "нинди агач җилсез шаулый" (усак) кебек табышмаклар яшьләрдә күзәтү культурасын үстерүгә ярдәм итәләр. Күп кенә татар халык әкиятләренең ахыры шаяру, уйдырма характерында бетә. Алар шулай ук балаларны күзәтүчәнлеккә, игътибарлылыкка һәм мөмкин булган реаль вакыйгаларны уйдырмалардан аера белергә өйрәтә.

Татар халык педагогикасында зирәклекне чуалткычлар ярдәмендә ныгытулар да практикага кертелгән. Чуалткычлар балаларның сөйләм телен, аларның уйлау сәләтен үстереп, баетып кына калмыйлар, ә бәлки әсәрдә нәрсәнең реаль чынбарлык, нәрсәнең уйдырма икәнен аера белергә дә өйрәтәләр. Алар балаларның игътибарын тиз арада төрле күренешләргә юнәлдереп, киеренке шартларда тиз генә уйларга мәҗбүр итәләр. Чуалткычлар акыл, уйлау сәләтен, күзәтүчәнлекне үстерүдә аеруча зур әһәмияткә ия. Монда бер предметның билгеләре икенче әйберләргә күчә.

Чуалткычлар балаларны ана телендәге синонимнар һәм антонимнарның үзенчәлекләрен төшенергә, аларны урынлы куллана белергә өйрәтәләр, уйлау сәләтләрен үстерәләр (анализ ясау, чагыштыру, каршы кую һ. б.).

Ата-аналарның роле. Балаларга акыл тәрбиясе бирүдә ата-аналар һәм гаиләдәге башка өлкән кешеләр зур роль уйный. Күп кенә татар халык әкиятләре, тормыш иткән зирәк картлар вакыты җитеп, үзләре үлгәндә, үзләренең тормыш тәҗрибәләрен, белемнәрен балаларына васыять итеп әйтеп, тапшырып калулары белән башланып китә. Тылсымлы әкиятләрдә, гадәттә, атасы, мирас итеп үз улларына кылычын һәм нинди дә булса берәр тылсымлы әйберен биреп калдыра. Әтисеннән әлеге мирасны кабул итеп алган һәм аталарының зирәк киңәшләрен истә тоткан уллары тормышта һәм көрәштә зур уңышларга ирешкәннәр. Ә этиләренең һәм аксакалларның зирәк киңәшләрен тотмаган угыллар һәрвакыт тормышта һәм көрәштә уңышсызлыкка очраганнар, халык аларны үткен тәнкыйтьләгән.

Гомумән, әкиятләр үзләреннән-үзләре өлкәннәрнең күпьеллык тормыш тәҗрибәләрен яшь буынга тапшыру чарасы булып торалар. "Зирәк карт", "Мәгънәле кыз", "Уңган егет", "Тапкыр кыз”, "Карт белән ялкау егет" һ. б. әкиятләрдә яшьләргә белем бирү өлкәсендә зур әһәмияткә ия булган күп кенә файдалы киңәшләр әйтелә.

Әкиятнең төп герое, бернинди кара көч тә җиңә алмый торган уңай герое — халык үзе. Ул һәр әкияттә диярлек исемсез герой сыйфатында яки таз малай, хезмәтче, уңган кыз образларында катнашып, тормышның әшәке якларын, халыкка карата начарлык кылучы тискәре геройларны, явыз патшаларны һәм яшәргә комачаулык итүче һәртөрле кара көчләрне аяусыз рәвештә камчылый, күпчелек очракта исә бөтенләй юк итә.

Халык әкиятләрендә хезмәт ияләренең сөекле, уңай образлары барлык караңгы көчләргә каршы, дөреслек, гаделлекне өскә чыгару, кимсетелгәннәрне яклау, явызлыкны, җәберне җиңү өчен көрәшәләр. Татар халык әкиятләрендә Алдар таз, Шомбай, хезмәтчеләр һәм ярлы егетләр, хезмәт ияләренең тормыш тәҗрибәсенә, акыл байлыгына таянып, табигатьнең гади халыкка яшәргә уңайсызлаучы, комачаулаучы һәртөрле һәлакәтен, стихиясен, шулай ук кешеләрнең чын дошманнарын, башкалар хезмәте исәбенә яшәүче соры кортларны һәрвакыт җиңеп чыгалар. Бу көрәшләрдә халыкның батырлыгы, тапкырлыгы, зирәклеге, нинди генә кыенлыклар алдында да тез чүкмәслек булып чыгуы гәүдәләнә.

* * *

Унҗиденче лекция

МӘГЪРИФӘТЧЕ КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

Һәр халыкның тарихи үсешендә тирән эз калдырган данлыклы уллары, кешелек бәхете өчен көрәштә зур өлеш керткән галимнәре һәм әдипләре була. К. Насыйри — татар халкының әнә шундый олы хөрмәтенә лаек булган күренекле мәгърифәтче-галим.

XIX йөзнең 60 елларыннан башлап, ярты гасыр дәвамында тырыш һәм гаять нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән Каюм Насыйри татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле булды. Ул — бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган галим. Татар халкын аң-белем ягыннан күтәрү, аның культурасын үстерү буенча тарихи әһәмиятле хезмәтләр күрсәтте, мәдәниятебезнең демократик нигездә үсә башлавына һәм халыкчан әдәби телнең барлыкка килүенә этәргеч булды.

Россиядә алдынгы кешеләр, галимнәр җитәкчелегендә барлыкка килгән иҗтимагый-сәяси, гыйльми-педагогик тармаклардагы зур үсешләр барлык халыкларның, шул исәптән татарларның да иҗтимагый культура хәрәкәтенә уңай йогынты ясады. Каюм Насыйри шул уңай йогынтыга тартылган татар интеллигенциясе арасында күренекле галим һәм язучы иде.

Күренекле татар мәгърифәтчесе К. Насыйри үзенең иҗатында һәм эшчәнлегендә татар халкының тормыш-көнкүрешен, тарихын өйрәнергә омтылуга, мәктәп-мәдрәсәләрдә схоластик укытуга каршы көрәш ачуга, рус телен өйрәнүне пропагандалауга, укыту-өйрәтү юллары белән яшь буынны алдынгы мәдәният белән таныштыруга, балаларны дөньяви белемнәр белән коралландыруга нык әһәмият бирә. Ул татар балаларын русча укыту өчен көрәшә, төрле фәннәрдән дәреслекләр яза, рус һәм татар халкы арасындагы дуслыкны алга сөрә, кеше акылына, гыйлемгә дан җырлый.

Мәгърифәтчеләр җәмгыятьне үзгәртеп кору мәсьәләсендә татар халкының фәкыйрьлеге наданлыктан, культура түбәнлегеннән килә, аны экономик яктан алга җибәрү, мул тормышка чыгару өчен иң элек аны агартырга, аң-белем бирергә, тәрбияләргә кирәк дип

уйлыйлар. Шуның өчен дә аларның игътибары мәктәп-мәдрәсәләргә юнәлтелә, алда торган иң беренче әһәмиятле бурыч итеп, алар уку-укыту эшләрен саныйлар. Алар фикеренчә, мәгърифәт — җәмгыятьне үзгәртеп кору, халыкны мул, бәхетле тормышка чыгару юлы — кешене дөнья көтү өчен кирәкле мәгълүматлар белән коралландырып, һөнәр өйрәтеп, ялкаулыктан, бозыклыктан, түбәнлектән саклап, кешеләр арасында дуслык, үзара ярдәмләшү, ихтирам мөнәсәбәтләре урнаштырудан гыйбарәт.

Бу карашлардан К. Насыйри да читтә кала алмый. Чөнки ул рус демократик әдәбиятындагы һәм прогрессив фәнендәге уңай фикерләрне татарларга беренче җиткерүче була, төрле милләт халыклары арасындагы дуслыкны һәм туганлыкны пропагандалый. Ул мәдәниятебезнең һәр тармагына башлап сукмак сала, искелеккә каршы көрәш ача, төп игътибарын фән һәм гыйлем, культура һәм прогресс өлкәсенә юнәлдерә. К. Насыйри татарларның рус телен өйрәнүләре, рус культурасы һәм фәне белән якынаюлары, ана телен гыйльми өйрәнү, аны камилләштерү һәм демократлаштыру өлкәсендә игътибарга лаек зур эшләр башкара.

1885 елда К. Насыйрины Духовное училищега татар теле укытучысы итеп чакыралар. Аның беренче практик эше — укытучылык хезмәте шунда башлана. Соңрак шул ук училищеның дәвамы булган Духовная семинариядә татар теле дәресләре укыта. Семинария укытучылары белән аралашу аңа рус телен һәм башка фәннәрне киңрәк өйрәнергә ярдәм итә, соңыннан ул Казан университетына ирекле тыңлаучы булып керә.

К. Насыйри үзенең укытучылык эшенә бик җитди һәм таләпчән караган. Аның семинариядәге шәкертләре арасыннан П. П. Масловский кебек соңыннан татар теле белгече булып җитешкән галимнәр дә чыккан.

Каюм Насыйриның иң зур хезмәтләреннән берсе — аның тел өлкәсендәге эшчәнлеге. Бу өлкәдә ул бик катлаулы һәм күпьяклы хезмәтләр башкарды. К. Насыйри татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын, шуңа хакы һәм сәләте барлыгын исбат иткән. Аның башка телләрдән артта торуын фәкать эшләнмәгәнлектән генә күрә. Аны практик һәм фәнни яктан эшкәртү юлында гаять кыю һәм зур эшчәнлек күрсәтә. К. Насыйри тел гыйлеме һәм сүзлекләр төзү буенча шулкадәр катлаулы һәм кирәкле эшләр башкарды ки, бу өлкәдә ул кагылмаган, хезмәт күрсәтмәгән бер генә тармак та юк дию дә хата булмас.

Татар халкының олы мәгърифәтчесе һәм галиме булган Каюм Насыйриның тел гыйлемендәге эшчәнлеген зур диңгезгә коя торган зур һәм саф елгага тиңләргә мөмкин. Һәр елга агымын чишмәләрдән, вак елгалардан башлаган кебек, Каюм Насыйри да үзенә кадәр булган гыйлемнәрне тагын да үстереп, киңәйтеп, яңа тармаклар белән баетты.

Бөек мәгърифәтченең эшчәнлеген бүгенге татар тел гыйлеме үсешеннән аерым карау мөмкин түгел. Андагы тармакларның күбесе К. Насыйри хезмәтләреннән һәм ул күтәргән проблемалардан башлана. Хәзерге тел гыйлеме, К. Насыйри күрергә теләгәнчә, югары ноктага күтәрелде, киң үсеш алды һәм җентекле, фәнни тикшерелүен дәвам итә. К. Насыйриның мәгърифәтчелек идеяләре һәм лингвистик карашлары татар мәдәниятының һәм тел гыйлеменең үсешенә нәтиҗәле йогынты ясады.

К. Насыйриның тәрбия һәм педагогика өлкәсендәге фикерләре әсәрләренең төрле урыннарында бирелгәннәр. Ул күп еллар укытучы булып эшләгән практик кына түгел, бәлки шуннан алган бай тәҗрибәсеннән чыгып, теоретик хезмәтләр биргән педагог та. Мәгърифәтче галим тәрбия сүзенең эчтәлеген билгели: гаиләдәге тәрбия белән иҗтимагый тәрбиянең үз вакытында һәм күбрәк булырга тиешлегенә басым ясый.

Каюм Насыйри яшәгән һәм иҗат иткән елларда, музыка сәнгатенә игътибар ителмәү генә түгел, хәтта музыканы тыңларга ярыймы, юкмы дип кызу бәхәсләр бара иде. Насыйри бу өлкәдә дә читтә калмый. Ул бу турыда реакцион укымышлыларның карашын җимереп, музыка файдасына сөйли. Үз фикерләрен куәтләү өчен, әдәби хезмәтләрендә күп кенә дәлилләр китерә. Җырның, музыканың күңелгә шатлык, хәрәкәткә батырлык бирүен әйтә. "Фәвакиһел җөләса..."ның 30 нчы раузасы музыканың әһәмиятен аңлатуга багышланган: "Хәкимнәр әйтмешләрдер ки, гоннә (көй) рухның азыгыдыр. Фәһемне саф кылыр, зиһенне нечкәртер, табигатьне йомшартыр, мәрхәмәтлене мактатыр, җөбенне (куркакны) баһадирландырыр, саранны юмартландырыр, димешләрдер".

Тәрҗемә өчен әсәрләр сайлаганда да К. Насыйри яшьләрне этик һәм эстетик тәрбияләүгә ярдәм иткән әсәрләрне сайлап ала. Шундыйлардан "Кабуснамә" һәм башкаларны күрсәтергә була.

Каюм Насыйри мәдрәсәдә укыганда һәм Казан университетының ирекле тыңлаучысы булып йөргән вакытта бик тырышып рус телен өйрәнә.

Аның беренче басылып чыккан китабы — "Татар теленең кыскача грамматикасы" — рус телендә язылган, ул русча өйрәнүче татарларга һәм татар телен өйрәнүче башка милләт вәкилләренә ярдәм итүне күздә тотып төзелгән. Каюм Насыйри татар әдәби телен фәнни яктан нигезләү, инде алда әйтелгәнчә, аны башка әдәби телләр дәрәҗәсенә күтәрү өчен күп көч куя. Телнең сафлыгы, халыкчанлыгы өчен көрәшә. Ул татар теленең грамматикасын ("Әнмүзәҗ"), аңлатмалы сүзлеген ("Ләһҗәи татари"), матур һәм дөрес язу кагыйдәләрен ("Кавагыйде китабәт") төзи. Беренче русча-татарча, татарча-русча сүзлекләрне дә ул бирә, математика, география, табигать фәннәре буенча халыкка аңлаешлы терминнар өстендә эшли, татар балаларына рус телен өйрәтү өчен уку китапларын, рус теле грамматикасын яза.

Киң колачлы галим Насыйри татар халкын төрле фәннәрнең нигезләре белән үз ана телендә таныштыру өчен тырыша. Математика, география дәреслекләре, ботаникадан үсемлекләрнең исемнәре китабын яза. Аның табигать белеменә багышланган "Буш вакыт" исемле китабы татар телендә чыккан беренче фәннипопуляр әсәр булып санала. Ул унбиш ел буе өстәл календарьлары чыгарып тора. Бу календарьлар ярым журнал характерында булалар. Аларда табигать белеме һәм башка фәннәр буенча мәкаләләр урнаштырыла, күп кенә файдалы киңәшләр бирелә.

Каюм Насыйриның тарих, археология өлкәсендә дә күренекле хезмәтләре байтак. Ул халык авыз иҗатын, гадәт-йолаларын гомере буе өйрәнә, җыя. Бу турыда китаплар яза. ("Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары", "Татар этнографиясе материаллары"). Татар халкын үз ана телендә туган ил тарихы белән таныштыручы да — Каюм Насыйри ("Зөбдәтен мин тәварихи Русь"). Күп кырлы талант иясе, мәгърифәтче К. Насыйриның күп кенә хезмәтләрендә тарих язу өчен материаллар бирелә. Мифология һәм этнографиягә караган хезмәтләрендә ул тарихчылар тарафыннан кузгатылмаган, тикшерелмәгән материалларны табып, фән дөньясына тапшыруны бурыч итеп куя: "Безнең Максудыбыз рус историясендә булмаган эшләрне, халык авызындагы риваятьләрне мәйданга чыгармакдыр", дип, аларның тарих битләренә кереп калуларына нык игътибар бирә. Бу өлкәдә куйган хезмәтләре өчен аны 1885 елда Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең әгъзасы итеп сайлыйлар.

Каюм Насыйри — мәшһүр тәрҗемәче һәм язучы. Матур әдәбият өлкәсендә дә аның тарихи әһәмияткә ия булган хезмәтләре бар. Әйе, ул тәрҗемәче дә, оригиналь әсәрләр тудыручы да, халык авыз иҗатын җыеп, аны гыйльми нигездә эшләп бастыручы да, үзенә кадәрге татар шагыйрьләре әсәрләрен тикшерә башлаучы галим дә. Ул "Кырык вәзир кыйссасы"н, "Әбүгалисина кыйссасы”н татарчалаштыра, аның "Кырык бакча" китабы күп буын кешеләре өчен кызыклы, мавыктыргыч әсәр булып тора.

К. Насыйри — халык иҗатындагы һәм язма әдәбияттагы үзара йогынтыны күзәтү буенча да башлангыч хезмәтләр авторы. Ул үзе җыйган унбер татар әкиятен рус һәм татар телләрендә бастыра, аларда башка халыклар белән уртаклыклар булуга игътибар итә.

Каюм Насыйриның балаларны ана телендә укыту таләбе белән чыгыш ясавы ул чор өчен прогрессив һәм революцион адым булган. Татар теле белем бирү чарасы, әдәби-гыйльми тел булсын өчен аның нигезләрен эшкәртергә, грамматик һәм лексик үзенчәлекләрен өйрәнергә кирәк иде. Менә шуңа күрә дә татар теле белеменә нигез салу эшенә беренчеләрдән булып К. Насыйри алына. Яшь буынны тәрбияләүдә гарәп, фарсы, төрки телләре өстенлек алган вакытта татар теленең фәнни нигезләрен эшкәртмичә ана теленә карата тис-кәре карашны бетерергә мөмкин түгеллеген ул яхшы аңлаган. "Бәла татар теленең ярлылыгында түгел,— ди Насыйри,— ә татарларның үз телләрен белмәвендә. Безнең тел — бай, ләкин бу телне белүче юк". Ул бу сүзләрне туган телгә реакцион караштa торучыларга карата әйткән.

К. Насыйри, татар телен игътибар белән өйрәнеп, түбәндәге нәтиҗәләргә килгән: "Әгәр дә без игътибар белән үзебезнең телебезне өйрәнсәк, аның сүзләр күләме, атамалар, төшенчәләр, гомумән төзелеше буенча гарәп, фарсы телләреннән ким түгеллеген, кайбер яктан, бигрәк тә фигыльләр өлкәсендә байрак та булуын күрербез".

Татар халкына туган телен өйрәнүдә аның фәнни хезмәтләре зур әһәмияткә ия булдылар. 1898-1899 елларда Каюм Насыйри тарафыннан төзелгән ике томлы "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге" татар теленең никадәр бай икәнен күрсәтте. Аның бу сүзлеге бүгенге көннәрдә дә зур фәнни хезмәт буларак кулланыла. Бу сүзләрдә еш очрый торган гарәп, фарсы сүзләренә аңлатма бирелгән, татар теленең бәхәсле мәсьәләләре күтәрелгән, сүзләрнең килеп чыгышы чагылдырылган.

Бу сүзләрне рус галимнәре дә зурлап бәяләгәннәр. Профессор Н. Катанов, Радлов, Будаговларның сүзлекләреннән яхшырак булуын әйткән. Чөнки К. Насыйри бу сүзләргә тормышта кулланылган һәр сүзне кертеп, мәгънәсен аңлатып биргән.

Шулай ук аның 1894 елда фонетика, сүз төркемнәре һәм берникадәр синтаксистан мәгълүмат кертеп язылган "Өнмүзәҗ" татар грамматикасы басылган. Ул бу китабында беренче тапкыр авазларга классификация ясап, аларны 10 сузык авазга, 29 тартык авазга бүлеп күрсәтә, рус терминологиясендә кулланылган теш, тамак, аңкау, борын һ. б. терминнарны файдалана. Әйтергә кирәк, күпчелек телчеләр шикелле үк К. Насыйри да хәрефләрне авазлардан аермаган. Сүз төркемнәрен тикшергәндә ул өч сүз төркемен күрсәткән: исем (исем, сыйфат, сан), фигыль хәрефләр (ярдәмлек сүзләр). К. Насыйри мондый классификацияне грамматик формалардан чыгып түгел, ә сүзләрнең логик мәгънәләреннән чыгып ясый. Шул ук вакытта, аның грамматикасында кайбер сүзләрнең мәгънә төслекләре аерып бирелгән. Мәсәлән, ул күрсәтү алмашлыкларының кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклап, "шул" — ераклык, "бу" — якынлык дип аңлаткан. Ул иң бай сүз төркеме итеп фигыльне күрсәткән, аның ясалыш формаларына игътибар итеп, бер тамырдан йөзгә якын ясалма сүз барлыкка килүен әйткән. Шулай ук аның гади җөмлә синтаксисы буенча да күзәтүләре кызыклы.

К. Насыйри үзенең хезмәтләрендә татар теленең сүзлек составын чистартуга да зур әһәмият биргән, гарәп, фарсы сүзләрен татар һәм рус теле сүзләре белән алыштыруны яклап чыккан. Төрки телләргә ияреп, "бар" сүзен "вар" дип, "бирде" сүзен "вирде" дип, "кирәк" сүзен "кәрәк" дип язучыларны кискен тәнкыйть иткән.

Җанлы сөйләм теленнән, табышмаклардан, мәкальләрдән җырлардан һ. б. фольклор үрнәкләреннән мисаллар китерү аның хезмәтләрен һәр укучының күңеленә ярарлык итте. Татар укытучылары өчен К. Насыйриның китаплары беренче фәнни кулланмалар булдылар.

Ул татар телендә укучылар өчен берничә дәреслек язды. 1892 елда дөрес язу һәм орфография кагыйдәләрен үз эченә алган "Кагыйдәләр китабы" ("Кавагыйде китабәт") басылып чыкты. Бу хезмәтендә ул: "Һәрбер культуралы кешенең ике төрле теле була: шуларның берсе — анасыннан сөт имгән вакытта өйрәнгән тел, икенчесе укытучыдан укыганда — гыйлем һәм фән терминнары

белән ачылган тел...",— дип язды. Күргәнебезчә, К. Насыйри фәнни төшенчәләргә, терминнарга зур игътибар биргән, тел, әдәбият һәм башка фән тармаклары буенча фәнни терминалогия булдыруга зур хезмәт куйган.

1894 елда аның татар телендә "Ижек һәм әлифба" китабы басылган. Балаларга аваз турында беренче мәгълүмат биргәндә сүзләр сайланышы белән бу әлифба беренче көндә дә методик кызыксыну уята.

Каюм Насыйриның башка хезмәтләре дә рус телен татар теле белән чагыштырма планда өйрәнү өчен зур әһәмияткә ия. Ул татар телен өйрәнүне рус теле белән бергә бәйләгән. Ана телен белү башка телләрне өйрәнүгә ярдәм итә, ди Насыйри. Башта ана теленең грамматикасын бик яхшы белергә кирәк, һәр телнең грамматик төзелеше була. Грамматик төзелешне өйрәнгәч кенә балага башка телнең грамматикасын үзләштерү җиңел.

Насыйри тел белән оста файдаланырга киңәш итеп: "Сүзне аңлаешлы һәм кисәкләргә бүлеп әйт; сөйләшкәндә ашыкма, бер сүз икенче сүз өстенә менмәсен, тыңлаучыларга сине аңлау кыен булмасын. Озын фразалар белән сөйләшмә, башта әйтәсе фикереңне уйла, соңыннан кыска формада теләгәнеңне тыңлаучыга җиткер",— дип язган "Этика турында китаб"ында.

Насыйри яшьләргә уйлап һәм тәэсирле итеп сөйләшергә киңәш итә. Кеше теле белән танылa: әгәр дә ул сөйләшмәсә, аның турында бер фикер дә әйтеп булмый, ә инде сөйләшә башлагач, аның акылына һәм белеменә бәя бирергә мөмкин.

Башка телләрне өйрәнү өчен ана телен белү кирәк. “...Кеше үзенең телен яхшы белмәсә, башка телгә төшенә алмас, тик бик озак вакытлардан соң гына аңа күнегә алыр”, – ди Насыйри. Үзенең тәҗрибәсеннән чыгып, ул менә шундый нәтиҗәгә килгән. “Әнмүзәҗ” китабында ул: “Утыз-утыз биш елдан бирле ике фәннән, ягъни үз телебездән һәм рус теленнән сабак укытканда, бигрәк тә рус телен укытканда, үз телебезнең грамматикасына аңлатучы бер китапка мохтаҗ була идем. Милләтебез халкыннан бер булдыклы кеше чыгып, телебез өчен грамматика төземәсме икән дип көтә идем. Берәү дә сикереп чыгучы булмады. Үз телебезнең кагыйдәләренә мохтаҗлык соң дәрәҗәдә зур иде...", – дип язды. Менә шуңа күрә дә татар грамматикасын төзүгә К. Насыйри үзе алынган.

К. Насыйри чорында буржуаз татар гаиләсеннән чыккан яшьләр Көнбатышка укырга киткәннәр, чөнки урта гасыр мәдрәсәләре

аларны канәгатьләндермәгән. К. Насыйри бу тенденциягә каршы чыккан. Чит илдә яшьләр үз халкының интересларына битараф булып үскәннәр. Шул ук вакытта, мондый уку бик азларына гына насыйп булган. Халык арасында мәгърифәтчелекне киңрәк җәелдерү өчен укучы яшьләргә рус һәм ана телләрен бик яхшы белергә кирәк булган.

Ул вакытта татар телендә басылган әдәбият та булмаган. Дини эчтәлекле китаплар да гарәп, фарсы, төрки телдә язылган, күпчелек халык массаларына аңлашылмаган. Менә шуңа да аңлаешлы әдәбияты булмау балаларның ана телләрендә укытуын тоткарлаган. Укытучы алга җибәрү өчен укыту предметлары буенча кулланмалар, әдәби әсәрләр булдырырга кирәк булган. Татарларда китап басу эше күптәннән башланган булса да. Казан типографияләрендә дини китаплар гына басылган.

Мондый шартларда К. Насыйриның татар телендә басылып чыккан әдәби әсәрләрнең, дөньяви фәннәр буенча чыгарган китапларының әһәмияте әйтеп бетергесез зур булган. К. Насыйри үзе дә матур әдәбият әсәрләре язган, рус һәм көнчыгыш әдәби әсәренең иң яхшы үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә иткән.

Татар телендә укыту дәреслекләре төзегәндә ул халык авыз иҗаты үрнәкләреннән файдаланган. Духовная семинариядә эшләгәндә үк, укыту эшләрендә куллану өчен, татар фольклорын туплый башлаган. Аның бу эшен башка укытучылар хуплаган. П. П. Масловский 1870 елның 16 ноябрендә Казан архиепископы Антониягә биргән "Татар теле һәм татарлык фәне буенча программа" проектында: "Бездә 15 ел татар теле укыткан, күп санда табышмаклар, мәкальләр, җырлар, экиятләр туплаган К. Насыйровка һәм миңа, алда әйтелгәннәрдән чыгып, хрестоматия төзүне рәсми тәкъдим итмәссезме" П. П. Масловский К. Насыйрины укучыларны татар халык теле, аның сүз составы һәм сөйләм конструкцияләре белән таныштыру өчен педагогик яктан әһәмиятле зур фактик материалларына таянып тәкъдим иткән.

"Кырык вәзир кыйссасы" (1868), "Әбугалисина кыйссасы" (1881), "Фәвакиһел җөләса" (1884), "Гөлрах һәм Камәрҗан экиятләре" (1896) һ. б. әсәрләрендәге образ һәм темаларны Каюм Насыйри халык авыз иҗатларыннан, этнографиядән, тарихтан сайлап алган. Бу китаплар күп тапкырлар кабат-кабат бастырылган, яшьләр өчен татар телендәге бу уку әдәбиятларын берничә буын татар интеллигенцияләре дә файдаланган. Профессор В. О.

Смирнов "Россиядә мөселман басма нәшрияты" хезмәтендә К. Насыйриның татар әдәбиятын бастыру өлкәсендәге хезмәтен бәяләп: "Әле күптән түгел мөселман басмасы Константинопольдә чыккан китапларны кабат-кабат бастыру эше белән шөгыльләнә иде. Инде хәзер татарлар үз телләрендә мөстәкыйль әсәрләр бастыра башладылар. Алар арасыннан бигрәк тә К. Насыйриның "Фәвакиһел җөләса" китабы һәм еллык календарьлары күбрәк бастырылды",— дип язган.

К. Насыйриның халык авыз иҗатын файдаланып ана телендә язган әсәрләрен халык бик яратып кабул иткән. Ул халык авыз иҗатын укыту процессында да файдаланган, уку китапларына да керткән. Халык җырлары, табышмаклар, экиятләр, мәкальләр, әйтемнәр балаларның уйлау сәләтләрен үстергән, аларны тапкыр, җитез булырга өйрәткән. Насыйри татар фольклористларыннан беренче булды. Аларның халык авыз иҗаты буенча хезмәтләре шул чор галимнәре тарафыннан зурлап бәяләнгән. Профессор Н. Катанов К. Насыйриның "Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре" хезмәтенә язган кереш өлешендә: "Татар теленә күптән игътибар ителсә дә, Европада Казан татарларының халык әдәбияты әле яңа гына өйрәнелә башланды. Археология, тарих һәм этнография Җәмгыятенә Габделкаюм Насыйров 28 табышмак, 243 мәкаль, 145 җыр туплаган мәкаләсен тапшырды. Казан татарларының фольклорын башка фольклористларга караганда иң күп тапшырганы Каюм Насыйри булды. Аның тапшырган материалларыннан чыгып, шуны әйтергә була: чыннан да ул үз халкының телен, тормышын, гореф-гадәтләрен бик яхшы белгән. Бу фольклористның җыйган табышмаклары гына да халыкның зирәклеген, үткен акылын күрсәтеп тора" – дип язган.

Каюм Насыйри арифметика, геометрия, физиология, җирчелек тарих предметлары буенча да татар телендә уку дәреслекләре язган. Танылган татар язучысы Ф. Әмирхан 1907 елда "Әльислах" газетасында К. Насыйри хезмәтләренә зур бәя биреп: "К. Насыйрига хәтле мәктәпләрдә төп укыту теле булып гарәп теле исәпләнде. К. Насыйри татарларга, беренчеләрдән булып, үзләренең теле барлыгын күрсәтте. Аннан соң ул барлык кешеләргә дә аңлаешлы булган татар телендә әдәби әсәрләр тудырды",— дип язган.

К. Насыйриның татар телен шулай югары күтәрүе дин әхелләренә ошамаган. Алар гарәп, "төрки тел"не яклап чыкканнар. Татар буржуазиясе дә башта татар телендә укытуны хупласалар,

соңыннан "төрки тел"не пропагандалаганнар. К. Насыйри "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"нең кереш өлешендә: "Татар телебезгә хезмәтләр була килмәгәнлек сәбәпле, татар телебез артта, бик еракта йоклап калган. Әмма татар телебездә хезмәтче мин булыйм дип, утыз биш ел уздырдым. Ләкин күп мәгънә чыкмады. Көн-төн никадәр тырышсам, шулкадәр җәфа чиктем. Милләтебез халкын татар дип атасам, яратмадылар, татар теле дисәм, яратмадылар...",— дип язган. Шул ук вакытта, К. Насыйри эшчәнлеген яклап, аның эшен дәвам иттерүчеләр дә булган. Мөхетдин Корбангалиев үзенең истәлекләрендә: "Мин 1903 елда Казанга килдем. Монда һәрвакытта да тел һәм орфография буенча җыелышлар булып торды. Җыелышта мин һәрвакытта да тел мәсьәләсендә К. Насыйри яклы идем. Татар телен яклап чыккач, Казанның танылган бер тел белгече һәм педагог: "Татар теле ломовойлар теле, әдәби, яңгырашлы тел булып гарәп теле тора. Шуңа күрә әдәби телдә гарәп сүзләре күбрәк булырга тиеш",— диде. Үземнең 30 ел педагогик һәм әдәби эшчәнлегемдә мин К. Насыйриның 10 сузыкка нигезләнгән татар теле орфографиясе принципларына таяндым. Минем шикелле аның юлыннан баручылар күп иде"— дип язган. Алдынгы педагогларның тырышлыгы нәтиҗәсендә татар теле һәм әдәбияты мәктәп курсына кертелгән, соңыннан мәктәптә укытуның нигезе булып киткән.

М. Укмаси белән әңгәмә вакытында Насыйри аңа киңәш итеп: "Руслар белән Ватаныбыз уртак. Аларның укымышлылыклары зур. Ә без аны файдаланырга өйрәнмәдек. Безнең иң зур кимчелегебез булып мәдрәсәләрдә рус телен укытмаулар тора. Безгә гарәп теле түгел, ә рус теле кирәк. Русча укыштыргалап, шул чакта гына син үзеңә кирәкле белемне алырсың",— дигән.

К. Насыйриның татарларга мәҗбүри рус телен укыту идеясе аның халыкчанлык, татарларны фәнни прогресс һәм алдынгы мәдәният белән таныштыру теориясе белән бәйләнгән.

Татар балаларына рус телен укыту өчен К. Насыйрига кадәр бернинди дә кулланмалар, тәҗрибәләр, аз-маз уйланган планнар да булмаган. Насыйри, беренчеләрдән булып, рус телен укыта торган мәктәп ачкан, кулланмалар төзегән, татарларга рус теле укытуның методикасын эшләгән.

Инде 1860 елда ук аның татар балаларына рус телен, рус балаларына татар телен укыту өчен "Синтаксис" дәреслеге бастырылган. Аннан соң "Татарча-русча сүзлек" (1875), "Русча уку"

("Русское чтение" 1889), "Үрнәк яки рус теленең грамматикасы" ("образец или грамматика русского языка" 1891), "Русча-татарча сүзлек" (1892) китаплары дөнья күргән. Шулай ук ул татар теле буенча язылган хезмәтләрендә дә рус телен укытуга зур игътибар биргән. Мәсәлән, "Әнмүзәҗ" китабында ул рус телен өйрәнү өчен татар теленең кагыйдәләрен өйрәнергә кирәклеген әйткән.

К. Насыйри, кечкенә яшьтән үк рус телен өйрәнергә кирәк дип, бик дөрес әйткән. "17-20 яшьләрдә рус телен өйрәнү авырлаша" Шулай итеп, ул татарлар өчен башлангыч мәктәптә үк рус телен укытуны керткән.

Насыйри үзенең «Русча-татарча сүзлегендә» татарларга рус телен укыту методикасы буенча карашларын хикәяләп биргән. Рус телен әдәби үзенчәлекләре һәм бөтен нечкәлекләре белән белү өчен кимендә 10-15 мең сүз өйрәнергә кирәк. Моның кадәр сүзне өйрәнү һәм истә калдыру бик авыр. Шуңа күрә, кәрзингә җиләк җыйган шикелле, уку дәверендә һәр сүзне өйрәнеп, истә калдырып бару кирәк. Бу эштә ашыгырга ярамый. Ул һәркемнән даими, озак еллар буе эш алып баруны таләп итә. Кайбер кешеләр шикелле рус телен өйрәнүгә җиңел карарга ярамый. Алар: "Адрес язарлык ике-өч ай өйрәнсәң җитә",— диләр. Ике юллык адрес язу өчен дә кагыйдәләрне белү кирәк.

Татарларга рус телен өйрәнүдә икенче момент — рус авазларының дөрес әйтелешен үзләштерү. Моның өчен ул телдән гамәли күнегүләр үткәрергә карар иткән.

Өченчедән, рус телен өйрәнүчеләр рус теленең морфологиясен һәм синтаксисын белергә тиешләр. Әгәр дә укучы үз ана теленең грамматикасын, кагыйдәләрен белсә, рус телен ул җиңелрәк үзләштерә.

Дүртенчедән, рус теленең үзенчәлекләрен, бигрәк тә, бәйлек, алкушымча һ. б. үзләштерү мөһим. Болар турында рус грамматикасында да аз сөйләнә, чөнки ул китаплар руслар өчен чыккан. Телнең бу күренешләре белән беренче тапкыр очрашканга күрә татар балалары зур кыенлык кичерәләр. Менә шуның өчен, барлык үзенчәлекләрне исәпкә алып, татар балалары өчен аерым дәреслекләр төзергә кирәк. К. Насыйри үзе үк шушы эшкә алынган.

Русча укый башлау өчен К. Насыйри "Русча уку" ("Русское чтение") китабын язган. Бу китапта рус телен өйрәтү татар теленә нигезләнеп бирелә. Китапта 40 дәрес билгесе бер системага салынган: 1 нче дәрестә рус алфавиты белән таныштырыла, 2-3 нче

дәресләрдә баш һәм юл хәрефләренең дөрес язылышы күрсәтелә, 4 нче дәрестән иҗекләр өйрәнелә башлый. Бу дәресләрдә ике аваздан торган иҗекләр: бер тартыкның барлык сузыклар белән, бер сузыкның барлык тартыклар белән килүе өйрәнелә (4-9). Унынчы дәрес иҗекләрнең чиратлашуына багышлана.

К. Насыйри 1871 елда чыккан беренче календаренда ук татар балаларына рус телен укыту мәктәпләре оештыру хакында мәкалә урнаштырган.

Хәтта "Буш вакыт" китабында да еш кулланыла торган сүзләрдән рус-татар сүзлеге төзергә кирәклеген әйтә. Профессор Н. К. Дмитриев К. Насыйри турында: "Татар халкының мәдәниятен рус мәдәнияте аша гына күтәрергә мөмкин булуын татарлардан ул беренче булып аңлады. Татар белән русны беренче чиратта дип, тел түгел, ә шул чордагы рус властеның сәясәте аерып торганлыгын да К. Насыйри аңлады",— дип язган.

Әлбәттә, татарларның рус телен өйрәнүләре ул чорда яңалык булган. Насыйри администраторлыкка каршы чыгып, рус теленең әһәмияте турында аңлату эшләре алып барган, рус телен белгән очракта гына дөньяви фәннәрне үзләштерү мөмкин булуын әйткән. Шуңа күрә дә ул, җирле шартларны белмичә, үзләренең чараларын үткәреп комачаулаган түрәләрне күрә алмаган.

Алда әйткәннәрне йомгаклап, шуны әйтергә кирәк: "К. Насыйри зур мирас калдырган. Аның татар балаларына рус телен укыту буенча төзегән дәреслекләре һәм ярдәмлекләре бүгенге көндә дә милли мәктәп укытучылары һәм методистлары өчен зур кызыксыну уяталар".

К. Насыйри белем алу эчтәлеген тел белү белән генә чикләмәгән. Башлангыч классларда ук ул арифметиканы керткән. 1873 елда К. Насыйри тарафыннан татар телендә арифметика буенча беренче "Хисаплык" китабы язылган. Бу китапны язу өчен ул халыкның математика мәгълүматларыннан үлчәү, озынлык, вакыт берәмлекләрен өйрәнгән һәм җирле материалны гомуми кабул ителгән берәмлекләр белән чагыштырган. Насыйри дәреслеккә балаларның уйлау сәләтләрен үстерерлек кызыклы мәсьәләләр керткән. Ул үзе билгеләп үткәнчә, арифметика белән балалар шулкадәр кызыксынганнар, дәреслектәге мәсьәләләрне эшләп бетергәч, балалар тагын шундый типтагы мәсьәләне сораганнар. Соңыннан К. Насыйри һәр дәрескә өстәмә рәвештә берничә мәсьәлә алып килә башлаган. Уку елы дәвамында,

дәреслектән тыш, балалар өстәмә рәвештә 500 дән артык мәсьәлә чишкәннәр. Бу ул вакытта К. Насыйриның, педагог буларак, зур казанышы булган. Хәзерге вакытта кайбер сыйныф укучылары дәреслектән тыш моның кадәр мәсьәлә чишә дә алмыйлар.

Аның арифметика дәреслегендә теоретик фикерләр, методик киңәшләр зур урын алган: арифметика фәненең билгеләмәсен биреп, аның гамәли кулланылышын күрсәткән. Насыйри, беренчеләрдән булып, Европа илләрендә кабул ителгән гарәп цифрларын кулланган, саннарны рус системасы белән үзләштерүгә юнәлеш биргән. Профессор Н. Катанов "Хисаплык" китабы турында: "Хисаплык татар китабы. Ул иске гарәп телендә түгел, ә яңа Европа алымы белән, бөтенесенә дә аңлаешлы телдә язылган. Бу китап Габделкаюм Насыйров тарафыннан язылган, 1873 ел белән чагыштырганда, бермә-бер арттырылып, 1200 данәгә җиткерелеп, икенче тапкыр бастырыла. Мәсьәләләр арасында гомум таныш булган бүре, кәҗә һәм кәбестә турында; бер каз һәм бер көтү каз турында; бер-берсеннән бер сарыкны сораучы ике көтүче турында рус мәсьәләләре дә бар. Терминнарның барысы да уңышлы уйланылган, моңарчы дәреслекләрдә кулланылган, аңлаешсыз булган кайбер гарәп сүзләре татар сүзләре белән алыштырылган. Гомумән, Насыйриның дәреслеге файдалы, татар педагогикасында зур игътибарга лаек" дип гарәп һәм рус терминологиясен оста чагыштырып, К. Насыйри арифметик гамәлләрне (сумма һәм аерма, тапкырлау һәм бүлү) җентекләп аңлаткан, аерым арифметик гамәлләрне чишкәндә саннар тәртибенә урнәкләр, кагыйдәләр биргән.

Башлангыч укытуны ул рус, татар теле, арифметика өйрәтүгә нигезләнгән булса, аннан соңгы дәвердә тарих, география, биология, авыл хуҗалыгы нигезләре, геометрия, астрономия, химия һ. б. фәннәрне системалы өйрәнүне тәкъдим иткән.

К. Насыйри фикеренчә, тарих һәм география буенча белемнәр һәр укымышлы кешегә кирәк. Ул елларда татарларның тарихтан объектив дөрес язылган китаплары да булмаган. Мәдрәсәдәге укыту курсларында бирелгән кайбер тарихи белешмәләр традицион характерда, күбесенчә ислам һәм кайбер Көнчыгыш илләренең тарихын яктыртканнар. К. Насыйри тарих буенча дәреслекләр язуга алынып, (күп кенә китаплар тәрҗемә иткән) Петр Масловскийның "Гомуми тарих" китабын тәрҗемә иткән.

Шулай ук П. Устрялов, Н. М. Карамзин һ. б. хезмәткәрләрен файдаланып, уннан артык тарих, этнография һәм археологиягә караган хезмәт язган. К. Насыйри, авыл җирләрендә булып, казу эшләре алып барган, этнографик һәм этнографик материаллар туплаган. П. П. Масловский аның хезмәтләрен өйрәнеп, "хезмәт сөючән Насыйровның татар этнографиясе буенча язмалары бай һәм нигезле. Алларны бастырып чыгарырга кирәк" — дигән.

Туган якны өйрәнүгә, укучыларны җирле чыганаклар белән таныштыруга әһәмият биреп, ул авыл тарихын, кабар ташларын өйрәнергә, этнографик һәм фольклор материаллары җыярга тәкъдим итә.

Татарлар арасында тарихи белемнәрне тарату өчен "Рус тарихының әһәмиятле этаплары" (1890) китабын бастырган. Соңыннан бу китап кабат чыгарыла. Тарих, география, буенча календарьларда мәкаләләр урнаштырган. 1871 елгы календарьда рус тарихы һәм географиясе турында мәгълүматлар бирелә, 1873 елгы календарьда гомуми һәм Россия географиясе турында мәгълүматлар, Казан һәм Казан ханлыгы турында очерклар урнаштыра, 1874 елгы Хива сугышы тарихы турында материаллар бастыра, 1876 елгы календарь укучыларны Россиянең кыскача географиясе белән таныштыра, ә 1877 елгысында Россия, Азия, Африка турында мәкаләләр бирелгән 1881 елгы календарьда Казан тарихы, 1884 елгы календарьда татар һәм татар теленең барлыкка килүе, 1891 елгы календарьда Төркиянең кыскача тарихы бирелә. Календарьларда Азия (1884), дөнья (1878) географик карталары бирелгән, Россиянең Төп законнары турында мәкаләләр урнаштырылган.

К. Насыйри тарих укытканда илебез тарихына, Россия тарихына әһәмият биргән. Ул, беренчеләрдән булып, татарларга рус тарихын җиткергән: Чыңгыз хан, Батый хан походларына дөрес итеп характеристика биргән. Чыңгыз хан рус җиренә зур бәла-казалар алып килгән. Ул миллионлаган кешеләрне үтергән, шәһәрләрне җимергән. Батый хан да шулай ук бәхетсезлек китергән. Ул басып алган җирләр таланган, гөрләп үскән шәһәр көлгә әйләнгән.

К. Насыйри татарларның борынгы бабалары татар монголлары, алтынурдалылар түгел, ә болгарлар булуын әйткән.

К. Насыйри Иван III, Иван IV үзләштерелгән рус дәүләтен төзү эшчәнлегенә уңай караган. Чөнки бу дәүләт, чит ил басып алучы-

ларына каршы торып, җиңүче булып калган. Насыйри шулай ук Петр I, М. В. Ломоносовның эшчәнлекләренә зур бәя биргән.

Ул зур кызыксыну белән, Пугачев восстаниесе турында материаллар туплаган, бу хәрәкәтнең татар байларына һәм хезмәт ияләренә мөнәсәбәтен объектив ачып бирүгә ирешкән.

Шулай итеп, татарлар үзләренең мәгърифәтчеләре аркылы беренче тапкыр рус тарихының күренекле эшлеклеләре Ярослав Мудрый, Александр Невский, Дмитрий Донской, Минин һәм Пожарский, Суворов, Пугачев турында белгәннәр.

Насыйри дөньяны танып белүдә географиянең ролен дә бик яхшы аңлаган. "Әгәрдә кеше үз өенең төзелешен, күршеләрен белмәсә, төзелешнең бүлмәләре, ишекләре һәм башка өлешләре белән танышкан булмаса, мондый кешеләрне барысы да орышачаклар. Шуның шикелле үк, үз илеңнең дөнья кисәкләренең картасын белмәгән кешене дә орышырга кирәк",— ди Насыйри. Географияне өйрәнеп, укучы төрле җирләргә сәяхәт итә.

К. Насыйри география буенча да ярдәмлекләр язган: "География буенча терминнар" (1890), өч томлыкта "Зур география" (1984, 1898, 1899).

Насыйри төрле белем тармаклары буенча татар телендә фәнни терминология булдыру өчен зур хезмәт куйды. Бастырылып чыгарылганнан тыш, аның кульязма хәлендәге терминологик сүзләре дә сакланган. Биология терминнарының латинча-гарәпчә сүзлеге, ботаника терминнарының татарча-латинча русча сүзлеге, биологик терминнарның татарча сүзлеге, ботаника терминнарының русча-латинча-татарча сүзлеге, гомум фәнни терминнарның гарәпчә-татарча-латинча сүзлеге һ. б. үзләре үк Каюм Насыйриның татар фәнни терминологиясенә нинди зур әһәмият биргәнен күрсәтәләр. Болар барысы да татар телендә төрле фәннәрне укытуда да, шулай ук сыйныфтан тыш уку өчен дәреслекләр һәм популяр әдәбият язу өчен дә кирәк була. Фәнни терминологияне төзегәндә К. Насыйри халыкка аңлашылмаган гарәп, фарсы сүзләрен татар, рус һәм интернациональ сүзләр белән алыштырган. Мәсәлән, иске Аврупа, Азия, Ингельтера, Бельджика, Руссия һ. б. терминнарны интернациональ Европа, Азия, Англия, Бельгия, Россия һ. б. ш. терминнар белән алыштырган. Ул кулланган күпчелек терминнар татар фәнни әдәбияты фондына кереп калганнар.

К. Насыйриның "Зур география" китабы турында рус галимнәреннән берәү: "Автор рус чыганакларыннан файдалангач, тарихи вакыйгаларның елын русча биргән. Татарларның төгәл

фәннәр буенча китаплары юк, шунлыктан Насыйровның дәреслеге иллюстрацияләре булмаса да, азмы-күпме файда китерер...",— дигән.

К. Насыйрига хәтле татарларның биология турында карашлары да бик ярлы булган. Ул бу өлкәдә дә зур көч куйды. 1894 елда "Гәүдә әгъзаларының функцияләре һәм гигиена законнары" китабы басылып чыккан.

1892 елда Насыйри "Җирчелек фәне турында" китабын бастырып чыгарган. Бу китапта агрономиянең элементар кагыйдәләре, кара туфраклы җирләрнең барлыкка килүе, аларның үсемлек өчен әһәмияте, тиреснең һәм ашламаларның туфракны ашлаудагы роле турында материаллар тупланган, шулай ук яктылыкның, һаваның, җылылыкның һәм дымлылыкның үсемлек үсешенә йогынтысы күрсәтелгән. К. Насыйри уңышның нигезе кешеләрнең хезмәтендә, орлыкларның сортында, ашлауда икәнлеген раслый.

Мәгърифәтченең фикеренчә, төп белемне тырышлык куеп, системалы, дәвамлы өйрәнү нигезендә математика фәне аша гына алырга мөмкин. Бу фән гамәли тормышта (механикада, җирчелектә һ. б.), астрономия һәм физика фәннәрен өйрәнү өчен кирәк.

1895 елда К. Насыйри геометрия буенча сызымнар, циркуль һәм транспортир куллануны аңлатып, "Геометрия фәне" китабын бастырып чыгарган. Ул китапның кереш өлешендә: "Геометрия башка фәннәрне үзләштерү өчен зур файда китерә. Миңа татар яшьләренә аң-белем бирүдә ярдәм итәрлек төрле фәннәр буенча дәреслекләр бастырырга туры килде. Үземнең тәҗрибәмә куанып, өлкәдә белемем җитәрлек булмаса да, геометрия дәреслеге язарга булдым",— дип язган.

К. Насыйри реаль белем бирү яклы буларак, аерым һөнәрчелеккә багышлап, берничә ярдәмлек бастырган. 1900 нче елда "Ювелирлык һәм слесарьлык эше турында" китабын язган. Бу китапта аерым алымнар химия һәм физика законнарына таянып аңлатылган. К. Насыйриның мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә химия, табигать фәннәрен укытмыйча, бу өлкәдә руслардан артта калуына бик офтанган. Ярдәмлектәге химик һәм физик терминнарны рус һәм татар телләрендә биргән. Насыйри графит, фосфор, гипс, зәһәр ка-лий, күкертле водород, бакыр һәм тимер купоросын, цинк, сода, бакыр оксидын һ. б. кулланырга өйрәткән.

Ул шулай ук "Кулинария буенча кулланма" китабын да бастырып чыгарган. Бу китапта аш-су әзерләүнең 70 тән артык төрен биргән.

Бу мәктәпләрдә файдалы һөнәрләр һәм кул хезмәте укытуны яклап чыккан.

1896 елда "Гарәп теленең кагыйдәләре" китабы дөнья күргән. Ул вакытта мәдрәсәләрдә гарәп телен укыту формаль-грамматик юнәлештә, схоластик методка корылган булган. Көнчыгыш телләрне болай өйрәнүне туктату өчен гади һәм аңлаешлы итеп гарәп теле грамматикасын тудырган, һәр кагыйдә аерым мисаллар өстендә аңлатылган.

Татар телендә дәреслекләр төзү өчен К. Насыйридан төрле тармаклардан хәбәрдар, белемле, бетмәс-төкәнмәс эрудициягә ия булу соралган. Мәсәлән, "Зур география" китабын төзү өчен ул уннарча рус һәм көнчыгыш телләрендәге географияне өйрәнгән, татар телендә оригиналь географик фәнни терминология төзегән. Үзенең кулъязмаларын ул күп кешеләргә биреп укытып чыккан.

Китапны кабат бастыру өчен ул аңа өстәмәләр, төзәтмәләр керткән. Дәреслек яңартылып чыгарылган. Насыйри дәреслекләренең эффектлы һәм методик яктан дөрес төзелгәнлегенә ышану өчен укыту процессында эксперимент үткәргән. Тикшерүне үзе үткәргән, яки башка татар мәктәпләрендә эшли торган элеккеге укучыларына тапшырган. Халыкка аң-белем бирүдә аның дәреслекләре зур роль уйнаган, татарларның дөньяга карашларын киңәйткән.

"Бер фән икенчесеннән өйрәнү предметы, темасы, эчтәлеге, бурычлары белән аерыла",— дигән.

Насыйри дәреслекләренең методик структурасын, аның төзелү принципларын тикшергәч, мәгърифәтченең түбәндәге таләпләрне куйганын күрәсең:

1. Дәреслек предмет буенча төзелергә тиеш, һәр фән буенча үзенең дәреслеген булдырырга кирәк.
2. Анда фәннең предметына төгәл билгеләмә бирелергә тиеш. Өйрәнүнең теоретик һәм гамәли әһәмияте күрсәтелергә; кереш өлешендә курсның төп эчтәлеге һәм идеясе чагылдырылырга тиеш.
3. Дәреснең эчтәлеге материалның бирелү стиле һәм эчтәлеге белән аерым яшьтәге балаларга аңлаешлы булырга тиеш.
4. Дәреслек балаларның аңын, уйлану сәләтләрен, тапкырлыкларын, мөстәкыйльлекләрен, инициативаларын үстерерлек биремнәргә бай булырга тиеш.
5. Бастырып чыгарыр алдыннан ул тәҗрибәдә сыналырга, ә кабат бастырганда төзәтелергә һәм өстәмәләр кертелергә тиеш.

К. Насыйриның бу дидактик таләпләре аның эшен дәвам иттерүчеләргә, татар мәктәпләренең авторларына маяк булып хезмәт иткән.

К. Насыйри татар мәктәпләренең укыту эчтәлеге буенча танылган специалист, популяр дәреслекләр авторы булды. Аңа ярдәм сорап бик күпләр, шул исәптән, мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов та мәрәҗәгать иткән. Ә Оренбургтан капиталист Әхмәт Солтанов бухгалтерия эше буенча дәреслек тәрҗемә итүне сорап хат язган. "Бу китапны тәрҗемә итүнең максаты,— ди ул,— түбәндәгедән гыйбарәт: бу бухгалтер эшенә 20-30 кеше укытырга уйлыйбыз. Россия мөселманнары арасыннан бухгалтерия эшен белә торган кешене күп эзләдек, ләкин таба алмадык. Шуңа күрә (Сезгә мөрәҗәгать итәргә булдык) үзебезнең мәктәптә бу фәнне укытырга булдык".

Насыйриның уку планнары, дәреслекләр өлкәсендә зур хезмәтләрен күреп, аңа мәктәп җитәкчеләре дә киңәш сорап, я башка мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иткәннәр. Сөләйман Аитов, үзенең яңартылган татар мәдрәсәсе буенча уку планының проектын тәкъдим итеп, аерым бүлекләре буеңча күрсәтмәләр бирүне, я үзенең проектын төзүне үтенә.

К. Насыйри дәреслекләрнең эчтәлегенә генә түгел, ә тышкы бизәлешенә дә зур таләпчәнлек күрсәткән. 1883 елгы календаренда: "Дәреслекләрнең, ярдәмлекләрнең тышкы бизәлеше балаларны җәлеп итәрдәй, шрифты җиңел укылырдай, яхшы кәгазьгә басылган булырга тиеш",— дип язган.

Әлбәттә, Насыйриның дәреслекләре һәм ярдәмлекләре беренче күзлектән чыгып караганда примитив булып күренәләр. Ләкин бу китапларның, XIX гасырның икенче яртысында, татарлар арасында мөселман схоластикасы киң таралган вакытта язылганын да истә тотарга кирәк.

Насыйри китаплар һәм дәреслекләр төзегәндә рус һәм көнчыгыш чыганакларыннан файдаланган. Аның дәреслекләренә профессор В. О. Смирнов зур бәя биреп: "География, грамматика дәреслекләренең бастырылып чыгарылуы сөенечле күренеш, чөнки алар татар грамоталыларын басма китаптагы гомум тормыш эчтәлегенә өйрәтәләр",— дип язган.

Насыйриның дәреслекләре татар укытучы-практикларына зур ярдәм иткәннәр. Ул вакытларда аерым предметлар буенча күрсәтмәлелекләр, уку программалары да булмаган. Шул шартларда балаларга фән нигезләрен өйрәтү өчен аның китаплары бердәнбер дәреслек булган. Мөхетдин Корбангалиев үзенең истәлекләрендә: "1895 елда учительская школаны (укытучылар мәктәбен) тәмам-

лагач, Мамадыш өязенә эшкә киттем. Баруга ук рус теле дәреслекләре белән бергә К. Насыйриның барлык дәреслекләрен дә алдырттым",— дип язган.

Шулай итеп, Каюм Насыйри дәреслекләр төзүнең фәнни нигезләрен, аларга карата таләпләрне эшләде һәм үзе дә мәктәп дәреслекләре төзеде. К. Насыйриның дәреслекләре нигезендә татар мәктәпләре өчен китаплар языла башлады.

Насыйри чорында урта гасыр мөселман педагогикасының нигезе булып схоластика, формализм һәм ятлау торган. К. Насыйрины мәктәпләрдәге һәм мәдрәсәләрдәге схоластик методлар канәгатьләндермәгән.

Ул татар халкының педагогик фикерләрен үстерүдә яңадан-яңа дидактик принциплар уйлап тапкан. Әлбәттә, бөтендөнья дидактикасы күзлегеннән караганда, К. Насыйри укыту принциплары теориясен баету өлкәсенә зур өлеш кертмәде. Әмма ул, күренекле татар педагогы буларак, беренчеләрдән булып, үзенең практик эшчәнлегендә дәреслекләр, ярдәмлекләр төзүдә башка халыкларның дидактика өлкәсендәге уңышларын оста файдаланды.

Фән һәм тәрбия халыкка хезмәт итәргә тиеш дигән күзлектән чыгып, Каюм Насыйри рус педагоглары тәҗрибәсендә укытуны тормыш, тәрбияне халык ихтыяҗы, теорияне тәҗрибә белән бәйләргә омтылды. Укучылар тормышта һәм тәҗрибәдә куллана алырлык белемнәр белән коралланырга тиеш. Кеше үзенең алган белемен эштә файдалана алмаса, ул тормышка яраксыз була: мондый кешенең үзенә дә, башкаларга да файдасы булмый,— ди Каюм Насыйри. Дәреслекләрне төзегәндә дә ул теорияне тәҗрибә белән бәйләү принцибыннан чыгып эш иткән. Ул һәрбер очракта аерым һөнәрнең фәнни нигезен, теорик белемнең гамәли әһәмиятен аңлатып биргән. Шуңа күрә ул арифметикадан, геометриядән һәм физикадан гамәли мәсьәләләр чишүгә игътибар иткән.

Аның бу принцибы укыту процессында да ачык чагылган. Ул слесарь эше, кул хезмәте, җирчелек нигезләре, өй эшләре предметларына күбрәк вакыт бирүне таләп иткән.

Насыйри укыту процессында күрсәтмәлелеккә дә зур игътибар биргән. Татар мәктәпләрендә бертөрле дә күрсәтмәлелек булмаган вакытта ул глобус, географик карталар, геометрик фигуралар файдаланган. Болар барысы да укыту процессын җиңеләйткәннәр, балаларның танып белүләрен, материалны үзләштерүләрен яхшыртканнар. Ул күрсәтмәлелекләрдән экскурсияләрне, сәяхәтләр-

не тәкъдим итеп, бу тезисларны халыкның "Күп яшәгән түгел, күп күргән белер", "Йөргән таш шомарыр, яткан таш мүкләнер" кебек мәкальләре белән ныгыткан.

К. Насыйри догматив укытуга каршы чыккан, белем алуда укучыларның активлыгын аңлылыгын таләп иткән. Ул укучыга мөрәҗәгать итеп: "Дәрестә нәрсә генә өйрәнсәң дә белемсез һәм аңламыйча китмә; белмәсәң укытучыдан сора, иптәшләреңнән дә сорарга оялма!" — дигән.

Укыту процессында ул укытучыларга дәреслекне генә файдаланмыйча, укучыларны активлаштыру өчен, иҗади якын килергә, материалны укучыларның үсеш дәрәҗәсен исәпкә алып, төрле мисаллар белән баетырга киңәшлекләрен һәм инициативасын үстерү өчен актив методлар файдаланырга тиеш.

К. Насыйриның дидактик методлары догматив укыту методларыннан аерылып торган. Ул "Кырык бакча" китабындагы "Акылны сынау" бүлегендә балаларның аңын һәм тапкырлыгын үстерү өчен халык мәсьәләләрен кулланган. Менә шундый мәсьәләләрдән берсе:

Бабай елга буенда бер егетне очраткан. Алар икесе дә сарык көткәннәр. Бабай аңа мөрәҗәгать итеп:

— Әй, егет! Миңа бер сарыгыңны бир әле, ул вакытта минем сарыкларым синекенә караганда 2 тапкыр күбрәк булыр,— дигән.

Егет уйлап торган да:

— Юк, хөрмәтле бабай, болай дөрес булмый. Сез миңа үзегез бер сарыгыгызны бирегез, ул вакытта безнең сарыклар тигез булыр,— дигән.

Аларның һәрберсенең ничә сарыгы булган?

К. Насыйри, төп дидактик принциплар итеп, чиратлашып, системалылыкны алган. Бу принциплар рус теле, татар теле, математика укытудан балаларга нык белем алуга зур ярдәм иткән. Шуңа күрә дә, К. Насыйри мәсьәләләр, күнегүләр һәм сукыр карталар белән эш итүнең системасын булдырган. Ул киңәш итеп: "Өйрәнгәнеңне онытмас өчен кабатларга, ятларга кирәк",— дигән. Кабатлауның, бигрәк тә, математика фәнен өйрәнүдә зур әһәмияткә ия булуын әйтеп: "Бу фәннәрне даими кабатларга кирәк, чөнки алар тиз онытыла",— дигән.

Фәнни белемнәр укучыларга аңлаешлы булсын өчен татар мәгърифәтчесе бик күп көч куйган. Ул фәнни материал балаларга аңлашылсын өчен укыту процессына уен элементларын, халык авыз иҗаты әсәрләрен, төрле башваткычларны керткән. Шул ук

вакытта, ул ирекле тәрбия бирүгә каршы чыккан. Уку бала өчен зур хезмәт, ул тырышып укуны таләп итә: "Укырга вакыт юк димә, башлаган эшеңне калдырма, өйрәнгәнчегә кадәр тырышып укы. Белем алуга вакыт чикләнмәгән: гомер буе укы, яшь чагында да, картайгач та укырга кирәк!" — дип язган Насыйри.

К. Насыйри укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен тәҗрибәдә куллану үрнәкләрен бирде. "Русча — татарча иткән. Укытучы һәр сүзне, кагыйдәне, законны яхшылап аңлатырга, укучыларның мөстәкыйль сүзлек"нең кереш өлешендә рус теленә өйрәтүдә укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алырга тәкъдим иткән: яшьрәк булган саен кеше ныграк үзләштерә. "Мин моны 30 еллык тәҗрибәмнән чыгып әйтәм. Мәсәлән, у — о — а — ы авазларын аеруны өлкәннәргә караганда җиңелрәк үзләштерәләр, җиңелрәк әйтәләр."

К. Насыйри, укытучы буларак, балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен игътибар белән өйрәнгән, ата-аналар белән очрашкан, кемнең нәрсәгә мохтаҗ булуын белгән. Ул һәрвакытта да балаларда белем алуга кызыксыну уятырга тырышкан: тырышып укы, белемнең дусты, дөнья мәшәкатьләренең дошманы бул; үзеңнән кечеләрдән өйрәнергә оялма, дигән. Ул белмәгән, башкалардан сорамаган кешеләрне гаепләп чыккан: "Башкаларга караганда күбрәк беләм дип хыялланма, чөнки акылга җиңелрәкләр генә шулай уйлыйлар; әгәр дә кеше аз белә икән, бу инде аның нәрсәдер белгәнен күрсәтә" (Кабуснамә).

Барлык әйтелгәннәр үзләре үк К. Насыйриның татар мәктәпләрендә дидактик принципларны үзгәртү өчен күп хезмәт куйганын күрсәтеп торалар. Әлбәттә, ул татар мәктәпләрендәге мәдрәсәләрдәге схоластиканы бетерә алмаган. Чөнки патша түрәләре К. Насыйриның күркәм, гуманлы башлангычын хупламаганнар, патша хөкүмәте интересларыннан чыгып эш иткәннәр. Ләкин К. Насыйри, барлык авырлыкларга да карамастан, XIX гасырның 60 нчы елларындагы рус методистларының уңышларын файдаланып, дидактик системаларны үзгәртү өчен көрәш алып барган. Аны, чын мәгънәсендә, татар мәктәпләренең беренче реформаторы дип атарга мөмкин.

6. Каюм Насыйри хезмәтләрендә тәрбия мәсьәләләре.

К. Насыйриның Педагогик концепцияләрендә укыту теориясе һәм аерым методикага караган мәсьәләләр үзәктә торса да, ул шәхәс тәрбияләү проблемасына зур игътибар биргән. Аның "Тәрбия китабы" (1891), "Этика турында кыскартылма китап"

(1884), "Этика турында зур китап" (1890), "Кабуснамә" (1881) китаплары һ. б. мәкаләләре тәрбиянең аерым якларына багышланган.

К. Насыйри халыкчанлык белән гуманлыкны тәрбиянең төп принциплары итеп санаган. Беренче принцип халыкка, прогресска хезмәт итү өчен тәрбия бирүне чагылдырса, икенче принцип тәрбиядә балага гуманлы якын килү, баланы шәхес буларак хөрмәт итүне күз алдына китереп бастыра.

К. Насыйри яшьләрдә Туган илгә мәхәббәт, кыюлык, батырлык, тапкырлык, хезмәт сөючәнлек, дөреслек, тугрылык, күркәмлек, дисциплиналылык кебек әхлак сыйфатларын тәрбияләргә киңәш иткән.

"Этика турында кыскартылган китап"та ул тәҗрибәле кешенең үз-үзеңне тәрбияләү өлкәсендәге киңәшләрен биргән: "Ашаган, эчкән, йоклаган кеше (хайван да шулай эшли) түгел, ә әдәпле итеп сөйләшә, уйлый, эш итә белгән кеше генә чын кеше була ала".

Каюм Насыйри балаларның яхшы характерын формалаштыруга да зур әһәмият биргән. Кемнең характеры яхшы, ул бөтенесе тарафыннан да хөрмәт ителә, ә кемнең характеры начар, аның тормышы да, кешеләр белән мөнәсәбәте дә начар булачак. Баланың ихтыяр көчен дә ныгытырга кирәк. Әгәр дә кеше үзе белән идарә итә алмаса, башкалар белән дә идарә итә алмый. Кешегә сәламәт акыл, ихтыяр көче кирәк. Кешенең уңай (үзенчәлекле) характер билгеләре бары тик хезмәт процессында гына формалашканын К. Насыйри бик яхшы аңлаган.

К. Насыйри әхлак тәрбиясенең төп нигезе итеп хезмәт тәрбиясен алган. "Кеше хезмәттән һәм кайгыртудан аерылмаска тиеш. Әгәр дә тормышта канәгатьләнү хисе кичерәсең килсә, үз хезмәтең белән яшә, чөнки хезмәттән башка канәгатьләнү хисе тумый",— ди Насыйри, "Кабуснамә" авторының фикерен куәтләп.

“Баланы хезмәт тәрбияли”, — ди ул. Тәрбиясезләр, бозык кешеләр иң беренче чиратта бай гаиләләреннән килеп чыга. Чөнки алар иҗтимагый файдалы хезмәт белән шөгыльләнмиләр, һөнәрләре юк. Ә гади крестьян гаиләсендәге балалар кечкенәдән үк хезмәткә өйрәнеп үсәләр. Мондый гаиләләрдә тәрбиясез, бозык кешеләр сирәк очрый.

Каюм Насыйри үзе үк хезмәт сөючәнлеге белән балаларга үрнәк булып торган. Ул акыл хезмәте белән физик хезмәтне оста чиратлаштыра белгән. Утырып эшләүдән кан тамырлары оеша, дигән ул. Шуның өчен көн саен ике-өч сәгать физик эш белән шөгыльләнгән:

столяр, слесарь эшләрен башкарган, китаплар тышлаган, крахмал ясаган, пешерү эшләрен дә белгән. Аның өендә дә төрле эш кораллары, столяр верстагы, приборлар, төрле эшләнгән әйберләр булган.

М. Укмаси инде язучы булып танылгач, К. Насыйри белән булган сөйләшүен искә төшерә:

— Хөрмәтле Каюм ага, сез акыл хезмәте белән шөгыльләнүче, бу верстак сезгә нәрсәгә?

— Әй, энем! Даими акыл хезмәте кешене талчыктыра. Баш мие арыганда физик хезмәт белән шөгыльләнергә кирәк. Ул чагында баш мие яхшырак эшли башлый, күбрәк тә эшлисең. Менә сезгә мәдрәсәдә дә мастерской булдырырга кирәк. Китап, каләм белән озак эшләү кешене талчыктыра. Әгәр дә уку белән бергә мастерскойда да эшләсәләр, уку да яхшырак барыр, файдалы һөнәр дә үзләштерерләр иде.

Авылда булганда да Насыйри авыл хуҗалыгы эшләрен яратып башкарган, ата-аналарына хуҗалык эшләрендә булышкан. Бер язмасында ул: "35 ел Казанда яшәгәч, ниһаять, туган авылым Шырданга кайттым. Монда каләм түгел, күбрәк чалгы, сука төзәтергә туры килде",— дигән.

Насыйри төрле һөнәрләр үзләштерү җиңел булсын өчен мәктәпләрдә хезмәт укытуны таләп иткән. Төрле һөнәрләрне үзләштерү өчен "Ювелирлык һәм слесарьлык эше", "Җирчелек нигезләре", "Кулинария" кулланмаларын язган.

"Русча уку" ("Русское чтение") китабында мәгърифәтче: "Байлыкны законлы юл, хәләл хезмәтең белән генә тупла, аның өчен үзеңне куркыныч астына куйма. Әгәр дә байлыгыңны законлы юл белән тапсаң, үзеңә калыр, файда китерер. Ә инде дөрес булмаган юл белән табылса, кулыңнан ычкыныр, сиңа тиешле җәзасын да бирер",— дип язган.

"Этика турындагы китап"та К. Насыйри бала өчен иң әһәмиятле хезмәт итеп белем алу хезмәтен атаган: белем алу өчен ялкауланма. Ялкаулыкны, эшлисе килмәгәнлекне җиңәргә кирәк, чөнки ул башка кимчелекләрне дә китереп чыгара.

Эшләргә кирәклекне ул хайваннар образы аша ялкаулык белән эш сөючәнлекне капма-каршы куеп күрсәтә, "Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше" китабында ул балалар өчен файдалы булган әрлән белән бака турындагы мәсәлне китерә.

Бер заман кыш гаять суык булып, бер бака әрләннән азык сорады: "Ашарыма юк, бераз ризыклык рәхим итсәнә",— диде.

Әрлән әйтте: "Җәй көне көн буенча авыз күтәреп кычкырып

тордың, ни эшләдең, ник кыш өчен азык әзерләмәдең?" — диде.

Хезмәт — материаль байлыкның нигезе. Шуңа күрә хезмәтне, хезмәт кешеләрен яратырга кирәк. Хезмәт, ди Насыйри, җәмгыятькә, халыкка файдалы булырга тиеш. Шәхси интересларыңны кайгыртып, үзеңә килерлек файда турында гына уйлап яшәргә ярамый: "Әгәр дә яхшы яшисең килсә, үз эшеңне яхшылап башкар, синең эшеңне башкалар да хөрмәт итсеннәр".

Һәрбер балада үз халкыңа патриотик хезмәт итү идеясе тәрбияләнергә тиеш. Туган ил төшенчәсен Насыйри киң мәгънәдә аңлый. Ул бу төшенчәгә Россиянең барлык халкын керткән һәм үзен дә "Россия гражданины" дип атаган. Үз илеңнең тарихын һәм географиясен белү, туган халкыңның телен һәм мәдәниятен ярату патриотик тәрбиянең состав өлешләре булып тора.

Насыйри туган як табигатен бик яраткан һәм аның байлыклары белән горурланган. Беренче нәүбәттә Россиянең үзенең киң табигать байлыкларыннан файдаланырга чакырып, башка илләрдән генә көтеп торуны урынсыз саный: "Тәхкыйк без Россия халкы. Ни өчен башка йорттан килгән даруларга мохтаҗ булабыз? Кайчан ки, үз җиребездә дәвага яраклы үсемлекләрнең һәммәсе бардыр. Хәтта мәмләкәтебездәге нәбатәт вә дәваларның куәте башка йорттан килгән дәваларның куәтеннән артыграк, имеш, ләбаса. Үз җирләребезнең дәвалары һәммәсеннән артык икән, ләбаса!" — дигән.

К. Насыйри патриотик тәрбияне тар милләт интереслары белән генә чикләми. Ул милләтләр арасындагы бәйләнешне, халыклар арасындагы дуслыкны ныгыту өчен көрәшкән. Насыйри рус халкын, аның мәдәниятен хөрмәт иткән. Татар халкына материаль һәм мәдәни яктан үсәргә ярдәм иткән рус халкына хөрмәт мәктәп эскәмиясендә үк тәрбияләнергә тиешлеген әйткән. Руслар белән татарлар арасында дуслык элементәләрен ныгыту өчен ул русларны үз халкының мәдәнияте белән таныштырган. Шул максаттан чыгып, ул рус телендә берничә хезмәт тә язган: "Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре" ("Образцы народной литературы казанских татар"), "Башка халыкларның әкиятләре белән чагыштырма планда Казан татарларының әкиятләре" ("Сказки казанских татар в составлении со сказками других народов"), "Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары" ("Поверья и обряды казанских татар") һ. б.

К. Насыйри милләтләр арасында дошманлык утлары кабызган эксплуататор сыйныфларның мораль йөзләрен фаш иткән. Ул

яшьләргә дә дусларны дини һәм милли үзенчәлекләренә карап түгел, ә аларның акылларына, эчке сыйфатларына карап сайларга киңәш биргән. К. Насыйри иң яхшы сыйфатларны хезмәт ияләрендә күргән, шуңа күрә дә, Туган ил төшенчәсен аның хезмәт сөйгәнгән халкы, табигать матурлыгы, җир байлыгы белән бәйләп күрсәткән. Туган ил һәр яшүсмернең йөрәгенә якын булырга тиеш. Туган илне дошманнардан саклау өчен ул батыр, кыю булып үсәргә тиеш. "Куркак булма, сугышта үлем турында уйлама, үзеңнең көчсезлегеңне, куркаклыгыңны башкаларга күрсәтмә",— ди Насыйри үзенең "Кырык бакча" китабында.

Ул татар халкының гаделлек, намуслылык сыйфатларын мактый. Бу сыйфатлар яшьләрдә үстерелергә тиеш. "Дөресен сөйләшү, дөрес эш итү — кешенең иң уңай сыйфатлары. Дөреслекне яраткан кеше җәмгыятьтә зур хөрмәткә ия була",— дигән Насыйри. Ул үз халкыңны алдау, икейөзлелек сыйфатларыннан балаларны сакларга кирәклеген әйтә. "Үлем алдында торганда да алдама, дөреслек җиңеп чыгар,— ди ул.— Дөреслекне тану кайвакытта ачы булса да дөресен әйтергә кирәк" ("Этика турындагы китап"). "Этика турындагы китап"та дуслык һәм иптәшлекнең белем алуда һәм хезмәттә кешеләрне берләштерүе әйтелә. Туганнарың булмауга караганда дусларың булмау начаррак. К. Насыйри бу турыда халык мәкален дә китерә: "Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын". Ул эгоизм, буржуаз индивидуализмны гаепли. Үзеңне башкаларга каршы куярга ярамый: җәмгыятькә зыян китерерлек эш эшләмә. Җәмгыять, халык интересларын шәхси интереслардан өстен куярга кирәк.

Гуманизм белән киң күңеллелек — тәрбияле кешенең иң әһәмиятле сыйфатлары. К. Насыйри киңәш итеп: "Барлык кешеләр белән дә яхшы мөгамәләдә бул, алар белән ягымлы сөйләш, яхшылык эшлә...", "әгәр дә синнән яхшы әйбер сорасалар, аны кызганма, бүләк ит.., саран булма" ',— дигән. Башка әсәрләрендә дә яхшылыкны кызганма, көчеңнән килгәнчә, халыкка хезмәт ит дип кабатлый.

Аның педагогик хезмәтләрендә дисциплина һәм тәртип мәсьәләләре дә үзәктә тора. Өлкәннәрне хөрмәт итү, кечкенәләргә игътибарлы булу, әдәплелек, кунакчыллык — бу сыйфатлар һәркемгә дә кирәк. "Ахмак сүзләр әйтмә, әйтәсең икән, башкалардан да шуны ишетерсең",— дип кисәтә ул. Кунакчыллык хезмәт кешесенә хас сыйфат, балалар да аны үзләштерергә тиешләр.

Ул шулай ук балаларның өстәл артында утыру кагыйдәләренә дә

туктала: беренче булып ашый башлама, зур кисәкләрне авызыңа алма, кеше тәлинкәсенә карама, үз тәлинкәңә кара, иң яхшысын гына сайлап алма, ашаганда ризыкның гаебен эзләмә һ. б. ("Кабуснамә").

К. Насыйри мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдәге таяк дисциплинасына каршы чыккан. Бу хәлне сарказм белән бер хикәясендә тасвирлый: "...Бер хәлфәне күрдем, янында бер озын вә бер кыска таяклары бар, бер быргы, дәхи барабаны бар.

— Болар ни эшкә? — дип сорадым. Хәлфә әйтте:

— Бу авылда мин балалар укытып торамын. Балалар шаяралар, сабакларын укымыйлар. Миңа якынрак утырганнарын кыска таяк белән сугамын, ерактагыларын озын таяк белән сугамын. Алар минем сүземне тыңламыйлар, үземнең өстемә ташланалар. Аннан соң барабанны борамын, быргыны кычкыртамын, шуннан соң халык җыелып, мине коткаралар".

Мондый педагогика белән балаларда аңлы дисциплина тәрбияләп булмаганлыкны К. Насыйри бик яхшы белгән. Укытучы таләпчән, укытуны һәм ялны дөрес оештырган вакытта гына дисциплина урнаша. Укучыларның хезмәтен рациональ оештыру, укуда уңышларга ирешү өчен дә дисциплина кирәк.

К. Насыйриның таләпчәнлеге түбәндәге фактта да күренә. Казан промышленнигы Сөләйман Аитовның улы Исмәгыйл К. Насыйрида укыган. Исмәгыйлнең атасы К. Насыйрига мөрәҗәгать итеп: "Хәзергә суык торганда минем улым өйгә кунарга кайтсын иде. Әгәр дә галим булу өчен генә идәндә йокларга кирәк булса, ул өйдә дә идәндә йоклый ала...",— дип хат язган. Насыйри аңа үз кулы белән: "Улыгыз акыллылана төшкәнче әллә 2-3 ел укытмыйсызмы?!"— дип кискен рәвештә җавап язган. Насыйри байның галимгә кисәтүле карашын, атасының иркә баласына либераль мөнәсәбәтен менә шулай бәяләгән. Баланы көеннән торып бозарга ярамый, нык-лы режим аңа файдалы гына була дип, К. Насыйри бик дөрес әйткән.

Бала тәрбияләүдә таяк, тән җәзасы түгел, ә ышандыру көче зур роль уйный, ди Насыйри. "Этика турында", "Тәрбия турында", әдәби китапларында ул балаларны ышандыруга зур игътибар биргән. Халыктан туплаган һәм китапларда файдаланган халык авыз иҗаты әсәрен дә ул балаларны ышандыру өчен кулланган. Аның әкиятләрендә гаделлеккә, дөреслеккә, халык эшенә бирелгәнлеккә, батырлыкка дан җырланган. Ул балаларны яхшы үрнәккә иярергә чакырган: "Яхшылык эшләргә теләсәң, көзгегә караган шикелле

башка кешегә кара: әгәр дә ул яхшылык эшләсә, аңарга охшарга тырыш, әгәр дә ул әшәкелек эшләргә җыенса, шулай эшләүдән кач".

Олылар һәрвакытта да кечкенәләргә үрнәк булып торалар. Ул "Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше" китабында бер фактны сурәтли.

"Бер сабый бала, олуглар белән ашарга утырган, кашыгын куйды да елый башлады.

— Ник елыйсың?— диделәр.

— Бик кайнар, авызымны пешерә,— диде.

— Азрак сабыр ит, суынсын,— диделәр.

— Мин сабыр итәр идем, сез сабыр итмисез анда,— диде". Бала никадәр кечкенәрәк булса, ул шуның кадәр башкалар үрнәгенә тизрәк иярә. Менә шуның өчен тәрбия кечкенәдән үк башланырга тиеш. Бигрәк тә, балалар үзләрен белә башлаган чор, мәктәп чоры зур әһәмияткә ия. Ул чордагы мәктәпләрдә, мәдрәсәдә балаларга тиешле тәрбия бирелмәгән. Менә шуңа күрә дә К. Насыйри үзенең китапларында үз-үзеңне тәрбияләү, характерыңны яхшырту мәсьәләләренә зур урын биргән.

Шулай итеп, К. Насыйри әхлак тәрбиясе өлкәсендә зур хезмәт куйган. Балага гуманлы мөнәсәбәт, тән җәзасыннан баш тарту, хезмәт ияләренең иң яхшы мораль сыйфатлары үрнәгендә тәрбияләү кебек прогрессив идеяләр белән аны тагын да баеткан.

К. Насыйри кеше өчен физик тәрбиянең әһәмиятенә, аны акыл хезмәте белән аралаштырырга кирәклегенә күп тапкырлар басым ясаган. Бу идеясен раслау өчен ул халык мәкален китергән: "Сәламәт тәндә сәламәт акыл". Баланы ашату, эчертү генә физик тәрбияне тәшкил итми. Физик тәрбия кешенең акыл һәм әхлак үсешенә нигезләнгән булырга тиеш. Сәлам алмашулар турында кайгыртканда, ата-аналар үзләренең физик хәлләре турында да кайгыртырга тиешләр. Ата-ана агачның нигезе булса, балалар шул агачның җимешләре булып торалар. Агач яхшы үссә, аның җимешләре дә яхшы була, дигән Насыйри.

Шуңа күрә дә ул кешенең анатомиясе, физиологиясе һәм гигиена кагыйдәләре турында китап язган. Бу китабында физкультура һәм йокының кеше сәламәтлеге өчен әһәмиятенә, азык, чиста су, саф һава мәсьәләләренә зур урын биргән. Барлык тереклек өчен, ди Насыйри, саф һава кирәк. Ул кешенең үпкәсе аша гына түгел, тиресе аша да үтә. Шуңа күрә балалар чисталыкны сакларга, шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәргә тиешләр.

1890 елгы календарьда К. Насыйри мәктәпкәчә тәрбия мәсьәләсенә караган мәкалә бастыра. Бу мәкаләсендә яшь аналарга күкрәк сөтен имезү кагыйдәләрен төшендерә, күкрәк сөтенең әһәмияте һәм киң таралган бала тирбәтүнең зыяны турында фикерләре белән уртаклаша.

Башка хезмәтләрендә дә яшьләрнең гигиенасына һәм туклану режимына әһәмият биргән. Татарларда яшелчә ризык буларак аз кулланылганлыктан, яшелчә ризыкларын да тәкъдим иткән, организмга начар булганлыктан, йоклар алдыннан күп ашамаска киңәш биргән.

К. Насыйри тәмәкенең һәм аракының бала организмына зарарлы булуын күрсәткән. Кешенең эшкә сәләтлелеген торгызуда йокы зур урын алып тора. К. Насыйри да йокларга бер үк вакытта ятып, 8 сәгать йокларга киңәш биргән. Ул шулай ук мунчадан ничек файдаланырга икәнен дә әйткән: һәр атнаны мунчада юынырга, мунчадан соң ятып ял итеп алырга, мунчага ашап бармаска һ. б. ш.

Насыйри мәдрәсәләрдәге тәрбия системасын кискен тәнкыйтьләгән, чөнки анда яшьләрнең физик үсешенә әһәмият бирелми, дигән. Ул физик тәрбия халыкның хәрәкәтле уеннарын, бәйрәмнәрен файдаланырга кирәклеген әйткән. Физик тәрбиянең батырлык, кыюлык, тәвәккәллек, үз сүзендә торучанлык, ихтыяр көче һ. б. сыйфатларны тәрбияләүгә йогынты ясавын К. Насыйри яхшы аңлаган.

К. Насыйри яшәгән чорда эстетик тәрбия бирү бөтенләй диярлек булмаган. Ислам дине музыка тыңлауны да тыйган. Шундый шартларда К. Насыйри кешеләргә эстетик тәрбия бирүне, мәктәпләрдә рәсем, җыр, музыка укытырга кирәклекне күтәреп чыккан.

Ул музыканы бик яраткан, үзе дә татар халкының уен коралы — кубыз ясаган. К. Насыйри чордашлары аның өендә еш булганнар. Аларның истәлекләреннән күренгәнчә, К. Насыйри берничә уен коралында уйный белгән (курай, кубыз, скрипка, балалайка һ. б.).

"Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре" китабының 30 бүлеген ул татарлар арасында музыканы пропагандалауга биргән һәм түбәндәге фикерне әйткән: "Кемне дә булса кайгы, борчу басса, ул яхшы җыр тыңласын. Әгәр дә берсенең йөрәге янса, яхшы җырдан аның уты сүнәр". Матур тавыш рухи азык булып тора, ул уйны яктырта, акыл эшчәнлеген үстерә, табигатьне яхшырта, мәрхәмәтлене олылый, йөрәксезне батырга әйләндерә, үтә саранны юмартка әверелдерә".

Сәнгать кешене канатландыра, аның иҗади көчен үстерә.

Борынгы греклар, ди Насыйри, авырулырга да музыка тыңларга кушканнар. Аларның фикеренчә, музыка авыруларның авыртуларын, сызлануларын баскан. Кем яхшы җыр һәм соклангыч музыка вакытында бар нәрсәгә битараф калса, мондый кешенең йөрәген мүк каплаган булыр, ди Насыйри.

Ул халык җырларын халыктан язып алып пропагандалаган. Шуңа күрә дә эстетик тәрбиянең төп чыганагы итеп ул халык авыз иҗатын алган. Шулай ук ул яшьләрне төрле музыка коралларында: скрипкада, гитарада, курайда, балалайкада, кубызда һ. б. уйнарга өйрәнергә чакырган.

К. Насыйри музыка белән җыр арасындагы бәйләнешне бик яхшы аңлаган. Ул: "Әгәр кәрван музыка белән хәрәкәт итсә, дөяләр дә тизрәк һәм күңеллерәк атлый. Шуның шикелле яшьләргә дә укуда һәм хезмәттә музыка һәм җыр кирәк",— ди.

Укучыларның эстетик зәвыгын формалаштыруда әдәби әсәрләрнең дә әһәмияте зур. Насыйри халык әкиятләрен, табышмакларын, мәкальләрен бик уңышлы файдаланган.

Әгәр дә укучылар үзләре шигырьләр язсалар, бу бик файдалы. Мондыйларга К. Насыйри киңәш биреп: "Шигырьләр ачык, тирән идеяле, сүзләре аңлаешлы булырга тиеш. Чөнки алар шагыйрьнең үзе өчен генә түгел, башкалар өчен, халык өчен языла",— дигән.

К. Насыйри рәсем сәнгатенә дә зур игътибар биргән. Ул үзе рәсем ясаган, сызым сызган, укучыны да шуңа өйрәткән.

Дин буенча халык биюләре тыелса, К. Насыйри халык биюләренә зур игътибар биргән, аны бик яраткан. Балаларның биюләрен дә бик кызыксынып күзәткән һәм аларны бүләкләр белән бүләкләгән.

К. Насыйри рәсем сәнгатенә дә игътибарын юнәлткән. Ул үзе дә рәсем ясаган, сызым сызган, укучыларны да шуңа өйрәткән.

Укытучы һәм ата-аналар турында. Каюм Насыйри укытучы хезмәтенә зур бәя биргән. Укытучы — яшьләрнең остазы, ул үсеп килүче яшь буынны киләчәк тормышка әзерли; балаларның белем һәм тәрбия дәрәҗәсе, аларның характеры ничек формалашуы укытучының шәхесенә нык бәйле.

Насыйри фикеренчә, уку-укыту эше укытучыдан билгеле бер күләмдә фәнни хәзерлек, күпьяклы эрудиция, киң күңеллелек һәм түземлелек таләп итә. Үзәнең "Кырык бакча" китабында ул: "Әгәр кемне дә булса, нәрсәгә дә булса өйрәтергә телисең икән, иң элек син үзең бу эшне бик яхшылап өйрән, сиңа карап башкалар да бу эшкә өйрәнергә теләрләр",— ди.

"Тәрбия" мәкаләсендә Насыйри укытучыга мондый таләпләр куя: укытучы укучыларга һәрвакыт игътибарлы булырга тиеш; аларның психологиясен исәпкә алырга, укучыларга тән җәзасы бирмичә генә укытырга тиеш. "Укытучы баланың күңелендә үзенең әти-әнисенә, туганнарына һәм җәмгыятькә, хезмәткә һәм белемгә мәхәббәт, эшсез буш селкенеп йөрүгә һәм мәгънәсез күңел ачуларга нәфрәт тәрбияләргә тиеш" — ди ул. Яхшы укытучы үз укучыларына шундый тәэсир итә ки, алар укытучыларын гомерләре буе онытмыйлар һәм яраткан укытучылары алар күңеленә салган принциплар буенча яшиләр.

К. Насыйри укытучының сөйләменә югары таләпләр куя. Укытучының мөләем йөзле, яхшы гадәтле, оптимист булуы зур әһәмияткә ия. Насыйри яңа төр укытучы — үз эшенең остасы өчен көрәшә. Укытучы кебек изге эшкә очраклы кешеләр үтеп кермәскә тиеш. "Тәрбия" мәкаләсендә ул: "Укытучы-педагог үзен бөек эшкә, изге эшкә алынган кешеләр исәбенә кертелергә тиеш. Әгәр син укытучы һәм педагог икәнсең, укучыларыңны шулай итеп тәрбиялә ки — син биргән тәрбия укучыңа якын тормышында төп юнәлеш булсын.

Насыйри үзе дә таләпчән, җыйнак, балаларны яратучы тәрбияче буларак, башкаларга үрнәк булып тора. Ул педагогика өлкәсендә галим-теоретик кына түгел, ә бик яхшы укытучы — практик та иде. Насыйри һәр дәрескә җентекләп әзерләнә, үз эшенә бик таләпчән карый иде. Аның укучысы проф. П. Масловский үзенең истәлекләрендә К. Насыйриның бу сыйфатлары турында болай ди: "Ун баллы система буенча мин һәр фәннән 10, 9, 8 балл ала идем. 1855 елдан татар телен безгә Зөя өязе Шырдан авылы татарлары Каюм Насыйри укыта башлагач, мин 6 һәм 8 балл гына ала идем һәм бу билгеләр К. Насыйриның иң югары билгеләре иде.

Ләкин Насыйриның таләпчәнлеге нигезле һәм яхшы ниятле иде, ул укучыларның ихтыяҗларын аңлый һәм һәрвакыт аларга төрлечә ярдәм итә иде. Ул укытучыларга: әгәр нинди дә булса эш кушасың икән, нинди эш кушасыңны алдан ук уйлап куй; эш кушканда тәвәккәл бул, бер генә әйт һәм үгетләп торма,— дип киңәш бирә. Укучылары аны бик яратканнар, аны үзләренең дусты һәм остазы дип санаганнар, аңа барысы да ышанганнар.

Каюм Насыйри иң авыр шартларда да халык мәгарифенә армый-талмый хезмәт итүнең ачык мисалы булып тора. Мохтаҗлык һәм тормыш мәшәкатьләренә карамыйча, ул укытучы һөнәренә тугрылыклы булып кала. Ничектер, абыйсы Габделхәйгә ул үзенең ярлы

яшәве, ашау-эчү һәм юньле киенү өчен акча җитмәве, фатирының начар булуы һәм түбәсеннән су үтүе турында яза, ләкин мәгърифәтче үз эшеннән матди файда алу ягын гына эзләмәгән.

Насыйри балаларны җәмгыятьтә тәрбияләү ягында булса да, тәрбиядә гаиләнең роленә дә ул зур игътибар биргән.

Балалар һәм эти-әни арасында үзара аңлашу урнашкан тату гаиләдә баланың акыл, рухи һәм физик үсеше өчен уңайлы шартлар тудырыла. Әгәр дә ата-ана үзләре белемгә омтылмасалар, хезмәт яратмасалар, билгеле, балалары да, алардан күреп, белем алуга һәм хезмәткә күңел бирмәячәкләр.

Яшь аналарга киңәш бирү формасында язылган "Балаларны тәрбияләү турында" дигән тирән эчтәлекле мәкаләсендә Насыйри баланы туган көненнән алып дөрес тәрбия бирүдә ананың ролен ассызыклап күрсәтә.

Яхшы ата-аналар балаларының укытучылары белән даими элемтәдә торалар, аларны ихтирам итәләр. К. Насыйриның үзләренең балаларына белем бирүче укытучыларга үзләренең байлыклары белән масаючы, өстән көлеп караучы кайбер бай ата-аналардан ачы көлеп язган сатирик шигыре дә бар.

Ата-аналар балаларына таләпчән, игътибарлы һәм кечелекле булырга тиешләр. Насыйри, баласына артык табынып, аны сукыр мәхәббәт белән яратып, баласының һәр көйсезлеген үтәргә әзер торучы ата-аналарны кискен гаепли. Шул ук вакытта, ул балаларга эти-әниләрен, олыларны һәм картларны хөрмәт итәргә киңәш бирә. Аның кулъязма "Казан шәһәрендә яшәүчеләргә өндәмә" дигән китабында (150 якын битле) ата-аналарга түбәндәге киңәшләр бирелә: 1) балаларның тормышын оештыру; 2) кием-салым; 3) бала-ларны тәрбияләү; 4) фәннәрне үзләштерү; 5) гигиена кагыйдәләре; 6) белем алу; 7) телләрне өйрәнү методлары (бигрәк тә рус телен һәм туган телеңне); 8) мәдрәсәдәге искергән программаларны һәм укыту методларын тәнкыйтьләү һ. б. Кызганычка каршы, бу китап басылып чыкмаган.

К. Насыйри өлкәннәрне укыту мәсьәләсендә дә зур хезмәт куйган. Татар халкы арасында гомуми наданлык хөкем сөргәндә, мәктәптә генә балаларга тәрбия биреп, уңышка ирешеп булмаслыгын, өлкәннәргә дә белем бирергә кирәклеген К. Насыйри бик яхшы аңлаган.

Шул максаттан чыгып, К. Насыйри өлкәннәр өчен фәнни китаплар бастырып чыгару эшенә керешкән.

Белемнең файдалы булуын оператив пропагандалау, тормышта вакыйгаларны яктыртып бару өчен газета кирәк була. К. Насыйри татар телендә "Таң йолдызы" исеме белән газета чыгарырга тели. Ләкин патша хөкүмәте газета чыгаруга ризалык бирми. Менә шул вакытта татар телендә календарьлар чыга башлый. Календарьлар 1871 елдан 1897 елга кадәр чыгарыла. Алар күпмедер дәрәҗәдә газета-журналларны алыштырганнар. Календарьның эчтәлеге төрле темаларга караган педагогика, анатомия, физиология, гигиена, агрономия, космография, законоведение, публистика һ. б. Шуңа күрә дә К. Насыйриның бу календарьлары һәркемнең өстәл ярдәмлегенә әверелгән.

Аның календарьларының популярлыгын бер факт раслый. 1886, 1887, 1895 нче елларда аның календарьлары бастырылмагач, бик күп сораулар белән хатлар агыла башлый. Ә 1897 елда патша цензурасы календарьлар чыгаруны туктаткач, укучылар авторга үзләренең теләктәшлекләрен белдереп, кайгырып хатлар язганнар.

Семипалатинскийдан Габделкаюм Габделлатыйпович Насыйрига язган хатында: "1898 елга сезнең календарьларны чыгарырга рөхсәт бирмәүләрен белгәч, бик борчылдык. Сезнең һәр китабыгыз 100 сумнан да артыграк",— дигән.

К. Насыйриның рус, гарәп, фарсы һ. б. телләрдән татар теленә тәрҗемә иткән китапларының әһәмиятен бәяләп бетергесез. Ул, чын мәгънәсендә, тәрҗемә остасы булып танылды.

Мәгърифәтче шулай ук санитария, гигиена, медицина белемнәрен халык арасында пропагандалауга да зур көч куйды. 1885 елда чыккан календарьда "Кеше организмының хәле һәм гигиенасы" мәкаләсендә татарларның кан агызу, сөлек салдыру эшләрен тәнкыйть иткән, ә 1890 елгы календарьда тәмәкенең зарарын ачып биргән.

К. Насыйри татар тормышындагы искелек калдыкларына каршы аяусыз көрәшкән. 1888 елда "Эчкеченең хәле" поэмасын язган. Соңыннан бу китап берничә тапкыр кабат бастырылган. 1896 елда эчкечелеккә каршы плакат төзелгән. Эчкечелекнең нинди нәтиҗәләргә китерүен яхшылап аңлаткан, укучыны аракы эчмәскә, сәламәтлекләрен сакларга өндәгән.

Каюм Насыйри өлкәннәрне укытуда да күрсәтмәлелек принцибын оста файдаланган.

Аның "Чәчәкләр һәм үләннәр" хезмәтендә киң таралган 153 авыруга аңлатма бирелгән, төрле үләннәрнең дәвалау үзенчәлек-

ләре тасвирланган. Насыйриның бу хезмәте халык медицинацын өйрәнеп, рус телендәге чыганаклардан файдаланып язылган. Ул ныгыту, ярсыту, эч йомшарту, сидек кудыру, тир чыгару һ. б. дәвалау максатыннан еш кулланыла торган 192 үсемлеккә тасвирлама биргән.

1894 елда чыккан "Гәүдә әгъзаларының функциясе һәм гигиенасы законы" хезмәтендә кешенең анатомиясен һәм физиологиясен татар телендә тасвирлап биргән.

К. Насыйри төрле өлкәләргә караган китаплар бастырып чыгаруда халык массаларының соравына да зур игътибар иткән. Мәсәлән, Мөхәммәтйосыф Казаков аңа мөрәҗәгать итеп: "Акыл иясе, хөрмәтле Габделкаюм әфәнде! Сезгә үземнең сәламнәремне җибәреп, сездән хәер-фатиха көтеп калам. Әфәндем, Сезнең төрле өлкәләргә караган бик күп китапларыгызны күрдем. Һәрбер китабыгыз искиткеч файдалы һәм кирәкле. Аннан соң, әфәндем, безнең мөселман телендә техникага, һөнәрләргә караган китаплар юк. Әгәр дә бу өлкәләргә караган китаплар язсагыз, Сезнең безгә карата зур ярдәмегез, игътибарыгыз булыр иде",— дип хат яза.

Насыйри бу сорауга җавап итеп, слесарь һәм ювелир эшләре буенча ярдәмлекләр төзегән.

К. Насыйри башка авторларга да ярдәм кулы сузган. Мәсәлән, аның җитәкчелегендә Зыя Бәхтияров 1898 елда өстәл календаре һәм астрономия буенча дәреслек язган.

К. Насыйриның китапларына сорау бик зур булган. Әгерҗедән: "Хөрмәтле язучыбыз, Габделкаюм әфәнде! Сезгә күп сәламнәр җибәреп, сездән хәбәр итүегезне үтенәбез: быел чыгарырга вәгъдә иткән "Татар теле сүзлеге", "Гарәп теле кагыйдәләре" басылып чыкмадымы? Бу китапларның басылып чыгу вакытын, бәясен хәбәр итүегезне үтенәбез. Алга таба нинди китаплар чыгарырга уйлыйсыз? Әгәр дә исемнәрен хәбәр итсәгез, бик шат булыр идек. Милләт өчен файдалы китаплар язуыгызда уңышлар теләп калабыз. Әгерҗе авылы укучылары Мөхәммәтфатыйх Мансуров (икенчесенең имзасы танылмый) 2 январь 1895 ел."

Аңа Казан губернасыннан гына түгел, Пенза губернасыннан Госман Мостафилов, Астраханнан "Русча-татарча сүзлек", Верхнеуральскийдан Лотфулла Надиров, Орскидан Кәшиф Шәриповлар китап сорап мөрәҗәгать итәләр.

К. Насыйри китапларына сорау күп булганлыктан, аның китаплары кат-кат бастырылган. Мәсәлән, "Буш вакыт" китабы гына да 8

тапкыр бастырылган. Аның китаплары фәнни югарылыкта, һәркемгә аңлаешлы, бәясе ягыннан һәркем дә алырлык була. Насыйри үзенең акчаларын китап бастыруга тоткан.

Казан губернасының иң ерак авылларында китаплар тарату өчен К. Насыйри бу эшкә үзенең укучыларын, мәдрәсә шәкертләрен тарткан. Гали Чокрыйның улы Гарифулла 5 ел каникулга киткән вакытта халык арасында тарату өчен Насыйридан төргәк-төргәк китаплар алуын искә төшерә.

К. Насыйриның бу эшен күрә алмаучылар да булган, аңарга төрлечә каршы төшкәннәр, куркытканнар, янаганнар. Ләкин К. Насыйри үз алдына куйган максатыннан тайпылмаган. "Һәр уйлап табучы, новатор үзенең идеяләрен тормышка ашырганда, каршылыкларга очрый. Колумб белән Гутенбергның бәхетсезлеге һәркемгә билгеле, ләкин соңгы буын гына ал арның бөеклеген белде",— дип язды К. Насыйри,

Каюм Насыйри үзе дә яшь буынның, халыкның аны күрсәткән хезмәтләреннән чыгып бәяләүләренә ышанган.

К. Насыйри татар балалар әдәбиятына нигез салучыларның берсе булды. Ул укуны ял итүнең бер төре итеп карады һәм китапны зур бәя биреп: "Китап — ул гаҗәеп бакча, аның юллары — нәркис гөлләре",— дигән. Ул дөньяви эчтәлекле матур әдәбият әсәрләрен укырга рөхсәт итмәгән ата-аналарны шелтәләгән. Китап укыганда бала үзенең буш вакытын файдалы хезмәт белән үткәрә, фән һәм тормыш өчен кирәкле белем ала.

Иң яхшы укытучы булып китап тора. Китап — ул киңәшче, кешене күп кенә кыенлыклардан саклый, төрле эшләргә ярдәм итә. Менә шуңа күрә дә, башка танылган педагоглар шикелле, К. Насыйри да үзенең иҗади эшчәнлегендә балалар әдәбиятын булдыруга игътибар бирде.

Татар китапларын басу өчен типографияләр фәкать 1801 елда гына эшли башлый. К. Насыйрига кадәр балалар дини эчтәлекле "Кисекбаш" (1845), "Бәдавам" (1846), "Ахырзаман китабы" (1847), "Рисалаи Газизә" (1807 елда языла, 1847 елда бастырыла), "Фәзаимии шогур" (1854) һ. б. китапларны гына укыганнар, дөньяви эчтәлекле китаплар бөтенләй булмаган. Бу китаплар гарәп, фарсы, төрки телләрдән алынган сүзләр белән язылганнар, дини эчтәлеккә корылганнар. Балаларда пессимизм һәм куркыту уятканнар. К. Насыйрига кадәр балаларга класстан тыш уку өчен Салихҗан Кукляшевның "Диване хикаяте татар" (1859) хрестоматиясе

һәм Хуҗа Насретдин турында татар халык легендалары һәм мәзәкләре" (1845) генә булган.

К. Насыйри "Бакырган", "Фәзаилеш шогур", "Тук һәм ябык җен" китапларының балага бернинди дә файда бирмәгәнлеген әйткән. Мәсәлән, "Фәзаими шогур" китабында гөнаһлыларны түбә өрлегенә асып куюлары әйтелә. К. Насыйри көлеп сорау бирә: "Бу өрлек чыдатыр дип уйлыйсызмы? Әгәр дә тимер булса ул эриячәк, әгәр агач булса, ул яначак. Бу белем бирә торган китап түгел, ә чепчи ялган".

К. Насыйри үзенең беренче әсәрләрен күренекле рус педагогикасы классигы К. Д. Ушинскийның дидактик әкиятләреннән чыгып язган. Аның "Буш вакыт" китабында баланың дөньяга карашын киңәйтерлек табигать күренешләре, табигать турында файдалы мәгълүматлар бирелгән. Бу китап 1860 елда дөнья күрсә, ә 1868 елда өстәмәләр белән кабат бастырылган. Әлеге китап балалар әдәбиятының башлангычы булып тора. Китап бик күп бүлекләрне үз эченә алган: "Кеше гәүдәсе һәм йөрәге", "Яңа җир" (Христофор Колумб), "Күк йөзе", "Ераклык", "Җир", "Җир шарының әйтелеше", "һава насосы", "Һава шары", "Температураның үзгәрүе", "Су", "Яңгыр", "Бәс", "Кар", "Боз", "Кыш", "Яз , "Җәй", "Көз", "Балчык", "Кирпеч", "Пыяла", "Тоз", "Шикәр", "Күкерт", "Тимер", "Бакыр", "Болан", "Кит", "Кошлар" һ. б. һәр бүлектә К. Насыйри чынбарлыктагы фактларны китереп, табигать күренешләрен ышандырырлык аңлатып биргән.

Фәнни материалны популяр итеп аңлатып бирү өчен автордан зур көч кую таләп ителгән.

К. Насыйриның балалар әдәбиятына кергән "Тәрбия турында", "Этика турында", "Кырык бакча", "Кабуснамә" һ. б. китаплары дидактик жанрда язылганнар. Аның "Кырык бакча" (1880) китабы кыска дидактик хикәяләрдән, мәсәлләрдән, өйрәтү характерындагы такмаклардан тора, теге яки бу сорауларга җавап табарга ярдәм итә.

"Әдәбият буенча әңгәмәдәшләргә китап" (1884) хрестоматия характерында өлкәннәргә атап язылса да, бу китаптан балалар да уңышлы гына файдаланганнар. Халык шагыйре Г. Тукай да үзенең 8-9 яшьлек вакытында, бу әсәрне укып, авыл кешеләрен таныштыруын искә төшереп язган.

К. Насыйриның "Җәваһирел хикәят" китабы халык зирәклегенә, тапкырлыгына нигезләнгән, күптөрле мәсәлләр һәм хикәяләр тупланган ("Эт һәм сөяк", "Ана һәм бала", "Кыз һәм бала", "Челән һәм чыпчык" һ. б.).

К. Насыйри рус, көнчыгыш телләреннән "Кабуснамә" (1881) "Әбүгалисина кыйссасы" (1881), "Кырык вәзир кыйссасы" (1868), "Гөлрөх һәм Камәрҗан экиятләре" (1896) китапларын татарчага тәрҗемә иткән. Ул китапларны тәрҗемә иткәндә, тәрбия бирүне күз алдында тотып, текстны үзгәрткән, эшкәрткән. Аның үз фикере бигрәк тә "Кабуснамә" китабында ачык чагыла.

Укучылар арасында К. Насыйриның "Әбүгалисина" китабы зур популярлык казанды. Бу фантастик повесть К. Насыйри яшәгән чорда да 7 тапкыр басылган. Бүгенге көндә дә бу әсәрне укучылар рус һәм татар телләрендә яратып укыйлар. Китаптагы вакыйгалар укучыларның күзаллауларын үстерә, фантастик күренешләр реаль күренешләр белән үрелеп барыла, халыкның караңгылыктан, усал көчләр изүе астыннан чыгарга омтылышы чагылдырыла.

Аның "Кырык вәзир" китабы 80 новелланы үз эченә алган. Бу китап 8 тапкыр басылып чыккан.

К. Насыйриның әсәрләре халыкка аңлаешлы булган, аны яратканнар, кулдан-кулга йөртеп укыганнар. Мәдрәсәләрдә аның китапларын укырга рөхсәт итмәсәләр дә, шәкертләргә бу китаплар таныш булган.

"Әдәбият турында мәҗлесләрнең җимеше" китабы уңаеннан шәкерт М. Укмаси: "Шүрлектә никадәр китап булса да, мин татар егете бу китапларның берсен дә аңламый идем. "Йосыф", "Алма китабы", "Бакырган" китаплары миңа ят иделәр. Ә Насыйриның китабын мин кулымнан да төшермәдем, яшьләр кичәсенә дә алып бардым, анда бергәләп укый идек. Безгә бу китап рухи азык бирә иде. Егетләр Казанга барып кайттылар, ләкин бу китапны таба алмадылар. Шулай булса да, бу китаптан барыбыз да файдаланды",— дип искә ала.

К. Насыйриның балалар китабына карата таләпләре, аның үрнәкләре татар халкының балалар әдәбиятын үстерүгә нигез булып торалар.

К. Насыйри татар педагогикасының күренекле вәкиле булып тора. Аның тырыш хезмәте, ныклыгы нәтиҗәсендә татар педагогикасы, схоластик тәрбия системасын кире кагып, прогрессив педагогикага мөрәҗәгать итте. Мәгърифәтченең бөтен эшчәнлегендәге татар һәм рус халкын якынайту, татарларга рус педагогикасының демократик тенденцияләрен җиткерү кызыл җеп булып сузыла. К. Насыйри И. Хәлфин, Х. Фәезхановның мәктәп өлкәсендәге эшчәнлекләрен дәвам иттереп, татарлар өчен рус мәктәбе тибында

ана телендә укыта торган мәктәпләр ачуны, мәҗбүри рәвештә рус телен укытуны таләп итте.

К. Насыйриның һәр язган хезмәтен чордашлары зурлап бәяләделәр. Яратып укыдылар. Аның мәгърифәтчелек идеяләрен Г. Ильяси, З. Бигиев, Ф. Халиди, Г. Камал кебек язучылар күтәреп алдылар. К. Насыйриның мәгърифәтчелек эшен дәвам иттергән халык шагыйре Г. Тукай да аның әсәрләре белән тәрбияләнгән. М. Гафури, Ш. Камал, Х. Ямашев, Г. Коләхмәтов кебек татар халкының алдынгы кешеләре К. Насыйри традицияләрендә тәрбияләнеп җиткәннәр.

Вакытлар, еллар үткән саен, Каюм Насыйриның тарихи урыны, халыкка күрсәткән хезмәте, фәнгә, мәдәниятка керткән өлеше тагын да ачыла бара.

Киң эрудицияле мәгърифәтче галим Каюм Насыйриның фәннең төрле тармакларындагы күп яклы гыйльми хезмәтләре татар халкы мәдәниятенең кадерле, кыйммәтле хәзинәсе булып тарихка керде.

* * *

Унсигезенче лекция

ДЕКАБРИСТЛАРНЫҢ ПЕДАГОГИКАГА ҺӘМ РОССИЯ МӘКТӘБЕНӘ ЙОГЫНТЫСЫ

Самодержавие крепостной стройга каршы революцион көрәшләрендә декабристлар халык мәгариф эшенә зур игътибар биргәннәр. Декабристлар хәрәкәтенең программасы таләпләренең берсендә халык арасында укый-яза белүне булдыру куелган. Галимнәр һәм укытучылар эшчәнлеге артыннан хөкүмәт тарафыннан урнаштырылган бюрократик күзәтү системасын декабристлар катгый тәнкыйтькә тартканнар, патша чиновникларының илдәге мәдәният һәм фән үстерү эшен кысрыклауга һәм комачаулауга каршы кискен протест белдергәннәр.

Декабристларның яшерен оешмалары аерым декабристлар кебек, солдатлар арасында грамоталылыкны киңәйткәннәр, мәктәпләрнең солдат балалары өчен хәрби-ятимнәр бүлегенә зур йогынты ясаганнар, үзләренең утарларында крепостной крестьяннар балалары өчен, ә шәһәрләрдә ярлыларның балалары өчен мәктәпләр ачканнар. Алар халык мәктәпләренең киң челтәрен булдыруга ирешкәннәр. Аларның фикеренчә, мәктәпләр җәмгыять көчләре белән ачылып, хөкүмәт тикшерүеннән бәйсез булырга тиеш.

Бу дворян революционерлары җәмгыять үсешенә карашларында идеалистлар булганнар. Җәмгыять мөнәсәбәтләрен үзгәртеп коруда бик мөһим фактор итеп мәгарифне санаганнар. Шулай да кайбер декабристлар (П. П. Пестель һ. б.) мәгарифнең хәзерге стройдан бәйле булуын дөрес аңлау дәрәҗәсенә кадәр күтәрелеп җиткәннәр. Мәгариф һәм дөрес тәрбия өчен кирәкле шартлар булачагын алар самодержавиене һәм крепостнойлыкны бетерүдә күргәннәр.

Тәрбия кешеләрнең материаль яшәү шартлары, сәяси азатлык һәм хәзерге җәмгыять строеның үзенчәлеген чагылдыручы башка факторлар белән бәйле икәне турыдан-туры П. П. Пестель төзегән "Русская правда"да күрсәтелгән. Идарә итүне төзәтергә кирәклеге турында һәм аннан соң гореф-гадәтләр үзгәрәчәге турында әйткән Пестель.

Деспотизмнан һәм крепостнойлыктан азат ителгән яңа Россиядә барлык гражданнарның мөһим хокугыннан белем алуга хокук бу-

лырга тиеш дип санаганнар декабристлар. Яңа дәүләт хакимияте барлык халык өчен киң мәктәпләр челтәрен булдырырга һәм җәмгыять мәнфәгате буенча гаилә тәрбиясенә көн саен йогынты ясарга тиеш дип уйлаганнар алар.

Яңа тәрбия үзенең эчтәлеге буенча патриотик, халыкчан, барлык халык та үти алырлык һәм максаты буенча гражданнар гадел, үз халкын яратучан һәм барлык көчен ватанның чәчәк атуына биргән булырга тиеш. Дворян революционерлары хөкүмәтнең яшьләрдә барлык урыслыкка җирәнеп карауны, ә чит илләрне ихтирам итүне тәрбияләвенә зур ачу күрсәткәннәр. Урыс телендә халыкның бөеклеге булган ватан тәрбиясен үткәрүне таләп иткәннәр. Декабристларның берсе: "Халыкның саф күңеллеге һәм горурлыгы чит ил тәрбиясе белән бетерелүе — җәмгыять кайгысы",— дип язган.

Декабристлар укытучыларга зур җаваплы бурычлар тапшырганнар. Укытучыларга яшь буынны яңа һәм гаделрәк тормыш шартларына әзерләргә туры киләчәк.

Дворян революционерлары фикеренчә, тәрбиячеләр "гаделлектә сыналган, ватанга мәхәббәт ягыннан билгеле, халык горурлыгы белән сугарылган, чит илләр йогынтысына нәфрәтле булырга тиеш-ләр. Барлык халыкның бөек игелекләрен тасвирлап аларга карата охшарга теләүне тәрбияләнүчеләр йөрәгендә урнаштырырга тиешләр".

Дворян революционерлары балаларны укытуда алдынгы методлар куллануны кискен яклаганнар, өйрәнергә тиешле материалларны механик рәвештә хәтергә алуга, ятлауга һәм муштрага каршы чыкканнар. Укучыларга фактлар һәм күренешләр белән танышуга мөмкинлек биреп, акыл эшчәнлекләрен үзлектән эш итүне тәэмин итеп өйрәтүнең оештыруын һәм методын таләп иткәннәр.

Ялутор шәһәрендә каторганы үтеп мәктәп ачучы декабрист Якушкин: "укытучы нинди фәннән укытса да, укучыга фән төшенчәсен әзер итеп әйтми, ә оста укытып... укучының үзеннән төшендерүгә ирешә ала",— дип әйткән.

Халыкта белем күтәрү чарасы итеп декабристлар үзара укыту (ланкастер) системасын, ягъни дәресләп сыйныф буенча түгел, ә бүлекләр (дистәләр) буенча, өлкән укучыларга укытучылар тарафыннан кулланма биреп, укытуны тапшыру тәртибендә үткәрелә торган мәктәпләрне санаганнар.

Көнбатыш Европада кулланыла башлаган ланкастер системасы буенча үзара укытуны патша хөкүмәте Россиядә халык арасында

дин һәм изге язмаларны тарату исәбеннән кертергә җыенганда декабристлар халык арасында укырга-язарга өйрәтүне, белем, ә кайчакта революцион пропаганда тарату өчен үзара укыту мәктәпләрен оештырганнар. Алар халык өчен мәктәпләр оештыручы, халык арасында укыла торган уку әдәбиятын һәм китапларны чыгару белән шөгыльләнүче, укытучылар әзерләүче, укучыларга түләүсез медик ярдәм күрсәтүче "Үзара укыту училищеларын төзүче ирекле оешма" ("Вольное общество учреждения училищ взаимного обучения") исемле җитди җәмгыять оешмасын корганнар. Чынбарлыкта бу оешма декабристларның "Иминлек берләшмәсе" ("Союз благоденствия") дигәннең педагогик филиалы булган, ә берләшмә таратылгач, декабристларның "Төньяк җәмгыяте" ("Северное общество") белән якын бәйләнештә торган. Декабристлар йогынтысы буенча урыс укытучылары бу вакытта Петербургта, Киевта һәм Мәскәүдә укый-язарга өйрәтү өчен эчтәлегенә крепостнойлыкка каршы идеяләр керткән дидактик материаллар ("таблицалар") төзегәннәр. Декабристлар восстаниесе тар-мар ителгәч "Ирекле оешма" ябылган, таблицаларны юк иткәннәр, ә дворян революционерлары тарафыннан ачылган үзара укыту мәктәпләре бетерелгән.

Декабристлар восстаниесе тар-мар ителгәннән соң патша хөкүмәтенең халык мәгарифе өлкәсендә сәясәте. Декабристлар восстаниесенең сәбәбен Николай I аң-белем таратылуыннан күргән һәм бу эштә фәнне һәм мәктәпне, профессорларны һәм укытучыларны гаепләп чыккан.

1826 елда уку йортларын оештыру буенча аерым Комитет төзелгән. Мәктәп мәгарифе системасы халык аңында самодержавие-крепостной идеологиясен сеңдерерлек дәрәҗәдә сәләтле булсын өчен Комитет ашыгыч рәвештә барлык уку йортларына бертөрлелек кертергә тиеш булган. Фәннәрне укытуда хөкүмәткә каршы урнашкан барлык зарарлыкны "туктатырга, юк итәргә, аларны дингә ышану, патша һәм ватанга тугрылыклы булу һәм бурычны үтәү башлангычларына кайтару өчен кирәкле чараларны булдырырга,— дип әйткән Мәгариф министры Шишков. ...Барлык фәннәр кирәк булмаган фикер йөртүләрдән чистартылырга тиеш". Шулай да белем бирү "укучылар алырга тиешле званиеләр белән туры китерелергә тиеш".

Мәктәптә укытыла торган фәннәр һәм аларны укыту методлары, иман, законнар һәм әхлаклык турындагы төшенчәләр белән бергә укучыларны катламыннан күтәрелергә онытылмыйча, иттерүне

булдырырга тиеш, дип патша Николай I комитетка язган. Мәктәпнең төп бурычы кешене үз катламның вазифаларын үтәргә әзерләү булырга тиеш, дип күрсәткән ул.

1828 елда **"Университетлар карамагындагы гимназияләр һәм училищелар уставы"** ("Устав гимназий и училищ, состоящих в ведении университетов") исемле реакцион устав чыгарылган. Һәрбер мәктәпнең төре төгәлләнгән характер алган һәм аерым катламга ярдәмгә тартылган. Мәктәп системасының катлам үзенчәлеген ныгыту максатыннан чыгып 1804 елда кертелгән уку йортлары арасындагы бәйләнеш юк ителгән һәм мәхәллә училищелары "иң түбән хәлдәге" малайлар һәм кызлар өчен исәпләнеп, аларны өяз училищеларына әзерләргә тиеш булмаган.

Өяз училищелары дворянлыкка кермәгән сәүдәгәрләр, кәсепчеләр, мещаннар һәм шәһәрнең башка халык балалары өчен билгеләнеп, инде өчьеллык уку йортларына әйләнгәннәр. Аларда түбәндәге фәннәр укытылган: алла законы, изге һәм чиркәү тарихы, россиялеләр теле, арифметика, геометрия (стереометриягә кадәр һәм дәлилсез), география, кыскартылган гомуми һәм Русь тарихы, матур язу, сызым һәм рәсем. Физиканы һәм табигатьне укыту туктатылган, ә математика догматик рәвештә укытылырга тиеш булган. Шәһәрнең привилегиясез катлам балаларын гимназиягә керүдән аеру өчен өяз училищеларда өстәмә курслар ачарга рөхсәт ителгән. Теләгән балалар анда укуларын дәвам итеп ниндидер һөнәр алырга хаклы булганнар. Укытучыларның эшчәнлеген тикшереп бару өчен хөкүмәт дворяннарны тарткан.

Гимназияләр дворяннар һәм чиновниклар өчен билгеләнгәнлектән, университет белән бәйләнешләрен саклап калганнар. Алар университетта уку хәзерлеген бирергә, шулай ук яшьләрне белемнәрен "хәлләренә җиткерерлек итеп" тормышка чыгарырга тиеш булганнар. Гимназиядә тел-әдәбият һәм логика, латин, немец һәм француз телләре, география һәм статистика, тарих, физика укытканнар. Университетлы шәһәрләрдәге гимназияләрдә грек телен дә өйрәнгәннәр.

Шулай итеп гимназияләр классик уку йортларына әйләнеп киткәннәр. Классицизм француз буржуаз революциясе чорында барлыкка килгән идеяләргә карата үзенчәлекле реакция була.

1828 елның уставында һәм хөкүмәтнең шуннан соңгы әмерләрендә уку йортларының эшчәнлеге, анда таяк тәртибе урнаштыру артыннан күзәтүгә зур игътибар бирелгән. Патшалык барлык мәк-

тәпләрне казармага, ә укучыларны һәм студентларны солдатларга әвереллерергә омтылган. Мәктәпләрдә физик җәза куллануга рөхсәт бирелгән. Уку йортларында укучыларның һәм укытучыларның тотышларын күзәтүче ролен башкаручы чиновниклар штаты күбәйгән.

Мәктәп полициясе артуы белән бергә губерния һәм өяз чиновникларының мәгариф эшенә тыкшынуы көчәйгән. 1831 елдан соң Кавказ мәктәпләре Кавказ баш управляющие, ә себер мәктәпләре Себер губернаторы күзәтүенә бирелә. Патша полициясе өйдә укытуга һәм хосусый укытучыларның эшчәнлегенә каршы бик кискен көрәш алып барган. Гимназия яисә университет бетерү турында аттестаты булмаган, яисә остаз хокукын алуга ирешү имтиханын тапшырмаган кешеләрнең укыту эше белән шөгыльләнә алмаулары турында катгый кисәтү булган. Тәрбиянең төп бурычы патшага турылыклы гражданнар әзерләү, аллага һәм өстәге хакимияткә карата вазифалары турында укучыларга төшендерү булган.

Россия кырында патша сәясәте империягә кергән халыкларны урыслаштыруга юнәлдерелгән булган.

Православие, самодержавие һәм халыкчанлык, мәгариф өлкәсендәге сәясәтнең идеология нигезе. 1830 елдагы Европа революциясе, 1830-1831 еллардагы поляклар восстаниесе, Россия эчендә күп халыклар чуалышы нәтиҗәсе Николай I эчке сәясәтенең реакцион курсына китерә.

1833 елда халык мәгарифе министры итеп С.С. Уваров билгеләнгән. Мәгариф эшендә хөкүмәт программасын нигезләп, ул "яшьләрнең фикерләрен биләп алырга", аларда "котылуыбызның соңгы чарасы һәм ватаныбыз көченең гадел ышанычы һәм бөеклеге булган православие, самодержавие һәм халыкчанлыкның чын урыс саклавыч башлангычын" тәрбияләргә кирәклеген белдергән.

Православие, самодержавие һәм халыкчанлык башлангычларын мәктәптә укытуга кертү халык мәгариф эшчәнлегенең төп юнәлеше булып киткән. Аның гамәлгә ашуы "бозык төшенчәләр" белән, яшьләр үсешенең юлындагы "акыл плотиналарын күбәйтеп" “зиннәтле” (ягъни, киң) белемнәрне алуга омтылуны йөгәнләп бертуктаусыз көрәш буенча башкарылган.

1835 елдагы университетлар өчен чыгарылган яңа устав буенча университетларның мәктәпләрне идарә итү һәм фәнни оешмалар төзү хокукы юкка чыгарылган. Уку йортлары турыдан-туры уку округы караучыларына тапшырылган, университетларда автономия

чынлыкта беткән һәм разночинецларның университетка керүен кысрыклау чаралары күрелгән.

Патша Николай I бигрәк тә Мәскәү университетын күрә алмаган. Катгый режим булуга карамастан университетта революцион түгәрәкләр барлыкка килгән. Мәскәү университетының инспекторына махсус инструкция тапшырылган. Аның буенча студентларны полицияләрдән күзәттерү түзә алмаслык чиккә җиткән.

Халык мәгарифе министры гимназиядә белем алу күләмен озайту өчен күп кенә чаралар караган. 1844 елда гимназиянең уку планыннан статистика алынган, 1845 елда математика укыту кыскартылган. 1847 елда логика фәне бетерелгән. Уку вакытының 41% өлеше борынгы латин һәм грек телләрен өйрәнүгә киткән.

Гимназияләрдә укучыларга җәза бирү чаралары көчәйгән. 1828 ел уставы буенча физик җәза өч җәза өч кече класс укучыларына кулланылса, 1838 елдан барлык гимназистларны да җәзага тарту кертелгән.

"Дворяннар чыгышыннан булмаган яшүсмерләрне белем алудан тоткарлау өчен" 1845 елда Уваров укыту өчен түләү хакын арттырырга тәкъдим биргән. Николай I аның тәкъдимен хуплаган һәм докладына язган: "Өстәвенә уйлап карарга кирәк, разночинецларның гимназиягә керүен туктату җае юкмы икән". Патша халык массаларының белемгә омтылышына каршы көрәшне кискен көчәйтергә өндәгән.

1848 елдагы Көнбатыш Европа илләрендәге революциядән соң патша хөкүмәте мәктәпләргә репрессияләрне яудыруны яңадан көчәйткән. 1828 елда гимназияләрдә кертелгән классизм зарарлы дип игълан ителгән, чөнки Греция һәм Римның антик әдәбиятен һәм тарихын өйрәнү, анда республикача яшәү төре булганлыктан, яшьләрнең самодержавие-крепостной стройга турылыклы булуына комачаулый икән дип ачыкланган. Табигать фәнен өйрәнүгә нигезләнгән урта белем алуның реаль юнәлеше укучылар аңында материалистик идеяләр уяту мөмкинлеге хөкүмәтне куркыткан. Хөкүмәт урта мәктәпнең гомуми белем бирү үзенчәлегенә каршы көрәшү юлына баскан.

1852 елда өч типтагы гимназияләр булдырылган, һәрберсенең аерым уку планы булган: 1) борынгы телләрне өйрәнү сакланган, антик әдәбиятны өйрәнү урынына чиркәү язучыларының әсәрләрен уку кертелгән; 2) латин теле сакланган гимназияләр, ә уку фәннәренең классик циклы урынына табигать фәнен өйрәнү кертелгән,

ләкин дәлилсез тасвирлау рухында һәм табигать күренешләрен теологик аңлатмалар күзеннән үткәреп; 3) төп игътибар законнар белеме исемле курсны укытуга бирелгән гимназия, шулай ук тасвирлама — эмпирик рухында һәм юридик теорияне өйрәнүдән башка.

Реформа университетка әзерли торган урта мәктәпләр санын киметүгә китергән. Урта уку йортларында дифференциацияләнгән укыту һәм булачак белгечлеккә хәзерләү кертелгән булган. Аерым циркулярда мәктәпләр администрациясенә укытуның идеология юнәлешенә, фикерләү үзенчәлегенә, укучыларның үз тотышларына, укытучыларның һәм тәрбиячеләрнең сәяси теләктәшлектә булуларына җентекле игътибар бирергә боерылган.

Уку өчен түләү арткан, дворяннардан булмаган түбән хәлле укучыларга түләүсез уку мөмкинлеге тыелган.

Патша хөкүмәте эзлекле рәвештә мәктәпләрне дворянлык һәм монархия мәнфәгатьләренә яраклаштырган.

XIX гасырның икенче чирегендә мәктәп үсеше. Катламнар мәктәпне ныгытуга караган, халыкны санга сукмаган царизм сәясәте, барыбер үсә килгән капиталистик уклад таләпләренә яраклашырга мәҗбүр булган. Николай I нең канлы диктатурасы самодержавие — крепостной стройдан канәгатьсезләнүнең арта баруын бастыра алмаган. 1826 елдан 1834 ел эченә кадәр 145 крестьяннар чуалышы булса, елына 16 чуалышка чаклы, 1845 елдан алып 1854 ел эченә кадәр — 348, уртача елына 35 чуалыш булган. Халыкның белемгә омтылуын самодержавие үлемгә дучар итә алмаган. Монархия илдәге мәктәп эшенә киртәләр куюына карамастан, Россиядә әкрен булса да башлангыч училищелар челтәре үсә. XIX гасырның беренче чиреге ахырында 349 мәхәллә училищелар булса, 1841 елда алар 1021 гә җитә, ләкин алар күбесенчә шәһәрләрдә булганнар.

Алпавытлар кул астында торучы крепостной крестьяннар дьячокларда һәм йорт укытучыларында укыганнар. Укый-язарга өйрәткәндә, часослав укыганда хәрефләр кушу методы кулланылган. Крепостной крестьяннар авылларында мәктәпләрне помещиклар ачарга тиеш булганнар. Ләкин XIX гасырның 50 нче елларына кадәр крепостной авылларда мәктәпләр булмады диярлек. Халык мәгарифе министрлыгы крестьяннарга мәктәп оештыру турында берничек тә кайгыртмаган.

Шәһәрләрдәге мәхәллә училищеларында, бигрәк тә, Россиянең үзәк губернияләрендә яңа методлар һәм уку ярдәмлекләре кул-

ланылган, мәсәлән, укый-язарга өйрәткәндә авазларга анализ ясау, укырга өйрәтү өчен күрсәтмә әсбаплар (кисмә әлифба, әлифба лотосы, картиналы хәрефләр һ. б.).

Дәүләт һәм удел крестьяннары яши торган авылларда 30 нчы елларның башыннан дәүләт милке идарәсе һәм удел идарәсе мәктәпләр оештыра башлый. Алар алдында крестьян балаларын укый-язарга өйрәтү һәм крестьяннарны идарә учреждениеләр өчен писерләр һәм хисапчы хезмәтчеләре әзерләү бурычы торган. Бу мәктәпләрдә укучыларны әйбәт почеркка һәм телдән исәпләүгә өйрәтүгә зур игътибар биргәннәр. Арифметика дәресләрендә күрсәтмә әсбаплары булып урыс счетлары киң кулланылган. Бу мәктәпләрне крестьяннардан җыйган акчалар исәбенә тотканнар. 1842 елдан 1858 ел эченә кадәр дәүләт крестьяннары авылларында 2975 мәктәп булдырылган. XIX гасырның 40 нчы елларында алар халык өчен авыл мәктәпләренең иң күбесен тәшкил иткәннәр.

Дәүләт крестьяннары мәктәпләр белән (XIX гасырның 40 нчы ел башында Россиядә 20 миллионнан артык крестьян булган) дәүләт милке министрлыгының Галимнәр комитеты шөгыльләнгән. Чирек гасыр чамасы (1838-1862) бу комитетта халык мәгарифе комитетының өлкән әгъзасы булып күренекле җәмгыять эшлеклесе, язучы һәм музыка белгече, атаклы педагог-мәгърифәтче Владимир Федорович Одоевский (1804-1869) эшләгән. Ул хөкүмәт крестьяннарының авыл училищеларында укыту эшчәнлеген педагогик идарә итүне башкарган.

Дәүләт милке министрлыгының авыл мәхәллә училищеларында, шулай ук кайбер уку округларының (Петербуруг, Казан) мәктәпләрендә В. Ф. Одоевский төзегән уку ярдәмлекләре, уку өчен дәреслек һәм Халык китаплары кулланылган. Балаларны укый-язарга өйрәтүче бу ярдәмлекләр аларны табигать, география, тарих буенча башлангыч мәгълүматлар, тирә-яктагы эшчәнлек белән таныштырганнар, аларның акыл сәләтләрен үстерүгә ярдәм иткән, гомуми белем күләмен киңәйткәннәр. Укый-язарга өйрәтүдә хәреф кушу методы урынына Одоевский аваз методын ("Таблица складов", 1839 ел) керткән.

Арифметика өйрәтү өлкәсендә шулай ук яңа дидактик идеяләр кулланылган. Мәсәлән, 1828 елда Петербургта ачылган Баш педагогия институтының математика профессоры Ф. И. Бруссе арифметиканы укытуны балаларны телдән исәпләргә, сан үзлекләрен үзләштерергә, зурлык мөнәсәбәтләрен аңларга өйрәтү-

дән башларга тәкъдим иткән. Бруссе дәреслекләрендә укучыларны нәтиҗәләргә һәм кагыйдәләргә кадәр җиткерә алганнар, төп игътибарны математика күренешләрен төшендерүгә биргәннәр.

Кайбер гимназияләрдә урыс теле һәм сөйләм-әдәбият, тарих, әдәбият әңгәмәләре буенча язма эшләр конкурсларын үткәргәннәр. Шунда ук укучыларның яхшы эшләрен укып тыңлаганнар һәм тикшергәннәр. Ләкин яңа дидактик идеяләргә хөкүмәт органнары тарафыннан ярдәмлек күрсәтелмәгән, яхшы педагогик тәҗрибәләр гомумиләштерелмәгән һәм мәктәпләргә таратылмаган. Самодержавиенең сәяси бурычларына "муштра һәм ятлау" якынрак торган һәм ул аларны тәхетнең тыңлаучан, тугрылыклы ялчыларын әзерләү мәнфәгатьләре өчен киң рәвештә таратырга омтылган.

Илнең, промышленностьнең һәм авыл хуҗалыгының җитештерүче көчләренең үсүе профессиональ белем үсешендә берникадәр этәреш тудырган. Югары техник уку йортлары ачылган (1828 елда Петербургта технологик институт, ә 1832 елда Граждан инженерлары институты ачылган, элекке Тау һәм Урман институтлары үзгәртелгән). Губернияләрдә дәүләт урта һәм түбән авыл хуҗалыгы (Көнбатыш Европада алар гадәттә хосусый булганнар), техник һәм коммерция уку йортлары оештырылган (1839 елдан кайбер гимназияләрдә һәм өяз училищеларда техник һәм коммерция фәннәрен өйрәнү буенча реаль сыйныфлар ачылган).

Дворян булмаган яшьләргә патша хөкүмәте күбрәге практик һәм кәсеп осталыгы, һәм күнекмәләре, һәм әзрәк рәвештә гомуми белем бирүне артык санаган.

* * *

Унтугызынчы лекция

В. Г. БЕЛИНСКИЙ ҺӘМ А. И. ГЕРЦЕННЫҢ ПЕДАГОГИК ТЕОРИЯЛӘРЕ

XIX гасырның 30-40 елларында урыс прогрессив җәмгыять — демократик карашның үсешендә В. Г. Белинский һәм А. Г. Герцен зур роль уйнаганнар. Алар урыс педагогикасында дөньяга революцион-материалистик караш нигезендә революцион-демократик юнәлеш булдырганнар. Ул юнәлеш Россиянең революцион хәрәкәт мәнфәгатенә туры килгән.

В. Г. Белинскийның педагогик карашлары. Виссарион Григорьевич Белинский (1811-1848), атаклы революционер-демократ, үзенең әсәрләрендә крепостной хокукка каршы протест белдергән, крестьяннарның мәнфәгатен яклаган. В. И. Ленин тәгаенләве буенча, ул урыс социал-демократия элгәрләренең берсе булган. В. Г. Белинский даһи тәнкыйтьче булган, Россиягә бетмәслек, ялкынлы мәхәббәт йөзе белән караган, аның матур киләчәгенә нык ышанган. В. Г. Белинскийның ватанына мәхәббәте башка халыкларны хөрмәтләү белән бәйле булган. "Гомумилек хосусыйлыкта гына була,— дигән ул,— кем үзен ватанныкы дип исәпләсә, ул инде кешелек дөньясына да керми".

В. Г. Белинский идеясенең үсешендә катлаулы юл үткән. Ул башта җәмгыятьнең гадел төзелешен аң-белем таратып кына булдырырга мөмкин, дип уйлаган. XIX гасырның 40 нчы елларында революцион мәгърифәтчелектән революцион демократизмга күчкән, материалистик философия принципларын нык яклаган, дөнья үсеше турында диалектик карашлар әйткән. Какшамас материалист булгач, Белинский аңа хас булган һәвәслек белән православие чиркәвенә һәм төрле дини ышанмаларга каршы чыккан. Ул чиркәү белән тигезсезлеккә, деспотизмга, халыкны кысрыклауга нигезләнгән җәмгыять төзелеше арасында якын бәйләнеш барлыгын күрсәткән.

"Чиркәү иерархиядә торган, димәк, тигезсезлекне яклаган, хакимлеккә ялагайланган, кешеләр арасындагы туганлыкның дош-

маны һәм эзәрлекләүчесе булган, хәзер дә шундый",— дип язган ул.

В. Г. Белинскийның атеистик карашлары Н. В. Гогольгә язган мөһим хатында чагылган. В. И. Ленин ул хатны демократик матбугатта бүгенге көнгә кадәр әһәмиятен саклаган иң яхшы әсәрләрнең берсе дип санаган.

"Россия үзенең котылып калуын мистицизмда, атеизмда шагыйрьлектә түгел, ә цивилизация, мәгариф, гуманлык уңышларында күрә", дип аңлатып, Россиянең киләчәге акыл һәм гаделлек нигезендә тамырдан үзгәртеп кору белән бәйле, дигән Белинский.

Белинский сәнгать, әдәбиятны, мәгарифнең һәм тәрбиянең халыкчан булу теориясен эшләп чыккан. Шул ук вакытта даһи тәнкыйтьче официаль халыкчан теориянең эчтәлеген реакцион булуын фаш иткән, борынгы урыс көнкүрешенең консерватив терәгенә славянофиль рәвешендә баш июгә каршы чыккан. Белинский һәртөрле милләтчелеккә нәфрәт белдергән. "Кешелекне танымаган һәрбер халыкка ләгънәт төшсен",— дигән ул. Белинский кешелекне прогресска, иң яхшы җәмгыять стройга омтылучы халыклар гаиләсе дип санаган.

40 нчы елларда Белинский социалист-утопист булып киткән. Көнбатыш Европа социалист-утопистлардан (Р. Оуэннан һ. б.) аермалы буларак социализмны тыныч юл белән, халык революциясеннән башка урнаштырып булмый дип санаган. Ул үз заманында иң бөек идея юлбашчысы булган. Аның тирәсендә яңа, иркен Россия өчен көрәшүче алдынгы, кыю кешеләр берләшкән булганнар.

Тәрбиянең роле һәм асылы. Кешенең табигате тәрбия мөмкинлеген нигезли дип, заманында киң таралган карашка В. Г. Белинский кискен рәвештә каршы чыккан. Киресенчә, дип санаган ул, табигать кешеләрне мөмкинлекләр һәм сәләтләр белән юмарт бүләкли, ә сәләтсез һәм аңгыра кешеләр физик гарипләр кебек сирәк очрый. Тәрбия һәм белем алуга хокук кешенең нинди генә катламнан булса да чикләнмәскә тиеш.

А. Н. Радищев кебек кешенең җәмгыять асылы икәнен танып Белинский әйткән: "Кешене табигать китерә, ә җәмгыять үстерә һәм белем бирә". Җәмгыять барлык кешеләрне тигез тәрбия белән тәэмин итәргә, аның рухи көчләрен чыныктырырга һәм индивидуаль сәләтләрен үстерергә тиеш. Кешеләргә тигез хокук бирәчәк

социалистик җәмгыять кенә кешене һәрьяклы үсеш һәм дөрес тәрбия белән тәэмин итәчәк.

Бала үсеше һәм тәрбиянең төп нигезе турында Белинский **прогрессив педагогик карашлар** белдергән. Тәрбия процессы турында буш савытка эчтәлек тудырган кебек зурлар да баланы шулай тудыралар дип, механик күзаллама йөртүгә ул каршы чыккан. Бала тәрбияче кулында әйбер дә, уенчык та түгел дип, Белинский демократик педагогиканың балага өмет белән каравы турында, һәрбер балада яхшы яклар бар икәнен басым ясап әйткән. Тәрбияләү осталыгы аларны күрә белүдән, үстерүдән һәм формалаштырудан гыйбарәт.

Педагоглар баладагы уйдырма җитешсезлекләрне бастырырга түгел, ә балалар гаебенең сәбәбен бетерергә тиеш. Баланың тискәре гадәтләренә каршы көрәшү белән беррәттән, аларның уңай хасиятләрен һәм сыйфатларын үстерергә кирәк.

Тәрбияләү максатлары. В. Г. Белинский тәрбия эше алдында яңа, прогрессив бурычлар куйган. Тәрбиягә рәсми педагогиканың балаларны киләчәктә катлам-профессиональ бурычларны үтәргә әзерләү дип каравына каршы буларак, ул гомумкешелек тәрбияләү таләбен күтәреп чыккан "Тәрбия башлангычы баланы киләчәктә чиновник, шагыйрь, кәсепче итеп түгел, ә кеше итеп, соңыннан йә бу, йә башка итеп, ләкин һәрчак кеше итеп күрергә тиеш",— дигән ул. Тәрбия эше балада иҗтимагый хәленә, милләтенә, билгелегенә, байлыгына карамастан һәрбер кешедә булырга тиешле сыйфатлар һәм үзенчәлекләр үстерә. "Кешенең төрле эшчәнлек сферасында, иҗтимагый иерархия баскычындагы югарылыгында төп бурычы — кеше булып калу",— дигән Белинский.

Белинский әдәбиятта үзе төзегән халыкчан теориясендә балаларны туган илне ярату рухында тәрбияләргә кирәклеге турында педагогик нәтиҗә ясаган. Урыс телен һәм ватан әдәбиятын укытуны да мөһим фән итәргә кирәк. Пушкин, Крылов, Гоголь һәм Россиянең башка бөек язучылар иҗатында Белинский урыс халыкчанлыгының һәм намуслы патриотизмның ачыктан-ачык беленүен күргән. Белинский балаларда урыс халкына хас булган батырлык, тапкырлык, рух ныклыгы, эш сөючәнлек сыйфатларын формалаштырырга чакырган.

Тәрбиянең халыкчанлык идеясен Белинский "православие, самодержавие һәм халыкчанлык" теориясен яклаучыларга, урыс халкының төп сыйфатлары борынгылыкка бирелгәнлек, динчелек

һәм буйсынучанлык булырга тиеш дип санаучыларга каршы каты көрәштә саклап калган һәм үстергән.

Тәрбия максатлары турында мәсьәләгә Белинский үзенең материалистик карашлары нигезендә 40 нчы елларда ачыклык керткән.

Кешелек идеясен нык яклаган Белинский, шул ук вакытта, абстракт гуманизмга каршы чыккан. Чын гуманизм эрәмтамакларга каршы, башкаларга зыян китереп үзенә файда эзләүчеләргә каршы көрәше белән, балаларны дусларына карата ярату һәм эксплуататорларга карата нәфрәт хисендә тәрбияләү белән, кешеләрне килешсез җәмгыять төзелешенә каршы көрәшкә күтәрерлек итеп тәрбияләү белән бәйле дип санаган ул.

Белинский 40 нчы елларда чит ил беллетристларын, урыс тәрҗемәчеләрен, балалар китапларын язучыларын вәгазьләгән, хыялыйромантик идеалларны бертуктаусыз һәм аяусыз фаш иткән. "Жан-Поль Рихтердан антология" ("Антология из Жана-Роля Рихтера") исемле китапка рецензиясендә ул ироник рәвештә әйтеп уза: "Жан-Польнең барлык авыруларга да бер даруы бар — ярату".

Тәрбиянең максаты итеп Белинский иң яхшы җәмгыять төзелеше өчен куркусыз көрәшчеләрне әзерләү дип санаган. Ул җәмгыятьтә эксплуатация һәм изелү булмыйча, барлык кешеләр үзләренең ирекле илендә тигез хокуклы гражданнар булачаклар.

Мәктәп тәрбиясенең эчтәлеге һәм методлары. Белинскийның педагогик категориясенең төп фикерләренең берсе булып кешенең гармоник үсеше тора.

Физик тәрбия, дигән Белинский, балалар сәламәтлеген саклауны, дөрес яшәү рәвешен оештырып, аларның физик көчләрен, җитезлеген һәм сыгылмалыгын үстерүне, уеннар оештыруны, гимнастик күнекмәләрне башкаруны үзенең бурычы итеп куя. Ул шулай ук шәхси һәм җәмгыять гигиенасы кагыйдәләрен үтәүгә һәм кеше кеше табигате турындагы фәнни белемнәрне үзләштерүгә басым ясаган. Аның фикеренчә физик тәрбия әхлак тәрбиясе белән якын бәйләнештә үтәлергә тиеш.

"Тәрбия эшенең бер ягын да күз алдыгыздан җибәрмәгез,— дип язган Белинский,— балаларга пөхтәлек, тышкы чисталык турында, гадәтләрнең һәм кешеләр белән мөгамәләдә намуслылык һәм абруй-лык кирәклеге турында әйтеп торыгыз".

Әхлак тәрбиясе. Белинский фикеренчә, кешене — җәмгыять эшлеклесен формалаштыруның иң мөһим ягы. Әхлакый тәрбия-

ләүнең чаралары һәм юллары турында әйткән сүзләре бай һәм эчтәлекле. Тирән диалектик һәм нечкә психолог буларак, ул әхлак тәрбиясенең психология нигезләрен ачыкларга тырышкан, бу процессның катлаулы икәнлегенә педагогларның игътибарын юнәлткән, һәм бу эшкә формаль караштан сакланырга кушкан. Бу формализм үгет һәм сентенция буенча, әхлак хисләрен эстетик зәвыкларны, аңны, ихтыярны үстермичә эш иткәндә, әхлак тәрбиясенең катлаулы процессын сүз белән димләүгә әйләндергәндә килеп чыга.

Балалар башта яхшылыкны яратырга өйрәнгән. Кече яшьтәге балаларның психик яшәешнең төп ролен эмоцияләр уйный, дип күрсәткән Белинский. Шуның сәбәпле, баштан ук балаларның аңына түгел, ә хисләренә йогынты ясарга кирәк. "Хис белемнән алда килә, кем әхлак хисләрен кичермәгән, шул аны аңламас",— дип әйткән Белинский.

Бала никадәр кече яшьтә булса, шул кадәр аның тәэсоратлары һәм күзаллаулары беркатлы булалар. Шуның сәбәпле кечерәк яшьтәге балада яхшылыкка омтылыш һәм начарлыктан җирәнү тәрбияләргә кирәк.

Кече яшьтәге баланы начарлыктан ерак йөртергә кирәк, дип күрсәткән Белинский, балалар уңай үрнәкләрне күреп үсәргә тиеш. Балаларны уңай якка көчләп түгел, ә һәвәсләндереп тартырга кирәк. Күбрәге аларны өйрәтергә түгел, ә гадәтләндерергә кирәк. "Бала никадәр кечерәк булса, әхлаки тәрбиясендә шулкадәр табигыйлык булырга тиеш, ягъни барлык нәрсәгә күнектереп, һәм ашыкмыйча, табигый үсешеннән тайпылмыйча уңай хисләргә, омтылышларга һәм тотышларга күбрәге өйрәтеп түгел, ә гадәтләр нигезләргә".

Олырак яшьтәге балаларга карата ярату һәм яхшылык тәрбияләү белән генә чикләнеп булмый. Балалар акылы да хисләр кебек үсешкә ия булырга тиеш. Шуның өчен яшүсмерләрнең аңын киңәйтергә кирәк, шулай булганда яхшылыкка юл табылыр.

Белинский балаларның үсеш дәрәҗәсенә таянырга тәкъдим ясаган. Әхлак турында төшенчәләрне вакытыннан алда җиткерсәң дә, тормыш тәҗрибәсе әз булу сәбәпле, балаларда аңлы рәвештә зиһенгә алу булмаячак һәм әхлаксыз кылган эшләрен әхлак турында сүзләр белән алыштыручы кешеләр формалашачак. Ул тәрбиячеләргә балаларның башын әхлак-дидактик турында фикерләр белән, әдәпле тотышлар турында интектергәч

сөйләшүләр белән катырмаска тәкъдим иткән, югыйсә бу файдасыз һәм монафыйклыкка гына китерә, — дип дәлилләгән Белинский.

Әхлак тәрбиясендә Белинский ихтыяр көче үстерүгә, холык чыныктыруга нык игътибар биргән. Болар авырлыклардан һәм киртәләрдән курыкмыйча явызлыкка каршы, үзеңнең карашыңны саклау өчен каты көрәш алып барырга кирәк.

Өлкәнрәк яшьтә әхлак тәрбиясе акыл белеме белән берләшергә тиеш, чөнки катлаулы һәм җаваплы бурычлар тора.

Акыл белемен бирү. 7 яшьтән соң баланы даими рәвештә укыта башларга кирәк. Бу хосусый да, махсус та, яисә гадәттән тыш булырга тиеш түгел". Укыту гомумкешелекле рәвешендә үткәрелеп, булачак кешенең барлык акыл көчләрен үстерергә, дөньяга карашларын һәм аңлы фикерләрен формалаштырырга һәм нык сакларга тиеш.

Белинский үз заманындагы мәктәпне каты тәнкыйтьләгән. Анда белем бирү урыс фәненең үсешеннән нык артка калганын, дәреслекләрнең утилитар-эмпирик юнәлештә булуын күрсәткән. Укучылар күпмедер белем алырга гына түгел, ә тулыланган фәнни карашлар алырга тиеш, дип санаган ул, фән белән укыту фәннәренең, теория һәм практика аермаларын бетерүне таләп иткән.

Белинский фәнне тормышка якынлаштыру өчен җитди көрәш алып барган. Хәзерге мәктәп мәгарифе халыкның мәнфәгатьләренә һәм ихтыяҗларына туры килми, дип белдергән ул. Баланы укырга бирү — димәк аны белергә генә түгел, ә эш башкарырга, белемнәрен тормышта кулланырга өйрәтергә кирәк, дип халык бик дөрес уйлый.

Белинский дин дәресләрен үткәрүгә каршы, дөньяви мәгариф өчен, белем бирүнең дәрәҗәсен илдәге фән нәтиҗәләренең тормышын исәпкә алып күтәрү өчен көрәшкән.

Укытыла торган мөһим фәннәрдән Белинский гуманитар фәннәрне (туган телне, әдәбиятны, тарихны) санаган, чөнки алар әхлак тәрбияләүгә, кешеләрне "чын кеше итәргә" ярдәм итәләр. Шулай ук файдалы мәгълүматлар бирүне балалар өчен бик кызык булган табигый фәннәргә зур игътибар биргән. "Бу фән аларга якын, алар табигать белән адым саен танышалар, табигать балаларга ошаган".

Белинский мәктәптә балаларның активлыгына һәм мөстәкыйльлегенә нигезләнгән, яшь үзенчәлекләрен, шәхси һәвәслек-

ләрен исәптә тоткан яңа методларны куллануга зур кызыксыну күрсәткән.

Аның фикеренчә, укытуның төп юлы булып индуктив метод куллану тора. "Иң файдалы укыту системасы — анализдан синтезга күчү, мисаллардан кагыйдә булдыру". Догматик укытуга Белинский бик каты каршы чыккан.

Педагогларның балалар акылын үстермичә, укучыларның механик хәтере белән артык мавыгулары һәрвакыт Белинскийның кире кагуына дучар булганнар. Гомуми кагыйдәләрнең һәм абстракт төшенчәләрнең укытучы тарафыннан укучыларның алдында чыгарылуын таләп иткән. Шул чакта белем укучыларның аңында сакланачак, белем бирү үсмер буыннарда тирән фәнгә нигезләнгән аңлы карашлар булдырачак.

Гаилә тәрбиясе. Гаилә тәрбиясенә Белинский күп игътибар биргән. Гомумкешелек тәрбияләү бурычы җәмгыятькә генә түгел, шулай ук гаиләгә һәм ата-аналарга кагыла. Гаилә тәрбиясе балаларда кече яшьтән үк җәмгыятьчә игътибар һәм омтылыш үстерергә тиеш. Моның өчен олылар һәм балалар арасында ышанычлы мөгамәләләр урнашырга тиеш.

Ата-аналарның балаларны ярату турындагы гадәти күзалламаларны Белинский ялгыш дип санаган. Ата-аналар үзләренең балаларын еш кына инстинктив, эгоистик рәвештә, "Простакова Митрофанушканы, сарык үзенең бәтиләрен яраткан кебек" яраталар дип әйткән ул. Кешенең яратуы табигатьтә була торган югары дәрәҗәле ярату кебек булырга тиеш һәм ата-аналарның балаларны яратуында олыларның үзләрен генә сөю, эгоистик, масаючан исәпләр булырга тиеш түгел. Ата-аналар балаларда киләчәк кешене күреп яратырга тиеш, шуның өчен ата-аналарның балаларны яратуларының нигезендә үзеңне сөю түгел, ә хакыйкатьне, кешелекне ярату булырга тиеш.

Үзләренең балалары белән тәрбия эшен үткәрмичә, очраклы хәл кушуына ризалашкан ата-аналарны Белинский кискен гаепләгән. Ләкин балаларны попугайга әйләндереп, олылар әйткәнне, таләп иткәнне ялагайланып кабатларга мәҗбүр иткән тәрбия йогынтысы турында да ул начар фикердә булган. Андый атмосфера балаларның "энергиясен, ихтыяр көчен, холкын, тормышын бетерә, аларны күндәм статуяга әйләндерә, кол кимчелекләре — хәйләләп, яшерен рәвештә алдарга, котылырга дучар итә.

Бу кимчелекләрне ата-аналар һәм балалар арасында дөрес мөгамәлә урнаштырып кына бетереп була. Ул олыларның бала шәхесе белән исәпләшүенә, кешелек абруен тануына нигезләнгән. Зурлар баланың барлык яхшы ягын үстерергә, үз камилләшүенә омтылышларында ярдәм итәргә тиешләр. Белинский гаилә деспотизмын бетерүне, бурыч һәм җаваплылык хисен үстерүче тәртип урнаштыруны яклап чыккан, баланың дәрәҗәсен төшерә торган җәза куллануга каршы булган.

Крепостной гаиләдә хатын-кызлар тәрбиясенең кызларга кече яшьтән үк хатыннарның роле, җәмгыятьтә урыны турында төшендерә торган бозык күзалламалар ялгышын Белинский ачып салган. "Хатын-кыз да ир кеше кебек" дип ул малайларга һәм кызларга тигез белем бирүне хуш күргән.

Гаиләдәге әхлак тәрбиясендә балалар әдәбиятының әһәмияте зур икәнен әйтеп, Белинский балалар язучыларына җәмгыять җаваплылыгы турында күрсәткән. "Балалар китабы тәрбия эше өчен языладыр,— дип әйткән ул, ә тәрбия үзе зур эш, ул кеше язмышын хәл итә". Тормышка карашны балаларга бозык, мещан рәвешендә күрсәтүче, әхлак дигән булып әхлаксызлык турында сөйләүче китапларны Белинский ачулы мыскыллаган. Андый китапларны йогышлы кызамык һәм чәчәк авырулары кебек куркыныч дип санаган.

Балалар китабының балаларда яхшылыкны һәм яхшыны яратуны уятуын, сентенция һәм үгет-нәсихәт белән түгел, ә үзенең бөтен идея эчтәлеге белән тәрбияләвен теләгән. Белинский фикеренчә, язучы алдынгы карашларга һәм югары әхлак йөзенә ия булырга, балаларны яратырга, аларның яшь үзенчәлекләрен белергә, җанлы образлы итеп сөйли алырга тиеш.

Белинский педагогик фикерләре Россиянең прогрессив көчләренең крепостной тәрбиягә, муштра һәм ятлау мәктәбенә каршы көрәштә зур роль уйныйлар.

А. И. Герценның педагогик карашлары. Урыс революцион хәрәкәтенең бөек вәкиле, зур сәясәт эшлеклесе, бик яхшы публицист һәм талантлы язучы **Александр Иванович Герцен** (1812-1870), Белинский кебек XIX гасырның 30-40 нчы еллар вакытында урыс революцион-демократик педагогик карашның тарафдары булган. XIX гасырның 40 нчы елларда Россиянең крепостной шартларында Герцен бик югары күтәрелә алган, заманындагы бөек акыл ияләре белән бер дәрәҗәгә җиткән, диалектик материализмга

якын килеп җиткән һәм тарихи материализм алдында туктаган. Герцен мистика, идеализм, руханилар белән каты көрәшкән, "фән белән диннең берләшүе мөмкин түгел" дигән караштa торган. Крепостнойлыкның һәм самодержавиенең җан дошманы буларак, Герцен капитализмны бик шәп тәнкыйтьләгән. Ләкин буржуазия властен бәреп төшереп, социализм урнаштыручы көч үсеп килгән пролетариат булуын ул аңлап җиткермәгән. Герцен Россиянең крестьяннар оешмалары аркылы социализмга күчүе турында хыялланган.

Ләкин Көнбатыш Европа социалист-утопистларыннан аермалы буларак, яңа җәмгыять урнаштыру өчен халык революциясе кирәк дип санаган ул. Герцен Огарев белән бергә чит илдә ирекле урыс типографиясен һәм матбугатын булдырган, яшерен әдәбият тараткан, анда самодержавиегә каршы көрәшкә чакырган.

Патшаның мәктәп сәясәтен һәм системасын фаш итү. Николай I нең патшалык итүен Герцен утыз ел буена мәктәпләрне һәм университетларны эзәрлекләү дип атаган, һәм Николай мәгариф министрлыгының халык белемен күтәрүне ничек булганын күрсәткән. Герцен әйтүенчә, патша хөкүмәте "баланың тормыш юлында беренче адымын ук саклап торган һәм кадет — баланы, гимназист — яшүсмерне, студент — яшь егетне бозган. Аларның кешелеклек башлангычын аяусыз һәм бертуктаусыз таптаган, күндәмлектән башка кеше хисләренең барысыннан да, әйтерсең, җитешсезлектән, биздергән. Тәртип бозучы кеше яшьләргә җәзаны башка илләрдә җинаятьчеләрне җәзалаудан да каты биргән.

Чиркәү үзенең йогынтысын халык мәгарифенә көчәйткәннән-көчәйтә барган, мәктәпләр исә караучылар һәм поплар белән бастырылган",- дип күрсәткән Герцен. Тәрбиядә динне катыштыруга, мәктәпләрне һәм университетларны крепостной һәм самодержавие строен ныгыту чарасына әйләндерүгә ул җитди рәвештә каршы чыккан.

Революцион-демократ Герцен әйткәнчә, башбаштаклык, ирексезләү, кеше шәхесен мәсхәрәләү һәм кеше абруен санга сукмау хас булган катлам-крепостной строй балаларны бозу рәвешендә йогынты ясый. Ә гади халык иң уңай йогынты ясый. Халык нәкъ үзе урыс милләтенең яхшы сыйфатлары вәкиле, дип санаган Герцен. Халыкның яшь буыны хезмәтне хөрмәт итәргә, буш ятуга нәфрәт белән карарга, ватанны чиксез яратырга өйрәнә.

Герцен белдергәнчә, халыкта "крестьяннарның җиргә хокуклы булу", крепостной коллыкны гаделсезлеге белән гасырлар буе килешмәү, ирексезләүгә һәм башбаштаклыкка нәфрәт хисләре нык сакланган. Урыс тәрбиясенең демократик гадәтләрен самодержавие бик нык бастырса да, бөтенләйгә бетерә алмады, дип аңлаткан ул. Алдынгы профессорлар һәм укытучылар "бәйсезлек һәм башбаштаклыкка нәфрәт идеясен вәгазьләгән".

Герцен тәнкыйтькә тәрбиянең крепостной системасын гына түгел, ә ул заманда Көнбатыш Европа илләрендә һәм өлешчә Россиядә күренгән, буржуазия җәмгыятендә башланып килгән тәрбияләү системасын да тарткан.

Иске системага алмашка килә торган җәмгыять һәм хосусый тәрбия системасы да тигезсезлекне, идеалистик карашларны һәм дини күзалламаларны урнаштыруга юнәлдерелгән. Ул да комсыз эшкуарларны әзерли, балаларга мещаннарча тормышка карашны гадәтләндерә.

Герцен буржуазия педагогика һәм мәгариф системасының тискәре якларын күрсәткән.

Герцен тарафыннан Руссо һәм Оуэн педагогик теорияләрен бәяләү югары була. Герцен Руссоның һәм Оуэнның педагогик теорияләре турында әһәмиятле фикерләр әйткән. Бу теорияләрнең тарихи прогрессив әһәмиятләрен күрсәтеп, шул ук вакытта ул җитешсезлекләрен дә аңлаткан. Идеализм позициясендә торган Руссо, Песталоцци һәм башка педагоглар тараткан сентименталь — романтик идеалларындагы тәрбияләүне ул көлкегә калдырган. Аларның карашлары буенча тәрбияләнгән кеше аяусыз һәм кырыс көрәшкә сәләтле булмаячак, ә көрәшсез алдынгы идеаллар тормышка ашмаячак, дип белдергән. Герцен Руссоны балаларны тирә-яктагы тормыштан аеруы өчен, кешелек тарафыннан булдырылган акыл тәҗрибәләрен кире кагуы өчен тәнкыйтьләгән. "Әйтерсең тәрбия һәрбер кешегә тормыш мирасын бирү түгел",— дип әйткән Герцен. "Ирекле тәрбияләү" теориясенә ул кискен рәвештә каршы чыккан, балаларда кече яшьтән үк кылган эшләре өчен җаваплылык бурычын сизү, аңлылык һәм тәртип тәрбияләүне таләп иткән.

"Кем гаепле?" ("Кто виноват?") исемле романында Герцен кешелеклеккә омтылган тәрбиячеләр тарафыннан тәрбияләнгән әйбәт яшьләр кырыс крепостной чынбарлыгында үзләрен кулланууга юл таба алмыйлар, "артык кешеләргә" әвереләләр. Биредә ул гаепне

яшь кешеләрне формалаштырган һәм тәрбия биргән авыр җәмгыять шартларыннан күргән. Аның роман герое Бельтов читләтелгән тәрбия алу сәбәпле тормышта үзенә урын тапмаган. Тәрбиячеләр аны кырыс чынбарлык белән очрашудан саклаганнар һәм чынбарлыкның тискәре якларын яшергәннәр. Нәтиҗәдә алар кешелеклеккә омтылучы, ләкин "бәйләнештә булган тере вакыйгаларга төшенергә" сәләтсез, явызлыкка һәм гаделсезлеккә каршы тора алмаучы, үзенең прогрессив карашлары өчен көрәшә алмаучы кеше тәрбияләгәннәр.

Үзенең "Чынбарлык һәм уйлар" ("Былое и думы") исемле әсәрендә Герцен Роберт Оуэн тарафыннан Нью-Лэнаркта үткәрелгән иҗтимагый һәм педагогик гамәлләр турында яхшы бәя биргән, аның тәҗрибәсе социализмны утопиядә гаепләүче һәм тәҗрибәдә бернинди дә эш башкара алмаучы кешеләрнең тамагына сөяк булып кадалган, дип белдергән. Шул ук вакытта ул Оуэнның теория нигезләренең күбесе ялгыш дип санаган, "яңа тәртип урнаштыруның төп юлы — тәрбия", кеше үзе тәрбиянең һәм вакыйгаларның пассив продукты, дигән тәгълиматына каршы чыккан. Тарихта кешеләрнең актив роле җәмгыять явызлыгына һәм гаделсезлеккә каршы көрәш процессында формалаша, дип әйткән ул.

Социаль-утопистларны тәнкыйтьләүдә Герцен тарихи материализмга шактый кыная төшкән, ләкин ул эшчеләр сыйныфының җәмгыять тарихындагы үзгәртеп коручы ролен ахырына кадәр аңлап җитмәгән.

Дөньяга материалистик караш формалашуы турында. Герцен тәрбиянең төп бурычы итеп халык хәстәрендә яшәүче, җәмгыятьне килешле рәвештә үзгәртеп коруга тырышучы кешелекле, ирекле шәхес формалаштыруны санаган.

Деспотизмга һәм иҗтимагый башбаштаклыкка каршы көрәштә Герцен фәннең бик зур әһәмияте булуын билгеләгән. Халык арасында мәгърифәтне, белемне киң таратуга ирешкән. Галимнәрне кабинетлар стенасыннан фәнне чыгарып, барысына да җиткерергә өндәгән.

Мәгарифнең зур мөмкинлекләренә бәя биреп, Герцен акыл белеменә, дөньяга материалистик караш формалаштыруга күп игътибар биргән. Акыл белем күтәрүнең мөһим чарасы итеп Герцен табигатьне өйрәнүче фәнне санаган. Бу фән серле, мистик кебек күренешләрне аңлата. Табигый фәннәр дини ялгыш фикерләрнең,

хорафатларның тамырларын бетерә, чынбарлыкны дөрес өйрәнү методларын күрсәтә.

Яшь буыннарга аңлату исәбеннән Герцен ике махсус әсәр язган: "Яшьләр белән әңгәмә үткәрү тәҗрибәсе" ("Опыт бесед с молодыми людьми") һәм "Балалар белән сөйләшү" ("Разговоры с детьми"). Бу әсәрләр дөньяга карашларның катлаулы проблемаларын талантлы, популяр рәвештә тасвирлау үрнәге булып торалар. Галәмнең барлыкка килүен автор балаларга материалистик позициядән, гади һәм кызыклы формада аңлатып бирә. Фәннең ялгыш карашларга хорафат һәм юк-барга ышануга каршы көрәштә зур ролен ул ышандырырлык дәлилли һәм кешенең җаны тәненнән аерым яши ала дигән идеалистик уйдырманы кире кага.

Герцен яшьләрдә табигатьне өйрәнү буенча зур кызыксыну уятырга, тирә-якка материалистик мөнәсәбәт булдырырга, атеистик караш формалаштырырга тырышкан.

Тәрбияләүдә һәм белем бирүдә табигать фәннәренең ролен зурлап, Герцен һәр яклап гомуми белем бирү системасын яклаган. Ул гомуми мәктәп укучыларының әдәбиятны (шул исәптән антик халыклар әдәбиятын), чит ил телләрен, тарихны, беррәттән табигать белеме һәм математика белән өйрәнүләрен теләгән.

Укучыларның үзлектән фикерләү үсешенә мәгарифнең туры килергә тиешлегенә Герцен басым ясап әйткән. "Уйларны һәм хөкем йөртүләрне чәчәк салуга ошатып тагу", "хакыйкатьне әзер килеш" колакка туку кебек мәктәп эшендәге догматизмны һәм формализмны ул гаепләп чыккан. Аның фикеренчә, белем алуның нәтиҗәлелеген, укырга теләгәннәрнең өзлексез хезмәте һәм үзлектән фикер йөртүе буенча гына була ала. "Фән юлында тирләп-пешеп эшләүдән башка ысул юк",— дип яза ул.

Гомуми белем бирү, гаиләдә баланы тәрбияләү, балаларның укырга өйрәнүе һәм үзлектән белем алуы турында Герцен бик күп әһәмиятле фикерләр әйткән.

Әхлак тәрбиясе. Тәрбиячеләрнең деспотизмына һәм балаларны ирексезләвенә каршы Герцен кискен протест белдергән. Балаларга ирекле үсешне тәэмин итү өчен шартлар бирелергә тиеш. "Үз дигәнеңчә эшләүләрнең акылга яраклы өлешен тану кеше абруеның югары һәм әхлак якларын тануга тиң",— дип язган ул.

Көндәлек тәрбия эшчәнлегендә "озакка түзеп ярату таланты , тәрбияченең баланы үзенә ышандыруы, аны хөрмәт итү аның ихтыяҗын белү зур роль уйный. Әхлак тәрбиясенең мөһим шарты —

гаиләнең сафлыгы, балалар белән тәрбиячеләр арасындагы дөрес мөгамәлә.

Баланың аралашуга һәвәслеге тумыштан килгәнгә күрә, аны җәмгыятькә омтылыш һәм гадәт итеп киңәйтергә кирәк. Моңа яшьтәшләр белән аралашу, балаларның күмәк уеннары һәм бергәләп шөгыльләнүләре ярдәм итә. Балалар һәм яшүсмерләр иптәшләре белән аралашып иҗтимагый сыйфатларга, үз-үзеңне тыеп калуга, башкаларның таләпләре белән исәпләшергә, инициативалы һәм мөстәкыйль булырга өйрәнәләр.

Баланың теләген кысуга Герцен каршы булган, ләкин шул ук вакытта тәртипнең мөһимлеген онытмаган, тәртип булдыру дөрес тәрбиянең төп шарты дип санаган. "Тәртип булмаганда, тынычлап ышану да, тыңлау да, сәламәтлек саклау һәм хәтердән котылу да юк",— дип язган ул.

Гаилә һәм җәмгыять эшләренең таләпләре буенча тәрбиячеләр балаларга да билгеле таләпләр куярга һәм үтәлүен булдырырга тиеш. Әхлак тәрбиясенең максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруга ирешү өчен шәкертләрне оста идарә итә белергә кирәк.

Герценның революцион-педагогик карашлары оригиналь идеология өчен бик куркыныч булганнар, патша Россиясендә эзәрлекләүгә дучар булганнар. Тормышны үзгәртеп коруда актив катнашучы кешене әрбияләү турындагы, балаларда иҗтимагый мәнфәгать үстерү турында, тәрбиядә ирек һәм тәртип турында, шәкертләрдә дөньяга фәнни карашлар формалаштыру турында, балаларны гаиләдә тәрбияләү турында булган һәм Герценның башка фикерләре чорыбыз педагогикасы, мәктәбе һәм гаиләсе өчен дә әһәмиятен саклаган.

* * *

Егерменче лекция

А. Н. РАДИЩЕВ ҺӘМ РОССИЯДӘ МӘГАРИФ ҮСЕШЕ

А. Н. Радищевның педагогик карашлары аның үзенең материализм һәм революцион-мәгърифәт фикерләренең көчле һәм йомшак якларын чагылдыра. Кешене ул табигать әгъзасы итеп саный. Кешегә идеалистик карашка каршы чыгып, Радищев: "Кешеләрне тән төзелеше буенча башка җанварларга ошатсак та, бер үк табигать законнарына бәйле булуын күрсәтсәк тә, кимсетмибез",— дип яза. Ул күрсәткәнчә, кешенең физик һәм акыл үсеше араларында элемтә бар; аның сүзләре буенча "кешедәге акыл көчләрен тән көчләре буенча ачыклап була". Радищев тәрбиянең төп мәсьәләсе итеп, шәхес аңы югары әхлак сыйфатлары булуны, барысыннан да артык илен яраткан кешене формалаштыруны санаган. Изелгән халыкның игелеклеге өчен самодержавие белән актив көрәшергә сәләтле кеше генә чын патриот була ала дип уйлаган ул. Үзенең шундый бөек фикерләрен "Беседа о том, что сын Отечества" ("Ватан улының нәрсәне аңлатуы турында әңгәмә") дигән искиткеч әсәрендә бәян дә итә.

"Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт" дигән әсәрендә исә ул крестьян балаларының алпавытлар тарафыннан каты интегүен сурәтли. "И, Кояш,— дип өзгәләнә Радищев,— үзеңнең мул нурларыңны сибә-сибә, бәхетсезләргә дә кайгырту йөзеңне күрсәт". Крепостной строй крестьян балаларының рухи үсешенә комачаулый, аларның табигый сәләтләрен томалый, зиһенен тупасландыра дип күрсәткән ул, балаларны иҗтимагый катлауларына карамыйча тәрбияләүне таләп иткән, конституциянең мөһим пункты җәмгыять һәм хосусый тәрбиягә багышланырга тиеш дип санаган. Хөкүмәт үсеп килә торган буынның кирәкле тәрбия алуы һәм шуның аркасында баланың сәләте үсүе, аннан чын патриот, Ватанның чын улы булдыру турында кайгыртырга тиеш.

Радищев балаларны ата-ана таләбенә сукырларча буйсындыруга каршы чыга. Ата-аналар белән балаларның мөнәсәбәтләре хосусый эш түгел, ә җәмгыять эше дип күрсәтә. "Әгәр ата баласын кол итеп күрсә, ә үзенең хакимлеген закон кагыйдәсеннән эзләсә, ә улы

мирас исәбеннән генә атасын хөрмәтләсә, җәмгыятькә нинди файда? Йә тагын бер кол шундый күпләргә өстәлә, йә куенга елан урнаша..." Ата-аналарның балаларга мөнәсәбәте үзара хөрмәтләүгә, мәхәббәткә, дәлилле таләпчәнлеккә нигезләнгән булырга тиеш дип санаган Радищев; шулай булуда бөтен җәмгыять һәм һәрбер шәхес мәнфәгатьле.

"Ватанның чын улын" тәрбияләүдә Радищев белем үзләштерүгә, акыл үсешенә зур урын бирә. Заманындагы барлык алдынгы кешеләр белән бергә ватан телен фән һәм мәгариф теле итүне таләп итә. Шуның аркылы Россиядә фән, шулай ук демократик мәгариф үсешен күргән. Җәмгыять һәм табигать белемнәрен керткән мәгарифнең киң программасын төзи.

Радищев француз мәгърифәтчеләренең карашларын югары бәяләгән, шул ук вакытта аларның кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре турындагы теорияләрен җентекләп тәнкыйтьли. Кешеләр җәмгыятьтә туплангач, үз ирекләрен югалтып тигезсезлеккә дучар булганнар дип, Руссоның әйтүенә ул каршы төшә. Борынгы община строе вакытында кешеләр көчсез, килбәтсез, хәлсез, җәмгыятьтә берләшеп кенә көчле булдылар, дигән ул. Радищев катгый рәвештә: "Кеше җәмгыять тормышы өчен туган",— дип әйткән... "Әйе, кешеләр хайваннар шикелле, таркалмаслар" ("Да, человеки не разыдутся как звери"). Кешене ул җәмгыять заты, җәмгыятьтә генә үсешкә ия була ала, җәмгыять берләшмәсендә генә көч җыя ала, үз-үзен формалаштыру өчен кешеләр белән аралашуга мохтаҗ дип санаган.

Радищев Руссоның индивидуалист тәрбияләү концепциясен тәнкыйтьли, аның тарафдарларыннан көлә, аларның тәрбияләү чараларының һәм методларының, "урманнар, болыннар һәм басулар буенча элләләндерү күзалламаларының" килешсез икәнен күрсәтә, балалар табигатен артык идеальләштерүгә каршы чыга. Шул ук вакытта балаларның үзенчәлеге белән исәпләшергә өнди. "Тәрбияләү көчен танысак та, без табигать көчен аерып ташламыйбыз",— дип яза ул,— тәрбияләү табигатькә бәйле һәм аның көченә таянуы хак булып кала, ләкин табигать көчләреннән һәм тирә-яктан нинди шартларда кулланырга өйрәнү кешенең үзеннән тора".

Радищев фикеренчә, кешене формалаштыруда иң мөһиме табигый бирелмәләр түгел, ә тормыш шартлары, кешене ураган иҗтимагый факторлар.

Ябык, тирә-яктагы тормыштан аерым булган тәрбияләү-укыту учреждениеләрен тәнкыйтьләп, Радищев тәрбия оештыруның кешеләрне җәмгыятькә авыштыруда ярдәм итәргә тиешлеген күрсәткән. Җәмгыятьтән аерым торган тәрбия эшендә җәмгыять омтылышы, мәнфәгатьле һәм һәвәслекле кешеләрне тәрбияләп булмый дип санаган ул. "Федор Васильевич Ушаковның көнкүреше", "Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт" дигән әсәрләрендә, "Ватанның чын улларын" формалаштырганда деспотизм, көчләү һәм гаделсезлек белән көн саен көрәшү зур роль уйный дип билгеләгән.

Радищев үз заманындагы иң яхшы фикер ияләре арасында була. Ул XVIII гасырдагы чит ил җәмгыять карашына да йогынты ясай. Француз буржуазия революциясе вакытында Радищев бюсты Парижда урнаштырылган була. Аның "Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт" әсәре кулъязмада килеш француз Конвент эшлекләләре арасында тарала. Бу китап Лейпцигта немец теленә тәрҗемә ителә.

Радищевның йогынтысы, бигрәк тә Россиядә, революцион-демократик караш үсешендә зур урын алып тора.

XIX гасырның беренче яртысында җәмгыять хәрәкәтенең мөһим өлешен педагогик хәрәкәт тәшкил итә. 60 нчы елларда, мәсәлән, урыс прогрессив педагогикасы зур мәсьәләләр күтәреп чыга: крепостной тәрбияне кискен тәнкыйтьләү, катлам мәктәбенә каршы булу, кешене һәм шәхесне тәрбияләү өчен, хатын-кызларга белем бирү өчен көрәшү, догматизм һәм схоластикага, механик ятлауга һәм муштрага каршы чыгу, бала шәхесен ихтирам итү, дидактик мәсьәләләрне прогрессив нигезендә эшләү, халык мәктәпләренең киң челтәрен булдыруны таләп итү, югары мәктәпнең автономлыгы.

Педагогик хәрәкәт, билгеле инде, бертөрле булмый. Төрле җәмгыять юнәлешләренең педагоглары мәсьәләләрне, әлбәттә инде, үзләренең сыйныф карашлары буенча аңлатканнар.

Бу чорда педагогик тәрбия һәм тәҗрибәнең мөһим проблемаларын хәл итү максатын куйган җәмгыять оешмалары барлыкка килә. 1859 елда Петербургта педагогик җыелыш төзелә, соңыннан ул Петербург педагогик җәмгыять исемен йөртә башлый. Аның эшендә П. Г. Редкин, К. Д. Ушинский, В. Я. Стоюнин, В. И. Водовозов, Д. Д. Семенов, А. Я. Герд һәм башка күп педагоглар, методистлар катнаша.

1861 елда Ирекле икътисадый җәмгыятендә Грамота комитеты төзелә. Анда халык мәктәпләре оештыру турындагы мәсьәләләр

буенча җанлы фикер алышулар бара. Якшәмбе мәктәпләре ачылган, анда революционерлар үзләренең эшләрен алып барганнар. Эшче балалары өчен мәктәпләр, ә кайбер урыннарда — мәктәпкәчә учреждениеләр ачыла.

Бу елларда җәмгыять — педагогик хәрәкәт тәэсире астында педагогик журналистика эшли башлый; күп кенә журнал битләрендә тәрбия һәм укытуның төп сораулары буенча ялкынлы тикшерүләр алып барыла.

Әдәбият һәм сәяси журналларда тәрбия һәм халык мәгарифе мәсьәләләре дә яктыртыла. Революцион-демократик юнәлешендәге "Замандаш" ("Современник") журналында Н. Г. Чернышевскийның тәрбия һәм белем бирү мәсьәләсенә кагылышлы берничә мәкаләсе һәм Н. А. Добролюбовның "Тәрбиядә авторитет хакында", "Сыек чыбык белән бетерелгән бөтенроссия иллюзияләре" һәм башка әсәрләре ("О значении авторитета в воспитании", "Всероссийские иллюзии, разрушаемые розгами" и др.) урнаштырылган.

Тәрбиянең гомуми мәсьәләләренә 60 нчы елларның башында кайбер махсус журналларның битләре дә бирелгән. Мәсәлән, 1856 елда "Диңгез җыентыгы" ("Морской сборник") журналында Н. И. Пироговның "Тормыш мәсьәләләре" ("Вопросы жизни") исемле мәгълүм мәкаләсе бастырылган. Ул мәкалә педагогик дискуссия башланып китүенә сәбәпче була.

Н. И. Пироговның педагогик эшчәнлеге. Николай Иванович Пирогов (1810-1881) Мәскәүдә туа. Мәскәү университетын (медицина факультетын) тәмамлаганнан соң, Дерпта (Тарту шәһәрендә) профессурага хәзерлек үтә һәм медицина докторы дәрәҗәсенә диссертация яклаганнан соң, Германиядә белемнәрен камилләштерү өстендә эшли. 26 яшендә башта Дерпт университетында, ә соңыннан Петербургта медик-хирургия академиясендә хирургия профессоры була.

1854 елда Севастополь камалган вакытта Пирогов үз теләге белән "шәфкать туташлары" оешмасын булдыра һәм аның җитәкчесе итеп, фронтка җибәрелә.

Биредә, сугыш хәрәкәтләре театрында Пирогов сугышчыларның яраларын төзәтүгә барлык көчен бирә. Ул берничә мең операция ясый. Аның хирургия буенча теоретик эшләре һәм хирург буларак гамәли эшчәнлеге бөек галим, хәрби-кыр хирургиясенең атасы данын бик тә лаеклы күтәрәләр.

Пироговның 1856 елда мөһим тәрбия мәсьәләләрен яктырткан "Тормыш мәсьәләләре" ("Вопросы жизни") исемле мәкаләсе чыга.

Бу мәкалә алдынгы идеяләре белән җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә, авторын бик мәшһүр итә.

1856 елда Пирогов Одесса уку округының махсус караучысы иттереп куела. Александр II Пироговка тискәре караштa торган, аны "кызыллардан" дип санаган (Пирогов либерал гына булса да), ләкин патшаның халык мәгарифе турында кайгыртуын күрсеннәр дигән уй белән генә бу постка аны билгеләгән.

Одесса уку округын ике ел идарә иткәндә Пирогов гимназияләрнең педагогик совет дәрәҗәсен күтәрергә тырышкан, директорларга, уку йорты укытучыларына балалар белән кешелекле мөнәсәбәттә булу кирәклеген төшендергән. Одессада университет ачу эшен әзерләгән. Уку округы эшендәге либераллыгы Одесса генерал-губернаторда иркен фикер йөртүдән, хакимлекнең абруен төшерүдән шикләнү тудырган. Пирогов Киев уку округы караучысы Вазыйфасын үтәргә Киевка күчерелә. Биредә ул мәктәп эшләрен яхшыртуны дәвам иткән, укытучыларга бер-берсенең дәресләрендә булырга тәкъдим ясаган, методик эзләнүләрне хуп күргән, гимназия тәҗрибәсенә сыйныфтан тыш әдәбият әңгәмәләрен керткән, Россиядә беренчеләрдән булып Киевка зурлар өчен якшәмбе мәктәбен ачуга мөмкинлек биргән.

1881 елда Пирогов әлеге вазифасыннан азат ителгәч, Киевның прогрессив җәмәгатьчелеге аңа тантаналы саубуллашуны оештырган. Пироговны эшеннән азат итү "Россия тиләләренең Россия үсешенә каршы эшләнгән иң кабахәт эшләренең берсе",— дип Герцен "Колокол"да язып та чыга.

Хөкүмәт Пироговның тәҗрибәсен кулланырга ниятләнүен күрсәткән булып, аны чит илдәге профессурага хәзерләнүче яшьләрнең җитәкчесе итеп билгеләгән, ләкин 1866 елда бу вазифадан да мәхрүм иткән. Бөек хирург, зур галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм педагог Пирогов энергиясе тулы вакытта югалырга һәм Украинада үзенең кечкенә генә утарына урнашырга мәҗбүр булган. Анда 1881 елда вафат була.

Пироговның педагогик карашлары — катлам-профессионал мәгарифне тәнкыйтьләү һәм гомумкешелек тәрбиясе ул. "Тормыш мәсьәләләре" мәкаләсендә һәм башка педагогик әсәрләрендә Н. И. Пирогов катлам мәктәпкә һәм патша хөкүмәте яшьләрнең гомуми белем нәтиҗәсен төшереп кертергә тырышкан утилитар-профессионал өйрәтүне ашыктыруга каршы чыккан. Белем бирүнең рәсми курсына ул киң карашлы, югары әхлаклы кешене җәмгыять

тормышына әзерләргә тиеш булган гомумкешелек тәрбия идеясен каршы куйган. "Кеше булдырырга — менә нәрсәгә алып барырга тиеш тәрбия эше",— дип язган Пирогов, моның өчен һәвәслеге һәм сәләте сизелә башларлык яшькә җиткәннәрнең барысы да "бер үк әхлак-фәнни мәгарифнең нәтиҗәләре белән файдаланырга тиеш",— дип күрсәткән. Балаларның карашын тарайтучы һәм әхлак үсешен тоткарлаучы, вакытыннан алда башланучы специальләштерүгә каршы торган. "Нигә гомумкешелек белем файдасын бик тиз гамәли, берьяклы специальләшүгә алыштырырга? Гамәли чынбарлыгыгыз белән ашыкмагыз. Кешенең үзенә, эчтәлегенә өлгерергә, ныгырга бирегез",— дип, профессионал укытуның нигезе киң гомуми белем булырга тиеш икәнен күрсәтеп бирә Пирогов.

Төп идеясе гомуми кешелек мәгарифен яклауда булган "Тормыш мәсьәләләре" мәкаләсе замандашларга зур тәэсир ясаган, алдынгы педагогик җәмәгатьчелек ягыннан бәя бирүгә җәлеп иткән. Мәкаләне буржуазия-либераль дә, буржуазия-демократик тә һәм революцион-демократик матбугат та котлаган. Ләкин югары әхлаклы, мәдәниятле кешене крепостнойлыкка һәм патшалыкка каршы көрәшче дип аңлаганнар. Пирогов кеше идеалын үзенчә аңлаган, абстракт кешелеклелек рухында тәгъбирләгән.

Пирогов катлам мәктәбенә каршы булган өр-яңа мәктәп системасының проектын тәкъдим иткән. Мәктәп системасының нигезе итеп ул икееллык башлангыч мәктәпне санаган. Бу мәктәптән урта мәктәпкә барлык теләгәннәргә дә юл ачылган. Үзенең мәктәп системасын Пирогов берләштерелгән мәктәп принцибында төзегән.

Пирогов тәкъдим иткән мәктәп системасы берничә баскычтан торган, һәрбер баскычта уку вакыты ул кадәр озак сузылмаган, атап әйткәндә: икееллык башлангыч мәктәптән соң — дүртьеллык курс белән ике типтагы прогимназия (тулы булмаган урта мәктәп); аннан соң ике типтагы гимназия килә — өч ел һәм биш ел укыту дәвамлылыгы белән. Бу системаны югары мәктәп йомгаклый (университетлар һәм югары махсус уку йортлары).

Пирогов тарафыннан проекты төзелгән мәктәп системасын шундый схема белән күрсәтеп була:

Университет	Югары махсус уку йортлары
Махсус уку йортлары	Классик гимназия (уку вакыты 5 ел)
Реаль гимназия (3 еллык)	Классик прогимназия (4 еллык)
Реаль прогимназия (4 еллык)	

ЭЛЕМЕНТАР (БАШЛАНГЫЧ) МӘКТӘП (2 ЕЛЛЫК)

Урта мәктәп системасының төп урынын Пирогов борынгы телләргә (латин һәм грек телләренә), урыс теленә һәм әдәбиятка, математикага һәм тарихка биргән. Реаль уку йортына караганда, классик урта мәктәпне ул артыграк күргән, классик мәктәптә уку срогы 2 елга озаграк була. Классик гимназиянең уку планы гомуми белем бирү үзенчәлегендә торган, ә реаль гимназияләрдә гамәли (профессиональ) уку фәннәре кертелә, бу инде реаль гимназиядә бирелә торган гомуми белемне шактый озайта, өстәвенә, аның курс озынлыгы 3 ел гына (ә классик гимназиядә — 5 ел) икәнен исәпкә алырга кирәк. Классик һәм реаль прогимназияләрнең башлангыч ике классларында укыту курсы бертигез диярлек. Классик прогимназиянең III классыннан латин телен, ә IV класстан грек телен өйрәтә башлыйлар. Реаль прогимназияне бетергәннәр яисә реаль гимназия, яисә классик прогимназиянең III классына, яисә практик эшкә китәләр. Классик гимназиядән соң университетка яисә югары махсус уку йортына керергә була, ә реаль гимназияне бетерүчеләр югары махсус уку йортына гына яисә практик эшкә керә алганнар.

Ярлыларның югары белем алу мөмкинлеге булсын өчен Пирогов укыту өчен түләүне киметергә тәкъдим иткән.

Уку округы өчен төзегән циркулярларында Пирогов укытуда иске, догматик ысулларны ташлап яңа методларны кулланырга дип, укытучылар игътибарын җәлеп иткән. Укучыларның фикерләү мөмкинлекләрен уятырга, акыл сәләтләрен җәелдерергә, үзлектән эшләү күнекмәләрен булдырырга тәкъдим итә ул.

Тәҗрибәле укытучы укучылар игътибарын һәм бирелә торган уку материалларына кызыксыну уятырга тиеш, ә бу инде, Пирогов фикеренчә, укытуда уңыш казану өчен иң мөһиме.

Төп дидактик принциплар итеп Пирогов укытуның мәгънәлелеген, активлыкны һәм күрсәтмәлелекне саный.

Гимназияләрдәге педагогик советлар эшенә Пирогов шактый яхшыртулар керткән, тикшерелә торган мәсьәләләрне карауның эчтәлеген киңәйткән, дидактик мәсьәләләр буенча докладлар һәм фикер алышулар системасын керткән, укытучыларның методик эзләнүләрен һәрчакта хупларга тырышкан, укытучыларга берберсенең дәресләрендә булырга тәкъдим иткән.

Укучылардан һәм прогимназия белән гимназия җитәкчеләреннән укучылар һәм аларның өлгерешләре турында яхшы белүләрен таләп иткән, Пирогов бер класстан икенче класска күчерүне уку-

чыларның еллык өлгерешләре буенча башкарырга киңәш иткән. Күчерү имтиханнарына ул каршы мөнәсәбәттә булган, аларда очраклылык һәм формализм элементлары булгалавын белдергән.

Югары мәктәптә укытырга Пирогов зур галимнәрне тартырга тәкъдим иткән, профессорларга студентлар белән әңгәмә үткәрүне, семинарлар, просеминарлар һәм гамәли дәресләрне үткәрүне һәм студентларның үзлектән төпләп эшләүне көчәйтергә киңәш биргән.

Укучылар тәртибе проблемасы. Укыту һәм әхлак тәрбия эшендә уңышка ирешүдә мөһим шартларның берсе итеп Пирогов яхшы тәртип булдыруны санаган. Мәктәпләрдә заманында хөкем сөргән башбаштаклык, казарма режимын, балаларга карата битараф мөнәсәбәтне гаепләп һәм тәртип урнаштыруда кешелеклелекне, шәфкатьлелекне таләп иткән. Укучы гаеп эш чыгарса, педагог игътибарлы рәвештә гаеп эше булган барлык шартларны исәпкә алып, гаделлек белән аңа бәя биреп, укучының гаебен һәм җәзаның урынлы булуын гаепләнүченең үзенә аңлатып җиткерергә тиеш.

Одесса уку округындагы гимназия директорының хезмәт хисабына карата җавап булган "Балаларны чыбыкларгамы һәм башка балалар алдында кыйнаргамы?" ("Нужно ли сечь детей, и сечь в присутствии других детей?") дигән мәкаләсендә (1858) Пирогов тән җәзасын принципиаль рәвештә гаепләгән һәм чыбык куллануның педагогикага сыймавын, балада булган оялучанлыкны бетерүен, балаларны бозуын бик тә дәлилләгән һәм гамәлдән чыгарга тиеш диеп санаган.

Ләкин бу мәсьәләдә ул ахырына кадәр эзлеклелекле булмаган. Моннан соңгы 1859 елда Пирогов Киев уку округы буенча "Киев уку округындагы гимназия укучыларының гаеп эшләре буенча җәзага тартуның төп башлангыч кагыйдәләре" ("Основные начала правил о проступках и наказания учеников гимназий Киевского учебного округа") исемле циркуляр хат бастырган. Анда ул чыбыклауны принципиаль рәвештә кире какса да, ләкин гамәлдә аннан бөтенләйгә баш тартып булмый дип санаган һәм гимназияләрдә җәза бирүне педагогик совет карары буенча гына, гадәттән тыш чара итеп кенә кулланырга киңәш биргән.

* * *

Егерме беренче лекция

XIX ГАСЫРНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ ПЕДАГОГИК ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ

60-80 нче елларның атаклы педагогы И. Н. Ульянов. Илья Николаевич Ульянов (1831-1886) Әстерхан шәһәрендә "тегү цехы" мастеры гаиләсендә туа. Шулай "тегү цехы мастеры" дип, аның әтисе имана түләүчеләр катламындагы кешеләр исемлегенә гомерлеккә кертелә. Андый кешеләр патша казнасына авыр налоглар түләргә һәм башка йөкләмәләр үтәргә дучар булалар.

И. Н. Ульянов яшьтәшләре арасында киң сәләтлелеге һәм укырга көчле омтылышы белән аерылып тора. Ләкин әтисенең бик иртә вафат булуы аркасында ятим калган гаилә өчен күп эшләргә туры килә. Туганнарны карауның төп авырлыгын җилкәсендә татыган олы абыйсы Василийның бик зур кайгыртучанлыгы һәм аталарча мөнәсәбәттә булуы ярдәмендә, кече Ульянов Әстерханда (1843-1850) башлангыч мәктәпне һәм гимназияне тәмамлау мөмкинлеген ала. Аның киләчәк язмышында зур роль уйнаган гимназия директоры А. В. Тимофеев гимназия тәмамлау турындагы таныклыкта, укучы И. Н. Ульянов әйбәт тәртибе һәм "кергән фәннәрдә зур нәтиҗәлелеге белән" аерылып торды, дип яза. Яшь егеттән инде ни эшләргә ниятлисең, дип сорагач, "Казан университетына" дип катгый әйтеп салган.

Ләкин И. Н. Ульяновның югары белем алу өчен кайнар омтылыш юлында, патша крепостниклары тудырган авырлыклар килеп баскан: XIX гасырның 40 нчы елларында университетта уку өчен түләү күтәрелгән һәм "имана түләүчеләр катламыннан" булган яшь кешеләргә анда керү өчен киртәләр куелган.

Балигъ булган И. Н. Ульянов, Казан университетына гимназия белеме турында документларын гына түгел, ә шәһәр мещаннары җәмгыятеннән "җибәрү рөхсәте таныклыгы" ("отпускное свидетельство") да тапшырырга тиеш булган. Ләкин андый документ канцелярияләрнең юри тоткарлык ясавына, түрәләр ришвәтчелегенә төртелгән, озак һәм түбәнсетү процедуралары аркылы әзерлек үткән. Бертуган Ульяновларның бу киртәләрне үтәрлек көчләре булмаган.

Хезмәт ияләренең акыл хезмәте белән шөгыльләнүе юлында патшалык нинди авырлыклар куйганын чыгышы һәм халәте буенча ярлы булган талантлы егет үз тормышында кичерә. Моны Илья Николаевич бервакытта да онытмый.

Үзенең тырышлыгы һәм максатчанлыгы, олы абыйсының кайгыртуы, Әстерхан гимназия педагогларының юллавы, Казан уку округы караучысының ярдәмчесе Н. И. Лобачевский теләктәшлеге аркасында И. Н. Ульянов керү имтиханнарын уңышлы биреп, Казан университетына кабул ителә. Имана түләүче кешегә тиешле документларның барысы да булмау сәбәпле, халык мәгариф министрлыгы Ульяновны казна (хөкүмәт) хисабына укучылар санына кертүне кире каккан. Студент И. Н. Ульяновка репетиторлык белән шөгыльләнергә һәм абыйсының ярдәменә таянырга туры килгән. Тик соңыннан гына, укуындагы уңышлары һәм Н. И. Лобачевскийның юллавы аркасында, ул үз хакына тулысынча тиешле булган стипендиясен ала башлаган.

Дөньяга танылган атаклы галим Н. И. Лобачевский җитәкчелегендә булган һәм үзенең укытучыларының прогрессив юнәлеше белән аерылып торган Казан университеты И. Н. Ульяновның җәмгыять, фәнни һәм педагогик карашлары формалашуга зур йогынты ясый. Бу карашларының моннан соңгы үсеше гасырның икенче яртысында илне самодержавиедән, крепостной тәртипләрдән, төрле хорафатларның зарарлы йогынтысыннан, халыкның караңгылыгыннан һәм наданлыгыннан коткару өчен Россиянең чын патриотларының революцион көрәшенең көчәюе белән билгеләнә.

Казан университетын тәмамлагач, 1854 елда И. Н. Ульянов урта уку йортларында математиканы һәм физиканы укыту хокукына имтиханнар тапшырган һәм ул вакытта Казан уку округы караучысының ярдәмчесе булган Н. И. Лобачевскийдан Пенза дворяннар институтында математика һәм физика укытучы вазифасын үтәү өчен эшкә билгеләнгән.

1855 елда 1869 ел буена кадәр И. Н. Ульянов бу фәннәрне башта Пенза дворяннар институтында (1855-1863), ә соңыннан Түбән Новгород дворяннар институтында һәм гимназиядә (1864-1869) укыткан. Педагогика мәйданында Ульянов табигать фәннәре, педагогика һәм методика өлкәсендә үзен югары квалификацияле белгеч, яшьләрне бик әйбәт тәрбияләүче, әһәмиятле җәмгыять башлангычларының инициаторы итеп күрсәткән. Ләкин патшалыкның официаль рәвештә урта мәктәптә табигать белемен кимсетү һәм классик белемне тагу курсы белән ризалашмау сәбәпле, ул урта уку йортларында укыту эшен калдырырга мәҗбүр булган.

1869 елда исә И. Н. Ульяновка Халык мәгарифе өлкәсендә чын мәгънәдә педагогик эшчәнлеген дәвам итү мөмкинлеге бирелгән.

Бу чакта халык мәгарифнең яңа тармагын — халык училищеларының инспекциясен төзегән Халык мәгарифе министрлыгы, Казан уку округы җитәкчелегенең үтенече буенча, 1869 елда И. Н. Ульяновны югары дәрәҗәле эш урыннарына башта инспектор (1869-1874), ә соңыннан Сембер (хәзер Ульяновск) губерниясендәге халык училищеларының директор вазыйфаларына (1874-1886) күчергән.

16 ел буенча халык мәгарифенең җитәкчесе булып ару-талусыз, нәтиҗәле эшчәнлегендә, күп җәфа чиккән, халык алдында бурычын башкару дип аңлаган И. Н. Ульянов мәдәният ягыннан артта калган Сембер губерниясен мәгърифәт өлкәсендә алдынгыларга әйләндергән. Халык мәгарифе эшлеклесе буларак, И. Н. Ульянов турында, ул "бөтен Россиягә билгеле", дип әйтә торган булганнар.

И. Н. Ульянов бик иртә, 55 яшькә кадәр яши алмыйча, вафат була. Халык мәгарифе эшенә, катып калганлыкка һәм томаналыкка каршы көрәшкә ул үзенең бөтен көчен һәм талантын биргән.

И. Н. Ульяновның Пенза һәм Түбән Новгород уку йортларында укытучы буларак педагогик эшчәнлеге. И. Н. Ульяновның педагогик эшчәнлеге Россиядә беренче революцион ситуациянең үсә барган елларында (1859-1862) башлана һәм революцион хәрәкәтнең икенче чорында җәелеп китә.

Бу чорның башлангыч елларында революцион хәрәкәт Н. Г. Чернышевскийның һәм аның катнашуы буенча төзелгән "Җир һәм ирек" ("Земля и воля") исемле революцион оешма җитәкчелегендә бара. "Җир һәм ирек" катлаулы, киң җәелдерелгән түгәрәкләр, үзара ярдәм җәмгыяте, кассалар, китапханәләр һ. б. ш. системаларыннан торган. Бу системага актив рәвештә укытучылар, бигрәк тә югары уку йортларындагы элекке студентлар тартылган. Ул елларда югары уку йортларында студентлар хәрәкәте гөрләп торган.

1855 елда Пенза дворяннар институтында математика һәм физика укытучысы вазыйфаларына керешеп, И. Н. Ульянов бирелә 50 нче еллардагы демократик күтәрелеш һәм аңа тыгыз бәйләнгән 60 нчы еллар хәрәкәте идеясеннән чыгып уку процессын яңача төзергә омтылучы, дус эшләүче прогрессив укытучыларга юлыккан.

Бу педагоглар, Ульянов урнашкан әдәби сүз укытучысы В. И. Захаров фатирында, кичләрен җыела торган булганнар. Биредә үк институтта тәрбияләнүчеләрнең кайберләре дә яшәгәннәр.

Алар арасыннан "Җир һәм ирек" оешмасы белән бәйләнештә булган "Ишутинецлар җәмгыяте" ("Общество ишутинцев") төзегән Н. И. Ишутин һәм аның туганнан туган энесе Д. М. Каракозов булганнар. Д. М. Каракозов соңыннан Александр II патшага һөҗүм ясауны оештыручы буларак билгеле булып киткән.

В. И. Захаров яшьләргә зур йогынты ясый алган, чиновникларның берсе тасвирлаганча, ул "тәрбияләнүчеләргә сәяси рәвештә тәэсир итә белгән". Захаров янындагы җыенда яшьләрнең күңеленә хуш килгән "Замандаш" ("Современник") журналын укыганнар (бигрәк тә җәмгыять көрәшенә чакырган мәкаләләрне йотлыгып укыганнар), шулай ук Герценның "Чаң" ("Колокол") журналын, Некрасовның кулъязма төрендә таратыла торган шигырьләрен, Полежаев, Огарев, Радищев әсәрләрен өйрәнгәннәр. 1862 елда Чернышевскийның "Нәрсә эшләргә?" ("Что делать?") дигән романын берләшеп укыганнар. Бу романны автор тоткында чакта язган, ә Н.А. Некрасов "Замандаш" журналында тиз генә бастырып чыгарган була.

Җыелышларга килә торган укытучылар, ә алар арасында И. Н. Ульянов та була, тәрбияләнүчеләргә ул вакыттагы давыллы вакыйгаларның мәгънәсен аңлатканнар, югары җәмгыять идеалларын формалаштырганнар, интеллигентларның халык алдындагы бурычлары турында кат-кат әйтеп килгәннәр, крепостной тәртипләрне, чиновникларның законсызлыкларын фаш иткәннәр.

И. Н. Ульянов табигать фәннәре өлкәсендә бик укымышлы белгеч икәнен, эчкерсез кеше эшчәнлеге, тотышы һәм әхлак йөзе белән коллегаларына һәм тәрбияләнүчеләргә үрнәк бирүче, тыйнак һәм тактлы педагог буларак үзен бик тиз таныта.

Н. И. Лобачевский кушуы буенча ул Пенза институтында метеорологик станция һәм искиткеч мәһабәт физик кабинет төзегән. Станциядә даими рәвештә һәм квалификацияле күзәтүләр алып борган. И. Н. Ульяновның файдалы эш башлап җибәрүе институттагы уку-укыту процессын яхшыртырга, физика буенча гамәли дәресләр алып барырга, математика укытуда теорияне тәҗрибә белән бәйләнешкә кертергә, укучыларга программада күрсәтелгән материалны тирән һәм аңлы рәвештә үзләштерергә мөмкинлек биргән. Институтның тикшерү актларының берсендә И. Н. Ульянов турында түбәндәгечә язылган була: "Үзен бик яхшы педагог дип таныткан Ульянов, чынлап та яхшы укытучылар арасында тиешле урын алып тора. Тәрбияләнүчеләр белән аның йомшак һәм ягымлы мөгаләмәсе, һәрчак тыныч һәм акыллы такты укучыларны үзенә

тартып тора һәм теләкле рәвештә шөгыльләндерә. "Зур түземлек белән" ул көчсез һәм аз белемле укучыларны укытылырга тиешлене үзләштерүгә кадәр җиткерә".

Үзенең укыту һәм фәнни эшен И. Н. Ульянов җәмгыять эшчәнлегендә 60 нчы еллардагы иҗтимагый-педагогик хәрәкәт таләпләре һәм аның алдынгы җитәкчеләре — демократ революционерлар Добролюбов һәм Чернышевский идеяләре рухында актив катнашу белән берләштерергә омтылган.

В. И. Захаров, И. Н. Ульянов, А. В. Тимофеев һәм башка актив педагогларның тырышлыгы нәтиҗәсендә, Пензада җәмгыять акчасына китапханә — уку бүлмәсе ачык булган. Көчле энтузиазм белән эш итеп В. И. Захаров һәм И. Н. Ульянов, Россия эшчеләре өчен уку йортларының беренчеләреннән итеп, мастеровойлар өчен якшәмбе мәктәбе булдыра алганнар. Мәктәп бик тиз абруй яулап алган. Укучылар саны 40 тан 120 гә чаклы арткан.

Мәктәп оештыручылары үзләренең эше өчен бернинди түләү алмасалар да, мәктәпне кысынкы бинадан гимназиянең төзек бинасына күчерә алганнар. Бу эш җирле түрәләрнең бик зур канәгатьсезлеген тудырган.

Прогрессив педагоглар якшәмбе мәктәбе өчен материалистик идеяле уку программалары төзегәннәр.

Программалар Халык мәгарифе министрлыгы тарафыннан расланмаса да, эшчеләр өчен мәктәптәге уку процессы укучыларга фәнни белемнәр һәм алдынгы карашлар бирүгә юнәлдерелгән була.

Шулай да илдәге хәл бик кискенләшкән. 1861 елның җәендә Петербург, Мәскәү, Казан университетларында, ә элек Пенза мәктәпләрендә укыган яшьләр, студентлар чуалышында актив катнашканнары өчен, үз шәһәрләренә куып кайтарылганнар. Алар арасында Захаров, Ульянов һәм башка алдынгы педагогларның укучылары күп булган.

Моннан элегрәк, патшаның крестьяннарны бушату турындагы 1861 ел указына протест белдереп, Пенза губерниясенең Кандеевка авылында крестьяннарның беренче восстаниесе кабына. Патша хөкүмәте аны көчкә бастыра. Бу вакыйгалар йогынтысы һәм куылган студентларның агитациясе буенча гимназия һәм институт укучыларының консерватив педагогларга каршы чыгышлары көчәя.

Җирле хакимият прогрессив педагогларга каршы һөҗүмгә күчә. Губернатор аларны эш урыннарыннан кууны таләп итә башлаган. В. И. Захаров педагогик эшчәнлегеннән куылган А. В. Тимофеев

Түбән Новгородка дворяннар институты һәм гимназиясе директоры итеп җибәрелә. Соңыннан ул В. И. Захаровны һәм башка укытучыларны урнаштыра алган.

И. Н. Ульянов, 1863 елда алдынгы табиб Мария Александровна Бланк кызына өйләнеп, Түбән Новгородка күчерүләренә ирешкән.

1864 елның башында А. В. Тимофеев һәм И. Н. Ульянов инициативасы буенча, педагогиканың һәм халык мәгарифенең теоретик һәм гамәли мәсьәләләрен хәл итү өчен Түбән Новгородта җирле педагогик җәмгыять төзү турында Мәгариф министрлыгына үтенеч әзерләнгән булган. Җәмгыять әгъзаларының һәр еллык керемнәре исәбенә шәһәр педагогик китапханәсен төзү уйланылган булган. Имин булган һәм акылга ятышлы бу инициатива, кызганычка каршы, министрлыкта хупланмаган.

70 нче елларда Россиянең уку округларында мәктәпләр өчен яңа уставлар проектлары буенча фикер алышу башлана. Казан уку округларының җитәкчеләре берничә урта уку йортлары булган очракта бу мәктәпләрнең укытучылары берләшкән педагогик советлар төзергә тәкъдим иткән. Түбән Новгородта шундый коллегияле педагогик берләшмә төзү турында А. В. Тимофеев күрсәтмә алган. Түбән Новгородның берләштерелгән педагогик советы берникадәр вакытта 60 нчы еллардагы прогрессив идеяләрне саклый һәм үстерә алган. Совет секретаре булып сайланган һәм аның рухы булып киткән И. Н. Ульяновның роле бу эштә зур була, әлбәттә.

Совет утырышларында укучыларның дәреслекләр белән үзлектән эшләүләре турында, "критик һәм догматик рәвешендә" укыту методлары һәм күрсәтмә ысуллар белән укыту турында, әдәбият дәресләренең эчтәлеге турында, күп санлы проблемалар буенча кызу фикер алышулар булган.

Педагогиканың һәм дидактиканың мөһим мәсьәләләре, шул исәптән, укытучылар һәм укучылар мөгаләмәләре турында, мактау һәм җәза бирү турында мәсьәләләр фикер алышу аркылы үткәрелгәннәр.

Математика һәм физика буенча өстәмә темалары, химик элементлары кертелгән яңа уку программалырын совет үзе төзегән һәм раслаган. Институтта һәм гимназиядә табигать — математика фәннәрен укыту дәрәҗәсен күтәрергә ярдәм иткән бу.

Берләшкән педагогик советның барлык эшчәнлекләрендә дә И. Н. Ульянов бик тә актив катнашкан. Аның чыгышлары һәм тәкъдимнәре җентекләп уйланылган һәм нигезләнгән булганнар,

алар буенча тәрбияләнүчеләрне яхшы белү, аларга бертигез илтифатлы мөнәсәбәттә булу, һәркемгә ярдәмгә килергә омтылыш сизелеп торган.

Бу вакытта Идел буендагы иҗтимагый хәл шактый катлауланган. Хөкүмәткә каршы торган зур фетнә ачып салынган. Фетнәне тикшерү Түбән Новгородка кадәр сузылган булган.

Вакытында институт һәм гимназиянең кайбер укытучыларында тыелган материаллар табылган: Добролюбов хатлары, Герцен портреты, Языковның ирек турында шигырьләре, төрле язмалар; берничә укытучы кулга алынган, тоткында аларның икесе үлгән. В. И. Захаров качып йөрергә мәҗбүр була. Аның педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүен бөтенләйгә тыйганнар. Укытучыларны якламакчы булган А. В. Тимофеевка тикшерү эшләренә тыгылмаска боерылган. Тиздән ул директор вазифаларыннан азат ителгән һәм Казанга күчерелгән. Патшаның үз күрсәтмәсе буенча аның урынына үтә реакционер кеше утыртылган. Ул педагогик советның рәисе булып киткән. Бу шунда ук совет составының һәм эшчәнлек характерының үзгәрүенә китергән.

Тимофеев эш урыныннан алынгач, И. Н. Ульяновка дворяннар институтын калдырырырга туры килә. Ул гимназия укытучысы булып кала. Ләкин гимназиядә белем бирүгә хөкүмәт тарафыннан кертелгән яңа юнәлеш И. Н. Ульяновның иҗтимагый һәм педагогик карашларына кискен каршы килә. Түбән Новгород гимназиясе — ә ул анда укытучы булып эшләгән — мәктәпләр өчен яңа устав нигезендә классик гимназиягә әверелгән. Анда борынгы ике тел кертелгән, ә элегрәк И. Н. Ульянов төзегән һәм уку процессына керткән математика һәм физика буенча уку процессына кирәксезгә әйләнгәннәр. Математика һәм физиканы укытуның эчтәлеге һәм ысуллары тулысынча үзгәрергә зарурилана. Табигый фәннәр укытуны христиан дине белән бәйләнешкә кертергә кирәк булган.

Судка кадәр һәм суд тикшерүләре барышы күрсәткәнчә, "Каракозов эшендә" катнашучыларның күбесе революцион оешманы тәшкил иткәннәр. Оешма хөкүмәткә каршы баш күтәрү максатыннан крестьяннар арасында аң-белем тараткан. Оешма белән Н. И. Ишутин идарә иткән. Турыдан туры җинаять билгесе булмаганга күрә прогрессив педагоглар Хакимият тарафыннан суд җаваплылыгына тартылмасалар да, Түбән Новгородта педагогик эшләрен алып барудан мәхрүм ителгәннәр.

И. Н. Ульянов бу шартларда укыту эшчәнлеген калдырырга һәм бары тик халык мәгарифен оештыру мәсьәләләре белән шөгыльләнергә мәҗбүр булган.

И. Н. Ульяновның кызы Анна Ильинична әтисенең бу карары турында болай язган: "Хәзер И. Н. Ульяновка иң мохтаҗлар өчен, белем алуы бик кыен булганнар өчен, кечәге колларның балалары өчен, ягъни крепостной әсирлектән котылган крестьян балалары өчен... эшлисе калды".

Казан уку округы идарәсенең прогрессив өлеше ярдәмендә һәм анда эшләгән А. В. Тимофеевка карата И. Н. Ульянов үзенең күркәм ниятен тормышка ашыра алган. 1869 елда ул Сембер өязендә халык училищелар инспекторы итеп билгеләнгән.

И. Н. Ульяновның 1869-1886 еллардагы инспектор һәм Халык училищелары директоры вазыйфаларында педагогик эшчәнлеге. 1869 елның ноябрендә И. Н. Ульянов хатыны һәм кече балалары Анна һәм Александр белән Сембергә килә һәм халык училищелар инспекторы вазифасын башкарырга керешә. Башлангыч училищелар турындагы положение нигезендә И. Н. Ульянов, инспекторларның иң яхшысы буларак, Сембер губерниясенең халык училищелар директоры итеп билгеләнгән.

И. Н. Ульяновның үз алдында куйган максатының мөһиме — мәктәпләрне матди карамакта тотуның авыр бурычларыннан халыкны азат итеп, бу бурычларны земство һәм хөкүмәткә йөкләтеп, крестьяннар дөньясында мәктәпкә һәм укытучыга хөрмәт булдыру, аннан соң, мәктәпләрнең укыту-тәрбияләү эшен, укытучыларның гомуми белем һәм махсус педагогик әзерлеген һәрьяклап яхшырту. Сембер губерниясендә И. Н. Ульянов халык мәгарифенең тирән реформасын үткәрергә тели дә инде.

И. Н. Ульянов эшчәнлегенең төп юнәлеше шундый була: авыл мәктәпләренең ныклы матди базасын булдыру һәм алар өчен махсус мәктәп биналарын төзү; реаль белемнәрнең мәктәп курсын киңәйтү, крестьян мәктәпләренең бурычларын, эчтәлеген һәм ысулларын үзгәртү; укытучыларның матди хәлен яхшырту, укытучыларны әзерләү һәм аларның белемен күтәрү системасын булдыру; халык мәгарифе учреждениеләрен фәнни нигездә тикшерү һәм алар белән идарә итү системасын эшләп чыгу. Мәктәп тарафыннан крестьян халкының өлкән буыны белән мәдәни-мәгърифәт эшен алып баруына И. Н. Ульянов күп игътибар бирә.

Җирле реакционерлар белән өзлексез көрәше аркылы И. Н. Ульянов үзенең программасын максатчан һәм җаваплы рә-

вештә алып бара. Аның 16 ел буе инспектор һәм директор эшчәнлеге вакытында Сембер губерниясендәге халык училищеларының саны 450 гә җиткән, укучы малайларның һәм кызларның гомуми саны ике тапкыр арткан.

Шушы еллар эчендә Идел буендагы урыс булмаган мордва, чуваш, татар халыкларының мәктәпләр челтәре яңадан төзелгән.

Җирле консерваторлар бу халыкларны укырга, үзләренең милли мәдәниятен булдырырга сәләтсез дип санаганнар; шовинистик максатлардан чыгып, аларны православие рухында дини тәрбияләүгә ирешкәннәр, балаларны туган телләрендә укытуга ризасызлык белдергәннәр. Боларның барысына да каршы И. Н. Ульянов килешүсез көрәш алып барган. Аның актив катнашуында, чуваш халкының мәгърифәтчесе И. Я. Яковлев белән бергә, чуваш укытучылар мәктәбе оештырылган.

Чувашлар арасында белем таратуда, мәгърифәт һәм мәдәният үстерүдә, алар арасыннан белемле һәм үз халкына тугрылыклы укытучылар әзерләүдә бу мәктәп зур роль уйнаган, әлбәттә.

Укытучыларның матди хәлен яхшыртуга, аларның белем һәм педагогик осталыгын үстерүгә И. Н. Ульянов күп көч куйган; аның тарафыннан укытучылар әзерләү һәм аларның белемен күтәрү өчен нәтиҗәле система төзелгән булган.

1869 дан 1873 ел эченә кадәр И. Н. Ульянов халык укытучылар педагогик курсының өч чыгарылышын уздырган. Курслар укытучылыкның укмашуына, аларны башлангыч авыл мәктәпләрендәге укыту-тәрбияләү эшенең прогрессив принциплар белән таныштыруга ярдәм иткәннәр. И. Н. Ульянов курсларда табигать белемен укыткан, үрнәк дәресләр биргән, курсантларга эш тәҗрибәсе турында доклад әзерләргә булышкан, иң яхшы укытучыларның дәресләре буенча фикер алышуны оештырган.

И. Н. Ульяновның халык училищелар директоры эшен башлап җибәргәндә, училище дирекциясе оешканда һәм И. Н. Ульяновның иң якын фикердәшләреннән инспекторлар саны арткан чакта, губерниядә өяз укытучылары съезды үткәрелгән.

И. Н. Ульянов бу съездларны эшлекле рәвештә хәзерләгән, укытучыларга доклад темаларын сайларга, идея, фәнни-педагогик юнәлешләрен билгеләргә ярдәм иткән. Мәсәлән, 1874 елда икенче съездан укытучы Малеевның "Аңлатмалы укуны үткәрү турында" ("О ведении объяснительного чтения") исемле докладында халык мәктәбенең максатлары һәм бурычлары турында мәсьәләләр кер-

телгән булган: "Мәктәпкә бик мөһим бурыч куела: файда бирмәгән тормыш шартлары белән көрәшкә әхлакый омтылыш бирергә... укучының барлык рухи якларын үстерү бурычы куела... көчле рухлы кеше әзерләргә һәм аны билгеле белемнәргә төшендерергә".

Революционер-демократларның мәктәп белеменә карата тәгъбир иткән максат юнәлтелешенә якын бу төп фикер И. Н. Ульянов — эшчәнлегенең программа юнәлеше булган, И. Н. Ульянов тарафыннан оештырылган һәм рухи яктан формалаштырган укытучыларны беркеткән.

1874 елда патша хөкүмәте укытучылар съездларын үткәрүне тыйган. Съездлар сәяси яктан зыян китерәләр, ә педагогик яктан файдасыз, янәсе.

И. Н. Ульянов укытучылыкка һәм мәктәпкә ярдәм күрсәтү формаларын яңадан эзләп тапкан. Горецкий авылында 1873 елда үзе ачкан укытучылар семинариясендә ул укытучыларның җәйге курсларын үткәргән. Укытучылар съездларында һәм элекке курсларда ирешкән тәҗрибә әһәмиятен биредә дә саклап калган.

И. Н. Ульянов тормышының Сембердәге чоры педагогик эшчәнлегендә шактый нәтиҗәле һәм көч таләп иткән булган. Бу чорда И. Н. Ульяновның оештыра белү таланты бөтенләйгә җәелеп киткән, халык мәгарифенә тулысынча бирелгән тугрылыгы, Россиянең революцион-демократик педагогикасына хас булган халыкка һәм крестьян балаларына мәхәббәте беленгән.

И. Н. Ульяновның энергияле, фидакарь эшчәнлеге, инспектор һәм директор эшенең төгәл үтәлүе, крестьяннар белән элемтә урнаштыра белүе, тирә яктагы прогрессив кешеләрне халык мәгарифе эшенә тартуы ярдәмендә Сембер губерниясе халык мәгарифендәге уңышлары буенча беренчеләрдән булып китә дә инде.

Күренекле земство эшлеклеләренең берсе Николай Александрович Корф (1834-1883) була. Земство мәктәпләре һәм алардагы укыту, тәрбияләү эшләрен яхшырту өчен ул күп эш башкарган. 1867 елда Корф земстводан Александровск өязе (элекке Екатеринослав губерниясе) әгъзасы итеп, ә соңыннан бу советның председателе итеп сайланган. Аның энергиясе һәм җитәкчелеге ярдәмендә Александров өязендә (элекке Александровск, хәзер Запорожье) 40 тан артык земство мәктәбе ачылган. Аның тарафыннан земствоның өчьеллык типтагы мәктәбе төзелгән. Дәресләрне анда бер үк укытучы берьюлы өч сыйныфта алып барган. Корф андый дәресләрнең җентекле планын эшләтеп чыгарган, башлангыч укытуның зур ме-

тодисты булган. "Александровск өязендәге училищелар советы отчетлары" белән, методик китаплары һәм статьялары белән, "Безнең дус" ("Наш друг") исемле сыйныфта уку китабы белән башка губернияләрдәге земство мәктәпләренә дә Корф уңай йогынты ясаган.

1872 елда Корфның земство эшчәнлеге тукталган: халык мәгарифе буенча аның либераль эшчәнлеге белән земстводагыларның риза булмаган өлеше сайлауда аны үткәрмәгән.

XIX гасырның икенче яртысында башлангыч мәктәпнең күренекле педагогы Николай Федорович Бунаков (1837-1904) булган. Земство мәктәбе үсешенә ул зур йогынты ясаган, башлангыч укытуның методикасына шактый өлеш керткән. Рус теле буенча теоретик-методист һәм башлангыч мәктәпнең гамәли хезмәткәре буларак, XIX гасырның 70-80 елларында берничә губерниядә ул укытучыларның җәйге съездлары һәм курслары белән идарә иткән, аларны алдынгы педагогик идеяләр пропагандалау өчен кулланган. Укытучылар арасында Бунаков зур абруйга һәм мәхәббәткә ия булган.

Н. Ф. Бунаков Ушинскийның педагогик карашлары юлыннан баручы булган. Ушинскийның дидактик һәм методик тәкъдимнәре нигезендә ул җентекле рәвештә аңлатмалы укуның методикасын эшләп булдырган һәм камилләштергән.

Аның "Туган тел, өчъеллык курслы башлангыч мәктәптә укыту фәне буларак" ("Родной язык, как предмет обучения в начальной школе с трехгодичным курсом") исемле методик эше, шулай ук "Әлифба һәм уку дәресләре" ("Азбука и уроки чтения") укытучылар арасында ифрат яхшы билгеле булганнар.

Бунаков укырга өйрәтүнең авазлы аналитик-синтетик методы ягында торучы һәм гомуми белем бирү идеясын дәртле яклаучысы булган.

1884 елдан Бунаков Воронеж губерниясендә Петин авылында үзенең зур булмаган утарында үз акчасына башлангыч мәктәп төзегән һәм балаларны үзе укыткан. Мәктәп каршында китапханә булдырган. Аннан крестьяннар да файдаланганнар, "могҗизалы фонарь" кулланып укулар, урыс язучыларына багышланган кичәләр оештырганнар. Зурлар өчен гомуми белем мәктәбе эшләгән.

Бунаков Россиядә крестьяннар үзешчән театрларының беренчеләреннән берсе оештыручы булган (1888). Бунаков җитәкчелегендә Петин мәктәбен тәмамлаучылар арасыннан драма кружогы оешты-

рылган булган. Аның репертуарына урыс һәм чит ил классик әсәрләр кертелгән (А. Н. Островский, Л. Н. Толстой, А. С. Пушкин, Н. В. Гоголь, Мольер һәм башкаларның әсәрләре).

Авыл халкы арасындагы педагогик һәм мәгърифәт эшчәнлеге өчен Бунаков, башка күренекле педагог-мәгърифәтчеләр кебек, репрессиягә тартыла. Эчке эшләр министры боерыгы буенча 1902 елда Бунаковка педагогик һәм мәгърифәт эшчәнлеге белән шөгыльләнү тыела. Аның тарафыннан булдырылган мәктәпләр һәм мәдәният-мәгариф учреждениеләре полиция тарафыннан ябыла, ә Бунаков үзе Петиннан Воронеж губерниясендәге шәһәрләрнең берсенә полиция күзәтүенә куела.

Бунаковның педагогик һәм мәгърифәт эшчәнлеге мәгариф һәм халык мәгърифәте эшенә фидакарь хезмәт итү үрнәге булып тора. "Искра" газетасы (1902) Н. Ф. Бунаковның прогрессив карашларына һәм эшчәнлегенә зур бәя биреп яза.

Урта мәктәп педагогикасын һәм методикасын эшләп булдыручылардан XIX гасырның 70-80 елларында бик танылган педагоглар В. Я. Стоюнин, В. И. Водовозов, В. П. Острогорский, А. Я. Герд булганнар.

Владимир Яковлевич Стоюнин (1826-1888) урта мәктәптә К. Д. Ушинскийның идеалларын, бигрәк тә халыкчанлык принцибын кулланырга, аны Пироговтан алынган гомумкешелеклек идеясе белән берләштерергә омтылган, "һәрбер халык тәрбиясендә,— дип язган Стоюнин,— гомумкешелеклек юнәлеше белән бергә үз халыкчанлык юнәлеше өлеше булырга тиеш. Ул барысын тере иттерүче рухны тәшкил итә". Стоюнин урыс халкы тарихын, көнкүрешен һәм психологиясен исәптә тотучы урыс педагогикасын төзүне хуплаган, халык мәгариф министрлыгының урыс халык милли традицияләрен һәм яшәү шартларын белмәгән чит ил реакцион педагогларга киңәш сорап мөрәҗәгать итүенә ачу белдергән.

Стоюнин бик бөек методист булып санала. Әдәбият укытуга үзенең хезмәтләре белән күп әһәмиятлелек керткән. Укытуда формаль юнәлешкә каршы көрәш алып барып, Стоюнин, әдәбиятның укыту фәне буларак, бигрәк тә тәрбияләү ролен күтәреп чыккан.

Василий Иванович Водовозов (1825-1886) К. Д. Ушинскийның юлыннан баручы һәм эшен дәвам иттерүче искиткеч педагог булган. Ушинский Смольный институтыннан куылгач, Водовозов ризасызлык белдерү йөзеннән отставкага китә.

"Халык мәктәбендә укыту фәннәре" ("Предметы обучения в народной школе") исемле китабында Водовозов башлангыч укыту методларының психологик нигезләрен иншаллаган, һәм уку-язу белән арифметикага өйрәтүне дөрес кую турында әһәмиятле күрсәтмәләр биргән. Ул "Халык мәктәпләрендә башлангыч уку китабын" ("Книга для первоначального чтения в народных школах") төзегән. Ике өлештән торган бу китап уннарча-уннарча мең данәләрдә таралган. Китап укучыларга география, тарих, Россиянең табигате һәм промыселлары турында киң белем биргән.

Урта мәктәптә классицизмның өстенлеккә куелуына Водовозов ризасызлык белдергән һәм төп уку фәннәре итеп урыс телен һәм әдәбиятны тәкъдим иткән. Әдәбият укыту методикасында зур гражданлыкны, җәмгыятьчелекне һәм патриотизмны тәрбияләү чарасын күргән. Водовозовның бу юнәлештә "Яңа урыс әдәбияты" ("Новая русская литература") һәм "Нәфис сүз мисалларда һәм тикшерүләрдә" ("Словесность в образцах и разборах") кебек бөек хезмәтләре төзелгәннәр. Водовозовның "Урыс тарихыннан хикәяләр" ("Рассказы из русской истории") киң танылуга ия булганнар.

Виктор Петрович Острогорский (1840-1902) урыс теле һәм әдәбияты буенча методист буларак, эстетик тәрбияләү мәсьәләләрен эшләгән. Толстой — Делянов хакимият мәктәбе эстетик тәрбиягә бернинди дә игътибар бирмәгән (1871 елдан уку планында рәсем һәм җыр дәресләре бөтенләй дә булмаган) дип, ул гадел күрсәткән. Острогорскийның "Эстетик тәрбия турында хатлары" ("Письма об эстетическом воспитании") педагоглар арасында зур популярлыкка ия булганнар.

Александр Яковлевич Герд (1841-1888) исә табигать белеме буенча зур методист була. Дарвинизм рухында табигать белемен укыту методикасын һәм дәреслеген эшләве бик әһәмиятле саналган. Башлангыч мәктәп өчен ул "Предметлы дәресләр" ("Предметные уроки") төзегән. Күрсәтмәлелекне киң файдаланып, балаларны табигать белән таныштыралар алар... Урта мәктәп өчен аның "Табигать белеменең кыска курсы" ("Краткий курс естествознания), "Кошлар аныклатмасы" ("Определитель птиц"), "Минераллар аныклатмасы" ("Определитель минералов") һ. б. зур әһәмияткә ия булганнар.

* * *

Егерме икенче лекция

БӨЕК ПЕДАГОГ К. Д. УШИНСКИЙ

Константин Дмитриевич Ушинский (1824-1870) Тула шәһәрендә туа аның балачагы элекке Чернигов губерниясенә кергән Новгород-Северский янында урнашкан ата-аналарының зур булмаган утарында үтә.

Новгород-Северский гимназиясен тәмамлагач, Ушинский Мәскәү университетының юридик факультетына укырга керә, аны 1844 елда бик уңышлы тәмамлый, 22 яшендә Ярославль юридик лицеена камераль фәннәре (хокукны, хуҗалык турында фән элементларын, финанс хокукын, дәүләт хокукын кертқән гомуми төшенчә) буенча профессор вазифаларын үтәргә билгеләнә.

Ләкин ике елдан соң ук лицей студентлары арасында "тәртипсезлекләр" булу сәбәпле, Ушинскийның уңышлы башланган профессорлык эшчәнлеге бүленә һәм ул үзе 1849 елда алдынгы фикер карашлары өчен профессорлар арасыннан куыла. Аннары Ушинский эчке эшләр министрлыгында кече чиновник булып хезмәт итәргә мәҗбүр була, ләкин чиновник хезмәте аны канәгатьләндерми. Әлеге хезмәте турында үзенең көндәлекләрендә ул җирәнеп бәя бирә. Тик чит ил журналларында басылган мәкаләләр, рефератлары, материаллар, күзәтү буенча инглизчәдән тәрҗемәләрне "Современник, "Библиотека для чтения" ("Уку библиотекасы") журналларында урнаштыру эше генә аңа нindидер канәгатьләндерү китергән.

1854 елда Ушинский Гатчина ятимнәр институтына башта укытучы, соңыннан инспектор эшенә билгеләнә. Ул анда укыту һәм тәрбияләү эшенең тормышын шактый яхшырткан.

Иҗтимагый-педагогик хәрәкәте башланышы тәэсире буенча Ушинский 1857-1858 елларда "Тәрбияләү журналында" ("Журнал для воспитания") берничә мәкалә: "Педагогик әдәбиятның файдасы" ("О пользе педагогической литературы"), "Иҗтимагый тәрбия эшендәге халыкчанлык турында" ("О народности в общественном воспитании"), "Мәктәпнең өч элементы" ("Три элемента школы") һ. б. урнаштырган. Бу мәкаләләр аңа дан — шөһрәт китерә, әлбәттә.

1859 елда Ушинский Смольныйның асылзат кызлар институтының инспекторы итеп билгеләнә. Патша сарае белән элемтәдә торган бу учреждениедә патша хатынының якын даирәсе һәм фаворитлары алдында ялагайлану һәм ярарга тырышу халәте хөкем сөрә. Кызларны христиан әхлагы шулай ук ир хатыны һәм ана вазифалары турында ялгыш күзалламалар рухында тәрбияләгәннәр, аларга реаль белемне бик әз биргәннәр, ә күбрәге дөньявилык манарасын, патшалык алдында табынуны гадәтләндерү турында кайгыртканнар.

Реакцион педагогларның каршылыгына карамастан, Ушинский кыюлык белән институт реформасын үткәргән, урыс телен, урыс әдәбият әсәрләрен, табигый фәннәрне, төп предметлар итеп яңа уку планына керткән, укытуда киң рәвештә күрсәтмәлелек кулланган, биология һәм физика дәресләрендә тәҗрибәләр үткәргән. Укытучылыкка Ушинский күренекле педагог-методистларны чакырган: әдәбият буенча — В. И. Водовозовны, география буенча — Д. Д. Семеновны, тарих буенча — М. И. Сельевскийны һәм башкаларны. Тәрбияләнүче кызларны файдалы хезмәткә хәзерләү өчен җиде сыйныфлы гомуми белемгә өстәп ике еллык педагогик сыйныф кертелгән. Шушы ук вакытта Ушинский тарафыннан түбән сыйныфларда укыту өчен булган һәм табигать белеменә кагылган күп материаллар туплаган "Балалар дөньясы" ("Детский мир") (1861) исемле ике кисәктән торган урыс теле буенча хрестоматия дә төзелә.

1860-1861 елларда Ушинский "Халык мәгарифе министрлыгының журналын" ("Журнал министерства народного просвещения") редакцияли. Ул аның программасын тәмам үзгәрткән, коры һәм кызыгы аз булган рәсми идарә органы булган фәнни-педагогик журналга әверелә.

Шул елларда "Халык мәгарифе министрлыгы журналында" Ушинский үзенең берничә педагогик мәкаләләрен урнаштыра: "Хезмәтнең психик һәм тәрбияләү мәгънәсе" ("Труд в его психическом и воспитательном значении"), "Туган тел", ("Родное слово"), "Укытучылар семинариясе проекты" ("Проект учительской семинарии").

Реакция һөҗүменнән файдаланып, институт җитәкчесе һәм Ушинскийдан кудырылган укытучылар аны эзәрлекләүне көчәйткәннәр, алласызлыкта, тотнаксыз фикерлелектә һәм сәяси ышанычсызлыкта гаепләгәннәр. 1862 елның җәендә ул Смольный инсти-

тутыннан куыла. Ушинскийны законсыз чыгаруны сиздермәскә тырышып, патша хөкүмәте аны чит илгә хатын-кызлар мәгарифен өйрәнү өчен озак командировкага җибәрә. Бу командировканы ул үзе гадел рәвештә яшертен сөргенгә тиңләгән.

К. Д. Ушинский чит илдә берничә илдәге хатын-кызлар мәгарифен, Швейцариядә башлангыч укыту тормышын өйрәнгән, сыйныфта уку өчен "Туган тел" ("Родное слово") (1864-1870) исемле искиткеч китап һәм аңа методик кулланма төзегән, "Кеше тәрбия карашында педагогик антропология тәҗрибәсе" ("Человек как предмет воспитания "Опыт педагогической антропологии" (т. 1-2. 1867-1869) һәм бу зур һәм мөһим хезмәтнең өченче томына материаллар җыйган.

Бик каты авыру буларак, көче беткәнен сизеп, Ушинский мөмкин кадәр күбрәк эшләп калырга тырыша. Россиягә кайткач (1867) ул озак яшәми һәм 1870 елда 47 яшендә вафат була. Үзенең кыска гына гомерендә Ушинский бик күп эш башкарган. Ул яшүсмер вакытында көндәлегендә язылган хыялын тормышка ашырган: "Үз ватаным өчен мөмкин кадәр күбрәк файда китерергә — минем тормышымда бу бердәнбер максат һәм мин менә аңа барлык сәламәтемне юнәлдерергә тиеш".

К. Д. Ушинский педагогик системасының фәлсәфи нигезе. Фәлсәфи үсешендә Ушинский идеализмнан материализмга күтәрелгән, ләкин бу юлы төгәлләнмичә калган. Төрле фәлсәфи системаларын яхшы үзләштереп, бу системаның уңай якларын уйлап файдаланып, ул дөньяга үзлектән үзенең оригиналь карашын булдырырга тырышкан.

Табигатькә карашында исә Ушинский Дарвинның эволюцион тәгълиматын хуп күргән. Танып белү теориясендә һәм психологиядә материалистик элементлары күп булган. Метафизик, коры фикерләүгә нигезләнгән, абстракт психология системаларына, (мәсәлән, Гербарт системасы), капма-каршы буларак, Ушинский психологияне физиология нигезендә төзергә тырышкан. Ләкин мәгърифәтчеләрнең күбесе кебек җәмгыять үсешенең этәргеч көчләре дип акылны, идеяне танып, иҗтимагый мәсьәләләрдә ул идеалистик карашларда торган. Материалистик сенсуализм карашларыннан чыгып үзенең башлангыч эшендә үк, "Камераль белем турында" ("О камеральном образовании") дигән речендә язган: "әйбернең бердән-бер критериумы булып аның турындагы безнең төшенчәбез түгел, ә әйбер үзе тора".

60 нчы елларның икенче яртысында, реакция һөҗүмгә күчкәч материализм турында уңай итеп телгә алуга, әз генә яклауны белдерүгә дә хөкүмәт даирәләре дошманнарча караганнар, эзәрлекләү күрсәткәннәр. Ушинский курыкмыйча, материалистик фәлсәфә "фәнгә һәм фикер йөртүгә күп уңайлык бирде һәм бирә тора; соңгы вакытта тикшеренүләрдә өстенлек иткән материалистик юнәлешләргә, бигрәк тә тәрбияләү осталыгы, гадәттән тыш күп бурычлы",— дип белдергән.

Байтак мәсьәләләр буенча Кантны һәм Гегельне тәнкыйтьләп, К. Д. Ушинский Гербарт психология теориясенең абстрактлыгын, уйдырмалыгын белдергән. Ләкин материалистик фәлсәфәдән ул канәгатьләнү тапмаган, материализм үзенең "Гегелен көтә әле" дип санаган. Шул заманда шактый киңәйгән тупас материализмга ул бик тискәре караштa торган. Кешенең тирә-якка яраклашу нәтиҗәсендә һәм организмының җайлануы аркасында киләчәктә канатлары үсеп чыгачак дип санаучы фәлсәфәчеләргә (аерым алганда, Спенсерга) да каршы торган. Ул болай язган: "Кешенең куәте — аның пар машиналары, аның тизлеге — паровозлар һәм пароходлар, ә кешенең канатлары үсүе һәм киң таралуы аэростат очуын ниятле идарә итәргә өйрәнгәч булачак". Бу сүзләр аэропланнар булганчы ярты гасыр элек әйтелгән иде.

"Хезмәтнең психик һәм тәрбияләү мәгънәсе" дигән мәкаләсендә Ушинский җәмгыять каршылыкларын игълан итәрлек дәрәҗәгә күтәрелгән: "Һәртөрле мөстәкыйль производство өчен капиталның һаман күбәйтелү ихтыяҗы арта бара; мөстәкыйль производстволар саны кими бара; бик тә зур фабрика меңләгән кечерәкләрен йота һәм мөстәкыйль хуҗаларны көнлекләп эшләүчегә әйләндерә; бераү симезлегеннән ахмаклана, икенчесе хәерчелектән кыргыйлана, берәүне байлык һәлакәтлеккә китерә, икенчесе чиктән тыш хәерчелек машинага әверелдерә..." Ләкин җәмгыять каршылыкларының коточкыч күренешен үткен сүзләр белән тасвирлап, капитал туплану фактларын һәм эре производстволар белән конкуренциягә түзә алмыйча вак производстволарның җимерелүен дөрес бәяләп, үзенең сыйныфлар турында карашларының тар булуы аркасында бу каршылыкларның сәбәбен ачыклый алмаган, җәмгыятьнең сыйныфлар төзелешен һәм сыйныфлар көрәшен аңлау дәрәҗәсенә кадәр күтәрелмәгән, димәк, җәмгыятьнең бу каршылыкларын бетерү юлларын күрә алмаган.

Шул ук мәкаләсендә Ушинский тик ятуны фаш иткән һәм хезмәтне югары бәяләгән, байлыкларны нәкъ хезмәт булдыра дип

күрсәткән, ләкин җәмгыять һәм кеше үсешендәге хезмәтне бәяләүдә ул идеалистлар карашында торган.

Крепостной хокукның җимерелүен Ушинский кайнар сәламли, ирекле Россия турында хыяллана, ләкин бу үсешләрнең булуы революция юлы белән түгел, ә тыныч рәвештә хәл ителер дип санаган. Сәяси карашлары буенча Ушинский буржуазия демократы бул-ган. Халыкның дәүләт белән идарә итү хокукын таныган.

Ушинский христиан динен (аерым алганда, православиене) әхлак һәм тәрбия нигезе дип санаган, халык мәктәпләренең мөдирләре һәм укытучылары итеп изге аталарны куярга тәкъдим иткән, мәктәпне "чиркәү алды" дип санаган.

Тормыш азагында һаман дини кеше булып калса да, ул фән белән динне төгәл аерган. Шул вакытта болай язган: "Чынындагы һәрбер фән — ә башка фәнне без белмибез — һәр диннән аерым тора, чөнки ышануларга түгел, ә фактларга таяна..."

Үзенең соңгы әсәрләрендә, мәсәлән инде телгә алынган "Кеше тәрбия карашында" исемле өченче том әсәре өчен материалларда, кешенең төп сыйфаты итеп Ушинский кешеләрне яратуны саный, хәтта кешеләргә кешелекле мөнәсәбәттә булган атеист якындагы ярату хисенә җитәрлек бирелмәгән дин тотучыдан күбрәк христианлы дип ышандыра.

"Халык өчен безнең мәктәпләрнең барлыкка килүенә гомуми караш" исемле мәкаләсендә (1870) халык мәктәпләренең иң яхшы укытучылардан изге аталар булалар дигән үзенең элекке карашын Ушинский кире каккан һәм ул заман өчен шактый батыр рәвештә язган: "Чиркәү мәктәпләре идеясы безнең халыкта да руханилар арасында да тамыр җибәрә алмады... чиркәүләр каршында мәктәпләр төзергә омтылуда... ниндидер ясалмалык булды һәм уңай нәтиҗәләр булмады... Крестьяннар үзләре крестьяннар мәктәбенә укытучылар итеп мәхәллә руханиларын билгеләнүгә каршы фикер әйтәләр һәм кайчакта шактый кискен рәвештә".

К. Д. Ушинский педагогик фән һәм тәрбия осталыгы турында. Ушинский педагогика теориясен төзер алдыннан тәрбия карашындагы кеше турында фәнни тирән белемнәр белән коралланып, киң белемле фикер иясе булып җиткән иде.

Педагогика теориясе анатомия, физиология, психология, фәлсәфә, тарих һәм башка фәннәргә нигезләнергә тиеш дип күрсәткән Ушинский. Бу теория педагогик рецептлар белән чикләнмичә, тәрбия законнарын ачыкларга тиеш. Заманындагы педагогика аңа бик таныш булган.

Коры фикерләргә нигезләнгән кабинет педагогика теориясен кире кагып, Ушинский һәммә педагогикадагы эмпиризмны булдырмаска кирәклеген кисәтә. Тәрбия эшендә уңышка ирешүгә карамастан шәхси тәҗрибәгә нигезләнү генә җитми дип, бик тә гадел күрсәтә. Ул теория һәм гамәл бердәмлеген таләп иткән. "Бер нәрсәгә дә нигезләнмәгән буш теория, әйтерсең, яраксыз әйбер булып китә, бернинди дә фикер таба алмаслык, йә алдан, йә соңыннан идея бирмәгән фактка яисә тәҗрибәгә әйләнә. Теория чынбарлыктан кача алмый, факт фикерсез була алмый",— дип язган Ушинский. Теориясез педагогик тәҗрибәне ул медицинадагы имчелеккә тиңләгән.

Педагогикага принципларны һәм тәрбия эшенең конкрет кагыйдәләрен үзләштерү җитми, аңа кеше табигатенең төп законнары турында белем белән коралланырга һәм аларны һәрбер конкрет очракта куллана белергә кирәк дип бик дөрес дәлилләгән ул. "Әгәр педагогика кешене бөтен яктан да тәрбияләргә тиеш икән, ул башта кешене дә барлык яктан белергә тиеш",— дип белдерә. Бу таләпне тормышка ашыру өчен Ушинский үзе "Кеше тәрбия карашында" исемле ике томлы бик әһәмиятле хезмәт яза.

Ул вакытта психологиядә ике юнәлеш капма-каршылыкта торган: психологияне коры фикергә нигезләп, "җан" билгеләмәсеннән априор башлап төзүчеләр вәкиле булган метафизик психология һәм тәҗрибәгә таянуны, фактларны һәм психик тормышның гади күренешләреннән башлап өйрәнүне яклаучылары булган яңа юнәлеш.

Ушинский тәҗрибә ягында торган, күзәтүгә зур әһәмият биргән. Аның психологик карашларында материалистик элементлар байтак. Психик тормышка аның үсеше аркылы караган.

Ушинский Гербартка метафизик һәм берьяклы булуы өчен ризасызлык белдергән, ул вакыттагы икенче бер күренекле немец психологы Бенекның карашлары тар икәнен күрсәткән. Вакыттан һәм пространстводан тыш торган абстракт кеше психикасын түгел, ә яши торган, гамәлдә торучы, мәгълүм тирәлектә үсешкә ия булган кеше психикасын карарга тырышкан.

Тәрбия халыкның тарихи үсеше белән бәйле икәнлеген Ушинский дөрес билгели. Халык үзе киләчәккә юл ача, ә тәрбия эше бу юлдан, башка җәмгыять көчләре белән бергәләп эш итеп барса гына, аерым шәхесләргә һәм яңа буыннарга ярдәмгә киләчәк. Шуңа күрә тәрбия системасын уйлап чыгарырга яисә башка халык алып торырга мөмкин түгел, аны иҗади рәвештә төзергә кирәк.

К. Д. Ушинский педагогикасында тәрбиянең халыкчанлык идеясы. Ушинскийның педагогика системасы нигезендә Халык-

чанлык идеясы тора. "Һәркем өчен бердәнбер гомуми табигый һәвәслек халыкчанлык дип атала. Ул тәрбия эшенең ышанычлыгын тәшкил итә... Халык тарафыннан тудырылган һәм халык башлангычына нигезләнгән тәрбия эшенең абстракт идеяларга төпләнгән яисә башка халыктан күчереп алынган бернинди система да тиңләшә алмый... Һәрбер тарихи исән халык — алланың җирдәге иң шәп иҗаты, ә тәрбиягә бу бай һәм чиста чыганактан кирәген сосып алырга гына кала",— дип язган, Ушинский "Иҗтимагый тәрбия эшендә халыкчанлык турында" (1857) дигән мәкаләсендә.

Ушинский халыкчанлык дип һәрбер халыкның тарихи үсеш белән, географик һәм табигать шартлары белән булдырылган үзенчәлеген аңлаган.

Шул җәһәттән "Иҗтимагый тәрбия эшендәге халыкчанлык турында" дигән мәкаләсендә ул тәрбия мәсьәләсен анализлауны төрле халыкларның тарихи рәвештә барлыкка килгән сыйфатларын халыкчанлык рухында тасвирлаган. Ушинский француз, инглиз, немец һәм американ тәрбиясенә төгәл тасвирлама һәм тирән анализ бирә. Бигрәк тә, ул вакытта реакцион булган немец педагогикасын җентекләп тәнкыйтьли. Бу педагогикага патшалык ориентлашкан була. Ушинский бу педагогиканы урыс җирлегенә механик рәвештә күчерүнең мәгънәсезлеген исбатлаган.

Халык тәрбиясенең үзенчәлеге балаларның патриотизмын үстерү, ватанга тирән мәхәббәт булдыру белән бәйле икәненә К. Д. Ушинский басым ясый. Аның фикеренчә, халыкчанлыкның иң мөһим билгесе булып туган тел торганга күрә, урыс балаларын укыту нигезендә урыс теле булырга тиеш. Башлангыч мәктәптә укыту балаларны урыс тарихы, Россия географиясе һәм табигате белән шулай ук яхшы таныштыру белән бәйле булырга тиеш.

Халыкның ватанга карата булган зур мәхәббәтен XVII гасырның башында поляк интервентлары белән көрәштәге, 1812 елда Ватан сугышындагы, 1853-1855 елларда Кырым компаниясендәге батырлыклары белән күрсәткән һәм күрсәтә бирә дип аңлаткан К. Д. Ушинский.

Ушинскийның фикеренчә, "вакыт-вакыт чын арыслан көче белән уянучы" бу хис кайбер кешеләрдә тик ватанга куркыныч янаганда гына кабынып китә.

Халыкчанлыкка нигезләнгән бу тәрбия патриотик хисне һәрвакыт, һәр көн гражданнарның үз иҗтимагый бурычларын үтәгәндә күрсәтергә өйрәтергә тиеш.

Бу тәрбия балаларда милли горурлык, ләкин шовинизмны читләштергән һәм башка халыкларны хөрмәтләү белән берләштерел-

гән хисне үстерергә тиеш. Балаларда ул ватан алдында бурычлылык хисен тәрбияләүгә, иҗтимагый мәнфәгатьләрне шәхси мәнфәгатьләрдән өстен куюны өйрәтергә тиеш.

Ушинскийга халкының иҗади көченә нык ышану хас. Үз куәтенә, батырлыгына, ныклыгына күрә халык төрле изүләргә бирешмәде, Көнбатыш Европаны яучыларының басып алуыннан коткарды, ватанның бәйсезлеген чит ил дошманнарының кул сузуыннан күп тапкыр коткара килде. "Халык үзе шундый тирән мәгънәле тел булдырды ки, аның тирәнлегенә без һаман да төшенә алмадык; бу гади халык тудырган поэзия мәзәкле балалар бетелдәве рәвешендә безнең чит илләргә иярүдән коткарды; нәкъ халык чыганагына таянып без үзебезнең бөтен әдәбиятны яңарттык һәм бу әдәбиятны халык исеменә лаеклы иттек",— дип язды Ушинский.

Халык иҗатыннан шулай ук музыка һәм рәсем сәнгате, фәлсәфә күп нәрсә алдылар: томана, кара, тупас массадан гаҗәп халык музыкасы агыла. Аннан шагыйрь да, рәссам да, музыкант та, иҗади дәрт алалар. Төгәл, тирән мәгънәле сүз ишетелсә... филолог төптән уйланып кала һәм фәлсәфәче бу сүзнең тирәнлегенә һәм гаделлегенә таң кала...

Ушинский халкының куәтле иҗади көчләренә нык ышанып, халык мәгарифе халыкның үзенә бирелергә тиеш һәм хөкүмәтнең интектергәч һәм бу халык мәгарифе үсешен туктатучы күзәтчелектән котылырга тиешлеген таләп иткән. "Әгәр берәрсе Россия тарихы белән таныш булса, бер минут та уйланып тормастан халык мәгарифен халыкның үзенә бирер иде",— дип язган Ушинский.

Ушинский системасы тәрбия нигезе булган халыкчанлык белән якын бәйләнештә торган, анда туган телнең тәрбия һәм белем әһәмияте турында мәсьәлә куелган.

"Туган тел" дигән искиткеч мәкаләсендә Ушинский болай яза: "Халык теле — халыкның тарих чигеннән узып башланган рухи тормышының иң яхшы, беркайчан да шиңми торган һәм һәрчак өр-яңадан ачылучы чәчәге. Бу тел белән бөтен халык һәм бөтен ватан рухлана, анда туган илнең күк йөзе, һавасы, табигать күренешләре, климаты, кырлары, таулары һәм үзәнлекләре, урманнары һәм елгалары, давыллары һәм яшеннәре халык рухының иҗади көче белән фикергә, сурәткә һәм авазга күчә. Табигатьнең бу тирәнтен, фикер һәм хис белән тулы авазы кешенең кайчакта кырыс була торган туган иленә мәхәббәте каты яңгырый, якын җырында һәм моңнарында, халык шагыйрь телләрендә ишетелә. Халык теленең якты һәм саф тирәнлекләрендә туган илнең бер табигате генә түгел, ә

халык рухи тормышының бөтен тарихы чагыла... Тел ул — халыкның элекке, хәзерге һәм киләчәк буыннарын бөек, тере тарихи бөтенлеккә берләштерүче иң тере, иң бай һәм нык бәйләнеш. Тел халыкның яшәешен генә белдерми, ә нәкъ бу тормышның үзе булып тора. Халык теле югалса — халык инде юкка чыга!"

Туган тел, Ушинский күрсәтүенчә, халыкның рухи үзенчәлеген иң яхшы чагылдыручы гына түгел, китаплар да, мәктәпләр дә булмаганда ул халыкны өйрәтүче иң яхшы халык тәрбиячесе. Туган телне үзләштергәндә, бала бер үк авазларны, аларның кушылуларын һәм төрләнүләрен генә түгел, ә чиксез күп төшенчәләрне, карашларны, хисләрне, нәфис образларны зиһенгә ала.

Әхлак тәрбиясенең максатлары һәм чаралары. Кеше физик, акыл ягыннан камилләшкән һәм әхлак, гармоник үсешкә ия булырга тиеш, дип санаган К. Д. Ушинский. Шуның сәбәпле тәрбияне ул гармоник үсешкә ия булган шәхесне максатлылыкны, аңлы рәвештә формалаштыру процессы дип билгели. Тәрбиянең төрле якларыннан Ушинский төп урынны әхлаклылык тәрбияләүгә билгеләгән. Ул болай яза: "...Әхлак тәэсире тәрбиянең төп бурычын, гомуми акыл үсешенә, башны белемнәр белән тудыруга караганда да мөһимрәк булып тәшкил итә, дип без үзебезнең карашларыбызны белдерәбез".

Ушинский фикеренчә, әхлак тәрбиясе балада кешелеклелекне, намуслыкны һәм гаделлекне, эш сөючәнлекне, тәртиплелекне һәм җаваплылык хисен, тыйнаклык белән берләшкән үз абруйлылык хисен үстерергә тиеш. Тәрбия баланың нык характерын һәм ихтыярлыгын, түземлеген, бурычлары хисен үстерергә тиеш.

Патриотизмны, ватанга карата чын күңелдән һәм эшлекле мәхәббәтне тәрбияләү, Ушинскийның бөтен төп педагогик системасы — халыкчанлык буенча булган, үзе тәкъдим иткән әхлак тәрбия системасында нигезле урын алып тора. Ватанга мәхәббәт — кешенең иң көчле хисе.

Әхлак тәрбиясе балаларда кешеләргә карата мәхәббәт, аларга чын күңелдән, изгелекле һәм гадел мөнәсәбәт булдырырга тиеш.

Сукыр таяк тәртибенә нәфрәт белдереп, Ушинский болай язган: "Элекке мәктәптә дисциплина бер дә табигый булмаган башлангычларда — бүләкләүче һәм җәза бирүче укытучыдан куркуда нигезләнгән булган. Балаларны бу курку табигый булмаган хәлгә генә түгел, ә алар өчен зарарлы хәлгә: хәрәкәтсезлеккә, сыйныфтагы күңелсезлеккә һәм икейөзлелеккә дучар иткән".

Ушинский балаларга карата кешелекле булган, ләкин иркәләндерүдән читләттергән мөнәсәбәтне таләп иткән. Педагог балаларга

кара чамалы таләпчәнлек күрсәтеп, аларда бурычлылык һәм җаваплылык хисен тәрбияләргә тиеш.

Ушинский эгоизмны, карьеристлыкны, бушлыкны, комсызлыкны, икейөзлелекне һәм башка бозыклыкларны тәнкыйть итә.

Ушинский этика карашларының уңай якларын билгеләп тә, шул ук вакытта аның әхлаклык турындагы хезмәте дин белән берләшкән булуын күз алдында тотарга кирәк. Шулай да аның дингә карашлары үзгәрүен әйтмәсәк дөрес булмас.

Мәктәпкә чиркәүгә каршы торырга кирәкмәсә дә, мәктәп реаль тормыш ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән читләшмәү сәбәпле, чиркәү белән бер нигездә төзелергә тиеш түгел, дин белеме үзенә башка, ә дөньявиныкы үзенә башка, дип әйткән Ушинский үзенең бер мәкаләсендә.

Ушинскийның әхлак тәрбиясендә башта дин элементлары өстенлектә булса, соңыннан ул әхлак тәрбиясендә төп урынны гражданнар бурычына, эшлекле, җәмгыять бурычына — эшлекле, җәмгыять бурычын яхшы тоючы итеп, ватан гражданын әзерләүгә биргән.

Ушинский фикеренчә, әхлак тәрбиясенең чаралары шулар: 1) укыту (бу яктан аның уку китапларында сөйләм үсеше, белем бирү һәм укучыларның әхлакый тәрбияләү мәсьәләләренең урынлы берләшүләре бик тә килешле); 2) укытучының шәхси үрнәге (Ушинскийның образлы әйтеме буенча, яшь йөрәк өчен кояшның бу уңышлы нуры, аны бер нәрсә белән дә алыштырып булмый); 3) инану, моңа ул зур әһәмият биргән; 4) укучылар белән оста мөгамәләдә булу (педагогик такт); 5) алдан ук кисәтеп кую чаралары; 6) мактау һәм шелтә.

Баланың эшчәнлеге һәм активлыгы. Хезмәт һәм аның тәрбияви мәгънәсе. Баланың эшчәнлеге һәм активлыгы аның үзен тәрбияләүдә һәм укытуда мөһим шартларның берсе булып тора дип, Ушинский бик дөрес әйтә. Шуннан чыгып баланың тормыш режимына ул зур әһәмият бирә. Режим баланы оешканлыкка өйрәтергә, эшчәнлеккә омтылыш булдырырга тиеш. Әхлакый тәрбия процессында һәм укытуда ул һәрвакыт күнегүләрнең әһәмиятлегенә басым ясаган.

Үзенең психологик әйтемнәрендә Ушинский ихтыяр әһәмиятен югары бәяләгән. Уен-көлкеле педагогикага каршы чыгып һәм балаларны авырлыкларны җиңәргә өйрәтергә кирәклеген кисәтеп, укытуны ул активлык процессы дип санаган. Укыту процессы бала өчен тулысынча кызыклы булмас һәм ихтыяр көче ярдәмендә бала

үз бурычын аңлау исәбеннән кызык булмаганны һәм авырлыкларны да җиңеп чыгарга өйрәнсен. Баланың эшчәнлек һәм активлык мөһимлегенә карашлары хезмәт турындагы әйтемнәрендә ачык чагылган.

Кешенең дөрес үсешенең кирәкле шарты дип Ушинский хезмәтне саный. "Хезмәтнең психик һәм тәрбияләү мәгънәсе" исемле күләмле мәкаләсендә хезмәт матди байлыкларны булдыруда төп фактор, кешенең физик, акыл һәм әхлак яклардан камилләшүе өчен, кешенең абруе, аның иреге һәм бәхете өчен кирәк дип белдергән ул. Хезмәткә кеше югары дәрәҗәдә ләззәтләнү минутлары өчен бурычлы. Хезмәт гаилә тормышын ныгыта.

Ушинский әйтүенчә, әгәр тәрбия кешегә бәхет бирергә теләсә, кешене бәхет өчен түгел, ә хезмәт, тормыш өчен әзерләргә тиеш. Тәрбия кешедә хезмәткә мәхәббәт һәм хезмәттә күнегүле булуны ныгытырга тиеш.

Ушинский физик хезмәткә зур әһәмият биргән, кеше үзенең эшчәнлегендә физик һәм акыл хезмәтен берләштерсә, бу файдалы була дип санаган, авыл хуҗалыгы хезмәтенең (бигрәк тә авыл мәктәпләрендә) тәрбияләү әһәмиятен аерып күрсәткән. Хезмәт турында фикер йөрткәндә "уку ул үзе хезмәт һәм тулы мәгънәсе белән хезмәт булып калырга тиеш" дип билгеләгән Ушинский. Күңел ачу, мәзәкләнү рәвешендә укытуга, кайбер педагогларның балалар өчен укытуны мөмкин кадәр җиңел итәргә омтылуларына ул кискен каршы чыккан. Уку барышында балалар хезмәткә өйрәнергә һәм авырлыкларны кичәргә тиеш. Уен аркылы тик кечкенә балаларны өйрәтергә була, дип язган Ушинский. Акыл эше авыр, әлбәттә, күнекмәгәнгә, тиз арыта да. Балаларны авыр хезмәткә әкренләп, чамадан тыш биремнәр йөкләтмичә генә өйрәтергә кирәк.

Хезмәтнең тәрбияләү өчен бик әһәмиятле булуы турында Ушинскийның күрсәтмәләре "уку ул хезмәт, һәм җитди хезмәт..." дигән фикере безнең көндәге педагогика өчен дә бик мөһим булып тора.

К. Д. Ушинский дидактикасы. Ушинскийның дидактик карашлары зур тирәнлек һәм оригинальлек белән аерылып тора. Укытуны оештыруда балалар үсешенең яшь чорын һәм психологик үзенчәлекләрен исәпкә алуны таләп иткән ул. Атап әйткәндә, укыту вакытында балалар игътибарын куллану буенча әһәмиятле күрсәтмәләр биргән. Игътибарның ике төрен: актив яисә ихтыярлы һәм пассив яисә ихтыярсыз төрләрен билгеләп, Ушинский балалык чорын исәпкә алып, пассив игътибарга "азык" бирергә, шул ук вакыт-

та киләчәк өчен төп булган актив игътибарны һәрьяклап үстерергә кирәк дип санаган.

Хәтер һәм ятлау турындагы сүзләрендә, Ушинский еш кабатлау онытуны булдырмый дип, тәрбияләнүченең хәтер ышанычлыгын ныгытырга күрсәткән.

Шунысы аеруча зарури, укыту бала өчен көче җитәрлек һәм эзлеклелек принципларында оештырылырга тиеш.

Артык талчыктыру булмасын өчен, укытуның беренче елларында уку дәресләре белән чамадан тыш йөкләтүгә ирек бирмәскә кирәк.

Бала яшенең психологик үзенчәлекләреннән чыгып, күрсәтмәлелек принцибына Ушинский зур әһәмият бирә. "Бала һәрвакыт формалар, төсләр, авазлар, тойгылар белән фикерли..."; шуңа күрә балалар өчен күрсәтмәле укыту кирәк була, "бу укыту гомуми күзалламалар һәм сүзләр буенча түгел, ә бала тарафыннан турыдан-туры зиһенгә алынган конкрет образлар буенча төзелергә тиеш",— дип яза ул.

Ушинский укытуның күрсәтмәлелек принцибын гносеологик ягыннан дәлилләп, безнең белемнәребезнең бердәнбер чыганагыннан "тышкы тойгылар тарафыннан китерелгән тәҗрибәбез" була ала, дип күрсәткән. Тышкы мохиттан турыдан-туры зиһенгә алынган образлар, димәк, бердәнбер шундый материаллар булалар ки, алар өстендә һәм алар ярдәмендә безнең фикерләү мөмкинлегебез гамәлгә урнаша.

Ушинский сүзләре буенча, "укуның конкретлыктан абстрактлыкка, читләштерелгәнлеккә, күзалламалардан фикерләүгә шулай барышы шундый табигый һәм психология законнарына шундый ачык нигезләнгән ки, моның кирәклеген укытуда, гомумән, кеше табигате белән, аерым алганда, балалар үзенчәлеге белән исәпләшергә кирәк дип тапмаганнарның гына танымаулары ихтимал".

Күрсәтмәлелек принцибының теоретик эшкәртмәсенә һәм кулланылышына Ушинский кыйммәтле күп тәкъдимнәр керткән: күрсәтмәлелек принцибына материалистик нигез биргән. Ушинскийның күрсәтмәлелекне аңлавында Коменскийга хас булганча күрсәтмәлелекне артык бәяләү, Песталоццига хас булганча, балаларны тирә-як белән таныштыруда рәсмилек һәм педантлык юк. Укыту процессында күрсәтмәлелеккә Ушинский килешле урын биргән; күрсәтмәлелекнең укучыларга тулы белемнәр бирү һәм укучыларның логик фикерләвен үстерү шарты булуын билгеләгән.

Песталоцциның рәсми күнегүләрен кире кагып, Ушинский балаларны әйберләр белән барлык яктан таныштырырга омтыла, балаларның бу әйберләр арасында булган чын бәйләмнәрен аңлавын тели. Искиткеч яисә, хәтта, бөек фикер — "әйберләрне чынбарлыкта, куелганча барлык яктан, бөтен мөнәсәбәтләре аркылы күрү сәләте",— дип яза ул.

Укытуда элек Коменский, Песталоцци, Дистервег төзегән күрсәтмәлелек методикасын Ушинский шактый киңәйтә һәм яңа ысуллар белән баета. Мәсәлән, балаларга ул сурәтләр буенча сөйләү хакында җентекле күрсәтмә эшкәртмәсен булдыра, әңгәмә өчен кулланылган сурәтне, әңгәмә буенча алынган мәгълүматларны ныгыту һәм кабатлау өчен класста эленгән килеш калдырырга дип күрсәтә һ. б.

Уку материалын балалар тарафыннан үзләштерүдә мәгънәне аңлауга, нигезлелеккә һәм ныклыкка Ушинский күп игътибар бирә. Бу принципларны аңлауда һәм куллануда да күп яңалыклар кертә. Мәсәлән, ул уку материалын кабатлау турында җентекле методика эшкәртмәсен булдыра (онытуны кисәтү, кабатлау вакытында уку материалын киңәйтү һәм тирәнәйтү, яңа материалны яхшырак аңлау өчен кабатлауның роле һ. б.). Ушинский аерым күзалламалардан балаларда гомуми күзалламалар һәм төшенчәләр оештыру методикасын, балалар фикеренең сөйләм белән бер үк вакытта үсешкә ия булу методикасын җентекләп эшкәртә. Шуның белән бергә, формальлеккә дә бирелми.

Укыту процессын Ушинский ике чорга аера. Беренче чорда балалар укытучы җитәкчелегендә әйберләрне яисә күренешләрне күзәтәләр һәм аның турында гомуми төшенчә төзиләр. Бу чор өч баскычка бүленә: беренче баскычта балалар укытучы җитәкчелегендә әйберләрне яисә күренешләрне турыдан-туры зиһенгә алалар. Икенче баскычта укытучы җитәкчелегендә бу әйбер яисә күренеш турында табылган күзалламаларны үзлекләре буенча һәм үзара аералар, чагыштыралар һәм тиңләштерәләр, ниһаять, әйбер яисә күренеш турында төшенчә булдыралар. Өченче баскычта укытучы үзенең ачыклап аңлатуы белән балалар төшенчәсенә өстәмәләр кертә, төшенчәләрне системага китерә, әһәмиятлене әһәмиятсезлектән аера. Икенче чорда табылган белемнәрне гомумиләштерү һәм ныгыту башкарыла.

Тәрбияче һәм укытучы арасында тәрбияләү һәм укыту функциясен бүлүгә Ушинский каршы чыга. Укытуны ул тәрбиянең бик мөһим чарасы итеп карый. Башлангыч мәктәптә аерым фәннәрне

укыта торган аерым укытучылар урынына бу сыйныфта барлык фәннәрне укыта торган сыйныф укытучысы булуын таләп итә ул.

Рәсми һәм материаль белем теориясен һәм классик мәктәпне тәнкыйтьләү. XIX гасырда дидактикада белем бирүнең иң уңай үзенчәлеге турында ике теория барлыкка килә. "Рәсми белем" дигәнне яклаучылар (күпчелектә классик белемне яклаучылар) белем бирүнең төп бурычы — хәтер, игътибар, фикерләү һәм сөйләм үсешен булдыру дип санаганнар. Өстәвенә, бу үсешнең кайсы уку материалында (хәтта тормыштан ерак булган һәм гамәли әһәмиятсез материалда) җиткерелүе — икенче мәсьәлә дип саналган. "Материаль белем" дигәнне яклаучылар, киресенчә, уку материалын төп әһәмият иясе дип санаганнар, уку материалының тормышта һәм гамәли мәгънәле булуын таләп иткәннәр. Шуңа күрә алар урта мәктәптә латин һәм грек телләре укытуга каршы торганнар, төп урынны туган тел һәм әдәбиятка, математикага, табигать белеменә һәм яңа чит телләргә билгеләгәннәр, ләкин укучыларның акыл көчләрен үстерүгә җитәрлек әһәмият бирмәгәннәр.

Бу ике теорияне Ушинский беркатлылык дип тапкан, укучыларның акыл көчләре һәм сәләтләре үсешенә дә, шулай ук тормышта кирәкле белемгә ия булуларын да мөһим дип санаган. Анысы да һәм монысы да кирәк дип, алай гына да түгел — берсенең икенчедән башка булуы акылга сыймаслык дип күрсәткән һәм шуңа күрә рәсми һәм материаль белемнәрне бер-берсенә каршы кую мәгънәсез, дип санаган.

"Гасырның индустриаль юнәлеше фәннең дә индустриаль булуын таләп итә" һәм балаларны табигать һәм кеше турындагы фәннәр белән таныштыру кирәк, дип санаган Ушинский үзе. Балалар туган телне һәм әдәбиятны, тарихны, географияне, математиканы белергә тиеш, кеше өчен табигать фәннәре бик әһәмиятле. Педагогика аларны да "грамматика, арифметика яисә тарих белемнәре кебек табигый итергә тиеш".

Халык мәгариф министры булып реакционер Толстой эшләү чорында урта мәктәптә классицизмны көчләп такканнар. К. Д. Ушинский аны кискен тәнкыйтьләп чыкты. "Безгә балаларыбыз белән ни эшләргә" дигән үзенең соңгы мәкаләләренең берсендә (1868) белем бирүдәге классицизмны яклаучылар белән бәхәскә кереп, Ушинский табигать белеменең уку һәм тәрбия өчен искиткеч зур әһәмияте турында әйтә һәм гомуми белемнең реаль юнәлешен яклый.

Табигать фәннәре тормышны күзәтү мөмкинлекләрен үстерә, алар латин һәм грек төрләнешләренә караганда балалар өчен кызыклырак, логик фикерләү үсешенә ярдәм итәләр һәм зур гамәли әһәмияткә ия булып торалар, дип күрсәтә ул. "Балалар дөньясы" дигән уку китабында Ушинский башлангыч укыту өчен табигать белеме буенча уку материалын биргән. Авыл мәктәпләрендәге укучыларның гамәли дәресләрен яшелчә бакчасында һәм кырда үткәрергә дип тәкъдим иткән.

К. Д. Ушинский дәресләр һәм укыту методлары турында. Үзенең педагогик системасында Ушинский дәрескә күп игътибар бирә. Уку шөгыльләренең кирәкле шартлары дип, класс — дәрес системасының үзенчәлекле сыйфаты дип классны саный ул. Класс шөгыльләренең үзгәрмәс расписаниесе, барлык укучылар белән фронталь шөгыльләрне аерым шөгыльләр белән берләштерү һәм укытучының төп роле булу аеруча әһәмиятле.

Дәрестә уку шөгыльләренең төрләре күп була: яңа белемнәр бирү, күнегүләр, үткәнне кабатлау, белемнәрне тикшерү, укучыларның язма һәм график эшләре. Һәрбер дәрес максатчан юнәлешле булырга, төгәлләнергә һәм тәрбиягә кагылышлы булырга тиеш. Балалар игътибарының (бигрәк тә кече яшьтә) бик тиз сүрелүен исәптә тотып, Ушинский шөгыльләрне алыштырып кертүне һәм методларны төрләндерүне тәкъдим итә.

Балаларның мөстәкыйль рәвештә эшли алуына зур игътибар биреп, укытучы дәрестә мәктәп шөгыльләренең башыннан ук балаларны, мөстәкыйль эшнең дөрес ысулларына өйрәтсен, дип киңәш бирә Ушинский. Аның фикеренчә, моның өчен башта балаларга мөстәкыйль эшнең дөрес күнекмәләрен үзләштергәнче, өй эшләре бирмәскә кирәк.

Башлангыч мәктәптә аңлатмалы укулар нигезендә тарих, география, туган тел дәресендә табигать белеме буенча Ушинский элементар мәгълүматлар бирергә тәкъдим итә. Аңлатмалы уку процессында аңлашылмаган сүзләрне һәм әйтемнәрне аңлаталар һәм әхлакый нәтиҗә ясыйлар һ. б. Ләкин шуның белән бергә үзенең аңлатмалары белән укытучының балаларны укытыла торган новелладан яисә шигырьдән читкә алып китмәве, төп материалның игътибар үзәгендә булуы таләп ителә.

"Урыс телен башлап укыту турында" (1864) дигән атаклы мәкаләсендә Ушинский мөһим методик күрсәтмәләрен бирә. Аның фикеренчә, бу укыту өч бурычтан тора: 1) бала телен камилләштерү; 2) балаларны туган тел хәзинәсен аңлы рәвештә үзләштерүгә

алып керү; 3) телнең логикасын (аның грамматикасын) үзләштерү. Өч бурыч барысы бер үк вакытта һәм берләштереп башкарыла.

Сөйләмне камилләштерү өчен Ушинский систематик күнегүләр — башта телдән, соңыннан катлауландыра барып үткәрүне тәкъдим итә. Укытучы сөйләменең дөреслегенә зур әһәмият бирелә. Икенче бурыч халык поэзиясен һәм матур әдәбиятның иң яхшы үрнәкләрен өйрәнү ярдәмендә ирешелә.

Балалар укуы өчен әсәрләрне җентекләп сайлауга да Ушинский зур игътибар биргән. Әсәрләр югары дәрәҗәдә нәфисле, балалар төшенә алырлык, балаларда куәт, шат күңеллелек тудыра алырлык булырга тиеш.

Балаларны әкиятләр, халык җырлары, мәкальләр, табышмаклар белән таныштыруга Ушинский зур әһәмият бирә. Урыс язучыларының әсәрләреннән балалар өчен аңлаешлы булган Пушкинның, Крыловның һәм башкаларның сайланма әсәрләрен тәкъдим итә ул.

Тел логикасы булган грамматикага зур әһәмият биреп, Ушинский ике капма-каршылыктан сак булырга куша: коры грамматизмнан — грамматика белән артык мавыгудан, бер яктан, һәм грамматиканы санга сукмаудан, бәя биреп җиткермәүдән — икенчедән, һәрбер грамматик кагыйдә балаларга инде билгеле булган тел формаларын куллану нәтиҗәсе булырга тиеш. Балаларны грамматик кагыйдәләргә төшендерү акрынлап күнектерү буенча китереп җиткерергә кирәк.

Ушинскийның Россиядә укырга өйрәнүдә аваз методын кертүе һәм киң таратуы зур әһәмияткә лаек. Бу методның күп төрләреннән Ушинский язма-укуның аналитик-синтетик аваз методын тәкъдим иткән һәм үзенең беренче "Туган тел" дәресләрен бу методы буенча төзегән.

К. Д. Ушинскийның уку китаплары. Башлангыч уку өчен Ушинский ике "Туган тел" ("Родное слово") уку китабы төзегән. Алар — әлифбадан соң башлангыч уку өчен. Балаларның фикерләү үсеше һәм тирә як турында белем байлыгы киңәйгәнгә күрә, китапта төп игътибар урыс теленә юнәлдерелгән. "Балалар дөньясы" ("Детский мир") китабы — өлкәнрәк яшьтәге укучылар өчен (өченче һәм дүртенче ел укый торганнарга чамалап). Анда табигать белеме һәм география буенча башлангыч мәгълүматлар бирү үзәк мәгънә булып тора.

Уку китапларының икесе дә эчтәлек байлыгы, тел камиллеге һәм методика үрнәкләре булып тора. Алар зур уңышка ирешә һәм

революциягә чаклы Россиядә киң таралган булалар ("Туган тел" 150 тапкыр кабат бастырылган). Бу китаплар ярдәмендә күп урыс укучылары буыны тәрбияләнгән. Бу китаплар Россиянең башка халык балалары өчен уку китаплары төзүдә үрнәк булганнар: мәсәлән, грузин телендә атаклы грузин педагогы Я. С. Гогебашвили (Ушинский тарафдары) һәм башкалар язган уку китаплары, шулай ук берничә славян илләре (мәсәлән, Болгария) өчен.

Җентекләп сайлап алынган нәфис материаллардан (шигырьләрдән, мәсәлләрдән, әкиятләрдән һ. б.) һәм әхлакый эчтәлекле кечкенә хикәяләрдән башка, Ушинский "Туган телдә" агачлар, хайваннар һ. б. турында мәкаләләрен урнаштырган. Алар искиткеч гадилек, аз сүзлелек, фәнни эчтәлек, гүзәл һәм образлы тасвирлама белән аерылып торганнар.

Бигрәк тә 2-3 юлдан торган, ниндидер әхлак темага багышланган мәкалә-хикәячекләр педагогның игътибарына лаеклылар. Мәсәлән: "Аксак һәм сукыр. Сукырга һәм аксакка тиз агымлы инеш аркылы кичәргә туры килгән. Сукыр аксакны җилкәсенә утырткан һәм икесе дә уңышлы кичеп чыкканнар".

"Туган телдә" мәкальләр, әйтемнәр, тиз әйтемнәр, табышмаклар киң кулланылган. Балаларның чагыштыру, аеру, гомумиләштерү осталыгын үстерү өчен булган күнегүләр бик шәп сайланып кертелгән.

Тасвирламаның гадилеге, образлылыгы һәм эмоциональлеге, материалның күптөрлелеге һәм байлыгы (нәфис әдәбияттан, географиядән, тарихтан, табигать белеменнән), тел гүзәллеге, баланы кызыксындыра алу, белем һәм тәрбия элементларын берләштерү, күнегүләрнең күптөрлелеге һәм байлыгы — "Балалар дөньясының" һәм "Туган телнең" педагогика ягыннан өстенлекләре менә шул. Бу китапларда Ушинский беренче тапкыр Жуковский, Пушкин, Кольцов, Никитин һәм башка урыс язучыларның әсәрләрен кулланган.

Ушинский дәреслекне "укытуның яхшы нигезе" дип санаган. Ул вакытта Россиядә һәм Көнбатыш Европада чыккан дәреслекләрне бәяләп, Ушинский аларның ике төп җитешсезлекләрен күрсәтеп үткән: артык гомумиләштергәндә гамәли материалның (фактларның, исемнәрнең, даталарның) ярлылыгы һәм, киресенчә, гомумиләштерүнең һәм идеяләрнең ярлы булганында, хәтер өчен артык тутырылган фактларның эмпирик характерындагы күплеге.

Укытучы һәм аны әзерләү. Ушинский укытучы ролен югары бәяли. Педагогның укучы балага тәэсире тәрбияләү көчен тәшкил

итә, аны бернинди дә уставлар һәм программалар ярдәмендә, уку йортларының бернинди оештырулары белән алыштырып булмый, "тәрбия эшендә тәрбияче шәхесе бар нәрсәне нигезли", дип саный Ушинский.

Педагогның эшчәнлеге башка эшчәнлекләргә караганда гел рухландыруга мохтаҗ: ул тышкы яктан бертөрле, аның нәтиҗәләре тиз генә беленми, елдан-ел бер нәрсәне укытып, шуңа "тартылу һәм укытуны механик рәвештә башкару" куркынычы көчле анда, дип күрсәтә Ушинский. Ул укытучыларны бу куркынычтан сак булырга кисәткән, бертуктаусыз алга барырга чакырган. Укытучы роле тышкы яктан күренми, әмма чынбарлыкта аның хезмәтенең иҗтимагый әһәмияте нинди зур! Җәмгыять укытучыга зур хөрмәт һәм кайгыртучанлык, өзлексез игътибар күрсәтергә тиеш дип саный Ушинский.

Укытучы ниндидер фәннәрне укытырга гына түгел, ә тәрбияче булырга, үзенең профессиясен яратырга, тәрбия эшендә зур җаваплылык хисе мөнәсәбәтендә торырга, белемле кеше булырга, педагогиканы һәм психологияне яхшы белергә, педагогик осталыкка һәм педагогик тактка ия булырга тиеш. "Укытучылар семинариясе проекты" мәкаләсендә (1861) Ушинский башлангыч мәктәпләр өчен укытучылар әзерләү планын төзи. Бу проект буенча укытучылар семинариеләрен зур үзәкләрдә түгел, ә бәлки кечкенә шәһәрләрдә, хәтта авылларда ачарга кирәк. Зур шәһәрләрнең күңел аздыруы буенча тәрбияләнүчеләргә начар йогынты ясавы булмас, ә укытучыларга башка уку йортларында өстәмә эш белән мавыкмыйча, укытучылар семинарияләрендә бөтен күңелләрен биреп эшләргә мөмкинлек бирер бу.

Укытучылар семинариясендә тәрбияләнүчеләрнең күбесе крестьян балалары булу мөһим. Әхлакый тәрбияне һәм укытучылар ягыннан йогынтыны көчәйтү исәбеннән тәрбияләнүчеләр интернатта, гади, кырыс һәм эшлекле тормышка күнегеп яшәргә тиеш.

Ушинский укытучылар семинариясендә булачак укытучылар өйрәнергә тиешле фәннәрнең киң түгәрәген билгели, атап әйткәндә: урыс теле һәм әдәбияты, арифметика, география, тарих, табигать белеме (ботаника, зоология, анатомия һәм кеше физиологиясе буенча мәгълүматлар, шулай ук авыл хуҗалыгы һәм медицина буенча кайбер мәгълүматлар).

Ушинский проекты буенча укытучылар семинариясе курсында зур урынны педагогика циклы фәннәре алып торганнар: психология, педагогика һәм башлангыч укыту методикасы. Семинария

тәрбияләнүчеләре нәфис уку, матур язу, рәсем ясау, сызым һәм җыр буенча күнекмәләргә ия булганнар. Семинария тәрбияләнүчеләренең педагогик тәҗрибәсе укытучылар семинариясе карамагында булган халык мәктәбендә үткән. Семинариягә аннан башка берничә якындагы мәктәпләр теркәлгән була. Аларда семинаристлар шулай ук педагогик практика үткәннәр, ә семинарияне тәмамлаучылар укытучыларның ярдәме белән ел буенча башлангыч укытучы-стажер булып эшләгәннәр. Семинарияләр үзендә элек тәрбияләнгән укытучылар белән элемтәдә торганнар.

Укытучылар семинариясе университет белеме алганнар өчен югары педагогик курслар оештырыла торган педагогик үзәк булган. Семинария җитәкчеләре һәм укытучылары педагогик һәм башка темаларга лекцияләр оештырганнар.

Ушинский проекты буенча укытучылар семинарияләрнең иң яхшылары ачылган (мәсәлән, Ушинский фикердәше Д. Д. Семенов тарафыннан Гори шәһәрендә Кавказ арты укытучылар семинариясе һәм берничә земство укытучылар мәктәбе оештырылган).

Ушинский педагогика укытучылары һәм урта мәктәп укытучылары әзерләрлек педагогика факультеты булдыру турында фикер әйтә. Ул болай яза: "Әгәр бездә медицина факультетлары була торып педагогика факультетлары юк икән, әхлакый сәламәтлеккә һәм тәрбиягә караганда тән сәламәтлегебезне артыграк күрүебезне генә аңлата бу".

Педагогика һәм мәктәп үсеше өчен К. Д. Ушинскийның әһәмияте. Ушинский — бөек урыс педагогы, Россиядә халык мәктәбенә нигез салучы, тирән һәм килешле педагогика системасын төзүче, искиткеч уку китаплары авторы. Аның китаплары буенча Россиядә ярты гасырдан артык уннарча миллион кеше укыган. Ул —"урыс укытучыларының укытучысы" — укытучылар семинариясендә халык укытучылары системасын эшләгән. Иң яхшы халык укытучылары үзләренең педагогик эшендә Ушинский әсәрләрен кулланганнар.

Пушкинның поэзия даһилыгы Пушкин мәктәбенең бер төркем шагыйрьләрен тормышка алып килгән кебек, Ушинскийның педагогик даһилыгы да 60-70 еллардагы искиткеч педагогларның пәйда булуына китергән.

Россиянең башка халыкларның алдынгы (Грузия, Әрмәнстан, Казагыстан) педагогларына, Болгария, Чехия һәм башка славян халыкларына Ушинский зур йогынты ясаган.

1895 елда Ушинскийны искә алуның 25 еллыгына багышланган утырышта Модзалевский әйткәнчә: "Ушинский — нәкъ безнең халык галиме — Ломоносов, безнең халык шагыйре — Пушкин: безнең халык композиторы — Глинка кебек үк, безнең чын халык педагогы да".

К. Д. Ушинский үзенең эшчәнлеге белән башлангыч халык мәктәбенең белем дәрәҗәсен шактый югары күтәрде. Моңа бигрәк тә аның "Балалар дөньясы" һәм "Туган тел" исемле уку китаплары ярдәм итте.

Ул элек Коменский, Песталоцци, Дистервег төзегән күрсәтмәле укытуның методикасын киңәйтте һәм яңа ысуллар белән баетты, аңлылык, төплелек һәм ныклылык принциплары, шулай ук балаларның активлыгын һәм эшчәнлеген үстерү буенча күп яңалыклар кертте.

Бигрәк тә Ушинскийның мәктәп белән тормышның бәйләнеше турында идеясе әһәмиятле. Тормыш юлына аркылы торган мәктәпне тормыш бик тиз алып ташлый, "чын тәрбия бер яктан мәктәп белән, ә икенче яктан тормыш һәм фән белән арадашчы булырга тиеш", дип әйткән ул. Укытучы яңа буынны мәктәптән тормышка алып чыгуын, тәрбияләнүчеләрнең эшчәнлегеннән җәмгыять нигезенең үсеше бәйлелектә булуын һәрвакыт истә тотарга тиеш.

* * *

Егерме өченче лекция

К. Д. УШИНСКИЙ ҺӘМ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ

Атаклы педагоглардан Константин Дмитриевич Ушинский татар мәктәпләренә зур йогынты ясаган педагогларның иң олысы булып тора.

Урта белемне Чернигов губернасында, Новгород-Северский шәһәрендә, классик гимназиядә ала. Мәскәү университетының юридик факультетына кереп укый (1840-1844 нче еллар). Прогрессив профессорлардан тарихчы Грановский һәм либераль педагог Редкин аңа нык тәэсир итә. Редкин Ушинскийның философия белән кызыксынуына сәбәп була. Ул философиядән яхшы белем ала, ләкин бу белем идеалистик юнәлештә була. Университетны уңышлы бетереп, 1846 нчы елда Ярославль юридик лицеена профессор итеп билгеләнә. Талантлы укытучы булганга студентлар аны яраталар. Ләкин реакцион хөкүмәтнең педагогик политикасына каршы чыгуы өчен аны 1850 нче елда лицейдан китәргә мәҗбүр итәләр. Хәтта аңа өяз мәктәпләрендә укыту урыны да бирелми, ул политик яктан ышанычсыз кеше санала. Шуннан соң ул эчке эшләр министрлыгында вак чиновник булып эшли башлый, ләкин реакционер начальнигы Д. А. Толстой белән килешә алмыйча, бу эшен ташларга мәҗбүр була. 1866 нчы елда Д. А. Толстойны исә халык мәгарифе министры итеп күтәрәләр.

Ушинский 1855 нче елда Гатчинадагы ятимнәр институтына башта укытучы, соңыннан инспектор итеп билгеләнә. Шушы ук елларда педагогик мәкаләләр язу һәм тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә. Аның исеме педагоглар арасында таныла башлый.

Бу елларны язган мәкаләләреннән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: "Иҗтимагый тәрбиядә халыкчанлык турында" (1857 ел), "Хезмәт һәм аның психик һәм тәрбияви әһәмияте" (1860 ел). "Туган тел" (1861 ел) һ. б.

Ул 1859 нчы елны Петербургта Смольный институтының инспекторы булып эшли башлый. Бу институт дворян кызлары өчен ачылган ябык уку йорты була. Ушинский инициативасы буенча институтка күп яңалыклар кертелә. Уку вакыты

кыскартыла, ата-аналар белән бәйләнеш мәсьәләсе куела, яңа педагоглар туплана, институт каршында укытучылар хәзерләү курслары ачыла. Яңа уку планы төзелеп, ана телендә (рус теле) укыту кертелә. Моңа кадәр укыту француз һәм немец телендә барган була. Укучы кызлар (дворян һәм мещан кызлары) арасында дәрәҗә аерымлыкларын бетерү өчен көрәшә. Шушы ук елларда (1859-1862) Ушинский "Журнал министерства народного просвещения"ның мөхәррире булып та эшли. Педагогика, психология, халык мәгарифе эшләренә журнал аеруча зур урын бирә башлый. Элек бу журнал күбрәк рәсми отчетлар белән канәгатьләнеп килә торган була.

Ушинский шул вакытның алдынгы карашлы педагоглары белән педагогик-методик кичәләр, киңәшмәләр үткәрә.

Ләкин Ушинский прогрессив эшләрен киң җәелдерә алмый. Дошманнары — реакцион элементлар — аның өстеннән шикаять ясап, 1862 нче елда аны институттан кудыралар. Бу аның сәламәтлеген какшата, ләкин ул яраткан эшеннән аерылмый.

1862-1867 нче елларда Ушинский, укыту эшләрен өйрәнү өчен, чит илләргә командировкага китә. Анда "Родное слово", "Человек как предмет воспитания" дигән һәм башка атаклы әсәрләрен яза. Аның тарафыннан язылган "Родное слово" һәм "Детский мир" уку китаплары булып хезмәт итәләр.

Реакцион элементлар Ушинскийны дошман күрәләр, министр Д. А. Толстой хәтта аның китапларын мәктәпләрдән алдырта. 1866 нчы елда "Детский мир" дигән китабын укытуны тыялар. Прогрессив укытучылар Ушинскийга яхшы карыйлар. Аның "Родное слово" дигән дәреслеге рус мәктәпләрендә генә түгел, хәтта, чуваш, татар мәктәпләрендә дә бик күп тарала.

Ушинскийның сәламәтлеге елдан-ел начарлана, 1870 нче елда ул Кырымга дәваланырга бара һәм шуннан кайтышлый Одессада үпкә авыруыннан үлә. Россия үзенең атаклы педагогын югалта.

К. Д. Ушинский — патриот педагог. Ул туган иленә бөтен акылы, көче белән файда китерергә тырыша. Үзенең көндәлегенә ул түбәндәге сүзләрне яза: "Минем тормышымның бердәнбер максаты — Ватанга мөмкин кадәр күбрәк файда китерү, үземнең барлык сәләтемне мин шуңа юнәлдерергә тиешмен".

К. Д. Ушинский — реформа яклаучы педагог, ләкин революционер түгел. Ул крепостнойлыкны бетерү турындагы 1861 нче

елгы реформаны яхшы каршыласа да, Россиянең акрынлап үсүен тели, үзенең революцион хәрәкәттән куркуын ачык күрсәтә.

Ушинский — философик карашы буенча идеализмнан материализмга баручы. Аның философик һәм педагогик карашларында дин шактый зур урын тота.

Ушинский педагогиканың нигезе итеп психологияне ала. Ул, балага яхшы тәрбия бирү өчен, элек аның үзен һәрьяклап өйрәнергә, баланың психик үзенчәлекләреннән чыгып тәрбияне оештырырга кирәк, ди. Без аның бу фикере белән килешәбез, психологиянең педагогикага ярдәм итәргә тиешлеген таныйбыз. Ушинский укытучылар каршына эмпирик (тәҗрибәгә нигезләнгән) психологияне өйрәнү бурычын куя. Ул хәтер, дикъкать, кызыксыну, фантазия һ. б. турында уйлана, бу турыдагы фикерләрен укытучылар төркеменә язып калдыра.

К. Д. Ушинский — рус педагогикасын системага салуда күп энергия түккән педагог. Аңа кадәр бу мәсьәлә белән махсус рәвештә кызыксынучы кеше булмый.

Ушинский педагогик идеяләрендә халыкчанлык — "народность" идеясе кызыл җеп булып сузылып тора. Соңгы елларында анда халыкчанлык идеясе көчәя һәм ул укытучыларны халыктан — крестьяннар арасыннан хәзерләү мәсьәләсен куя, руханиларның укытучы булуына каршы чыга.

Тәрбия өлкәсендә Ушинский халыкчанлык мәсьәләсенә зур әһәмият бирә. "О народности в общественном воспитании" дигән мәкаләсендә бу мәсьәләгә карата төп фикерләрен яза. Ушинский фикеренчә, халык дәүләткә төп фактор булып тора. Халык дәүләт тормышында материаль кыйммәтләрне генә түгел, бәлки барлык рухи кыйммәтләрне дә барлыкка китерә. Хезмәт ияләре — гаять зур иҗат көченең, даһи һәм мәңгелек кыйммәтләренең чыганагы. Шагыйрь дә, музыкант та, фәлсәфәче дә, филолог та,— ди Ушинский,— илһамны халыктан алалар. Ушинский карашлары буенча, тәрбия эше халык ихтыяҗларын, халык үзенчәлекләрен, аның тарихи тормышын читләтеп үтә алмый. Шунлыктан башка халыклардагы тәрбия системасын механик күчереп алуга, аңа сукырларча иярүгә бернинди нигез юк. Россия үзенең тәрбия системасын булдырырга тиеш һәм булдырачак. Рус халкының иҗат көченә Ушинский нык ышана. Ул иҗтимагый тәрбиянең халыкчан булуын, халыкчанлыкка нигезләнүен, халык төркемнәренең тормыш мәнфагатьләренә нигезләнүен таләп итә. Белем бирү эше, дип белдерә

Ушинский, әгәр дә Ватан тормышын, әйләнә-тирәдәге табигатьне, географияне һәм туган илнең тарихын, аеруча рус телен инкарь итсә, халыкчан була алмый.

Халыкчанлык идеясеннән чыгып, Ушинский туган телдә укытуны таләп итә. Бу һичшиксез дөрес һәм прогрессив таләп була. Ушинский "Родное слово" дигән мәкаләсендә (1861 ел) туган телне "гаҗәеп педагог" дип атый. Шуңа күрә ул ана телен өйрәнүгә зур әһәмият бирә. Телне өйрәнеп, телнең төзелешен, логикасын, ягъни грамматиканы белергә кирәк, ди. Ләкин бу гына җитми. Балаларны телне аңларга өйрәтү — ул Ушинский әйткәнчә, аларны тел хәзинәләрен аңлы рәвештә белүгә алып бару дигән сүз.

Ана теленең әһәмиятен Ушинскийга кадәр берәү дә болай югары куйганы булмады.

Ушинскийдан соң ана телен яклаучы, педагоглар, методистлар күбәя башлый, әлбәттә.

Балаларны гаиләдә тәрбияләү эшенә ул нык әһәмият бирә, гаилә тәрбиясен мәктәп тәрбиясе белән бергә алып баруны яклый.

Башлангыч укуга карата Ушинский әһәмиятле күрсәтмәләр бирә. Балаларны укыту Көнбатыш илләрендәгечә бик яшьли (5-6 яшьтән), яки бик соң башланмаска тиеш, баланы, 7 яшьтә укуга хәзерли башлап, 8 яшьтән укытырга керешергә кирәк, ди ул. Бу яшьтәге балаларның акыл үсеше олы кешеләр җитәкчелегендә бик тиз үсеп китә. Тормышыбызның беренче җиде яки сигез елында,— ди Ушинский,— безнең хәтеребез шулкадәр күп нәрсә үзләштерә ки, калган бөтен тормышыбыз буена ул елларда үзләштергән кадәр күп үзләштерә алмыйбыз.

Ул гомуми белем, шуңа нигезләп кенә махсус белем бирү мәсьәләләрен куя. Бу фикер 1860 нчы еллардагы прогрессив педагоглар өчен характерлы. Алдынгы прогрессив педагог буларак, Ушинский фикеренчә, кеше хезмәт аша гына кеше була ала. Тәрбия хезмәткә нигезләнергә тиеш. "Хезмәт һәм аның психик һәм тәрбияви әһәмияте" исемле мәкаләсендә Ушинский болай яза: "Чын һәм шиксез ирекле хезмәт кеше тормышы өчен шундый әһәмиятле ки, аннан башка тормыш үзенең бәясен һәм бөтен кыйммәтен югалта. Хезмәт — кешенең алга баруы өчен генә түгел, хәтта аның ирешкән уңышын саклау өчен дә кирәкле шарт".

Ушинский балаларда эш сөючәнлекне тәрбияләү кирәк, ди. Тәрбия кешедә эшне сөю, эшкә гадәтләнү тойгыларын үстерергә

тиеш; ул кешегә тормышта хезмәтне эзләп таба белү юлын күрсәтергә тиеш,- ди.

Ушинский болай яза: "...Тәрбия кешенең акылын үстерү һәм кешегә билгеле күләмдә мәгълүмат бирү белән генә чикләнмәскә, бәлки кешедә җитди хезмәткә сусау да булдырырга тиеш".

Ушинский фәнгә белем ягыннан гына түгел, тәрбия ягыннан да зур әһәмият бирә. Ул, фәндә гаять зур тәрбия көче бар, ди.

Ушинский баланың шәхесен ихтирам итә. Ул балалар белән йомшак мөгалләмә таләп итә, ләкин урынсыз иркәләнүләргә каршы килә.

Педагог һәм аның карашлары мәктәп эшендә хәлиткеч урын тоталар. "Тәрбиячинең балага йогынтысы шундый көчле ки, аны бернинди уку китаплары белән дә, мораль өйрәтүләр белән дә, җәзалау һәм бүләкләү чаралары белән дә алыштырып булмый",— дип яза Ушинский.

Укыту процессына Ушинский актив һәм үзенчәлекле процесс итеп карый. Бала өчен уку җитди, ләкин көч җитә торган, аның сәләтен үстерә торган хезмәт булырга тиеш, ди. Яңа һәм актив укыту методларын яклап, Ушинский күрсәтмәлелекне аеруча алга куя.

Күрсәтмәлелек баланың фикерләү табигатенә бик туры килә. Моның турында Ушинский түбәндәгечә яза:

"Баланың табигате күрсәтмәлелекне таләп итә. Сез баланың үзенә билгеле булмаган биш сүз өйрәтеп карагыз, ул алар өстендә бик озак азапланыр; ә шундый ук егерме сүзне картинага бәйләп бирегез — бала шунда ук аларны үзләштерер. Сез балага бик гади фикер аңлатасыз, ул сезне аңламый; сез шул ук балага катлаулы картинаны аңлатыгыз, ул бик тиз аңлар. Бер үк вакыйганы бертигез сәләтле ике балага — берсенә картина буенча, икенчесенә картинасыз сөйләп карагыз, һәм шул ук вакытта сез картиналарның балалар өчен булган бөтен әһәмиятенә бәя бирерсез".

Күрсәтмәлелекне яклау белән бергә, Ушинский сөйләү методын да кире какмый, тик нык хәзерлек белән эшләргә кирәклекне әйтә. Ничек хәзерләнү һәм сөйләшүне ничек уздыру турында без Ушинскийда файдалы күп киңәшләр табабыз.

Ушинский укытучылык эшенә җитди карый: уен-көлке аша гына укытып булмый. Шуңа күрә укуны балалар өчен тоташ юанычка, күңел ачуга әйләндерергә ярамый. Балалар, алда торган бурычларны аңлап укырга тиешләр. Моның өчен балаларда

белемнәрне үзләштерүгә кызыксыну һәм мәхәббәт уятырга кирәк,- ди. Аның түбәндәге киңәше тулысынча нигезле: "...Шуны хәтердә тотыгыз, укытуда барысы да күңелле булмаска мөмкин, дәрестә, әлбәттә, күңелсез нәрсәләр бар һәм булырга тиеш. Сез баланы тормышка хәзерлисез, ә тормышта барлык бурычлар да кызыклы түгел, һәм әгәр сез баланы 10 яшенә кадәр җиңеллеккә өйрәтсәгез, сез аны куркыныч газапка хәзерләгән булырсыз; ул соңыннан кайвакыт бөтенләй кызыклы булмаган җитди уку бурычлары белән очрашыр".

Ушинский — киң карашлы, тирән белемле, теоретик яктан көчле, гамәли педагог.

Ушинский педагогикасындагы уңай яклардан без хәзер дә файдаланабыз. Ул педагогиканы фән итү өстендә иң күп эшләүче, схоластикага каршы көрәшүче, үрнәк дәреслекләр төзеп бирүче, аваз методын яклап чыгучы зур педагог иде. Аның дәреслекләре үрнәгендә күп дәреслекләр төзелде инде.

Ул табигать фәннәре укыту, хатын-кызларга ирләр белән тигез белем бирү мәсьәләләрен алга куйды. Ушинский педагогикасы дидактик материалларга бик бай. Ул укытучылык профессиясен югары күтәрде, педагогика өлкәсендә генә түгел, җәмәгать эшлеклесе булып та (педагогика җәмгыятен оештыра) күп хезмәт күрсәтте.

Константин Дмитриевич Ушинскийны, хаклы рәвештә, рус педагогикасының атасы, рус халык мәктәбенең нигезен салучы, укытучыларның укытучысы дип атыйлар. Шуның белән бергә, К. Д. Ушинский — рустан башка халыкларның, шул исәптән Идел буе татарларының, уку-укыту эшләре һәм педагогик фикерләренә дә зур йогынты ясаган.

XIX гасыр урталарына кадәр Россиядә теоретик педагогика җитәрлек эшләнмәгән, мәктәпләр аз булган, укытучыларны педагогик һәм методик хәзерләү турында кайгыртучы булмаган. 1856 нчы елда бөтен Россиядә башлангыч мәктәпләр саны 8227 булып, аларда укучылар саны 450002 кеше исәпләнә иде. Бу мәктәпләрдә укыту эшенең куелышы иң гади таләпләргә дә җавап бирми, аларда хадимнәр, аларның хатыннары, отставкага чыккан солдатлар, ә кайбер урыннарда аз белемле крестьяннар гына укыта. Мондый укытучылар балаларга белемне дә бирә алмаганнар.

Рустан башка халыклар арасында эш тагын да начаррак була. 1863 нче елда Россиядә рустан башка халыклар өчен барлыгы 331 мәктәп булып, анда 22753 кеше укыган. Идел буенда яшәүче рустан

башка халыклар арасында мәктәпләр саны турында төгәл мәгълүматлар юк, чама белән алганда, бер-ике дистәдән артмаган булса кирәк.

XIX гасырның 60 нчы еллары Россия тормышында борылыш чоры булып санала. Крепостное право җимерелә, суд эшләренә, земствога һәм башкаларга реформа кертелә, халык мәгарифе мәсьәләләре яңача куела, җәмәгать эшләре җанлана. Болар барысы да феодаль Россиянең буржуаз Россия булып үсүенә бәйләнгән.

Реформага кадәрге уку йортлары яңа тарихи шартларга җавап бирерлек түгел иде. "Реформа эпохасына" кадәр үк педагогика мәйданына чыккан К. Д. Ушинский крепостное право җимерелүен шатланып каршы ала. Ушинский: җәмгыятьнең төп принцибы — алга бару, дигән караштa тора. Алга китүне ул азатлыктан һәм аңбелемнән башка күз алдына китерә алмый. "1861 нче елның 5 нче марты" исемле мәкаләсендә ул: "Гражданнарча яшәү өчен уянган бу халык өчен... никадәрле күп мәктәп кирәк!" дип язды. 1862 нче елның ноябрендә язган хатында ул: "Нәкъ менә хәзер Россиягә оештырылган мәктәпләр, яхшы хәзерлекле укытучылар, күп һәм бик күп мәктәпләр кирәк булган вакыт килеп җитте",— дип язды. Рус халкының белемгә булган зур омтылышын күрсәтеп: "...Кайда гына мәктәп салынмасын, ике-өч көн эчендә ул шыгрым тулы була",— дип билгеләп үтте.

Рус халкы тормышында XIX гасырның 60 нчы елларында булган үзгәрешләр Россиядәге башка халыкларның тормышына да тәэсир итә. Бөек рус халкы, аның алдынгы кешеләре гасырлар буе аралашкан халыкларның тарихи язмышларына уңай йогынты ясый. 60 нчы еллардан башлап, Россиянең зур уңышларга ирешкән фәне, әдәбияты, сәнгате рустан башка халыкларның, шул исәптән, Идел буе халыкларының үсешендә дә зур роль уйный.

Мәктәп-белем бирү эшенә рус педагогик фәненең тәэсире турында сөйләгәндә, К. Д. Ушинскийны беренче планга куймый мөмкин түгел. РСФСР Педагогик фәннәр академиясе академигы профессор Медынский 1954 нче елның 4 нче октябрендә "Известия" газетасында басылган мәкаләсендә: "Безнең илебезнең төрле халыкларының иң яхшы прогрессив педагогларына — грузиннарга (Я. Гогебашвили), әрмәннәргә (Агаян), азәрбайҗаннарга (Рәшит Әфәндеев), казахларга (Алтынсарин) һәм татарларга Ушинскийның, педагог буларак, йогынтысы гаҗәеп файдалы иде. Яңа әлифба

һәм уку китапларына Ушинскийның "Родное слово" дигән дәреслегенең йогынтысы аеруча көчле булды",— дип яза.

Илья Николаевич К. Д. Ушинскийга бик якын була. Сембер губернасы мәктәпләренә, шул исәптән татар мәктәпләренә дә Ушинскийның йогынтысы аның аркылы керде. Илья Николаевич Ушинский идеяләрен һәм аның методик күрсәтмәләрен мәктәп практикасына кертергә тырышты. Аның "Родное слово" исемле уку китабын Сембер губернасы мәктәпләре куллана башлады. Ушинскийның аваз методын, укыту эшендә күрсәтмәлелекне Сембер губернасы укытучылары бик киң кулландылар.

Казан мәктәпләре эшенә, татарлар арасында педагогик фикер үсүгә К. Д. Ушинскийның йогынтысы зур була. Татар мәгърифәтчесе, язучы һәм педагог Каюм Насыйри К. Д. Ушинскийның замандашы була. Каюм Насыйри рус мәдәниятын якын күрә һәм татар халкын рус халкы белән якынлаштыру ягында тора. Ул заман мәктәпләрендә фән укыту мәсьәләсен куючы, фәнни эчтәлекле дәресләкләр язучы кеше Каюм Насыйри була. Каюм Насыйри татар балаларына рус теле укыту мәсьәләсен куя һәм шул юлда практик эш башлап җибәрә. Каюм Насыйри эшчәнлеге белән К. Д. Ушинскийның педагогик фикерләре арасында зур уртаклык бар. Бу — аларның бер үк төрле иҗтимагый шартларда эшләүләре белән аңлатыла. Мәсәлән, К. Д. Ушинский ул вакыттагы рус җәмгыятенең югары катлавы булган дворяннарның халык массасы теленә кимсетеп каравына, чит ил телләрен өстен күрүләренә каршы үзенең бөтен педагогик көче һәм таланты белән көрәшә һәм ана телендә укытуны яклый. Каюм Насыйри да үз заманындагы "укымышлы" морзалар һәм руханиларның гади халык теленә кимсетеп карауларына каршы көрәш ача, татар телен фәндә, әдәбиятта һәм педагогик эштә файдалану һәм аңа чын гражданлык хокукы бирү мәсьәләсен алга куя. XIX гасырның икенче яртысында яшәгән татар галимнәре, язучылары һәм педагоглары арасыннан берсе дә татар теленең ролен һәм әһәмиятен Каюм Насыйри кебек көчле һәм кискен итеп куймый. Шуңа күрә бу мәсьәләдә Ушинский нинди роль уйнаган булса, татар халкы өчен Каюм Насыйри да шундый ук рольне уйный.

Ушинский һәм Насыйриның хезмәт һәм хезмәт тәрбиясенә бер үк төрле карауларын аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк. Алар икесе дә акыл хезмәтенә дә, физик хезмәткә дә югары бәя бирәләр. Кешенең яхшы әхлаклы һәм бәхетле булуының чыганагын алар хезмәттә

күрәләр, хезмәт кешене югары күтәрә диләр. Балаларга мөрәҗәгать итеп, Насыйри: "Һөнәр өйрәнегез, һөнәре булмаган кеше үзенә дә, бүтәннәргә дә файда китерә алмый",— ди.

Насыйри да укытуда күрсәтмәлелек авазлар методы яклы, схоластикага, шаблонга һәм трафаретка каршы көрәш алып бара. Ушинский кебек үк, укытучыга югары бәя бирә, аңа зур таләпләр куя.

Ушинский "Родное слово" исемле уку китабында фольклор материалларына (әйтемнәргә, мәкальләргә, әкиятләргә һ. б.) зур игътибар бирә.

К. Насыйри да халык аваз иҗаты белән кызыксына, фольклор материалын җыйный, өйрәнә. Насыйри — татарның беренче фольклорчысы, К. Д. Ушинский үзенең уку китапларында бай фольклор материалыннан файдалана. Бу нәрсә Каюм Насыйрида да көчле. Каюм Насыйриның Казанда саклана торган архив фондында аның тарафыннан төзелгән уку китаплары исемлегендә К. Д. Ушинскийның "Детский мир"ы да күрсәтелә. Бу китап урта мәктәпнең түбән сыйныфлары өчен тәкъдим ителгән. Каюм Насыйри үзенең уку китапларында "Детский мир"дагы мәкаләләрне кертә. Кайбер хикәяләрнең эчтәлегеннән бик оста файдалана.

Ушинский тәэсирен профессор Мөхетдин Корбангалиев эшчәнлегендә, аның методик хезмәтләрендә һәм методик кулланмаларында, беренче чиратта, ана теле укыту методикасында да ачык күрергә мөмкин.

Г. Тукайның тәрбия һәм укыту мәсьәләләре турындагы фикерләрен К. Д. Ушинскийның педагогик идеяләре белән чагыштырып карасак, Г. Тукайда да, К. Д. Ушинскийда да педагогик идея — халыкчанлык, ана теленә зур мәхәббәт, балаларга фәнни белем һәм хезмәт тәрбиясе бирү, гуманлылык кебек иң яхшы сыйфатларга корылганнар.

Мәктәпләр өчен Г. Тукай тарафыннан төзелгән "Яңа гыйбарәт" һәм "Мәктәптә милли әдәбият дәресләре"ндә Ушинскийның "Родное слово", "Детский мир" тәэсире бар, һәм китаплардагы хикәя һәм шигырьләрнең кайберләрен Тукай үз әсәрләренә керткән. Г. Тукайның "Эш беткәч, уйнарга ярый" һәм "Бала белән күбәләк" дигән шигырьләре Ушинскийның "Кончай дело — гуляй смело" һәм "Мотылек" исемле шигырьләренә якын торалар. Г. Тукай, Ушинский кебек үк, ана телен халыкчанлыкның иң гүзәл күренеше дип атады. Тукайның педагогик фикерләрендә ана теленә гаять зур

урын бирелү менә шуннан килеп чыга да инде. Г. Тукай ана теленең белем һәм тәрбия бирүдәге әһәмиятен искиткеч тирән һәм тулы аңлады.

Ушинский рус дворяннарының үз ана телләренә караганда француз яки немец телен артыграк күрүләрен гаепләде. Г. Тукай исә татар "укымышлылары"ның гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә укытуларын һәм язуларын каты тәнкыйтьләде.

Г. Тукай Белинский, Толстой, Крылов, Некрасов, Кольцов, Плеханов һәм башкаларның әсәрләре белән дә бик кызыксынды, аларны өйрәнде. Иң алдынгы рус язучылары, шагыйрьләре, педагоглары эзеннән барып, аларның алдынгы идеяләре һәм фикерләре белән танышу өстенә, Тукай татар балаларының һәм яшьләренең тормыш шартларын, көнкүрешләрен, әхлакларын, аң-белем дәрәҗәләрен исәпкә алып, үзенең иҗади әсәрләрен тудырды. Ул профессиональ педагог һәм мәгариф эшчесе булмаса да, уку китапларының авторы буларак, педагогика һәм дидактиканың иң әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итүгә ярдәм итте. Тукай рус телендә басылып чыккан уку китапларын, шул исәптән, К. Д. Ушинский әсәрләрен зур игътибар белән тикшереп барды, татар мәктәпләре өчен иң файдалы һәм яраклы дип тапкан материалларны җыйды, үзенең уку китапларында да файдаланды.

К. Д. Ушинскийның балалар өчен язган күп хикәяләре татарча "Туган тел" дәреслекләренә урнаштырылып, хәзер дә татар балалары аларны укый. Башлангыч сыйныф программасының сыйныфтан тыш уку өчен тәкъдим ителгән китаплары исемлеге бүлегендә Ушинскийның байтак әсәрләре күрсәтелә.

Идел буе татарларының педагогик фикерләренә К. Д. Ушинскийның йогынтысы, һичшиксез, зур булды. Ушинскийның уку китаплары һәм аның методик кулланмалары мәктәптә укыту-тәрбия эшләренә күп яңалык керттеләр. Ушинскийның халыкчанлык, гуманизм идеяләре, мәктәпләрдә ана телен укыту, фәнни белем бирү, укучыларны хезмәткә өйрәтү турындагы карашлары үзләренә лаеклы урын алдылар. Шуңа күрә К. Д. Ушинский — рустан башка халык укытучыларының да остазы дип әйтсәк, ялгышмабыз.

* * *

Егерме дүртенче лекция

Н. Г. ЧЕРНЫШЕВСКИЙ — ЯЗУЧЫ ҺӘМ МӘГЪРИФӘТЧЕ

Николай Гаврилович Чернышевский 1828 нче елны Саратов шәһәрендә рухани гаиләсендә туа. Саратовта духовная семинариядә укып урта белем алганнан соң, ул 1846 нчы елны Петербург университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Университетта рәсми укытыла торган фәннәр белән генә канәгатьләнми, белемен үзлегеннән күтәрү өстендә дә нык эшли.

Ул XXIII йөздәге француз материализмын өйрәнә. Немец фәлсәфәчесе, материалист Фейербах Чернышевскийга зур йогынты ясый, ләкин Чернышевский аның фәлсәфәсе белән генә канәгатьләнми. Активлыкка, көрәшкә өндәми торган Фейербах фәлсәфәсе революционер Чернышевскийга ошамый, ул моның белән килешә алмый.

Чернышевский университетта укыган елларда Николай I хөкүмәтенең реакцион сәясәте көчәя. Патша хөкүмәте һәртөрле революцион хәрәкәтләрне рәхимсез баса. 1849 нчы елны Петрашевский түгәрәге таратыла. Түгәрәккә катнашучылардан 5 кеше кулга алына. Чернышевский бу түгәрәкнең әгъзасы булмый, ләкин алар белән элемтәдә була. Европадагы 1848 елгы революция яшь Чернышевскийга нык тәэсир итә.

1850 нче елда инде ул монархиянең дошманы булып әверелә. Аның уйлавынча, Россиядә крестьян революциясе булырга тиеш. Ул революцион газета чыгарырга уйлый һәм коралны восстание планын хәзерли.

Университетны 1850 елны тәмамлагач, Чернышевский туган шәһәре Саратовка кайтып, гимназиядә әдәбият укыта башлый. Ул прогрессив карашлы, яңа тип педагог була. Аны укыту эше генә канәгатьләндерми. 1853 нче елны Саратовтан Петербургка күчеп, анда профессорлык диссертациясе якларга хәзерләнә.

Диссертация өчен "Эстетические отношения искусства к действительности" ("Сәнгатьнең чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәте") дигән теманы сайлый. Чернышевский диссертациясен бик уңышлы яклый. Ләкин "гыйльми киңәшмә" аның эшен идеологик зарарлы дип таба. Чөнки ул заман галимнәре Чернышевскийның материалистик карашы белән килешмиләр.

Шуннан соң Чернышевский әдәби эшкә керешә. Петербургта чыга торган "Современник" журналының әдәби хезмәткәре булып китә. "Современник"та 1854 нче елны аның диссертациясе басылып чыга.

1856 нчы елдан Чернышевскийның тәнкыйтьче материаллары басыла башлый. "Современник" журналында крепостной рус тормышын үзгәртү турында мәкаләләре басыла. Бу журнал алдынгы революцион идеяләренең органы була.

1858 нче елны Чернышевский яңа гына институт бетереп чыккан яшь революционер Н. А. Добролюбовны журнал редакциясенә алуга булыша һәм аңа журналның әдәби тәнкыйть бүлеген тапшыралар.

Чернышевский, Добролюбов белән берлектә, "Современник"ны шул заманның алдынгы журналына әверелдерәләр. Бу журналда һәм журналга өстәмә итеп чыгарылган китапларда Чернышевскийның крестьян мәсьәләсе буенча күп кенә хезмәтләре, "Рус әдәбиятының Гоголь чоры очерклары", "Лессинг, аның заманы, тормышы һәм эшчәнлеге" һ. б. мәкаләләре басылып таратыла.

1856-1862 нче елларда инде ул революцион язучы булып китә. 1861 нче елгы реформадан соң Россиядә крестьяннар хәрәкәте көчәя. Бу хәрәкәт башында Чернышевский тора. Патша хөкүмәте 1862 нче елны Чернышевскийны кулга алып Петропавловский крепостена яба.

1863 нче елда "Современник" журналында Чернышевскийның Петропавловский крепостенда язган "Нәрсә эшләргә?" дигән атаклы романы басылып чыга. Чернышевскийның 20 ел гомере төрмәдә, Себердә уза.

1881 нче елның беренче мартында патша Александр II үтерелә. Хөкүмәт революцион көчтән бик курка. Нәтиҗәдә, Александр III кайбер ташламалар ясарга мәҗбүр була. 1881 нче елны Чернышевский азат ителә. Ләкин аңа үзәк шәһәрләрдә тору хокукы бирелми. Ул Астраханьда яши. Тик үләр алдыннан гына туган иленә кайтырга рөхсәт ителә. Чернышевский 1889 нчы елда вафат була.

Соңгы көннәренәчә демократиягә тугрылыклы булган Н. Г. Чернышевскийга бик югары бәя бирелә.

Чернышевский психиканы материянең бер үзлеге итеп карый. Материядән тыш бернинди сизү, ирек һәм уй булу мөмкин түгел. Рух материягә бәйле хәлдә генә яши.

Чернышевский Кант карашына каршы чыга: "Тормышның материаль шартлары бөтен үзгәрешләрнең нигез сәбәпләрен һәм шул хисаптан тормышның югары сферасын биләп торалар",— ди ул.

Чернышевский "Сәнгать сәнгать өчен" дигән идеалистик карашка үзенең диссертациясендә каршы чыгып, сәнгатьнең чынбарлык белән тыгыз бәйләнештә булуын аңлата.

Кеше яхшы тормышка аңлы рәвештә омтылырга тиеш. Димәк, патша Россиясендә изелеп килгән крестьяннар да яхшы тормыш өчен көрәшергә тиешләр. Чернышевский, әлбәттә, реализмга таба бара. Әдәбият чынбарлыкны чагылдырырга тиеш һәм ул эчтәлеге ягыннан иҗтимагый әһәмиятле булырга тиеш, ди Чернышевский.

Чернышевский кешенең табигатендә дөньяны тану ачкычын күрде. Ул тарихи процессның закончалыклы үсешен, идеянең икътисади һәм сыйнфый мөнәсәбәтләргә бәйле булуын таныды.

Билгеле, Чернышевский диалектик материализм югарылыгына кадәр күтәрелеп җитми. Ул Фейербах антропологизмында материализмның иң югары формасын күрә. Иҗтимагый тормыш мәсьәләләрендә ул идеализмга якын тора.

Чернышевский Россия крепостной төзелешенә каршы көрәшә. Ул крестьян революциясенең идеологы буларак, массаны крепостнойлыкка, изүчеләргә каршы көрәшкә өндәде. Масса арасында культура-агарту эшләрен юлга салу өстендә эшләде. Һәм шуларны тормышка ашыруны үзенә бурыч итеп куйды. Ул либералларга каршы көрәште. Тормышны көрәш аша үзгәртүне алга куйды. Ләкин ул эшче сыйныфның, пролетариатның ролен тулысынча аңлап җитмәде. Аның бу җитешсезлеге Россиянең артта калып яшәвеннән килә иде.

Чернышевский үзенең педагогик эшендә шул чордагы мәктәп һәм мәгариф эшләренең куелышына каршы чыга, чөнки патша Россиясендә уку, укыту-тәрбия эшләре гадәттән тыш начар була. Педагогик карашлары белән Чернышевский революцион-демократик педагогикага таянучы, аны үстерүче була. Ул Белинский һәм Герцен тарафыннан күтәрелеп чыккан демократик педагогика идеяләрен тагын да югары күтәрә, баета. XIX йөзнең икенче яртысында революцион-демократик педагогика зур көч булып әверелә. Ул чорда мәктәпләрдә белем бирү бары тик дворян, буржуа катлавы өчен генә булып, хезмәт ияләре балалары өчен бик аз санда башлангыч мәктәпләр генә яши.

Чернышевскийның педагогик карашлары аның әдәби әсәрләрендә, публицистик һәм тарихи мәкаләләрендә бирелгән. Ул крестьян массасына белем бирүне нигез итеп куя һәм бу фикерен алдынгы идеяләр белән бәйләнештә үстерә. "Мәгариф — һәрбер яхшылыкның тамыры",— ди Чернышевский. "Белем бирү — кеше өчен иң бөек яхшылык",— ди. Тәрбия, белем бирү һәм укыту арасындагы тыгыз бәйләнеш турында Н. Г. Чернышевский болай дип яза: "Белемле кеше дип, күп белем алган һәм шуның өстенә нәрсәнең яхшы һәм дөрес булуын, һәм нәрсәнең начар һәм дөрес булмавын тиз һәм дөрес уйларга күнеккән, яки, бер сүз белән әйткәндә, "Фикер йөртергә" сәләтле кеше; һәм, ниһаять, аңы һәм тойгылары яхшы һәм югары дәрәҗәле юнәлеш алган, ягъни бөтен яхшы һәм гүзәл нәрсәләрне нык ярата торган кеше атала. Кешенең чын мәгънәсендә белемле булуы өчен шушы сыйфатларның өчесе дә — киң белемле, фикер йөртүгә сәләтле һәм тойгыларның яхшы булуы зарур".

Тәрбия һәм белем бирүдә максат — яшь буынны киләчәк төзү өчен көрәшерлек кешеләр итеп тәрбияләү,— дип яза Чернышевский.

Ул үзенең диссертациясендә тулысынча материалистик карашларны чагылдыра. "Сәнгать һәм әдәбият тормыштан аерым яшәми, алар җәмгыять тормышы белән бәйле. Ләкин тормышны алга җибәрү өчен хәрәкәт итәргә, көрәшергә кирәк, тормышны алга алып баруга комачаулаучы нәрсәләрне юк итәргә кирәк. Әдәбиятчы, язучы шул чынбарлыкны чагылдырырга тиеш",— ди ул.

Чернышевский үз заманындагы мәктәпләрне каты тәнкыйть итә, алар балаларны бозалар, тупасландыралар, ди. Үзенең мәкаләләрендә мәктәпләрнең бик аз проценты гына балаларны үз эченә алуы турында, укыту методларының начар һәм схоластикага нигезләнгән булуы турында, мәктәпләрне җиһазландыру эшләренең бик начар торуы турында күрсәтеп уза.

Чернышевский шул чорның мәктәп һәм педагогика эшләрен тәнкыйть итү белән генә калмый, мәгариф эшен яхшыртуга карата кискен таләпләр куя. Россиядә фәннең кысылып яшәвен, һәр тип мәктәпләрнең (башлангыч, урта, югары) белем бирүләре бик түбән булуын күрсәтә. Укучы сәләтен үстерүнең юклыгын, талантка урын булмавын тәнкыйтьли. 1862 нче елда "Ясная поляна" журналының I һәм II китаплары белән танышканнан соң, ул Л. Н. Толстойның, тәрбия һәм белем бирү мәсьәләсендә каршылыклар белән тулы

булган педагогик идеяләрен тәнкыйть астына ала. Толстойның: "Халык грамотага өйрәнергә теләми" дип раславын ул аеруча тәнкыйтьли. Чернышевский халыкны — крестьян массасын — агарту кирәклеген әйтеп, халык мәктәпләренең санын арттыруны таләп итә.

Чернышевский тәрбиянең икътисадый шартлар белән бәйле булуын күрсәтә. Барлык милләтләргә белем бирү кирәклеген кую белән бергә, ул һәр милләтне ана телендә укытуны һәм ана телендә дәреслекләр белән тәэмин итүне яклап чыга.

Ул хатын-кызларга ирләр белән тигез белем бирү ягында була. Аның бу карашы "Нәрсә эшләргә?" романында бик ачык чагыла.

Романда әйтелгәнчә, кеше үз акылы белән җитәкчелек итә белерлек булырга тиеш.

Хатын-кызларны ирләрнең колы булып торудан коткарырга, аларга тормыш өчен үзләренә ышанычлы кешене сайлап алырга ирек бирергә кирәк. Аларга ирләр белән бертигез белем бирергә, аларны эшкә, хезмәткә тартырга, хатын-кызларны җәмгыять эшчесе итеп тәрбияләргә кирәк.

Мәсәлән, Вера Павловна тегүчелек мастерское оештыра. Бу хосусый оешма гына булмыйча, кооператив оешма үрнәге була.

Вера Павловна төшендә 4 көн рәттән алдынгы җәмгыять төзелешен күрә. Аларда киләчәктә булачак тормыш тасвирлана.

Революционер Рахметов элек дворян була. Соңыннан барлык байлыгын революция эшенә бирә, үзе эшче була, физик көчен сыный, тәнен чыныктыра, көрәшкә хәзерләнә. Рахметов шул чорның иң алдынгы, кирәкле кешесе — ялкынлы көрәшче була. Рахметов аша Чернышевский көрәшче образын гәүдәләндерә.

Чернышевский романында көчле оптимизм чагыла. Бу роман оптимист булырга, киләчәктәге бәхетле тормыш өчен нык көрәшергә өнди. "Нәрсә эшләргә?" романы азлап-азлап "Современник" журналында басылып бара. Басылып беткәч кенә, цензура бу романның патша режимы өчен зарарлы булуын сизеп ала һәм аны бастыруны тыя. Бу роман үзенең укучылары, шул чордагы разночинец яшьләр өчен тормыш программасы булып хезмәт итә.

Ул: "Тарихи алга барыш фәнгә, белемгә тулысынча ия булганнан соң гына мөмкин",— ди. Бу — аның җитешсезлеге. Бу фикер аның дөньяны материалистик тануда диалектик материализм карашына күтәрелеп җитә алмавын күрсәтә. Шул ук вакытта Чернышевский белемгә ия булуның икътисадый шартларга бәйле булуын да әйтә.

Ул танылган педагогларның карашлары белән таныша (Руссо, Песталоцци, Оуэн һ. б.). Ул гомуми белем бирүне яклый, һәр яктан хәзерлекле, белемле яңа җәмгыять төзергә яраклы кешеләр тәрбияләүне максат итеп куя. Шулай ук ул алган белемне тәҗрибәгә бәйли белүгә зур әһәмият бирә. Укучыларга яшьтән үк белгечлек бирүгә каршы чыга.

Патша Россиясе мәктәпләрендә махсус тар белем бирелә. Түбән катлауны урта һәм югары мәктәпләргә җибәрмәс өчен төрле чикләүләр куелган. Чөнки патша хөкүмәте түбән катлауның аңы үсүдән курка. Чернышевский махсус белемнең гомуми белемгә нигезләнгән булуын әйтә. Белгечләр хәзерләү белән уйнарга ярамавын күрсәтә.

Чернышевский һәр яктан хәзерлекле кешене тәрбияләп чыгару өчен, акыл белеме белән физик тәрбияне бергә бәйләп алып баруны яклый. Тәрбияләнгән, белем алган кеше производствоның бер тармагында гына эшләмәскә, төрле тармакларында эшли белергә тиеш,— ди ул. Уку-укыту планнары балаларда һәм акыл белемен, һәм физик тәрбияне бергә бәйләп алып барырлык итеп төзелсен һәм балага чынбарлыкны дөрес аңларга ярдәм итсен, баланы киләчәк җәмгыять тормышын төзерлек итеп хәзерли торган фәннәр укыту планына кертелсен,— ди.

Чернышевский фәннәрне үзара бутамауны, аларны тиешенчә нигезле һәм системалы, дөрес эчтәлекле итеп укытуны яклый, тәрбия һәм белем бирүдә чит телләрне өйрәнүгә һәм сәяхәткә зур урын бирә. Ул латин, грек, француз, немец, инглиз телләре белән дә таныш була, татар телен өйрәнү өстендә дә күп кенә эшли. Аның кулъязмалары арасында 1200 сүзне эченә алган татарча-русча сүзлеге Мәскәүдә үзәк әдәбият архивында саклана.

Чернышевский һәр фәнне укытуны (бигрәк тә әдәбият укыту) балалар тәрбиясе белән нык бәйләнергә тиеш, ди. Балаларны көчләү, җәзалау алымы белән тәрбияләүгә каршы чыга. Бала белән укытучы арасында яхшы мөнәсәбәт булырга тиеш, укытучы баланы һәр яктан тулы өйрәнергә, шуннан чыгып кына балаларга якын килергә тиеш,— ди ул.

1851-1852 нче елларда Чернышевский Саратов гимназиясендә укыта. Ул балалар белән дөрес мөнәсәбәт булдыра. Тар программалар белән генә канәгатьләнеп калмый, программадан тыш балаларга киң белем бирә, укучыларга крепостной төзелешнең зарарлыгын аңлата.

Балаларны өйрәнмичә, алар белән зурлар шикелле мөнәсәбәт оештыру — җинаять,— ди Чернышевский. "Теге яки бу эшкә баланы көчләп кушмаска, бәлки аның инициативасын үстерүгә ярдәм итәрлек мөнәсәбәт тудырырга кирәк",— ди. Н. Г. Чернышевскийның бу күрсәтмәләреннән Толстойча ирекле тәрбия бирүне аңларга ярамый, бәлки балага дөрес тәрбия, дөрес юнәлеш бирә торган тәрбияне аңларга кирәк.

Чернышевский шул чорның дәреслекләрен тикшерә. Аларга карата түбәндәге таләпләрне куя:

1) Дәреслекләр фәнни булсыннар, шул чорның фәнни яңалыкларын эчләренә алсыннар;

2) Дәреслекләр материалның бөтен ваклыкларын эченә алмаска, ә гомуми белем бирүгә нигезләнеп, кыйммәтле нигез материалны гына эченә алырга тиеш;

3) Материалның системалы бирелүе зарури;

4) Нигез материалны вак моментларны чагылдыра торган материаллар белән бутамаска, дәреслек тулы, ләкин җыйнак булырга тиеш;

5) Материал төгәл һәм ачык итеп бирелсен.

Ул балалар әдәбиятына да зур игътибар бирә. Борынгы мәктәпләрдә балаларга ялыктыра, кызыксынуны югалта торган идеясез китаплар, экиятләр бирелгән. Чернышевский мондый дәреслекләрне каты тәнкыйтьләп, балалар әдәбиятына карата түбәндәге таләпләрне куя: катлаулы булмаган, грамоталы китаплар бирергә, бу китапларга тормышта булмаган нәрсәләрне тутырмаска, психологик нечкәлекләр белән мавыкмаска кирәк. Балалар әдәбияты табигый, дөрес һәм гади булырга, моның өчен балаларның телен, аларның нәрсә белән кызыксынуларын өйрәнергә кирәк.

Н. Г. Чернышевский укытучылар эшенә югары бәя бирде һәм крепостной Россиядә педагогның роле хурлыклы рәвештә бозылуын әйтте. Укыту һәм тәрбия эшенең сыйфаты укытучының хәзерлекле булуына бәйле булып, баланың артта калуының сәбәбен беренче чиратта укытучыдан эзләргә кирәк дип күрсәтте.

Ул укытучыга педагогик яктан хәзерлекле булу таләбен генә түгел, бәлки сәяси яктан да хәзерлекле булу кирәклеген куйды. Балаларны бөек таләпләргә җавап бирерлек итеп тәрбияләү — педагогның төп максаты, диде.

* * *

Егерме бишенче лекция

А. С. МАКАРЕНКОНЫҢ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

Гүзәл педагог Антон Семенович Макаренко 1888 елда, 1 (13) мартта Харьков губернасы, Белополь шәһәрендә туган. Аның атасы тимер юл мастерскойларының маляр цехында оста булып эшләгән.

Шәһәр училищесын һәм укытучылык курсларын тәмамлагач, 1903 елда, А. С. Макаренко Крюково поселогында (элекке Полтава губернасы) ике класслы тимер юл училищесында укытучы булып эшли башлый. Аның педагогик эшчәнлеге менә шуннан башлана да инде.

1905 ел революциясе чорында Антон Семенович укытучы булып эшли торган мәктәп шул урындагы революцион эшнең үзәге булып китә. Мәктәп мөдире М. Г. Компанцев һәм А. С. Макаренко бу эштә актив катнашалар. Мәктәптә, еш кына, тимер юл эшчеләренең җыелышлары үткәрелә.

Бу хәл администрациягә беленә һәм халык училищелары инспекторы Компанцевны Харьков губернасы, Долинская станциясе янындагы икенче мәктәпкә күчерә. 1911 елда А. С. Макаренко да шул мәктәпкә эшкә китә.

Бу мәктәптә 3 елга якын эшләгәч, инде халык укытучысы хезмәтендә 10 ел стажы булган Антон Семенович, 1914 елда, Полтава укытучылар институтына укырга керә һәм аны 1917 елда алтын медаль белән тәмамлап чыга.

1917 елның 1 сентябреннән ул Крюково поселогындагы югары башлангыч училищега инспектор булып билгеләнә.

Октябрь революциясен А. С. Макаренко зур шатлык белән каршы ала. Революция чорын исенә төшереп, ул еллар турында соңыннан Антон Семенович: "Октябрьдан соң минем алдымда зур перспективалар ачылды. Без, педагоглар, ул перспективалардан шул кадәр исердек ки, хәтта үз-үзебезне оныттык",— дип яза.

Әле яңа гына оештырылган совет мәктәбендә эшли башлаган. А. С. Макаренко, шул чакта ук инде тәрбия эшендә яңа юллар эзли башлый: ул укучылардан ныклы, бердәм коллектив тупларга тыры-

ша, аларның мәктәп яны участогындагы эшләрен оештыра, укучылардан хезмәт отрядлары төзи, аларның хезмәт эшчәнлегенең хәрби формаларын тудыра, тынлы оркестр оештыра.

1920 елның көзендә Полтава губерна мәгариф бүлеге Антон Семеновичка яше җитмәгән закон бозучылар өчен колония оештыру эшен тапшыра.

Полтавадан 6 километр ераклыктагы элекке кече яшьтәге җинаятьчеләр өчен булган колониянең ярым җимерек бинасында А. С. Макаренко Горький исемендәге хезмәт колониясенә нигез сала.

Революциягә кадәр яшәп килгән колониянең барлык җиһазлары таланып беткән, тәрәзә пыялалары алынган, мичләре сүтелгән була. Антон Семеновичка алар белән бергә эшләргә туры килгән, беренче тәрбияләнүчеләр төркеме — үткәннәре төрле җинаятьләр белән бәйләнешле, эшсезлеккә гадәтләнгән, педагогларны мыскыллап хурлаучы берничә яшүсмер һәм яшь егетләрдән торган төркемчә була. Тиздән тагын берничә төркемчә килә. Февральгә инде колонистларның саны 50 гә җитә. Зур түземлелек һәм педагогик такт белән, үзенең тәрбияләнүчеләре турында тирән кайгыртучанлык күрсәтеп, хуҗалык җимереклеге һәм оештыру чоры аркасында килеп чыккан кыенлык һәм азапларны алар бергә кичереп, колониянең тәрбия һәм хуҗалык эшләрен рәтләүгә бөтен энергиясен биреп, Антон Семенович тәрбияләнүчеләрдән ныклы, тату коллектив оештыруга ирешә. 1926 елда, колониянең хуҗалыгы инде чәчәк аткан чорда, колонистлар Харьков янындагы Куряжга күчәләр. Элек анда тәрбия күрмәгән, бозылган 280 бала яшәгән. Кыска гына вакыт эчендә Куряж танымаслык хәлгә килә: Антон Семенович һәм аның "горькилылары" куряжлыларны үз йогынтыларына буйсындыруга ирешәләр. Куряжга күчү һәм Макаренконың андагы эше аның педагогик системасының дөреслеген һәм нәтиҗәле булуын иң ышандырырлык рәвештә раслаучы дәлилләрдән берсе булып тора. Кыска гына вакыт эчендә куряжлылар Горький исемендәге колониянең элекке тәрбияләнүчеләре кебек үк тәртипле, ыспай булып китәләр, үзләренең бурычларын аңлау һәм намуслылык тойгылары белән сугарылалар. Колонистларның саны 500 гә җитә.

Кайбер педагог — администраторларның аның тәрбия системасына кире караулары нәтиҗәсендә, 1928 елның җәендә Макаренко Горький исемендәге хезмәт колониясендә эшләвен ташларга мәҗбүр була һәм үзенең бөтен көчен Харьков шәһәре читендә урнаш-

кан Дзержинский исемендәге хезмәт коммунасының эшенә җитәкчелек итүгә бирә. Бу коммунада тәрбиячесез калган балалар һәм яше җитмәгән закон бозучылар тәрбияләнгән була.

Дзержинский исемендәге коммунада А. С. Макаренко үзенең инде сыналган һәм тәмам төгәлләнеп җиткән тәрбия системасын куллануын дәвам итә һәм тәрбия эшендә искиткеч яхшы нәтиҗәләргә ирешә.

Авыл хуҗалыгы хезмәте һәм Горький исемендәге колониянең үз ихтыяҗларына хезмәт күрсәткән мастерскойларда эшләү белән генә канәгатьләнмичә, үзенең "коллективны алга этәрү" принцибына нигезләнеп, Антон Семенович, хезмәт тәрбиясенең яңа формаларын кертә: Дзержинский исемендәге коммунада катлаулы ике предприятие: фотоаппаратлар җитештерү һәм электр бораулары җитештерү предприятиеләре төзелә.

Барлык коммуналылар көнгә 4 сәгать предприятиедә һәм, югары техникага нигезләнгән завод предприятиесендә эшләү белән бергә, урта мәктәптә дә укыйлар. Коммунарлар урта мәктәпне билгеләнгән вакытта, бик яхшы дәрәҗәдә белем алып тәмамлыйлар һәм төрле белгечлекләр буенча булган югары уку йортларына керү имтиханнарын бик уңышлы бирәләр. Предприятиеләр бик рентабельле булып чыгалар: предприятиеләрне оештыру һәм җиһазлау өчен алынган ссудалар бик кыска вакыт эчендә кире кайтарылалар, коммуна тулысынча коммунарларның шул предприятиеләрендәге хезмәтләреннән килгән акчага яши, һәм, аның өстәвенә, 1934 елның 1 январена 3 600 000 сум саф табыш алына.

Культура-агарту эшләре коммунада киң куелган: үзенең театры, клубы бар, төрле түгәрәкләр эшли, хәрби-физкультура эшләре алып барыла. Коммунарларның 60 музыканттан гыйбарәт тынлы оркестры Харьковта иң яхшы оркестр булып хисаплана. Коммунада иң югары орган булып коммунарларның гомуми җыелышы хисаплана.

Коммунаның үзенең традицияләре тудырыла һәм бу традицияләр тәрбияви яктан гаять зур роль уйныйлар. Коммунаның намусы барлык коммунарлар тарафыннан югары дәрәҗәдә ихтирам ителә.

Антон Семенович коммунарлар арасында гаять зур абруй белән файдалана, ләкин бу абруй һичбер төрле басымга нигезләнмәгән. Киресенчә, коммунаның барлык иң мөһим эшләре коммунарларның гомуми җыелышы һәм командирлар советы тарафыннан хәл

итэлэ торган була. Антон Семенович бу җыелышларда һәрвакытта катнашса да, ул аларда шактый сирәк хәлләрдә генә чыгып сөйли. Шул ук вакытта коммунаның бөтен тормышына юнәлеш бирүче һәм аның белән җитәкчелек итүче Антон Семенович булуын һәрбер коммунар сизә.

1935 елда А. С. Макаренко Дзержинский исемендәге коммунадан китә, ул элек Киевка, аннан Мәскәүгә күчеп, әдәби эш белән шөгыльләнә башлый.

Горький исемендәге колониядә үзенең эшчәнлеген башлап җибәрү чорында ук, оригиналь педагогик тәҗрибәнең беренче уңышлы нәтиҗәләре күренгәч тә, 1925 елда, Антон Семенович Макаренко үзенең гүзәл әсәрен — соңыннан киң күләмдә танылган һәм дан казанган "Педагогик поэма"ны яза башлый. Бу әсәрнең беренче өлешен ул 1928 елда язып бетерә, ләкин әле соңыннан да тагын биш ел буенча бу әсәр өстендә эшләвен дәвам итә.

1930 елда ул "Педагогик поэма"ның кульязмасын Горькийга җибәрә, Горький бу әсәргә, дөнья әдәбиятының гүзәл әсәрләреннән берсе сыйфатында югары бәя бирә.

"Педагогик поэма" 1933-1935 елларда Альманахта басылып чыга һәм, басылып чыгу белән үк, укучыларның игътибарын үзенә тарта. 1933, 1935 һәм 1940 елларда аның бер-бер артлы аерым басмалары чыгып тора. "Педагогик поэма"да кеше тәрбиясенең гаять зур әһәмияте һәм искиткеч киң мөмкинлекләре бик ачык күрсәтелгән. Анда бик матур, гади, шул ук вакытта гаять тирән рәвештә Макаренконың, соңрак байтак кына теоретик хезмәтләрендә ачыкландырылган, бөтен педагогик системасы тулысы белән диярлек бирелгән.

"Педагогик поэма" басылып чыккач, Антон Семеновичка бик күп хатлар килә башлый. Укытучылар һәм ата-аналар анардан киңәш сорыйлар, үз тормышларында һәм эшләрендә очраган кыенлыклар турында аның белән уртаклашалар. Ул аларга шәхси консультацияләр бирү, радио аша сөйләү һәм докладлар, лекцияләр уку юллары белән җавап бирә, үзенең мәкаләләре белән еш кына матбугатта чыга.

Ул чорда гаилә тәрбиясе мәсьәләсе аерата үткен төс ала. Бу хәл Антон Семеновичның үзенең "Ата-аналар китабы" исемле әсәрен язарга мәҗбүр итә, бик күп ата-аналар белән аралашу нәтиҗәсендә Антон Семеновичта бу мәсьәлә буенча зур материал тупланган була. А. С. Макаренконың бу әсәре 1937 елда "Красная новь" журналында һәм шул ук елда аерым китап булып та басылып чыга. Бу

әсәрдә балаларның һәм ата-аналарның ачык образлары, реаль көн-күреш эпизодлары һәм педагогик күренешләр кызыклы һәм оригиналь педагогик фикерләр белән аралаштырылып биреләләр һәм менә шуларның барысы педагогик принциплар тирәсенә берләштереләләр, бу принциплар исә бөтен бер системаны тәшкил итәләр.

1938 елда "Октябрь" журналында Антон Семеновичның "Башня-ларда флаглар" исемендә өченче зур күләмле педагогик әсәре — өч бүлектән торган повесте басылып чыга. Бу повесть "Педагогик поэма"ның дәвамы рәвешендә бирелеп, анда Дзержинский исемендәге коммунаның педагогик казанышлары сурәтләнә.

Шул ук вакытта Макаренко "Колхозные ребята", "Смена", "Дружные ребята" һәм башка журналларда балалар һәм яшүсмерләргә язылган күп кенә хикәяләрен бастыра.

"Известия" газетасында һәм башка вакытлы матбугатта күп кенә педагогик мәкаләләр белән чыга, "Литературная газета"да тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләрен урнаштыра.

Үзе вафат булганнан соң басылып чыккан мәкаләләрен һәм чыгышларының стенограммаларын кушып исәпләгәндә, Антон Семеновичның әдәби әсәрләренең гомуми саны 80 гә җитә, ләкин әле аның бөтен язганнары һәм докладларда, лекцияләрдә сөйләгәннәренең күп өлеше матбугатта басылып чыга алмый.

Эшкә тәмам бирелеп, Антон Семенович ял һәм дәвалану турында уйламый, ә аның талчыккан организмы ялга һәм дәвалануга мохтаҗ була.

Ул 1939 елның 1 апрелендә язучыларның шәһәр янындагы ял йортыннан кайтканда вокзалда кинәттән вафат була.

Антон Семенович белән саубуллашырга төрле яклардан аның тәрбияләнүчеләре килә. Ул тәрбиячесез калган һәм закон бозучы балалардан 3000 ләп кешене — чын-чыннан яңа кешеләрне, Ватанга чиксез бирелгән намуслы гражданнарын, үзенең бурычын тирәнтен аңлаган, зур ихтыярга ия булган, инициативалы кешеләрне, тәртипле, хезмәт сөюче кешеләрне тәрбияләп чыгарды.

Антон Семеновичның элекке тәрбияләнүчеләре арасында бик күп һәм төрле-төрле һөнәр вәкилләре: инженерлар, агрономнар, хәрби кешеләр, укытучылар, врачлар, юристлар, шоферлар һ. б. бар.

Аның тәрбияләнүчеләренең күбесе Кызыл Армия сафларында немец илбасарларына каршы көрәште. Күбесе орденнар белән бүләкләнделәр. Алар арасында Советлар Союзы Геройлары бар.

А. С. Макаренконың педагогик мирасы — аның озак дәвам итеп килгән тәрбия эше тәҗрибәсе, бу тәҗрибәне әдәби әсәрләрендә чагылдыручы һәм педагогика буенча теоретик хезмәтләре, тәрбия мәсьәләләренә карата язылган күп сандагы мәкаләләре — оригиналь һәм төз бер педагогик системаны тәшкил итәләр.

Макаренко тәрбия эшендә диалектик материализм законнарыннан бик оста файдалана, төрле каршылыкларны, мәсәлән, шәхес һәм җәмгыять, ирeклек һәм зарурлык, бурыч һәм хокук, педагогның хакимлеге һәм тәрбияләнүчеләр оешмасы хокуклары, таләпчәнлек һәм мәхәббәт кебек каршылыкларны чишү юлларын эзли һәм таба, шул ук вакытта ул бу каршылыклар арасында югалып калмый, аларны бер-берсенә капма-каршы итеп куймый, бәлки, аларның бердәмлеген таба.

Макаренко һәрбер кешенең шәхесенә бәя бирә белгән: кеше кабатланмый, дип сөйләргә яраткан ул. Кешедә ул һәрбер шәхеснең үзенә генә хас булган үзенчәлекне күрә белгән, шул ук вакытта ул, кешене җәмгыятьтән тыш итеп уйлау мөмкин түгел, дип бик дөрес күрсәткән, һәрбер кешенең шәхесенә сак мөнәсәбәттә булу һәм һәрбер тәрбияләнүчене гаҗәп осталык белән өйрәтү белән бергә, Макаренко һәрвакытта да беренче планга коллектив таләпләрен куйган: "Шәхси бәхет өчен түгел, бәлки гомуми бәхет һәм гомуми көрәш өчен тәрбияләргә кирәк",— дигән ул.

Макаренконың бөтен педагогик системасы дөрес куелган тәрбиянең көченә һәм киң мөмкинлекләренә тирән ышаныч белән сугарылган.

Макаренконың барлык педагогик эшчәнлеге һәм педагогик фикерләре кешегә, аның көченә һәм мөмкинлекләренә, шулай ук тәрбиянең әһәмиятенә тирәнтен ышанып карау белән кыйммәтле.

"Минем тәҗрибәмнән кайбер педагогик нәтиҗәләр" дигән мәкаләсендә ул болай дип яза: "Кешегә карата мөмкин кадәр зуррак таләпчәнлек, ләкин шуның белән бергә аңа карата мөмкин кадәр зуррак ихтирам күрсәтү — һәрвакыт минем төп принцибым булып килде. Хәзер, безнең диалектикабызда ул башкача була да алмый, чөнки үзен ихтирам итмәгән кешедән зур нәрсәләр таләп итү мөмкин түгел".

Менә шул гуманлылыктан чыгып, Антон Семенович үзенең һәрбер тәрбияләнүчесенә канун бозучы итеп карамый, бәлки зур иҗат көченә ия булган кеше итеп, бары тик аның өчен уңышсыз хәлләр туу аркасында гына беркадәр бозылган кеше итеп карый.

Макаренконың педагогик системасы чыганакларын, аның гуманизмын һәм оптимизмын, аның шәхескә һәм җәмгыятькә карата булган карашларын аңлау өчен һәм аның педагогик принципларын тәрбия эше эшчәнлегендә куллану өчен һәр педагогка Антон Семеновичның "Минем тормышымда Горький" исемле мәкаләсен бик зур игътибар белән укып чыгарга кирәк. Ул мәкаләдә, әлбәттә, укытучы педагог әзер рецептлар таба алмас, ләкин ул мәкалә укытучыны тәрбияләнүчеләргә карата дөрес караш белән коралландырыр, Макаренконың педагогик системасын аңлау һәм көндәлек педагогик эшчәнлектә ул системаны дөрес һәм иҗади рәвештә куллана белү ачкычын бирер.

Теге яки бу укучы укытучыга нинди генә дәрәҗәдә тәртипсез, ялкау, гыйлемсез кебек булып күренсә дә, Макаренконың педагогик системасы эзеннән барырга теләгән укытучы-педагог көчсезләнеп, аптырап калырга, бу укучыны төзәлүдә ышанычсыз дип, аңардан котылырга тырышырга тиеш түгел, бәлки, ул укучыны яхшылап өйрәнергә, аның уңай, яхшы сыйфатларына нык ышанып, аның яхшы якларын уятырга һәм үстерергә тиеш.

Макаренконың педагогик системасының иң мөһим принципларыннан берсе булган "перспектив сызыклар системасы" җәмгыятьтә шәхес проблемасы, гуманлылык һәм оптимизм, балаларга карата таләпчән мәхәббәт белән тыгыз бәйләнештә тора. А. С. Макаренко үзенең "перспектив сызыклар системасын" аңлатып, "Педагогик поэма"сында түбәндәгечә яза: "Әгәр дә кешенең киләчәк тормышында бернинди дә шатлык-өметләре булмаса, ул кеше дөньяда яши алмый. Кешенең иртәгә булачак шатлыгы — тормышының чын стимулы ул... Кешедә без иң кадерле һәм кыйммәтле дип санарга гадәтләнгән сыйфатлар — көч һәм матурлык. Кешене тәрбияләү — аңарда кешенең киләчәктәге шатлыкларының перспектив юлларын тәрбияләү дигән сүз".

Тәрбияләнүчеләрнең бөтен коллективында һәм аның һәрбер әгъзасында нindидер бер максатка омтылыш һәм дәрт тудырырга, аларның йөрәкләрендә шул максатка омтылу утын кабызырга кирәк: көч, хезмәт кую һәм көрәш нәтиҗәсендә шул максатка ирешү — тирән канәгатьләнүне — "иртәнге шатлык"ны бирер. Билгеләнгән максатка ирешү белән тукталып калмаска, бәлки алга тагын да күбрәк, тагын да киңрәк, тагын да иҗтимагый — әһәмиятлерәк яңа бурычлар куярга һәм, үз көченә тагын һәм тагын зуррак ышаныч белән, күбрәк һәм яхшырак эшләргә кирәк.

А. С. Макаренконың "перспектив сызыклар системасы"ның асылы кыскача гына әйткәндә шуннан гыйбарәт.

А. С. Макаренконың педагогик системасының беренче положениесе — коллективист тәрбияләп үстерү. Коллектив эчендә, коллектив өчен һәм коллектив аша тәрбияләү мәсьәләсенә А. С. Макаренко үзенең һәрбер чыгышында һәм һәрбер мәкаләсендә диярлек туктала, һәм бу бик аңлаешлы, чөнки шәхес һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәте мәсьәләсе аның системасында методологик нигез булып тора. Шәхесне җәмгыятьтән тыш, коллективтан тыш итеп карарга мөмкин түгел.

Коллектив төшенчәсе астында Макаренко кешеләрнең очраклы җыелмасын гына аңламый, бәлки гомуми хезмәт аша гомуми максатка ирешү өчен берләшкән, билгеле бер системага салынган вәкаләтләре һәм җаваплылыгы булган кешеләр берләшмәсен, аның аерым өлешләре арасында билгеле үзара мөнәсәбәт һәм үзара бәйләнешлелек урнаштырылган берләшмәсен аңлый.

Балалар коллективына җитәкчелек итә белүне, коллективның ихтыярын тудыруны һәм аны бөтен нәрсәдә тәрбиячинең җитәкче ихтыярына туры килә торган ихтыяр итүне Макаренко дөрес куелган тәрбия бурычларыннан иң мөһиме итеп хисаплады. Үз абруен балалар алдында югары куя алган, балаларның гаять тирән ышанычына һәм мәхәббәтенә ирешкән, зур педагогик такт һәм сизгерлеккә ия булган һәм үз тәрбияләнүчеләрен белгән педагог кына коллективка, ул үз җитәкчесенең ихтыярын гәүдәләндерерлек итеп җитәкчелек итә ала. Бары тик шул шартларда гына тәрбиячинең абруе һәм коллективның зур реаль хокуклары гармоник берләшәләр.

Коллектив тормышында үз бурычыңны һәм намусыңны аңлау тойгысы, коллективны ихтирам итү тойгысы зур әһәмиятле урын тота. Коллективның һәрбер әгъзасы бу тойгылар белән рухланган булырга, бөтен коллектив өчен җавап бирергә һәм коллектив үзенең һәрбер әгъзасы өчен җавап бирергә тиеш.

Макаренко фикеренчә, аерым шәхескә тәэсир итү ул аның әгъзасы булып торган коллективка тәэсир итү юлы белән үткәрелгәндә күпкә көчлерәк була. Бу положениене Макаренко "параллель тәэсир итү принцибы" дип атый.

Ныклы, тату коллектив бары тик аның эчендә өлкәннәрдәге яхшы якларны кечеләргә тапшыру, өлкән яшьтәгеләр белән кече яшьтәгеләр арасында дуслык мөнәсәбәте яшәгәндә генә туа ала.

һәрбер коллективта, вакыт үтү белән, билгеле традицияләр тудырылырга, һәм бу традицияләр коллективка килеп кергән яңа әгъзалар тарафыннан төгәл дәвам иттерелергә тиеш.

Макаренко коллективта уенга зур урын бирә. "Балалык чорында уен, ул — норма, һәм бала һәрвакытта да, хәтта җитди эш башкарганда да уйнарга тиеш,— ди ул. — Балада уенга дәрт бик зур, һәм менә шул дәртне канәгатьләндерергә кирәк".

Макаренконың педагогик системасының икенче төп сыйфаты — хезмәткә тәрбияләү.

Хезмәт сөючәнлек һәм хезмәткә сәламәтлек системалы рәвештә тәрбияләнергә тиеш,- дип Макаренко бик дөрес исәпли. Хезмәт иҗади, шатлыклы булырга, аңлы хезмәт булырга, шәхес һәм талантны күрсәтүдә төп форма булырга тиеш. Хезмәт, гаять зур иҗтимагый әһәмияткә ия булу белән бергә, кешенең шәхси тормышында гаять зур роль уйный, чөнки хезмәт акыл, әхлакый, эстетик һәм физик тәрбия белән тыгыз бәйләнгән, кешегә үзенең көченә карата ышаныч тудыра, үз-үзеннән зур канәгатьләнү һәм шәхси бәхет тудыра.

А. С. Макаренко җитәкчелегендә тәрбияләнүчеләрнең хезмәт эшчәнлеге Горький исемендәге колониядә бик зур урын алып тора, ә инде Дзержинский исемендәге коммунада исә иң югары ноктага күтәрелеп җитә.

Хезмәт тәрбиясе мәсьәләсенә карата әйткән фикерләрендә: "Педагогик поэма"да, "Башняларда флаглар"да, "Ата-аналар китабын"да, "Балалар тәрбияләү турында лекцияләр"дә һәм кайбер мәкаләләрендә Антон Семенович күп кенә кыйммәтле методик күрсәтмәләр бирә. Балаларның хезмәт эшчәнлегендә, бигрәк тә эшне планлаштырганда, ориентировкалана белүгә, вакыт белән, производство кораллары һәм материаллар белән эш итә белүгә, эшнең сыйфатына зур игътибар бирергә кирәк. Хезмәт тәрбиясе процессында билгеле күләмдә эшнең төрлелеге, бер эштән икенче эшкә күчә белү, шул ук вакытта инде туйдырып бетергән эшне дә ахырынача эшләп җиткерә белү зур әһәмияткә ия булып тора.

Тәртип, җаваплылык, намуслылык тойгысы тәрбияләү — Макаренконың тәрбия системасында өченче төп нигез булып тора.

Макаренконың педагогик системасында тәртип проблемасы зур урын тота.

Тәртипне элекке гадәт буенча тәрбия чарасы гына итеп карауга каршы буларак, Макаренко тәртипне тәрбиянең нәтиҗәсе итеп ка-

рый, һәм ул нәтиҗәгә ирешү өчен педагог тарафыннан зур көч кую таләп ителә, ди.

Тәртипне "көрәш һәм җиңеп чыгу дисциплинасы" итеп аңлауны алга сөрә, Макаренко бу мәсьәләне балада ихтыяр, батырлык һәм ныклы характер тәрбияләү белән тыгыз бәйләнештә ала.

Үзеңнең бурычыңны аңлау идеясенә тыгыз бәйләнешле рәвештә, Макаренко, намуслылык тойгысы тәрбияләүне куйды.

Коллектив эчендә тәрбияләү, хезмәт тәрбиясе, аңлылык һәм үз бурычыңны аңлау, намуслылык һәм дисциплина тойгылары тәрбияләү, эстетик һәм физик тәрбия, гаилә тәрбиясе, педагогик такт һәм педагогик эш стиле мәсьәләләре һәм тәрбия эше буенча булган башка бик күп мәсьәләләр Антон Семенович тарафыннан оригиналь, тирәнтен һәм кыю рәвештә теоретик эшләнделәр һәм тәҗрибәдә, гамәлдә сыналдылар.

Ул эстетик тәрбиягә күп игътибар бирде. Чисталык, киемнең пөхтә булуы, төгәллек, максатка омтылучанлык һәм гүзәл гадилек, хәрбиләштерү һәм символик элементлары, хор һәм оркестр, театр, кино һәм киң күләмдә куелган клуб эшләре, матур әдәбият уку, чәчәкләр, көнкүрешнең, хезмәтнең һәм ялның, сөйләмнең һәм хәрәкәтнең матурлыгы, эш итү һәм фикер йөртү эстетикасы — эстетик тәрбияне Антон Семенович менә шундый киң итеп аңлады һәм аны акыл, әхлак һәм физик тәрбия белән тыгыз бәйләнештә булырак карады.

Бу эстетика коммунарларның — Макаренкода тәрбияләнүчеләрнең бөтен тышкы күренешләрендә үк күзгә бәрелеп тора, җыйнаксызлыкның бөтенләй булмавы, хәрәкәтләрнең аныклыгы, фигураның ыспайлыгы һәм төзлеге, сөйләмнең кыска һәм эчтәлекле булуы коммунарларны характерлый торган сыйфатлар иде.

А. С. Макаренко педагог проблемасын бик кызыклы һәм оригиналь эшләде. Яңа кешеләр тәрбияләү белән бергә, иң элек педагог үзе яңа кешенең үрнәге булырга — олы шәхес булырга тиеш. Ул төгәл белемгә һәм педагогик осталыкка ия булсын.

Педагог балаларны яратырга, шуның белән бергә үк таләпчән, катгый, үз дигәнендә нык торучан булырга, балаларны күзәтә белергә, алар алдында абруйлы булырга тиеш.

А. С. Макаренко — бик нечкә психолог, ул балаларны аларның хезмәт һәм ял вакытларында, бер-берсенә мөнәсәбәтләрендә, уеннары вакытында күзәтү юлы белән бик тирәнтен өйрәнә белә. Бу турыда А. М. Горький: "Макаренко үзенең күп сандагы тәрбиялә-

нүчеләренең һәрберсен бик яхшы белә һәм берничә сүз белән аларның характерын әйтеп бирә, ул биргән характеристика шул кадәр дөрес була ки, әйтерсең, ул фотографиягә төшереп ала",— дип язды.

Макаренко — педагог-рәссам, һәм аның педагог-рәссам булуы гүзәл сәнгать әсәрләре язуында гына түгел, бәлки аның һәрбер тәрбияләнүчесенә педагог-рәссам булып якын килүендә, педагогик мәсьәләләрне дөрес итеп чишә белүендә. Макаренко эштә шаблон, трафарет, әзер рецептлар куллануга бервакытта да юл куймый һәм аларны дошман күрә, һәрбер аерым очракта мәсьәләне иҗади һәм чын мәгънәсендә чишә.

Шуңа күрә үзенең педагогик системасын тулы һәм матур итеп, үзенә бертөрле сәнгать-педагогик формада бирүе бик табигый хәл.

* * *

Егерме алтынчы лекция

КАПИТАЛИСТИК ИЛЛӘРДӘ МӘГАРИФ

Үсешкә ия булган капиталистик илләрдәге халык мәгарифе системасының гомуми үзенчәлекләре шундый: мәктәпнең сыйнфый үзенчәлеге, раса, милли һәм дини дискриминация, привилегияле хосусый мәктәпләр булуы. Хезмәт ияләре балаларының интеллектуаль кимчелеге турында фикернең киң таралуы, хезмәт ияләре балаларына тиешле белем бирүне юкка чыгарырга юнәлдерелгән "акыл сәләтлелеге" исемле теорияне кертү.

Феодал заманыннан аермалы буларак, ә ул чакта мәктәп катлам үзенчәлекле иде һәм һәрбер катлам өчен аерым мәктәпләр төзелгән булган, капитализмда рәсми яктан берләштерелгән мәктәп игълан ителгән. Ул мәктәпкә халыкның барлык катламы да керә ала, ләкин чынында мәгариф өлкәсендә тигезсезлек хөкем сөрә. Буржуазия мәктәбе белем бирүне киңәйтүдә феодал мәктәбенә караганда бер адым алга атлады, ләкин белемне һәркемгә җиткерерлек итмәде. Хезмәт ияләре балаларының барысы да урта мәктәпкә керә алмый, аларның сирәк саны гына укуын дәвам итә ала. Түләүсез урта белем бирү турында игълан иткән илләрдә хезмәт ияләре балалары бу хокуктан файдалана алмый: дәреслекләр хакын, спорт шөгыльләрен, лаборатор эшләрен һәм уку вакытында үз чыгымнарын каплау өчен түләргә акчасы юк.

Буржуазия халык мәгарифе системасының үзенчәлеге ике яклы. Белем алуда барысы да тигез мөмкинлектә һәм хокукта икәнлеге турында реклама таратылып торса да, чынында исә ике аерым система яшәп килә: берсе элита өчен, икенчесе матди яктан ярлылар өчен. Балаларның бер системадан икенче системага күчүе мөмкин түгел диярлек. Хезмәт ияләре балалары гадәттә мәҗбүри мәктәптә һәм аның белән бәйләнештә булган түбән профессиональ уку йортында укыйлар. Алар өчен тупик мәктәпләр булдырылган. Ул мәктәпләрдә гомуми белемне уку дәвамын урта мәктәпләрдә башкару өчен биреп җиткермиләр, ә укучыларны физик хезмәт өлкәсендә эшләү өчен әзерлиләр.

Предприятие тотучыларның һәм коммерсантларның, югары чиновникларның һәм интеллигенциянең өстенлекле өлеше балалары урта мәктәпләрдә укыйлар, соңыннан югары уку йортларына керәләр. Аларның күпчелеге дәүләт мәктәпләрен түгел, ә уку өчен артык түләүле булса да, яхшы җиһазланган һәм квалификацияле укытучылар булган хосусый мәктәпләрне артык күрәләр. Алар промышленностьта, сәүдә, дәүләт аппаратында җитәкче эш урыннарын алу өчен әзерлиләр.

Франциянең югары уку йортларында эшчеләр гаиләсеннән булган студентлар саны илдәге эшчеләр саны белән чагыштырганда 5 тапкыр кимрәк, ә өстенлекле катламның студентлары иҗтимагый төркемнең чагыштырма санына караганда 6 тапкыр артык.

Капиталистик илләрдә хезмәт ияләренең урта һәм югары мәктәпләргә керү мөмкинлекләрен чикләү мәгариф өлкәсендәге раса, милли һәм дини дискриминация дә сәбәп булып тора. Феодализм белән революцион көрәш вакытында буржуазия мәгарифнең дөньявилыгына, чиркәүнең мәктәпкә йогынтысын бетерүгә ирешә алган булса, хакимиятне алгач, буржуазия мәгарифнең дөньявилыгын тулысынча булдыра алмады, ә чиркәүнең мәктәп белән бәйләнеше урнашты.

Ләкин, мәктәп үсешенең перспективасын билгеләүдә хәлиткеч тавыш, ахыр чиктә, монополия вәкилләрендә кала, һәм алар барлык яңалыкларны үзләренең позицияләрен ныгыту өчен һәм халык массаларына каршы кулланырга тырышалар.

Хәрби промышленность комплексның концерн, фирма, монополия тотучыларның сәясәте сыйнфый көрәшнең һаман кискенләшә баруына китерә. Безнең көннәрдәге кебек, аның беркайчан да шулай кискенләшкәне булмады. Хезмәт ияләренең империалистлар белән ашкынып кораллануга каршы, хәрби конфликтлар китереп чыгаруга, хәерчелек, салымнар авырлыгы һәм эксплуатация артуга каршы сыйнфый бәрелешләренең нык кызган шартларында прогрессив укытучыларның эшчәнлеге активлаша. Укытучылар эш шартларын яхшырту һәм хезмәт хакларын таләпләре белән беррәттән раса дискриминациясен бетерү һәм бербилгеләүне арттыру өчен лозунглар белән чыгыш ясыйлар. Бу эштә аларны укучыларның прогрессив өлешләре яклый.

Студентларның оппозицион хәрәкәте бик киң җәелеп китте. Мәгарифнең демократик реформаларын үткәрү таләпләре белән

беррәттән алар империалистик хөкүмәтләрнең тышкы һәм эчке сәясәтенә каршы чыгалар.

Халык мәгарифенең һәм мәктәпнең хәле. Югарыда күрсәтелгәнчә, хәзерге буржуазия мәктәбенең үзенчәлекле сыйфатлары һәрбер капиталистик илдә халык мәгарифенең тарихи рәвештә урнашкан аерым система кысаларында күренә. Үсешкә ия булган кайбер капиталистик илләрдәге халык мәгарифе системасын карап үтәбез.

Англия мәктәпләре. Англиянең халык мәгарифе системасы структурасы 1944 елдагы мәктәп законы яисә "Мәгариф турында акт" ("Акт об образовании") исеме белән билгеләнгән. Сугыштан соңгы демократик хәрәкәтләрнең үскән шартларында кабул ителгән бу закон мәктәп системасының унификациясен, барлык гражданнарның урта белем алу мөмкинлекләрен киңәйтүне яшьләрнең табигать фәннәре һәм техника өлкәсендә әзерлеген яхшыртуны, укучыларның кызыксынучанлыгын һәм сәләтлелеген үстерүне күздә тота.

Чынбарлыкта бу мөһим бурычлар, иң беренче өстенлектә торучы көчләр мәнфәгате өчен хәл ителә.

Англиядәге халык мәгарифе системасының нигезендә 5 тән 11 яшькә кадәр балаларга исәпләнгән башлангыч мәктәп тора. Ул ике баскычтан тора: 5-7 яшьлек балалар өчен ике еллык мәктәп һәм 7-11 яшьлек балалар өчен дүртьеллык уку вакыты булган чын мәгънәсендә башлангыч мәктәп.

Башлангыч мәктәпләрдә укырга, язарга, санарга, кул эшенә, йорт эшенә, дингә өйрәтәләр. Түбән классларда балалар белән физик һәм эстетик тәрбия үткәрәләр, ә югары классларда табигать белеме, география, тарих буенча мәгълүмат бирәләр.

Мәктәпкә кергәндә балаларга тестлар буенча җавап бирергә тәкъдим итәләр һәм шулай итеп аларның акыл сәләтлелеген билгелиләр.

11 яшьтә балалар акыл сәләтлеген сынауга тартылалар һәм сынау нәтиҗәләренә карап, урта мәктәпнең төрле типларына җибәреләләр.

1944 елның "Мәгариф турында акт" буенча урта белемнең 3 төре каралган: җиде һәм сигез еллык урта грамматик мәктәп; биш һәм җиде еллык уку вакыты булган урта техник мәктәп; һәм ниһаять, хәзерге заман исемле дүртьеллык мәктәп.

Урта дип аталган барлык бу мәктәпләр бер-берсеннән уку вакыты, максатлар, бурычлар, белем бирүнең эчтәлеге һәм метод-

алымнары һәм мәктәп тәмамлаучыларга биреләчәк хокуклары буенча аерылып торалар.

Англиядә яңарыш чорыннан бирле яшәп килүче һәм традиция буенча классицизмны һәм гуманитар фәннәрне ихтирам итүче грамматик мәктәпләр генә тулы урта белем бирәләр һәм университетка кирәргә әзерлиләр.

Укучыларның күп өлеше биш классны тәмамлагач, бу мәктәптән чыгып китә; тиешле имтиханнарны тапшыргач, алар фирма, контора хезмәткәрләре һ. б. булып урнашалар, яисә профессиональ мәктәпләрдә укуларын дәвам иттерәләр.

Калган укучылар ике ел эчендә грамматик мәктәпнең өлкән классларында җитди белемнәр үзләштереп, "югары" дәрәҗәдәге таныклык — өлгергәнлек аттестаты алалар һәм вузга керергә хокуклы булалар. Грамматик мәктәпләрдә дифференцияле укыту кулланыла.

Түбән классларның уку планнарында вакытның 60-65 процентын гуманитар циклдагы фәннәр (туган тел, латин теле һәм хәзерге телләрнең берсе, тарих, география, музыка, сәнгать), математика һәм табигать белеме — 20-25 проц., физик тәрбия — 10-13 проц., дин — 3 проц., алып торалар. Кызлар йорт эшләре белән, малайлар агач һәм металл эшләре белән шөгыльләнәләр. Укучылар III-IV класслардан башлап сайлап алынган гуманитар, табигать фәннәре, математика профильләре буенча укуларын дәвам иттерәләр. Бу чикләнү гомуми белем алуга зыян китерә. VI чыгарылыш класста тагын да ниндидер бүлек сайлап алырга кирәк була: гуманитар, табигать, математика (яисә табигать-математика), иҗтимагый-икътисади, техник, йорт эшләре бүлекләре һ. б. Биредә һәркем үз теләге буенча түбән рәвештә күп санда булмаган уку фәннәре өйрәнә.

Грамматик мәктәпләр уку-укыту җиһазлары белән яхшы тәэмин ителгән балалар белем ала, анда квалификацияле укытучылар эшли.

Соңгы егерме ел эчендә грамматик мәктәпләрдә укучылар саны бераз артты, хәзер бу яшьләрдәге 20-25 процент кешеләр тулы урта белем алалар һәм аларның кайбер өлеше югары уку йортына керә.

Белем бирүнең эчтәлеге буенча үткәрелгән реформа грамматик мәктәпләрдәге уку планында табигать белемнәре дәрәҗәсен күтәрде. Ләкин "яңа тәрбия"нең һәм прагматизмның традиция йогынты-

лары аркасында мөстәкыйль "тикшеренүләр" һәм укытучыларның үз "ачышлары" белән артык мавыгу күзәтелә.

Башлангыч мәктәпне тәмамлаучылар арасыннан табигать һәм техник фәннәрне өйрәнүдә зур сәләтлелек күрсәткән укучыларны (чагыштырмача күп санда булмаган) урта техник мәктәпләргә җибәрәләр. Алар башлангыч мәктәп тәмамлаучыларның 5-7 процентын тәшкил итәләр. Урта техник мәктәпләрдә, югары техник уку йортларында укуларын дәвам итәргә җыенганнар өчен шактый зур белемнәр бирелә.

Башлангыч мәктәпләрне тәмамлаучыларның шактый күпчелеге дүрт, бишьеллык уку срогы каралган хәзерге заман мәктәпләренә җибәреләләр. Англиянең төп типтагы бу мәктәпләрдә хезмәт ияләре балаларының иң күп процент өлеше укый. Бу мәктәпләр җирле органнар акчасына тотылалар һәм хөкүмәт ассигнацияләрен алмыйлар.

Аларда инглиз телен өйрәнүгә 960-1100, иҗтимагый фәннәргә – 560, чит ил телләренә – 480, табигать-математика циклы фәннәренә – 920-960, кул эше һәм техник сызымга – 600 сәгать вакыт бирәләр. 10 проц. чамасы уку вакыты физик тәрбиягә, 6 проц. – дингә юнәлтелә.

Ләкин укучыларның белем күләмнәре һәм сыйфатлары, нинди юнәлештә укулары белән билгеләнә. Укучыларның 16-20 проц. гына өлгергәнлек аттестатына имтихан бирә, калганнарның барысы да мәктәпне тәмамлау турында таныклык алалар. Таныклык югары уку йортына юл ачмый. Фән нигезләре буенча теоретик белемнәр урынына, укучыларның күпчелегенә гамәли үзенчәлекле мәгълүматлар бирәләр. Бу мәктәптәге укыту системасы артык утилитар булуы белән аерылып тора һәм бөтен атмосфера укучыларның рухи кызыксынучанлыгын формалаштыруга ярдәм итми, чөнки укучыларны түбән интеллектлы һәм практик гамәлгә генә сәләтле дип саныйлар. Бу мәктәптәге укучыларның белемнәре түбәнлегенә шулай ук укучылар санының күплеге, кирәкле җиһазларның юклыгы, укытучылар хәленең һәм әзерлегенең канәгатьләнерлек булмавы сәбәп булып торалар.

Акыл сәләтлелеге теориясенә карап, берләштерелгән мәктәпләр төзелә. Алар өч бүлектән торалар: гуманитар, техник, табигать, математика бүлекләре. Берләштерелгән кайбер мәктәпләрнең югары сыйныфларында профессиональ бүлекләр бар. Укучылар анда механик, төзүче, су үткәргеч эшчесе һ. б. һөнәрләрне алалар. Бу

мәктәпләрдә тестлар буенча сайлап алу ул кадәр үк катгый рәвештә үткәрелми. Прогрессив җәмәгатьчелек бу мәктәпләрне җәелдерү өчен көрәшә. Хакимияткә килгән консерваторлар хөкүмәте, мәктәп сәясәтен монополияләр мәнфәгатенә яраштырып үткәрә һәм җәмәгатьчелекнең бу көрәшенә каршы тора.

Англия мәгариф системасының аерым үзенчәлеге шундый: паблик скулз дип аталган бик кыйммәтле хосусый мәктәп-интернатлар бар. Алар аристократиянең традицион уку йортлары, XVII – XVIII гасырларда барлыкка килгәннәр һәм инглиз буржуазиясе арасында бик абруйлы булып торалар. Буржуазия аларның өстенлеген нык яклый, инглиз тәрбиясенең үрнәге дип саный.

Бу мәктәпләрнең төп бурычы — дәүләт һәм сәясәт өчен булачак эшлеклеләрне әзерләү. Хәзерге Англия дәүләте җитәкчеләренең шактый күпчелеге паблик скулзны тәмамлаганнар, ә соңыннан, башлыча, Оксфорд яисә Кембридж университетында укыганнар. Бик зур матди байлыклары булганга күрә (укыту өчен түләү бик югары), Англия аристократиясе һәм буржуазия яклавы сәбәпле, паблик скулз шәкертләренең үсеше һәм белеме өчен кирәкле шартларны булдыра ала.

Англиянең профессиональ белем системасы берничә баскычтан тора, түбән баскычы, башлыча, промышленность һәм коммерция фирмалары тарафыннан оештырыла.

Югары белем өч еллык уку вакытыннан торган университетларда бирелә.

Укучыларны әзерләү өч еллык педагогик колледжларда (башлангыч һәм "хәзерге заман" мәктәпләр өчен) һәм университетларда башкарыла. Колледжка грамматик мәктәпне тәмамлаганнар кабул ителә. Университетныңниндидер факультетын тәмамлагач, булачак укытучы университетның бер еллык педагогик бүлегендә шөгыльләнергә тиеш була.

Югары белем биргәндә традиция буенча гуманитар фәннәрне артык күрәләр. Бу консерватив традиция, Англия өчен инженерлар, техниклар, табигать-математика белемле кешеләр бик кирәк булса да, нык яклапып килә.

АКШ мәктәпләре. Халык мәгарифе белән идарә итү штатларга тапшырылган. Штатларның мәктәпләр идарәсе органнары бар. Органнар педагоглар белән түгел, ә кагыйдә буларак промышленность вәкилләре, банкирлар, чиновниклар белән туплана, һәрбер

штат уку округларына бүленә. Округлар территория, материаль җиһазлар һ. б. буенча аерылып торалар.

XX гасырның 70 нче елларында оештыру эшен башкарган федераль мәгариф Министрлык (элек сәламәтлек саклау, социаль тәэминат һәм мәгариф министрлыгына кергән мәгариф Ведомствосы булган), милли фәнни, тикшеренү мәгариф институты төзелгәннәр. Федераль хөкүмәтнең мәктәп эшләренә катышуы соңгы елларда көчәеп китә, ләкин финанслау системасы үзәк бюджетка түгел (акчаның күп өлешен кораллану чыгымнары бетерә), ә штатлар акчасына нигезләнә.

Идарә итүне һәм финанслауны децентрализацияләү җәмәгать инициативасын берникадәр җәелдерсә дә, төрле уку округларындагы мәктәпләрнең матди шартларында тигезсезлек тудыра, җирле реакцион көчләрнең мәктәпкә йогынтысын көчәйтә.

Балаларга башлангыч белем бирү 6 дан 12-14 яшькә кадәр, укыту дәвамлылыгы 6 яисә 8 ел булган элементар мәктәпләрдә башкарыла.

Зур булмаган пунктларда 8 + 4 дигән система бар, ягъни сигез еллык элементар мәктәпкә дүрт еллык урта мәктәп ялгана. Шәһәрләрдә һәм зур торак пунктларында кертелгән 6 + 3 + 3 һәм 6+6 системалары киң таралган. Бу системага алты еллык элементар мәктәп, өч еллык түбән урта мәктәп һәм өч еллык югары урта мәктәп керә. Түбән һәм югары урта мәктәпләр аерым, яисә алты еллык мәктәп итеп берләштерелгән булалар (6 + 6).

Дәүләтнеке белән беррәттән, АКШта түләүле хосусый мәктәпләр бар. Анда укучыларның 8 проценты укый. Бу мәктәпләр төрле дини оешмалар, башлыча, католиклар карамагына керәләр. Анда тормышның зур урынын дин алып тора.

Америка мәктәпләренең эчке төзелеше төрле үзенчәлекләре белән аерылып тора. Балаларны, Англиядәге кебек, тест ярдәмендә сайлап юнәлешләргә бүлүдән башка, аерым фән буенча белем дәрәҗәсенә карап төрле төркемнәргә дә бүләләр. Бу шуның белән аңлатыла ки, Америка мәктәпләрендә күчерү имтиханы тапшырмыйлар, өлгерешләре ничек булса да, барлык укучылар класстан класска күчеп баралар. Яңа уку материалын үзләштерә алмаган укучылар ачыклангач, аларны аерым төркемнәргә җыялар.

Укыту эшен оештырганда коллектив формасына караганда, индивидуаль форманы яхшырак саныйлар. Берләштерелгән дәресләргә һәм укытучы аңлатуларыннан укучыларның биремнәр һәм

"проектлар" буенча мөстәкыйль эшләрен артык күрәләр. Мәктәп эше шулай оештырылганга күрә, бер үк укучының төрле төркемчәләрдә төрле фәннәр буенча шөгыльләнүе ихтимал, ә бер юнәлештәге һәм класстагы укучылар белеменең дә төрлечә булуы мөмкин.

Урта мәктәптәге укытуны оештыру һәм эчке төзелеш зур катлаулылыгы белән аерылып тора. Урта мәктәпнең уку планы укучылар өчен бик үк мәҗбүри түгел. Кайбер мәҗбүри уку фәннәре белән беррәттән, күп итеп ирекле сайланган уку курсларын өйрәнәләр. Югары классларда дифференциацияле укыту үткәрәләр һәм "профильле" дип аталган төрле бүлекләр бар.

Әгәр урта мәктәпләрнең VI һәм VII классларында 6 + 3 + 3 (яисә 6 + 6 системаларында) бер юнәлешнең (A, B, C) барлык укучылары бер үк уку фәннәрен өйрәнсәләр, IX класстан башлап алар мәҗбүриләрдән башка ирекле сайланган фәннәрне яисә курсларны өйрәнәләр.

IX-XII классларда мәҗбүри фәннәрдән туган тел һәм әдәбият (3-4 ел), АКШ тарихы яисә гражданлык белеме (1 ел), физик тәрбия (1-2 ел) өйрәнәләр. IX класста һәрбер укучы математиканың ниндидер курсын (алгебра, геометрия, кайчакта физика, бәлки география өлкәсендәге белемнәр белән берләштерелгән математика курсы) өйрәнергә тиеш. Укучы башка фәннәрне һәм шөгыльләрне мәктәптә алып барыла торган курслардан һәм профильләрдән сайлап алган. Шөгыльләр цикллары — курслар — бер еллык яисә (сирәгрәк) ярты еллык булалар. Һәрбер укучы ел саен үз теләге буенча шундый 4 курс, ә IX-XII классларда укыганда 16 курс үзләштерергә тиеш. Фән нигезләре буенча белем циклыннан торган академик уку предметларыннан башка алар арасында гамәли белем курслары да булуы ихтимал, мәсәлән, "көнкүрештәге химия" "сәүдә арифметикасы" яисә кызлар өчен хәтта "яраттыру сәләте" курсы.

Димәк, 12 еллык урта мәктәпне традицион уку программалары буенча тәмамлаган укучының гомуми тарих, биология, физика, химия һәм башка фән нигезләре буенча системалы белемнәре булмавы ихтимал.

Урта мәктәпләрдәге укучыларның аз өлеше генә физика, химия, геометрия, биология фәннәрен өйрәнә, дип АКШ та рәсми расланган. Квалификацияле укытучылар, укыту җиһазлары һәм мәҗбүри уку планнары һәм программалары булмау сәбәпле, күмәк мәктәпләрдә табигать белемнәре фәннәрен укыту түбән дәрәҗәдә тора, дип күрсәтелә.

Югары классларлардагы укучылар, элек әйтелгәнчә, берничә төрдәге профильләр буенча бүленә. Алар арасында академик профиль (А һәм В юнәлеше укучылары гына кабул ителә, югары мәктәпкә әзерли); коммерция профиле (төрле фирмалар, компанияләр, агентстволар өчен вак хезмәткәрләрне әзерли) һәм гомуми профиль. Гомуми профиль тулаем урта белем бирми. Ул гамәли эшчәнлеккә әзерләргә тиеш, конкрет специальләштерүгә җиткерми. Икътисадый яктан авыл хуҗалыгы өстенлектә булган кайбер округларда ата-аналар хуҗалыгында яисә капиталистик эре фермаларда укучыларны эшләргә әзерләү өчен авыл хуҗалыгы профильләре оештырыла. Академик профильдә укучыларның чама белән 30 проц., коммерция профилендә — 8-10 проц., гомуми профильдә 40-45 проц. укыйлар. Шулай итеп, барлык укучыларның яртысы диярлек, урта мәктәпне тәмамлагач, гамәли, утилитар белем ала. Бу белемнәр аз түләүле сферага эшчеләр көчен әзерләүгә генә ярый.

Берләштерелгән һәм күп профильле Америка мәктәбендә сыйнфый дифференциация хөкем сөрә. Бай ата-аналарның балалары академик профильдә югары мәктәпкә керергә хәзерләнә. Урта буржуазия катламы балалары коммерция профилен тәмамлыйлар. Ә гомуми профильдә эшче һәм фермер балалары укый, шуның өстенә, укучыларның яртысы мәктәпне тәмамламыйча да китеп баралар һәм үзләре дә эшсезләр санып тагын арттыралар. Алар җитди белем дә, җитәрлек профессиональ әзерлек тә алмыйлар. Шулай итеп, АКШның төрле профильдән торган урта мәктәбе белем алуның тигез булмаган төрле юлларын тәшкил итә, ә укучыларның профиль буенча бүленүе хәзерге америка буржуазия җәмгыятенең сыйнфый структурасына туры килә.

Соңгы елларда "Милли саклану өчен мәгариф турында акт" ("Акт об образовании в целях национальной обороны"), "Элементар һәм урта белемнәре үсеше турында акт" ("Акт о развитии элементарного и среднего образования") нигезләрендә урта мәктәптәге уку планнары һәм программалары үзгәрәләр. Алар хөкүмәтне мәктәп эшенә берникадәр үзгәрешләр кертергә мәҗбүр итүче хезмәт ияләренең һәм прогрессив көчләрнең куәтле хәрәкәтләре нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Бу законнар кабул ителү сәбәпле, федераль хөкүмәтнең мәктәп чыгымнарын финанслау чыгымнары арта төште. Төсле тәнле кешеләр яши торган кайбер районнарда туган телдә укыту кертелгән,

түбән классларда тел һәм арифметика буенча укыту җайланган табигать белеме нигезләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә.

Урта белем бирүнең оештырылуы һәм эчтәлеге буенча үзгәрешләрнең күбесе "академик профильгә сәләтлеләр" бүлегендә булдырылды. Алар өчен булган фән нигезләре буенча уку программаларын төзүдә фәнни-тикшеренү үзәкләре, төрле фәнни җәмгыятьләр, университет профессорлары катнаштылар. Күп көчләр кую нәтиҗәсендә, табигать, математика фәннәре һәм чит ил телләре буенча яңа уку программалары һәм дәреслекләр төзелде.

Бу җитди мәсьәләләр тирәсендә, программалы укыту һәм укытуның техник чараларын эшкәрткән чактагы кебек үк, конкуренциянең һәм ыгы-зыгының начар күренешләре барлыкка киләләр һәм тырышлыкның күбесе юкка чыга.

Яңа уку материаллары "сәләтлеләр" өчен, яисә элек тә яхшы үсеш һәм уку шартларына ия булганнар өчен исәпләнгәннәр, алар буенча хосусый мәктәпләрнең берникадәр өлеше һәм бай халык яши торган уку округлары мәктәпләре укучылары укыйлар. Реформа күпчелек укучыларга, белем бирү системасына бик аз кагыла. Шуның өстенә класс-дәрес системасына игътибарны аз бирәләр. Аны индивидуаль эш белән һәм кечкенә төркемнәрдә укыту белән алыштыралар, һәрбер укучы үз темпы белән алга барсын, дип саныйлар. "Уку — индивидуаль процесс, һәм һәрбер бала үз укуын үзе башкарырга тиеш",— дип әйтелә рәсми документларның берсендә.

АКШның профессиональ уку йортлары челтәре күп кырлы, төрле дәрәҗәле һәм белгечле уку йортларыннан тора. Аңа дәүләт һәм хосусый оешмалардагы уку срогы төрлечә булган мәктәпләр һәм курслар керә. Көндез стационар шартларда укыту белән беррәттән, эш кешеләре өчен кичке белем бирү формалары киң таралган. Профессиональ белем бирүдә күпчелек урыннарны промышленность, авыл хуҗалыгы һәм коммерция мәктәпләре һәм курслары алып торалар.

АКШта югары белем университетларда, колледжларда һәм төрле профессиональ институтларда бирелә. Алар монополияләр һәм компанияләр тарафыннан финанслана һәм турыданторы аларның йогынтыларына дучар була. Югары мәктәпләр укыту өчен студентлардан зур түләү алалар, ә бу инде америка студентларының иҗтимагый составын билгели. Уку еллык акча тоту америка гаиләсенең еллык кеременнән югары бул-

ганга күрә, чынбарлыкта матди яктан байларның гына югары белем алу мөмкинлекләре бар.

Франция мәктәпләре. Франция мәгариф системасының төп буыны — биш еллык башлангыч мәктәп. Анда 6 яше тулган барлык балалар керәләр (белем алуның элементар циклы дип атала). Бу мәктәп нигезенә төрле уку йортлары куелган: башлангыч мәктәпнең югары класслары, гомуми белем колледжлары (тулы булмаган урта мәктәпләр); 11-14 яшьлек яшүсмерләргә мәҗбүри сигез еллык белем бирелү тәмамлана һәм лицейларда 11-19 яшьлек үсмерләргә һәм егетләргә тулы урта белем бирелә.

Башлангыч мәктәпләрне тәмамлаганнан соң, алар профессиональ-техник училищеларда укыйлар яисә физик хезмәт сферасындагы квалификациясез эшкә урнашалар. Колледж тәмамлаучылар махсус урта уку йортларында укыйлар яисә хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшлиләр. Лицейлар гына югары уку йортларына юл ача. Шулай итеп, укучыга 11-12 яшь тулганда инде аның киләчәге хәл ителә. Сәләтлелегенә карап, ә чынында матди мөмкинлекләренә һәм иҗтимагый хәленә карап, башлангыч мәктәп дирекциясе һәм уку округы инспекторы тәкъдиме буенча, белем алуын дәвам итү өчен, тиешле уку йортын сыйлый. Кагыйдә буларак, башлангыч мәктәпнең югары сыйныфларында эшче һәм крестьян балалары күбрәк була, гомуми белем бирүче колледжларда — урта катлам кешеләрнең балалары, лицейларда — иҗтимагый элита; ә инде лицей тәмамлаучылар арасында эшчеләрнең балалары бик аз процент тәшкил итә.

Француз мәктәпләрендә аерым укыту үткәрелә.

Лицейлар классик (гуманитар) һәм реаль (табигать фәне) булалар. Аерым уку планнарын куллану беренче уку елыннан ук башлана. Тулы урта белем бирү ике циклга бүленә: беренче циклга VI-III класслар, икенчесенә — II, I һәм чыгарылыш класс керә (сыйныфлар саны кире тәртиптә бара). Классик бүлек өченче елдан тагын икегә бүленә. Икенче циклдагы укыту 7-8 бүлекләрдә үткәрелә. Һәр циклдагы гуманитар һәм табигать белеме фәннәре өчен сәгатьләр саны башкача була. Укучылар, 1 сыйныфны тәмамлагач, бакалавр булу өчен имтиханның беренче өлешен тапшыралар. Бу исемне алучылар фәлсәфә, табигать белеме һәм математика бүлекләре булган чыгарылыш классына күчәләр. Анда алар университетның әлеге бүлекләргә туры килгән факультетларына керергә әзерләнәләр. Бу классны бетергәч, алар университеттагы комиссия-

ләргә бакалавр булу өчен имтиханның икенче өлешен тапшыралар. Уңышлы тапшыручылар университетка укырга керәләр. Шулай итеп, урта мәктәпләрдә кирәкмәгәннәрне даими төшереп калдыру системасы эшләп килә. Бертуктаусыз "сәләтлеләрне", ә чынбарлыкта бай сыйныф балаларын сайлап торалар. Урта белемгә берьяклылык хас: өстенлекне гуманитар фәннәр алып тора.

Прогрессив җәмгыять эшлеклеләре икенче бөтендөнья сугышыннан соң француз мәгарифенең аристократик һәм сыйнфый үзенчәлеген үзгәртергә, аны демократлаштырырга, мәктәпләрнең берләштерелүен һәм күчүчәнлеген булдырырга тырышып карадылар. 1947 елда Ланжевен-Валлон комиссиясе төзелде. Ул мәктәп реформасының мөһим проектын эшкәртте. Ләкин реформа тормышка ашмады.

1959 елда мәктәп реформасы үткәрелде. Ул мәҗбүри укуның вакытын 16 яшькә кадәр озайтты һәм 11-15 яшьтәге барлык укучылар өчен "күзәтү һәм ориентлашу циклын" өйрәнүне билгеләде. Бу чорда барлык мәктәпләрнең педагоглары балаларның сәләтлелеген һәм кызыксынучанлыгын акыл сәләтлелеге тестлары буенча гына түгел, ә башка алымнарны да кулланып тикшерергә тиешләр. Француз мәктәбенең бу үзенчәлеген һәм укытучыларның төрле типтагы мәктәпләр эчендәге иҗтимагый диффренциациясен реформа бетерә алмаган тормыш үзе раслады.

1965 елда лицейның югары II һәм I сыйныфларындагы дифференциация берникадәр үзгәрде, классик һәм хәзерге заман бүлекләре якынлаштылар, ләкин шул ук вакытта, лицейның I һәм чыгарылыш сыйныфларында бүлекләр өстәлде һәм гомуми белем бирүне кыскарту исәбенә һәрбер бүлектә специальләштерү үткәрү көчәйде.

Профессиональ белемне Франциядә төрле мәктәпләрдә һәм дәрәҗәләрдә үткәрәләр. Профессиональ түбән белем типлары 1 елдан 3 елга кадәрле дәүләт һәм хосусый укучылар үзәкләрендә киң таралган. Укучылар башта эзлекле рәвештә берничә ашханәләрдә эшлиләр, ә соңыннан сайлаган профиль буенча гамәл кылалар. Крестьян балалары гадәттә өч еллык авыл хуҗалыгы курсларына йөриләр. Укуларын дәвам иттермәгән 14-17 яшьтәге егетләр өчен бу курслар мәҗбүри булып тора.

Профессиональ урта белем бирү системасына техник колледжлар һәм кәсеп мәктәпләре керә. Техник колледжлар промышленность һәм сәүдә өчен урта квалификацияле кадрлар әзерли,

югары техник уку йортларына керергә хокук бирәләр (Кәсеп мәктәпләре исә ия булалар, югары мәктәптә укуын дәвам иттерү хокукын алмыйлар).

Урта профессиональ мәктәпләр арасында "нормаль мәктәп" исемлеләре дә бар. Анда башлангыч мәктәп укытучыларын әзерлиләр.

ГФР мәктәпләре. Германия Федератив Республикасында халык мәгарифен оештыру аерым җирләр (барысы 10 җир) карамагында тора. Бу территорияләрнең һәркайсында мәдәният, мәгариф, дин мәсьәләләрен хәл итүче министрлык төзелгән.

Гомум федератив хокукы нигезендә, министрларның Даими конференциясе эш итә. Аның составында мәгариф һәм тәрбияләү мәсьәләләрен хәл итүче Германия комитеты бар. Мәктәп эшенең гомуми үзенчәлеге, юнәлеше һәм эчтәлеге җирләрнең 1946 елдан соң кабул ителгән төрле законнары буенча билгеләнә.

1955 елда Даими конференция "Декларация" кабул итте. Бу документ ГФРның барлык мәктәпләре эшләрен унификацияләде.

Гомуми белем системасы Халык мәктәпләрен, тулы булмаган урта мәктәпләрне һәм гимназияләрне эченә ала.

Халык мәктәбе балаларны 6 яшьтән кабул итә һәм ике баскычка бүленә: 1) барлык балалар йөрергә тиешле төп мәктәп (I-IV класслар); 2) халык мәктәбенең югары баскычы (V-VIII, кайчакта IX класслар); 1965 елдан соң ул "баш" баскыч дип йөртелә. Мәҗбүри баскычны тәмамлаган балалар, "сәламәтлеге" һәм конкурс имтиханнары буенча сайланып, укуны дәвам итү өчен бүленәләр. 75-80 проц. балалар югары баскычта укып кала. Аны тәмамлаганнан соң гадәттә, физик хезмәт белән шөгыльләнергә тиешләр. Алар арасын-нан бик әзләре генә түбән профессиональ мәктәпләргә керәләр, кыскартылган гимназияләргә (IX-XI) классларга) керү мөмкинлеге бирә торган махсус әзерләү классларына тагын да азы эләгә.

Укуларын дәвам итәргә сәләтле дип танылган һәм имтихан тапшырган төп мәктәп укучыларының 20-25 проценты алты ел уку сроклы тулы булмаган урта мәктәпләргә (1965 елдан соң "реаль" исемле) һәм тугыз ел курслы классик гимназияләргә күчәләр.

Гимназия — урта мәктәпнең төп тибы. Укучыларны югары белемгә ул гына әзерли.

Халык мәктәпләре профессиональ принцип буенча оештырылганнар һәм католик, инжил (евангелие) һ. б. мәктәпләргә бүленәләр. Мәктәпләрнең төрле дин буенча бүленүе бик вaклануга һәм комплектлыкның аз булуына китерә. ГФР мәктәпләренең яртыдан күбесе бер яисә ике комплектлы.

Халык мәктәбендә укытуның комплекслы системасы кулланыла, кул хезмәтенә, җимеш һәм яшелчә бакчачылыгына күп игътибар бирелә. Табигать белеме дә шуларга бәйләнгән рәвештә бирелә, укыту турыдан-туры гамәли юнәлештә үткәрелә.

Мәктәпнең укыту-тәрбияләү эшендә дин зур урын алып тора. Аны укыту өчен атнасына 2-4 сәгать вакыт бирелә.

Гимназияләр классик, яңа телләр һәм табигать, математика төрләренә бүленәләр. Классик гимназиядә латин, грек һәм бер хәзерге заман телен өйрәнәләр. Башка типтагы гимназияләрнең уку планы V-X классларныкына туры килә. Югары классларда игътибарны профильдәге фәннәргә күбрәк бирәләр. Гимназияләрнең барлык типларында төп игътибарны телләр һәм математика укытуга юнәлтәләр.

Гимназияләргә күбрәге буржуазия катлам кешеләренең балаларын кабул итәләр. Ләкин аларның барысы да гимназияне бетерә алмыйлар, чөнки соңгы югары классларда укудан төшеп калу бик күп булып китә.

25-30 проц. укучылар гына өлгергәнлек аттестаты ала. Алар бу яшьтәге балаларның 5 процентын гына тәшкил итә. Димәк, ГФРда яшьләрнең бик аз өлеше генә тулы урта белем ала.

6 еллык тулы булмаган урта мәктәп — реаль мәктәп — урта квалификацияле кадрлар әзерли, имеш "теоретик-гамәли сәләтлелеге" булган балалар өчен билгеләнгән була. Бу мәктәпкә, башлыча, вак буржуазия балалары һәм материаль яктан хәлле эшче балалары керәләр. Бу мәктәпнең уку планына укучылар сайлап ала торган шундый фәннәр керә: латин, француз телләре, табигать фәннәре белеме, музыка, физкультура, кул эше, йорт эшләре һ. б. Барлык бу фәннәр гамәли, утилитар үзенчәлекле һәм укучыларны гамәли эшчәнлеккә әзерләү максатына куелганнар. Мәктәпне тәмамлаучылар профессиональ мәктәптә укыгач һәм ике ел җитештерү эшендә булгач урта техник уку йортларына керергә хокук алалар.

Профессиональ белем бирү үз эченә төрле типтагы мәктәпләрне ала. Алар арасында халык мәктәбе базасында эшләүче, тар

производство специальләшүенә исәпләнгән түбән профессиональ мәктәпләр күп. Башка профмәктәпләр тулы булмаган урта мәктәпләрнең яисә гимназияләрнең 10 сыйныфын тәмамлаганнарны кабул итә һәм техник югары уку йортларына керү хокукы бирә.

Югары белем университетларда һәм махсус институтларда бирелә.

Халык мәктәпләре укытучылары гимназиядән соң өч еллык уку сроклы педагогик институтларда һәм академияләрдә әзерләнәләр.

Институт тәмамлаучылар укытучылыкка беренче имтихан тапшыралар һәм халык мәктәпләрендә стажер булып эшлиләр. 2-3 еллык педагогик эштән соң, алар штаттагы эш урынына хокук бирүче укытучылыкка икенче имтихан тоталар.

Гимназия укытучылары университетта әзерләнәләр. Ике еллык гамәли эштән соң һәм укытучылыкка икенче имтихан тапшыргач, тулысынча укытучы хокукын алалар.

* * *

Егерме җиденче лекция

ИДЕЛ БУЕ ТАТАР МӘКТӘПЛӘРЕ ТАРИХЫННАН

Хәзерге Татарстан территориясе патша заманында аяусыз сыйнфый көрәш мәйданы булып торды. Биредә яшәгән төрле милләтләрнең хезмәт ияләрен рус һәм үз милләте алпавытлары, капиталистлары изеп, җәберләп килделәр. Патша хөкүмәте һәрвакыт бөтен көче белән бу изүчеләрнең интересларын яклап барды.

Хезмәт иясе татарлар, чувашлар, марилар, удмуртлар, мордвалар һ. б. халыклар ике кат изелү: сыйнфый һәм милли яктан изелү астында яшәделәр. Патша хөкүмәте бу милләт хезмәт ияләрен великорус хезмәт ияләре файдаланган вак-төяк сәяси "хокук"лардан да мәхрүм итте.

Патша хөкүмәте милләтләр арасында ясалма рәвештә милли дошманлык сәясәтен үткәрде. Дин милли дошманлык тудыру коралларының берсе булып хезмәт итте. Бер яктан, православие попларының, православие миссионерларының тулаем штаты, икенче яктан, мөселман рухани-фанатиклары халык арасында бер-берсенә каршы дошманлык уяталар иде.

Патша хөкүмәте, татарларны икегә аерырга омтылып, аларны көчләп чукындыра, христиан динен татар телендә өйрәтүне оештыра һәм чукынган татарларны мөселман татарларга каршы котырта.

Казан ханлыгы бетерелгәч, татар халкын чукындыру һәм руслаштыру сәясәте төрле тарихи этапларда, патша хөкүмәте тарафыннан төрле юллар һәм алымнар белән үткәрелде.

Ул рустан башка милләтләрнең, шулар эчендә Идел буе татарларының, хуҗалык сәяси һәм культура үсешләрен буып, кысып килде. Патша хөкүмәтенең колониаль-талаучылык сәясәте милли районнарда җитештерүче көчләрнең үсүен, милли культураның үсүен тоткарлады.

Төрле милләт хезмәт ияләре көчләү сәясәтенә каршы күп тапкырлар күтәрелделәр: 1662 нче елдагы башкортлар восстаниесенә, 1773-1775 нче еллардагы Пугачев восстаниесенә башкорт, татар һәм башка милләтләр актив катнаштылар.

Россия өлкәләренең хуҗалык, икътисади яктан бәйле хәлдә яшәүләре, халыкның сәяси хокуксыз булуы, культура-көнкүреш

ягыннан артталыгы, самодержавие хөкүмәтенең христианлаштыру һәм руслаштыру сәясәте, дин белән халыкның агулануы, төрле милләт халыклары арасында дошманлык таратылуы — болар барысы да хуҗалык, мәдәният төзелешенең, шул исәптән халык мәгарифенең дә гадәттән тыш акрын үсүенә сәбәп булдылар. Шуңа күрә Европаның барлык илләре арасында патша Россиясенең культура ягыннан иң артта калган илләрнең берсе булуы бер дә гаҗәп түгел.

Патша Россиясендә хатын-кызлар санга да алынмады. Рустан башка халыкларның хатын-кызлары арасында башлангыч белем алу иң түбән дәрәҗәдә иде, ә урта белем алу бөтенләй булмады.

Милли мәктәпләр, шулар арасында татар мәктәпләре, чиктән тыш авыр шартларда яшәделәр. Мәктәпләр матди яктан тәэмин ителми, аларның биналары яраксыз, укучыларның ана телендә дәреслекләр һәм ярдәмлекләре юк, укытучылар күбесенчә хәзерлексез иде. Мәктәпләрдә беренче класстан ук дәресләр укучыларга аңлаешсыз телдә, татар мәктәпләрендә төрки, гарәп, фарсы телендә алып барыла; мәктәп өстеннән һәрвакыт кемдер күзәтеп тора; мәгариф түрәләре мәктәп эшендәге һәрбер вак-төяк өчен бәйләнәләр, мәктәптә укытыла торган фәннәр белән гамәли тормыш арасында бернинди дә бәйләнеш булмый. Болар барысы да мәктәп эшенең сыйфатын төшерәләр, балаларда белемгә омтылышны сүндерәләр, халык күзендә мәктәпнең бәясен киметәләр иде.

Мәскәү патшалыгы, Казан ханлыгын үзенә буйсындыргач, татарлар һәм Идел буендагы башка милләтләр арасында христианлаштыру һәм руслаштыру сәясәтен үткәрә башлый. Бу омтылыш үсә һәм катлаулана барып, XIX йөзнең икенче яртысында реакционер чиновник Д. А. Толстой һәм К. П. Победоносцевның уң кулы, профессор Н. И. Ильминскийның миссионерлык педагоглык системасында бу сәясәтне тормышка ашыру үзенең тулы чагылышын тапты.

Казан өлкәсендәге мәктәпләрне руслаштыру сәясәте патша Иван Грозный заманасыннан ук, Казанның беренче архиепископы Гурий тарафыннан башланган. Аның күрсәтмәләре буенча, яңа чукындырылган халыкларның балалары өчен Казан өлкәсендәге иң эре монастырьлар каршында — Казанда Спас-Преображенский, Елан тавы һәм Зөяддәге Успенский монастырьлары янында беренче христиан мәктәпләре ачылган. Чукынган кешеләрнең балалары бу мәктәпләргә көчләп алынган, алардан поплар һәм башка дин хезмәткәрләре хәзерләнгән.

Ул заманда христиан динен тарату өчен дини мәктәпләр күп ачылса да, гомумән, уку-укыту эшләренә тиешле әһәмият бирелмәгән. Хакимиятләр төп игътибарны башкага юнәлдергәннәр. Халык арасында куркыту яки бүләкләү, чукынучыларга төрле льготалар һәм өстенлекләр бирү юлы белән христиан динен таратканнар. Алар чукынган кешеләрнең балалары үзләреннән үзләре христиан булып китәр дип уйлаганнар.

Патша хөкүмәте, Казанны сугышып алганнан соң, татар мәчетләре белән бергә алар янындагы мәктәпләрне юкка чыгарырга тырышты. Ләкин мәктәп-мәдрәсәләр яшәүдән бөтенләй туктамадылар. Авыл җирләрендә мәктәп-мәдрәсәләр сакланды. Заман узу белән, шәһәрләрдә дә мәчет белән бергә мәктәпләр дә яңадан терелә башлады.

Ислам учреждениеләрен бетерү сәясәте вакытында татар мәктәпләре авыр хәлдә яшәделәр. Феодаллар һәм руханилар белән тыгыз бәйләнгән мәктәп-мәдрәсәләр, XVIII йөзнең уртасына кадәр һәм аннан соң да, торгынлык хәлендә булдылар. Бу чорда Казан өлкәсендәге мәктәп-мәдрәсәләр, Бохара, Сәмәрканд, Хоканд мәдрәсәләренә караганда, азрак, билгеле.

XVIII йөзнең уртасыннан, бигрәк тә XVIII йөзнең 70 нче елларыннан башлап, Россиядә ислам диненең һәм мәктәп-мәдрәсәләрнең хәле шактый җиңеләя. Бу хәл башкорт халкының 1662 нче елгы восстаниесенә һәм бигрәк тә 1773-1775 нче еллардагы Пугачев восстаниесенә бәйле булса кирәк. Изелгән крестьяннарның, аерым алганда Урал һәм Идел буендагы башкорт, татар һәм башка милләт крестьяннарының куркынычлы зур көч булып күтәрелүләре патша хөкүмәтен нык уйланырга мәҗбүр итә.

Патша хөкүмәтенең ислам дине һәм руханиларга карата сәясәте бераз үзгәргән чорда дини мәктәп-мәдрәсәләрнең хәле дә үзгәрә. XVIII йөзнең 70 нче елларыннан башлап мәктәп һәм мәдрәсәләр саны арта башлый. Шул чорда Казан шәһәрендә яңа мәктәп һәм мәдрәсәләр ачыла (Ахун мәдрәсәсе, Апанаев мәдрәсәсе, Әмирханов йорты янындагы мәдрәсә һ. б.). Шул ук чорда авылларда мәдрәсәләр саны арта (Кышкар, Сатыш, Мәңгәр, Саба мәдрәсәләре). Тәнкыйтькә каршы аяусыз көрәш игълан ителә. Дин нигезләре бәхәссез хакыйкать итеп кабул ителә. Ислам галимнәре, ислам динен бердән-бер дөрес һәм акылга муафыйк дин дип, исбат итәләр. Бу максат белән алар борынгы грек философларыннан Платон һәм, бигрәк тә, Аристотель әсәрләренә таяналар. Аристотельнең формаль логикасы мәдрәсәдә берничә ел буена өйрәнелә.

Патша хөкүмәте мәктәп-мәдрәсәләргә беркадәр иркенлек бирсә дә, руслаштыру сәясәтен ташламый, үз сәясәтен тормышка ашыру максаты белән, патша хөкүмәте һәм чиркәү рус халкының үз эченнән, беренче чиратта дворяннардан һәм руханилардан, татар телен белүче кешеләр әзерләү чарасын күрә. 1769 нчы елның 12 нче маенда Казан гимназиясе янында татар теле сыйныфы оештырыла.

Руслаштыру һәм миссионерлык сәясәтен үткәрү теләге белән, 1797 нче елда Казанда элекке Духовная семинария урынына Духовная академия ачыла. Казан Духовная академиясе колонизатор-миссионерлар кадрлары хәзерләүче үзәк булып хезмәт итә. Аның йогынтысы бөтен көнчыгыш Россиягә җәелгән була.

1804 нче елда ачылган Казан университетына да колонизаторлык бурычлары йөкләнде. Николай I вакытында Казан гимназиясендә һәм университетында көнчыгыш телләрен укытуны киңәйтергә тәкъдим ясала. Казан университеты янында көнчыгыш факультеты оештырылу да шуңа бәйләнгән. Көнчыгыш телләрен өйрәнү кирәклеге Николай I хөкүмәтенең көнчыгышны сугышып алу сәясәтеннән килеп чыга да инде.

XIX йөзнең башында татар теле, яңа ачылган Духовная академиядә һәм Казан укыту округының шактый сандагы өяз мәктәпләрендә укытыла. Дини китапларны татар теленә тәрҗемә итү чаралары күрелә. Бу чаралар татар теле өстендә эшләүгә, аны үстерүгә ярдәм итә. Татар теленең сүзлеге шушы вакытта төзелә.

Александр I һәм Николай I хакимлеге чорында рустан башка милләтнең кайбер авылларында чиркәү мәктәпләре һәм ведомство мәктәпләре ачыла. Бу мәктәпләр җирле халык эченнән писарьлар һәм башка шундый хезмәткәрләр хәзерләүне максат итеп куйганнар. Хөкүмәтнең бу чаралары рус башлыгы халык массасы арасында да, шул исәптән татарлар арасында да, теләктәшлек тапмый. Укытуның рус телендә алып барылуы, укытучыларның балалар белән каты мөгамәлә итүләре, мәктәп чыгымнарының таланган халык өстенә йөкләнүе һәм халыкның үз кирәкләре исәпкә алынмавы — болар барысы да балаларны һәм ата-аналарны мәктәпләрдән читләштерделәр.

XIX йөз уртасында педагогика мәйданына Н. И. Ильминский килеп чыга (1822-1891). Татарлар һәм Идел буендагы башка милләтләр арасында алып барган миссионерлык эше белән Ильминский үзен алпавыт-дворяннар идеологиясен яклаучы педагог итеп танытты. Ильминскийның бөтен теоретик һәм гамәли эше аның иң

соң чиктәге монархист, ортодоксаль чиркәүче, эзлекле руслаштыручы миссионер, колонизаторлык сәясәтен җаны-тәне белән яклаучы педагог икәнен күрсәтте. Шуңа күрә дә Ильминскийга алпавыт бюрократизмның иң чиктәге уң канаты вәкилләре һәрвакыт булышлык күрсәтәләр.

Великодержавиечеләрнең өч сүздән торган: "Православие, самодержавие, народность",— дигән лозунгысында Ильминский төп әһәмиятне православиегa бирә иде. Ильминскийның карашы буенча, руслаштыру сәясәте ышанычлы рус кешеләре җитәкчелегендә азчылык милләтләрнең үз араларыннан чыккан кадрлар тарафыннан, шулай ук чиркәү, мәктәп, дини матбугат аркылы милләтләрнең йогынты ясау өчен элек кулланылган көчләү чаралары урынына Ильминский рустан башка халыкны чиркәү, чиркәү мәктәбе аркылы, халыкның туган телендә язылган дини китаплар аркылы идеологик яктан тәрбияләү кирәклеген күтәреп чыга. 1885 нче елның 24 нче июнендә Победоносцевка язган хатында Ильминский: "Минем снарядларым — инородец телендә чыккан китаплар, инородец телендә үтәлә торган дини гыйбадәтләр, изге ата җитәкчелегендә инородец телендә үтәлә торган дини җырлар...",— дип язды.

Халык мәгарифенә Ильминский үзенә күрә бер миссионерлык итеп карады. Аны православие динен ислам, мәҗүси, протестант диннәрен җиңүе кызыксындырды. Ул үзенең бөтен көчен һәм белемен шул җиңүне оештыруга бирде. Аның карашы буенча азчылык милләтләрнең белем алуы башлангыч мәктәп белән чикләнергә тиеш, туган телендә укыту мәктәпнең тик беренче уку елларында гына әһәмиятле. Туган телне Ильминский миссионерлык максатлары өчен файдалана. Ильминский халыкның җанлы сөйләшү телен яклый һәм массага миссионерлык йогынтысы ясау өчен иң файдалы корал дип саный.

Аның укытучыга һәм педагогикага карашы урта гасыр педагоглары карашыннан берни белән дә аерылмый.

Яңа типтагы земство мәктәпләре укытучыларына Ильминский начар карый. Аның идеалы — патриархаль борынгылык. Үзенең иҗтимагый-сәяси һәм педагогик карашлары буенча Ильминский чиркәүче педагог Гачинскийга бик якын тора. Алар һәрвакыт дусларча хат язышып торганнар.

Ильминский системасына татар җәмәгатьчелегенең мөнәсәбәте турында тулы рәвештә сөйләнүнең кирәге юк. Татар җәмәгатьчелеге бу системаның миссионерлык руслаштыручылык характерын

яхшы аңлый һәм шуңа күрә ул Ильминский йогынтысын кертүгә һәрвакыт каршы тора.

Патша хөкүмәтенең, миссионер-руслаштыручыларның күп йөз еллар буенча татарлар арасында алып барган җимерү эшендә Ильминский аеруча күренекле урын тота. Бу җимерү эше аркасында, бердәм татар милләте мөселман татарлар һәм керәшен татарлар дип икегә аерылды. Бер яктан, миссионер-руслаштыручыларның һәм аларның хезмәтчеләренең, ә икенче яктан, фанатик муллаларның һәм панисламистларның эше нәтиҗәсендә, татар халкының бу ике өлеше үзара тату яшәмәделәр.

Ярты йөздән артыграк яшәгән Казан керәшен-татар мәктәбе һәм туганлык мәктәпләре православие дине, христиан чиркәве юнәлешен алга сөрделәр. Рус динчеләре бу мәктәпләргә матди һәм мораль булышлык күрсәттеләр. Аң-белем бирү дәрәҗәсе чиктән тыш түбән булса да, керәшен татарлар өчен башка мәктәпләр булмаганлыктан, халык бу мәктәпләргә үз балаларын бирергә мәҗбүр була иде. Казан керәшен-татарлар мәктәбе башта башлангыч мәктәп, ә 1878 нче елдан ике класслы училище итеп үзгәртелә, XX йөз башыннан исә ике класслы чиркәү-приход мәктәпләренең программасы буенча эшли башлый. Туганлык мәктәпләре чиркәү юнәлешендәге башлангыч белеме мәктәпләре тибында булалар. Укучыларда көчлеләргә баш ию, буйсыну, аларның сүзен тыңлау һәм түбәнчелекле булу идеяләре тәрбияләнгән.

Керәшен татарлар һәм чукынган башка халыклар арасында дәүләт, чиркәү һәм дини җәмгыять хисабына мәктәпләр ачылган вакытта, мөселман татарлар арасында халык акчаларына яки татар байлары акчаларына яши торган дини мәктәп һәм мәдрәсәләр эшләп киләләр әле.

XIX йөзнең 70 нче елларына кадәр патша хөкүмәте бу мәктәпләрнең укыту эшенә турыдан-туры катнашмый. 1870 нче елның 26 нчы мартында инородецларны агарту чаралары нигезендә патша хөкүмәтенең татар дини мәктәбенә каршы һөҗүме чагыла башлый. Бу илдә реакциянең көчәйгән чорына туры килә.

1870 нче елның 26 нчы март кагыйдәләре белән азчылык милләтләр ике төркемгә: христиан халыкларына һәм мөселман татарларына бүленәләр. Халыкның теге яки бу төркеменә мәктәпләр аркылы руслаштыру чаралары билгеләнә.

Татарларга карата бу кагыйдәләр халыкның үз акчалары хисабына мәктәп-мәдрәсә янында рус теле класслары төзүне

билгели һәм рус теле класслары ачмыйча торып, яңа мәктәпләр ачу тыела. Мәктәп һәм мәдрәсәләр янындагы рус классларын күзәтеп тору халык училищелары инспекторларына йөкләнә.

Татарларга рус телен өйрәтүне мәҗбүр итү өчен түбәндәге чаралар билгеләнә: а) дини хезмәткә керергә теләүчеләр рус теленнән һәм арифметикадан таныклыклары булганда гына бу урыннарга сайлана һәмраслана алалар; б) рус теле һәм грамотаны белү турында таныклык тапшырганда гына татарлар җәмәгать хезмәтләренә сайлана алалар. Бу таләпләрне тормышка ашыру вакыты халык мәгарифе министрының эчке эшләр министры белән килешүе буенча билгеләнергә була.

Мәктәп һәм мәдрәсәләр янындагы рус классы татарларны рус теленә, рус культурасына якынайту ягыннан уңай роль уйнарга тиеш була. Ләкин бу классларның ирексезләп кертелүе һәм югарыдан халыкның үз хисабына оештырылуы сәбәпле, алар киң катлау тарафыннан яхшы каршы алынмыйлар, нәфрәт һәм каршылык күрсәтүгә очрыйлар.

1905 нче ел революциясе вакытында рус теленә һәм рус мәдәниятына караш яхшыра. Моның сәбәбе ачык: революция җәмгыятенең бөтен сыйныфларын хәрәкәткә китерә. 1905 нче ел революциясендә татар укытучылары, мәдрәсә шәкертләре хәрәкәте көчәя. Революция чорында алдынгы татар укытучыларының төп таләпләре түбәндәгедән гыйбарәт була:

1. Байлар кулыннан мәктәп һәм мәдрәсәләрне алып, халык тарафыннан сайланган идарәләргә тапшырырга.

2. Мәктәп, мәдрәсәләргә ана теле, рус теле һ. б. фән предметлары кертергә.

3. Укытуны ана телендә алып барырга.

4. Татар укытучыларын хокук ягыннан хөкүмәт уку йортларындагы укытучылар белән тигез ясарга.

5. Татар укытучыларына дәүләт хисабыннан хезмәт хакы билгеләргә.

6. Мәгариф органнарында татар инспекторларын булдырырга.

7. Татарлардан укытучылар хәзерләү өчен педагогика уку йорты ачарга.

8. Укыту программалары һәм дәреслекләр булдырырга һ. б.

Бу таләпләр культура-агарту һәм икътисади характерда булалар. Шулай булса да, алар прогрессив роль уйныйлар һәм сәяси төс алалар, чөнки алар татар халкының милли азатлык көрәше белән

бәйләнгән була. Бу елларда күп мәдрәсәләр яңача эшли башлады. XX йөзнең башында яңа метод — аваз методы белән эшләүче мәдрәсәләрнең иң күренеклеләре түбәндәгеләр була: а) Казанда — "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе; б) Оренбургта — "Хөсәения" мәдрәсәсе; в) Уфада — "Галия" мәдрәсәсе; г) Вятка губернасының Сарапул өязендә — Иж Бубый авылы мәдрәсәсе; д) Уфа губернасы, Стәрлетамак өязендә — Стәрлебаш мәдрәсәсе һ. б.

Патша хөкүмәте яңа метод белән эшләүче мәдрәсәләрне һәр төрле юл белән кысып килә, "ышанычсыз" булганнарына иң каты репрессив чаралар күрә.

Идел буе татарларының дини мәктәп һәм мәдрәсәләре озын һәм катлаулы үсеш юлын үтәләр. Алар, феодаль һәм капиталистик җәмгыятьнең изүче катлавы интересларына хезмәт итеп, бөтен көчләре белән искелекне яклыйлар, һәр төрле яңалыкларга каршы көрәш алып баралар. Татар буржуазиясе үскән чорда мәктәп-мәдрәсәләрнең тормышына һәм анда эшләүчеләр карашында беркадәр үзгәреш туа, ләкин искелек, гасырлар буе яшәгән нигезләр яңа туып килүче элементларга бөтен көч белән каршы торалар. Илдә промышленностьның, техниканың, капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсүе белән, сыйнфый көрәш нәтиҗәсендә, мәктәп һәм мәдрәсәләр башта акрынлап, ә соңыннан кискенрәк төстә реформа юлына басарга тиеш булалар. XIX йөздә Россиядә промышленностьның күтәрелүе белән бергә эшчеләр сыйныфы үсә, эшчеләрнең оешкан хәрәкәте барлыкка килә. Шуларга бәйле рәвештә, 90 нчы елларда мәгариф өлкәсендә мәктәпләргә, аерым алганда, татар мәктәпләренә һәм мәдрәсәләренә реформалар кертү көрәше киң җәелә. XIX йөзнең 90 нчы елларыннан башлап буржуаз-реформаторлык хәрәкәте җәелә.

* * *

Егерме сигезенче лекция

АЛДЫНГЫ ФИКЕР ИЯЛӘРЕ

Н. Г. Чернышевскийның һәм Н. А. Добролюбовның дөньяга карашлары. Николай Гаврилович Чернышевскийның (1828-1889) һәм Николай Александрович Добролюбовның (1836-1861) эшчәнлеге урыс азатлык хәрәкәтендә тулы бер чорны тәшкил итте.

Н. Г. Чернышевскийның дөньяга карашы В. Г. Белинский һәм А. И. Герцен, шулай ук немец классик философиясе, бигрәк тә Л. Фейербах идеясе йогынтысы астында формалашкан, ләкин Фейербахтан аермалы буларак, Чернышевский Гегельнең диалектикасын материалистик рухта үзгәртергә тырышкан. Үзенең теоретик карашларын ул тулысынча хезмәт ияләрен коллыктан азат итү өчен көрәшкә буйсындырган. Барлык утопистлар арасыннан Чернышевский фәнни социализмга бик якын килгән, үзенең өметен революциягә баглаган. Аның утопик социализмы революцион демократизм белән тыгыз бәйләнештә булган.

Чернышевскийның һәм Добролюбовның революцион демократизмы крепостниклар һәм аларның реакцион сәясәте белән килешмәүчән көрәштә үскән һәм формалашкан. Революцион демократлар XIX гасырның 60 нчы елларында патшалык тарафыннан үткәрелгән реформаларының талау характерын ачыклаганнар, динне әхлакны, тәрбиянең официаль теориясен аяусыз тәнкыйтьләгәннәр. Алар крестьяннар деомкратиясе мәнфәгатьләрен чын мәгънәсендә даими саклаучылар буларак, демократиянең эксплуатация формаларының барысына да каршы чыкканнар. Һәлакәт протестын революцион чыгышларга әверелдерергә теләгәннәр. Россиянең икътисади, сәяси һәм мәдәният үсешен киң юлга чыгарырга омтылганнар. Моның өчен алар Россияне революцион рәвештә үзгәртеп кору теориясен эшләгәннәр һәм самодержавиегә каршы восстание күтәрерлек яшерен революцион оешманы төзегәннәр. Бу максаттан чыгып, алар яшьләрне демократик рухта тәрбияләүгә аерым игътибар биргәннәр.

Н. Г. Чернышевский һәм Н. А. Добролюбов капитализм строеның чагыштырмача прогрессив икәнен таныганнар, әмма шул ук

вакытта аның эксплуататор нигезен ачык күргәннәр. Буржуазия строен төпле һәм гадел дип күрсәтүче капитализм апологетларын алар бертуктаусыз фаш иткәннәр. Добролюбов Көнбатыш Европа илләренең буржуазия революцияләреннән соң хәлен бәяләп әйткән: рольләр алышынды, әмма шул ук пьеса уйнала, ягъни феодаллар тарафыннан изелгән буржуазия хакимияткә килде, ә халык һаман элеккечә коллыкта һәм изелүдә калды.

Фәлсәфә буенча мохитнең материаллыгы һәм бердәмлеге, дөньяның танып белүчәнлеге, үсеше һәм башка шуның кебек мәсьәләләрне тирәнтен тикшергәннәр. Революцион демократларның тәкъдир ителерлек хезмәтләренең мөһиме булып диннең һәм чиркәү роленең халыкны изү системасында реакцион сыйфатын ачыклау тора.

"Фәлсәфәдә антропологик принцип"' ("Антропологический принцип в философии") исемле билгеле хезмәтендә (1880) Чернышевский материалистик теориянең дөньяга чын фәнни караш икәнлеген һәрьяклап исбатлаган. Марксизмга кадәр җәмгыять тарихында беренче тапкыр ул сәяси һәм фәлсәфә системалар һәм аерым сыйныфларның мәнфәгатьләре арасында бәйләнеш булуын күрсәткән.

Революцион демократлар табигый фәннәрнең мәгълүматларыннан файдаланып кешенең психик эшчәнлегенең матди нигездән торуын һәм нерв эшчәнлеге белән бәйләнгән булуын дәлилләгәннәр.

"Кешедә башкарылучы һәм беленүче барлык нәрсәләр аның реаль натурасы буенча башкарыла... аның башка натурасы юк",— дип әйткән Чернышевский.

Н. Г. Чернышевскийның беренче көрәштәше буларак, Н. А. Добролюбов кешенең физик һәм рухи табигать бердәмлеге матди рәвештә бәйләнештә торалар дип басым ясаган. "Телсез сөйләп булмый, колаксыз тыңлап булмый, мисез тоеп һәм уйлап булмый",— дип язган ул.

Н. Г. Чернышевскийның һәм Н. А. Добролюбовның иҗтимагый-педагогик карашлары. Урыс кешеләрен переворотка хәзерләү бурычын куеп, Чернышевский һәм Добролюбов Россия чынбарлыгының тискәре якларын фаш итүгә күп игътибар биргәннәр. Алар үз эшчәнлегенә кешеләр аңын революционлаштыру чарасы, аларда революцион караш формалаштыру дип караганнар. Шул сәбәптән алар җәмгыять игътибарын хәзерге

стройның аерым җитешсезлекләренә генә түгел, ә төп кимчелекләренә җәлеп итәргә тырышканнар. Россия дәүләт организмын ашаучы казна талау, ришвәтчелек кебек бозык күренешләрне фаш итеп, Добролюбов либераллардан аерма буларак бюрократларның зарарын һәм бюрократияне тудыручы шартларны ачыклап күрсәткән. Урыс тормышының төп җитешсезлекләре җәмгыять строе сәбәпле барлыкка килүенә инанган буларак, ул хәзерге стройны тирәннән үзгәртмичә Россия мәгарифен яңартып төзеп була дип уйлаучылардан, наданлык нигезен начар укытучылар һәм дәреслекләр белән аңлатыла дип санап, яхшы укытучылар әзерләү һәм дәреслекләр төзү бөтен мәгарифнең яхшыруына китерәчәк дигән кешеләрдән көлгән. Андый "сәяси маниловщинага" революционер-демократар Россиянең мәгариф системасын революцион рәвештә үзгәртүне таләп итеп каршы куйганнар. Көнбатыш буржуазия революцияләре идеологларыннан һәм Россия либералларыннан аерма буларак сәяси хакимлек халык тарафыннан яулап алынгач кына һәрбер илнең мәгариф системасы чынлап халык карамагына күчүен аңлаганнар алар.

Бу мәсьәләне аңлауда Чернышевский тарихи материализмга якын килеп, "Июль монархиясе" (1860) исемле мәкаләсендә өч әйбернең — сәяси хакимлек, материаль муллык һәм белемлелек — өзелмәс дәрәҗәдә берләшкәннәр дип алдан сизеп раслаган. Ярлылыктан чыга алмаган кеше үзенең акыл көчләрен җәелдерә алмый; акыл көчләре үсешкә ия булмаган кеше хакимлек белән файдалы куллана алмаячак; сәяси хакимлектән файдаланмаган кеше изелүдән, ягъни наданлыктан котыла алмаячак.

Чернышевский кешеләргә җайлы хокуклар бирүче законнарның мөһимлеген кире какмыйча, гадәттә хәерчелектә булган, наданлыкта интеккән хезмәт ияләре законда күрсәтелгән хокуклар белән чынлап та файдалана алсыннар өчен кирәкле шартлар булырга тиеш дип күрсәткән. Ирек мәгънәсен либерализм бик тар рәвештә кабул итә, либераллар формаль ягыннан гына кешеләргә формаль хокук бирдерергә, "кәгазь рөхсәте турында", "юридик тыюларның булмавы" турында кайгырталар.

Урыс крестьяннары тулаем диярлек надан икәнен билгеләп, Чернышевский бу хәл халыкның начар шартларда яшәү нәтиҗәсе белән һәм фәнне, белемне үз кулында тотучылар һәм грамоталылык таратуны хәл итүчеләр сәясәте белән бәйле булуын исбатлаган. Патшалык алдынгы кешеләргә халык арасында белем таратуга, мәктәпләрдә эшне җайлы оештырырга, үсеп килә торган

буынга дөрес тәрбия бирүгә комачаулый. Илдә прогрессив юнәлешле яхшы укытучылар бар, ләкин алар мәктәпләрдә гамәли эштә үзләренең белемнәрен һәм карашларын реальләштерү мөмкинлекләреннән мәхрүм ителгән. Мәктәп рухсыз чиновниклар һәм үҗәт руханилар белән тулган; белем бирү эчтәлеге фәнен бик артка калган, бу инде укучыларда табигать һәм җәмгыять вакыйгалары турында бозык күзалламалар булдыра, ә укыту методикасы балаларның кызыксынучанлыгын бетерә, аларның үзлектән фикерләү үсешенә комачаулый.

Бик кискен тәнкыйтьне Добролюбов мәгариф министрлыгының һәм аның хезмәткәрләренең эш системасына төбәлгән үзенең яшерен басмаларында ("Свисток" исемле студентлар журналы һ. б.) һәм мәкаләләрендә ул Миллер-Красовскийның "Тәрбиянең төп кануннары" ("Основные Законы воспитания") исемле әсәрләрен ачулы рәвештә фаш иткән. Миллер-Красовский яшьләрнең "граждан бурычлары — "аллага һәм патшага һичсүзсез буйсына белү һәм тугрылыклы хезмәт итү", хөкүмәткә һәм ватан законнарына һичшиксез буйсыну" дип язган булган.

Добролюбов бу теориянең иҗтимагый мәгънәсен аңлаткан: балаларны ятларның кушуы буенча гомер буе күндәм рәвештә башкаручы итәргә тырышу җәмгыятьне мәңгелек торгынлыкка, "берьюлы мәңгегә урнаштырылган бер үк йолаларны һәм хорафатларны һәрвакыт кабатларга" дучар итә; яңалыклар һәм камилләшүләр булдыру бу система тарафыннан юкка чыгарыла, тамырланган явызлыкка каршы һәрбер көрәш, теләсә нинди эштәге һәрбер реформа гаепләнә. Фикерләү өчен яңа юллар ачкан, җәмгыять төзелешенең яңа башлангычын күрсәткән, яңа система, кешелек эшчәнлеге өчен яңа законнар корган кешеләр — Миллер-Красовский әфәнденең тәгълиматы буенча, барысы да "башбаштаклыктан, начар тәрбияләнүдән, ялгыш юлдан киткән малайлыктан артмаган" кешеләр.

Барлык хәрәкәтсезлекне һәм искергәнлекне кырып баручы очлы каләмен Добролюбов реакцион фикерләрен кешенең гражданлык бурычына төбәп әйтергә тырышканнарга каршы юнәлдергән. "Тормыш фәне" ("Наука жизни") китабының авторы Дымман катламкрепостной моральне сакларга чыккан чакта Добролюбов "Тормыш фәне" үзенең кагыйдәләре белән "әхлаксызлык нигезендә әхлак һәм акылның таркалуының соңгы дәрәҗәсен тәшкил итә",- дип язган.

Чернышевский һәм Добролюбов рәсми әхлакның һәм педагогиканың реакцион булуын фаш иткәннәр, күпкырлы эшчәнлек җәел-

дергәннәр, яңа әхлак төшенчәләре, чын мораль кагыйдәләре "тулаем көч" алсыннар һәм гражданлык көнкүрешендә кирәкле булып китсеннәр" дип омтылганнар.

Революционер-демократлар кеше үсешендәге тәрбия роле һәм тәрбия бурычлары турында. Кешенең җәмгыятьтә халәте һәм урыны, сәләтләр үсеше мөмкинлеге кебек, кешенең барлыкка килүе һәм нәселе буенча билгеләнгән дигән фәнни булмаган карашны Чернышевский һәм Добролюбов һичшиксез кире какканнар. Бу теориянең хезмәт ияләрен изүчеләр тарафыннан буйсындыру хаклыгын дәлилләү максатын күзләүче сәяси үзенчәлек икәнен ачыклап, Чернышевский хөкем сөрүче сыйныф идеологларының бу теорияне калкан иттереп халык массаларына дошман булган сәясәтне, аерым алганда халык мәгарифе эшендәге патша хөкүмәтенең сәясәтен яшерүләрен күрсәткән. Халыкка белем бирүдә хөкүмәт бик аз эшли, нәтиҗәдә халык мәдәниятсыз һәм белемсез дип белдергән ул. Патша ялчылары булган галимнәрнең халык томаналыгын һәм наданлыгын урыс халкының табигатеннән дип, "урыс нәселе имеш, белем алырга теләми" дип аңлатырга тырышуларын Чернышевский фаш иткән. Мондый уйдырмаларны Чернышевский халыкка яла ягу дип атаган. Массаларның белемгә омтылуына басым ясап ул язган: "Крестьян балаларына кирәкле белем бирә алмаулары сәбәпле, бик тә теләрләр иде, ләкин чаралар булмагач, ни эшләргә дип хәтта елыйлар".

Кешеләр табигате белем җәелдерүгә чик куймый: "Әгәр тискәре шартлардан котылып булса, кешенең аңы ачыла һәм холкы яхшыра".

Кеше организмы, психикасының да шәхсән аермалары булуын, кешеләрнең бер-берсеннән тышкы кыяфәт белән генә түгел, ә кайбер психик үзлекләре белән дә аерылып торуларын танып, Чернышевский тумыштан килгән хасиятләр тормыш һәм тәрбия шартларына карап беленәләр һәм үсешкә ия булалар дип аңлаткан.

Балалар бозыклыкка гына бирелүчән, табигатьләре буенча "акылсыз", ә шулай булгач, һичшиксез, зурлар акылыннан чыкмаска тиешләр дип раслаучы рәсми педагогика вәкилләренә мөрәҗәгать ясап, Добролюбов болай язган: "Үзегезнең системагыз буенча маймылга акыллылык бирегез (ягъни шундый педагогика ярдәмендә маймылны акыллы итегез) һәм шул вакытта бөтен дөнья хөрмәт белән сезнең система алдында баш иячәк һәм аның буенча балаларын тәрбияләячәк. Ләкин табигатендәге акыллылык хакын

тыныч кына таныргa сез моны эшли алмыйсыз һәм шуңа күрә баланың үз табигатендәге акыллылык хакын тыныч кына таныргa һәм түбәнсетмәскә, ә табигать биргән файдалардан уйлап кулланырга тиеш буласыз".

Добролюбов "Тәрбия эшендә абруйның әһәмияте турында" ("О значении авторитета в воспитании") (1857) исемле трактатында бала үсешенең законнарын тәрбияләүдә табигать фәннәре аныклавы буенча исәпкә алуны пропагандалаган. Рәсми педагогика бик мөһим шартны — чын тормышны, балалар табигатен һәм гомуми тәрбияләнүчеләрне күрми дип әйткән ул. Тәрбиячеләр балалар табигатенең үзенчәлекләрен белеп һәм аларга таянып, балалар үсешен чамалап идарә итсеннәр, алдынгы кешегә хас сыйфатларны булдыру өчен балаларны ирек белән тәэмин итсеннәр дип, басым ясаган ул.

Чернышевский һәм Добролюбов бөек гуманистлар булганнар, чын алдынгы әхлакны яклаганнар. Алар яңа кеше идеалын тәкъдим иткәннәр. Шуның буенча тәрбия максатын һәм бурычларын билгеләгәннәр. Аларның фикеренчә, яңа кеше үз иленең чын патриоты, халыкка якын булырга, аның мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын тәэмин итү өчен көрәштә эшлекле рәвештә катнашырга тиеш. Чернышевский һәм Добролюбовка мондый кеше югары карашлы, физик һәм рухи кагылышта һәрьяклап үсешкә ия булырлыктай күз алдына килгән.

Революционер-демократлар чын кешедәге мөһим сыйфатларның берсе итеп билгеләнгән, нык карашлар булуны, авырлыклар очравына карамастан, аларны саклау сәләтенә ия булуны хуп күргәннәр.

Фикерләрнең, сүзләрнең һәм эш итүнең бердәмлеген Добролюбов кешедә тәрбияләнергә тиеш дип санаган. Яшь кешеләр идеяле, принципллы булып үсәргә тиеш һәм үзләренең тормышында җәзадан курку һәм бүләкләнү исәбеннән файда күзләргә түгел, ә яхшылыкка һәм дөреслеккә бирелүчәнлек, хакыйкатьне һәм гаделлекне ярату турылыгыннан чыгып эш итәргә тиешле дигән фикерне дә әйткән ул. Балаларның тормыш тәҗрибәсе аз тупланганга һәм фикерләүләре өлгереп җитмәгәнгә күрә, алар, билгеле, усаллык ясап куялар, гел яхшылык эзли алмыйлар, аларның тәртибендә тәрбиячеләр зур роль уйный. Ләкин бу абруй килешле рәвештә кулланырга тиеш. Тәрбиянең килешлеге укытучыга да, тәрбияләнүчегә дә аңлашылып торырга тиеш. Балаларда тәрбияче мөстәкыйль аң үстерү турында кайгыртырга тиеш.

Чернышевский һәм Добролюбов авторитар крепостной педагогиканың фәнгә каршы торуын һәм реакцион асылын фаш иткәннәр. Шул ук вакытта Л. Н. Толстой күтәреп чыккан "ирекле тәрбияләү" теориясен тәнкыйтьләгәннәр. Балаларга карата килешле һәм гадел таләпләр бирүне яклаганнар.

Революционер-демократлар алдынгы кешегә хас булган мөһим сыйфатларның берсе итеп ватанны һәм үз халкын яратуны санаганнар.

"Һәрбер урыс кешесенең тарихи әһәмияте, үлчәнеше ватанга тәкъдир итәрлек хезмәте, кешелеклелек дәрәҗәсе — патриотизм куәте буенча үтәлә",— дип әйткән Чернышевский.

Добролюбов "Жеребцов әфәнде иҗат иткән рус цивилизация әсәре" ("Русская цивилизация, сочиненная г. Жеребцовом") (1858) исемле мәкаләсендә патриотизмны тәрбияләү һәм ялган патриотизм белән көрәшү хакында мөһим фикерләр әйткән. Аның фикеренчә, чын патриотизм ялган патриотизмнан аермалы буларак, башка халыкларны күрә алмау белән сыеша алмый, ватанны яратуны шәхси мәнфәгатьләрдән һәм теләкләрдән югары куя. "Кешелекне ярату белән бик тыгыз элемтәдә тора. Чын патриотизмның нигезендә гомумкешелек бәхете идеясы, илдә урнаштырылган тәртип буенча барлык кешелек һәм халыклар өчен кешелеклек булдыру теләге ята. Намуслы кешенең патриотизм хисе үз илең өчен хезмәт итү теләге белән турыдан-туры бәйле, мөмкин кадәр яхшылык эшләүгә нигезләнгән."

Революционер-демократлар тәртип мәсьәләсенә күп игътибар биргәннәр. Алар таяк тәртибен, тәрбияләнүченең кешелек дәрәҗәсен кимсетеп чыбык һәм башка чаралар куллануны кискен гаепләп чыкканнар, бу чараларны педагогикага сыймаучы һәм варвар дип атаганнар. Тәрбияләүдә һәм укытуда "фикер йөртмәскә, ә үтәүне генә карарга", балалардан аңлы фикерләп һәм актив эш итүче гражданнар түгел, ә җәберләүчеләрнең кушканнарын буйсынып үтәүчеләр әзерләргә теләүчеләрдә генә ул чаралар хуш күрелгән.

Андый карашларны яклаучыларга каршы каты көрәшне Добролюбов һәрбер намуслы кешенең һәм педагогның бурычы дип, һәм ул көрәштән тайпылуны чиктән тыш зарарлы, дип санаган. Мондый фикер почмагыннан ул Пироговның физик җәзага карата тоткан юлын бәяләгән. Пирогов андый чараларны гаепләгән, ә соңыннан килешүчәнлек күрсәткән һәм Киев уку округы гимназияләрендә чыбык куллануны педагогик йогынты чарасы дип тапкан.

"Чыбык белән җимерелүче бөтен Россия иллюзияләре" ("Всероссийские иллюзии, разрушаемые розгами") (1860) һәм "Яңгырдан ук суга" ("От дождя в воду") (1861) дигән мәкаләләрендә Добролюбов Пироговның мәктәптә физик җәзаларны куллану мәсьәләсендәге эзлексезлегенә каршы кискен чыккан.

Добролюбов фикеренчә, аңлы дисциплина рәткә салынган тәртипне үтәмәү дигән сүз түгел, һәммә тәрбияләнүчеләрдән нәрсәнедер үтәүдә боерыкны түгел, ә кирәк булганны искәрү таләп ителә! Тәрбиячеләрнең таләпләр гаделлеге тәрбияләнүчеләрнең аңына мөмкин кадәрлек җитәргә тиеш.

Тәрбияләнүчеләр арасында аңлы тәртип саклау шартлары һәм чараларының иң мөһиме итеп демократлар укытучылар белән укучылар арасындагы кайгыртулы һәм тигез мөгамәләләрне, укучыларга үзләренең бурычлары турында вакытлы игълан ясауны, тәрбияләүчеләрнең үрнәген һәм тирә-яктагы уңай үрнәкләрне куллануны, укытучы таләпләрендәге нык торучанлыкны һәм даимилекне санаганнар.

Акыл белемен бирү. Кеше тәрбияләүнең гомуми системасында Н. Г. Чернышевский һәм Н. А. Добролюбов гомуми белем бирүгә зур урын билгеләгәннәр. Кеше киләчәктә нинди генә белгечлек сайламасын, гомуми белем аның алдында торган эшчәнлеккә нык нигез салырга тиеш. Алар әйткәнчә, гомуми белем — ул фундамент һәм аның өстендә махсус белемнәр корыла.

Кешене тормышка әзерләү системасында демократлар акыл белеменә зур әһәмият биргәннәр, укучыларны ул табигать һәм җәмгыять турында төпле һәм һәрьяклы белемнәр белән коралландырырга тиеш. Бу белемнәргә таянып, укучылар табигать һәм җәмгыять тормышы күренешләре турында ачык һәм дөрес күзаллауларга ия булырга, төрле хорафат һәм юк-барга ышануларга каршы көрәшергә, тормышта дөрес урын табарга һәм практик эшчәнлек өчен юллар билгеләргә тиеш.

Чернышевский патшалык утырткан классик мәгарифнең реакцион үзлеген фаш иткән, яшьләргә яңа тарихны тирәнтен өйрәнүләрен булдырып сәяси белем бирүгә карата, материалистик карашлар формалаштыру өчен табигый фәннәрне өйрәнүнең әһәмиятлегенә күрсәтү ясаган. Уку дәресләрендә грамматика һәм әдәбият укытканда укучыларны заманындагы революцион идеяләрдән читләштерү өчен филология нечкәлекләрен тикшерү белән тулаем шөгыльләнергә омтылышлы рәсми методиканың сәяси юнәлештә булганлыгын ачыклаган ул.

Укучыларның бик алдан специальләшүен һәм вакытыннан артта калган белем бирү системасы буларак классицизмны кискен тәнкыйтьләп, Добролюбов берләштерелгән гомуми белем мәктәбен яклап чыккан. Берләштерелгән мәктәптә үтеләчәк төп фәннәр итеп ул туган телне, әдәбиятны, тарихны, чит телләрне, математиканы, география һәм физика белән табигатьне санаган.

Укытуның оештырылуы, методлары һәм ысуллары укучылар тарафыннан төрле белемнәр үзләштерүгә, аларның рухи көчләрен һәм сәләтләрен һәрьяклап үстерүгә, аларда дөрес карашлар формалаштыруга ярдәм итәргә тиеш дип уйлаганнар Чернышевский һәм Добролюбов. Уку материалы күләмен, үзлеген һәм укыту ысулларын билгеләгәндә алар укучыларның сәләтен, көчлелеген исәпкә алырга, бәян иткәндә, билгеләмәләр ясаганда, йомгаклауны һәм нәтиҗәне тәгъбир иткәндә һәрчакта һәм һәрбер шартларда ашыкмауны һәм эзлеклелекне катгый рәвештә үтәргә, мөмкин кадәр ачыклык һәм төгәллек булдырырга тәкъдим иткәннәр. Үзләштерергә тиешле кагыйдәләрне һәм нәтиҗәләрне ышандырырлык дәлилләр һәм исбатлаулар ярдәмендә укучылар аңына җиткерергә кирәк. Алар һәрбер догматик укытуны зарарлы һәм педагогикага каршы күренешкә тиңләп кире какканнар. Укучыларның фикер үсеше өчен, шулай ук аларга күнекмәләр һәм осталыклар гадәтләндерү өчен булган чараларны — үзлектән эш башкаруларны (шул исәптән үзлектән укуны) бик әһәмиятле дип санаганнар.

Укытуны күңелле итеп оештыруны Чернышевский һәрбер укытучының бурычы һәм вазифасы дип санаган, ләкин күңел ачу процессына әверелдерүгә кискен рәвештә каршы булган. Дәресне кызыклы үткәрү укытуның җитди һәм эчтәлекле нәтиҗәлелеген күтәрүче чара булып тора, аерым максат түгел, ә кызыксындыруны булдыру өчен аңлатуны килешле һәм кызыклы формада: гади һәм аңлаешлы, күп сүз кушмыйча, ышанычлы дәлилләр, көчле мисаллар, фактлар ярдәмендә үткәрәләр дип аңлаткан ул.

Укучыларда әйберләр турында дөрес төшенчәләр, шулай ук дөрес һәм нык карашлар булдыруны күзләгән укытуны Добролюбов та яклап чыккан. Дәрес үткәргәндә фәннең һәрбер төп фикере фактлар һәм мисаллар ярдәмендә, һәрбер йомгаклау фикер йөртүдән соң гына чыгарылырга тиешле булган укыту эше кирәк. Укытуны килешле оештыруның мөһим билгесе дип укучылар тарафыннан үтә торган материалны, фактларны, төшенчәләрне, йомгаклауны һәм нәтиҗәне аңлы үзләштерү, һәр гамәлдә һәм кылган эшкә аңлы мөнәсәбәт булдыру саналган.

Уку һәм балалар әдәбияты турында. Н. Г. Чернышевский һәм Н. А. Добролюбов уку һәм балалар әдәбияты белән нык кызыксынганнар. Заманындагы дәреслекләрне һәм балалар өчен китапларны җентекләп тәнкыйтьләгәннәр. Дәреслекләр шулкадәр камилләшмәгәннәр ки, җитди рәвештә берничек тә укый алмаслык, дигән Добролюбов. Дәреслекләрнең берәүләрендә материал турыдантуры ялгыш һәм бозык килеш, икенчеләрендә зарарлы ялганнар булмаса да, төп һәм нигезле фикерләрне чуалыштыручы, әһәмияте булмаган хосусый, вак фактлар, исемнәр һәм атамалар белән тутырып бирәләр. Добролюбов фикеренчә, балалар өчен уку китапларын чыгару эше яхшыдан тормый. Балаларга уку өчен булган китапларның үзләренә хас сыйфатлары: реаль нигезен югалткан фантазия, интектергәч әхлак, тел ярлылыгы.

Укучыларда дәреслекләр табигать һәм җәмгыять күренешләре турында дөрес күзалламалар булдырырга тиеш, дип әйткән Добролюбов. Фактларны китергәндә, әйберләрне һәм күренешләрне тасвирлаганда артык гадиләндерүгә, бигрәк тә вульгарлаштыруга юл куярга ярамый, төгәллек һәм дөреслек булырга тиеш, ә дәреслекнең материалы балаларга аңлаешлы гади һәм ачык тел белән бирелергә тиеш. Дәреслектәге билгеләмәләр, кагыйдәләр, законнар фәнгә таянган материаллар нигезендә бирелергә тиеш.

Кешенең бөтен асылын чолгап алган китапларны гына Добролюбов балалар өчен чынлап та файдалы дип санаган. Аның фикеренчә, балалар өчен китап баланың кирәкле юнәлештә хыял итүенә хөрмәт күрсәтергә тиеш. Шул ук вакытта, китап фикерләүгә көч бирергә, баланың кызыксынучанлыгын уятырга, тирә-як белән таныштырырга һәм ахырда, аның хисләрен, ясалма әхлак кагыйдәләре белән бозмыйча, ныгытырга тиеш.

Дәреслекләр һәм балалар өчен китапларның тел мәсьәләсенә Чернышевский югары таләпләр куйган. Төрле озынмаларны, чуар җөмләләрне, әйтемнәрдәге ялгышларны, шулай ук аңлаешлы итәргә теләгән булып, әдәби телне гадиләштерүне һәм вульгарлаштыруны ул гаепләп чыккан. Китаплардагы телнең педагоглар теле кебек белем бирү һәм тәрбияләү чаралары булганын, укучыларның аның ярдәмендә белемне һәм сөйләм дәрәҗәсен үзләштергәннәрен онытмаска кушкан.

Укытучы-мөгаллим турында. Педагогик хезмәтнең әһәмияте һәм үзенчәлеге, тәрбиячедә тиешле сыйфатларны булдыру турында, укытучылык эшенең, бигрәк тә авыл укытучыларының,

матди-хокук хәлен яклау турында Чернышевский күп язма юлларын багышлаган. Педагогик хезмәтнең предметы һәм бурычы бик катлаулы һәм җаваплы, аларны чынлап башкаруны киң белемле (гомуми һәм махсус белемгә ия булган) һәм үзенең кешелек сыйфатлары ягыннан тәрбияләнүчесендә тиешле кебек булган, яисә эчкерсезлек һәм бөтен көчләре белән бу сыйфатларга омтылучы укытучы гына үтәп чыгачак дип белдергән ул. Укытучы үз эше белән һәрвакыт тырышып һәм намуслы шөгыльләнергә тиеш. Чернышевский боларга өстәп, укытучылар үзләренең укучыларын һичшиксез белергә, аны кеше буларак хөрмәт итәргә һәм аңа йогынты ясаганда кешелеклелеккә каршы булган ысуллар кулланмаска тиеш, дип әйткән.

Югары һәм киң кырлы гомумфәнни әзерлек үткән укытучы да "укыту һәм тәрбияләү осталыгы турындагы төшенчәләрне томанлы итеп күрсә", үз өлкәсендә яхшы сыйфатлы хезмәткәр була алмаячак, дип әйткән Добролюбов.

Укытучының карашына һәм әхлак йөзенә Добролюбов зур әһәмият биргән. Югары гомуми һәм педагогик әзерлектән башка ачык, нык һәм шик тудырмый торган карашларга ия булган, әхлак чисталыгының үрнәге булган һәм, әлбәттә, балаларны бирелеп яраткан укытучы гына яхшы тәрбияче була ала дигән ул.

Чернышевский һәм Добролюбов укытучының иҗади инициативасын күрсәтү мөмкинлеген бирерлек матди-хокук хәлен тамырдан үзгәртү өчен һәрвакыт көрәшеп килгәннәр. Тәрбияче үз заманындагы алдынгы идеяне аңлы рәвештә яклаучы булсын өчен ул нык торган. Чернышевскийның әйтүе буенча, югары идеяләр белән рухландырылмаган кешенең эшчәнлеге файдасыз һәм әһәмиятсез.

Хатын-кызның хәле һәм аны тәрбияләү. Н. Г. Чернышевский үзенең әсәрләрендә, бигрәк тә "Нәрсә эшләргә" ("Что делать?") (1861) исемле романында хатын-кызга карата, аны түбән сыйфатлы җан иясе, димәк, акыл эшчәнлегендә һәм җәмәгать хәрәкәтендә ирләр белән бертигез актив рәвештә катнашырга сәләтсез дип санау, чынбарлыкны тупас бозу дип күрсәткән. Мондый карашлар буенча хатын-кызларның белем алу хокукының тарайтылуы һәм хатын-кызлар мәгарифенең бозык булуы килеп чыга, дип әйткән ул.

Чернышевский бик нигезле рәвештә хатын-кызларның рухи сыйфатлары ягыннан ирләрдән аерылмавын, акыл үсеше өчен ирләр кебек табигый хасиятләргә ия булуларын дәлилләгән. Хатын-

кызны җәмгыять тормышыннан мәхрүм итү, ирләр белән бертигез белем алу хокукын чикләү генә түгел, хәтта юкка чыгару фәнни мәгълүматларга һәм акыллы фикергә сыймый, килешсез заман тәртипләре нәтиҗәсендә булдырылган дип санаган ул.

60 нчы еллардагы җәмгыять хәрәкәтендә хатын-кызның белем алу хокукы турындагы мәсьәләләргә күп игътибар биргәннәр. Матбугатта авторлар тарафыннан хезмәт иясләренең ямансу көнкүрешен сурәтләп, аның төп сәбәбе наданлыктан һәм гаиләләрдә аналарның тупаслыгыннан гыйбарәт дип күрсәткән мәкаләләр барлыкка килгән. Бу хәлдән котылу юлын "кызларны киләчәк аналар вазифасын үтәргә" өйрәтүдә күргәннәр. "Гаиләләрдә аналарга белем бирмичә, һичшиксез, дөрес һәм яхшы мөнәсәбәтләр урнаштырып булмас" дип санап, Добролюбов хатын-кызларның матди һәм җәмгыять хәлен тамырдан үзгәртмәгәндә, хатын-кыз мәгарифе турында сүзләр алып бару һәм хәтта хатын-кызның белем алырга юридик хокукка ия булуын тану буш аваз гына булып калачак дип, бик тә гадел күрсәткән.

* * *

Егерме тугызынчы лекция

Л. Н. ТОЛСТОЙНЫҢ ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

Лев Николаевич Толстойның (1828-1910) педагогик эшчәнлеге 1849 елдан башлана. Шул вакытта ул Ясная Поляна крестьяннарының балаларын укырга-язарга өйрәтеп йөргән. Активрак педагогик эшен ул 1859 елда алып бара башлаган. Кырым сугышыннан кайткач, ул Ясная Полянада мәктәп ачкан һәм якын-тирәдәге авылларда тагын берничә крестьян мәктәбе оештырырга ярдәм иткән. Моның турында соңыннан Толстой үзе язганча, бу өч еллык эш белән мавыгуга дәртләнеп керешеп киткән.

Илнең белемле кешеләренең белем алуга зур мохтаҗлыкта булган халык массасының законлы бу омтылышларын канәгатьләндерү белән бәйле мөһим эшне патша хакимлегенә ышанмыйча, халыкка актив булышырга тиешле вакыты килеп җитте, дип санаган Толстой (ул вакытта Россиянең беренче революцион ситуацияне һәм иҗтимагый-педагогик хәрәкәтне кичерүен искә төшерик).

1860 елда Толстой мәгърифәтчелек җәмгыятен оештырырга ниятләнгән булган. Җәмгыять бурычы — крестьяннар өчен мәктәпләр ачу, алар өчен укытучылар сайлап табу, укыту курсын оештыру һәм укытучыларга эшләрендә ярдәм күрсәтү.

Крестьяннар мәктәбен төзү эшенә җәмгыять көчен болай берләштерүгә рәсми рөхсәт ала алмаслыгын аңлап, "яшерен җәмгыять оештыруны кирәк", дип ышандырган Л. Н. Толстой. Ул үзенең ниятен тулысынча гамәлгә ашыра алмаган, ләкин Ясная Поляна өендә аның мәктәбенең һәм күрше крестьян мәктәпләренең укытучылары даими рәвештә җыела торган булганнар. Алар крестьян балалары мәктәпләрендә прогрессив педагогиканы тормышка ашыру өчен дуслашкан фикердәшләр ковын тәшкил иткәннәр. Аларның уңай тәҗрибәсе шул вакытта язучы тарафыннан чыгарыла торган "Ясная Поляна" журналында яктыртылган. Журналда Толстойның халык мәгарифе турында мәкаләләре, аларның Л. Н. Толстой җитәкчелеге астында үткәрелгән җыелышларында алдан каралган укытучылар хәбәрләре бастырылган.

Журналның сәркатибе булып авыл укытучыларының берсе, И. Н. Ульяновның элекке тәрбияләнүчесе, Н. Н. Петерсонның эш-

ләве игътибарга лаеклы. Н. Н. Петерсон, ахрысы, "Җир һәм Ирек" ("Земля и Воля") оешмасының яшерен әгъзасы булган һәм 1866 елда Каракозовның патшаны үтермәкче булу сәбәпле сорау алырга тартылган, әмма иреккә чыгарылган.

Халык мәгарифе буенча "Ясная Поляна" журналында бастырылган аның мәкаләләре Л. Н. Толстой тарафыннан хупланган. Крапивень өязе Тула губерниясе авыл мәктәпләре укытучыларының эшчәнлеге идеяле юнәлештә булулары турында сөйли.

1861 елның язында чит илдән кайткан Толстой алпавытларның, фабрикантларның һәм банкирларның хирыс мәнфәгатьләренә туры китерелгән буржуаз цивилизацияне кискен рәвештә тәнкыйтьләгән. Халыкка кирәкне өйрәтмәүче, ә халык массаларын кысрыклаучыларга һәм җәберләүчеләргә кирәк булган заман мәктәбен Толстой шулай ук кискен тәнкыйтькә тарткан.

1858 елда Толстой тарафыннан ачылган Ясная Поляна мәктәбе 1861 елның көзеннән үзгәртеп оештырылган. Аның эш нигезенә Л. Н. Толстойның укытучылар ярдәмендә балаларның иркен һәм нәтиҗәле иҗаты турындагы фикере куелган. Кыска гына вакыт арасына карамастан, Л. Н. Толстой үзенең "Ясная Поляна" исемле педагогик журналында систематик рәвештә яктырткан бу мәктәп Россия һәм чит илләрдә җанлы кызыксыну уяткан һәм өйрәнү өчен үрнәк булган.

Ләкин Л. Н. Толстой ярдәмендә оештырылган авыл мәктәпләрендәге укыту-тәрбияләү эшенең андый юнәлеше җирле алпавытлар ягыннан ачулы каршылыкларга очраган. Мәктәпләргә һөҗүмнәр башланган, укытучылар өстеннән шикаять яуган.

1862 елның җәендә, Толстой булмаган чакта Ясная Поляна мәктәбендә жандармнар тарафыннан тентү үткәрелгән. Язучыны бу бик кимсеткән һәм протест билгесе итеп Толстой үзенең бик тә кызыклы педагогик эшчәнлеген туктаткан.

1869 елда Л. Н. Толстой тагын да педагогика белән мавыгып шөгыльләнә башлаган. 1872 елда Толстой төзегән "Әлифба" ("Азбука") чыккан, 1875 елда үзгәртелгән "Яңа әлифба" ("Новая азбука") һәм дүрт "Уку китабы" ("Книга для чтения") дөнья күргәннәр. Шул ук вакытта ул арифметика китабын төзегән һәм башлангыч укыту методикасы һәм халык мәктәпләренең башка эш мәсьәләләре белән шөгыльләнгән.

1874 елда "Халык мәгарифе турында" ("О народном образовании") исемле мәкаләсендә ул земствоны үзләре үк авыл мәктәпләре

төзергә омтылган крестьяннарның активлыгын тоткарлаганы өчен, крестьян массаларының мәнфәгатьләрен санга сукмыйча, крестьяннар акчасына земство ачкан мәктәпләрне артык күрүләре өчен кискен тәнкыйтьләнгән. Халык мәгарифе буенча земство эшчәнлеген тәнкыйтьләүдә Толстой "буяуларны артык куертса" да, крестьяннарның балаларын тәрбияләү мәсьәләсен хәл иткәндә үз тавышы булырга тиешле турындагы крестьяннар хокукын яклауда Толстой гаделлек күрсәткән.

Земство мәктәпләрендә күрсәтмәле укыту эшендә бозып аңлатулар һәм казна училищеларда башлангыч укытудагы формальлекне ул, һичшиксез, дөрес тәнкыйтьләгән.

Халык мәктәпләре эшенең эчтәлеге һәм методикасы турында үзенең күзалламасын булдырып, Л. Н. Толстой 70 нче елларда Крапивень өязенең земствосына үзенең кандидатурасын тәкъдим иткән. Сайланганнан соң, ул биредә земство мәктәпләрен төзүдә һәм аларның эшен камилләштерүдә күптөрле эшчәнлек җәелдереп җибәрә. Толстой зур өяз мәктәкләренең җитәкчесе булып китә.

70 нче елларда Толстой Ясная Поляна өендә балаларны яңадан укыта башлаган, крестьян укытучылары семинариясе проектын төзегән. Семинарияне ул шаяртып "чабаталы университет" ("университет в лаптях") дип атаган. 1876 елда ул халык мәгарифе министрлыгыннан семинария ачарга рөхсәт алган, ләкин земство ягыннан таяныч очратмагач, бу проектны гамәлгә кертә алмаган.

Толстойның педагогик эшчәнлегендәге соңгы чорында ул элекке чагында тәрбияне белемнән аеруын хата дип таныган һәм балаларны тәрбияләргә мөмкин генә түгел, ә кирәк дип саный. 1907-1908 елларда ул крестьян балалары белән дәресләр үткәрә. Толстой бу елларда эшче яшүсмерләр өчен Мәскәү кичке мәктәбендә укыту эшчәнлегенә катнашуны сораган, ләкин моңа халык мәгарифе министрлыгыннан рөхсәт алмаган.

60-70 елларда Л. Н. Толстойның халык мәгарифенә, тәрбиягә карашы. Бу вакытта үзенең күп мәкаләләрендә халык мәгарифе мәсьәләләре буенча, мәктәптә укыту-тәрбияләү эшенең эшчәнлеге һәм методлары турында Л. Н. Толстой оригиналь тәгълимат тәкъдим иткән.

Халык өчен мәктәпләрне төзүдә кем хокуклы һәм тиешле булуы, һәм анда балаларны ничек тәрбияләргә һәм укытырга кирәклеге турындагы үзенең күзалламаларын Толстой 1859-1862 елларда "Ясная Поляна" журналында үзенең беренче

мәкаләләрендә иншалаган. Оригиналь рәвештә мәсьәләләрне куюы һәм бигрәк тә мәсьәләләрне чишү ысулларын тәкъдим итүе буенча бу мәкаләләр зур кызыксыну һәм җанлы бәхәс уятканнар.

Үзенең караңгылыгы һәм наданлыгы аркасында белем алуның мөмкинлеген халык аңламый һәм шул сәбәпле аны патша хакимлеге һәм белемле җәмгыять бүләк итеп биргән мәктәпләрдә укырга мәҗбүр итәргә кирәк дип, ул заманда әйтелеп килгән хорафатларны Л. Н. Толстой кире каккан. Н. Г. Чернышевский кебек үк, Толстой да крестьяннарның балаларын мәктәпкә бирергә теләмәүләре патшалык сәясәтенең халык мәгарифе өлкәсендәге юнәлеше халыкка каршы булуы белән аңлатыла, дип санаган.

Хөкем сөрүче сыйныфның ихтыяры буенча бик авыр шартларда булуга карамастан, халык барыбер белемгә омтыла һәм аның бу, бигрәк тә 60 нчы елларда сизелгән, омтылышы халыкның табигый һәм мәңгелек ихтыяҗын тәшкил итә, дип чын күңелдән әйткән Л. Н. Толстой. Моны дәлилләгәндә Толстой Крапивень өязендә авыл мәктәпләре оештыруы буенча үз тәҗрибәсенә таянган: өяз кешеләре яңа башлангычка булган беренче ышанмауларын бик тиз үтә алганнар һәм мәктәпләр ачуда бик теләп булышканнар, ә мәктәпләр крестьян балалары белән тиз тупланган.

Әгәр мәктәпләр халык ихтыяҗларына һәм мәнфәгатьләренә туры килсә һәм мәктәпләр оештыруга халык үзе тартылган булса, мәктәпләрне аның үз эше итеп санаячагында бернинди дә шик була алмый. Л. Н. Толстой мәкаләләренең берсе бу тема буенча үзенчәлекле исем белән аталган: "Халык арасындагы мәктәпләрнең ирекле рәвештә барлыкка килүе һәм үсеше турында" ("О свободном возникновении и развитии школ в народе"). Халык мәгарифен оештыруда басым юклыгы, "Халык мәгарифе эше халыкта дошманны түгел, ә дусны табачак һәм... җәмгыятьне мәңгелек камилләшү максатына туктаусыз алып китәчәк" икәненә шундый юл булуын дәлилләгән.

Халык мәгарифен оештыруда халыкны ирексезләмәгән демократик ысуллар кертү белән беррәттән, педагогиканың теоретик нигезләрен, шулай ук мәктәпләрдә кулланыла торган тәрбияләү һәм укыту методларын яңадан карап чыгу кирәк.

Толстой 1860 елда Англиядә, Бельгиядә, Германиядә, Франциядә һәм Швейцариядә булып, Россиядә дә һәм Көнбатыш Европада да халык мәгарифе халыкның ихтыяҗларына һәм үтенечләренә җавап бирми, ә укытуның эчтәлеге һәм методлары балаларның омты-

лышларына һәм кызыксынуларына бер дә туры килми дигән нәтиҗәгә килә. "Песталоцци портреты иң яхшы Берлин мәктәбе" һәм Ясная Полянадан ерак булмаган авыл урыс мәктәбе "бик тә ошаганнар һәм бертигез": икесе дә кешегә 10 яисә 12 яшь тулганчы гына аның ирек, хокукын кире кагырга риза булган укытучыларның деспотизмы хакында нәфрәт уяталар.

Мәктәпләр һәм анда эшләүче укытучылар балалар ихтыяҗларына һәм мәнфәгатьләренә дошманнарча карыйлар, ирексезләү методларына таяналар, һәрвакыт җәза кулланалар, балаларны кимсетәләр, укыту-тәрбияләү процессын балаларны мыскыл итүгә әйләндерәләр. Шундый фикерләү нигезендә Толстой шушы кагыйдәне тәгъбир иткән: "Педагогика критериумы — иреклек" ("Критериум педагогики — свобода"). Бу кагыйдәсе аны Руссога иярүдә һәм "ирекле тәрбияләү" ("свободное воспитание") идеясен пропагандалауда гаепләүдә сәбәп булган.

"Мәктәпкә кергәндә киемнәре ертылып беткән, пычрак, ябык балаларның ачык күзләрен, фәрештә йөзләрен күргәч, миндә борчылу, курку туа, суда баткан кешеләрне күргән кебек хисләр уяна... Балалар кыяфәте буенча күзгә ташланган иң кыйммәтле, менә шул рухилык бата да инде.

Мин халык өчен белем бирүне батып китүче Пушкиннарны, Остроградскийларны, Ломоносовларны коткару өчен телим дә. Андыйлар һәрбер мәктәптә тулып ята".

Алпавыт-монархистик Россиянең дә, буржуаз Европаның да хәзерге барлык мәктәпләре балалар үсешен булдыру урынына балалар табигатен бозыклыкка китерәләр дип, Толстой рәсми педагогикага гаепләү ташлый. Моның өстенә, барлык нормаль балаларның әхлакый һәм акыл үсеше өчен һәрьяклы мөмкинлекләре бар.

Л. Н. Толстой фикеренчә, гаделсез һәм идеалдан ерак җәмгыятьтә формалашкан зурларга караганда, үзләренең табигате буенча камилләшү идеалына балалар якынрак торалар. Үзенең фикерен үткенләтеп һәм сәяси яктан арттырып та җибәреп, Толстой болай язган: "Сәламәт бала дөньяга без үзебез белән йөрткән гаделлек, матурлык һәм яхшылык тиңдәшләре булган шартсыз гармония таләпләренә туры килеп туа... Кеше тугач, гармониянең, гаделлекнең, матурлыкның һәм яхшылыкның беренче образын тәшкил итә".

Бу сүзләре аркасында Л. Н. Толстой бала табигатендә мистика, алла башлангычын таный. Язучының дөрес фикерләрен сизмичә

булмый: балалар зурлар белән аралашырга омтылалар, акылга яткан педагогик йогынтыга балалар бирелүчән булалар, үсеш һәм тәрбия өчен аларда мөмкинлекләр күбрәк була.

Л. Н. Толстойның ирекле тәрбия турындагы катгый таләбе патшага, рәсми педагогикага һәм казна мәктәбенә протест күрсәтү формасы булуын билгеләп үтү бик мөһим.

Халык мәгарифен төзүдә һәм балаларны укытуда демократик һәм кешелеклелек принциплар турындагы күзалламаларын Л. Н. Толстой 1859 елда Ясная Полянада үзе оештырган һәм 1861 елда яңадан оештырган мәктәптә гамәлгә ашырган. Толстой тирән психолог, балалар күңелен искиткеч белүче булган. Моны аның әсәрләре һәм бөтен педагогик эшчәнлеге раслый. Н. К. Крупская әйтүенчә, Толстой бала күңелен аңлый белгән: "Караңгылык хакимлегеннән" (из "Власти тьмы") Анютка күңелен дә, "Анна Каренинадан" Сережа күңелен дә, Коленька Иртеньев күңелен дә, Ясная Поляна балаларының күңелен дә белгән.

Толстой балаларны кызыксындыра, аларның иҗат мөмкинлеген уята һәм җәелдерә, аларга үзлегеннән фикерләргә һәм тирән хисләр кичерергә ярдәм итә белгән. Ул педагогик эш белән чын күңелдән мавыккан, бертуктаусыз эзләнүдә булган һәм һәрбер мәктәп үзенчә педагогик лаборатория булуын таләп иткән. 1861-1862 елларда Ясная Поляна мәктәбе шундый лаборатор һәм эксперименталь мәктәп була да инде.

Л. Н. Толстой халык мәктәбендәге укыту эчтәлеге мәсьәләсен үзенең төрле вакыттагы педагогик эшчәнлегендә төрлечә һәм капма-каршы рәвештә башкарган. Беренче чорда мәктәп программасын — уку, язу, арифметика, алла законың күз алдында тотып, "Марфутканы һәм Тарасканы үзебез белгәнгә өйрәтсәк, җитеп тора",— дип санаган.

Соңыннан укучыларның кызыксынуы укыту фәннәренең эчтәлеген һәм күләмен билгеләүче булып киткән. Толстой мәктәптә унике уку фәнен санап күрсәткән, ләкин дәресләрдә аларның һәрберсенең күләме һәм вакыты балалар теләгенә бәйләнгән булган. (Балаларның грамматика белән географияне яратмавын искә ала ул).

Зур булмаган уку-язу мәктәпләре ачу турында Толстой тәкъдим ясаганда, укытуның эчтәлеге дип балалар кызыксынуын түгел, ә патриархаль крестьяннарның карашларын санаганнар. Толстой бу карашларны барлык крестьянлыкка хас дип ялгыш уйлаган. Элек әйтелгәнчә, Толстой ул вакытта халык мәктәбе тик урыс һәм славян

белемнәрен бирергә, санарга, алла законын өйрәнергә генә тиешле дип санаган.

Ахырда, педагогик эшчәнлегенең соңгы елларында укыту эчтәлегенең (яисә ахыр чиктә бу эчтәлекнең төп өлешенең) юнәлеше тагын алышынган: Толстой укытуда иң мөһим итеп "чистартылган христианлык" рухындагы дини-әхлакый тәрбияне таныган. Әгәр мәктәптә укытучы "арифметикага, грамматикага, орфографиягә тышкы механик укыту белән генә чикләнсә", андый мәктәпне Толстой юк-бар шөгыль дип атаган.

Толстойның бу чордагы карашларында тәрбия һәм белем бирүне аерырга ярамый дигән фикере дөрес булган. 1909 елда Булгаковка җибәргән хатта Толстой болай язган: "Тәрбия һәм белем бирү турында минем элеккеге һәм хәзерге мәкаләләрдә капма-каршы-лыклар һәм аңлаешсызлыклар булуы бик тә ихтимал... Беренчедән, педагогик статьяларымда белем һәм тәрбия арасында мин үткәргән бүлем ясалма рәвештә булды дип әйтер идем. Белем бирү дә, тәрбияләү дә бүленмиләр. Белем бирмичә тәрбияләргә мөмкин түгел, ә һәрбер белем тәрбия бирә".

Үзенең элекке карашларыннан башка булган, дөрес карашны — тәрбияви укыту принцибын тәкъдим итеп, Толстой ул карашка махсус эчтәлек салган, тәрбияләү һәм белем бирү нигезенә гомумризалык, тыйнаклык, явызлыкка көч күрсәтмәү һ. б. принциплы дини-әхлакый тәгълимат куелырга тиеш дип таләп иткән.

Укыту методикасы турында Толстой әһәмиятле күп фикерләр әйткән. Методларны сайлаганда һәрбер методика буенча укучыларның аңа булган мөнәсәбәтеннән чыгып эш итәргә тәкъдим иткән ул. "Укучыларга ошаган ысул гына дөрес",— дип язган Толстой. Бер генә методны кулланырга ярамый, чөнки универсаль үзенчәлекле бер метод та юк. Төрле методлар кулланырга һәм яңаларны табарга кирәк. Мәктәп педагогик лаборатория булырга, укытучы үзенең укыту-тәрбияләү эшендә мөстәкыйль иҗат үрнәкләре күрсәтергә тиеш.

Төрле методлар арасыннан төп урынның Л. Н. Толстой укытучының җанлы сүзенә (сөйләүгә, әңгәмәгә) биргән һәм үзе дә бу методны оста кулланган, балаларны кызыксындыра һәм аларның тирән хисләрен кичерә белгән.

Балалар иҗадилыгының үсешенә әһәмият биреп, Толстой укучыларга мөстәкыйль эшләр, мәсәлән, төрле темаларга сочинениеләр бирергә тәкъдим иткән. "Язарга кемгә кемнән өйрәнергә: крестьян балаларына бездәнме, әллә безгә крестьян балаларын-

нанмы?" ("Кому у кого учиться писать: крестьянским ребятам у нас или нам у крестьянских ребят?") исемле педагогик поэзия белән тудырылган мәкаләсендә Толстой укучыларның коллектив сочинение язу процессын нәфисле итеп тасвирлаган.

Укытуны барлык укучылар да өлгерә алырлык итеп алып барырга кирәк, дип әйткән Толстой. Ул "Әлифбаның" методик теркәтмәсендә укытуны уңышка китерә торган шартларны санап чыга: укучыга нәрсәне белә һәм аңлый алмавын, шулай ук инде нәрсәне яхшы белүен әйтмәү; укучының укытучыдан һәм иптәшләреннән уңайсызланмавы, ә алар арасында гади, табигый мөнәсәбәтләр булу; укучының, төшенә алмагач, җәза бирүләреннән курыкмавы, аның акылының артык талчыкмавы, һәм аның һәрбер дәрескә көче җитүе. "Әгәр дәрес артык авыр булса,— дип язган Л. Н. Толстой,— укучы биремне үтәү өметен югалта һәм икенче шөгыльгә күчәчәк, бернинди дә тырышлык күрсәтмәячәк, әгәр дәрес бик җиңел булса, шундый ук хәл булачак. Бирелгән дәрес укучының бөтен игътибарын йотып барсын өчен тырышырга кирәк. Укучыга һәрбер дәресне укуда ул бер адым алга китү итеп тоярлык эш бирегез".

Укучылар белемне аңлы рәвештә үзләштерергә тиеш, кагыйдәләр, билгеләмәләр укучыларга фактик материалның йомгагы итеп бирелергә тиеш.

Укытуның тормышчанлыгына әһәмият биреп, укучыларны күзәтүчәнлеккә өйрәтеп, күрсәтмәлелек принцибына тиешле бәясен биреп, Ясная Поляна мәктәбендә Толстой гамәлгә киң рәвештә экскурсияләр һәм тәҗрибәләр керткән, таблицалар һәм картиналар кулланган (әмма ул балаларга чын күренешләрне һәм әйберләрне табигый һәм натураль килеш күрсәтүне артык санаган). Шуның белән бергә күрсәтмәлелек принцибын бозудан, аерым алганда немец методистларының "предметлы дәресләр" тәкъдим итүеннән ул ачулы, гадел көлгән.

60-90 елларда иң яхшы урыс педагоглары тәкъдим иткән укуязуга авазлы (звуковой) метод белән өйрәтүгә Толстой тәнкыйть күзеннән караган. Тартык хәреф сузык хәрефтән башка әйтелә алмый, дигән ул.

Толстой тәкъдиме буенча Мәскәү грамота комитеты уку-язуга авазлы метод һәм Толстой методы буенча укытуның нәтиҗәсен укучылар составы бер үк яшьтә булган ике мәктәптә экспериментале тикшерү оештырган. Укыту җиде атна дәвам иткән, аннан соң

экспертиза билгеләнгән. Ләкин ул билгеле бер нәтиҗә бирә алмаган: укый-яза белү дәрәҗәсе чама белән бертигез булып чыккан.

Л. Н. Толстойның "Әлифбасы" һәм уку өчен китаплары. Башлангыч укыту өчен китапларның нинди булуы турында Толстой үзенең дидактик әйтемнәрендә күп күрсәтмәләр бирә. Китапларга кертелгән материал балалар өчен кызыклы, аңлаешлы булырга тиеш. Язылган китаплар гади һәм аз сүзле булсын. Башлангыч мәктәп өчен китапларда истә җиңел калырлык һәм балаларга көчле тәэсир ясарлык ватан тормышыннан алынган материал бирергә кирәк.

Уку китапларына карата булган үзенең дидактик карашларына һәм таләпләренә туры китереп, Толстой "Әлифба" төзегән. Ул 1872 елда басылып чыккан. Соңыннан ул ике тапкыр эшкәртелгән һәм соңгы редакциядә 1875 елда "Яңа әлифба" ("Новая азбука") исеме белән яңартылып чыгарылган. Толстой шулай ук дүрт төрдә "Уку өчен урыс китабы" ("Русские книги для чтения") төзегән "Әлифба" кебек уку өчен китаплар һәрберсе 30 дан артык тапкыр чыгарылган, миллионлаган данәләрдә таратылган һәм Ушинскийның "Туган тел" китабы кебек башлангыч земство мәктәпләрендә иң күп кулланылучы уку китаплары булган.

Толстой төзегән уку өчен китапларның үзенчәлекле сыйфатларыннан югары нәфислек, җанлылык, кыскартулык һәм гадилек, балалар өчен тулаем аңлаешлылык, кызыклылык, искиткеч урыс теле булган. Бөтен материал урыс тормышыннан, күп өлеше, әлбәттә инде, авыл тормышыннан алынган. Табигать белеме, география, тарих буенча мәгълүматлар әдәби хикәя формасында бирелгәннәр. Күп хикәяләр әхлак темасына багышланып, 3-4 юл гына алып торалар.

Бу уку китаплары дөньяга чыгу белән үк, аларны педагогик матбугат гадел рәвештә югары бәяләгән. Мәсәлән, Ушинскийның күренекле көрәштәше, бөек педагог Д. Д. Семенов, бу китаплар "психология һәм әдәбият ягыннан югары дәрәҗәдә камилләштерелгән,— дип язган.— Сурәтләүдә нинди картиналылык, өстәвенә чын урыс, халык һәм безнең картиналылык!"

Ләкин бу китапларның мөһим җитешсезлекләрен дә әйтергә кирәк: кайбер хикәяләр Толстойның субъектив карашлары белән сугарылган.

Толстой язган уку китаплары өчен хикәяләр эчтәлеге буенча бай һәм күптөрле; алар балалар өчен кыйммәтле өлеш булганнар. Бу

хикәяләрнең күбесе башлангыч мәктәптә уку өчен булган китапларга кертелгән.

Л. Н. Толстойның күпкырлы педагогик иҗатында урыс педагогик фикере һәм Россиянең революциягә чаклы мәктәбен баеткан күп уңай яклары булган.

Аның педагогик тәгълиматының әлеге уңай үзенчәлегенә балаларга карата тирән мәхәббәт, бала шәхесен хөрмәтләү, балалар иҗатын ояту һәм үстерү осталыгы; һәрбер аерым укучының үзенчәлекләренә нечкә психологик анализ үткәрү керә. Л. Н. Толстойның бертуктаусыз педагогик эзләнүләрен педагогик эшчәнлек белән чын күңелдән мавыгуын, иҗатка ялкынлы чакыруын, укытучы һәм уку китапларын төзүче буларак, аның зур педагогик осталыгын билгеләү аеруча әһәмияткә лаек.

Урыс педагогика тарихына Л. Н. Толстой зур оригиналь педагог-фикер иясе һәм новатор булып керде. Н. К. Крупская әйтүе буенча, "Һәрбер педагог өчен, нинди генә карашларда булмасын, Толстойның педагогик мәкаләләре фикер һәм рухи ләззәтләнүнең бетмәс-төкәнмәс хәзинәсе булып тора".

Хезмәт ияләре өчен халык мәктәбен оештыруда актив катнашырга тиеш дигән Л. Н. Толстой фикерләрен Н. К. Крупская кыйммәтле дип санаган. Педагогика Толстой өчен катып калган доктрина түгел, ә катлаулы һәм үсүче эш булган. Ул балаларны кайнар яраткан, укытучыларны үзләренең бурычын дөрес аңларга өйрәткән, балаларга укытучылар белән иркен һәм тартынмыйча хис итәргә, белемне актив рәвештә алырга мөмкинлек биргәндә генә укытучының эше уңышлы булачак икәнен күрсәткән.

Педагогикага гына караган һәрбер мәсьәләне ул кискен рәвештә, бөтен киңлегенә җәелдереп, вакыт һәм пространство буенча түгел, ә тирәдәге чынбарлык белән бәйләнешкә нык кертеп кую юлында ул мактауга лаеклы.

Л. Н. Толстойның Ясная Поляна мәктәбе. Тәрбия мәсьәләләре буенча үзенең беренче мәкаләләрендә Л. Н. Толстой заманындагы педагогиканы абстрактлык, догматизм, тормыштан читтә булуы өчен кискен тәнкыйтьләп чыга. Укытучыларның тәҗрибәсен һәм эшчәнлеген педагогиканың мөһим чыганагы дип таныган ул.

Ясная Поляна мәктәбе язучы тарафыннан прогрессив педагогик принципларга туры килүче, балалар тәрбиясенең яңа эчтәлеген һәм методларын төзүче педагогик лаборатория итеп уйланыла. Бу мәк-

тәп бала шәхесен хөрмәтләүдә, аның активлыгына һәм мөстәкыйльлегенә, барлык сәләтлегенә нигезләнергә тиеш булган.

Бу мәктәптә дәресләр укытучы белән укучылар арасындагы иркен әңгәмә формасында төзелергә тиеш була. Уку, язу, матур язу, грамматика, алла законы, урыс тарихыннан хикәятләр, арифметика, табигать белеменнән һәм географиядән элементар мәгълүматлар, рәсем һәм җыр укытыла. Табигать белеме, география һәм тарих буенча мәгълүматларны урыс теле дәресләрендә Толстой әдәби хикәяләр формасында сөйләгән. Шундый хикәянең үрнәге итеп Толстой 1812 елдагы Ватан сугышы темасына багышланган хикәяне "Ясная Поляна мәктәбе" ("Яснополянская школа") исемле мәкаләсендә китерә. Язмада балаларның хикәяне чын күңелдән мавыгып, кызыксыну белән тыңлаулары һәм нинди матур хисләр кичерүләре күренә.

Уку шөгыльләре буенча бернинди дә төгәл уку планы, укыту программасы һәм расписаниесе булмаган. "Кайчакта берәр кызык нәрсә турында сөйләшеп китәбез дә, шулкадәр мавыгабыз ки, хәтта кичкә кадәр сөйләшеп утырабыз",— ди, Толстой. Балалардан мәктәпкә көн саен килүләре таләп ителмәсә дә, балалар килә торган булганнар һәм шулкадәр мавыгып китә торган булганнар ки, аларга өйгә кайтырга вакыт икәнен исләренә төшерергә туры килгән. Нindидер шелтә һәм җәза куллану Ясная Поляна мәктәбендә бөтенләй булмаган.

Укучылар өч сыйныфка — кече, урта, өлкән сыйныфларына бүленгәннәр һәм сыйныфларда 40-50 кеше укыган. Расписание буенча һәрбер укытучы көн саен 5-6 дәрес биргән. Уку көне ике өлешкә бүленгән: 12 дән 15 сәгатькә кадәр төшке аш тәнәфесе булган, ләкин укучыларның күбесе өйләренә кайтмыйча, мәктәптә иртәнге сәгать 9 дан кичке сәгать 6-7 гә кадәр булганнар. Өй эшләре гамәлдә булмаган, барлык биремнәр сыйныфтан укытучылар белән якын аралашып, өлкәнрәк һәм белемлерәкләр кечерәкләргә һәм көчсезрәкләргә ярдәм биреп эшләнелгән.

Мәктәпнең зур булмаган коллективы бик дус һәм җайлаштырып эшләгән. Укытучылар көндәлекләр һәм язмалар алып барганнар, атналык эш планы билгеләнгәннәр һәм алар буенча бергәләп фикер алышу үткәргәннәр. Коллегаларның фикере, балаларның кызыксынуы һәм соравы буенча уку планнарына төзәтмәләр кертелгән.

Л. Н. Толстой үзе өлкән сыйныфларда математика һәм тарих буенча укыткан. Аның җитәкчелегендә укучылар күп сочинение язганнар. Балалар бигрәк тә ирекле темага сочинение язуны ярат-

каннар, сочинение исеме һәм иң яхшы текстлар укылган һәм сыйныфта алар буенча коллектив рәвештә фикер алышканнар. Толстой шулай ук физика буенча әңгәмә, физик экспериментлар үткәргән.

Укытучыларның исәп-хисабы системалы рәвештә "Ясная Поляна" журналында бастырылган. Алар уку тәрбияләү процессының барышы турында җентекле язмалардан торган. Шуннан башка, әдәби осталык һәм педагогик тирәнлек белән балаларның үз-үзен тотышы, укытуның ниндидер методларына балаларның мөнәсәбәте, укытучыларның балалар белән мөгамәләләре тасвирланган. Әлеге исәп-хисапларда крестьян балаларының үзенчәлекләре, кайбер укучыларның аерым сыйфатлары киң яктыртылган, балалар үсешенең аерым чорлары теркәлгән.

Замандашларының мәктәпне тасвирлауларына караганда, Л. Н. Толстой Ясная Поляна мәктәбен оештыручы һәм аның укытучысы буларак, чынлап та үзенең мәктәбендә педагогик лаборатория булдыра алган. Мәктәптә балалар белән яхшылыкка омтылу, иҗади атмосфера хөкем сөргән; укучылар укытучылары белән мөнәсәбәттә ачык һәм саф күңелле булганнар, үзләренең танып белү кызыксынуларын үстерә, күп белем үзләштерә, мөстәкыйль рәвештә фикерле һәм эшли алганнар.

Ясная Поляна мәктәбенә күп кешеләр, шулай ук чит ил педагоглары һәм язучылары килгәннәр, мәктәп турында Россиядә һәм чит илдә күп язганнар. Л. Н. Толстойның мәктәбе, аның педагогик карашлары һәм эшчәнлеге турында Болгариядә, Англиядә, Германиядә, Франциядә һәм АКШта эшләр бастырылган. Бер автор язганча, Көнбатыш Европа мәктәпләре "Толстойдан күп нәрсә алдылар". "Балаларда үзенә ышану гадәтен үстерергә кирәк дигән аның... бик нык таләбе... сыйныф бүлмәсендә балага мөмкин кадәр ирек бирергә кирәк дигән ышанычы — бу компонентлар барысы да соңгы вакыттагы прогрессив мәгарифкә зур йогынты ясадылар. Мәктәпләр һәрвакыт педагогик лаборатория булырга тиеш дигән аның төп фикере... киң даирәләрдә дидактика алшартларының берсе дип кабул ителде".

Л. Н. Толстойның Ясная Поляна мәктәбендә укучыларга хөрмәт белән мөнәсәбәттә булу, аларның мәнфәгатьләрен өйрәнү, ирексезләмәү, укучыларга җәза бирмәү өчен бөек демократ Н. Г. Чернышевский да әлеге мәктәпкә зур бәя бирде.

Ясная Поляна мәктәбе, һичшиксез, кыйммәтле педагогик тәҗрибә үрнәге булды.

* * *

Утызынчы лекция

XIX ГАСЫРНЫҢ 60 нчы ЕЛЛАРЫНДА МӘКТӘП РЕФОРМАСЫ

XIX гасырның алтмышынчы елларындагы мәктәпләр реформасының гомуми тасвирламасы. Шунысын билгеләп үтү мөһим һәм зарури булыр: унтугызынчы гасырның алтмышынчы елларында җәмәгатьчелек хәрәкәте йогынтысы астында патша хакимияте кайбер үзгәреш — реформалар үткәрергә мәҗбүр булган: крестьяннар (крепостной правоны юкка чыгару), суд, хәрби, мәктәп, земство реформалары.

Үзенең эчтәлеге буенча бу реформалар буржуаз реформалар булган, хакимияттә торучы крепостниклар тарафыннан үткәрелгән. Шуның сәбәпле, алар өстендә яртылашлык, икеле-микеле мөһер торган. Бу үзенчәлекләр 60 нчы еллардагы мәктәпләр реформасына да, аерым алганда, 1864 елдагы башлангыч һәм урта мәктәп реформаларына һәм 1863 елдагы университетлар реформасына хас күренеш.

Реформага хәзерлек сигез ел буена дәвам иткән (1856 елдан башлап). Реформалар проекты берничә тапкыр төзелеп, үзгәртеп эшләнелгән була. 60 нчы елларның башында реформалар проекты, мәктәп реформалары да, аларның 1863-64 елларда расланган соңгы вариантларына һәм законнарына караганда, либеральрәк булган.

1863 елда расланган университет уставын һәм бу уставның биш тапкыр үзгәртеп эшләнелгән проектын тасвирлап, Герцен болай яза: "Бик күп гөнаһ җыеп өлгергән Иерусалим хаҗилары кебек, хөкүмәт өч адым алга, ике адым артка күчте. Алай да бер адымы калып барды". Бу сүзләр башлангыч һәм урта мәктәпләр реформасына да тулаем диярлек туры килә.

1864 елның 19 июлендә исә "Башлангыч халык училищелары турында положениеләр" расланган. Бу "Положение" буенча башлангыч халык училищеларының максаты болай билгеләнгән: "Халыкка дини һәм әхлакый төшенчәләр кертеп җиткерергә һәм файдалы башлангыч белемнәр таратырга" (§1). Башлангыч халык училищеларына барлык ведомстволарның, казна, җәмгыять һәм хосусый шәхесләр исәбенә эшләүче шәһәр һәм авыл элементар мәктәпләре кергән (§ 2).

Башлангыч мәктәпләрдә алла законы, "граждан һәм чиркәү матбугаты буенча" уку, язу, дүрт арифметика гамәле һәм, мөмкин булганда, чиркәү җыры укытылган. Бөтен укыту урыс телендә алып барылырга тиеш булган. "Положениедә" укытуның дәвамлыгы күрсәтелмәгән. Чынбарлыкта ул яхшы (земство, шәһәр) мәктәпләрдә өч ел, ә башка күп (бигрәк тә чиркәү-мәхәллә) мәктәпләрдә ике ел булган. "Положениедә" укучыларның яше дә билгеләнмәгән.

Халык училищеларына барлык катлам балалары да алынган. Малайлар һәм кызлар өчен аерым училищелар ачарга мөмкинлек булмаган урыннарда берләштереп укыту рөхсәт ителгән. Башлангыч училищеларда укыту түләүле дә, бушлай да булган. Бу мәсьәлә училищеларны тотучы ведомстволар, җәмгыять һәм хосусый кешеләр карамагы буенча хәл ителгән.

1864 елдагы "Положение" буенча укытучы хокукына чиркәүлеләр (священниклар, дьяклар һәм дьячоклар) яисә дөньяви затлар ия була алганнар. Рухани кешеләрдән укытырга әзерлекне, мәрхәмәтле әхлаклыкны һәм сәяси ышанычлыкны раслаучы бернинди дә документлар таләп ителмәгән, дөньяви затлар өяз училище советы өчен билгеле кешеләрдән мәрхәмәтле әхлаклык һәм ышанычлык раславын алып тапшыргач, советның махсус рөхсәте буенча укытучы исемен алгач кына, башлангыч училище укытучысы була алганнар.

Төрле министрлык һәм ведомство карамагында буган барлык башлангыч халык училищелары Халык мәгариф министрлыгына буйсындырылган, ләкин руханилар тарафыннан ачылган училищеларга искәрмә ясалган һәм алар синод карамагында булганнар.

Мәктәпләрнең, чиркәү-мәхәллә мәктәпләреннән башка, укыту-тәрбияләү эше белән җитәкчелек итү өчен урыннарда 1864 ел "Положениесе" буенча өяз, губерния училищелары советы төзелгән. Өяз училище советы составына халык мәгариф министрлыгы вәкиле (уку округының караучысы билгеләве буенча, гадәттә, гимназия укытучысы яисә өяз училище караучысы), эчке эшләр министрлыгы вәкиле (губернатор билгеләве буенча, гадәттә, исправник ягъни өяз полиция начальнигы), руханилар идарәсе вәкиле (архиерей билгеләве буенча — священник), өяз земствосыннан ике вәкил (өяз земствосы җыелышында сайланганнар), шәһәр үзидарә вәкиле кергәннәр. Совет әгъзалары арасыннан училище советы рәисе сайланган.

Өяз училище советы башлангыч мәктәпләр белән идарә иткән, мәктәпләрне ачарга, ябарга, күчерергә рөхсәт биргән, укытучыларны эшкә билгеләгән һәм эштән чыгарган. Губерния училищесы советы архиерейдан (совет рәисе), губернатордан, училищеларның губерния директорыннан, губерния земствосының ике вәкиленнән торган. Ул башлыча үз губерниясендә өяз советы карарлары буенча шикаятьләрне тикшергән.

"Башлангыч халык училищелары положениесендә" реформаның ике яклы икәне, аның буржуазия үзенчәлеге һәм реформага чаклы булган мәгариф системасы өстенлеген саклап калу күренә. Яңалыклар булып крепостной катлам башлангыч мәктәпне катламсыз, сыйныфлы мәктәп белән алыштыру, җирле үзидарә органнарына (земстволарга, шәһәрләргә), җәмгыятьләргә һәм хосусый кешеләргә халык училищелары ачу хокукын бирү, хатын-кызларга укыту рөхсәте бирү, мәктәп җитәкчелегенә коллегиаль органнар кертү торган. Моның белән бергә чиркәү-мәхәллә мәктәпләре сакланган. Халык училищелары максатын билгеләгәндә, әлбәттә инде, беренче планга дини-әхлакый белемнәрне тарату максаты куелган. Укыту өчен рөхсәт чиркәүләргә бернинди документсыз бирелсә, дөньяви кешеләргә — әзерлек, әхлаклык, ышанычлык турында таныклык алынгач кына бирелгән.

Гимназияләрнең, прогимназияләрнең 1864 елгы уставы. Гимназия уставы проекты эшләнеше берничә тапкыр үзгәртелгән, педагогик җәмәгатьчелек тарафыннан фикер алышынган һәм 1864 елның 19 ноябрендә расланган.

Бу устав буенча ике типтагы гимназияләр билгеләнгән: борынгы латин һәм грек телләре укытыла торган классик гимназияләр һәм борынгы телләр укытылмый торган реаль гимназияләр. Икесе дә — җиде еллык уку вакытында.

Реаль гимназияләрдә классик гимназияләргә караганда кайбер фәннәр күбрәк күләмдә укытылган: математика (барлык классларда атнасына 26 дәрес, классик гимназиядә 22 дәрес), табигать белеме (23 һәм 6 дәресләр), сызым (реаль гимназиядә генә). Реаль гимназияләрдә ике яңа тел, ә классик гимназияләрдә бер генә (немец яисә француз теле) тел укытылган. Калган фәннәр: урыс теле, әдәбият, тарих, география — барлык гимназияләрдә бер үк дәресләр санында (урыс теле реаль гимназияләрдә бер дәрескә артыграк) укытылган. Дәрес озынлыгы 1 сәгать 15 минут булган.

Реаль гимназиянең уку планы прогрессив үзенчәлекләр белән

аерылып торган һәм тормышчанрак булган. Шуның өстенә, математика, физика, табигать буенча белемнәрнең күбрәк булуы университетларның физика-математика һәм медицина факультетларына керү таләпләренә яхшырак туры килгән. Шуңа карамастан, университетка керү хокукы классик гимназия тәмамлаучыларга гына бирелгән. Алар барлык югары уку йортларына керә алганнар, ә реаль гимназияләрне тәмамлаучыларга техник һәм авыл хуҗалыгы югары уку йортларына гына керү мөмкинлекләре бирелгән.

1864 ел уставы буенча гимназияләр катламсыз уку йортлары дип игълан ителгәннәр, ата-аналарның дәрәҗәсенә һәм нинди дин тотуларына карамыйча, барлык катлам малайлары укучылар булып алынган. Укучыны тән җәзасына тарту бетерелгән. Гимназияләрнең педагогик советы хокуклары һәм функцияләре киңәйтелгән. Гимназия директорына совет карарларын юкка чыгару хокукы бирелмәгән, ә уку округы караучысына шикаять буларак кына җибәрә алган. Һәрбер гимназия урта уку йортларындагы укучылар һәм укытучылар өчен рөхсәт ителгән китаплардан торган китапханә, шулай ук табигать белеме, география, математика, рәсем буенча күрсәтмәле уку әсбаплары, физика кабинеты булдырырга тиеш булган.

Прогимназияләр тулы булмаган урта уку йорты булып саналган. Алар гимназияләрнең беренче дүрт классына туры килгән. Прогимназияләр зур булмаган, күпчелеге шәһәрләрдә ачылган.

Элекке катлам-крепостной гимназия буржуаз урта мәктәбенә әверелгән, ләкин 60 нчы еллардагы мәктәп реформаларының ике яклылыгы, яртылашлыгы гимназия реформаларында бик беленгән. Классик гимназияләргә караганда, урта мәктәптә математика, физика, табигать белеме буенча, шулай ук яңа телләрне һәм заман әдәбиятын, сызу һәм сызымнарга төшенү алымнарын киң күләмдә белү таләп ителгән. Реаль гимназия дә нәкъ менә шундый булган. Ләкин патша хөкүмәте классик гимназияне артык күргән. Барлык гимназияләрнең яртысы ярымклассик булып (бер латин теле белән), 25 проц. гимназияләр классик булып (латин һәм грек телләре белән) һәм 25 проц. кына реаль гимназияләр булып төзелгән.

1866 елда халык мәгарифе министры булып реакционер граф Д. А. Толстой билгеләнгән, реаль гимназияләргә ул дошманнарча караган, чөнки алар яшьләр арасында дөньяга материалистик караш таратканнар. Урта мәктәптә ул көчен кызганмыйча классицизм

кертә башлаган һәм тиздән барлык гимназияләрне классик гимназияләргә әверелдергән.

Хатын-кызларның урта белем алулары. 60 нчы елларның башында хатын-кызларга белем бирү хакында алга китеш сизелә. Ләкин бу мәсьәлә дә яртылаш кына хәл ителә. 1860 елның 10 маенда «Халык мәгариф министрлыгының идарәсендә хатын-кызлар турында положение» («Положение о женских училищах министерства народного просвещения») расланган. Бу «Положение» буенча хатын-кызлар училищесы ике разрядлы итеп билгеләнә. Беренче разрядлы училищеларда уку вакыты алты ел була. Аларда алла законы, урсы теле һәм сөйләме, арифметика һәм геометрия башлангычы, география, тарих (гомуми һәм урыс тарихы), табигать белеме, физика, матур язу һәм кул эше укытылган. Мәҗбүри булмаган фәннәргә француз һәм немец телләре, рәсем, музыка, җыр һәм биюләр кертелгән. Икенче разрядлы хатын-кызлар училищеларында өч еллык укыту курслары булган. Аларда алла законы, урыс теле, география, урыс тарихы, арифметика, матур язу һәм кул эше укытылган. Хатын-кызлар училищеларына барлык катлам кызлары алынган, кабул ителгән.

Ирләр гимназияләре белән чагыштырганда, беренче разрядлы хатын-кызлар училищеларында бер елга кимрәк укыту вакыты һәм тарайтылган укыту программасы булган. «Хатын-кызлар училищелары турында Положение» тәгълиматыннан күренгәнчә, бу училищелар хатын-кызларны ир-ат хатыны һәм балалар анасы итеп әзерләү өчен, әмма хатын-кызларны җәмгыять эшчәнлегенә әзерләү максатын куймыйча укытырга билгеләнгәннәр. Хатын-кыз училищеларының саны күп булмаган. 1870 елда бөтен Россия буенча барысы беренче дәрәҗәле 37 хатын-кызлар училищесы һәм икенче дәрәҗәле 94 училище булган. Шул ук елда алар хатын-кызлар гимназияләренә һәм прогимназияләренә әверелгәннәр.

Югары мәктәп реформасы. 60 нчы еллардагы җәмгыять хәрәкәтендә профессорлар һәм студентлар күп катнашкан. 1856 елда ук инде студентлар чуалышы башланган. Хөкүмәт аңа репрессияләр белән җавап биргән. Хәтта 1861 елда С.-Петербург университетының барлык студентларын куып чыгарганнар. Шуның белән бергә, хөкүмәт азрак юл куярга мәҗбүр булган. Университет өчен яңа устав төзү башланган. Аның проекты биш тапкыр төзәтелгән һәм, ахырда, 1863 елның 18 июнендә җәмәгатьчелек хәрәкәте басымы астында әлеге устав расланган.

Революциягә чаклы университет уставларының барысыннан да бусы прогрессиврак булган. Университетларга берникадәр үзлектән эшләү мөмкинлеге: гыйльми советка ректорны һәм проректорны (4 еллык срокка) сайлау хокукы; профессорларны конкурс буенча сайлау; факультетлар советының деканнарны сайлавы. Кафедралар саны арткан, аларга фәнни эш алып бару өчен рөхсәт бирелгән. Укытучылар составы бер ярым тапкырдан күбрәк арткан. Элеккеге Петербургта технология, Тау, Аралашу юллары институтлары, Мәскәү югары техник училищесе, Петровско-Размовский (хәзер Тимирязев исемендәге) авыл хуҗалыгы академиясе тулаем сыйфатлы институтларга әйләнгәннәр; Ригада политехник институт ачылган.

Халык мәгарифе буенча земство эшчәнлегенең башы. 1864 елда «Земство учреждениеләре турында положение» («Положение о земских учреждениях») расланган була. Бу «Положение» буенча күбесе урыс халкы һәм Идел буе халыклары яши торган Россиянең Европа өлешендәге 34 губернада җирле үзидарә земстволар кертелгән.

Земство кертү халыкка юл салу булып характерлана. Халыкка эре милек биләүчеләр йөзендә булган алпавытлар, фабрикантларга, йорт хуҗаларына, шулай ук крестьянлыкның нык тормышлы өлешләренә җирле хуҗалык һәм мәдәният эшләрен, сәламәтлекне саклауны, халык мәгарифен (башлангыч мәктәпләрне карамакта тоту һәм урта белемгә уңай караш тоту), юллар төзүне су белән тәэмин итүне һ. б. губернатор күзәтүе астында алып бару хокукы бирелгән.

Халык мәгарифе өлкәсендә патшалык земствога кечкенә роль калдыра: «Күбәрге хуҗалык мәсьәләләре ягыннан», ягъни земство (өяз училище советы рөхсәте буенча) мәктәпләр ача алган һәм аларны хуҗалык ягыннан (бина, аны җылыту, яктырту, җиһазлау, Халык министрлыгы рөхсәте нигезендә дәреслекләр һәм язу әсбаплары белән тәэмин итү, укытучыларга түләү һ. б.) карап тота алган. Земство мәктәпнең укыту-тәрбияләү эшенә кысылудан тыелган булган. Бу эш өяз училище советлары һәм халык училищелары инспекторлары карамагында булган. Инспекторлар вәкаләте (һәр-бер губернага берәр) 1869 елда кертелә.

Земство роленең башка яклардан да чикләнүе күзәтелә: земство урта мәктәпләргә кагылмыйча, башлангыч мәктәпләрне генә үз карамагында тота алган. Урта белем буенча земство урта уку йорт-

ларына акчалата ярдәм бирүне, урта мәктәп укучыларына стипендия билгеләүне «хуплау» хокукына гына ия булып тора.

Шулай да беренче ун елда күпчелек губерналардагы земстволар башлангыч авыл мәктәпләренең шактый челтәрен булдырганнар: аларның саны ун меңнән артып китә. Алдынгы земстволар махсус мәктәпләрдә халык укытучыларын әзерләүне оештырып маташканнар, укытучылар курсларын һәм съездларын үткәргәннәр; мәктәпләр каршында китапханәләр оештырганнар. Әлеге китапханәләрдән мәктәпне бетерүчеләр дә куллана алганнар.

Шуны ачыклап китәргә кирәк ки, мәктәпләр буенча хуҗалык чыгымнарның бер өлешен генә земство үз өстенә алган, ә төп чыгымнарны, гадәттә, (мәктәп өчен биналар алып тору, мәктәп биналарын төзү; җылыту, яктырту, укытучыга, каравылчыга түләү) авыл җәмгыятьләре каплаган.

Ул вакытта булган башлангыч мәктәп төрләреннән (земство, министрлык, чиркәү-мәхәллә) иң яхшысы земство мәктәпләре була. Земство укытучыларының белем дәрәҗәсе, башка башлангыч мәктәпләргә караганда, югарырак. Алар махсус биналы, уку әсбаплары белән яхшырак җиһазланган.

* * *

Утыз беренче лекция

МӘШҺҮР МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘР

Эчке Руссия татарларының иң мәшһүр һәм атаклы мәдрәсәләреннән берсе, асылда, милли университет вазифасын үтәгән "Мәдрәсәи Мөхәммәдия"не аның нигез ташларын салучысы, җитәкчесе, мөдәррисе Галимҗан Галиев-Баруди исеменнән башка күз алдына китерүе мөмкин түгел. Ул XIX йөз ахырларында ук күренекле мәгърифәтче, дин белгече һәм реформаторы, фәлсәфәче, педагог буларак, дистәләрчә китаплар язып бастыра. Бу олпат шәхеснең абруе XIX йөз азагы – XX гасыр башында гаять зур була. Рус мәмләкәтенең уннарча төбәкләрендә нәшер ителгән татарча газета-журналларда аның исеме бернинди аңлатмаларсыз "Галимҗан хәзрәт" дип кенә бирелгән. Үз чорында мондый популярлык һәм авторитетка бары берничә генә шәхес (Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, И. Гаспринский һ. б.) ия була. Рәсми русча документларда мәдрәсәнең исеме еш кына "Мөхәммәдия" дип түгел, бәлки нигезләүчесе һәм җитәкчесенә нисбәттән "Галеевское медресе" дип йөртелә.

Галимҗан хәзрәтнең исеме һәм эшчәнлеге совет чорында уңай яктан телгә алынмады диярлек. Бары тик 80 нче елларда, ягъни тарихка объектив бәя бирелә башлагач кына, Баруди кебек шәхесләрнең эшчәнлеген яктыртуда гаделлек ягы көчәйде.

Г. Барудиның кылган гамәлләре колач җитмәстәй зур. Аны кечкенә мәкаләдә генә нигезле яктыртып та, бәрәкәтле педагогик эшчәнлегенә тиешенчә тукталып та булмый. Шуңа күрә алар хакында кыскача гына әйтеп китәргә туры килә.

Галимҗан хәзрәт (Галимҗан бине Мөхәммәтҗан бине Гали) 1857 елның 2 февралендә Казан өязенең Кече Кавал авылында сәүдәгәр гаиләсендә туа. Казанга күчеп килгәннән соң, 1862 елда икенче мәхәллә мәдрәсәсенә укырга керә. Бу кадими уку йортында 4 ел чамасы укып китапларны өйрәнүне тәмам иткәч, морфология, гарәпчә гыйлемнәр һәм гомуми кулланылышта булган барлык китаплардан дәрес ала. Сәләте зур булу сәбәпле, хәлфә сыйфатында үзе алган гыйлемнәрдән шәкертләргә сабак та бирә.

1875 елда 18 яшьлек Галимҗан, белемен тирәнәйтү өчен, Бохарага китә. Анда "Мир-гарәб" мәдрәсәсендә 7 ел укып, өйрәнелә торган барлык фәннәрне үзләштерә һәм алар өстенә тәфсир, хәдис, хисап, алгебра, геометрия, медицина һәм табигать буенча белем ала, шул вакытларда Сәмәрканд, Ташкент кебек шәһәрләргә сәфәр кыла. 1882 елда Казанга кайта һәм анда 5 нче мәчеттә имамлык һәм дәрес бирү өчен, ягъни мөдәррислек өчен указ ала. Шул көннән башлап Галимҗан хәзрәт бөтен көчен яңа мәдрәсә бинасы салу һәм дәрес бирү эшенә юнәлтә. Бу хыялны тормышка ашыру гаять зур кыенлыклар белән бәйләнгәнлектән, Баруди, гыйлем арттыру һәм тәҗрибә туплау өчен, 1887 елда кабат зур сәяхәткә чыгып китә. Мисыр, Стамбул, Хиҗазга сәфәр кыла, андагы олуг галимнәр белән таныша, алардан акыллы фикерләр, киңәшләр ала.

Яшь чагыннан ук иске төрдәге мәдрәсәнең җитешсезлекләрен үз җилкәсендә татыган сәләтле һәм үткен акыллы Галимҗан Галиев мәгариф эшенең шул чордагы торышы милләт өчен зарарлы дигән нәтиҗәгә килә. Иске мәдрәсәләр, ди ул, төзәтелергә һәм дини юнәлешкә математика һәм табигать фәннәре кушылырга тиеш. Балаларга гамәли белем бирү ихтыяҗыннан чыгып, галим яшь буынга фәннең төрле тармакларыннан мәгълүмат бирү, сәүдә һәм промышленность эшен ныклы өйрәнү мәсьәләсен күтәреп чыга. Дини мәдрәсәләрдән баш тартмаган хәлдә, ул "профессор, фәлсәфәче, инженерлар" әзерли торган дөньяви мәктәпләр кирәк, дигән фикерне алга сөрә.

Киләчәктә даны Русиянең бөтен төрки-мөселман дөньясына таралган мәдрәсәгә 1882 елда Галимҗан хәзрәтнең атасы Мөхәммәтҗан тарафыннан, озынлыгы 16, киңлеге 8 метр итеп, таштан бер катлы бина салына. Ләкин салынган елны ук шәкертләр күбәеп, бинага сыймый башлагач, Мөхәммәтҗан шул таш өйнең астын казытып, тәрәзәләр куйдырткан һәм анда да шәкертләр тора башлаган.

Барудиның уку-укыту эшен җайга салуы, зур хәзерлекле мөдәррис (педагог) булуы, ә атасының укучы яшьләр ихтыяҗын канәгатьләндерерлек матди шартлар тудыруы аркасында шәкертләр саны һаман саен арта. Моңа нисбәтле рәвештә мәдрәсә дә киңәя, үсә бара. XX йөз башында инде "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе берничә катлы өч таш корпусны, ашханә, кухня, авырулар өчен хастаханә, итек-читек, кәвеш төзәтү, агач эше, китап төпләү остаханәләре һ. б. берләштергән зур бер комплекс тәшкил итә, анда заманча шартлар

(үзәктән җылыту системасы, электр яктыртуы һ. б.) тудырыла. Бу чын мәгънәсендәге олуг татар университетын төзү һәм оештыру эшендә мөдәррис үзе, аның хатыны Бибимаһруй абыстай, татарның бай сәүдәгәрләре Габдулла Үтәмишев, Әхмәд Хөсәенов һ. б. үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Ачылган вакытында "Мәдрәсәи Мөхәммәдия" башка иске тәрдәге уку йортларыннан берни белән дә аерылмый диярлек, фәкать гарәп теле һәм дин дәресләре генә яңа баскычка куела. Ләкин мәшһүр уку йортларында гыйлем алган һәм сәфәрләрендә бай тәҗрибә туплаган Галимҗан хәзрәт, реформа ясамый торып, милли мәгариф эшен алга җибәрү мөмкин түгеллеген яхшы аңлый. Моның өчен башта башлангыч сыйныфларны, аннары шуның нигезендә урта һәм югары классларны үзгәртеп кору кирәк дип табыла. Шул ихтыяҗның нәтиҗәсе буларак, 1891 елда "Мөхәммәдия"гә ысуле җәдидә, ягъни Европа мәгърифәте, Шәрыкъ казанышларына нигезләнгән яңа метод белән укыту гамәлгә кертелә. Җәдидчелек юнәлешен кыйбла иткән Баруди, яңа системаны юлга салу йөзеннән, бер-бер артлы дәрес китаплары һәм дини фәлсәфәгә кагылышлы гыйльми хезмәтләр чыгара башлый.

Яңа ысул белән укыту өчен ул, беренче чиратта, "Сәвадхан" исемле әлифба төзи. Ул яңа ысул белән төркичә (татарча) язылган беренче әлифба санала. 1891-1915 елларда аның 12 басмасы чыга. "Сәвадхан"ның беренче варианты 24 биттән торса, аның Тәкмиләсе тулыландырылган (өстәмә) басмасы ("Сәвадхан тәкмиләсе") 64 сәхифәне тәшкил итә һәм шулай ук күп мәртәбә кабат басыла. Шул ук 1891 елда аның арифметика буенча "Нәмунәи хисаб" дигән хезмәте басылып чыга һәм озак еллар буенча мәктәпләрдә кулланма булып йөри (ул да берничә мәртәбә нәшер ителә). 1891 елда мөдәррис үзенең "Саде пенд" исемле үгет-нәсихәт китабын бастырып чыгара.

Шул ук чорларда Г. Баруди гарәп теленә кереш мәгънәсендә "Мәдхәле гарәбия", "Өч тел сәлясе", гарәп морфологиясе буенча "Сарфы гарәби" һ. б. хезмәтләр иҗат итә. Алар мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек хезмәтен үтиләр. Олуг философ, дин галиме һәм реформаторы буларак, Галимҗан хәзрәт бер-бер артлы дин-иман, ислам-шәригатькә кагылышлы "Гыйльме әт-тәүхид", "Бәда-әл-мәгариф", "Әл-гокудәс-сәляс", "Гайнел-мәтлаб фи шәрех әбьят хөснел-мәшариб", "Сөаль вә җаваплы хөснел гыйбадәт", "Сөаль вә җаваплы бәда-әл-мәгариф", "Сөаль вә җаваплы гыйбадәте-сәляс",

"Сөаль вә җаваплы әүвәл-ән назафат", "Тарихел-әнбия", "Тәтимме", "Әзкяр шәрифә", "Әзкяр өс-салават", "Әүвәл-ән-назафат фи мәсаил эттаһара" һ. б. китаплар бастырып чыгара һәм төрки-ислам дөньясында зур шөһрәт казана. Аның "Мәгарифе исламия" дигән циклда чыккан хезмәтләре шундый зур популярлык казана ки, "Сөаль вә җаваплы хөснел-гыйбадәт"нең хәтта 1918 елда да 14 нче басмасы дөнья күрә. Барудиның кыйммәтле дөньяви хезмәтләренең берсе — гарәп грамматикасына багышланган 136 битле "Хөснел-мәшрәб фи сарыф лисан-әл-гарәби" (1891) дигән әсәре. Ул үзенең әһәмиятен хәзер дә югалтмаган.

Башлангыч мәктәпне яңа нигездә тәртипкә китереп, Галимҗан хәзрәт әкренлек белән рәшди (урта) сыйныфны ислах итә, 1899 елда яңартылган рәшдия бүлеген ача. Беренче баскычларны ныклы нигезгә куйганнан соң, педагог-реформатор XX йөзнең әүвәлге елларында игъдадия (уртадан югары) һәм иң югары сыйныф — галия класслары ачуга ирешә. Бу эшләрне гамәлгә ашыру юлында җитәкчелек тарафдары Галимҗан хәзрәткә, әлбәттә, гаять зур кыен-лыкларны җиңәргә туры килә.

Мәдрәсәдә ныклы тәртип урнаштырыла: шәкертләрнең килү-китү, керү-чыгу, яту-тору кебек эшләре махсус расписаниегә нигез-ләнә. Тору урыны, дәресханә һәм ашханә һәркайсы аерым бинага урнаштырыла. Шәкертләр гомуми ашау режимын сакларга тиеш булалар. "Мөхәммәдия"дә рус мәктәпләрендәге кебек парталар, мөнбәр (кафедра), кара такталар, тарих һәм география карталары, плакатлар булдырыла. Төгәл расписаниегә нигезләнгән дәрестә шәкертләр утырма якала тужурка, башларына тигез түбәле кәләпүш киеп утыралар.

Кыскасы, Галимҗан Баруди һәм аның фикердәшләре тырыш-лыгы белән "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе XX йөз башларында һәр җәһәттән уңышлар казана. 1907 елда татар җәмәгатьчелеге Галим-җан хәзрәтнең 50 яше тулган көннәрдә аның дин һәм мәгърифәт өлкәсендәге 25 еллык игелекле эшчәнлеген киң рәвештә билгеләп үтә. Газета-журналларда аның шәрәфенә дистәләгән мәкаләләр, котлаулар басыла. Мәшһүр җәмәгать эшлеклесе Йосыф Акчура хәтта аның турында махсус китап нәшер итә.

Мондый хөрмәт һәм игътибардан рухланган мәгърифәтче үзенең мәдрәсәдәге эшчәнлеген тагын да камилләштерә, аның программасына дөньяви фәннәрне тагын да күбрәк кертергә омтыла. Нәтиҗәдә, "Мөхәммәдия"дә киң планда "төрки", ягъни

татар, рус, гарәп, фарсы телләре, арифметика, алгебра, Русия тарихы, төрки кавемнәр тарихы, гомуми тарих, ислам тарихы, физика, гарәп әдәбияты, фәраиз (мирас бүлү фәне), әхлак, гигиена, ритмика, риторика, психология, логика, философия, методика, педагогика һ. б. предметлар укытыла.

1906 елдан башлап, Г. Баруди "Әддин вә-әл-әдәб" ("Дин һәм әдәп") дигән абруйлы журнал да чыгара. Анда, башлыча, коръән, дин-шәригать мәсьәләләре яктыртылса да, мәгарифкә дә шактый урын бирелә, дәрес программалары басыла.

Ул гына да түгел, Галимҗан хәзрәт яңа төрдәге мәктәп-мәдрәсәләр өчен дөньяви белемгә ия мөгаллимнәр әзерләүгә зур хезмәт куя. 1907 елның 2 маенда шушы максат белән "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе каршында махсус педагогик курслар ачыла. Аларга Казан, Уфа, Вятка һ. б. губерна авылларыннан 60 лап кеше җыела. Әмма түрәләрнең рөхсәтеннән башка ачылганга, бу курсларны 60 городовой ярдәмендә полиция туздыра. Таякның юан башы Г. Барудига төшә. Электән үк үзенең җәдидчелек инициативасы өчен эзәрлекләнгән дамеллага (аның "Дин һәм әдәп" журналыннан да "гаеп" табалар) җирле властьлар каты чара күрергә булалар. 1908 елның 8 маенда Галимҗан хәзрәтне берничә тарафдары белән берлектә, губернатор әмере белән 2 елга Вологда губернасына сөрәләр. Журналы да ябыла. Ләкин мөдәррис ныклы җирлеккә салган мәдрәсә, үз юлбашчысын вакытлыча югалтса да, баганалы юлыннан тайпылмый, милләт өчен сыйфатлы белгеч-кадрлар әзерләвен дәвам иттерә.

1910 елда Баруди сөргеннән исән-имин кайта һәм яңадан барлык көч-куәтен дин вә мәгариф эшенә бирә. 1913 елдан "Әддин вә әл-әдәб" яңадан нәшер ителә башлый, "Мөхәммәдия" дә уку-укыту, тәрбия җәһәтеннән тагын бер баскычка күтәрелә.

Гаять зур абруйлы Галимҗан хәзрәт 1917 елгы февраль инкыйлабыннан соң Уфадагы Диния нәзарәтенә мөфти булып сайлана, үз вазифасын намус белән үти. Аның мөфтилек хезмәте Октябрь күтәрелешеннән соң да дәвам итә. Бөек дин галиме, мәгърифәтче һәм педагогның үлеме дә изге юлда йөргәндә була. Мөфти хәзрәтләре 1921 елның декабрендә Мәскәүгә ачларга ярдәм итү мәсьәләсендә җәмәгать вәкиле буларак барган җирендә вафат була һәм Казанга алып кайтып җирләнә.

Татар милләте тарихында, бигрәк тә аның мәдәнияте һәм динифәлсәфи карашлары өлкәләрендә, якты эз калдырган бу олуг затны

без хаклы горурлык хисе белән искә алырга һәм аның күпкырлы эшчәнлеген фәнни нигездә өйрәнергә тиешбез.

Күренекле галим, татар иҗтимагый фикерендә рационалистик агымга нигез салучыларның берсе Габденнасыйр Курсави белемне Малмыж өязе Мәчкәрә авылы мәдрәсәсендә ала. Гаять сәләтле һәм белемгә омтылучан бу баланы мәдрәсәдә биргән белем генә канәгатьләндерми, ул үзлегеннән күп укый һәм кайбер мәсьәләләрдә остазларыннан өстенрәк фикер йөртә башлый. Мәдрәсәне тәмамлагач, Г. Курсави, шул вакыттагы традиция буенча, заманының гыйлем һәм мәгърифәт үзәге саналган Бохарга укырга китә. Андагы күренекле шәхесләрнең берсе — Мөхәммәт Ниязколый әт-Төрекмәнидән дүрт ел буе дәресләр ала. Бохарда ул һәрьяклап дини тәгълиматны өйрәнә, бик тырышып Көнчыгыш телләрен үзләштерү өстендә эшли, күренекле шагыйрьләрнең һәм урта гасыр фикер ияләренең әсәрләре белән таныша. Укуын тәмамлап, туган якларына кайткач, Курса авылында ул зур мәдрәсә ача һәм, үз тирәсенә шәкертләр туплап, мәгърифәтчелек идеяләрен пропагандалый башлый. Кыска гына вакыт эчендә тирә-якта зур дан казанып өлгерә.

Габденнасыйр Курсави уннан артык фәнни хезмәт язып калдыра. Алар арасында иң мәшһүре — "Әл-иршад лил-гыйбад" ("Кешеләрне туры юлга өндәү") исемле китап. Гарәп телендә язылган булса да, бу китапның әһәмияте татар иҗтимагый фикере өчен зур була: Курсави татарлардан беренче булып фәлсәфи тәнкыйтькә юл ача. Ул гасырлар буе дәвам иткән рухи һәм фикри торгынлыкны, искелеккә ябышып ятуны кискен тәнкыйть итә, схоластиканың һәм фанатизмның чын йөзен ачып бирә. Курсави XIX гасыр кешесенең Мөхәммәд пәйгамбәр заманыннан үзгәрешсез калган шәригать кагыйдәләре белән генә яши алмавын аңлый, халыкның киләчәген мәгърифәт юлына басуда, фәнни белемнәр алуда, ирекле фикер йөртүдә күрә.

Татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикер тарихында күренекле тарихчы-галим, фикер иясе һәм фәлсәфәче Шиһабетдин бине Баһаветдин әл-Мәрҗани тирән эз калдырды.

Ул 1818 елның 16 гыйнварында Казан артындагы Ябынчы авылында туа, әтисенең мәдрәсәсендә башлангыч белемне ала. 1839-1849 елларда Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләрендә укый. Монда ул мөселман дине тәгълиматын, гарәп һәм фарсы телләрен тирән үзләштерә, фәлсәфә һәм тарих фәннәрен өйрәнә, Көнчыгыш акыл

ияләренең мирасына зур игътибар биреп, күп вакытын китапханәләрдә уздыра.

1849 елда Мәрҗани Казанга әйләнеп кайта һәм Казанның беренче мәчетендә имам һәм аның каршындагы мәдрәсәнең мөдәррисе итеп сайлана, гомеренең ахырынача шул хезмәтендә кала. Аның бөтен гомере шәкертләр тәрбияләүгә, гыйлем-мәгърифәт таратуга һәм фәнни эзләнүләр алып баруга багышланган. Ул мәдрәсәнең уку-укыту эшләрен яңача үзгәртеп кора, укыту программасына тарих, география, математика, астрономия фәннәрен дә кертә. Аның дәресләре материалны анализлауның тирәнлеге, фәнни мәгълүматларга бай булуы белән аерылып тора. Татарлар тарихында беренче булып, мәдрәсәсендә эчке тәртип кагыйдәләре кертә, попечительләрне сайлап куюга ирешә, укыту эшен надан, шөһрәт яраткан байлар башбаштаклыгыннан азат итә. Шәкертләрен ул Көнчыгышның мәшһүр фикер ияләре һәм шагыйрьләре калдырган бай мирас белән таныштыра, татар халкының әдәби ядкарьләрен һәм авыз иҗаты әсәрләрен өйрәтә.

Татар халкының күренекле фикер иясе, мәгърифәтче, тарихчы һәм педагог, язучы һәм журналист Ризаэтдин бине Фәхретдин бине Сәйфетдин дәресләрне укымышлы әтисе һәм әнисеннән алганнан соң, 7 яшендә мәдрәсәгә керә, башта үз авылында, аннары Түбән Чыршылыда укый. Һәр нәрсә белән кызыксынучан шәкерт югарырак сыйныфларда китап күчереп язу белән шөгыльләнә һәм үз заманы өчен бай гына китапханә булдыра. Риза Фәхретдинов яшь вакытта ук Мәрҗани йогынтысында була, аның әсәрләрен җентекләп өйрәнә, 1886 елда Казанга барып, мәшһүр галим белән очрашып сөйләшү бәхетенә ирешә, бу очрашу аның күңелендә җуелмас эз калдыра. Ш. Мәрҗанинең фәлсәфи фикерләре, алдынгы карашлары яшь шәкертнең иҗади эшчәнлегенә уңай йогынты ясый. Мәдрәсәсен тәмамлап, балалар укыта башлагач, Р. Фәхретдин Мәрҗанинең алдынгы ысулларын куллана, тәрбия эшендә бай тәҗрибә туплый. Укыту эшчәнлеге белән беррәттән, Р. Фәхретдин фәнни эш белән мавыга, бик күп китаплар һәм мәкаләләр яза, татар халкының рухи тормышына караган язма чыганакларны җыя, тәртипкә сала. 1887-1888 елларда яшь галимнең бер-бер артлы балалар тәрбиясе, гарәп теле грамматикасы, мирас бүлү мәсьәләсендә шәригать кануннары, әхлак тәрбиясе турында татар һәм гарәп телләрендә дүрт китабы дөнья күрә.

Татар халкының һәм бөтен төрки дөньясының бөек улы, мәгърифәтче һәм мөгаллим, язучы һәм галим Исмәгыйль Гаспралы (Гаспринский) 1861 елның 8 мартында Кырымдагы Гаспра авылы янындагы Хаҗикөйдә мирза гаиләсендә туа. Исмәгыйль Мортаза улы башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала, аннан соң Воронеж шәһәрендә, Мәскәүдә кадет корпусында укый. Ләкин 14-15 яшьләрендә вакытта ул хәрби белем алуын калдырып, Идел, Дон елгалары, Азов диңгезе буйлап, Бакчасарайга Кырымга кайта. Биредә ул атаклы Зынҗырлы мәдрәсәсендә берничә ел буена укытучылык итә, аннан соң белемен күтәрү нияте белән Истанбулга китә. Истанбулдан Исмәгыйль Гаспралы Парижга барып чыга. Анда ул өч ел эшли. Эмиграциядәге русиялеләр белән очраша, хәтта И. С. Тургенев янында эшләп тә ала, Гаспралы татар, төрек, гарәп, фарсы, француз, рус телләрен бик яхшы белә, бу белемнәре аркасында ул Парижда төрле телләрдә чыга торган газеталарда эшли, мәкаләләр яза, әдәби иҗат белән шөгыльләнүе дә шул чорда башлана.

Туган якларына кайтканда, Гаспралы Алжир, Тунис, Мисыр, Греция аша кайта, дөньяны өйрәнә, кардәш мөселман халыкларның гореф-гадәтләре белән кызыксына. Юл сәяхәтендәге тәэсирләрдән чыгып, ул бөтен төркиләрне берләштерү, алар өчен уртак бер әдәби тел булдыру турында хыяллана башлый. Моның өчен уртак бер газета чыгару кирәклегенә төшенә.

Исмәгыйль бәй Гаспралының төрки милләтләр бәхете хакына башкарган җәмәгать эшләренә күз салсаң, аның активлыгына хәйран каласың. Беренче рус инкыйлабы елларында, мәсәлән, И. Гаспралы Кырым игенче-крестьяннарының ике съездын үткәргән, 700 дән артык делегат катнашкан бу съездларның мәҗлесләрендә җир мәсьәләләренә багышланган төрле чыгышлар ясый. Рәсәй тарихында иң беренчеләрдән булып, И. Гаспралы 1904 елда Бахчасарайда матбугат хезмәткәрләренең һөнәр-кәсеп оешмасын (профсоюзын) төзи. Исмәгыйль бәй шулай ук Рәсәйдә яшәүче төрки мөселман халыклары мәнфәгатьләрен тормышка ашыруны алгы сызыкка куйган "Иттифак әл мөслимин" партиясенең дә күренекле җитәкчеләреннән берсе була.

Шәмсетдин Күлтәси — Шәмсемөхәммәд Нурмөхәммәт улы Таһиров — XIX йөз ахыры – XX йөз башларында татарлар арасында фәнни белемнәрне һәм фәлсәфи идеяләрне пропагандалау буенча зур эш башкарган мәгърифәтче галим һәм педагог. Дин бе-

лән араны өзмичә, Күлтәси схоластикага каршы чыга. Прогресс һәм халык тормышын яхшыртуның төп шарты сыйфатында фәлсәфәне һәм фәнне дин белеменә каршы куя, ислам диненең фәнни-фәлсәфи проблемаларын шәригать канунары нигезендә хәл итәргә тырышучы догматикларны кыю тәнкыйтьли. Шәригать бары тик дин мәсьәләләре белән генә шөгыльләнергә тиеш, ә чынбарлыкның табигатен һәм кануннарын өйрәнү — фән һәм фәлсәфә бурычы дип аңлата.

Күлтәсинең кыю фикерләре, мәгърифәт эшчәнлеге искелек тарафдарларының ачуын чыгара, патша охранкасы аның өстеннән гел күзәтеп тора. Күлтәсинең халыкның фәнни-агарту эшчәнлеге татар иҗтимагый фикере үсешендә якты эз калдыра, урта гасырчылык белән сугарылган мөселман идеологиясен какшатуда әһәмиятле роль уйный.

Атаклы дин галиме, публицист, фәлсәфәче, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Муса Яруллаһ (Җарулаһ) Биги — танылган әдип Заһир Бигиевнең бертуган энесе. Ростов-Донда, Казанда, Бохарада мәдрәсәләрдә укыганнан соң, Якын Көнчыгышта Мәккәдә, Мәдинәдә, Каһирәдә, ә соңыннан Истанбулда күренекле галимнәрнең дәресләрен тыңлый. 1904 елда Русиягә әйләнеп кайта, ирекле тыңлаучы буларак, Петербург университетының юридик факультетында дәресләр ала. Гадәттән тыш зирәк һәм тырыш Муса Биги киң карашлы дин һәм хокук билгече булып җитешә. Петербургта Рәшит Ибраһимов чыгарган "Өлфәт", "Әт-Тилмиз" журналларында языша башлый, сәясәт эшләре белән кызыксына. Русия мөселманнарының милли-азатлык хәрәкәтенең актив эшлеклеләреннән берсенә әвереләә, мөселман съездларын оештыручылардан була, "Иттифак әлмөслимин" фиркасының җитәкче органнарына сайлана, нәшрият эшләре белән шөгыльләнә. Ул "Шура" һәм башка газета-журналлар битләрендә даими рәвештә бәхәсле мәсьәләләр буенча мәкаләләр бастыра, рефератлар яза, лекцияләр укый. 1917 елдан соң М. Бигиев Петербург һәм Мәскәү мәчетләренең имамы булып эшли. Ислам диненә реформа ясау, аны җанландыру, заманының иҗтимагый тормышы, фәне таләпләренә җайлаштыру идеясен алга сөргән дини фәлсәфи хезмәтләрен бастыра. Басылган әсәрләренең кайберләре: "Кавагыйде фикъһийә" ("Ислам хокукы нигезләре"), (Казан, 1910), "Инсанларның гакыйдәи илаһийәләренә бер нәзар" ("Кешеләрнең дини ышануларына бер караш"), (Оренбург, 1911), "Озын көйләрдә руза" (Казан, 1911), "Рәхмәте илаһийә

борһанлары" ("Аллаһының рәхмәтлелегенә дәлилләр"), (Оренбург, 1911), "Халык нәзарына бер мәсьәлә" (Казан, 1913) һ. б.

Муса Яруллаһ Бигигә үз замандашлары, шул исәптән Габдулла Тукай да югары бәя биргән. Чит ил галимнәре арасында аның исеме бик билгеле. Муса Яруллаһ Биги — үзгәртеп кору чорында татар халкына яңадан кайта башлаган исемнәр рәтендә. Озак еллар, дин галиме булганы һәм чит илгә киткәне өчен, аңа төрле ярлыклар тагып, исемен халык тарафыннан "онытып" торырга мәҗбүр иткәннәр иде.

Муса Яруллаһ Биги кебек үк, Габдерәшит Ибраһимовның да исеме озак еллар буе халкыбыз өчен билгесез калган исемнәрнең берсе.

Мәшһүр дин галиме, җәмәгать эшлеклесе һәм журналист Габдерәшит Гомәр улы Ибраһим Себердә Тубыл губернасының Тары өязендә 1850 елда дөньяга килә. Заманына күрә яхшы тәрбия ала, башта гаиләсендә укырга-язарга өйрәнә, аннары Казан артына, атаклы Кышкар мәдрәсәсенә килеп, егерме яшенә кадәр белем ала. Казах далаларына чыгып, балалар укыту белән шөгыльләнә, шул ук вакытта үзлегеннән укуын, тормыш тәҗрибәсен арттыруын дәвам итәргә, соңрак туган ягына кайтып мулла була.

1877 елда Истанбулга китә, анда бераз яшәгәч, Гарәбстанга — мөселманнарның изге туфрагы Мәккә белән Мәдинәгә барып урнаша. Монда ул дүрт ел буе ислам дине нигезләрен өйрәнүне дәвам итә, галимнәр, төрле илләрнең хаҗилары, фикер ияләре белән аралаша. Мәккәдә чакта Төньяк Кавказ халыкларының милли-азатлык көрәше каһарманы шәех Шамил белән очрашу аңарда тирән тәэсир калдыра. "Гасырлар буе урыс золымын татып яшәгән милләт баласы Габдерәшит илбасарлар һөҗүмен кырык ел буе кире кагып килгән, бөтен тормышын ат сыртында уздырган, бик күп җиңүләргә ирешкән атаклы кардәшенең хатирәләрен тыңлый. Куркусызлык, йөрәклелек, үз халкының иреге өчен көрәштә фидакарьлек белән тулы хикәятләр болай да татар язмышына ифрат ачынып йөргән егет йөрәгенә көрәш дәрте, батырлык ялкыны өсти, аның туган милләте хокукларын тергезү омтылышын дөрләтеп җибәрә, һичбер кыенлык, киртәләр алдында икеләнеп, өркеп калмаслык бер халәткә китерә. Шәех Шамил белән аралашу аның өчен кимсетелгән, изелгән милләтне кабат бастыру юлында иман ныгыту була. Ләкин яңа заманда бу көрәшне искечә дәвам итү мөмкин түгеллеген дә төшенә Себер егете. Шуңа күрә 1881 елда

яңадан Истанбулга әйләнеп килгәч, бәйсезлеген беркайчан да җуймаган, кардәш төрки халыклар, кабиләләр мәнфагәтен дә күз уңында тотарга тырышкан төрек җәмгыятенең алдынгы өлеше белән танышырга омтыла". (Т. Әйди, Габдерәшит Ибраһим. - Идел, № 1. - 31 б.)

Габдерәшит Ибраһим, Төркия тәҗрибәсен файдаланып, татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дини дөньяви белемнәрне бергә бирү фикеренә килә һәм шул хыял белән туган иленә кайта. Халкын озак дәвер дәвам иткән торгынлыктан, рухи коллыктан йолу өчен мәчетләрдә вәгазьләр укырга керешә, төрле җыелышларда мөселманнарны уянырга чакыра башлый. Тиз арада татарның күренекле акыл ияләре Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдиновлар белән бәйләныш урнаштыра. 1892 елда Оренбургта Диния нәзарәте идарәсенә сайлангач, Рәшит казый үз ниятләрен тормышка ашырырга керәшә. Ул Рәсәй халкының биштән бер өлешен тәшкил иткән мөселманнарны дини, мәдәни, сәяси яктан иректә итеп күрергә тели.

Габдерәшит Ибраһимов бәрәкәтле озын гомер кичерә. Ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр Азия мәмләкәтләрендәге мөселманнарны берләштерү фикере белән янып йөри, башка халыкларга ислам дине тарата. Икенче бөтендөнья сугышы елларында мөселман әсирләрен коткару эшен оештырып йөри. Аның эшчәнлеген Япония, Һиндстан, Индонезия һ. б. илләрдә югары бәялиләр, бөтен мөселман дөньясында аның исеме зур хөрмәт белән искә алына.

Мәгарифебез тарихына профессор Мөхәммәтхан Фазлуллин талантлы педагог, тирән эрудицияле лингвист һәм методист буларак кереп калган.

Заманалар авыр булса да, әтисе, әнисе аны белемле итәргә тырышалар, улларының мәдрәсәдә укып, мулла булуын телиләр. Башлангыч белемне авылда алганнан соң, М. Фазлуллин Казанның "Күл буе" мәдрәсәсенә укырга керә. Бу мәдрәсәне 1903 елда уңышлы гына тәмамлый, һәм аны шунда укытучы итеп эшкә калдыралар. Мәдрәсәдә эшләгән вакытында үзлегеннән рус телен үзләштереп, Казанның рус-татар укытучылар мәктәбендә (данлыклы "Казанская Русско-татарская учительская школа"да) укый башлый. Бу мәктәпкә укырга керүенә әтисе каршы булса да, Мөхәммәтхан укуын тәмамлый ала. М. Фазлуллин 1905 елгы инкыйлаб чорындагы шәкертләр һәм укытучылар хәрәкәтендә актив катнаша. Мәдрәсә, мәктәпләрдә хөкем сөргән уку-укыту системасына үзгәрешләр кер-

ту кирәклеге турындагы таләпләрне күтәреп чыга. Реакцион власть даирәләре аның бу фикерләрендә җавапсыз калмыйлар: Мөхәммәтханны 1905 елда укытучылар мәктәбеннән, ә 1906 елда мәдрәсәдән дә куалар. М. Фазлуллин үзлегеннән күп укый, белемгә теләген югалтмый. 1906 ел азагында аңа яңадан укытучылар мәктәбенә кайтырга рөхсәт бирәләр. Ике елдан ул бу мәктәпне бик яхшы билгеләренә генә тәмамлап чыга.

Шушы елларда Мөхәммәтхан Фазлуллин беренче гыйльми хезмәтен яза. Бу укыту һәм тәрбия өчен кыскача кулланма рәвешендә язылган "Дидактика кагыйдәләре" китабы була.

Татарстан педагогия җәмгыяте һәм халык комиссариаты каршындагы Академик Үзәк әгъзасы буларак, М. Фазлуллин татар мәктәпләре өчен дәреслекләр, программалар төзүдә актив катнаша.

* * *

Утыз икенче лекция

МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ — ДАНЛЫ МӘГАРИФ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ

Беренче! Бу сүзне татарның атаклы педагогы һәм методисты **Шакирҗан Таһири исемен телгә алганда кат-кат әйтергә туры килә.**

Мәгълүм ки, татар мәктәп-мәдрәсәләрендә укыту-тәрбия эшендә схоластика бик нык тамыр җәйгән була. Тик XIX йөзнең икенче яртысында гына, бигрәк тә 1890 елларда, аңа каршы көрәш көчәя. Шакирҗан Таһири әнә шул көрәшнең башында торучыларның берсе була.

Ул уку-укытуның эчтәлегенә һәм методларына реформа ясау, җәдит мәктәпләре өчен укыту әсбаплары булдыру, яңа методлар куллану мәсьәләләрен хәл итү өчен армый-талмый эшли. Таһири татарларда аваз (саутия) методын нигезли. Аның гарәп графикасыннан файдаланып иҗат ителгән татар алфавитын һәм имласын камилләштерү юнәлешендәге инициативасы да мактауга лаек.

Шакирҗан Таһири 1858 елда хәзерге Зеленодольск районының Ачасыр авылында туа. Анда башлангыч белем алганнан соң, Казандагы "Мәрҗани" мәдрәсәсендә укый.

1876 елда яңа ачылган Татар укытучылар мәктәбендә (Татарская учительская школада) белем ала, 1880 елда аны тәмамлагач, бер кадәр Пләтән (хәзерге Сәйдәшев) урамындагы рус-татар мәктәбендә — рус теле укытучысы, бераздан үзе белем алып чыккан укытучылар мәктәбендә рәсем, сызым һәм матур язу (каллиграфия) мөгаллиме булып эшли. һәм гомеренең ахырына кадәр әлеге мәктәптә шул хезмәтен дәвам иттерә. 1918 елның 14 гыйнваренда алтмышынчы яшендә вафат була.

Атаклы педагог һәм методистның гаять тынгысыз кеше булуы турында аеруча басым ясап әйтергә кирәк. Ул зур иҗат эше белән мәшгуль булуына карамастан, үзенең белемен туктаусыз күтәрә. Казан реальное училищесы рәссамы Пашковский белән эшлекле мөнәсәбәткә керә, аңардан хосусый дәресләр ала һәм 1883 елда, татарлардан беренче булып, Петербургтагы император сәнгать акаде-

миясендә имтихан тапшырып диплом ала. Диплом аңа өяз училищесында рәсем, сызым һәм каллиграфия укытучысы булып эшләү хокукы бирә. Ул дәвердә шәригатьнең мәктәпләрдә генә түгел, барлык татар дөньясында җанлы нәрсәләрнең сынын ясауны тыюын (ул сын, ахирәттә җаныңны ала, имеш) хәтергә төшерсәк, әлеге тырышлыкның нинди әһәмияткә ия булуы аңлашыла бугай.

Гомумән, Шакирҗан хәлфәнең сул карашлы шәхес икәнен әйтеп узу да урынлы булыр. Мәсәлән, 1907 елда революцион хәрәкәттә катнашкан укучыларны мәктәптән куу мәсьәләсе педколлективта тикшерелгәндә, ул бер үзе моңа каршы тавыш бирә. Февраль һәм Октябрь революцияләренә дә аның карашы уңай була һәм ул яңа совет мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләү курсларын оештыруда актив катнаша, шул курсларда лекцияләр укый.

Шакирҗан Таһири укытучылар мәктәбендә укыган һәм укыткан елларда грамотага өйрәтүнең алдынгы методлары белән якыннан таныша. Шушы мәктәптә алынган белем һәм турыдан-туры мәктәптә эшләү аңа үзенең "Бәдьә әл-тәгълим нәм мөкәммәл әлифбасын (1893 ел башында) ул чорларда инде рус мәктәпләрендә киң кулланылган аваз методы белән төзергә ярдәм итә. Ш. Таһири үзе төзегән әлифбаларны камилләштерү өчен күп көч куя. Бу — әлифбаның 1915 елда басылып чыккан VI басмасыннан бик ачык күренә. VI басма татарча укыту өчен генә төзелгән, башкаларындагыча, гарәпчә укыту өчен материал юк. Бер үк вакытта ике сыйныф белән эшләүчеләр өчен һәр дәрес ахырында язу күнегүләре бирелгән.

Моннан тыш, автор 1914 елда, фонетика нигезендә, Казан шивәсендә төзелгән рәсемле әлифба бастырып чыгара. Бу уңай белән шуны әйтергә кирәк: моңа хәтле чыккан рәсемле әлифбаларда җанлы нәрсәләрнең рәсемнәре әлифба дәреслегенә урнаштырылмый (Х. Зәбири, Ә. Мостафа). Ә Шакирҗан хәлфә әлифбасында кеше, кош-корт, мал-туар рәсемнәрен дә күрәбез.

"Рәсемле әлифба"да сурәтләрне ясаучы рәссамның фамилиясе күренми. Әмма Ш. Таһириның рәсем укытучысы булуына игътибар итсәк, сурәтләрне аның үзенең ясавына шөбһәләнергә урын калмый.

Ш. Таһири үзе төзегән әлифбаны ничек өйрәнергә кирәклеге турында методик кулланма да яза. Ул аны "Мифтахе бадьэ әл-тәгълим" дип атый. (Ягъни башлап укытырга өйрәтү ачкычы). Аның бу хезмәте 1893 елда нәшер ителгән беренче әлифбасының ахырына

урнаштырылган. Соңыннан ул ике тапкыр аерым китап булып та басылып чыккан. Моңа кадәр әлифба укыту тарихында гына түгел, гомумән, бездә махсус методик кулланма һәм дәрес эшкәртмәләренең бөтенләй булмавын искә алсак, "Мифтахе бадьэ әл-тәгълим"не татар методик әдәбиятының беренче карлыгачы дип атарга мөмкин.

Җыеп әйткәндә, Шакирҗан Таһири үзенең "Мөкәммәл әлифба"сын төзеп грамотага аваз методы белән өйрәтүгә нигез сала. Ул бу эшне татар алфавитын камилләштерү юнәлешендә эзләнүләрдән башлый. Ул вакытта гамәлдәге алфавитта сузык авазлар өч хәреф белән генә белдерелгән булса, әлифба авторы аларның санын арттыру, ягъни Каюм Насыйриның татар телендә 10 сузык хәреф булдыру кирәклеге идеясен тормышка ашырып, үзенең дәреслеген бөтенләй яңа, әле беркем тарафыннан да танылмаган һәм кабул ителмәгән 10 сузык аваз хәрефен файдаланып төзи.

Әлеге яңалык рус галимнәренең игътибарын үзенә җәлеп итә. Бу хакта, мәсәлән, Н. Катанов "Деятель" журналында болай дип яза: "Гарәп язуы төрек һәм татар фонетикасына аз туры килгәнлектән, кайбер мөселманнар, Максудовтан да (Һади Максуди) элегрәк, төрек һәм татар авазларындагы төгәллек хакына, гарәп хәрефләренә махсус билгеләр куя башладылар: бу мөселманнар Төркиядә — Әхмәд Вафин патша, Казанда — Ш. Таһиров һәм К. Насыйров. Татар сүзләрен уңышлырак транскрипцияләүчеләр Таһиров һәм Максудов әфәнделәр булдылар".

Башкача булуы да мөмкин түгел. Чөнки Ш. Таһири, бүтән авторлардан аермалы буларак, үзенең әлифбасын үз балаларына укытып тикшергәннән соң гына бастырып чыгара, әлифбаның басмадан камилләшә баруы да әнә шуның нәтиҗәсе дип уйларга кирәк. Бәлки шуңа күрәдер, аның гаиләсендәге 9 баланың җидесе әтиләре юлын сайлый, мөгаллимлек итә. Профессор Рифгать Таһиров әтисенең һөнәрен педагогия институтында дәвам иттерде.

Шакирҗан Таһириның, чит телне яхшы үзләштерергә теләгән кеше үз теленең үзенчәлекләрен тирәнтен белергә тиеш, мин балаларымны башта ике-өч ел татарча укытам, тик шуннан соң гына русча укыта башлыйм, дигән фикерләре безнең көннәрдә дә гаять зур әһәмияткә ия.

Шакирҗан хәлфә — тарихта шактый тирән эз калдырган 20 хезмәтнең авторы. Аның дөнья күрми калган хезмәтләре дә шактый. Алар арасында гарәпчә синтаксис, гарәп хәрефләре белән матур

язарга өйрәтү, башлангыч мәктәптә геометрия һәм арифметикага өйрәтү кебек дәреслекләр бар.

Шакирҗан Таһири — татар халкының горурланырлык педагогы һәм методисты.

Бөгелмә шәһәреннән 10 км ераклыкта урнашкан Спасское авылы чиркәвендә күренекле рус галиме, география, авыл хуҗалыгы, экономика һәм тарих буенча йөзгә якын фәнни хезмәт авторы, Петербург фәннәр академиясенең беренче член-корреспонденты, бөек галим М. В. Ломоносовның хезмәттәше Петр Иванович Рычков күмелгән.

Бу зур галимне безнең якларга нинди җилләр ташлаган соң?

П. И. Рычков 1712 елның 1 октябрендә Вологда шәһәрендә сәүдәгәр гаиләсендә туган. 1720 елда аны, чит телләргә, коммерция һәм бухгалтерия эшләренә өйрәнү өчен, Мәскәү туку фабрикалары директоры И. П. Томеска бирәләр. Малай кыска гына вакыт эчендә, немец, голланд телләрен һәм арифметиканы үзләштерә.

Укуын тәмамлагач, П. И. Рычковны Санкт-Петербург таможнясына тәрҗемәче һәм бухгалтер ярдәмчесе итеп билгелиләр. Аны бу эшкә кабул итү вакытында сенатның обер-сәркатибе, шул чорның күренекле географы һәм картографы И. К. Кириллов та катнаша. Галим — егетнең күп нәрсә белән кызыксынучан, хезмәт сөючән һәм гаять зирәк акыллы булуын күреп ала. Менә шушы факт П. И. Рычковның киләчәк тормыш юлын билгеләүдә гаять мөһим роль уйный.

И. К. Кирилов инициативасы белән 1734 елда П. И. Рычков Ор елгасының Җаекка коя торган урынында шәһәр салуга әзерлек максаты белән оештырылган экспедиция составына кертелә. Аның фәнни эшчәнлеге әнә шул чорда башлана.

Соңрак П. И. Рычков күренекле галим һәм дәүләт эшлеклеләре булган В. Н. Татищев, И. К. Кирилов һәм И. И. Неплюев тарафыннан Көньяк Уралга һәм Башкорстан җирләренә оештырылган экспедицияләрдә булып, җирле табигать, халык һәм аларның тарихы, икътисады һәм культурасы белән якыннан таныша. Шулар нигезендә ул икътисадын авыл хуҗалыгы, география һәм тарих буенча байтак кына фәнни хезмәтләр яза. Шундыйлардан "Оренбург тарихы", "Казанның борынгы һәм урта гасырлар тарихы тәҗрибәсеннән", "Оренбург типографиясе", "Татар-калмык лексиконы" һ. б. күрсәтергә мөмкин.

П. И. Рычковның И. Красильников төзегән топографик картага аңлатма формаларында язылган "Оренбург топографиясе" дигән хезмәте регионның климаты, рельефы, файдалы казылмалары, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы, шулай ук халкы турында киң мәгълүмат бирә. Аның бу хезмәте дөнья тәҗрибәсендә шундый типтагы әдәбиятның "беренче карлыгачы" санала.

П. И. Рычковның байтак кына хезмәтләрендә авыл хуҗалыгы һәм промышленностьны күтәрү, эчке базарларны һәм товарларны читкә чыгаруны киңәйтү, далада урман үстерү, умартачылык, Оренбург губернасындагы күмер һәм тоз ятмаларын эшкәртү кебек мәсьәләләр дә киң чагылыш таба. П. И. Рычков, беренчеләрдән булып, Көньяк Уралдагы табигый мәгарәләргә игътибар иткән.

Әнә шундый фәнни хезмәтләрен искә алып, 1741 елда ук инде В. Н. Татищев Фәннәр академиясе алдында П. И. Рычковны көмеш медаль белән бүләкләү һәм аңа Академиянең мактаулы әгъзасы исемен бирү мәсьәләсен күтәрә. Ләкин мәсьәлә ул чорда уңай хәл ителми кала. 1759 елның январенда Петербург Фәннәр академиясендә член-корреспондент дигән яңа фәнни исем кертелә. М. В. Ломоносов тәкъдиме белән П. И. Рычков беренче член-корреспондент итеп сайлана. Мондый югары исемгә лаек булу аны яңа иҗади эшкә рухландыра, ул үзенең фәнни-тикшеренүләрен зур дәрт белән дәвам иттерә.

1750 елда П. И. Рычков Академиягә татарлар турындагы хезмәтен җибәрә. Шул ук вакытта ул татар-калмык мәктәпләре оештыру, алар өчен ярдәмлекләр әзерләү белән шөгыльләнә, В. Н. Татищев кушуы буенча "Рус тарихы"ның аерым бүлекләрен яза.

П. И. Рычков Иректе икътисад җәмгыяте һәм Мәскәү университеты каршындагы Россия Ирекле җәмгыяте (собраниесе) әгъзасы була. Шушы җәмгыятьләр чыгарган фәнни җыентыкларда басылган хезмәтләре өчен ул Ирекле икътисад җәмгыятенең бер алтын һәм дүрт көмеш медале белән бүләкләнә.

1760 елда П. И. Рычков отставкага чыга һәм Бөгелмә янындагы үзенә бүләк итеп бирелгән җирдә үзе төзеткән Спасское имениесенә килеп урнаша. Монда килү белән, ул бакыр рудасын эзләү, бакыр эретү заводы төзү өчен урын табу мәсьәләләрен хәл итүгә керешә. Шул чорда галим җирле нефть ятмаларын өйрәнү эшен дә башлап җибәрә.

1777 елның мартында П. И. Рычков Екатеринбург (хәзерге Свердловск) заводлары идарәсенә башлык итеп билгеләнә. Ләкин

бу эштә аңа озак эшләргә туры килми. Инде сәламәтлеге нык какшаган 65 яшьлек П. И. Рычков шул елның октябрендә вафат була. Үзенең васыяте буенча аны Спасскоеда үзе салдырган чиркәүгә алып кайтып күмәләр.

Сүз ахырында шуны да әйтәсе килә. Моннан 220 ел элек төзелгән чиркәү хәзер дә саклана. Биредә бу зур галимгә мемориаль такта кую һәм аның музеен оештыру турында уйлыйсы иде.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчеләре һәм галимнәре арасында Мөхетдин Хафизетдин улы Корбангалиевның иҗади эшчәнлеге күренекле урын алып тора. Ул 1873 елда Вятка губернасы Алабуга өязе Биектау авылында (хәзер Татарстанның Әгерҗе районы) крестьян гаиләсендә туа. Авылда белем алгач, 1890-1895 елларда Казанда Татар укытчылары мәктәбендә укый. Шул елларда М. Корбангалиев күренекле татар педагогы, мәгърифәтче К. Насыйри белән таныша. Әлеге мәктәпне тәмамлагач, Мамадыш өязе Әбде волосте Чәбия-Чүрчи авылына земство карамагындагы рус-татар мәктәбенә арифметика һәм рус теле укытучысы итеп билгеләнә.

1899-1902 елларда М. Корбангалиев Вятка губернасы Алабуга өязе Биектау, Яңа Аккүз авылларында һәм Алмыжда арифметика һәм рус теле укытучысы булып эшли.

1903 елда аны Казанга бертуган Юнысовларның ятим балалар йортына күчерәләр. Ул 1917 елның октябренә кадәр шунда караучы вазифасын башкара, рус теле һәм арифметика укыта.

Казанда яшәгән чорда М. Корбангалиев иҗтимагый тормышта да катнаша, Хөсәен Ямашев белән таныша. Әмма фәнни-педагогик эшчәнлек аның төп шөгыле булып кала. Аңа хосусый башлангыч мәктәп һәм хатын-кызлар гимназиясе өчен устав һәм фәннәрне укыту программасын төзү эше тапшырыла.

М. Корбангалиев, үз тәҗрибәсе нигезендә, башлангыч мәктәпләр өчен татарча математика дәреслекләре яза. Менә аларның кайбер-ләре: Хисап мәсьәләләре һәм гадәти мисаллар, I китап. Иптидаинең I сыйныфы өчен, 1 дән 20 гә кадәр — Казан: Үрнәк, 1910. – 72 б.; Хисап мәсьәләләре, III китап. Иптидаинең III-IV сыйныфлары өчен. – Казан: Мәгариф, 1911. – 78 б.; Хисап мәсьәләләре. II китап. Иптидаинең II сыйныфы өчен. 20 дән 100 гә кадәр. – Казан: Мәгариф, 1913. – 64 б.

Дәреслекләр методик яктан җентекләп төзелүе, уку материалының максатка ярашлы итеп сайлап алынуы һәм дөрес урнаштырылуы, мәсьәләләрнең чишелешләре бирелүе белән аерылып тора.

Хисап мәсьәләләре җыентыклары 1929 елга кадәр күп мәртәбә басыла һәм татар-башкорт мәктәпләрендә киң тарала.

1912 елда Казанда "Мәктәп" журналы чыга башлый. Журналда М. Корбангалиевнең укыту методлары һәм төрле фән программалары турында язган мәкаләләре басыла. Революциягә кадәр ул татар-башкорт мәктәпләре өчен дәреслекләр, программалар төзи, татар мәктәпләре ачуда башлап йөри, авыл мөгаллимнәренең педагогик киңәшмәләрендә катнаша. М. Корбангалиев 1917 елның язында Казанда узган мөселман укытучыларының I Бөтенроссия съезды делегатлары төркемен җитәкли.

Татарстан Республикасы төзелгәч, тынгысыз мөгаллим мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеген дәвам иттерә. Ул шәһәр мәктәпләрендә инспектор, халык мәгарифе бүлеге мөдиренең урынбасары, Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты каршында бердәм хезмәт мәктәбен оештыручы һәм аның җитәкчесе, Академик үзәкнең редколлегия әгъзасы һәм методист-консультанты, "Мәгариф" журналының редколлегия әгъзасы була һ. б. ш. җаваплы эшләр башкара.

1923 ел ахырында Мәскәүдә татар-башкорт мәгариф хезмәткәрләренең Бөтенроссия съезды уздырыла. Съездда фәнни формулалар язу өчен латин алфавитын кабул итү турында карар чыгарыла. Революциянең бу өлешен М. Корбангалиев математик Гаяз Максудов белән бергә яза.

1923-1929 елларда педагог беренче баскыч Бердәм хезмәт мәктәпләре өчен математикадан методик кулланмалар төзи, 1923-1924 елларда, Г. Богданов белән бергә, беренче баскыч мәктәпләренең I, II, III, IV уку елы өчен "Рыязият (математика) дәреслекләре төзи. 1929 елга кадәр шул ук авторларның беренче баскыч хезмәт мәктәпләре өчен "Математика дәреслеге" бастырыла: 1 нче уку елы өчен (1925, 176 б.); 2 нче уку елы өчен (1926, I кис, 149 б.; II кис, 150 б.); 3 нче уку елы өчен (1929, 146 б.); 4 нче уку елы өчен (1929, 144 б.).

М. Корбангалиев математика укытуның фәнни-методик нигезләрен эшләүгә зур өлеш кертә. Шуның белән бергә, аның тел белеме өлкәсендә дә хезмәтләре игътибарга лаек. Галим-педагогның 100 дән артык дәреслеге һәм укыту кулланмалары басылып чыга.

Шунысы да кызыклы, М. Х. Корбангалиев гаиләсендә 4 бала булган; шуларның икесе — профессор. Улы Салих (1901 елда туган) — медицина фәннәре докторы, Санкт-Петербургтагы 1 нче медицина институтының гомуми хирургия кафедрасы мөдире. 1930-1931 елларда ул Казан медицина институтының беренче

директоры, ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары (1931-1935 еллар) вазифаларын башкарган, фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнашкан. Кызы Хәлимә (1910 елда туган) — биология фәннәре докторы, Казан дәүләт университетының умырткалар зоологиясе кафедрасы мөдире, Россия Фәннәр академиясе гидробиологик җәмгыятенең Казан бүлеген оештыручы һәм аның беренче рәисе була.

М. Корбангалиевнең фәнни хезмәтләре, педагогик эшчәнлеге хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнә. Аңа Хезмәт Герое (1928), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1940) исемнәре бирелә, ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

М. Корбангалиев югары уку йортларында татар телен дә укыта. Ул татар телен рус теле белән чагыштырма рәвештә укытуны яклый һәм студентларны русчадан татарчага һәм, киресенчә, татарчадан русчага тәрҗемә итүгә күнектерергә кирәклеген дәлилли, шушы юнәлештә эшләүнең метод һәм алымнарын тәкъдим итә.

М. Корбангалиев русларга һәм, гомумән, татар телен белмәүчеләргә татар телен өйрәтергә кирәклеге турында әйтә һәм ул 1923-1924 елларда ук, төрле авторлар белән бергә, башка милләт кешеләре өчен татар теле дәреслекләре төзи. Укытуның үзенчәлекләре, метод һәм алымнары турындагы өйрәтмәләрен шул дәреслекләрнең сүз башларыннан, аларның төзелү системасыннан һәм программалардан күрә алабыз.

1927-1937 елларда Р. Газизов белән бергә һәм үзе генә дә урта мәктәпнең — V-VII класслары өчен "Руслар өчен татар теле дәреслеге" һәм "Татарлардан башкалар өчен татар теле дәреслеге" дигән китапларны төзеп бастыра. Бу дәреслекләр Мәгариф Халык Комиссариаты тарафыннан техникумнар, югары уку йортлары һәм өлкәннәр өчен оештырылган русларга тәкъдим ителгән булган. Аларда сөйләм телен үстерүгә, укырга һәм язарга, грамматика һәм орфография кагыйдәләрен өйрәтүгә әһәмият бирелә.

М. Корбангалиев югары уку йортларында, шул исәптән Казан дәүләт университетында да, татар телен белмәүчеләргә татар телен ничек укыту турында "КДУдагы татар булмаган студентларга татар телен укыту методлары турында" дигән докладында аңлатма бирә. Ул студентларның сүзлек запасын баету, аларга бәйләнешле сөйләм күнекмәләре бирү, студентларны гади, ә соңрак катлаулы фразалар төзергә өйрәтү, грамматик күренешләрне аларның сөйләмнәрендә һәм язма эшләрендә файдалана белү күнекмәләре

бирергә тәкъдим итә. Зур булмаган текстларны үзгәртеп сөйләү һәм язу, татарчадан русчага һәм, киресенчә, русчадан татарчага тәрҗемә итү һ. б. шундый алымнарның белемнәрне тәҗрибәдә куллана белергә өйрәтүен һәм телне өйрәнүгә кызыксынуны үстерергә ярдәм итүен әйтә. Анынча, югары уку йортын тәмамлаганда, студент ирекле рәвештә татарча укый, яза һәм сөйли белергә, үз фикерләрен аңлату һәм аңлаша алу дәрәҗәсенә җитәргә тиеш.

М. Корбангалиев, үзенең эш тәҗрибәсенә таянып, 1934 елда, татар телен белмәүчеләргә татар телен өйрәтү максаты белән, техникум, рабфак, вуз һәм втузлар өчен "Татарлардан башкалар өчен татар теле дәреслеге" дигән кулланма әзерләп бастыра. Анда фонетика, морфология һәм синтаксис буенча тулы мәгълүмат бирелгән һәм матур әдәбияттан үрнәкләр дә китерелгән. Татар теленең грамматик күренешләре, бигрәк тә, морфология бүлеге, рус теле белән чагыштырылып бәян ителгән.

"Татарлардан башкаларга татар теле дәреслеге" (1941 елда бастырылып) урта һәм югары белемне рус телендә алган, татар телен читтән торып өйрәнүчеләр өчен төзелгән. Күренекле методистның әйтүенә караганда, бу дәреслектә фонетика, морфология һәм синтаксис буенча мәгълүматлар гомуми кабул ителгән грамматик системада түгел, бәлки, лексик-текстлы итеп, материалның таләп итүе буенча, комплекс рәвешендә бирелә.

Шулай итеп, профессор М. Корбангалиев башлангыч, урта һәм югары мәктәпләрдә татар булмаганнарга да татар телен өйрәтүне башлап җибәрүче, аны укыту юлларын, метод һәм алымнарын эшләп биргән методист һәм педагоглардан санала.

М. Корбангалиев татар мәктәпләрендә рус телен дә укыткан. Үз тәҗрибәсенә таянып, ул татар башлангыч һәм урта мәктәпләре өчен рус теле дәреслекләре дә төзи, алар белән эшләү өчен методик киңәшләр бастыра.

1941 елда аңа "Учпедгиз" тарафыннан рус мәктәпләреннән башка мәктәпләрнең VIII-X сыйныфлары өчен рус теле дәреслеге төзү эше тапшырыла. Сәламәтлеге аеруча начарлануга да карамастан, ул дәреслекне төзүне үз өстенә ала һәм аны күрсәтелгән вакытка өлгертергә сүз бирә. Дәреслекне төзү эшенә Х. Шабанов һәм Р. Газизовны да җәлеп итүен әйтеп, "Учпедгиз" нәшриятына хат яза. Ләкин, кызганычка каршы, бу изге эшне үти алмый — 1941 елның 3 июнендә аның йөрәге тибүдән туктый.

Татар тел белеме өлкәсендә зур урын алып торган галим, талантлы педагог һәм методист М. Корбангалиев кешеләр белән һәрвакыт гади мөгамәләдә була. Ул һәркем тарафыннан хөрмәт ителә. Аның хезмәтләре, методик өйрәтмәләре хәзер дә зур әһәмияткә ия.

Татар халкының мәгарифе тарихында танылган педагог, байтак кына методик хезмәтләр авторы, күпсанлы милли укытучы кадрлар остазы Нургали Сибгатулла улы Надиев та күренекле урын тота.

Мәшһүр педагог 1882 елның 20 августында Саратов губернасындагы Сөләй авылында туган. (1940 елның июнендә вафат була). Башлангыч белемне әти-әнисеннән һәм күрше Карлыган авылы мәктәбендә ала. Шуннан соң Дома һәм Пәлдәнгә мәдрәсәләрендә укый. 1894 елда 12 яшьлек Нургалине атасы Казандагы "Касыймия" мәдрәсәсенә китереп бирә. Анда җиде ел укыганнан соң, үзенең белемен киңәйтү өчен, Нургали "Учительская школа"га укырга керә. Ул вакытта анда милләтебезнең Х. Ямашев, Г. Коләхмәтов, Г. Исхакый кебек алдынгы яшьләре дә укый. Н. Надиев алар белән якыннан аралаша. Әлеге мәктәпне 1904 елда тәмамлагач, Уфа губернасына укытучы булып китә. Шундагы татар мәктәпләрендә тугыз ел эшләгәннән соң, тәҗрибәле педагогны Оренбургка земство карамагындагы гимназия әзерләү мәктәбенә эшкә чакыралар (Анда гимназиягә, башлыча, татар балаларын әзерләгәннәр).

Октябрь революциясен Н. С. Надиев Оренбургта каршылый. Мәгариф эшен җайга салуда актив катнаша. 1918 елда яңа ачылган Татар халык мәгарифе институтына директор итеп билгеләнә.

Биредә җиде ел эшләгәннән соң, Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты чакыруы буенча Казанга килә һәм гомеренең ахырына кадәр шунда яши.

Казанда ул башта — татар педагогия техникумында уку-укыту эшләре бүлеге мөдире, аннары — Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты каршында Академик Үзәк рәисе урынбасары, ә 30 нчы елларда Казан педагогия институтының педагогика кафедрасында — доцент, ә ахырда Татар фәнни-тикшеренү институтында өлкән гыйльми хезмәткәр вазифаларын башкара.

Н. С. Надиев педагогика-методика һәм дидактикага караган байтак кына фәнни хезмәтләр калдыра. Шундыйлардан аның "Мәктәп тәртибе мәсьәләләре" (К., 1928), "Мәктәп эшен проектлар методы буенча оештыру" (К., 1930), "Мәдәният эшенең бердәм планы һәм

халык мәгарифе системасы" (К., 1931) кебек хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин. Болардан тыш, ул русча хезмәтләрне татарчага тәрҗемә итү өлкәсендә дә эшли. Мәсәлән, Г. Бусыгин һәм М. Озеровның "Икмәк уңышы өчен көрәштә укучыларның роле" дигән хезмәтен, шулай ук "Мәктәпкәчә учреждениеләрдә тәрбия эшен ничек оештырырга", "Башлангыч мәктәптә эшнең сыйфаты" кебек мәкаләләрне татар теленә тәрҗемә итеп чыгарган Н. С. Надиев үзенең уй-фикерләре белән газета-журналлар аша да бик теләп уртаклашкан. 1910 елдан башлап, "Шура", "Мәктәп", "Мөгаллим", соңрак "Мәгариф" һәм "Просвещение и жизнь" журналларында үзенең күпсанлы фәнни-педагогик мәкаләләре белән актив катнаша.

Академик Үзәктә эшләгәндә күренекле педагог дәреслекләр һәм кулланмалар төзүгә, аларның сыйфатына җитди әһәмият бирә, һәм авторлар алдына мөһим таләпләр куя. Шундыйлардан, мәсәлән, анынча, дәреслек төзүче мәктәпне һәм тормышны яхшы белергә тиеш, ә дәреслекнең үзе исә халыкның тормышын дөрес чагылдырырга, баланың милли, мәдәни, яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен искә алырга, аңа политехник белем һәм күнекмә бирүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Күренә ки, таләпләр хәзер дә искермәгән.

Гомумән, Н. С. Надиевның хезмәтләрендәге идеяләр бүген дә әһәмиятен югалтмаган, уку-укыту эшен тагын да камилләштерүгә уңышлы хезмәт итә ала.

* * *

ЭЧТӘЛЕК

Кереш 3
Беренче лекция. Педагогиканың барлыкка килүе һәм үсеше 5
Икенче лекция. Борынгы җәмгыятьтә тәрбия 19
Өченче лекция. Колбиләүчелек җәмгыятендә тәрбия 23
Дүртенче лекция. Феодаль җәмгыятьтә тәрбия, мәктәп
һәм педагогик фикер 35
Бишенче лекция. Монополистик капитализмга кадәрге
чорда мәктәп һәм педагогика. Ян Амос Коменскийның
педагогик теориясе 45
Алтынчы лекция. Джонн Локкның педагогик карашлары 59
Җиденче лекция. Жан-Жак Руссоның педагогик тәгълиматы 65
Сигезенче лекция. XVIII гасыр француз
материалистларының (Гельвеций, Дидро) педагогик
карашлары 74
Тугызынчы лекция. Француз буржаз революциясе
чорында педагогик фикер һәм мәктәп 80
Унынчы лекция. Иоганн Генрих Песталоцциның
педагогик идеяләре 87
Унберенче лекция. Көнбатыш Европада һәм АКШта
педагогик фикер 93
Уникенче лекция. Феодализм чорына кадәр һәм
феодализм чорында тәрбия, мәктәп һәм педагогик фикер 109
Унөченче лекция. XI – XIII гасырлардагы
педагогик әдәбият.. 112
Ундүртенче лекция. Феодализм таркалган һәм капитализм
мөнә-сәбәтләре башланган чордагы мәктәп һәм педагогика 125
Унбишенче лекция. XIX гасырның беренче яртысында
Россия мәктәбе һәм педагогикасы 142
Уналтынчы лекция. Татар халык педагогикасында тәрбия 150
Унҗиденче лекция. Мәгърифәтче Каюм Насыйриның
педагогик эшчәнлеге 164
Унсигезенче лекция. Декабристларның педагогикага һәм
Россия мәктәбенә йогынтысы 201
Унтугызынчы лекция. Демократлар В. Г. Белинский
һәм А. И. Герценның педагогик теорияләре 210

Егерменче лекция. А. Н. Радищев һәм Россиядә мәгариф үсеше.. 223
Егерме беренче лекция. XIX гасырның күренекле педагогик эшлеклеләре 231
Егерме икенче лекция. Бөек педагог К. Д. Ушинский 244
Егерме өченче лекция. К. Д. Ушинский һәм татар мәгърифәтчеләре 264
Егерме дүртенче лекция. Н. Г. Чернышевский – язучы һәм мәгърифәтче 274
Егерме бишенче лекция. А. С. Макаренконың тормышы һәм педагогик эшчәнлеге 281
Егерме алтынчы лекция. Капиталистик илләрдә мәгариф 292
Егерме җиденче лекция. Идел буе татар мәктәпләре тарихыннан... 307
Егерме сигезенче лекция. Алдынгы фикер ияләре 315
Егерме тугызынчы лекция. Лев Николаевич Толстойның педагогик эшчәнлеге 327
Утызынчы лекция. XIX гасырның 60 нчы елларында мәктәп реформасы 339
Утыз беренче лекция. Мәшһүр мәгърифәтчеләр 346
Утыз икенче лекция. Милләттәшләребез — данлы мәгариф эшлеклеләре 358

Учебное издание

Хузиахметов Анвар Нуриахметович
Насибуллов Рамис Рафагатович

ФИЛОСОФИЯ И ИСТОРИЯ ОБРАЗОВАНИЯ

Курс лекций для высших и средних специальных
учебных заведений

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Хуҗиәхмәтов Әнвәр Нуриәхмәтович
Насыйбуллов Рәмис Рәфәгатович

МӘГАРИФ ФӘЛСӘФӘСЕ ҺӘМ ТАРИХЫ

Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен лекцияләр курсы

Редакторлары **И.Җ. Вәлиев, Ф.А. Галиев**
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы **М.Ә. Әхмәтов**
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы **А.И. Галиуллина**
Корректоры **А.Ф. Нафикова**

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.03.2015
Форматы $60x90^{1/16}$. Офсет кәгазе. “Times” гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 23,18. Басма табагы 21,62.
Тиражы 1500 данә. Заказ № 194/3.

Әзер оригинал-макеттан
Казан университеты нәшриятында басылды.
420008 Казан, Проф. Нужин ур., 1/37
Тел. (843) 233-73-28

ISBN 978-5-00019-394-5